

Разиль Валеев

# ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В четырех томах

## Том 2

*Роман, повести*

Казань
Татарское книжное издательство
2006

# Разил Вәлиев

# ӘСӘРЛӘР

Дүрт томда

## 2 том

*Роман, повестьлар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
В97

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Т.Г.Миңнуллин,
Г.В.Родионов (Гәрәй Рәхим), И.М.Ибраһимов,
Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Вәлиев Р.И.**

В97 Әсәрләр: 4 томда / Разил Вәлиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5–298–03957–X

2 т.: Роман, повестьлар. — 2006. — 511 б. рәс. белән.

ISBN 5–298–03958–8

ISBN 5–298–03958–8(2т.)
ISBN 5–298–03957–X

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Вәлиев Р.И., 2006



# *МИРАС*

*(роман)*

*«Бабаң авыр хәлдә. Булдыра алсаң, тизрәк кайтып җитәргә тырыш».*

Телеграмма кәгазенә тезелгән бу сүзләр, үзләреннән-үзләре җанланып, аның колак төбендә яңгырап тордылар да, әкрен генә чәнечкеле йомарламга әверелеп, күңеленә тыгызланып кереп утырдылар. Әле генә ап-ачык булып алда балкып торган хыяллар бер мизгелдә төссезләнеп калды, айлар-еллар буе күңелдә йөргән ниятләр, баш миендә буталып, мәгънәсен югалтты. Бу минутта ул, бабасы өчен хәсрәтләнүе өстенә, бер көйгә җай гына агып барган көннәренең, күңелне алгысытып торган ләззәтле уйларының тәртибе буталуга борчыла, бәргәләнә иде.

Чыннан да, хәле бик катлаулы иде Ихтыярның. Бүген — җомга көн. Ә иртәгә иртәнге сәгать унда алар Зәлия белән язылышырга тиешләр. Ул әле урындык аркасына элеп куелган өр-яңа кара костюмына, карават кырыенда күзләрне чагылдырырлык итеп ялтыраган ботинкаларына, әле акка кара белән язылган хәвефле сүзләргә карап, шактый ара бүлмә уртасында басып торды. Аның күз алдыннан ап-ак күлмәк кигән, кара чәчләренә ак чәчәк кадаган Зәлия йөгереп узгандай булды.

«Нишләргә? — дип, күңеленнән үз-үзенә сорау бирде ул.— Нәрсә булды икән? Моңа кадәр бабайның бер дә ныклап авырганы юк иде бит... Иртәгә язылышасыбызны да беләләр... Үзләре дә бүген килергә тиешләр иде бит. Әллә соң берәр хәйләләре генә микән бу? Юктыр, әткәй алай хәйләләп-нитеп маташмас, өйләндерәсе килмәсә, турысын ярып әйтер иде. Үткән хатында да: «Үзегез бер-берегезне ошаткач, без каршы килә алмыйбыз»,— дип язган иде. Юк, чыннан да, эшләр уеннан узгандыр монда...»

Кинәт кенә Ихтыяр хәлсезләнеп калды, әле генә кош канаты сыман талпынган куллары салынып төште, хәтта кояш та аксыл көл төсенә керде кебек. Ул, тәрәзә төбенә таянып, соңгы кабат күргәндәй, озаклап шәһәр урамына карап торды. Аннары битараф кыяфәт белән әйберләрен җыйнап чемоданга тутырды. Моңа кадәр бүлмәне яңгыратып гөрләшкән-шаулашкан егетләр, ни әйтергә дә белмичә, сүзсез генә аның һәр хәрәкәтен күзәтәләр иде. Менә Ихтыяр, кинәт кенә катгый бер фикергә килгәндәй, чемоданын күтәреп, торып басты, бүлмәдәшләре белән, гаепле кешедәй, кыенсынып сүрән генә саубуллашты.

— Көтелмәгән бәла сыртны сындырырлык итеп суга, дип әйтә торган иде бабай. Дөрес икән,— диде Ихтыяр һәм авыр көрсенеп куйды.

— Артык борчылма әле... Кайт та, тиз генә хәлен белеп, әйләнеп кил.

— Бәлки, әллә ни булмагандыр әле?.. Сагынып кына чакыруларыдыр?

— Юк, егетләр,— дип, ишеккә таба атлады Ихтыяр,— минем әткәй юкка-барга сөрән сала торган кеше түгел.

— Анысы шулайдыр да бит...

— Нишлисең, сезнең белән бергәләп бәйрәм итәргә, кешечә туй ясарга язмагандыр инде безгә. Бабай үлем хәлендә ятканда, авыз күтәреп җырлап утыра алмыйм инде мин. Зинһар, онытa күрмәгез, ашханәгә төшеп әйтегез әле: иртәгә әзерләнмәсеннәр. Хәлне сөйләп күрсәтерсез. Ярый, дуслар, мин киттем.

— Барысын да көйләрбез. Кайту белән, хәбәр итәргә тырыш...

Бүлмәдәш егетләр аның борчуын ничек бүлешергә дә, ничек хәленә керергә дә белмичә, баскыч төбенә кадәр озата чыктылар.

Ихтыяр, кемнедер эзләгәндәй, тирә-юньгә күз йөртеп алды. Шушы минутта кинәт кенә каршысына Зәлия йөгереп килеп чыгар да аны кочагына алып иркәләр, юатыр, башларыннан сыйпап, бар борчуларын, икеләнүләрен таратыр сыман иде. Шулчак аның күңелен көйдереп, бер уй йөгереп узды: «Чыннан да, бабайның хәле авыр булганга түгел, ә үземнең хыяллар челпәрәмә килгәнгә ныграк борчылам түгелме соң? Әйе, әйе, Зәлия, аның әти-әнисе, таныш-белешләр алдында үземне гаепле саныйм...»

...Урам, гадәти авазларын, шау-шуын югалтып, сүлпәнләнгән, трамвай-троллейбуслар да бүген дөбер-шатыр килеп чапмый, аптыраганнан гына сөйрәлә, кешеләр дә, көндәгечә, бар дөньясын онытып көлми, ә ирекле-ирексез генә елмая, Ихтыярның хәленә кергәндәй, тавышсыз гына көлә иде.

Ул, тәгаен бер карарга килә алмыйча, шактый гына тротуар читендә таптанып торды. Биш ел буе һәр иртәне мең авазлы гөрелтесе белән уятып, үз урамнарына чакырып чыгарган, көннәр буе аны сагалап-искәртеп торган, кояшта агач күләгәләре астына яшергән, яңгырлардан ышыклаган, суыкларда җылыткан, дуслар табышкан, сө-

енечләр бүләк иткән шәһәр әллә инде хәзер дә Ихтыярның борчуы белән борчыла, әллә инде иртәгә булачак олы бәйрәмне ташлап китүенә бөтен йортлары, бакчалары, урамнары белән берьюлы үпкәли иде.

Менә ул бер троллейбусны уздырып җибәрде, икенчесенә дә утырмады. Троллейбус ишекләре шыгырдап ябылган саен, Ихтыяр әле тирә-ягына гаҗәпләнеп күз ташлый, әле туган авылын күрергә, андагы хәлләрне белергә теләгәндәй, озаклап офык читенә карап тора. Вакыт узган саен, аның уйлары ныграк чуала, моңа кадәр һәр каникулда кайтырга атлыгып торган, һәр җәйдә аны чәчәкле болыннары, җиләкле аланнары белән каршы алган авылы күзгә күренеп ерагая, читләшә бара иде. Ихтыяр, моңа кадәр һәр йорты, инеш буендагы һәрбер талы, ерактан ук сәлам биреп килүче бертугандай якын кешеләре аермачык булып күз алдында шәүләләнгән авылының шундый тизлек белән хәтер томаны артына кереп югала баруына шаккатып, шактый ара аңышмыйча торды. Ул, хәтерен тәртипкә китерергә теләп, башын селкеп карады, учлары белән чигәләрен уды, ләкин авылны бөтенләй диярлек каплап киткән томан аның саен куера гына барды. Менә ул, хыялын җигәргә тырышып, күзләрен йомды, әмма аңа карап хыялы яктырмады, анда һаман дөм караңгы, шәһәр белән авыл арасында бөтереләбөтерелә кара томан елгасы ага, шул томан дулкыннары уртасыннан бары тик яшел түбәле бердәнбер йорт чагылып китә дә өй эчендәге түр бүлмәдә ятучы бабасының баштанаяк акка төренгән гәүдәсе шәйләнә иде.

Ниһаять, Ихтыяр күңеленең бераз тынычлана башлаганын сизде, бабасы белән исәнләшергә җыенгандай, алга таба талпынып куйды, иреннәренә сизелер-сизелмәс елмаю җәелде.

Тар урамны шыгырдавык авазлары белән тутырып, бөтен гәүдәсе белән калтырап янәшәсенә генә туктаган троллейбус Ихтыярга кинәт кенә бик вакытлы килеп җиткән «ашыгыч ярдәм» машинасы кебек күренде. Ул, әллә кайда, бик ерактагы атау читендә, талдан талга тартылган тимерчыбыкларны, шаулап аккан инеш өстеннән шул тимерчыбыкларга асылынып очып чыгучы үз гәүдәсен — малай чагын күз алдына китереп, көлемсерәп үк куйды. Хәзер, Ихтыяр кереп утыруга ук, троллейбус та акрын гына җирдән аерылыр да бакыр чыбыкларына асылынган килеш чыжлый-чыжлый очып китәр, берничә секунд

эчендә ярларны тутырып аккан бозлы сулы инешнең теге ягына — бабасының өй кырыена ук китереп төшерер кебек иде...

Һәр яз саен ташу ташыган чорда бабасы Зыятдин карт ике-өч атнага бөтен авылдашларыннан, бар дөньядан аерылып кала. Дөрес, ул болай да кешеләр белән артык алыш-биреш итми, аралашмый, аңа йомышы төшеп, йә тәрәзә рамнары, йә балта сабы, йә көянтә-мазар ясатырга килүчеләр булса да, үзе беркемгә йөрми, айга бер-ике кибет тирәсен урап кайта да, минем сезгә катнашым юк дигәндәй, тагын атавына кереп бикләнә. Аның төсе китә барган күзләренә, бер максатсыз-нисез, аптыраганнан, кирәк булганнан гына йөргәнгә охшаган кыяфәтенә карагач, ирексездән читен булып китә, үзеңне ни өчендер гаепле итеп тоя башлыйсың, әйтерсең йөзләгән кешеләр күңеленнән аерылып чыгып, аның күңелендә җыелып укмашкан ялгызлык белән очрашкандай буласың. Ә инде язгы ташуда бүленеп калган көннәрдә әлеге хис тагын да көчәя. Бу чорда Зыятдин карт аерата нык моңсулана, актарылып аккан бозлы суларга, авылга бер җиңен сузып торган зәңгәрсу урманнарга, урам буйлап чыр-чу килеп чабучы бала-чагаларга карап, сәгатьләр буе яр читендә хәрәкәтсез оеп утыра.

Аның яшелгә буялган калай түбәле, алты почмаклы шактый таза йорты бер ялгызы гына тулысы белән атауны биләп тора. Атауның ике ягыннан ике инеш урап килә дә, иске тегермән янында кушылып, бер булып ишәеп агып китә. Җире гектарга якын булса да, атауда бүтән берәү дә нигез корырга җөрьәт итми: әллә инде заманында дөнья җимертеп яшәп тә, картаймыш көнендә үзенүзе ялгызлыкка хөкем иткән Зыятдин бабайның рәнҗүеннән шикләнәләр, әллә инде һәр яз саен ике-өч атна буена дөньядан аерылып торуны өнәмиләр, әллә инде, яхшымы-яманмы, берәүнең дә гомер иткән ата-бабасы нигезеннән аерыласы килмиме — йөз яшьлек өянкеләр белән төрелгән атау, су уртасындагы галәмәт зур яшел кораб сыман, һаман бер көйгә тавышсыз-тынсыз гына вакыт диңгезе буйлап ага да ага иде.

Атау авылдан аерылып, үзе бер дәүләт сыман читтәрәк торса да, авыл кешеләре аны чит санамыйлар, узганбарганда инеш аша Зыятдин картка сәлам биреп узалар, хәлен сорашалар. Ул, башын күтәрмичә генә бераз тын торгач, билне язып, сәлам бирүчегә карый, аннары апты-

раган кыяфәт белән, минем нигә кирәгем чыкты дигәндәй, «яшибез әле... яшибез...» дип куя.

Зыятдин карт авылдашлары белән пычакка пычак килеп яшәмәсә дә, шулай ук кочакка кочак килергә дә атлыгып тормады. Ул берчакта да мәҗлесләргә яратып йөрмәде, сабан туйларында да, уртага кермичә, бер читтән генә карап торды, кеше биегәндә биемәде, кешегә кушылып җыр җырламады, кеше белән бар күңелен ачып, озак итеп утырып сөйләшмәде, гайбәт таратмады, арттан сүз йөртмәде. Зыятдин картның бөтен рәхәте дә, бөтен михнәте дә бары тик эш белән, үз атавында казыну, шунда эвәрә килү белән бәйләнгән иде. Ул эшсез үткән көнен әрәм узганга саный, инеш суы туктаусыз аккан кебек, кеше дә һәрчак хәрәкәттә булырга, аның сыман бертуктаусыз тегермән ташы әйләндерергә тиеш дип исәпли. Элегрәк чакта аны күрше авылга туганнарының хәлен белергә барганда да, юл уңайлый урманнан утын төяп бара, ә кайтканда болыннан бастырыклап печән алып кайта торган булган, дип сөйлиләр.

Еллар узып, йөрәгендә дәрман, тәнендә көчнең сыза барганын сизгән саен, кешеләр белән якынлашу, алардан ярдәм көтү урынына, ул, киресенчә, тагын да ныграк үҗәтләнде, атау читендә бөтенләй диярлек күренмәс булды, күренгәндә дә, маймыч сөзүче малайлардан гайре беркем белән рәтләп-юньләп сөйләшмәде. Җәй айларында атау бөтенләе белән өянкеләр арасына чума, атау белән бергә Зыятдин карт та тавышсыз-тынсыз юкка чыга, үз кабырчыгына кереп оялаган әкәм-төкәм кебек, көннән-көн кешеләрдән ерагая, йомыла бара иде. Хәзер аны авыл, колхоз, район хәлләре дә артык кызыксындырмый, бербер яңалык ишетсә дә, артык исе китмичә генә: «Шулайдыр шул... Дөнья булгач, бары да булыр...» — дип кенә куя. Әйтерсең ул, эшлисе эшләрен эшләп, сөйләшәсе сүзләрен сөйләшеп, уйлыйсы уйларын уйлап, хыялланасы хыялларын хыялланып бетергән дә, дөнья белән алышбирешен өзеп, соңгы хәбәр килгәнне генә көтеп ята иде.

Зыятдин картны ялгызлыктан араларга теләпме, бабасы янында күз-колак булсын дипме, әллә кулы эшкә өйрәнә торсынгамы — мәктәптән кайтуга, әнисе Ихтыярны атауга җибәрергә җай табып кына тора иде. Йә аларның тәбе калагы ярыла, йә йозаклары ватыла, йә җилпучны ашлатасы була. Бабасы беркайчан да аның йомышыннан баш тартмый, киресенчә, сөенә генә кебек.

Ихтыяр аның тирәсендә әвәрә килеп йөри, агач ышкылый, пычкының бер башыннан тартыша. Эш белән мавыгып, Зыятдин карт та беркавымга бар мәшәкатьләреннән арына, йөзе яктырып китә, гәүдәсе турая төшә, авыз эченнән бертуктаусыз нидер сөйли, вакыт-вакыт җырга охшатып көйләпме-ыңгырашыпмы ала. Ясыйсы әйберен ясап бетергәч, тирә-юньне әйбәтләп җыештыра да канәгать бер төс белән үзенең эшенә сокланып тора.

— Булдырасың, улым! — дип, Ихтыярга елмаеп күз кыса ул.— Кулың эшкә ятып тора.

Ихтыяр, чыннан да, бу нәрсәне үзе эшләгәндәй сөенә.

Беркөнне шулай икәүләшеп агач ышкылап маташканда, Зыятдин карт кисәк кенә сорап куйды:

— Үскәч, кем булырсың икән, улым?

Ихтыяр ык-мык итте, ни дип җавап бирергә белмичә, аптырап күккә карады. Зәңгәр күкне кыл урталай ярып, тонык кына гүли-гүли, самолет очып бара иде.

— Очучы булам! — дип кыяр-кыймас кына сузды Ихтыяр.

— Безнең авылдан очучы чыкканы юк. Безнең башка төкереп кенә китәсең инде аннары.

— Космонавт булам!

— Ай-һай! Булгач булсын, дисең инде, алайса. Ярый, карап карарбыз. Тик безнең тирәдән җыймыйлар бугай ул касманатларны.

— Безнең класста барысы да космонавт булам, ди. Чәберчек Әхмәттән башкалары.

— Әхмәткә нәрсә булган? Тал башына бөтенегездән дә җитезрәк үрмәли иде. Күккә дә алданрак менеп җитәр әле.

— Ю-ук... Аны әтисе җибәрми. Син күккә менсәң, мүкләк сыерны кем көтүдән алып кайтыр, ди. Сыерлары бик холыксыз аларның. Партизан исемле...

— Партизан, дисеңме?

— Әйе. Урманга качарга гына тора. Шуңа Партизан дип атаганнар аны. Сөте күп булмаса, әллә кайчан иткә тапшырыр идек, ди әниләре. Менә шул мүкләк сыер аркасында Әхмәт космонавт була алмыйча кала инде...— дип көрсенде Ихтыяр.

Зыятдин карт, инде ничә еллар җыелып килгән төкселеген онытып, тирә-юньне тутырып рәхәтләнеп көлде. Тынычланган, яшьләнгән күзләрен сөртеп, Ихтыярның маңгаеннан сыйпады.

— Берегезнең дә җир сөрәсе, йорт саласы килми инде, алай булгач. Барыгыз да күккә очып беткәч, без монда нишләрбез икән соң? Бик күңелсез булыр бит. Игеннәрне кем игәр икән? Тамак ачар бит. Күктән әйләнеп кайткач, ашыйсыгыз килер. Әллә сез аннан бөтенләй кайтмаска уйлыйсызмы?! Бер Әхмәт кенә барыгызның тамагын туйдыра алмас.

Ләкин Ихтыярның әле боларга тамчы да исе китми, ул, аерыла алмыйча, зәңгәр күк диңгезендә аксыл дулкыннар калдырып барган самолетны күзәтә иде.

— Бик очасың килгәч, әллә яраплан ясап карыйбызмы соң? — дип әйтеп куйды бабасы.

Ихтыяр капыл гына аңа борылып карады. Чынлап әйтәсеңме дигәндәй, беркавым аптырап текәлеп торды.

— Сызымнарын тап син ярапланның. Бергәләп тотынсак, нәрсә дә булса майтарырбыз.

Мәктәптән кайтуга, ашап-эчеп тә тормыйча, Ихтыяр бабасы янына йөгерә. Атауны авыл белән тоташтырган агач күпер инде күптән җимерелгән, бүрәнәләре язгы ташу суында агып киткән, Ихтыяр чалбар балакларын тез тиңентен сызгана да, төбенә чуерташ түшәлгән салкын сулы инешне ерып чыгып, йөгерә-йөгерә атауга менә һәм капка янына килә. Башын артка ташлап беркавым күккә карап торгач, капка баганасындагы кадакка бәйләнгән бауның элмәгеннән тартып җибәрә: шуны гына көтеп торгандай, өй кыегына кунаклаган фанер аэроплан томырылып аска атыла да дугайланып кинәт кенә өскә күтәрелә башлый, аннары, канатлары җил ирегенә җайлашкач, бинихая зур тилгән сыман, тау итәге буйлап инеш өстеннән талгын гына очып китә. Иптәш малайлары көтүләре белән җыелышып аста торалар. Әгәр дә аэроплан элеккесеннән еррак очса, дөнья рекорды куйгандай, шау-гөр килеп сикерешәләр, төшкән урынына билге куялар. Әгәр кем дә булса аэропланны төшкән җайга тотып ала алса, ул инде шул көннең героена әверелә, аэроплан аныкы була. Көне буе үзенең умарталары белән əвәрә килеп, җиләк-җимеш, кыяр-помидор бакчасында казынып, лапас астында агач юнып, ватылганны төзәтеп, төзәлгәнне шомартып онытылган Зыятдин бабай шулчак атау читенә килеп баса да, кулын чаларган кашлары өстенә куеп, апак мыеклары астыннан рәхәт елмаеп карап тора.

Бала чакта дөньяның кызыклары исәпсез-хисапсыз, кайсына карарга белмәссең! Аэроплан очыртып уйнау-

лар Ихтыярны да, малайларны да туйдырган булыр иде. Зыятдин бабай шул турыда уйлаптырмы, әллә ялгызлыктан котылырга теләптерме, атна саен диярлек аэропланнарны яңартып, башка төрлеләрен ясап тора. Ихтыяр мәктәп китапханәсендәге кирәкле журнал-китапларны алып кайтуга, икәүләшеп яңа модель җыярга тотыналар. Ниндиләре генә юк аларда: үрдәккә охшаган тупыйк борынлысы, чыпчык сыман кыска канатлылары дисеңме, акчарлак сыман сылулары, аккош кебек озын муенлылары дисеңме!.. Чын булса, беркөнне мәктәп директоры, атауга кереп, Зыятдин картны авиамодельчеләр түгәрәге оештырырга кодалаган, имеш. Атау карты көлгән генә.

— Мин ясамыйм аларны, Ихтыяр ясый, мин агач ышкылап кына бирәм,— дигән ул.

Шул көннән соң малайлар Ихтыярга көнләшеп карый торган булдылар, ул үзе дә моның шулай икәненә ышанган иде.

Аэроплан җене кагылгач, авыл кешеләренә бер кыен артты. Элек иләк тузса да, көянтә сынса да, Зыятдин карт янына йөгерәләр иде, хәзер ул боларның бөтенесен дә онытты. Элек, кулы тәмле, дип, эре малны бары тик аңардан гына суйдырырга тырышалар иде, хәзер исә ул эшләргә дә йөрмәс булды. Авылда картлар елдан-ел кимеп, адәм баласын соңгы юлга җиренә җиткереп, бөтен шартын китереп озата белүчеләр дә бетеп бара иде. Шуңа күрә үлем-китем була калса, тагын Зыятдин картка киләләр.

Әнә, шул рәвешчә, соңгы араларда авыл халкы атау ягына гадәттәгедән ешрак карый башлаган иде. Моңа кадәр үзе генә атауда гомер сөреп яткан, дөнья мәшәкатьләренә катнашмаган Зыятдин картның ниндидер күренмәс җепләр белән авылга бәйләнгәнен, тамырлары белән авылга тоташканын аңлаучылар аз булмаган, күрәсең.

Ә Зыятдин карт, әллә инде сабый акылы керә башлап, әллә, чыннан да, бала чагына кайтырга теләп, көннәр буе Ихтыяр белән лапас астында кайнаша. Очкычларны ул шулкадәр яратып ясый, хәтта күбәләк төсләренә кертеп бизи, аннары кояшка куеп киптерә. Аэропланнарны нигәдер үзе очыртмый ул, Ихтыяр мәктәптән кайтканны көтә. Инеш өстенә яшел түбә кыегыннан бөркеттәй атылган аэропланны күреп чыр-чу килгән, инеш буен яңгыравыклы авазлары белән тутырган бала-чаганы карап тору аңа ләззәт бирә сыман. Бу мәлдә аның бар хисләрдән бу-

шап калган ялгызак күңеле шул балалар шатлыгы белән тула, бу мәлдә ул аларның хыялы белән хыяллана, аларның шатлыгы белән шатлана иде.

Төптән юан чыккан Ихтыярны җир үзенә нығрак тарткангамы, ул күпме генә тырышмасын, бер тапкыр да очкан җайга аэропланны тота алмады. Йөгерүен дә бүтәннәрдән ким йөгерми сыман, елгырлыкка да башкалардан калышмый кебек, ләкин туп-туры өстенә очып килгән аэропланны күргәч, кинәт куркып кала, һәм табыш башкаларга эләгә иде. Аннары, ачудан ireннәрен тешләп, еламсыраган кыяфәт белән бабасы янына килә.

— Тагын тотып булмадымы? — дип көлемсери бабасы.— Карап-карап торам да... касманат чыкмас синнән, улым. Әллә җирдә генә каласыңмы соң? Бөтен кешегә дә очу димәгән бит, самолетлар ясарсың. Мондыйларны гына түгел, зурларын, чыннарын...

— Барыбер тотам мин аны! — дип, аскы иренен авырттырып тешли Ихтыяр.— Күккә карагач, баш әйләнмәсә, күптән тота идем инде мин аны.

— Бу юлы кемгә эләкте соң яраплан?

— Шул... Әхмәткә инде...

— Кайсы Әхмәт?

— Кайсы булсын... Чәберчек Әхмәт...

Зыятдин бабай йөзенә аптыраган кыяфәт чыгара, кемгәдер бармак янап куя. Бу минутта ул Ихтыярның әле эзгә төшмәгән уйларын тәртипкә китерергә, хыялына юнәлеш бирергә тырыша.

— Нигә Чәберчек дисез аңа? Каян чыккан ямьсез кушамат ул?

— Чәберчек булгач... Үзенә әйтеп кара, авызың белән маймыч тоттырыр...

— Анысы нәрсә була инде?

— Муен тамырыңнан кысып тота да башың белән суга тыга. Тының бетә башлагач, авызыңа балык керә, дип кычкыра. Кичә миңа Атау атаманы дигән иде, шуның өчен үзенә дә балык тоттырдым әле.

— Һе-ем,— дип тамак кырды Зыятдин карт. Аның йөзенә канәгать елмаю чыкты.— Атау атаманы, дисеңме? Чәберчек түгел инде бу!

— Беркөнне ул, уенчык трактор алам, дип, чебигә утырган тавыкларының бөтен йомыркасын йомырка җыючыга илткән,— дип сөйләп китте Ихтыяр.— Йомырка җыючы утка куеп карый да: «Чәберчек, Әхмәт»,— ди икән.

Тагын берне ала да тагын: «Чәберчек, Әхмәт»,— ди икән. Малайлар шуны ишеткәннәр.

— И-их, сез, сыбызгылар... Чәберчек Әхмәт инде ничә яраплан тотты, ә сез койрыгын гына карап калдыгыз. Борыныгызга чиртер әле сезнең шул Чәберчек. Кулына эләккәнне ычкындырмый, димәк, ул юк-бар хыял белән баш катырмый. Сез күктәге йолдызларга өмсенеп йөрерсез, ул иелеп җирдәгеләрен чүпләр. Кем белә, бәлки, берсен күкрәгенә дә кадап куяр. Нәселләре шундый аларның, бабалары да Герман сугышыннан тимер тәре тагып кайткан иде.

— Такмагае...

— Атау атаманы дигән кушаматны да ул чыгардымы?

— Шул булмый, кем булсын. Әле синең турында да...

Ихтыяр, сүзен йотып, туктап калды. Аның күзләрендә усал очкыннар кабынган иде.

— Минем турында нәрсә ди? — Зыятдин карт уң кулы белән Ихтыярның иңбашына кагып алды.— Ник дәшмисең? Начар сүз мәллә?

— ...

— Начар сүз ишетерлек нәрсә кылдым икән мин аларга?

— Үзенең бабасы булмаганга көнләшә ул,— дип юаткандай тезеп китте Ихтыяр.— Атауда бабаңның күмгән алтыны бар, сез икәүләп шуны саклап ятасыз, ди.

— Әйтәм җирле үткән көз кемдер карт алмагач төбен актарып бетергән иде. Тегермән янында да чокынып маташканнар. Шул башкисәрләр икән, алайса. Мин әлләниләргә юрап йөрим тагын... Алтын эзлиләр, алтын,— дип каударланып сөйләнде Зыятдин карт.— Тапканнар алтын эзләр җир. Җир астында түгел, менә монда ул алтын! — дип, кулларын алга суздды.

Ихтыяр, чыннан да алтын күрергә теләгәндәй, үрелеп аның җыерчыкланып беткән уч төпләренә, агач тамырына охшаган бармакларына карады. Аннан бабасы сүзләренең мәгънәсенә төшенеп елмайды.

— Шушы куллар туйдырды, шушы куллар мылтык та тотты, иген дә чәчте,— дип, уч төпләренә карап торды карт.— Алтын эзлиләр, дисең инде... Һәркемнең үз алтыны үзе белән. Читтән эзләмиләр аны...

Ихтыяр бөтен гәүдәсе белән бабасына елышты. Аның тән җылысын тою, кытыршы кулларының чәчләреннән, битеннән сыйпавы бик тә рәхәт иде.

— Мин бүтән аларның берсен дә атауга кертмим!
— Керсеннәр, йөрсеннәр,— диде Зыятдин карт.— Тик... яхшы ният белән генә йөрсеннәр. Монда урын барыбызга да җитә.
Бабасы шулай диде дә, саубуллашып, өйгә кереп китте.

* * *

Ихтыяр, эшафотка барган тоткын кебек, аякларын теләмичә генә өстери-өстери, дүртенче катка менеп, кыңгырау төймәсенә басты. Эчтә тавыш ишетелмәде. Тагын басты. Тынлык. Бөтен подъездны яңгыратып аның йөрәге типкәне һәм авыр итеп сулаганы гына ишетелә. Менә ул кыңгырауга басарга дип күтәрелгән кулы белән ишек яңагына таянды, маңгаен ишеккә куеп, беркавым хәрәкәтсез торды. Аннары, Зәлиянең өйдә булмавына сөенгән кебек, кесәсеннән ашыга-кабалана телеграмма кәгазен чыгарды, каләм алып, зур хәрефләр белән «Мин киттем. Кайтмыйча калырга ярамый. Гафу!.. Язылышу көнен күчерергә тырыш. Ихтыяр» дип, кәгазьнең буш ягына язды да ишек ярыгына кыстырды.
...Мәктәп тәмамлаганчы һәр яз саен атау бала-чага шау-шуы белән тула торган иде. Зыятдин карт ясаган аэропланнар күңелләренә канат куйгандырмы, әллә туган җиргә җибәргән тамырлары артык зәгыйфь булгандырмы — унны бетерүгә, аларның күбесе шау-шулы инеш буйларын онытты, ә озакламыйча, әрәмәле болыннарны, чишмәле яр буйларын, якты аланлы урманнарны ташлап, төрлесе төрле якка таралышып бетте.
Чәберчек Әхмәт кенә, көтүдән аерылган каз бәбкәсе сыман, ныгып аякка басканчы, канатлары ныгыганчы ук, башкалардан аерымрак йөри башлады. Җиденчедә укыганда ул инеш буена бөтенләй үк төшмәс булды. Әллә инде Ихтыяр белән борчаклары пешмәде, әллә аэроплан очыртуның кызыгын тапмады, әллә әтисе вафат булганнан соң ир затыннан үзенең өйдә бердәнбер терәк икәнен аңлап, вакыты булган саен, мал-туар арасында кайнаша башлады, җәйге каникул җитүгә, башта тракторда, аннан комбайнда ярдәмче булып йөрде. Атау буенда Әхмәт тоткан аэропланнар, читлектәге кошлар сыман, өй түбәсендә моңаешып тик тордылар. Иртә таңнан алсу офыклы кичкә кадәр басуда кайнашкач, аның күңеле бөтен күзәнәкләре белән җиргә беректе, ахрысы, ул яшь-

тәшләре арасыннан берүзе авылда торып калды, район үзәгендә механизаторлыкка укып, бер елдан чын-чынлап тракторга утырды. Ә Ихтыярның, бабасы янында йөреп, кулы остарды. Әтисе кат-кат авыл хуҗалыгы институтына керергә кыстаса да, үз киресен итте. Бабасы белән бергә ясаган авиамодельләрне төяп, авиация институтына барды һәм, беренче имтиханнан ук икеле алып, кире авылга кайтты. Гарьлегеннән айга якын бабасы атавыннан чыкмыйча ятты. Кышын вакыт узсын өчен генә клуб мөдире булып эшләп йөрде. Язын аны армиягә алдылар. Хезмәтен тутыргач, солдат киемнәрен дә салмыйча, төзелеш институтына барып гариза бирде.

Җаны тартканга, күңеле атлыгып торганга түгел, ә бары тик яшьтәшләре, авылдашлары арасында үзенең төшеп калган кеше түгел икәнен расларга дип кенә кергән иде ул төзелеш институтына. Беренче елын укыганда, шәһәргә, институтка, курсташларына ияләшә алмыйча шактый иза чикте. Аннары студент тормышына кереп чумганын сизмичә дә калды, моңа кадәр кая куярга белмәгән вакыты лекцияләр, кинолар, театрлар, дус-ишләр, китаплар белән шыплап тулды. Ә көннәрдән беркөнне Зәлия пәйда булды.

Өч ел буена моңа кадәр дә Зәлия институт коридорында аңа очрамый калмагандыр, билгеле. Ләкин Ихтыяр аны күреп тә игътибар итмәгән, Зәлия әйтмешли, өч ел буена «бәхетен читләтеп йөргән».

Өченче курсын тәмамлагач, аларның группасын, төзелеш отряды ясап, республика читендәге бер районга сыер абзары салырга җибәрделәр. Ихтыярны отряд командиры итеп билгеләделәр. Машиналарга төялешеп килеп төштеләр, өчәр-дүртәр кешегә бүленеп фатирга урнаштылар. Барысы да әйбәт кебек: торыр урын бар, ләкин ашау ягын рәтли алмыйча гына шактый тилмерделәр. Пешекче кызның аш-су ягыннан артык осталыгы юк идеме, әллә колхоз биргән ит-мазарның рәте булмадымы — өстәл янына утыргач, егетләрнең һәрчак йөзе җыерыла иде. Ихтыяр, аптырагач, беркөнне ит алырга складка үзе барды.

— Сезнең өчен дип көн саен мал суеп булмый. Кая куясың аны? Көнен ашап бетермәсәң, бозыла, суыткыч юк...— дип, склад мөдире сукрана-сукрана кисмәктән тозлаган ит ала башлады.

— Нигә суыткыч алмыйсыз соң?

— Анысын председательдән сора инде, энекәш. Минем эш — үлчәп алу, үлчәп озату.

Ихтыяр председательне эзләп тапты.

— Нәрсә кыяфәтең бик кырку күренә? — дип сүз катты аңа колхоз башлыгы.

— Кырку аш ашаганга.

— Анысы өчен чибәр кызыгызга үпкәләгез инде.

— Ул тозлы итне күпме ашарга була? — дип ярсый башлады Ихтыяр.— Тәүлегенә уникешәр сәгать кирпеч өябез, объектны бетерик дип, көнне төнгә ялгап эшлибез. Ә сез инде айга якын безгә тозлы ит кубеге эчертәсез.

— Әтәчләнмә әле, егет. Сезнең кебек егетләр ярым ач, ярым ялангач килеш Днепрогэслар төзегәннәр, тайгада тимер юллар салганнар. Тозлы ит булсын иде аларга! Симереп сикерәсез...

— Заманында сезнең кебек председательләр ачлы-туклы килеш колхоз төзегән, үгез белән сабан сөргән. Ә сезнең клуб хәтле йортыгыз, машинагыз, электр белән яга торган мунчагыз. Суыткыч турында әйткән дә юк инде.

— ОБХССтан килмәгәнсеңдер бит син? — дип сүзне уенга бормакчы булды председатель. Ихтыярның кыяфәте үзгәрмәгәч, тавышына кырыслык өстәлде.— Минем хуҗалыкка тыкшынып йөргәнче, отрядыңда тәртип урнаштырыр идең. Кичә тагын кызлар өчен авыл егетләре белән сугышканнар. Тозлы ит ашасалар да, җегәр бар үзләрендә.

— Беренчедән, отрядта бу турыда сүз булды инде. Икенчедән, авыл егетләре үзләре бәйләнгәннәр. Кызлары карамый башлаган... Сүзне читкә бормагыз, суыткыч алып бирәсезме безгә?

— Юк.

— Аванс хисабыннан ике йөз илле сум акча яздырыгыз. Үзебез алырбыз.

— Кассада акча юк.

Ихтыяр, кирәкмәс сүз ычкындырудан куркып, тешләрен кысып торды да борылып китеп барды. Ул үзенең булдыксызлыгыннан гарьләнә, пешекче кыз янына буш кул белән кайтырга ояла, шулай ук складтагы тозлы итне алырга да хурлана иде.

— Командир! — дип кычкырган тавышны ишеткәч, ул адымнарын акрынайтты, теләмичә генә артка борылып карады.

Председатель аңа кул болгый иде. Ихтыяр урыныннан кузгалмады.

— Минем өйдәге холодильник барыбер буш тора. Кереп алыгыз шуны,— дип кычкырды председатель.— Җәй көне азык-төлекне базда тотабыз.

— Рәхмәт, кирәк түгел,— дип үпкә катыш ачу белән әйтте Ихтыяр һәм, каршысына килеп туктаган председательнең балкып торган йөзен күргәч, өстәп куйды: — Егетләр бунт күтәрә, иртәгәдән эшкә чыкмыйбыз, диләр. Сыер абзары безгә генә түгел, сезгә дә кирәктер бит... Тозлы ит ашыйлар да көне буе су эчәләр.

Председатель, рәхәтләнеп, бөтен басуны тутырып көлеп җибәрде.

— Башта ук шулай диләр аны. Ә син суыткыч та суыткыч... Бар, бүген үк бер сарыкны суеп суыткычка тутырыгыз. Тик... менә суяр кешесен генә таба алырсыз микән. Уттай эш өсте бит.

— Үзем суям мин аны. Бабай суйганда ярдәм итеп торган бар иде.

— Белмәгәнең юк, тиккә бригадир итеп куймаганнар икән үзеңне,— дип, шапылдатып Ихтыярның җилкәсенә сугып куйды председатель.— Менә шундый егетләр кирәк иде миңа. Авызга карап тора торган түгел, авыздан тартып ала торган.

Пешекче кыз Ихтыярны көтә-көтә аптырап беткән, егетләрне төшке ашсыз калдырудан куркып, елар хәлгә җиткән иде.

— Бер сәгатьтә өлгертәбез аны,— дип юатты кызны Ихтыяр.— Син итне юып, вак итеп турап сал, алай итсәң, тиз пешә.

Шулай диде дә тау читенә барып кузгалак өзә башлады. Кузгалакны, ваклап турап, тәлинкәләргә салып чыкты. Һәркемнең алдына кыяклы суган тезеп куйды.

Егетләр, пешекче кызны мактый-мактый, күз ачып йомганчы тәлинкәләрен ялтыратып та өлгерделәр.

— Нинди бәйрәм бүген, Зәлия?

— Әллә гашыйк булдыңмы?

— Гашыйк кешенең ашы кырку була ул...

Егетләрнең кәефе күтәрелгән, һәммәсенең шаярасы, араларында бердәнбер хатын-кыз заты булган Зәлиягә сүз катасы килә иде. Ә ул бер читкә баскан да аларның барысына да яратып карап тора.

— Миңа түгел, командирга әйтегез рәхмәтне,— дип, Ихтыярга таба кулын суздык ул.

Ләкин аның сүзенә игътибар итүче булмады, рәхмәт

әйтә-әйтә таралыштылар да, Ихтыяр белән Зәлия икәве генә калды.

Беркавым, нидән сүз башларга белмичә, тын тордылар.

— Ә син нигә ашамадың? — дип, Ихтыярның тулы тәлинкәсенә күрсәтте Зәлия.

— Егетләргә аш бүлеп тордым бит.

— Ә-әй, мин сизмәгәнмен дә. Кешегә шулай тиз ияләшәм инде мин.

— Ә мин, киресенчә, ияләшә алмый тилмерәм.

— Кешегә ияләшү өчен, аны бер бик якын кешеңә охшатырга да шул дип уйларга гына кирәк.

— Мин кемгә охшаган соң?

— Әтигә. Ул да һәрчак әнигә аш пешерергә булыша. Кунаклар килсә, өстәл янына утырмый, аяк өсте торып сыйлый. Син дә бүген шулай иттең бит.

Зәлия Ихтыярга кайнар аш салды. Үзе аның янәшәсенә килеп утырды.

— Әйдә, әтисе, кунаклар киткәч, икебез генә рәхәтләнеп утырыйк әле бер. Күптәннән болай утырган юк.

Ихтыяр Зәлиягә тартынып та, гаҗәпләнеп тә карап торды-торды да, аштан буылып, бөтен гәүдәсе белән чайкала-чайкала йөткерергә тотынды.

Зәлия көлеп җибәрде. Ихтыяр да түзмәде, аңа кушылып тыела алмыйча көлә башлады.

Чикерткә сайрауларына, тургай авазларына кушылган көлү тавышы кичкә кадәр тынмады.

* * *

Имтихан вакытлары җитсә, Ихтыяр үзенә урын таба алмыйча тилмерә иде. Бүлмәдә китап укып булмый — һәрчак кеше, ә китапханәдә аны нигәдер йокы баса, күрше өстәлдәгеләрнең чыш-пыш сөйләшкәннәрен, кыштыр-кыштыр кәгазь актарганнарын тыңлый-тыңлый йокыга китүен сизми дә кала. Берничә тапкыр шулай хурлыкка калгач, китапханәнең уку залына йөрмәс булды ул.

— Әйдә безгә,— дип чакырды аны беркөнне Зәлия.— Барыбер бүлмәдә каңгырап утырасың. Картлар эштә. Икебезгә — өч бүлмә, укы да укы гына.

Стеналары, түшәмнәре келәмгә төрелгән фатирда Ихтыяр, үз-үзенә урын таба алмыйча, арлы-бирле йөренде. Бүлмәләрнең һавасы авыр иде, балкон ишеген ачып җибәрде. Китабын кулга тоткан килеш, балкон аратасына сөялде.

Каршыда гына елга җәелеп ага, яр буенда чайкалып утырган көймәләрнең сулкылдавы монда кадәр ишетелгәндәй тоела. Елга яры буйлап ап-ак йортлар тезелеп киткән.

— Матурмы? — Кырыена килеп баскан Зәлия ияге белән шәһәр манзарасына ымлады да иркәләнеп аңа сыенды.— Ә син, шушы матурлыкны, шушы елганы, шушы шәһәрне ташлап, әллә кая китмәк буласың. Балачагалык чыгып бетмәгән әле синнән, Ихтыяр.

— Бала-чага булсам, эти-әни куенында утырыр идем мин.

— Миңа төрттерәсеңме? Мин туган-үскән җиремдә калам, моның ни гаебе бар? Калада да кемдер эшләргә тиештер бит? Югыйсә яңа шәһәрләр корабыз, дип, искеләрен ташландык хәлгә калдырып бетердек инде...

— Яшь чакта дөнья күреп калырга кирәк. Нишләп ятасың монда, әйдә бергә киттек, калада бездән башка да кеше җитәрлек,— дип кочаклап алды аны Ихтыяр.

— Себергәме? Иске тема. Бу темага институтта биш ел, мәктәптә алты-җиде ел сочинение яздык, ничәмә-ничә кино, спектакль карадык. Шул җиткән. Себергә китеп кенә кешене шаккатыра алмыйсың хәзер. Илленче еллар романтикасы бу. Уңай герой өчен яңа ситуацияләр, яңа сюжетлар кирәк, дия иде безнең әдәбият укытучысы.

— Себер генә димәгән. Яңа шәһәрләр күп төзелә хәзер... Яңа сюжет дигән нәрсәне ничегрәк күз алдына китерәсең соң син?

— Шәһәрдә туып үскән героиняга, институт тәмамлагач, эти-әнисе янында калырга, укуын дәвам иттерергә була. Ә уңай герой, бәхет эзләп, җир читенә китеп бара. Еллар үтә. Герой эшли, эшли, эшли торгач, бөтен дөньясын оныта. Берзаман башын күтәреп як-ягына караса, яшьтәшләре өйләнешеп беткән, бала-чага үстергән, ә моның, чәчләре чалара башласа да, сукыр тиене дә юк. Бар нәрсәгә кул селтәп, бөтенләйгә кире кайтырга җыенганда, моңа героинядан туена чакырып телеграмма килеп төшә.

— Бик баналь сюжет, яңарагы юкмы?

— Икенче вариант: герой белән героиня икесе дә шәһәрдә калалар. Башта боларга кырын караучылар, аяк чалырга тырышучылар күп була. Ни әйтсәң дә, яңа төзелештәге япа-ялан кыр түгел, монда конкурентлар күп, монда көрәшергә кирәк, монда көчлеләр генә тамыр җәя ала. Ләкин боларның башкалардан бер өстен яклары

бар — икесе дә бер үк институтны тәмамлаганнар, бер үк профессия кешеләре. Еллар үтә, героиня кандидатлык диссертациясе яклый, геройны төзелеш идарәсе башлыгы итеп куялар яисә проект институтын ышанып тапшыралар. Менә бу җиңү ичмасам, моның өчен яшәргә дә ярый!

Зәлия, зур җиңү яулаган кеше сыман, дәртле көйләп, кухняга кереп китте, Ихтыяр, бер нәрсәгә исе китмичә, талгын елгага карап торуында булды. Ул бары тик өч нәрсәдән генә туймый, бары тик өч нәрсәгә: аккан суга, җил иркендә шаулаган урманга һәм бөтерелеп аккан болытларга гына көннәр буе күзен алмыйча карап тора ала. Шунысы гаҗәп: аларның өчесе дә күңел тынычлыгын ала, алгысыта, каядыр китәргә, күз күрмәгән җирләргә барырга, яңа дөньялар, яңа кешеләр күрергә чакыра иде.

* * *

Бөтенләйгә авылга кайтырга чакырып, Ихтыярга атна саен диярлек хат килеп тора, хат саен яңа төзелеш турында язалар. Зәлия дә, җай чыккан саен, өйләренә дәшәргә генә тора. Аның әти-әниләренең дә авызында һаман бер сүз — Ихтыярның эшкә кая китүе.

Шулай як-якка тарткалый торгач, Ихтыярның күңеленә дә әкренләп икеләнү корты кереп оялады, тора-бара икеләнү битарафлыкка әйләнә башлады.

— Комиссия кая җибәрә, шунда барам,— диде ул беркөнне тәмам теңкәсенә тиеп беткән Зәлиягә.

Зәлия шундук балкып китте, аның бит очларыннан үбеп алды.

— Егетлеккә тагын бер адым гына атлыйсың калды! — дип, Ихтыярның коңгырт чәчләрен тырыша-тырыша кирегә таба сыйпады ул.— Шулай итеп, язмышыңны тулысы белән комиссия кулына тапшырмак буласыңмыни инде? Егет кеше үз язмышына үзе хуҗа булырга тиеш! Синеңчә ничек?

— Гомер буена әти кул астыннан, бабай кул астыннан чыкмадым мин. Шуңадыр, ахрысы, һаман үз-үземә хуҗа булып булмый. Кемгәдер буйсынасы, авыр чакта кемгәдер барып сыенасы килә...

— Сыен алайса...— Зәлия, иркәләп, аның башын күкрәгенә кысты.— Гомер буе шулай торырга иде...— дип ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады ул.

— Гомер буена...— дип кабатлады Ихтыяр.

— Мин синең белән гомер буе шулай басып торырга да риза...

Зәлиянең сүзләре Ихтыярның бөтен тәнен кымырҗытып узды.

— Әйдә, тотабыз да икәүләп безнең якларга, яңа төзелешкә китәбез,— диде ул һәм, кинәт бер катгый карарга килгәндәй, Зәлиянең күзләренә тутырып карады.

Зәлия аны ишетми, ул, үз хыяллары эченә чумып, күзләрен зәңгәр күккә төбәгән килеш тын калган иде.

Институт тәмамлар көннәр якынлашкан саен, Ихтыярның уйлары, аның белән исәпләшеп тормыйча, атлаган саен туган авылына әйләнеп кайта торган булды. Гасырлар буе олы юл тузаны эчеп, инде үзе дә шул тузан төсенә кергән, бары тик якты тәрәзәләре белән генә дөньяга елмаеп карап торган ике йөз йортлы Ташлыярны, тау башыннан манзара кылганда, соры бәбкә көтүенә охшап күренгән шул авыл өйләрен, менә-менә күккә, урак ай янына очарга җыенган җиңел гәүдәле мәчет манарасын, капка төбендәге бүрәнәләргә чыгып утырган эшләпәле картларны, ишегалдында әвәрә килүче карчыкларны, эшкә ашыгучы яшь-җилкенчәкне, урам очыннан ук башланып киткән иген басуларын һәм шул басу түрендә мәгъруур ата казлар сыман тезелешеп баскан мәһабәт ташпулатларны, болындай киң проспектларны күз алдына китергәч, күңеле көннән-көн шунда алгысына, йөрәге урыныннан куба иде. Сызымнардан тизрәк котылып, үз куллары белән йортлар күтәрәсе, шуларга карап куанасы килә иде аның.

— Ә син миннән башка яши алыр идеңме? — Зәлиянең хыялый тавышы аны уйларыннан аерды.

— Белмим...

— Нәрсә генә беләсең соң син?

— Мин бүген бер нәрсә дә белмим,— дип, иңбашларын сикертте Ихтыяр.— Мин хәзер синең иркеңдә... Нәрсә кушсаң, шуңа риза!..

— Синме? Син киребеткән җанмы? Булырсың син риза...

Зәлиянең зәңгәр күк нуры иңгән күзләренә, иңнәренә дулкынланып агып төшкән чәчләренә, күбәләк сыман канат җилпеп торган керфекләренә, үпкәсен белдереп турсайган иреннәренә караган саен, Ихтыярның күңеле эри бара иде.

— Мин моннан китә алмыйм,— дип, Ихтыярның колагын кытыклап пышылдады Зәлия.— Син дә кал, минем белән кал. Кайда да бер дөнья... Ә монда мин бар... Монда без бергә була алабыз...

— Ә мине барыбер калдырмыйлар. Казанда калырга теләүчеләр болай да күп...

— Синең белән минем кебекләр күп түгел. Чынлап та калырга риза булсаң, чарасы бер генә инде аның... Бөтенләйгә бергә булу...

— Ә син ризамы соң? — дип, Ихтыяр Зәлиянең йөзенә күтәрелеп карады.

— Риза...

— Чынлапмы?

Ихтыяр, Зәлияне күтәреп, бүлмә буйлап бөтерелергә тотынды һәм, кинәт башы әйләнеп китеп, алар икесе бергә зәңгәр җәймә капланган караватка егылдылар.

Икенче көнне загска барып гариза биргәннән соң да, Зәлияләр фатирында аякны бөкләп келәм өстендә имтиханга әзерләнеп утырганда да, тулай торакка кайтып бүлмәдәш егетләр белән таң беленә башлаганчы сөйләшеп ятканда да, хыял исереклегеннән айный алмыйча, чүлдәге дәрвиш сыман бар дөньясын онытып, гел үзенең киләчәге турында уйлый иде ул. Ә бу киләчәктә йортлар да, кешеләр дә, гомумән, бер әйбер дә юк, бары тик алсу томан һәм шул томан эчендә Зәлия белән икәве генә чайкала иделәр.

Зәлия белән аларның язылышырга гариза бирүләре билгеле булгач, дус-ишләренең, курсташларының үзенә карата салкынайганын, аның белән аралашмыйча, читләтебрәк йөрергә тырышканын да сизмәде Ихтыяр баштарак. Бары тик комиссия утырышы вакытында ректорның кинаяле караш белән үзенә карап торуын күргәч кенә, эшнең нәрсәдә икәнен аңлагандай булды.

— Болай ашыгыч рәвештә гаилә корырга нәрсә сәбәп булды? — дип кырыс кына сорады ректор.— Интим мөнәсәбәтләрегезгә кереп тора алмыйм... Болай гына, кызыксынып соравым... Институтта укыганда да түгел, институт тәмамлагач та түгел, ә менә нәкъ эшкә кая китү мәсьәләсе хәл ителгән көннәрдә өйләнешкәнгә күрә генә әйтәм.

Ихтыяр мондый сорау буласын көтмәгән иде, шуңа күрә, беркавымга югалып калды. Гаепле кеше сыман кызарынып, тирләгән кулларын уды. Шуннан соң гына ыкмык итеп сүз башлады:

— Без инде күптән уйлаган идек... Башта этиләр риза булмады... Хәзер менә... институт тәмамлагач, үзебезгә үзебез хуҗа булабыз... Безнең бергә тормыш корасыбыз, бер шәһәрдә яшисебез килә...

— Аңлашыла...— дип сузды ректор.— Закон буенча, билгеле, без гаилә членнарын төрле җиргә җибәрә алмыйбыз. Ләкин сез әле язылышмаган бит. Гариза гына биргән.

— Нигә соң икесе бергә яңа төзелешкә китмиләр? — дип сүзгә кушылды институтның партоешма секретаре.

Шулчак комиссия членнары арасыннан өстенә ап-ак костюм кигән, уенчык кибетендәге негр курчагыныкы сыман кара бөдрә чәчләре, мул кара кашлары арасыннан карасу-коңгырт күзләре янып торган иң яшь һәм иң ыспай доцент торып басты.

— Зәлия Тарханова группада иң сәләтле студентларның берсе,— дип, һәр сүзен өзеп, саллы тавыш белән башлап китте ул.— Аның фәнни эшләре студентлар конкурсында берничә мәртәбә призлы урыннарны алды. Әле генә, җитәкче буларак, мин аның диплом эше белән танышып чыктым. Менә дигән диплом! Фикерләрен үстереп, нигезләп, тагын берничә ел утырса, кандидатлык диссертациясе якларлык эш. Мин аны аспирантурада калдыру ягында. Ә Батыршин турында бер сүз дә әйтә алмыйм. Миңа аның белән эшләргә туры килмәде. Ул туган якларына кайтырга теләк белдергән иде түгелме соң баштарак?

— Яшь егеткә аңа... кайда чибәр кызлар — шунда туган як,— дип көлемсерәде ректор.

— Ерак җир түгел, туган якларына кайтып, өч елын үткәреп килсен,— дип тагын сүзгә кушыласы итте әлеге яшь доцент.

— Батыршинга ирекле диплом бирәбез. Каршылар юкмы? — дип, икеләнергә урын калдырмыйча, тавышын күтәреп әйтте ректор.— Калганын үзләре уйлап бетерерләр.

Әллә инде беркемне дә күрәсе килмәгәнлектән, әллә вакытны ничек уздырырга белмичә, комиссиядән чыккач, ялгызы гына озаклап сыраханәдә утырды, аннары, фильмның исемен дә карап тормыйча, иң беренче очраган киногa керде. Кинодан чыкканда, шәһәр өстенә эңгер иңеп, бар дөнья, аның кәефе сыман, яктылы-караңгылы иде инде.

Икенче көнне иртән торып юынып йөргәндә, тулай то-

ракка Зәлия үзе килеп керде. Элеккеге кебек тартынып тормады, Ихтыярның әллә ничә ел бергә яшәгән хатыны сыман тиз генә түргә узып, кулындагы өч канәфер чәчәген өстәлдәге су тулы кефир шешәсенә утыртып куйды. Аны күрүгә, егетләр теләр-теләмәс кенә исәнләшкәндәй иттеләр дә, сөлгеләрен иңбашларына салып, коридорга чыгып киттеләр. Зәлия, яз күбәләге сыман, бүлмәнең бер башыннан икенче башына бөтерелеп йөрде, ишек төбендә каккан казык кебек хәрәкәтсез басып торган Ихтыярның барлыгын да сизмәгәндәй, берөзлексез авыз эченнән сөйләнде...

— Әйттем бит, барыбер үземнекен итәм, дип әйттем бит мин кызларга. Ә алар минем белән бәхәсләшкән булдылар. Ул авыл бозавын шәһәр урамына арканлап та алып керә алмыйсың син, диделәр. Оттырдылар, хәчтерүшләр!.. Оттырсагыз, минем туйга алтын балдак сезнең исәптән була, дигән идем... Менә хәзер тиеннәрен җыештырсыннар инде хәерчеләр...

Ихтыяр янына килеп кулларыннан кысып тоткач кына, Зәлия аңына килгәндәй булды.

— Нәрсә? Җибәр! — дип еламсырап кычкырды ул.— Авырттырасың, кыргый!

— Әгәр дә кызлардан берәр нәрсә алсаң, мине соңгы тапкыр күрәм дип сана! — дип ачу белән ярсып пышылдады ул.— Кирәк булса, мин сиңа ун балдак алып бирермен!

— Без... болай... шаярып кына... бәхәсләшкән идек,— диде гаепле кыяфәт белән Зәлия.— Минем үз сүземне сүз итәсем килде. Кирәк түгел миңа аларның балдагы. Син кирәк миңа...

Ихтыяр инде бераз тынычланып, үзен кулга алып өлгергән иде.

— Болай булса, син мине кәрткә дә оттырырсың әле,— дип, сүзне уенга борды ул.— Әтиең белән әниең минем монда каласын беләме соң әле?

— Алар аны синең белән миннән дә алданрак белә инде. Минем диплом җитәкчесе доцент Сарымсаковның апасы әни белән бергә эшли бит. Утырыштан соң ук ул безнең өйгә шылтыраткан. Кичә табын әзерләп, кич буе сине көттек. Доцент Сарымсаков та килгән иде... Ә син үз шатлыгыңны башкалар белән бүлешергә яратмыйсың. Эгоист! Үпкәләмә. Эгоист кешеләрне хөрмәт итәм мин. Бары тик үзен хөрмәт иткән кеше генә үз максатына ирешә бу дөньяда. Әгәр дә инде эгоист кеше үзенең кәләшен яисә хатынын, туганнарын, дус-ишләрен хөрмәт итә баш-

ласа, аны бездә патриот дип атыйлар. Күрәсеңме, эгоистлык белән патриотлык арасы бер адым гына икән.

— Әниеңнең ректор белән дә әшнәлеге юктыр бит? — дип киная белән сорады Ихтыяр.— Доцентның бер дә Казанда калдырасы килеп тормаган иде. Минем әнинең аның апасы белән бергә токмач кискәне юк бит... Сине күккә күтәреп мактады ул. Үз кул астына алмакчы була...

— Көнләшмә, юләрем, шушындый баһадирымны кырык яшькә җиткән карт буйдакка алыштыраммы соң?

— Ә нигә дип сезгә кунакка йөри соң ул? Әллә алышбиреш мәсьәләсе генәме?

— Мин туганнан бирле йөри инде ул безгә... Минем янга түгел, әти белән әни янына килә ул. Гаилә дусты.

— Ректор да килмәгән идеме соң? — дип, сүзне тагын уенга борырга маташты Ихтыяр.

— Анысы эре кош. Аның янына әти үзе барды.

Ихтыяр, бу сүзләрне ишеткәч, җете кызыл канәферләр янып торган кефир шешәсен ике кулы белән кысып тоткан килеш, ачкан авызын да ябарга онытып, Зәлиягә аптырап карады.

* * *

Берничә сүздән торган хәвефле хәбәр Ихтыярның зур авырлыклар белән акрынлап эзгә төшеп барган тормыш агышын бөтенләй актарып ташлагандай итте. Бабасының авыр хәлдә булуы турындагы телеграмманы алганнан соң, аның күңел офыгын һәрчак тутырып, бизәп торган иң якын күренешләр: балачак хатирәләрен саклаган авылы да, яшел корабка охшаган ялгыз атау да, ак әкият сыман балкып күренгән ак кала да, кул сузымы җитәр генә ераклыкта һәрчак үзенә чакырып, ымсындырып торган Зәлия сурәте дә каядыр китеп юкка чыкты, кинәт аңа бөтен нәрсә үзенең мәгънәсен югалткандай тоелды.

«Кешенең «ирек», «азатлык» дигән төшенчәләре бик якынча нәрсә икән,— дип уйлады ул.— Әгәр дә синең якын кешеләрең бар икән, димәк, син беркайчан да иректә була алмыйсың. Кеше меңләгән күренмәс җепләр белән туганнарына, дус-ишләренә, якыннарына, туган ягына, яши торган җиренә бәйләнгән. Шуңа күрә ул үзенең кылган эшләрендә, яшәү рәвешендә берничек тә иректә була алмый... Чөнки аның йөзләгән кеше алдында йөзләгән

бурычы, һәркемгә карата мөнәсәбәте бар. Димәк, адәм баласы тормышта түгел, ә бары тик үзенең уйларында, хыялында, рухи дөньясында гына үзен күпмедер дәрәҗәдә ирекле һәм азат итеп тоя ала...»

...Ул троллейбуста, тезләре өстенә куелган чемоданга таянган килеш, уйланып бара. Менә кинәт кенә тирә-юнь бушап калган сыман булды. Күтәрелеп караса, троллейбус салонында беркем юк. Ул сикереп торып алдагы ишеккә таба атлады һәм, каршысына агылган халыкны аралый-аралый, асфальт тротуарга чыгып басты. Аннары берсен-берсе этә-төртә эченә халык кереп тулган йөкле троллейбусның ишекләре ачы тавыш чыгарып ябылгач, капыл гына бер карарга килгәндәй, аэропортка таба җил-җил атлап китте.

Кара елан кебек сузылган чиратны өч-дүрт мәртәбә урап чыкканнан соң, бар булган усаллыгын җыеп, башын кассага сузды. Анда, кырт кисеп, билет юк, диделәр. Администратор тәрәзәсе янына барып, телеграмманы күрсәтмәкче булды. Кулын кесәсенә тыккач кына, Зәлияләрнең кара ишеге күз алдына килеп, әйтә башлаган сүзе ярты җөмләдә өзелеп калды:

— Бабай авыр хәлдә...

Администратор кыз, йомыркада утырган ана каз кебек, кинәт кенә башын сузды да ысылдап куйды:

— Күрмисезмени?! Самолетлар очмый! Һава бозылды, томан!

Ихтыяр бары тик шунда гына тирә-юньне каплап килгән күгелҗем томанның хыялдагы томан түгел, ә чын томан икәнен аңлады. Администраторның күңелне өшетеп ысылдаган авазы аның болай да чуалган уйларын тагын тузгытып ташлады. Ул аптырап, бик озаклап аэропорт тәрәзәсе артындагы офыкны каплаган томанга карап торды. Менә томан эченнән Зәлиянең үпкәләү катыш йөзе күренде кебек, нәрсәгәдер аптырап, як-ягына карады һәм, администратор кызның ике тамчы су кебек Зәлиягә охшаганын күреп, аптырап калды. Бу охшашлыкны күрү аңа бик тә кыен булды, моның белән Зәлияне рәнҗетүен тойды.

Ихтыяр, аэропорттан чыгып, телефон будкасы янына килде, кесәсен актарып ике тиенлек тапты. Ләкин теге башта трубканы алмадылар. Куен кесәсеннән телефон кенәгәсен алып, «И» хәрефеннән институтны эзләде, ашыга-ашыга кафедра телефонын җыйды. Трубканы доцент Сарымсаков алды.

— Тархановамы? Әле генә китте. Кая киткәнен белмим,— диде ул салкын гына һәм саубуллашмыйча гына трубканы куйды.

Нишләргә? Томан таралганын көтсәң, монда ике-өч көн утырырга мөмкин. Әллә соң Зәлияләргә генә кайтып, телефоннан аэропортка шылтыратып, белешеп торыргамы?

— Тимерхан малае түгелдерсең бит син, улым? — дигән авазга борылып караса, янәшәсендә түгәрәк ак сакаллы, салам эшләпәле, алтмышның аргы ягындагы агай аңа якынлашкан иде.

— Әйе... Ә сез кем буласыз соң?

— Сезнең күрше авылдан булам мин. Билет юнәтеп бирә алмассыңмы, улым? Өченче көн ятам инде. Монда яшәгәч, танышларың да бардыр.

— Томан бит. Алла белән әшнәлегең булса гына монда...— диде Ихтыяр һәм, артык сөйләшеп тормыйча, чемоданын әләктерде дә атлый-йөгерә машиналар агылып торган юлга таба китте.

— Әй, чибәр егет! Үзең генәме син? Әйдә, утыр,— дип, аксыл «Волга»дан башын тыгып кычкырды аңа шофер.

Ихтыяр сөрлегә-сөрлегә барып җиткәнче, машина ишеген яшь бала тоткан бер ханым ачып өлгергән иде. Карачутыр йөзле шофер көрәк хәтле кулларын як-якка җәйде.

— Әнә, артыңда гына машина туктады,— диде дә кузгалып китте.

Ул арада арттагы «Жигули»ны да «корт күче» сарып алды. Ихтыяр нәзек мыеклы, ындыр табагыдай фуражкалы чибәр егеткә үз хәлен аңлатырга тырышып карады.

— Исең киткән иске чикмәнгә,— дип, мыек астыннан читкә карап елмайды егет.— Картлар китәргә, яшьләр көтәргә тиеш. Студентмы? Студентларны самосваллар йөртә.

Ихтыяр, моның чыннан да шулай булуына ышангандай, чемоданын болгап, каршына килүче йөк машинасы алдына чыгып басты. Мыеклы егет чырык-чырык килгән кызлар белән нидер сөйләшә, сатулаша калды.

— Башың ике мәллә?!

Тормоз шыгырдаган тавышка күтәрелеп караса, кабина тәрәзәсеннән яртылаш тышка чыккан малай сымак кыяфәтле егет төкереген чәчә-чәчә аңа йодрык селки.

— Күзләреңә ак-кара күренми, әллә бөтенесе тилебәрән орлыгы ашаган инде?! Әйдә, утыр!

Ихтыяр, гаҗәпләнгән күзләрен текәп, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, бераз карап торды да, әле һаман да аңышмыйча, кабинага кереп утырды.

— Сезнең өчен җавап бир аннары,— дип йомшый төшкән тавыш белән сөйләнде шофер егет.— Самолетлар очмыймы? Хәзер тарала ул томан, бераз күтәргә ие.

— Ашыгам мин...

— Ашыккан ашка пешкән.

— Чыннан да... Зинһар өчен... Икеләтә түлим... Булдыра алган кадәр ку! — дип кычкырып диярлек әйтте Ихтыяр һәм сул кулы белән пинжәгенең эчке кесәсендәге стипендия акчасын капшап карады.

— Кая ашыгасың? Әнә анда безнең кебекләрне кабер казып күтеп торалар. Күрәсеңме, юл чите буйлап йолдызлы ташлар тезелеп киткән.

Шофер егет сөйләшкән саен, Ихтыярның ярсуы арта гына бара, бетон юл буйлап теләр-теләмәс сөйрәлгән машина аның ачуын чыгара иде. Ә тегесенең исендә дә юк: шакмаклы фуражкасын ямьшәйтеп башына каплады да ирене белән генә пачкадан суырып чыгарып, авызына сигарет капты, бер кулын рульдән ычкындырып, фокусчыдай җәһәт кенә шырпы кабызды. Тәнендәге бөтен күзәнәкләре тулырлык итеп көчәнеп суырганнан соң, йөзенә канәгать төс чыгарды да сүзен дәвам итте:

— Ике очракта гына ашыга кеше: шатлык килсә йә кайгы төшсә. Шатлык килгәнгә охшамаган, сөмсерең коелган. Нинди кайгың бар?

— Бәясеннән тормыйм, ку әйдә! — дип ярсып ук кычкырып җибәргәнен сизмичә дә калды Ихтыяр.

— Чү-чү! Бездә кычкырып сөйләшмиләр, чыпчыкларны куркытырсың.

Шофер егет фуражкасын янтайтып куйды.

— Бас инде газыңа! — дип ялварды Ихтыяр.

Егетнең дә түземлеге бетеп килә иде, ахрысы, тормозга басып, машинасын шыгырдатып туктатты.

— Мә, үзең утыр! Йә бүтәнгә күч...

Аннары, юкка кызып китүен аңлап, әкрен генә кузгалып китте.

— Кая ашыга? Нәрсә куа, кем куа бу халыкны? Авылларын су баскан диярсең...

Шофер егет сигаретын сикертеп кенә уң як ирен читенә күчерде дә сул як ирен чите белән ачык тәрәзәдән чертләтеп төкерде.

— Акча бездә — бер букча. Яңа төзелештә күрәп бирәләр акчаны, кая куярга белгән юк,— дип, гамьсез генә сызгырырга тотынды ул. Бераз баргач, нәрсәнедер искә төшереп булса кирәк, үз-үзеннән канәгать кыяфәт белән иренеп кенә көлде. Аннары өстәп куйды: — Элек Мәккәгә барган халык, ә хәзер безнең якка агыла. Шушы ташка баш орырга.— Ул, башы белән борылып, машина әрҗәсендәге бетон плитәләргә ымлады.

— Бабай авыр хәлдә минем. Җитешә алмавым бар,— диде Ихтыяр, теләмичә генә. Аның үз борчуы белән кешене бимазалыйсы килми, шуңа күрәдерме, тавышы хәзер күңел төпкелләреннән килгән кебек тоньк һәм салкын иде.

Шофер егет, ерылган авызын җәһәт кенә җыеп, җитдиләнде. Аннары бөтен йөзенә гаепле төс чыгарды, нишлим инде дигәндәй, ике кулын тиң рульдән ычкындырып, як-якка җәйде дә газ педаленә шытырдатып басты.

— Шуннан артыгын куа алмыйм. Югыйсә юл да бер дигән, туксан белән барырлык. Минем үз туксаным туксан, аның үз кырыгы кырык. Машина түгел, ишәк бу.

Шофер егет, болай да дер-дер калтырап барган машинасының барлык частьларын-шөрепләрен искә төшереп, шактый ук майлап-мазутлап сүгенде.

— Нигә ул кадәр күрмәгәндәй төядең соң? — Ихтыяр, кабинаның арткы тәрәзәсенә борылып, әрҗәдәге сыртлап төялгән бетон плитәләргә ымлады.— Соңгы рейсың түгелдер бит?

— Кая соңгы булсын! Әле башлыйбыз гына. Гомерең буе ташысаң да, очына чыгарлык түгел анда. Мир-ровой шәһәр салабыз бит, ишеткәнсеңдер инде. Шәһәр кырыенда мир-ровой завод булачак! Синең сөрсеп беткән шәһәрең түгел инде ул.

Ихтыяр, ризасызлык белдереп, кашларын җыерып куйды. Биш ел гомере узган шәһәргә тел тидерттерәсе килми иде аның. Шәһәр турындагы сүзләр турыдан-туры аның дусларына, курсташларына, институтка һәм... Зәлиягә барып кагыла, аларны рәнҗетә сыман иде.

— Борынгы калаларның үз матурлыгы бар,— дип тыныч кына сүзне алып китте Ихтыяр.— Һәр йорт үзе бер музей анда. Иске шәһәрнең һәр йорты, һәр ташы җанлы кебек. Яңа шәһәрләр дә бик әйбәт. Әмма яңа шәһәр стеналарына кеше җылысы сеңгәнче, шактый яшәргә кирәк әле. Иске шәһәргә тимә син, иске шәһәр — безнең тарих ул.

— Урамнары кәкре дә бөкре. Рәхәтләнеп йөреп тә булмый. Кешеләрен әйтер идем, бөтенесе, әллә кем булып, башын күккә чөеп йөргән була. Ун минутка соңга калдың, дип, кичә капка төбеннән борып җибәрделәр. Мин аларга ике йөз чакрымнан чаптырып килгән, ә ул сорыкортлар ун минут белән исәпләшеп тора. Шулар аркасында кабинада төн кунарга туры килде. Бездә булса!..

— Нәрсә сездә булса? Сездә бүтән сорт кешеләрме әллә? Дөнья кайда да бер ул, туган.

Ихтыяр бабасы сүзләре белән сөйләшә башлавын аңлады. «Кешегә акыл сатарга тотынсаң, картайганыңны, олыгайганыңны сизмәссең дә»,— дип уйлады.

— Кунсаң, нәрсә булган? Кабинаң хан тәхете шикелле синең. Хур кызлары да каршыңда тезелеп тора.

Егет, кабина түбәсеннән асылынып төшкән чуклы пәрдәләргә, бәрхет белән тышланган утыргычларга, барча яктан елмаеп карап торучы ярым шәрә кызларга карап, канәгать елмайды, каш сикертте.

— Йокларсың анда! Кая туктама, милиционер куып җибәрә. Аулак урын дип, күл буена туктаган идем, андагы ис!..— Шофер егет, офык читендә соргылт төтенгә күмелеп утырган йортларга ымлап, артка таба баш какты да көлеп җибәрде: — Сезнең анда хәзер бер чебенчерки дә калмаган, шәһәр уртасындагы сасы күл исеннән кырылып беткән, диләр. Хакмы шул? — Ул, Ихтыярның уйга чумган сүрән йөзенә карамыйча, һаман көлүендә булды.— Шул күл суын озакламый шешәләргә тутырып, таракан, кандала, тычкан, күсе агуы итеп кибетләрдә сатачаклар икән, дип ишеттем. И-и-и, рәхәтләнәчәк икән безнең як халкы!..

Юл кырыена тезелешкән яшь каеннар каршыга чабып киләләр дә, туктап тормыйча, артта калган шәһәргә таба ашыгалар. Ул, авылына якынлашкан саен, бабасы турында азрак уйлый барганын, һаман ешрак артка таба борылып каравын, ирексездән Зәлия өчен борчыла башлавын төшенде. «Ерактагы кояш...» — дип пышылдады.

...Атнадан артык үпкәләшеп йөргәннән соң, Ихтыяр үзе аны эзләп китте. Алар кичкә кадәр елга яры буенда йөрделәр, арыгач, дулкында тирбәлеп утырган көймәгә керделәр.

— Менә мин дә шушы көймә кебек инде,— дип шаяртты Ихтыяр.— Суда чайкалам, үз-үземә каядыр барган кебек тоелам. Ә үзем ярга бәйләп куелган.

— Нинди ярга?

— Минем ярым бер генә инде...— Ул, көймәне бер якка янтайтып, Зәлиягә сарылды, ирен очларыннан сак кына үбеп алды.

— Алдамыйсыңмы? — дип, күзләренә текәлеп карады Зәлия.— Ә мин куркам, китәрсең дә онытырсың дип куркам. Берәрсе башыңны әйләндерер дә үзенә өйләндереп куяр.

— Өйләнмим мин. Җиргә ныклап басып тора башламыйча, кеше булмыйча, өйләнмим! — Ихтыяр җилкенеп урыныннан сикереп торды һәм, тигезлек саклый алмыйча, чайкалып суга барып төште.

— Ах!

— Әллә төш күрәсең инде? — дип гаҗәпләнеп, күз кырые белән карап куйды шофер егет.— Аңламассың хәзер кешеләрне. Безнең әби әйтмешли, ахырзаман җитә инде әллә? Дөньясының да, шәһәрләренең дә рәте китте...

Ихтыярның күңеле әкренләп тынычлана төште.

— Ничек рәте китте? Нәрсә турында сөйлисең син? Үзең шәһәр салам, дисең, үзең шәһәрне сүгәсең. Төзүче кеше оптимист булырга тиеш. Бу плитәләрне кая алып барасың?

— Ташлыярга...

«Завод», «шәһәр» дигән сүзләрне ишетүгә үк, Ихтыярның күңеле кузгалган, машинаның шунда барганын чамалаган, утырганда ук шуны исәпләп утырган иде. Ләкин «Ташлыяр» сүзен ишетүгә, йөрәге тагын бер рәхәт сулкылдап куйды.

— Ташлыяр...— дип, авыз эченнән генә кабатлады ул.

— Сорамадым да... Шунда кайтасыңдыр бит?

— Шунда булмыйча, кая булсын! Бөтен юллар Римга түгел, Ташлыярга илтә хәзер. Ташлыяр — минем туган авыл ул.

Шофер егет, шапылдатып, аның иңбашына китереп сукты.

— Менә сиңа мә! Якташлар булып чыктык бит. Мин — Каенсардан. Ташлыярга алты чакрым гына.

— Каенсарны күчә дигәннәр иде бит...— Ихтыяр, шулчак күршесендәге үзгәрешне күреп, сагаеп калды.

Шофер егет, авырткан җиренә кагылгандай, йөзен чыткан, гәүдәсе белән бөрешеп рульгә сөрлеккән иде. Ул шактый вакыт сүзсез барды. Ихтыярның уңайсыз тынлыктан ничек котылырга белмичә боргаланып куюы сәбәп

булдымы, әллә каршыга килгән машиналардагы шофер егетләрнең авыз ерып кул болгаулары күңел юшкынын юып төшердеме — бераздан ул, телгә килеп, теш арасыннан гына берничә җөмлә сыгып чыгарды:

— Күчте безнең авыл. Таралып бетте. Теләгәннәренә шәһәрдә бер йорттан фатир бирделәр. Калганнары кайсы кайда үзенә оя корды. Туздырылган умарта күче кебек...

Тауга күтәрелә башлаган машина, буылып, төчкереп куйды. Егет, тизлекне күчереп, моторны бар көченә үкертергә тотынды. Тауны менеп җиткәч кенә сүзен дәвам итте:

— ГЭС коргач, авыл урынын су басты. «Кайтам инде, кайтам туган ягыма, кырларыма, тугайларыма» дип җырлый-җырлый, шул болыннарда тәгәрәп үскән идек. Хәзер инде менә ул җыр да авыл белән, кырлар, тугайлар, болыннар белән бергә су астында калды. Җырны да су астында калдырып, җырны да үтереп була икән... Хәзер инде, җәй җиткән саен, сабан туе көннәрендә, бу тирәдә калган авылдаш егетләр-кызлар җыелышып, көймәләргә төяләбез дә үзебезнең авыл урынына китәбез. Ишкәк ишә-ишә, көймә белән түбән очтан югары очка, югары очтан түбән очка кат-кат урыйбыз. Үзебез урам урыйбыз, үзебез гармун уйнап, элек җырлаган җырларны җырлыйбыз.

Шофер егетнең йөзе сөйләгән саен кырыслана, җитдиләнә барды, ул берничә минут эчендә күзгә күренеп өлкәнәйде, сабый төсмере чыгып бетмәгән кыяфәтенә олпат моңсулык иңде. Онытылып китеп, көймәдә баргандай, чайкала-чайкала авыз эченнән акрын гына бер көй сузды...

Хуш, авылым, сау бул, сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә.
Без җырларбыз сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

Ихтыяр шофер егетнең кинәт кенә бу кадәр моңсулануын, күңеле нечкәрүен аңламады, аның халәтен бөтен җаны белән тоймады, аның хәленә кереп юатырлык сүзләр эзләмәде. Хәер, эзләсә дә таба алмаган булыр иде андый сүзләрне. Чөнки Ихтыяр әлегә үз уйлары, үз хыяллары белән мәшгуль, аның үз кайгысы иң зур кайгы иде.

Шофер егет, җебеп төшүеннән оялыпмы, әллә юлдашының битараф карашын күрепме, капыл гына сүзне икенчегә борды:

— Бабаңа нәрсә булган?

— Белмим...

— Ничек инде белмисең? Белмәгәч, нигә ул кадәр бетеренәсең? Болай... сыныкка сылтау табып, сагынып кына чакырганнардыр әле. Коймак ашарга гына...

— Минем әти андыйлардан түгел...— Ихтыярның күз алдына шулчак басу буйлап зур адымнар белән атлап баручы әтисе килеп басты. Ул аның хәтеренә мәңгегә шулай уелып калган. Арыш саламы төсенә кереп кояшта уңган күлмәгенә, саргылт эшләпәсенә, җил ашаган озынча бакыр йөзенә караган саен, Ихтыяр әтисенең бу җирләргә, бу басуларга никадәр нык береккән икәнен күрә, ныграк аңлый бара. Әйтерсең ул шушы арышлар кебек җирдән шытып чыккан да, яңгыр сулары, кояш нурлары эчеп, шушы басуда үскән. Әнә ул хәзер дә, тук башаклы арыш сабагы сыман башын җиргә иеп, аның каршына килә кебек.

— Картларга баш төртер урын бетеп бара,— дип, шофер егет тагын тәмәкегә үрелде.— Без әле ничек тә көн күрербез, дөнья безнең кулда хәзер. Алар нишләр? Гомер-гомергә шул карт-коры, безнең ишеләргә иман биреп, олылар акылын безнең буш башларга дөңгечли-дөңгечли тутырган. Картлардан курыкканнар, картлардан оялганнар, алар алдында итагать саклаганнар... Ә хәзер? Хәзер без аларга пенсия бирәбез дә мич артына кертеп утыртабыз. Уттан качкан кебек, картлардан кача бит хәзер яшьләр. Безнең яңа шәһәрдә көндез чыра яндырып эзләсәң дә, ак сакаллы кеше таба алмыйсың син. Ә авылда — өй саен ялгыз карт-карчык.

— Теге әкияттәге кебек,— дип өстәде Ихтыяр.— Бер әкият бар бит әле... Патша алтмыш яшьтән узган картларны үтертә торган булган. Ә бер малай үзенең әтисен саклап алып калган. Хәтерлисеңме?

— Истә. Әтисенең ярдәме белән патшаның мәкерле сорауларына җавап табып, исән кала ул малай. Соңыннан бу җавапларны табарга әтисе ярдәм иткәнен әйтмичә булдыра алмый. Әлеге хәлдән соң патша картларга тимәс була...

— Яшьлек кызулыгы белән төзелгән шәһәр озын гомерле булыр микән соң? «Яшьлек шәһәре төзибез!» дип күкрәк сугу шәбен шәп тә, картларны санга сукмыйча, бер читкә этәреп кую бигүк дөрес микән?

Шофер егеткә сүзнең бу агымга кереп китүе ошап җитмәде, ахрысы, кабина тәрәзәсен төшереп, каршыга кил-

гән машинага кул селкеде. Тегесе, туктап, башын тышка сузды.

— Нәрсә булды?

— Таяклылар тора, артык кума,— диде ул каршыдагы машина шоферына.

— Нигә утыңны гына челтләтмәдең?

— Бөтенләй челтләгән инде ул, пенсиягә генә озатасы калган,— дип, кабина ишегенә сукты да газга басып кузгалып китте.

— Кемнәр ул — таяклылар? — дип кызыксынды Ихтыяр.

— ГАИ, үзебезчә әйтсәк, Гайнетдин була. Лейтенантларыннан, капитаннарыннан, хәтта полковникларыннан курыкмыйм мин аларның. Сержант очраса, баш бетте дигән сүз. Сандугач телләре белән сайрап та, чалбарың тишелгәнче тезләнеп ялынып та күңелен йомшартырмын димә.

— Принципиаль, димәк.

— Принципиаль, пычагым! Өч тәңкәлек принцип белән ерак китә алмассың. Бер мәзәк сөйлимме?

— Тыңлап карыйк.

— Шулай бер сержант көне буе постта тора икән. Үзе тора, үзе авыз эченнән һаман бер үк сүзне кабатлый, ди: «Икегә икене кушкач — дүрт, икене икегә тапкырлагач — дүрт». Кичкә таба түземе калмаган моның, рациядән ГАИ начальнигына эндәшкән: «Иптәш начальник, минем сезгә бер соравым бар иде. Мөмкинме?» — ди икән бу. «Тыңлыйм»,— дигән тегесе. «Иптәш начальник, инде менә ничә ел ГАИда эшләп, мин һаман бер сорауга җавап таба алмыйм. Сез укыган кеше, бәлки, аңлатырсыз? Икегә икене кушкач, дүрт була, икене икегә тапкырлагач та — дүрт. Ә менә өчкә өчне кушкач алты, өчне өчкә тапкырлагач, тугыз була. Нигә алай икән, ә?» — дип тын кала сержант. Рациядән ГАИ башлыгының: «Күпме аңлатырга була: сезнең бурычыгыз кушу да, тапкырлау да түгел, ә алу һәм бүлү. Аңладыгызмы, алу һәм бүлү».

Шофер егет сөйләп бетермәс борын ук тыела алмыйча көләргә тотынды, аның борын очлары тирләп чыкты, күзләре яшьләнде. Ихтыяр да көлгән сымак итте.

— Һәркемнең үз арифметикасы,— дип авыз эченнән генә сөйләнде ул. Аннары каршына килгән йөкле машиналарга төртеп күрсәтте.— Кая ташыйлар алар бу плитәләрне?

— Сезнең шәһәргә,— дип хихылдады егет. Ул әле һаман көлү өянәгеннән чыга алмаган иде.

— Нигә? Сез аннан монда ташыйсыз, ә болар яңа шәһәрдән иске шәһәргә? Аңлашылмый.

— Плитәләре төрле маркалы бит аның. Аларга бер марка кирәк, безгә — бүтәне.

— Күреп торам анысын. Ә булса соң?

— Булса соң да, булса соң... Бик акыллы икәнсең, бар да әйт үзләренә: нигә ул плитәләрне үзегездә генә чыгармыйсыз, ике йөз километрга машина куып, хөкүмәт акчасын җилгә очырасыз, диген. Башыңнан сыйпарлар анда синең...

— Әгәр һәр завод үзенә кирәкле плитәләр генә чыгарса, күпме транспорт, күпме эшче кулы бушар иде бит,— дип көрсенде Ихтыяр.

Шофер егет, күпне күргән кешедәй, башын селкеде:

— Алай булса, гел яхшы була бит ул. Ә без кыенлыклар белән көрәшеп өйрәнгән. Кыенлыксыз яши дә алмыйбыз бит хәзер, кыенлык, җитмәүчелек булмаса, аларны үзебез уйлап табабыз. Ике шәһәрдә — ике завод. Безнең завод теге шәһәргә кирәкле продукция чыгара, аларныкы — безнең шәһәр өчен кирәклене. Ни өчен алай, дисеңме? Җавабы бик гади аның. Сезнең шәһәрдәге завод элек үзе өчен кирәкле продукция чыгарган. Мәсәлән, культура-агарту учреждениеләре, халык-көнкүреше объектлары, спорт корылмалары төзү өчен кирәкле материаллар. Вакыт узган, андый объектлар төзү иске шәһәрдә бөтенләй диярлек туктатылган. Анда хәзер төп игътибарны торак төзелешенә юнәлтергә булганнар.

— Ә заводны үзгәртеп корырга онытканнармы?

— Онытмаганнар. Артык мәшәкатьтән курыкканнар. Алардан план сорыйлар бит.

Шофер егет ике яшел кыяр тартып чыгарды да берсен Ихтыярга сузды, үзе берсен шатыр-шотыр кимерергә тотынды. Сөйләгән сүзләренең кыяр кимерү кебек гади нәрсә икәненә ишарә ясарга теләгәндәй, беркавым тын гына барды. Ә Ихтыярның, киресенчә, күңелендәге тынычлык югалды.

— Шуннан, шуннан? — дип ашыктырды ул.— Шуннан сез бу плитәләрне яңа шәһәргә ташыйсыз...

— Безнең шәһәр әле бирнәсез кыз кебек, аңа барысы да кирәк: кияү дә, фатир да, чүпрәк-чапрак та...

— Аңлатыбрак сөйлә әле, минем өчен бик кызык бу...

— Нәрсәсен аңлатасың? Бала-чага да аңлый инде боларны... «Үзләренең коесы бар, безгә кереп су ала» дип җырлыйлар идеме сездә? Нәкъ менә шул инде. Чиләген тутырып ала да көлә-көлә югала... Ягъни мәсәлән, кесәсен тутырып акча ала да көлә-көлә югала...

— Берни аңламыйм,— дип, иңбашларын җыерды Ихтыяр.

— Эшең төшсә, аңларсың.

— Яңа шәһәрдә бетон заводы бардыр бит?

— Заводсыз шәһәр салып була димени?

— Соң, шулай булгач...

— Шулай булгач, бака шулпасы була... Безнең шәһәрдәге завод торак йортлар коруны истә тотып кына җиһазландырылган,— дип, юри лекторларча коры тел белән сөйләп китте ул.— Әлегә ул, бик теләсә дә, мәдәният сарайлары, мәктәпләр, балалар бакчалары, зур кибетләр, театрлар, ашханәләр салырдай төзелеш материалы чыгара алмый. Шуңа күрә яңа шәһәр, иске шәһәрдән шундый төзелеш материалы сорап, баш орырга мәҗбүр була. Ә анда, сезнең шәһәрдә, шомарган карт бүреләр утыра, алар сиңа «Әпипә» биегәнгә генә егылып китә торганнардан түгел.

— Бу нәрсәне дәүләт күләмендә хәл итәргә кирәк...

— Бүлдермә әле,— дип кырыс тавыш белән туктатты аны егет.— Бәлки, кемгәдер шулай яхшырактыр? Хөкүмәт барысын да күреп бетерә алмый, ул бирәү генә, без күбәү... Шулай итеп, дөнья үз агымы белән ага тора... Телиме-теләмиме, яңа шәһәр иске шәһәргә алмашка үзенә бик тә кирәкле төзелеш материалларыннан өлеш чыгарырга мәҗбүр. Шулай итеп, без, бер шәһәрдәге тавыкны икенче шәһәрдәге әтәчкә алыштырып, ике йөз километр араны киләп сарып йөрергә мәҗбүрбез. Аңлашылдымы минем лекция?

— Юкәдә икән чикләвек! — дип, Ихтыяр каршыга агылган йөк машиналарындагы плитәләргә карады да, үз эченә бикләнеп, уйга чумды...

«Бәлки, Зәлия хаклы булгандыр? Кеше, бер урыннан икенче урынга чабып, күченеп йөрергә тиеш түгелдер? Үзенә кулай шартлар эзләп йөргәнче, бәлки, күңелеңне үзгәртеп корырга, урындагы шартларга яраклаштырырга кирәктер? Күңелгә реконструкция ясарга... Күңелне үзгәртеп корырга... Юк! Юк!» Ул, уйларыннан арынырга теләп, чигәләрен уды.

Шофер егет аңа кырын карап алды да, төпчек башына төкереп тәрәзәдән ыргыткач, онытылган соравын яңадан кабатлады:

— Бабаңа нәрсә булган?

— Белмим, дидем бит...

— «Белмим»нән җайлы нәрсә юк бу дөньяда.

Ихтыяр илтифатсыз гына, хәтер саклау өчен генә җавап бирде:

— Атауда яши ул. Берүзе. Язгы ташу вакытында атауга кереп булмый.

— Атау Зыятдинмы? — Егет Ихтыярга сәер итеп карап куйды.— Беләм, беләм,— дип ашыга-ашыга тезеп китте аннары.— Безнең якларда аны белмәгән кеше бармыни? Кулы алтын аның! Холкы гына... Кичә үтеп киттем әле мин атау яныннан. Атауның янына якын барырлык түгел. Ярлары тулган, дөбер-шатыр боз ага. Эшләр шәптән түгел анда. Син кайтудан гына рәт чыкмастыр... Әгәр чынлап торып авырып та киткән булса, хуш, авылым!..

— Керәм мин анда, хәйләсе бар,— дип, малайларча үз-үзенә беркатлы ышаныч белән әйтеп куйды Ихтыяр.— Тизрәк кайтып кына җитик.

Шофер егет юл читенә күз ташлады.

— Утыз алты чакрым калды. Хәзер — түбән таба. Ярты сәгатьтән капка төбендә булырсың.

Һәркайсы, үз уйларына чумып, шактый вакыт сүзсез бардылар. Шофер егет авыз эченнән генә «Хуш, авылым»-ны көйли, Ихтыяр хыял атына атланып күз ачып йомганчы әле бабасы янына кайтып җитә, әле Зәлия каршына томырыла, аннары яңадан кирегә борыла. Казаннан ераклашып, туган авылына таба якынайган саен, Зәлиянең күз алдындагы сурәте томанлана бара, ә бабасының сурәте ачыклана. Ихтыяр хәтта аның күз кырыйларына җыелган хәйләкәр елмаюын күргән кебек булды.

Казан белән Ташлыяр арасында арлы-бирле чабып йөри торгач, хыял аты шабыр суга батып хәлсезләнде, ахрысы, Ихтыяр башын күтәреп юлга карады, маңгаена сәйлән-сәйлән тезелгән тир бөртекләрен кул сырты белән сыпырып төшерде.

«Бабай... бабай...— дип, авыз эченнән кабатлады ул.— Нигә мин сине дөньядагы бар кешеләрдән дә якынрак күрәм икән? Юк, юк! Әтине дә, әнине дә якын күрәм... Ә бабай... бөтенләй башка. Нигә алай икән? Бер карасаң,

аның уйлары да, максаты да зурдан түгел сыман... Җирдәге һәр кеше үз өендә, үз ишегалдында, үз бакчасында тәртип урнаштырырга тиеш, ди ул. Җирдәге һәр кеше бәхетле булса, ил дә бәхетле була. Әтисе, киресенчә, иң элек ил кайгысын кайгырта, бөтен илдә берьюлы тәртип урнаштырмакчы була. Үзләренчә икесе дә хаклы алар хаклысын. Бабасының юлы турырак, аның нәтиҗәләре тизрәк күренә. Ләкин дөнья аныңча барса, тырыш, булган, маһир кешеләр яңадан баеп китәчәк, ярлылар һәм байлар пәйда булачак. Димәк, әтисе белән бабасы арасындагы урталыкны сайларга кирәк... Әгәр алар икесе бергә килешеп эшләгән булсалар, безнең ил инде күптән бу торгынлыктан котылыр иде...»

— Йокыга киттеңме әллә? — дип, терсәге белән төртте аңа шофер егет.— Туган якларыңны әйбәтләбрәк карап кайт. Бәлки, соңгы кат күрүеңдер... Ярты Татарстанны кырып-җимереп киләләр инде. Башта, нефть чыгарабыз, дип, Әлмәт якларының җелеген суырдылар. Хәзер анда чишмәләрдән, инешләрдән тозлы-мазутлы су ага. Ярты Европага нефтьче-донор булдык инде... Үзебезнең генә эчәргә суыбыз, суларга һавабыз бетеп бара.

— Бөтен яклап бетәбез,— дип, аның сүзен җөпләде Ихтыяр.— Авылларда табигать бетә, халык шәһәргә кача, калганнары эчүгә сабыша, шәһәрдә татарча мәктәпләребез юк, телебез юк... Телсез халык була ала димени?

— Әле үткән атнада Казанда юри генә мәчеткә барган идем,— дип көлемсерәде шофер егет.— Шунда Америка татарларын очраттым. Синнән-миннән чистарак татарча сөйләшәләр. Ничек була инде бу? Америкада тел бетми, бездә бетә. Нәрсәдер дөрес түгел, кемдер нәрсәнедер уйлап бетермәгән монда.

Ихтыярның үз сүзен куәтләмәвен күргәч, шофер егет исәр кешедәй кычкырып җырлап җибәрде:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Җырның моңы, сүзләре генә түгел, ә шофер егетнең аңы бөтенләй үзенчә, үҗәтләнеп, кемгәдер юри үч иткәндәй артык кычкырып җырлавы җанына барып кагыла, болай да тынычсыз күңелен урти иде.

— Безнең халык алай тиз генә бетә торганнардан ту-

гел! — диде ул, шофер егет җырлап бетергәч.— Мең елда бетмәгән тел берничә елда гына бетмәс.

— Ничек кенә бетә әле! — дип көрсенде шофер егет.— Безнең бригадада утыз ике кеше. Шуларның унбише татар. Araларыннан ничә кеше татарча белә, дип уйлыйсың? Алтысы... Калганнары ипи-тозлык кына сукалый. Ә Себер ягыннан килгән ике егетнең икесе ике сүз дә белми. Утызынчы елларда бабаларын безнең яклардан сөргән булганнар. Ни гаепләре булгандыр, белмим, ләкин җәзаның катысы эләккән аларга...

— Нинди җәза?

— Туган иленне, туган теленне, туган җиренне тартып алудан да зуррак җәза юктыр инде ул?!

— Җәза... Җәза,— дип кабатлады Ихтыяр.— Тарих хаталары ул. Хәзер менә шул хаталарны төзәтәбез инде.

Шофер егет, сүзнең артык тирәнгә кереп, катлаулана баруын өнәмәдеме, әллә Ихтыярның фикерләре белән килешмәдеме, уйга чумды. Шактый вакыт шулай сүзсез баргач, кинәт кенә Ихтыярның иңбашына кагылды.

— Әнә, ә-нә безнең туган яклар,— диде ул, күңеле кузгалганын яшерергә теләп.

Йөзьяшәр өянкеләр кочагына кереп елышкан иркә дә, моңсу да кыяфәтле авыл өйләрен күздә тотып әйттеме ул, буп-буш басу уртасында чәчелгән биек-биек ак шакмак йортларга күрсәттеме,— Ихтыяр аңламады. Ләкин бу минутта аның өчен шофер егет нәрсә уйласа да барыбер иде. Бу мизгелдә ул яңадан бары тик яшел атаудагы бабасы турында гына уйлый, аның өчен хәзергә бар дөнья шул атаудан гына гыйбарәт иде.

— Кайчан кузгаласың? — дип сорады шофер егет дустанә кыяфәт белән. Ул инде юлдашына бөтенләй иялэшеп беткән, аны үзенең дустына саный башлаган иде. Ихтыярның, җавап бирмичә, күзләрен еракка төбәгән килеш алга сөрлегеп утыруын күргәч, ул уңайсызланып кына сүзен дәвам итте: — Кире якка кайчан юл тотасың?— дип әйтүем. Көн саен иртәнге җидедә кузгалам мин. Ул якка буш барам, җилдерәбез генә! ГАИның үз кырыгы — кырык, минем үз туксаным — туксан.

Шофер егет, әллә кайтып җитү сөенеченнән, әллә үзе уйлап тапкан шушы бердәнбер тапкыр сүздәнме — шаркылдап, рәхәтләнеп көлде. «Болай итеп бары тик сабый җанлы, чиста күңелле кеше генә көлә ала»,— дип уйлады Ихтыяр. Һәм, кинәт кенә исенә төшкәндәй, каршыга

килүче йөк төялгән машинага күрсәтеп, егетнең җиңеннән тартты.

— Нигә буш барасыз соң? Нигә бу плитәләрне сез төямисез?

— Алай булса, әйбәт була бит ул. Без — бер төзелеш оешмасыныкы, ә ул плитәләрне ташучылар — бүтән оешманыкы. Аларның — үз транспорты, безнең — үзебезнеке.

— Бушка машина куганчы, ике оешма килешеп, эшне җайга салып буладыр бит?

— Килешә алмый торганнардыр инде. Безгә, мәсәлән, бу айда егерме мең плитә кирәк, ә аларга — ике йөз генә. Шуны исәпләп алар берничә генә машина юлга чыгара. Киләсе айда киресенчә булуы мөмкин...

— Булса соң. Транспорт белән идарә итү буенча республикада бер координация үзәге төзеп, эшне тәртипкә салсаң...

Шофер егет Ихтыярга гаҗәпсенеп карады.

— Һаман да бер сүз... Төзелеш оешмалары уникенче гасырдагы Русь кенәзлекләре кебек бит алар. Берсе бер якка тарта, икенчесе бүтән якка каера. Бар, берләштереп кара аларны... Иван Грозныең да бер дәүләт төзи алмас иде алардан. Транспорт кына булса, бер хәл. Андагы әкәмәтләрне күрсәң, күзең маңгаеңа менәр иде. Полнейшая анархия, ди безнең начальник.

— Начальнигың нәрсә уйлаганны белмим, тик шулай да удар төзелештә бу кадәр үк хаос хөкем сөрүенә ышанып бетә алмыйм,— дип, Ихтыяр тавышын күтәрә төште. Шофер егетнең яңа шәһәр турында шундый сүзләр сөйләве аның горурлыгына кагыла кебек иде. Аннары Ихтыярның борчулы күңеле һаман да бабасы өчен өзгәләнә, теле төзелеш хакында сөйләсә дә, җаны, кисәк-кисәк сулкылдап, үзен сиздереп куя иде.

— Читтән килгәнгә синең читәнең кирәкми,— дип сукрануын дәвам итте шофер егет.— Кунакка гына кайтканда — барысы да матур, барысы да әйбәт. Иртән коймак пешкән, кичкә мунча ягылган. Ә төзелешнең эченә кереп китсәң — баш чыккысыз...

— Тумас борын картайгансың син,— дип, дорфа гына аның сүзен бүлде Ихтыяр.— Әллә шәһәр салуны бәрәңге ашау дип белгән идеңме? Бардыр, ялгышлары да китәдер,— дип, тавышын йомшарта төште.— Тик шулай да шәһәр төзелә бит. Димәк, анда эшлекле кешеләр дә җи-

тәрлек, димәк, анда «полнейшая анархия» түгел. Бөтен ил яшьләре урыннарыннан кубарылып бу якларга юкка гына агылмыйдыр.

— Бу якка да, теге якка да агыла. Башкала корреспондентлары бер көнгә килеп башлыклар бүлмәсендә җыелышта утыра да газетада ашъяулык кадәр мәкалә бастырып чыгара. Имеш, яңа төзелештә барысы да ал да гөл, барысы да җитеш. Әй китәләр тезеп аның перспективасын, булачак проспектларын тасвирлыйлар, булачак театрларын мактыйлар, булачак парклары буйлап йөртәләр. Ә бүгенгесе турында ник ләм-мим бер сүз булсын. Дөрес, мин артык кызып киттем бугай, бүген дә мактап телгә алырдай нәрсәләр бар анысы. Ләкин корреспондент әфәнде аларны күрми. Аның ялтыравыклы туфлиләре белән безнең шәһәрдә баскыч төбеннән ары китеп булмый шул.

— Корреспондентларның да төрлесе бар...

— Мин сөйләгән ишеләре күбрәк. Андыйлары башкалардан җәһәтрәк тә бит. Төплерәкләре килеп, өйрәнеп айлар буе төзелеш пычрагы ерып йөргән арада, болары инде үзләренең төче коймакларын күптән өлгерткән була. Аннары шуларның төче сүзенә ышанып монда яшьләр агыла башлый. Килеп карасалар, теге мәкаләдәге сөт елгалары да, әфлисун таулары да юк икәнен күрәләр дә күбесенең борыны салынып төшә. Сыеграк буынлылары шундук табан да ялтырата. Әгәр башта ук аларга яңа төзелешнең кыенлыкларын, андагы перспектива белән бүгенге авырлыкларын да сөйләсәләр, бүтәнчәрәк булыр иде. Мин үзем дә гәҗит теле белән сөйли башладым бугай,— дип, шофер егет Ихтыярга карап тагын бер көрсенде: — Әнә читтән ничек матур күренә ул ак шәһәр. Әгәр эченә кереп карасаң син аның...

Ихтыярның бу сүзчән һәм әче телле егеткә бераз хәтере калса да, аның күп фикерләре белән килешмәсә дә, ул һич көтмәгәндә үзенә шундый юлдаш очравына сөенде. Ташлыяр янында төзелеп яткан яңа шәһәр турында моңа кадәр ул үзе дә күбрәк газеттан укып кына белә иде. Җәйге каникулларда төзелеш отрядлары белән авыл районнарына ярдәмгә чыкканга, соңгы елларда үз авылына, туган якларына бик сирәк кайтырга туры килде. Ә менә шофер егет берничә сәгать эчендә аны төзелеш белән хәбәрдар итте, гигант корылышның үтә катмарлы дөнья икәнен аңлатты.

— Бу юлы шәһәрне аркылыга-буйга йөреп чыкмыйча калмыйм,— диде ул, басынкы һәм җитди кыяфәт белән.

— Бик йөрергә туры килмәс. Бабай авырый, диден түгелме соң?

— Соңгы елларда шактый бетеренде шул. Күңеле тыныч түгел, шуңа үз-үзенә урын таба алмый. Яше дә сиксәннең аргы ягына чыкты.

— Алай гына микән? Зыятдин бабайның холкын беләбез. Юкка-барга гына бирешә торган кеше түгел. Тешләгән җиреннән өзмичә калмый, карт бүре кебек... Әле генә яшь егетләр сыман йөри иде. Бүтән берәр сәбәбе бардыр моның.

— Эшли башлап, бераз аякка баскач, үз яныма чакырам мин аны,— диде Ихтыяр, шофер егет алдында акланырга теләгәндәй.

— Кая алдырасың? Казангамы? Бармый ул анда. Әйткән иде, диярсең. Беркая да китми ул моннан. Нигә үзең монда кайтмыйсың соң? Кайда укыйсың син?

— Төзелеш институтында.

— Алай булгач, суйган да каплаган инде! Дүрт куллап каршы алалар сине монда!

— Дөнья мин уйлаганга караганда катлаулырак булып чыкты шул,— дип авыр сулады Ихтыяр.— Өйләнәм мин... Казан кызына...

— Һе-һе! — дип мыскыллап елмайды шофер егет.— Аңлашыла. Койрыгың бозга ябышкан, димәк. Казанның боткасы майлырак шул! Авылыгызны ташлап, Казанга оялыйсыз да шуннан безгә акыл өйрәтеп ятасыз! Мәктәпләр бетә, тел бетә, тарих бетә, имеш. Кайда бетә? Иң элек Казанда бетә. Балык башыннан чери ул, туган. Бөтен Казаныгызга бер татар мәктәбе бар, адәм көлкесе! Ике йөз йортлы Ташлыярда да бар ул андый мәктәп. Башкала, имеш.

— Анысы синнән-миннән генә тормый. Мәсьәлә катлаулырак,— дип сузды Ихтыяр.

— Нәрсәсе катлаулы аның? Дөнья бер дә катлаулы түгел, без үзебез катлауландырабыз аны.

— Катлауландырасың шул. Көпә-көндез чаң сугасың. Бетмибез әле без, дускаем! Дүрт йөз елга якын рус патшалары астында бетмәгәнне, хәзер бетмибез инде. Халыкны тиз генә бетереп булмый аны. Халык зур ул...

— ...әдип ул, шагыйрь ул, көчле ул,— дип тезеп китте шофер егет.

— Артистланма,— дип туктатты аны Ихтыяр.

— Артист булу начармыни? Мин бәләкәйдән үк артист булырга хыялланган идем. Укырга гына җай чыкмады. Әле хәзер дә үзешчәннәр белән уйнап йөрим.

— Күренеп тора... Кайда уйныйсың соң? Клубыгыз бармы?

— Кая анда клуб! Кая туры килә — шунда җыелабыз.

— Күңел ачарга барыбер җай табабыз дисең инде?

— Күңел ачар урыннар җитәрлек бездә. Менә дигән өч ресторан салып куйдылар. Клуб салырга гына җитешә алмыйлар. Театр турында хыялланган да юк инде.

— Булыр, барысы да булыр,— диде Ихтыяр һәм, машинаның үз өйләре каршында туктавын күреп, кесәсенә тыгылды.

— Ләкин ул вакытта без булмабыз. Бу шәһәрдә театрга йөрерлек татарча белгән кеше дә, анда уйнарлык артистлар да булмас. Халык турында, туган як турында Казанда фәлсәфә сатып ятмагыз, кайтыгыз да эшләгез. Ярый, сау бул!

Шулай диде дә ул, Ихтыярның акча сузган кулын тупас кына этәреп, ишекне шапылдатып япты.

Машина кузгалып бераз баргач, кабина ишеге ачылды, аннан шофер егетнең башы күренде.

— Сау бул! — дип кабатлап кычкырды ул.— Хуш!

— Хуш...— дип кул селтәде аңа Ихтыяр һәм, үзе дә сизмәстән, «авылым» дип өстәде.— Хуш, авылым!

* * *

Ул пинжәгенә, чалбарына кунган юл тузанын каккалады да, капканы ачып, ишегалдына керде. Ишегалды түрендә казынучы тавык, аның кайтуына сөенгәндәй, җанфәрманга каршысына йөгереп килде дә, башын кыйгайтып туктап калды. Ихтыярның каккан казык кебек бер урында тик торуын күргәч, салмак кына борылып җырлый-җырлый китеп барды. «Тавык сөендерерлек әйберең дә булмагач, ник кайтып йөрдең монда?» дигән сыман, ул аңа битараф караш ташлады һәм чүп-чар туздырып тибенеп алды.

Ишеге ачык булса да, өйдә бер кеше дә юк иде. Ул чемоданын ишек төбендә калдырып түр яктан әйләнеп чыкты да инеш буена йөгерде.

Ихтыярны күргәч, каршыга очраган кешеләр, башлаган сүзләрен әйтә алмыйча, авызларын ачып карап кал-

дылар. Ул актарылып, бөтерелеп, ыңгыраша-ыңгыраша аккан кара бозларга карап торучы әнисен ерактан ук күрде һәм бер мәлгә тынычланып калды.

— Исәнме, әни! — дип, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән сорады ул һәм атаудагы йортка таба ымлады.

Әнисе:

— Бер көе әле, улым,— дип башын түбән иде.

— Бабай ни хәлдә?

— Белмибез шул, үзебез дә белмибез...— Әнисе күз карашын язгы ташу суыннан атаудагы яшел түбәле йортка күчерде.— Бер килсә килә бит ул адәм баласына... Гөнаһ шомлыгына каршы, ташу көчәеп кузгалганны сизмичә калдык. Бигрәкләр көтмәгәндә кисәк җылытты бит быел. Ашарына да кертергә өлгерми калдым. Соңгы арада сырхаулап та тора иде. Күпме үгетләп, ни монда чыкмады, ни больницага бармады. Инде менә өченче көн ни бер аваз салмый, тәрәзәсендә ут шәүләсе дә күренми. Әллә... бер-бер хәл булып...— Әнисе яулык почмагы белән битен каплап сулкылдарга кереште.

— Әткәй кайда?!

— И-и, анда атау кайгысымыни?! Холкын да үзең беләсең. Аралары көннән-көн бозыла гына бара. Башта: «Зыятдин картның гадәтен беләбез. Юри безне үртәп, канга тоз салып ятадыр әле»,— дип йөрде. Иртән торса — эш, кич ятканда — эш. Колхозга кендеге береккән инде аның, шунсыз яши алмый. Аннары... чәчү өсте дә җитеп килә. Иртә таң атса, шәһәрнекеләр белән сугышып гомере уза. Тегеләргә шәһәр салырга кирәк, моңа — җир... Гомерен бирер, бер карыш җирен бирмәс иде дә бит, аңардан гына торса... Сорап тормыйлар, шуңа җен ачулары чыга, шуңа котырына... Шулай да бүген иртән аның да күңеле йомшады бугай әле. Таңнан торып инеш буен бишалты урады. «Бабай! Бабай!» — дип кычкырып та карады. Ә атаудан ник бер аваз килсен...

Шулчак аларның каршына җир селкетеп трактор килеп туктады. Әтисе, башын иеп, кабинадан егетләрчә җиңел генә сикереп төште дә, сөенечен сиздермичә генә, эшлекле кыяфәт белән улына кулын сузды.

— Кайтып җиттекме? Булдыргансың. Әйдә, тотын!

Сүзне артыкка сузарга вакыт юк дигәндәй, трактор артына чылбыр белән тагылган бүрәнәләрне җәһәт кенә ычкындыра башлады.

— Һо-һо! Инженер кайткан! — Трактор авазын күмеп

киткән бу тавыштан Ихтыяр айныгандай булды. Аның каршысында баштанаяк майга-корымга буялып беткән якты күзле, ир уртасы кыяфәтле бик тә таныш кеше тешләрен ялтыратып басып тора иде.

— Чә... чәбер... Синме бу, Әхмәт?

— Мин булмыйча кем булсын! Яшьтәшләрдән мин генә бит хәзер авылда. Зыятдин бабай аэропланына утырып очып беттегез барыгыз да...— Ул, нәрсәдер күрергә теләгәндәй, аяк очларына басып үреләүреләү атау ягына карады. Аннары, малай чакларына әйләнеп кайткандай, нәкъ шул вакытлардагы сыман иттереп, кулын Ихтыярның иңбашына куйды. Зәңгәр пинжәктә биш бармак эзе ярылып калды.

— Хәлләрең ничек? — дип сорады Ихтыяр.

— Эшлибез. Җир җимертәбез! Камыр батырлар үрчетәбез.

Ихтыяр моңа кадәр, сүз арасында да гел атау ягын күзләгәнгә күрә, аяк астына карамаган иде, ул шунда гына Әхмәтнең күн итеген кочаклаган кара-чутыр малайны күреп алды. Малай аның аксыл йөзенә зәңгәр күзләрен төбәгән дә, кәгазь самолет тоткан кулын артка яшереп, икенче кулы белән тырыша-тырыша борын казый иде.

— Нәрсә мыштырдыйсыз анда? Соңыннан да җитешерсез.

Әтисенең шактый усал һәм кырыс тавышын ишеткәч, Ихтыяр аның янына килеп басты.

— Ике бүрәнәне бергә кысып бәйлибез дә суга төшерәбез. Шуңа менеп басасың да колга белән этеп теге якка чыгасың. Аңлашылдымы?

Ләкин әтисенең тырышлыклары юкка булып чыкты. Суга төшерүгә үк, өстенә менеп басарга да өлгермәделәр, ташкын суы салны бөтереп алып китте дә каршыдагы борылмага китереп сылады. Берсен-берсе этешеп, куышып килгән бозлар арасына кереп, сал бер минутта күренмәс булды.

Әтисе белән Әхмәт яңа сал бәйли калдылар. Ихтыяр башын күтәреп карт өянке очына карады да бер сүз дә әйтмичә өйләренә таба йөгерде. Кулына ыргак тотып трактор янына кире килгәндә, тегеләрнең яңа салы да әйләнеп капланган, көч-хәл белән боз өстенә сикереп ярга чыгарга өлгергән Әхмәтнең йөзе куе кызыл төскә кергән, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан иде. Әтисе, чарасыз калып, трактор чылбырына килеп сөялгән, әнисе,

инәлүле күзләрен яшел түбәле йортның бу яктагы сыңар тәрәзәсенә төбәп, хәрәкәтсез калган. Бары тик карачутыр йөзле малай гына, өлкәннәрнең өметсезлеккә төшүен аңламыйча, яр буйлап арлы-бирле чаба. Менә ул яр читенә үк килеп бар көченә кизәнде дә кәгазь самолетын утрауга таба очыртып җибәрде. Самолет, кая таба очарга белмичә, су җилендә шактый вакыт бөтерелеп торгач, лып итеп боз өстенә килеп утырды да, кырын яткан килеш агып китте. Малай елап җибәрде.

— Акырма әле! Туйган тавышыңнан! — дип, Әхмәт малаеның кулыннан тотып, җилтерәтеп трактор янына алып килде. Бер аягын тәгәрмәч чылбырына куйгач, ул китәргә дә, китмәскә дә белмичә, беркавым аптырап торды, аннары гына өскә менде.— Тимерхан абый, әллә шәһәрнекеләргә барып карыйсыңмы? — диде ул, нигәдер бик тә сак, кыюсыз тавыш белән.— Аларда техника күп бит. Берәр әмәлен табарлар иде. Гидростройга барсагыз, борып җибәрмиләр инде. Үзләренең дә сезгә йомышлары төшә бит...

Тимерхан, олы чүмеч белән су тондырган мунча ташы кебек, шул арада кайнап, ярсып чыкты:

— Шулар гына кирәк монда! Яз әйткәнгә көз килеп җитәрләр...

Ихтыяр пинжәге белән ботинкасын салып ташлады да, өйдән алып килгән ыргакны чалбар каешына эләктереп, карт өянке ботагына башта куллары белән асылынды, аннары, бераз атынып торгач, ботакны аяклары белән кочаклап алды да мәче җитезлеге белән җәһәт кенә өскә менеп басты.

— Нишләмәк буласың? Тагын нәрсә уйлап чыгардың? Төш аннан, юк нәрсә белән маташма!

Ихтыяр, этисенең сүзләрен ишетсә дә, аларга игътибар итмәде, аяк-кулларын сыдыра-сыдыра өскә үрмәләвендә булды һәм тал кәүсәсенә бәйләнгән тимерчыбык турына җиткәч, авыр сулап туктады.

— Малай чакта бабай янына шушы асылмалы юлдан очып кына чыга идем мин...

— Төш аннан! Ишетәсеңме, муеныңны сындырганчы төш! Ике потлы малай түгел син хәзер. Тимерчыбык чыдамас. Күгәреп беткәндер инде ул.

Ихтыяр үзе утырган тал очыннан каршы як ярдагы тал төбенә тартылган тимерчыбыкка ыргагы белән сукты. Тимерчыбык аңа бала чактагы кебек зеңгелдәп җавап бирде. «Болай булгач була»,— дип уйлады ул. Лә-

кин аста актарылып аккан инешкә карагач, башы әйләнеп киткәндәй булды. Үз-үзен тынычландырырга, каушавын басарга теләп, ул ят тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Өзелмәс. Ташлыяр циркы дип атый идек элек без бу төшне. Ул чакта теге яктан бу якка таба чыга торганы да бар иде...

Ихтыяр ыргакның бер башын тимерчыбыкка эләктердә дә икенче башының кәкресенә куллары белән чытырдапябышты һәм әкрен генә аска таба шуышып төшеп китте. Әнисе «аһ» дип ыңгырашты да күзләрен йомды, битен яулык белән каплады. Әтисе, алай-болай егылып төшсә, тотып калырга җыенгандай, бөтен гәүдәсе белән алга сөрлегеп, кулларын өскә күтәрде. Әхмәт трактор кабинасының түбәсенә үк менеп басты. Кара-чутыр малай, самолетын онытып, елаудан туктады. Өянке очында бөтерелүче каргалар гына, шомлы авазлар чыгарып, шашына-шашына каркылдарга тотындылар.

Инешнең уртасына җиткәч, тимерчыбык аска тартылып, Ихтыярның гәүдәсе су өстеннән ике-өч метр өстә асылынып калды. Аның авырлыгы басып сөзәкләнгән тимерчыбыктан ыргак ары шуыша алмый иде. Шулай да ул үз хәлен уенга борырга теләде:

— Троллейбус ватылды, ары бара алмый! Пассажирларның чыгуын сорыйбыз!

Ул кымшанган саен, тимерчыбык сузыла, ә гәүдәсе күзгә күренеп суга якынлаша иде.

— Селкенмә! Тимерчыбыгың өзелә! Селкенмә! — дип, җан ачысы белән кычкырды аңа әтисе.— Тик кенә тор! Әхмәт, чап шәһәргә! Янгын машинасы җибәрсеннәр! Мин әйтте, диген! Тиз бул!

Трактор усал эт кебек бар көченә ырылдап куйды да, бәйдән ычкынгандай, кинәт алга ыргылды.

Ихтыярның хәле уен-көлкедән узган иде. Асылынып торган саен, аның куллары оеп хәлсезләнә барды, гәүдәсе, таш тутырылган капчык сыман, аска тартылды, авызы кибеп, телләре аңкавына ябышты. Шәһәрдән ярдәм килгәнче ыргакта асылынып торырлык, көтәрлек түземе дә, хәле дә юк иде аның.

Менә ул, кинәт кенә катгый карарга килеп, бер кулын ыргактан ычкындырды да тимерчыбыкка тотынды, аннары икенче кулын да сакланып кына шунда күчерде. Күгәргән нечкә тимерчыбык аның бармакларын уеп кер-

де, авырту утлы ток булып бөтен тәнгә таралды. Гәүдәсен селкетмәскә тырышып, кулларын әкрен генә алга шудырды. Тимерчыбык бәгырьгә үтәрлек итеп көйдереп алды, ә ул, аның саен ныграк үҗәтләнеп, кулын тагын, тагын алга күчерде. Ихтыярның күз аллары караңгыланды, тирә-юньдә сары канатлы күбәләкләр очып йөри башлады. Менә ул күбәләкләр бөтен җирне каплап, аллы-кызыллы төсләргә кереп бөтерелергә тотындылар. Күбәләкләр белән бергә астагы кара бозлар, кара сулар, кара үләннәр бөтерелде. Әкренләп атауның яшел коймалары, яшел түбәле йорты, күзләрне камаштырырлык зәңгәр күге дә соры төскә керде.

Шушы куркыныч төсләр мәхшәреннән котылырга теләп, ул җан ачуы белән һаман алга таба шуышты. Тора-бара аның күңеленә битарафлык иңә башлады, бөтен хисләре тупасланып, сүнеп калгандай булды. Бары тик бер ачулы үҗәт хис кенә йөрәктән ташып чыга да тәне буйлап югары күтәрелеп, кулларына соңгы көчне биреп тора иде. Ул, күз алдында һаман саен ишәеп ныграк бөтерелгән төсләрдән котылыр өчен, күзләрен йомды һәм әллә кайда, еракта, талдан талга бәйләнгән тимерчыбык буйлап җирдән — атауга, атаудан — җиргә чыжлап очып йөрүче коңгырт чәчле, түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле малайны күреп елмайды. Атау белән җирне икегә бүлеп аккан, бабасы белән аларны аерып торган кара суларга ачуы да бер мәлгә онытылып, сүрелеп калды. Ачуы сүрелүгә, аның тәне дә бөтенләй хәлсезләнде, кан саркып чыккан бармаклары язылып, гәүдәсе капчык сыман аска тәгәрәде. Менә ул, аңына килеп, күзләрен ачты, артына борылып карарга куркып, яңа баш төртеп килгән саргылт-яшел үлән өстенә утырды.

Каршы як ярда бер чарасыз басып торучы әтисе белән әнисе, үзләре дә белешмичә, моннан егерме биш ел элеккеге кебек, бер-берсенә елышканнар да, бишектә йоклап ятучы алсу йөзле, зәңгәр күзле малайларына караган кебек, Ихтыярга төбәлеп онытылганнар иде.

* * *

Ихтыяр такта баскыч түшәлгән сукмак буйлап атау өстенә менеп җиткәнче мең төрле уйлар уйлап, тинтерәп бетте. Ниһаять, көч-хәл белән капка төбенә килеп терәлгәндә генә баганадагы элмәккә бәйләнгән бауны һәм өй кыегына

кунаклаган иләмсез зур канатлы аэропланны күреп, туктап калды. «Бабай минем кайтуны көткән. Бабай сагынган... Институтны тәмамлауга... самолет ясап куйган... Нәкъ теге чаклардагы кебек...» — дип уйлады Ихтыяр.

Элмәкне тартып җибәрүгә, язгы давыл чәчәге төсенә буялган аэроплан, читлектән ычкынган кош сыман, бер талпынып алды да аска томырылды, аннары көязләнеп өскә күтәрелде һәм салмак кына очып китте. Иреккә чыгуына сөенгәндәй, ул, ургылып аккан ташу суларына да исе китмичә, әле түбәнәеп, әле югары менеп, әле хикмәтле бөтерчекләр ясап очты да очты.

* * *

Капканы ачып ишегалдына кергәч, Ихтыяр гомерендә беренче тапкыр бу атауның никадәр буш һәм ялгыз икәнен аңлады. Әллә инде тирә-якта кабер тынлыгы хөкем сөргәнгә, әллә баш очында каргалар каркылдаганга — бүген ул нигәдер зиратны хәтерләтә иде.

Бабасы гомере буе эт тотмады, песиләре дә инде әллә кайчан,— Ихтыяр институтка кергәнче үк,— картаеп дөнья куйды. Эт, песи асраган кеше әле ул кадәр үк ялгыз була алмый. Яши-яши йорт җәнлекләре гаилә әгъзаларына әйләнә, аларга хәтта кеше акылы керә башлый сыман.

Ихтыяр ишегалдына күз йөртеп чыкты, лапаска керде. Анда бөтенесе дә тәртиптә: аяк асты ялт итеп себерелгән, кораллар барысы да рәт-рәт итеп стенадагы чөйләргә элеп куелган. Сул як стенада аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән көянтәләр эленеп тора. «Быел кыш та көянтәләр ясаган, язны көткән»,— дип уйлады Ихтыяр. Ул, сыкраган бармакларын йодрыкка йомарлаган килеш, һаман ишегалды буйлап йөри, өйгә керергә кыймый иде. Әйтерсең нинди авырлыклар белән атауга килеп ирешкәч, аның күңеле, үз бурычын үтәлде санап, тынычланып калган, гүя менә хәзер аксыл саргылт мыеклары астыннан елмаеп бабасы килеп чыгар да яратып орыша-орыша аның башыннан сыйпар сыман. Чынлыкта ул өй эчендәге билгесезлектән курка һәм шуңа күрә бимазаланып ишегалды буйлап арлы-бирле йөри дә йөри.

Менә ул әкрен генә болдыр ишеген шакыды. Тагын шакыды, ләкин җавап ишетелмәде. Аннары курку катыш тавыш белән:

— Бабай! Бабай! — дип кабатлады.

Өй ишеген ачуга, мич янындагы караватта толып астында бабасының гәүдәсен шәйләп, ашыга-ашыга шунда таба атлады. Саклык белән генә толып почмагын күтәрде. Бабасының керфекләре калтыранып куйды, һәм ул әкрен генә күзләрен ачты, хәлсез иреннәрен кыймылдатты:

— У-лым...

Бу мәлдә Ихтыяр өчен бөтен дөнья бабасы өенә сыеп беткән кебек иде. Аннары бүлмәнең нигә болай гаҗәеп зур һәм шыксыз икәненә төшенә алмыйча торды. Бар нәрсә дә үз урынында, бар нәрсә дә элеккечә, шулар янына бары тик җан өшеткеч шыксызлык кына өстәлгән. Ихтыярның тәне калтырап куйды. «Су-ык,— диде ул эчтән генә.— Шыксызлыкның сәбәбе менә нәрсәдә икән».

Ул йөгереп чыгып лапастан утын алып керде, чыра телеп ут тергезде дә мич ягып җибәрде.

Самавыр куйгач, өйгә бөтенләй җан кергәндәй булды. Ихтыяр куе итеп мәтрүшкәле чәй пешерде, аны өрә-өрә суытып, калак белән бабасының авызына салды. Тун чабуларын як-яктан кыстырып, бабасын җылытырга теләде һәм шулчак, кулы салкын тимергә тиеп, аптырап калды. Толып читен күтәреп караса, баштанаяк ап-актан киенгән бабасы янәшәсендә ике көпшәле кап-кара мылтык ятканны күреп, өнсез калды.

Ихтыяр бабасына карап бераз башын чайкап торды да салкын көпшәле мылтыкны чөйгә элде, аннары инеш ягындагы тәрәзәне барып ачты.

Мичтән чыккан төтенне күргәч, этисе белән энисе бераз тынычланган булсалар да, аларның күңеле һаман борчыла, билгесезлектә газаплана иде булса кирәк. Су читенә үк килеп басканнар да тораташтай катып калганнар. Ихтыяр, тәрәзәне ачып, үз-үзен белештермичә, бар атауны яңгыратып кычкырды:

— Исән! Бабай исән!

Энисенең тез буыннары йомшап китте бугай, әкрен-әкрен генә чүгәләде, хәлсезләнеп, яр буендагы ташка утырды. Этисе, кинәт кенә аңына килгәндәй, кырт борылды, бераз алга сөрлегә төшеп, авыл урамы буйлап хуҗаларча олы һәм ныклы адымнар белән китеп барды. Зыятдин картның исән булуына сөенү-сөенмәвен ул йөзенә чыгармады, хисләргә бирелмичә генә борылышка кереп югалды.

Мичне томалагач, өй җылынып китте, шул җылыда стеналарны, бөтен җиһазны сарган шыксыз ялгызлык та эреп юкка чыккан сыман булды.

Ихтыяр чолан аратасына эленгән каклаган казны алып кереп чуенга аш куйды, караватбашы янындагы биек киштәдән дарулар эзләп табып бабасына эчерде. Зыятдин картның йөзенә күзгә күренеп элекке алсулык кайта, күзләрендәге сүнеп барган очкыннар берәм-берәм яңадан кабына иде.

Икенче көнне иртәнге чәйне эчкәч, Зыятдин бабай урыныннан калкып мендәргә сөялде, тагын бер көннән аягына ук торып басты, ә Ихтыярның кайтуына дүрт көн дигәндә, таякка таянып ишегалдына чыкты.

Ул таягы белән тык-тык килеп арлы-бирле йөри, үзе, якты дөньяны беренче мәртәбә күргәндәй, гаҗәпләнеп, һаман бер үк сүзләрне кабатлый: «Җыяр ризыгың бетмәгәч, бик теләсәң дә китеп булмый икән... Менәтерә ничек бит ул. Менәтерә ничек бит ул...»

«Олы җиргә» чыгып әти-әнисе янында утырасы, аларның күңелен азга гына булса да юатасы, авылдашларын күреп сөйләшәсе, шәһәргә барып кайтасы килсә дә, Ихтыяр бабасын шушы хәлендә калдырып китү турында уйларга да кыенсына иде. Култыклап, аны инеш буена алып төште, бергәләп атау читләреннән әйләнделәр. Бабасының элеккеге кырыслыгы, элеккеге йомыкыйлыгы әллә кая юкка чыкан, ул, яңадан тугандай, бөтен нәрсәгә гаҗәпләнеп карый, һәрнәрсәнең нинди дә булса яңа ягын ача, моңа кадәр игътибар да итмәгән, күрмәгән нәрсәләрне күрә иде. Ул әле өянке башындагы карга ояларының күплеген күреп шакката, әле авыл өйләреннән күтәрелгән төтен баганасының турылыгына соклана, әле яңа гына чыгып килгән чирәмнең яшеллегенә аптырый иде.

Атауда яшәгән бер атна вакыт эчендә Ихтыяр гомерендә беренче мәртәбә кеше язмышы дигән нәрсәнең серенә төшенә башлаган кебек булды. Үзен-үзе ялгызлык читлегенә ябып, чит илләр белән бөтен элемтәләрен өзгән дәүләт кебек яшәүче бабасы аңа үтә горур да һәм шул ук вакытта кызганыч та тоелды.

Ихтыяр инде моңа кадәр дә Зыятдин бабасының язмышы, үткән гомере турында күп ишеткән иде. Әнисе аңа кичләр буе үзенең балачак хатирәләре белән аралаштыра-аралаштыра Бигәшевләр ыруы хакында сөйли торган иде.

Бигәшевләр нәселе элек-электән булдыклы, алтын куллы, эшлекле һәм шактый ук кырыс холыклылардан саналган. Әнисенең бабасы Арсланның алты малае булуын, шуларның төпчеге Зыятдин карт икәнен дә белә Ихты-

яр. Егерменче елларда шул алты туган берләшеп атауның аскы өлешендә, ике инеш кушылган урында су тегермәне корганнары, соңрак тегермән белән янәшә яргыч һәм сушилка салганнары хакында да ишеткәне бар. Ә менә бабасының нигә дип шушы атауга кереп бикләнгәнен, бар дөньяны онытып, шунда теше-тырнагы белән ябышып ятканын, кешеләрдән читләшкәнен аңламый иде. Дөрес, әтисенең бик кызып киткән чакларында «чабаталы морза», «сусыз тегермән», «тегермән өрәге» дип ычкындырганын ишеткәч, бабасын бу атауда нәрсә тотып торганын аңлагандай итә, бабасы белән әтисе арасында язгы ташу суы кебек ниндидер үтеп булмый торган аралык ятканын сиземли иде.

Бервакыт, күңеле йомшаганрак чак туры килдеме, әллә әнисенең көн-төн талкуы кирелеген сындырдымы, әтисе атауга керде. Ихтыяр мәктәптән кайтып, көндәгечә бабасы янында эвәрә килеп арыганнан соң, лапаста берүзе генә агач наган юнып маташа иде. Әтисе белән бабасы өйгә кереп шактый ара югалып тордылар. Ихтыяр, наганын бер читкә куеп, ниндидер гайре табигый хәл булуын көткән сыман, тынып калды. Түр яктагы тәрәзә аша аларның өзек-өзек сүзләре ишетелеп куя да атау тагын телсез-өнсез кала...

— Җитте, кеше көлдермә. Бөтен авыл сине сөйли. Һәрнәрсәнең чиге була.

— Сөйләсен. Сине түгел, мине сөйли. Авырлыгын да үзем күтәрермен.

— Сиңа нәрсә... Монда ялгыз бүре шикелле берүзең ятасың. Ә без кеше белән, халык белән яшибез. Кеше сүзе сиңа килеп җитми, безгә кагыла, йөрәккә тия...

Шактый вакыт сабыр гына сөйләшкәч, әтисе тагын кызып китте:

— Нәрәт яздырам да тегермән белән яргычыңны утынга сүттерәм! — дип кычкырып җибәрде ул.— Өеңне җәһәннәмгә олактырам... Күпме түзәргә була...

— Өйгә тияргә хакың юк, Тимерхан кияү. Закон кушмый. Өй минеке. Кулың бик кычытып тора икән, үзеңнең хан сараеңны җәһәннәмгә олактыр. Тегермәнгә дә мин исән чакта, Аллаһы боерса, кул тидерүче булмас. Чөйдәге куш көпшәм һәрчак корулы минем. Һәркемгә үз башы газиз. Ә мин яшисен яшәгән...

Ихтыяр өй эчендә әтисенең көчәнеп кенә көлгәнен ишетте.

— Сусыз тегермән өрәге, дип дөрес атыйлар үзеңне. Нигә диеп шуңа ябышып каттың икән? — Әкренләп аның тавышы җылына, салмаклана бара.— Нәрсәгә кирәге бар инде аның сиңа? Авыл читендә менә дигән электр тегермәне, кирәк икән — киптер, кирәк икән — ярдыр, кирәк икән — он тарттыр. Синең бу ташландык тегермәнеңнең күсе белән тычканнардан башка кемнәргә кирәге бар?!

— Сез шундый ташландык хәлгә китердегез аны. Егерме җидедән кырык бишенче елга кадәр бөтен тирә-якның карап торган бердәнбер тегермәне иде ул. Үз кулларым белән салганга күрә генә шулкадәр кадерле дип уйлыйсыңмы әллә син аны миңа?! Чатыр чабып дөнья куарга өйрәнгән кешеләр шул сез. Өстән кушканга гына йөрисез, план тутырыр өчен генә. Кеше күңел кушканны эшләргә тиеш, кеше кушканны түгел. Шунсыз кылган эшеңнең мәгънәсе дә, кадере дә булмый. Күмәк хуҗалык, дип бугаз ертасың, шул сүз белән минем авызны томаламак буласың. Әйтерсең сез генә акыллы башлар, әйтерсең моңа кадәр гел ахмаклар гына яшәгән. Алты туган бергә җыелып гел бергә яшәдек без. Эшебез дә, ашыбыз да гел бергә, уртак булды. Хәзер алты туганны бергә укмаштырып кара әле син... Ата улдан, ана кыздан бизеп бара. Ә син, күмәк тормыш, дисең. Акыллы хайван зур көтү белән йөрми ул. Бөркетләр көтүен күргәнең бармы синең?

— Үзеңне бөркеткә тиңләвеңме?

— Кирәк чакта бөркет тә булдык! Әллә син менә бу тегермәнне, яргычны кору бик җиңел булгандыр дип уйлыйсыңмы? Нинди еллар иде бит! Хәзер генә ул барны юк итеп йөргәч тә... Ә-әнә, яр буенда Әҗем тавы биеклеге тимер-томыр өеп куйгансыз. Ватасыз-җимерәсез дә расходка чыгарасыз. Без юктан барны ясый идек...

— Үзе өчен ни эшләмәс кеше. Кеше өчен, халык өчен, ил өчен тир түгеп кара син!

— Авызыңа — сыер боламыгы... Әллә ни әйттерерсең, кияү.— Зыятдин карт, дулкынланудан, ахрысы, буыла-буыла ютәлләде. Сулышы тигезләнгәч кенә, үпкәләгән бала сыман еламсырап, сүзен ялгый алды: — Үзең өчен, имеш! Кара син аны, кызыл сүз сөйләп каешланып беткән, бөтенләй иманы калмаган. Унсигез ел буе тирәюньнең утызлап авылы шул тегермән тарткан оннан ипи пешереп ашадымы? Ашады! Шул ипине ашап буй үстергән егетләр Берлинга кадәр барып җитеп, Гитлер мәлгуньнең муенын борып кайттылар!

Зыятдин бабай соңгы чиккә җитеп үпкәләгән, рәнҗегән, әгәр тагын берәр тупас сүз белән кагылсаң, артык түзеп тора алмас, күңеле тулып, елап җибәрер сыман иде.

— Ярый, кызма, бабай, кызма. Барысын да беләбез. Булган — беткән.— Этисе, тимерне артык бөгүен чамалап булса кирәк, ягымлырак итеп сөйләшүгә күчте.

— Бетмәгән шул! — дип үҗәтләнеп каршы төште аңа Зыятдин карт.

Картның тынычланганын көтеп, Тимерхан сүзгә кушылмаска булды, беразга икесе дә тынып калдылар. Зыятдин карт кына, туктый алмыйча, вакыт-вакыт көрсенеп, офтанып куя. Ул үзен аңламаганнары өчен газаплана, үзенең дә заманында бу дөньяга кирәк булганын, үзенең дә кешеләр өчен яшәгәнен төшендерә алмавыннан гасабилана, Тимерханның үз хәленә керә алмавын күреп, аның бөтенләй бүтән дөньяда яшәвен, буй җитмәс һәм уй җитмәс ераклыктан торып сөйләшүен сизеп изалана иде.

Тимерхан, сүзнең озынга китүен һәм күпме генә гәп корса да бабасын аяк терәп баскан урыныннан кузгата алмаячагын төшенеп, әңгәмәне йомгакларга булды.

— Булды, бабай,— диде ул, коры гына итеп.— Җыелыш тәмам. Гадәттәгечә, битарафлар юк, яклаучылар күп, ә каршылар санга керми. Без бүген һәммәбез бер-беребезне бетереп ташладык, үз-үзебезне якладык, мактанышып алдык. Һәркемнең — үз иманы, үз кыйбласы, үз фәлсәфәсе. Ләкин син бер нәрсәне онытма: без күбәү, ә син берүзең. Дөреслекне ялгыз гына эзләмиләр аны. Кайда көч — шунда хаклык.

— Көч сездә, шуңа үзегезне хаклыга саныйсыз.

— Сау бул! Син тегермәнеңне корып бетергәндә, инешнең суы кипкән иде.

Өйалды ишеге ачылып, аннан этисенең гәүдәсе сузылып чыкты. Ул лапас баганасына сөялеп тын торган Ихтыярга күз ташлап алды да туктап калды. Ишектән үзалдына сөйләнә-сөйләнә чыгып килүче Зыятдин карт күренде.

— Уенга алма, кияү. Минем күзләр дә ботак тишеге түгел, барысын да күреп, чамалап тора. Кулыңнан эш килә, кеше арасында сүзең үтә... Сугыш елларында күтәрәмгә калган колхозны да аякка бастырдың. Шушы бетәшкән картның да бер кәлимә сүзенә колак сал. Төзәттер шул тегермәнне. Бульдозерларың белән эттереп буа

будырт. Күп дигәндә, бер атналык эш ул колхозга. Буасында элекке заманнардагыча бер потлы сазаннар, җәеннәр үрчет, ә тегермәне, җанга рәхәтлек биреп, халыкка игелек эшләп, келтер-келтер килеп утырсын шунда. Колхозыңа да табыш китерер, халык та рәхмәт укыр үзеңә. Тегермәнгә күз-колак булуны, яшь-ыркынга киңәштабыш бирүне үз өстемә алам. Билләһи, мин әйтәм, тагын ун ел гөрләтеп эшләрлек чама бар әле минем.

Зыятдин картның күзләренә, бөтен карашына инәлүле, ялварулы кыяфәт иңгән иде. Әгәр дә каршы сүз әйтсә, аны мәңгегә рәнҗетәсен аңлап, Тимерханның тимер йөрәге дә түзмәде, ул да йомшарды.

— Аңлыйм, бик аңлыйм мин сине, бабай,— диде ул һәм көрәк кадәр кулын аның иңбашына куйды.— Ә менә син мине аңламыйсың. Аңларга да теләмисең. Халык бар бит әле дөньяда. Халык нәрсә уйлар, халык нәрсә дияр? «Тәки үзенекен итте, бабасының тегермәнен аякка бастырды»,— диярме? Болай да җай чыккан саен, синең исем белән авызны каплыйлар. Теге вакыттагы хәлләрне оныттыңмыни? Син онытсаң да, алар онытмый бит. Юк, берүк үгетләргә килгән дип уйлый күрмә. Хәзер соң инде. Колхоз синсез дә яшәр. Тик менә синең үҗәтлегең аркасында ике малаең тиң авылны ташлап китәргә мәҗбүр булды. Үз язмышың — бер хәл, аларның язмышына да кара тамга салдың. Совет хөкүмәтенең күңеле киң, кайда да югалмаслар алар. Әмма ләкин, минемчә, үз теләкләре белән китмәде алар моннан. Әби мәрхүмә дә, ил белән бергә көн күрә алмыйча, өеннән, атавыннан чыкмыйча саргаеп дөнья куйды. Барысы да синең кирелек аркасында. Имеш, аның үз куллары белән салган тегермәнен, яргычын тартып алганнар. «Кулак» исеме тагып, җәһәннәмгә сөрмәгәнгә сөенеп, шөкер итеп кенә утырасы урында... Алсалар, тегермәнеңне әллә кая куймаганнар бит. Элек тә шунда торган, хәзер дә шунда...

— Кияү, ачуым килмәгәе, Чатан Гаптеридән алган җиде класслык грамытың белән унике ел указлы муллада укыган бабаңа акыл өйрәтмә яме!

Грамота мәсьәләсе Тимерханның иң авырткан урыннарыннан берсе иде. Идарә утырышларында да, райкомда да колагына тукый торгач, ул, ниһаять, тартып-сузып техникум бетерде. Ләкин анысы белән дә канәгать булмадылар, соңгы арада югары белем таптыра башладылар. Алтмышның өске ягына чыккан Тимерхан инсти-

тутта читтән торып укуны күз алдына да китерә алмый һәм шулай ук әле танау аслары да кибеп өлгермәгән дипломлы егетләргә урынын бушатырга да атлыгып тормый иде. Хәзер менә бабасының да белә торып шул ярасына тоз сибүе аны чыгырдан чыгара язды.

— Анысы синең белән генә ярышырлык белем бар! — диде дә, сүзне дәвам итәргәме-юкмы дигәндәй, ишегалды түреннән әйләнеп килде.— Безнең яшьтәшләр арасында техникум бетерүчеләрдән бер мин генә авылда. Сугыш еллары туры килмәсә, институтын да бетергән булыр идек. Академиясен дә!

— Читтән торып уку шул син әйткән сусыз тегермән кебек инде ул. Тегермәне бар, ташы бар, тик оны гына чыкмый. Кызганып кына бирәләр анда сезгә дипломны.

— Әле шул техникумга да көчкә алдылар. Барысы да — синең аркада. Әллә атау өрәкләре белән саташып бөтенесен дә онытып бетердеңме? «Колхоз җитәкчесе була торып, кулак калдыгы Зыятдин кызына өйләнгән»,— дип, еллар буе күземне ачырмадылар, ничә мәртәбә райком бюросында тикшерделәр, илле икенче елны хәтта партиядән чыгармакчылар иде.

— Хәтерем яхшы минем,— дип бүлдерде аны Зыятдин карт.— Ул көнне салып кайтып атауга кергән идең. Төн уртасына кадәр тузынып чыктың.

Тимерхан аның сүзләрен ишетмәмешкә салынды, һаман үз сүзен сөйләвендә булды:

— Ярый әле ул чакта зурга җибәрмәделәр, акыллы кешеләр мине яклап чыктылар. Бер елга сынау шарты белән калдырганнар иде... Мине сынаган кешеләрнең күбесе үзләре үк вакыт сынавын уза алмады, ә без, күрәсең, һаман исән. Колхоз да исән...

— Зыятдин карт та теркелди,— дип өстәде тегесе.

— Аларның сүзләрендә дә күпмедер хаклык бар иде бит, бабай,— дип, аның йөзенә күтәрелеп карады Тимерхан.— Шикләнергә хаклары бар иде аларның да...

— Ә минем сүздә бер мыскал хаклык та юкмы?

— Бар анысы.— Тимерханның чал басып киткән кашлары җыерылып килде, озынча ябык йөзе суырылып, җыерчыкларга күмелде. Ул авырлык белән генә сүзен дәвам итте.— Тик... синең хаклык — бары тик синең өчен генә кирәк. Ә безнең хаклык — уртак хаклык, ул барыбыз өчен дә кирәк, ул халык өчен кирәк.

— Ә минем тегермән халык өчен кирәк түгелме? Ул

унсигез ел буе онны минем өчен генә тарттымы? Минем берүземә кул тегермәне дә җитә. Гомергә байлык җыярга да хирыслыгым булмады. Үзең күреп торасың: нәрсәм бар иде минем? Хәзер нием бар?

— Син тегермән турында уйламыйсың бит, бабай. Күреп торам, үзең турында уйлыйсың. Сиңа тегермән дә, он да, буа да, балык та, колхоз табышы да кирәк түгел... Тимерхан «халык та» дип өстәмәкче булган иде, тыелып калды.— Сиңа үз хезмәтең кызганыч, сиңа, әйтсәм әйтим, үзең кызганыч. Халыкны читкә тибәрүен тибәрдең дә, аларның синнән башка да бер дигән итеп яшәвен күргәч, эчеңне ялкын сарды. Ничек әле ул дөнья тоткасы булган Зыятдин карттан башка тормыш барырга мөмкин, ә?! Менә хәзер шуңа эчең яна да...— Тимерхан, ачуын басар өчен юри усалрак, чәнечкелерәк сүзләр сайлап сөйли, шуннан ләззәт таба сыман иде.— Дөрес,— дип, ишегалды уртасындагы тумранга уң аягын куеп, ышанычлы кыяфәт белән дәвам итте ул,— дөрес, сиңа тупас кагылганнар, синең белән исәпләшеп тормаганнар. Ә безнең белән һәрчак исәпләшеп тордылар дип уйлыйсыңмы? Кырыкка бөгеп карадылар, утка да, суга да салдылар. Хәзер күпме тыпырчынсаң да, берни эшли алмыйсың. Хәзер булганына шөкер итеп яшәүдән башка чараң калмый. Баш белән бәреп стена җимерә алмассың. Тик шуны кисәтеп әйтәм: әллә кайларга хатлар язып та, аһ-зар чәчеп тә мәшәкатьләнмә. Монда безне ышанып эш башына куйганнар икән, ышанычларын акларга тырышырбыз. Кирәк икән сугып егарбыз, кирәк икән тартып та торгызырбыз. Закон — үзебезнеке. Җавабын да үзебез бирербез.

— Һем-һем. Телим — асам, телим — кисәм, башың исәң, орден тагам булып чыга инде бу, алайса.— Зыятдин карт, бөкрәйгән гәүдәсен турайта төшеп, Тимерханга текәлеп карады. Аның күзләрендә усал очкыннар кабынып китте. Ләкин ул кулын илтифатсыз гына селкеп куйды да бүкән өстенә утырды.— Шуны аңла, кияү,— дип, шактый вакыттан гына телгә килде ул.— Сиксәнгә җитеп үзгәрмәгәнне, хәзер капыл гына алышынып булмас. Оныт син мине, бу дөньяда юк дип уйла, кермә дә, күренмә дә. Бер үтенечем генә бар: төзәтмәсәң төзәтмәссең, әмма ләкин җимерттермә тегермәнне! — Зыятдин карт таягы белән җиргә каты итеп сукты.— Син җиткермәдең аны! Кирәк икән — үзем җимерермен. Әлегә ашарга сорамый бит. Карап торган бердәнбер юанычым ул минем.

— Тагы бер кат әйтәм, бабай, әйдә, чык авылга, өебез иркен, барыбызга да урын җитәр. Мине яратмыйсың икән — сөйләшмәссең. Көне буе басудан кайтып кермим мин. Өйдә үзең хуҗа булырсың. Маһруй да бик бетеренде, аңа да иптәш кирәк. Сине уйлап бетеренә ул.— Тимерхан бу сүзләрне капка тоткасына ябышкач, артка борылып әйтте.— Күреп торасың, авыл мул яши хәзер, кешеләрнең дә күңеле көр. Сиңа теш кайрап торган кеше дә юк. Ятма монда үзеңә-үзең үчегеп, бөтен дөнья белән бәхәсләшеп...

— Авыл — сезнеке, шуңа күрә үзегез генә рәхәтләнеп яшәгез инде. Гомергә кеше өлешенә кермәдем,— диде Зыятдин карт.— Сездән соң, кем әйтмешли, мирас булып оныкларыгызга калыр. Ә минем авыл — менә шушы.— Ул бар кан тамырлары, җепселләре, сөякләре беленеп торган кулын изәп атауга күрсәтте.— Үлгәч тә шушы атауда гына күмәрсез. Мин үлгәч, тегермәннән үч алмагыз. Истәлеккә калсын! Васыятем бу минем, кияү!

Шулчак Зыятдин карт кисәк кенә тынычланып калгандай булды. Әйтерсең ул үз язмышының очына чыгып җиткән иде.

Алар икесе дә, әле яңа гына сугышып, инде хәзер ничек килешергә белми торган малайлар кебек, бер-берсенә карарга да кыенсынып, шактый вакыт тик тордылар. Зыятдин карт галошларын сөйри-сөйри койма буена килеп сөялде дә суга караган килеш, авыз эченнән үзалдына гына әйтеп куйды:

— Атау түрендә авылга ямь биреп, үткәннәргә һәйкәл булып торсын... Мирас булып... Сездән генә түгел, миннән дә мирас калырга тиеш ләбаса! Баш очыма иске тегермән ташы куеп, «Бигәшев Зыятдин Арслан улы» дип язарсыз. Кирәк кеше калганын үзе аңлар. Ай куйсагыз да, йолдыз уйсагыз да — миңа барыбер. Анысын үзегезгә карарсыз... Кайсысына лаек дип табарсыз... Бер фикергә килә алмасагыз, икесен бергә куйсагыз да ярый.

Зыятдин карт артка борылды да, Тимерханның барлыгын бөтенләй оныткан кебек, үзалдына сөйләнә-сөйләнә ишегалды түренә таба атлап китте. Тимерхан, сүзсез генә аның артыннан карап торгач, кырт борылып капкадан чыкты. Мондый тупаслыкны күптән күрмәгән атау капкасы, шапылдап ябылудан селкенеп, ыңгырашып куйды.

Ихтыяр бабасының әле артына, әле алдына төшеп, сүз катарга тырышып карады, ләкин Зыятдин карт гүя бу дөньядан киткән, гүя ул бернәрсәне дә күрми һәм ишетми иде.

* * *

Мондый хәлләр еш кабатланып торгангамы, әллә малайлыгы беләнме, әтисе белән бабасының чәкәләшеп алуына Ихтыяр шулай да теге вакытта артык игътибар итмәгән, хәтта аны бер җәй үтүгә бөтенләй диярлек истән чыгарган иде. Алдагы елда ул җәй буе тагын атауда мәш килде, тагын тал очларына үрмәләде, тагын бабасына тәрәзә рамнары, көянтәләр, бизәкләр ясарга булышты.

Менә хәзер атауда бер атна яшәү чорында ул кабат үзенең бала чагына, еллар пәрдәсе артында калган үткән тормышына кайткандай булды. Аның инде хәзер күзләре ачыла төшкән, зиһене яктырган иде. Заманында игътибар да итми үтеп киткән вакыйгаларны кат-кат күз алдыннан кичерде, һәр нәрсәнең асылын аңларга теләп уйланды. Үткән гомерен яңабаштан яшәп чыккан кебек булды.

Зыятдин бабасы да шактый үзгәргән, элеккеге кырыслыгын югалтып, күңеле йомшарган. Холкы күндәмләнгән, йомыкыйлыгы кимеп, никадәр ялгыз һәм эчпошыргыч бертөрле тормыш белән яшәвен аңлаган, аның горур-тискәре холкындагы ниндидер бик кирәкле нык кылы өзелгән иде. Ихтыяр, башкала зоопаркындагы моңсу күзле дәртсез арысланны искә төшереп, бабасын тагын да ныграк кызганды. Элек әле ул читлеккә яңа эләккән сыман ярсу да, сәер дә иде. Элегрәк аңардан, арысланнан өреккән кебек, куркалар да, шикләнәләр дә һәм шул ук вакытта, яратмыйча гына булса да, исәпләшәләр, хәтта ни дәрәҗәдәдер хөрмәт тә итәләр сыман иде. Ә хәзер ул, иске уенчык сыман, караватта тик ята.

Бераз җан кергәч, ул, үз хәленең шактый мөшкел икәнен төшенеп булса кирәк, элекке кыяфәтенә керергә тырыша башлады. Ишегалдын, өйне, каралты-кураны тәртипкә китерергә тотынды. Ихтыяр аның һәр хәрәкәтенең мәгънәсен аңлап, читтән генә карап торды, ул эшләгән эшләргә катнашмады, үз шөгыле белән мәшгуль булды: су алып кайтты, ашарга пешерде, табак-савыт юды. Мичкә якты. Эше беткәч, ишегалды уртасындагы бүкәнгә утырды да тын гына бабасын күзәтте. Аңа, ни әйтсә дә, Зыятдин картның терелеп җитмәгән күңелен рәнҗетердер сыман тоелды. Шуңа күрә Ихтыяр аның болай да ялтырап торган ишегалдын себереп маташуына да сүз әйтмәде, сап-сары такталы өй идәнен юарга җыенганын

күргәч, чүпрәген алып җиңнәрен сызганды да үзе үк юып чыгарды. Бабасының күңеле тыныч түгеллеген, тирә-юньдә тәртип урнаштырып, шул тәртипкә карап юанганын, куанганын сизенә иде ул.

Өй тирәсен карап-җыештырып бетергәч, бабасы аягын бөкләп ишегалды читендәге имән бүрәнәгә утырды. Ниһаять, аның йөзенә канәгатьлек төсе чыккан, тәненә дәрт тула башлаган иде. Ихтыяр бабасының сизелер-сизелмәс алсулык йөгергән ябык яңакларына, очкыннар кабынган коңгырт күзләренә, кара кәләпүше астыннан яктырып күренгән кыска чәчләренә, килешле итеп кырылган мыегына, түгәрәк сакалына карап, беренче күргәндәй, сокланып торды. Бабасы чын-чынлап терелеп җиткән, кыяфәтеннән тирә-юньгә җылылык тарала кебек иде. Менә ул, уч төбе белән койма буендагы бүрәнәгә сугып, Ихтыярга эндәште:

— Кил әле, улым, яныма утыр.

Ихтыяр колач җитмәс юан бүрәнәнең эре сырларыннан бармагы белән йөртә-йөртә бабасына карап торды, аннары, малай чагындагы сыман, бүрәнәгә сузылып ятып, ияге белән учларына таянды.

— Бетереп кайттыңмы, улым? Бөтенләйгәме? — дип, атна эчендә беренче тапкыр үз борчуларын бер читкә куеп, Ихтыярның хәленә керергә булды бабасы. Әйтерсең моңа кадәр авыру белән көрәшеп, ул Ихтыярны бөтенләй күрмәгән яисә күреп тә бу сорауларын киләчәккә, терелгәч әйтергә саклаган иде.

— Озак калмады. Ай ярымнан диплом алам.— Бабасына карамыйча, бүрәнә белән сөйләшкәндәй, битараф кына җавап бирде Ихтыяр.

— Әниең бик көтә инде. Картайган көннәрендә синнән башка таяныр терәкләре юк бит аларның.

— Безнең әткәйнең картаерга исәбе юк кебек, шөкер.

— Картлык сорап йөрми,— дип көрсенде Зыятдин карт.— Әтиеңне хәзергә эш картайтмый. Пенсиягә чыкса, иртәгә үк картая башлый ул. Чабыш аты тиз картая, diләр...

— Чабыш аты тиз картая торган булса, син картаер идең инде, бабай. Сиксәнне узып та бирешмисең бит әле.

— Бирешәбез шу-ул,— дип офтанып алды карт.— Аннары... Әтиең белән мине янәшә куйма син. Ул чабыш аты булса, мин — эш аты, йөк аты. Егерменче елларда тирә-юньнең күз өстендәге каш сыман кешеләре идек без.

Дөнья тоткасы безнең кулда чакта дуслар да, туганнар да күбрәк сыман иде. Менә картайган көнемдә бер ялгызым калдым.

— Синме ялгыз? Ә мин? — дип үпкәләгән кыяфәт алды Ихтыяр.

— Бер сине әллә ничәгә бүлеп булмый шул. Әти-әниеңнең күңелләрен күрә алсаң, бик җиткән. Минем малайлар ел буена бер хат та язмыйлар. Тәмам күңелләре бизде, ахрысы. Үземне түгел, аларны кызганам мин, алар өчен борчылам. Минем аркада, «кулак баласы» дип, аларның канына тоз салдылар. Пионерга алмагач, олысының мәктәптән үкереп җылап кайткաны әле дә күз алдыннан китми. Ул сабыйларның совет хөкүмәте алдында ни гаепләре булгандыр?

— Чакырып язганың бармы соң?

— Чакыру түгел, аркан белән тарттырсаң да, кайтмый инде алар хәзер. Хатыннары, балалары бар. Тормыш коргач, утырган урыныңнан кузгалу авырая ул.

Ихтыярга бу сүзләрне бабасы махсус аның өчен сөйли, үзенең уллары турында искә алу белән бергә аны да искәртә сыман иде.

— Кайтып дөрес иткәнсең,— диде ул, Ихтыярның уйларын белгән кебек.— Картайдык без, искердек.

— Мине бөтенләйгә кайтты дип кем әйтте әле?

— Беркем дә әйтмәде. Күңелем сизде. Туган авылы кырында гына шәһәр салуларын күрә торып, җаны түзмәс, ничек тә шунда кайтыр, дип уйладым. Җан тартмаса, кан тартыр, дидем. Һөнәрең дә бик кирәкле һөнәр бит. Безнең якка тарткансың... Безнең нәсел гомер-гомергә төзүче булган, балта остасы...

— Яшь чакта бераз дөнья күрергә тиеш кеше. Туган якка кайтып төпләнергә беркайчан да соң түгел.

— Һәр эшне үз вакытында эшләргә кирәк, улым. Аннары соң була ул. Аннары... дөнья күрүне яңа җирләр күрү, дип кем әйтте сиңа? Дөнья кайда да бер ул, кешеләр генә төрле, кешеләр генә бүтән. Исән чакта эш күрсәтеп калырга кирәк, эш! Зур эшләр эшләнгән җирдә дөнья да зуррак, кешеләр дә олырак була. Ил буйлап чатыр чабып бәхет эзләр чаклар үтте хәзер. Читтә тапкан бәхет — бер атналык тәхет кенә ул: бүген бар, иртәгә юк. Туган җирдә тамыр җибәрергә тиеш кеше.

Ихтыяр, авызына капкан коры үлән сабагын чәйнички чәйни, бүрәнә өстенә чалкан әйләнеп ятты. Зәңгәр күк-

нең тирәнлеген кеше күзеннән яшерергә тырышкандай, соргылт болытлар ишелеп ага. Әйтерсең болытлар, чиксезлеккә чумып онытылган кешеләрнең хыялын чикләп, аларны җиргә карарга, җир борчуы белән борчылырга, җир шатлыгы белән шатланырга, җир язмышы белән яшәргә өнди, хәтта шуңа мәҗбүр итмәк була иде. Аяз көнне кешенең уйлары югарырак, хыяллары биегрәк була, зәңгәр күккә карап торган чакта ул дөнья мәшәкатьләреннән беразга булса да арынып тора, чистарынып, күңеле яктырып кала. Ә болытлы көнне үз кабыгына кереп бикләнә, күбрәк үз бүлмәсе, үз өе, үзенең көндәлек эшләре белән мәшгуль була. «Аяз көнне җирдә җинаятьләр азрак кылынмыймы икән? Бу турыда берәр статистика мәгълүматы释бармы, беләсе иде...» — дип уйлады Ихтыяр. Болытларга карап озаграк яткан саен, аның уйлары да катлаулана, болгавыррак була бара иде.

— Улым, Ташлыяр авылы калыр микән?

Бабасының сак әйткән сүзләре аны сискәндереп җибәрде.

— Ничек?..

— Бу... яңа каланы килбәтсез зур булачак, диләр бит. Ташый-ташый Ташлыярны басып китмәсме, дим.

— Белмим... Шәһәрнең генераль планында ничек каралгандыр бит. Мин үзем калмас дип уйлыйм.— Ихтыяр тамагын каты итеп кырып куйды да, кемнәрнеңдер гаебен акларга теләгән сыман, ашыга-ашыга сөйләп китте: — Аннары авылны калдырам дип, шәһәрне шәрә тау башына салып булмый бит инде, бабай! Үткәнгә карап күз яшьләре сыгып утырып булмый. Читән башына менеп, үз кетәклеген мактап кычкыручылар күп булды. Ләкин заман аларны тыңламады, заманның үз законнары, үз юлы, үз проблемалары дигәндәй. Заманга масштаб кирәк аңа, киңлек, биеклек кирәк! Хуш, авылым...

— Нәрсә? Нәрсә? Аңлаешлырак итеп сөйлә әле, татарча сөйлә...

— Бер шофер утыртып алып кайтты мине. Күрше авылныкы үзе, Каенсардан... Юл буе шул бер җырны җырлады: «Хуш, авылым, сау бул...»

— Каенсарны су басты түгелме соң?

— Басса, кешеләрен басмады бит, кешеләре исән калды.

— Үзең исән була торып, авылыңны суга бастыргач, яшәвең ни дә, яшәмәвең ни... Туктале, улым, башкала-

дан әллә алыштырып кайтарганнар инде үзеңне?! Әллә ниткән киреле-башлы сүзләр кыстырып сөйлисең.

— Урбанизация, бабай. Техника заманы, фән чоры, шәһәрләр патшалыгы, дигән сүз ул. Киләчәктә авыллар бетәчәк. Көнбатыш илләрендә авылларның эзе дә юк хәзер.

— Таптың чагыштырыр нәрсә! Нигә безне алар белән чагыштырырга ди әле? Аларда катык юк, бездә бар, аларда чәкчәк юк, бездә бар. Авыл белән дә шул ук хәл. Бетми ул авыл, бетмәячәк. Бөтен җирне актарып бетереп, шул шырпы капларыгызны тезеп чыгарсыз чыгуын. Ә аннары, ачтан койрык чәнчи башлауга, яңадан авыллар кора башларсыз. Рәсәйнең терәге — авыл. Авылсыз яши алмый Рәсәй.

— Мин генә уйлап чыгарган нәрсә түгел бу. Урбанизация...

— Туктале, танавыңны корт чаккыры! Гүрбаниция дә гүрбаниция. Ә Каенсарны, Имәнлекне, Акчишмәне су астында калдыру да шул гүрбаницияГә керәме?

— Син тегермән буасын бугач, бер нәрсә дә су астында калмаган идеме? Елап-каргап йөрүчеләр булмадымы үзеңне? Дөнья — куласа, бер басмаса, бер баса, дисең бит үзең. Менә хәзер безнең авылларга чират җитте.

— Таптың чагыштырыр нәрсә! Биш-алты кешенең бакча башын басты да, Корчаңгы Әхмәйнең мунчасын күчерергә туры килде.

— Кәләпүшеңне салып уйлап карасаң, хәзер дә шул ук хәл. Бары тик колачлар гына бүтән. Бу ГЭС синең тегермәнеңнән миллион тапкыр зуррак дип санасак, йөз илле мең гектар болыннарны, басуларны су басып, ике йөз авылны күчерү гадәти хәл булып чыга түгелме?

Зыятдин карт, Ихтыярның сүзенә җавап таба алмыйча, тамак кыргалап куйды.

— Коры сүз тамакны ерта. Әллә чәйләп алабызмы, улым? — дип урыныннан торды ул.— Терелсәм, ишегалдында самавыр куеп чәй эчәрмен, дип адарынган идем.

Ихтыяр, өйдән самавыр алып чыгып, тиз генә тергезеп җибәрде. Ул чәй-шикәр әзерләп йөргән арада, самавырга җан кереп, тамак төбеннән чыккан салмак-нечкә аваз белән җырлый ук башлады, тиздән пошкырып кайнап та өлгерде.

— Син ул таш әрҗәндә болай рәхәтләнеп, чирәмгә ятып чәй эчә алырмын, дип уйлыйсыңмы? Кеше җирдә туган

икән, җирдә яшәргә тиеш,— дип, шикәр кетердәтә-кетердәтә, бер көйгә әкрен генә сөйләнде Зыятдин карт.— Канатлы кош кына агач башына оя кора. Нигә дип адәм баласы әллә ничәнче ятажда, күктә яшәргә тиеш әле? Җиргә аяк терәп, җир җылысын тоеп тормагач, нинди ныклыгы булсын аның?

— Җир җитми, бабай, җир,— дип каршы төште аңа Ихтыяр.— Һәркем үзенә аерым йорт сала башласа, кайда иген игәр идең?

— Моңа чаклы җиткән бит әле.

— Сугыштан соң гына да безнең илдә сиксән миллион кеше артты. Болай барса, берничә елдан өч йөз миллионны узып китәчәкбез.

— Фәрештәнең «Амин» дигән вакытына туры килсен бу сүзләрең, улым. Тагын сугыш-мазар чыкмаса, диген.

— Сугыш булмый хәзер! — дип ышаныч белән әйтте Ихтыяр.— Көчләр һаман шулай тигез булса, беркайчан да сугыш булмаячак. Үзенең дошманнан көчле икәненә ышанмыйча торып берәү дә сугыш башларга кыюлык итмәячәк. Тигезлекне генә югалтмаска кирәк безгә.

Шулчак инешнең аргы ягыннан бар атауны яңгыратып кычкырган тавыш ишетелде. Ул тавыштан өянке башында чыр-чу килгән чыпчык көтүе пырхылдап очып китте, әйтерсең өянке кинәт кенә йокысыннан уянып, пырхылдап көлеп җибәрде.

— Их-ты-яр! Их-ты-яр!

Инеш буена туктаган машина кабинасыннан ярты гәүдәсе белән чыккан шофер егет тырышып-тырышып кул изи, үзе, ут капкан сыман, берөзлексез кычкыра:

— Ихтыяр, сиңа йомыш төште! Иртәгә без идарә янында митинг үткәрмәкче булабыз. Табигатьне саклау, туган якны, авылларны саклау турында. Әзерләнеп беттек инде без. Тик митингта төпле итеп чыгыш ясарлык ораторларыбыз азрак.

— Дөрес эшлисез. Күптән кирәк иде, су басканчы ук,— дип, шофер егетнең сүзләрен куәтләде Ихтыяр.

— Алайса, риза? — дип авыз тутырып елмайды егет.

— Нәрсәгә риза?

— Митингта катнашырга инде. Сине шунда чакырырга килдем бит.

— Безнең авылны да су басамыни?

Шофер егет, гаҗәпләнгән сыман, Ихтыярга сүзсез карап торды.

— Ә сиңа үз авылың гына кадерлемени? — дип усалланып сорау бирде ул кинәт кенә.— Безнекен баскан инде, безнекенең язмышы хәл ителгән. ГЭС төзелеп беткәч, суны тагын алты метрга күтәрәчәкләр, ди. Димәк, тагын йөзләгән авыл су астында калачак. Шушы атаудан башка бер нәрсә дә кирәк түгелмени сезгә?

Егет бу сүзләрне Ихтыярга гына түгел, ә аның янәшәсенә чыгып баскан Зыятдин картка да атап әйтте сыман.

— Нәрсә анда көпә-көндез сөрән саласың? — дип сүз ташлады аңа Зыятдин карт.— Йомышың булса, кереп сөйләш.

Шофер егет ике кулын җәеп, ярларына тулып аккан суга күрсәтте.

— Керерсең сезгә!

— Шулай булгач, Ихтыярны ничек алып чыкмак буласың моннан?

— Кергән җиреннән чыга да алыр...

— Анда барып нишләрмен соң мин? — диде Ихтыяр, риза булып та, чарасын таба алмаган сыман.

— Авылларны саклап калуның — халыкны, аның гореф-гадәтләрен саклап калу икәнен сөйләрсең.

— Үзең дә беләсең бит... Нигә үзең генә сөйләмисең?

— Минем грамыт җитми. Син төзүче буларак, инженер буларак сөйлә. Мин инде егетләргә сине килә, дидем. Теге көнне бергә кайтканда туган яклар турында яратып сөйләгән идең. Безне яклап авыз ачып сүз әйтерлек инженерлар юк анда. Инженерларның да, башлыкларның да күбесе читтән килгән.

— Читтән килгәнгә синең читән казыгың кирәкми,— дип җөпләде аны Зыятдин карт.— Кыра, җимерә, аннан-моннан йорт утыртып куя да ары китеп бара алар. Ә безгә — монда яшисе...

Зыятдин карт бер караганда шофер егетнең Ихтыярны алырга килүен өнәмәсә, икенче караганда күңеле белән аның ниятен хуплый иде. Ул инде атна дәвамында онытына ияләшеп беткән, ялгызлыктан алҗыган җанына аның һәрчак монда булуы кирәк иде. Ихтыяр әле бабасының үҗәтлек сеңгән моңсу йөзенә, әле аның эшләпәсе төсендәге яшел түбәле, һәрчак ачык ишекле йортка, әле атау читендә каралып күренгән тегермән белән яргычка, инешнең текә яры өстенә салынган сушилкага карап, бер карарга килә алмыйча икеләнде. Аннары кисәк кенә башын күтәреп, офык түрендә түбәсе болытларга

ышкылып торган сөттәй ак йортларга, сәгать укларына охшаган краннарга текәлде дә сүзсез калды. Аяклары, бөтен тәне белән шушы җиргә, шушы атауга берегеп өлгергән булса да, күңеле белән ул анда — ак каланың ак йортлары арасында йөри иде. Менә Ихтыяр, уйларыннан арынып, егеткә кул изәде:

— Исемең ничек әле синең, Хуш, авылым?

— Рафаэль. «Ра»сын алып ташладым мин аның. Тур Хейердалга бирдем. Авылда Фаил дип йөртәләр иде.

— Нишләп «иде»?

— Әйттем бит инде, авылны су басты, дидем.

Нәрсә генә сөйләшсәләр дә, һаман шул бер сүзгә, бер нәрсәгә килеп төртелүләрен күреп, Ихтыярның чын-чынлап ачуы чыга башлаган иде. Институтта биш ел буена аларны яңа проектлар төзергә, яңа шәһәрләр, промышленность комплекслары кору эшенә өйрәттеләр. Хыял җитмәслек шәһәрләр, бакчага күмелеп утырган проспектлар, хан сарайларын көнләштерерлек театрлар, культура йортлары, спорт сарайлары турында көннәр буе да, төннәр буе да уйлады, хыялланып бетте ул, ә менә җирдә Каенсар, Имәнлек, Акчишмә авыллары булуын, аларда да үзе шикелле үк кешеләр яшәвен, зиратлардагы гасырлар җиле ашап бетергән кабер ташларын нигәдер искә дә төшермәде. Бар нәрсә дә дөньяга яшәр өчен килә, һәммә нәрсәнең, кешеләрнең генә түгел, җансыз затларның да, дөньяда яшәргә хаклары бар. Ә авыл кешеләре белән бу турыда киңәшкән, алар белән исәпләшкән, аларның ризалыгын сораган кеше бармы монда? Бәлки, мин ялгышамдыр, бәлки, Фаил кебек күңеле рәнҗегәннәр берән-сәрән генәдер? Ни әйтсәң дә, шәһәрдәге яшәү шартлары авылныкыннан күпкә яхшырак, менә дигән квартираларга күчәргә кем риза булмас икән?

— Мин киттем. Егетләргә нәрсә дим? — Фаил, кузгалырга җыенып, машинасын кабызды.

— Бер Ихтыярга терәлеп калмагандыр бит дөнья? Әйт үзләренә, вакыты җиткәч, үзе килер, диген.— Зыятдин карт, тизрәк юлыңда бул дигәндәй, Фаилгә ашыгып кул селтәде.

— Кергәндә кердем дә менә чыгып булмый бит әле.

Ул әле менә хәзер, Фаил килеп чакыргач кына, үзенең ничек кешеләрне сагынганын, үткән-сүткән карт-корыларга, бала-чагаларга сәлам бирә-бирә авыл урамнары буйлап йөрисе килгәнен, еракта ымсындырып торган шәһәр төзелешен тизрәк барып күрергә теләгәнен аңлады.

Атауда баштагы өч көн сизелми дә диярлек үтеп китте. Ул көне-төне бабасының баш очында утырды. Сораган бер әйберсен алып бирде, өстәл өстеннән тәүлек дәвамында кайнаган самавыр өзелмәде, алар сорашып-сөйләшеп туя алмадылар. Дүртенче көндә, бабасы аякка басып ишегалдына чыккач, шунда ук баштанаяк йорт-җир мәшәкатьләренә кереп чумдылар. Башта орлыкка диган бәрәңгене өйалды идәненә тараттылар, искергән сыерчык ояларын сипләп яңарттылар, ишегалдының куләгәле ягындагы бозны лом белән ватып кояшка тараттылар. Дөрес, бар эшне Ихтыяр берүзе эшләде, бабасы бары тик өйрәтеп, киңәш биреп кенә торды. Ләкин ул шуннан да ләззәт таба, зур эш кырган сыман бөтен күңеленнән сөенә иде.

Куллары эш белән мәшгуль булса да, Ихтыярның күзләре һәрчак диярлек инешнең аргы ягында иде. Эштән туктаган саен атау читенә килеп баса да сәгатьләр буе онытылып тик тора.

— Кил әле, улым, кул тимәгән тагын бер нәрсә көтеп тора икән бит әле безне,— дип яратып кына чакырып ала аны бабасы.

Көндезләрен шундый вак-төяк мәшәкатьләр белән тарта-суза уздырса да, кич җитте исә күңелне сагышлы моң сара башлый. Аптырагач, ул атаудан чыгу өчен берәр җайланма ясау турында да уйлый башлаган иде, бабасыннан уңайсызланып кына туктап калды...

Шушы бер атна эчендә Ихтыяр шактый йончыды. Бабасының йокысы бик начар, ул йокламагач, Ихтыяр да ятарга кыенсына. Көннәр үткән саен, ул Казан турында, Зәлия турында ешрак уйлый башлады. Беренче көннәрдә хәтта ул аны үзе кайтып төшәр дип тә көткән иде. Тора-бара аның кайтмасын аңлады, ул гына да түгел, шушында торып калса, Зәлия аны бөтенләй онытыр, бер тапкыр да исенә төшереп карамас кебек иде. Шактый икеләнеп йөргәч, беркөнне ул Зәлиягә хат язарга җыенды. Матча ярыгына кыстырып куелган җирдән карандаш белән бер бит саргайган кәгазь алды да өстәл янына барып утырды. Мич артындагы чикерткәләр аны үртәп кычкыралар, тәрәзә артында кул сузымы җитәрдәй якын булып күренгән тулы битле ай авызын ерып туп-туры аңа карап тора. Ул, малайларча, айга тел чыгарып күрсәтте дә ашыга-ашыга язарга тотынды.

— Конверт кирәк иде,— дип, иртән чәй эчкәндә бабасына сүз катты ул.— Хат язган идем.

Зыятдин карт шикәр кетердәткән сыман әкрен генә кеткелдәп куйды.

— Сагындырамы?.. Каян килсен монда конверт? Солдаттан кайтканнан бирле кулга кәгазь-каләм алганым юк. Кирәк кәгазьләрне дә Грамытный Гайфетдиннән яздырам. Балтага ныграк ята минем кул.

Ихтыярга утрау тагын да караңгыланып, тагын да ныграк күңелсезләнеп киткәндәй тоелды.

— Юк белән маташып йөрим. Конверт тапсаң да, ничек итеп җибәрәсең аны моннан? Почта күгәрченнәре юк бит,— дип сөйләнә-сөйләнә, карандаш белән кәгазьне яңадан матча ярыгына кыстырып куйды Ихтыяр.

...Шулчак Фаилнең риясыз яңгыравыклы тавышы аны иләс-миләс уйларыннан айнытып җибәрде:

— Чыннан да килеп алыйммы? Менә бабай да җибәргә каршы түгел. Мин түгел, син башлап йөрергә тиеш бу эшне...

— Нишлим, бабай?

— Чыга алырсыңмы соң моннан? Чыга алсаң, бар...

— Кирәк икән, ишегалды уртасына вертолет төшербез! — Фаил кабина ишеген шапылдатып япты да машинасын үкертеп китеп барды.

Урамның як-ягында бер-берсенә сыенышып утырган авыл өйләре куркынышып, калтырап куйдылар. Каршыдагы йортның капка төбендә колакларын шомрайтып торган көчек бар көченә ләң-ләң килеп машинаны куа китте.

* * *

Зыятдин бабай ике кулын артка куйды, шактый вакыт арлы-бирле йөргәч, өйгә керде, су буена төшеп менде, мунчаны карап чыкты, лапастагы коралларны урыннарыннан алып яңадан тезде. Әле кичә генә Ихтыяр белән түр тәрәзәгә дип ясаган рамнарны, куярга җыенгандай, өй кырыена китереп сөяде. Ул инде Ихтыярның монда, янәшәдә булуына шулкадәр күнегеп өлгергән, аның тиздән китәсенә, үзенең тагын мәңгелек борчулары белән бергә шушы атауда япа-ялгыз каласына ышанасы да, моның белән килешәсе дә килми иде.

— Берничә көннән су да эзенә төшәр инде. И-их, бу яшьләрне! Бер урында бәйләп тә тотып булмый шул сезне! — дип яратып кына сукранды карт.— Кара аны, чыгу белән туры шәһәргә чапма.— Аннары сүзен болай дәвам

итте: — Карап торам-торам да, җир сөрергә дә, шәһәр салырга да җыенган кешегә охшамыйсың әле. Казан ягына табан ялтыратырга гына исәбең. Кул сузымы җитәрлек җирдә шәһәр салынганда, ничек җаның түзеп ятасыңдыр ул Казанда?

Бүртеп кабарынган соргылт тал бөреләре арасыннан күңелне кытыклап күренеп торган яңа шәһәр манзарасы, җанны җилкетеп гөрелдәгән төзелеш шау-шуы соңгы көннәрдә тәмам тынычлыгын алган иде Ихтыярның. Әгәр дә мөмкин булса, ул хәзер үк инешне сикереп чыгып, басу юлы буйлап туп-туры шул якка йөгерер иде.

Ишегалды буйлап үз-үзенә урын таба алмыйча, арлы-бирле йөргән Зыятдин карт, озак эзләгән әйберен тапкандай, барган җиреннән туктап калды да бөтен ишегалдын яңгыратып Ихтыярга эндәште:

— Әниең сине өйләнергә йөри, дигән иде? Дөресме шул?

— Өйләнү... Өйләнеп кенә бирәр эш кырып булса икән бу дөньяда!

— Өйләнеп, башлы-күзле булып кайтсаң да, начар эш түгел. Өйләнгән кешегә ирләр акылы керә, төпле акыл.

— Киленегез буласы кешенең бер дә бу якларга кайтасы килми шул. Һәркемгә үз туган җире кадерле.

— Яратса, кайтыр. Яратмаса, үзенә карый инде.

— Өч бүлмәле фатирларыннан аерылып китмәс шул.

— Минем йорт аларның таш капчыкларыннан начармы әллә? Бергәләп кайтыгыз да шушында гына торыгыз! Йорт-җир иркен, атавыбыз, Аллага шөкер, оҗмах бакчасына тиң. Бераз карап, тегермән тавы итәгенә алмагачлар да утыртып җибәрсәң! Мин сезгә комачау итмәм. Миңа хәзер бернәрсә дә кирәкми. Атауның теге ягындагы мәңгелек йортка барырга да күп калмагандыр... Йортка, атауга хуҗа булыр идең... Кемгә ышанып калдырыйм мин аны?

— Мин монда кайтып төпләнсәм, эткәй нәрсә дияр соң? — Ихтыяр бабасына карап алды.— Алар да картаеп килә. Казан да ерак җир түгел. Ай саен, бәйрәм саен кайтып йөрергә була. Әллә нигә бер кайткан кеше кадерлерәк тә була әле ул...

— Шулайдыр... Шулайдыр...— дип, авыз эченнән көрсенеп кабатлады Зыятдин карт.

Ихтыяр, күңеленә оялый башлаган икеләнүле хисләрдән котылырга теләп, савыт-саба җыештырырга тотынды. Бабасы аның уйларының читтә — еракта икәнен си-

зенеп, Ихтыярның бары тик аны рәнҗетмәс өчен генә акланып сөйләвен, соңгы атнада пәйда булган соңгы өмет кошының да тавышсыз-тынсыз очып киткәнен күреп, кара кәләпүшен батырып киде дә, кулына себерке алып, болай да ялт итеп торган ишегалдын себерергә тотынды.

Соңгы таянычы булган Ихтыярга бу мизгелдә хәтере калган, аңа рәнҗегән иде ул. Кәефе киткәнен сиздермәскә тырышып, Зыятдин карт бөтен үчне себеркедән алды. Үзе себерде, үзе эчтән генә моннан ары беркемнән бер нәрсә сорамаска, беркемгә бер үтенечен белдермәскә иман яңартты.

Ихтыяр аны ялгызын гына калдырып өйгә керде. Стенадагы фотоларга, ишек кашагасы өстендәге шәмаилләргә, чөйдәге мылтыкка, өйгә нур биреп торган олы ак мичкә карап ятты. Җанына тынычлык тапмагач, сандык өстендәге тальян гармунны тартып, җырлап та карады. Әллә инде Фаил күңелен кузгатып киткәнгә, әллә инде бабасы белән сөйләшүдән соң, ул атауда үзенә урын таба алмый, мөмкин булса, хәзер үк бу әсирлектән чыгып качар хәлгә җиткән иде.

Ул чоланга чыкты, каклаган каз алып кереп, өстәлгә ваклап турап куйды. Йомырка пешерде, әле суынып та җитмәгән самавырны яңартты. Аннары, бабасына сүз катарга җай чыгудан куанган сыман, тәрәзәдән кычкырды:

— Бабай, ташла себеркеңне! Чәй яңарттым. Кер тизрәк!

Зыятдин карт себеркесен коймага сөяп куйды, теләр-теләмәс кенә өйгә таба атлады. Өстәл янына килеп, аягүрә баскан килеш бераз уйланып торды да, команда биргән кебек, кырыс тавыш белән әйтте:

— Төйнә бөтен ризыгыңны! Шушындый ямьле яз көнендә өйдә пышлыгып утырып булмас. Һава җитми башлады әле миңа бу өйдә... Киттек, улым, тегермән буендагы чирәмлеккә, җәйрәнгә төшеп утырыйк. Җәймә ал, ризык-әукатләрне күбрәк төйнәсәң дә ярый. Ә каклаган казга теш үтмәс шул минем.

Бабасының саубуллашыр алдыннан гына шулай күңеле кузгалуын, хискә бирелүен бигүк өнәп бетермәсә дә, ул аңа каршы төшәргә, аны юатырга кыймады.

Тегермәнгә аркасы белән терәлеп үк үскән карт өянке ышыгына җәймә җәеп азыкларны тараткач, Ихтыяр чирәмгә чүгәләп утырды. Ә бабасы, нәрсәдәр эзләгән кеше шикелле җиргә иелгән килеш, һаман арлы-бирле йөре-

нә. Әле тегермәннең муртайган бүрәнәләренә таягы белән суккалап куя, әле аяк астындагы чыбык-чабыкны бер читкә алып ташлый, әле яргычның капка хәтле ишеген шыгырдатып ача да эчкә кереп тора. Менә ул яргыч ишеген зур йозакка бикләде дә, таягына таянып, тегермәнгә күтәрелеп карады.

— И-их, шушылай коргаксып утырсын дип салган идеммени мин сезне? — диде ул, авыз эченнән генә сөйләнгәндәй итеп.

Яр читенә үк терәп салынган тегермәннең бүрәнәләре, яңгырдан каралып, тимер төсенә кергән, такта түбәсе тимгел-тимгел күгәргән, урыны-урыны белән яшькелтем мүк белән капланган. Уң ягыннан яртылаш тышка чыгып торган калаклы зур тәгәрмәченә карагач, иске тегермән Ихтыярга Том Сойер маҗараларындагы борынгы пароходка охшап күренә башлады. Әйтерсең ул илләр-җирләр гизеп йөргән-йөргән дә арып-талып мәңгелеккә шушы атау читенә килеп туктаган. Ялгыз тегермәнне кочагына алган карт өянке аны чит-ят күзләрдән, җил-давылдан саклап тора сыман.

Бабасы чыкмагач, Ихтыяр тегермәнгә керде. Эчтә дөм караңгы, кечкенә тәрәзәдән төшкән яктылык еллар буена куерган тыгыз караңгылыкны тарата алмый. Бабасы, тегермәнне хутка җибәрергә җыенгандай, кыштыр-кыштыр килеп өстә маташа, әле бер нәрсәсен алып карый, әле икенче нәрсәсен борып куя, үзе бертуктаусыз авыз эченнән мыгырдана:

— И-их, каһәр суккырлары! Сез генә җитмәгән идегез монда! Тегермәнгә канычучылар сездән башка да буа буарлык! Инде кырык ел элек коргаксыган тегермәннән нинди ризык таба аласыздыр?

— Нәрсә булган? Кем бар анда, бабай?

— Тычкан белән күседән котылыр әмәл юк. Мөшкәнең яртысын кимереп бетерә язганнар. Тәбе дә куеп карадым үзләренә. Институт бетергәннәрмени, башлылар, каһәр суккырлары, кагылып та карамыйлар.

Зыятдин карт күлмәк-чалбарыннан тузанны кага-кага тегермәннән чыгып табын янына утыргач та, Ихтыярның монда икәнлеген оныткандай, һаман үзалдына сөйләнде. Әйтерсең шулай итеп чуалган уйларының очына чыгарга, ничә ел эзләп тә җавап ала алмаган сорауларына, ниһаять, менә бүген җавап табарга тырыша кебек иде ул.

— Әрәм ага сулар... Тегермән ташын әйләндерәсе сулар әрәм ага. Аяк астында яткан алтынны күрмичә, әллә каян эзлибез шул аны...

Ихтыяр артык түзмәде, беркатлы кыяфәт белән аның сүзенә катышырга булды:

— Дөньяда һәрнәрсә үз урынында. Бу су да әрәм акмый, бабай. Шушы кечкенә генә инеш ничә авылга су эчерә, күпме басуны сугара. Аннары, Иделгә коеп, ГЭС куласасын әйләндерә, безнең өчен ток бирә.

— Элек-электән су сибеп үстермәгәннәр безнең якта игенне. Әллә нинди юк нәрсәләр уйлап чыгаралар. Күпме җирне бозып бетерделәр. Җир көчләгәнне яратмый ул. Ашласаң, кадерен күрсәң, бирәсен бирә. Артыгын бирә алмый. Бер ел көчләп алсаң, икенче елны үч кайтара. Тора-бара бөтенләй кысыр калуы да бар. Әнә, ферма буендагы иң яхшы җирне алты ел рәттән кукуруз чәчеп бөтенләй эштән чыгардылар бит. Канын суырдылар җирнең. Ә син әллә нинди ГЭСлар турында сөйлисең. Ул станция әллә кайда, ә без — монда. Үзебездә булдырырга кирәк, үзебезнең җирдә үзебез хуҗа булырга кирәк. Шушы инешнең куәте җитеп ашкан безнең авылга.

— Ил күләмендә уйламыйсың син, бабай,— дип, чынаякларга каты итеп чәй ясады Ихтыяр.— Сиңа инеш кадерле булса, безгә Идел дә шулай ук кадерле.

— Зур суга кушылгач, инешнең инешлеге бетә. Шуңа күрә инеш чагында матуррак ул миңа. Үзе эшләгән эшнең нәтиҗәсен инеш тә күрергә тиештер. Берүзе генә шушы тегермәнне әйләндереп утырасы, яргычта ярма ярдырасы, маймычлар куыштырасы, бала-чага чыр-чуын ишетәсе килә аның. Ил күләмендә, имеш... Өмә белән өй күтәргәнең бармы синең?

— ...

— Юктыр шул... Өмәдә бер бүрәнәне унлап кеше күтәрә. Барысы да тигез күтәрә дип уйлыйсыңмы? Шулай булмый гына торсын! Кайберсе җан көченә тырыша, кайберсе вакыт үтсенгә генә йөри, берсенең буе озын, бөтен авырлык аңа төшә, икенчесе, бот буйлысы, бүрәнәгә асылынып кына бара. Чынлап карасаң, дүрт кеше иркенләп күтәрерлек бүрәнә булып чыга ул. Менә сиңа бергә-бергә эшләү, менә сиңа — колхоз, күмәк хуҗалык.

— Монысы инде бөтенләй бүтән нәрсә, бабай. Монысы һәркемнең намусына бәйләнгән.

— Намус... Күмәк намус була алмый... Һәркемнең —

үз намусы. Бөтен ил байлыгы — һәркемнең байлыгы, имеш. Ышанмыйм мин үземнең шундый бай булуыма. Биргәндә генә уртак, алганда уртак булмый ул. Ә менә бу атау минеке. Моннан мине куучы да, монда миңа коммунизм вәгъдә итеп, юкка башымны катыручы да юк. Намус, дисең. Революция булганга ничә ел, ә намуслы кешеләрнең чутсыз ишәйгәне күренми. Элек тә бар иде түрәләр, хәзер дә бар... Тик кулыннан эш килгән кеше умырып ала, кешечә яши торган иде. Ә хәзер барысын да тигезләделәр. Шуңа күрә дә авылда кулына балта тотардай кеше бетеп бара. Чиләк төбе дә ямый белмиләр. Һөнәрчеләр бетә — барысы да тигез. Ә элек өй саен оста, урам саен тимерче, ике йортның берендә тегүче була торган иде. Намус, дисең... Арттан давайлап торганда, күзгә ак-кара күренмәгән чакта намус турында уйларга вакыт каламыни?

— Калырга тиеш, бабай! Кешеләр син уйлаганча ук начар түгел. Авылда иләк-чиләк ясаучылар бетә, дисең. Галәмгә кеше очканны, элек сезнең төшегезгә дә кермәгән машиналар ясаганны телгә дә алмыйсың. Менә элек, моннан җитмеш ел элек, шушындый шәһәрләр салып булыр идеме? — Ихтыяр авылның соры йортлары өстеннән яктырып күренгән шәһәргә таба кулын сузды.— Шундый кала корган кешеләрне намуссыз дип әйтә алмас идем мин...

— Тәртәне кирегә каерма, улым, сындырырсың. Сүзләрең бик матур, ызбач Сөләйман шикелле сөйлисең.— Зыятдин карт мыек астыннан хәйләкәр елмаеп куйды.— Инде мең ел җир куенында яткан мәетләрне кузгатып, ата-бабалар нигез салган авылларны куптаралар бит. Шуны яклыйсыңмы син? Шундый шәһәрнең нигезе бәрәкәтле булыр дип уйлыйсыңмы?

— Искене җимермичә, яңаны салып булмый.

— Кем әйтте сиңа бу сүзне? Институтыгызда шулай дип укыттылармы?

Ихтыяр җавап бирмәде, бу турыда сөйләшүнең очы да, ахыры да булмасын, аларның барыбер икесе ике фикердә каласын төшенеп, җирдә яткан шакмакларны алды да самавырга тутыра башлады. Шулай итеп, бу әчпошыргыч әңгәмәгә чик куясы, самавырга гына түгел, бабасының күңеленә дә яшәү дәрте саласы, шаярасы, көләсе, тормыштан ямь табасы килә иде аның. Вакыт үткән саен, ул бабасының күзгә күренеп үзеннән ераклашка-

нын, еллар буе берьялгызы корган серле дөньясына кереп бикләнгәнен тойды; бөтен гәүдәсе белән җиргә елышкан сабыр кыяфәтле йорт та, атау читендә тавышсызөнсез моңаеп утырган тегермән-яргыч та тора-бара үзләренең мәгънәсен югалта, хәтта бөтенләй кирәксез нәрсә булып күренә барды.

Атау аръягындагы урамда машина гүләгән тавыш ишетелде. Ихтыяр шул якка үрелеп карады. Юк, таныш шофер түгел. Ул, күңелсезләнеп кенә, иске хром итек белән самавыр торбасын өрдерергә тотынды. Атна буе атауда ятып, аның янына беркем, хәтта Әхмәт тә килеп карамады. Атауга керә алмасалар, теге яктан торып та сөйләшергә, хәл-әхвәл сорашырга була бит. Димәк, аны якын итмиләр, читләтәләр. Димәк, аның монда беркемгә дә кирәге юк. Шәһәрдә кешеләрне уртак фикер, уртак уй, уртак идеал йөртә... Ә авылда — уртак эш. Эше, йомышы төшмәсә, кешегә кеше керми авылда. Ихтыярның алар белән бергә эшлисе эшләре юк инде, алайса. Ялгызлык... Ялгызлык ул — кешеләргә кирәк булмау, ялгызлыктан авыррак газап юктыр, дип уйлады Ихтыяр.

Атау өстендә караңгылык куера барган саен, басу читендәге ташпулатлардан саркыган сүрән яктылык көчәйде, кран башларындагы, йорт түбәләрендәге прожекторлардан төшкән көлтә-көлтә нурлар күзгә күренеп күбәйде, куәтләнде. Яктылык ишәйгән, авыл артындагы гөрелте көчәйгән саен, Ихтыяр күңелендә тышауланып яткан хисләр ireккә омтыла, аның мускуллары куәт белән тула, тавышы көрәя, йөрәге ярсыбрак тибә иде.

— Синеңчә, менә сез, яшьләр, килгәч, без, карт-коры, дөньядан китәргә тиеш булабызмы? — дип, бабасы аның әллә кая барып җиткән уйларын кире җиргә төшерде.

— Чагыштыруың урынсыз. Ә-әнә, тыкрык буе Гыймазетдин абый яңа өен салгач, искесен сүттеме? Сүтте. Чөнки искесе аңа комачау итә, бөтен каралты-курасын ямьсезләп тора иде. Иске өен сүткәндә жәлләп елап утырмагандыр бит ул? Янәшәдә яңасы, яхшырагы булганда синең искеңә, аламаңа төкерми дә кеше...

— Һе-һем... Таптың сөйләр сүз, таптың мисал итеп сөйләр кеше. Бозау Гыймай нишләмәс ул? Иске өе дә бер дигән иде, хатыны Нәгыймә аркасында гына боздыртты ул аны. «Өйне кыек салдылар да, берләр генә туры коймак пешереп булмый»,— дип, бөтен авылга сөйләп йөргән бит. Бәлешенең төбе көйсә дә, казан төбенә касмак

утырса да, орчыгы караваты астына тәгәрәп кенә кереп китсә дә, телевизорлары юньләп күрсәтмәсә дә, гел шул өй салучыларны гаеп итеп сөйли, Гыймайның колак итен ашый иде. Мәлгунь. Чәр-чәр килгәне атауга хәтле ишетелә, шуның тавышыннан Гыймайның түгел, минем колак тона иде. Гыймайның бер дигән өен сүттереп, яңаны салдырудан башка чарасы калмады. Хәзер Нәгыймә нинди сәбәп кенә табар икән?

— Ә синең үзең турынданиләр сөйләгәннәрен беләсеңме соң, бабай? Дөньяны сүгүдән бушаганың юк. Зарланасың да зарланасың...

— Нәрсә дисең? — Зыятдин карт авызына китергән телемен яңадан табынга куйды.— Авызың нәрсә әйткәнне акылың белеп бетермиме әллә? Кара син аны, әй!..

Бабасы кызган саен, Ихтыярның һаман усаллашасы, нигәдер аны үртисе, берни белән дә җиңеп булмый торган үҗәтлегенә үч итепме, чыгырыннан чыгарасы килә иде.

— Нигә? Туры әйткән — туганына ярамаган, дип үзең сөйли идеңме әле? Кыек атып, туры тидердемме әллә? — Ул, башлаган уенынннан туктала алмыйча, торган саен эчкәрәк керә барды.— Кешеләр белән коймагың пешмәгәнгә, шушы тегермәнне сәбәп итәсең бит син. И-их, бар дөньяны гел үзеңчә генә яңабаштан корыр идең дә, кулыңнан килми. Шуңа өзгәләнәсең, шуңа бүгенге тормыштан ямь тапмыйсың...

— Инде син дә акыл өйрәтә башладыңмы? — дип ачуланып кычкырды Зыятдин карт.— Атаңның кырык ел буе канга тоз салуы гына җитмәгән иде, инде хәзер син тотындыңмы? Инде хәзер син дә минем күңелдә казына башладыңмы? Әнә үз тиреслегегездә казыныгыз! — дип, авылга төртеп күрсәтте ул.— Ә миңа кагылырга берегезнең дә хакы юк!

— Уйлаганым да юк. Бүген монда мин, иртәгә — тегендә. Әлегә кул-аяк бәйләнмәгән.

— Кул-аягыңны тиз кыскартырлар! Әллә кая китә алмассың. Җибәрмәсләр. Син — кирәкле кеше.— Зыятдин бабайның тавышы сөйләгән саен әкренәя барып, озакламый ул бөтенләй пышылдауга күчте.— Менә мин генә... Мин чыннан да бүген — монда, иртәгә — тегендә...

Бу сүзләр Ихтыярның йөрәгенә бозлы энә булып кадалды. Ул, моңа кадәр җыелып килгән бөтен ачуларын онытып, бабасын рәнҗеткәнгә үкенеп куйды. Бөрешеп,

җиргә якынайган гәүдәсен күргәч, күңеле бөтенләй йомшарды, аны юатырга, аның күңелен күрергә ниятләп, янәшәсенә елышып утырды. Ихтыярның сүз агышын тизрәк икенчегә борасы, бабасының күңеленә хуш килерлек сүзләр табасы килә иде.

— Ә бу тегермән ташын кайдан алдыгыз? — Ул теленә килгән иң беренче сүзләрне әйтте дә бабасына карап тын калды.

Зыятдин карт әле һаман үз уйларыннан арына алмый иде бугай, җавап кайтармады.

— Нигә монда чыгарып ташладыгыз аны? — Ихтыяр бабасын урыныннан кузгатырга, яңа әңгәмә башларга тырыша иде.— Юештә бозыладыр бит ул. Монда ятып ярылуы да бар...

— Э-э-э... Әйе.— Зыятдин карт, тегермән ташына кагылгач, сүзгә кушылмыйча булдыра алмады.— Тешәтергә дип урыныннан кузгаткан идек. Сугыш еллары, авылда тәртә каерырлык ир-ат та юк. Минем дә яралар төзәлеп бетмәгән. Төшерүен төшердек, ә кире урынына менгерергә хәл җитмәде. Шуннан калды инде...— Ул тегермән ташын кытыршы куллары белән сыйпады.— Пар ат җигеп Урал хәтле Уралдан алып кайткан идем бит мин бу рәхмәт төшкерене. Ике айдан артык кайттык. Кайтып җиткәнче дүрт тапкыр күчәр сынды, ике тапкыр тәгәрмәч алыштырдык. Инеш суы агар инде ул, тегермән ташын әйләндермәсә дә агар. Менә безнең гомерләр агып бетеп бара. Нәрсә күрдек тә, ни майтарып, ни әйләндердек? Дөньяны әйләндереп салырдай итеп тотынган идек тә, үз башыбызны әйләндерүдән артык китә алмадык. Кая бара бу дөнья, әле һаман белгән юк. Бер ягыннан төзеп киләләр, икенче яктан җимерелеп бара. Ярый, өсбаш, тамак ягына кытлык кимеде, шунысына шөкер. Ә гомер ике килмәс. Ә яңа шәһәргә бер үчем дә юк. Нишләп каршы булыйм, заманында үзем дә шактый төзегән кеше бит. Бу тирә авылларда ике йортның берсе минем кул белән салынган. Шуңа күрә корган-төзегән кешегә рәхмәттән башка сүзем юк. Тик менә без картларның күңеленә дә артык каты кагылмасагыз иде. Безнең күңел өчен дә берәр нәрсә калсын иде бу дөньяда. Нишлисең — шушы читән казыкларына җан береккән. Шулар бетсә, безнең дә кирәк калмас сыман...

Янәшәдә генә инеш шаулап ага. Ул мәңге шулай шаулар, бабасының инеш шавына кушылып сөйләгән сал-

мак авазы да шулай мәңге тынмас, ул җирдә мәңге яшәр кебек тоелды Ихтыярга. Егет, карашын офык читендәге төзелеш утларына төбәгән килеш бабасын тыңлый-тыңлый онытылып утыра торгач, йокыга киткәнен сизмәде.

...Менә Ихтыяр очы-кырые күренмәгән елга ярына килеп басуга, кемдер аны җилкәсеннән этеп суга кертеп җибәрде. Су салкыны аның аякларын өтеп алды, бөтен тәнен калтыратты. Ул, кирегә борылып, судан чыгарга талпынып карады, ләкин әллә кайдан пәйда булган егетләр стена булып тезелеп арттан киләләр, аңа ярга менәргә ирек бирмиләр иде.

Су төбендә авыл капкасы күренде. Камышларны, талларны, су үләннәрен аралап, каршыга йөзгән курку белмәс балыкларны уч төбе белән читкә этәреп бара торгач, авыл урамына килеп керделәр. Шулчак бер егет алга чыкты да бөтен көченә киерелеп гармун тарта башлады. Башкаларга, «Кушылыгыз!» дигән сыман баш кагып куйгач, урам буйлап олы-олы атлап китте. Бары шунда гына Ихтыяр гармунчы егетнең Фаил икәнен танып алды.

Авыл урамы куллары, аяклары, башлары өзелгән курчаклар белән түшәлгән иде. Ихтыяр, аларга басмаска тырышып, егетләр алдыннан атлады. Алар бер-берсе белән кочаклашканнар да ниндидер җыр җырлыйлар, ләкин тавышлары ишетелми иде. «Су астында тавыш ишетелми. Балыкларны менә нигә телсез диләр икән»,— дип уйлады Ихтыяр. Шулчак Фаил аңа борылып карады, йөзен җыерып, йодрык күрсәтте, җырларга кушты сыман. Тик Ихтыяр аның да тавышын ишетмәде, аңламаганын белдереп, иңбашларын гына селкетеп куйды.

Егетләр килеп җитүгә, каршыдагы өйнең тәрәзәләре ачыла, аннан аяк-куллары өзелгән курчаклар агып чыга һәм урам уртасына таралышып яталар. Курчакларга басмаска тырышып, Ихтыяр читкә тайпыла. Аргы баштагы авыл капкасына җиткәч, Фаил артка борылды, гармунын җиргә куеп, ике кулын тиң селтәргә тотынды. Гүяки аңа су астындагы бар нәрсә буйсына, аның сүзен тыңлый, гүяки ул бөтен су асты дөньясы белән дирижерлык итә иде. Ихтыяр гаҗәпләнгән күзләре белән як-ягына каранды: эреле-ваклы балыклар да, су төбендә әкрен генә башын селкеп утырган кабырчыклар да, рәт-рәт тезелгән егетләр дә, Фаил тылсымына бирелеп, бер үк көйне сузалар, бер үк җырны җырлыйлар сыман иде. Аның баш миен яктыртып, чигәләрен кыздырып утлы уй йөге-

реп узгандай булды. «Бу бит — Фаил җыры! «Хуш, авылым!» дип кычкырмакчы булды ул, ләкин күпме генә тырышса да, тавышы чыкмады.

Аннары Фаил аларны тигез рәтләргә тезеп авыл читенә алып чыкты. Зират янына җиткәч, авызларын ябып, барысы да торaташ сыман катып калды. Читтән карaганда, һәйкәлгә охшап күренәләр иде алар. Фаил, рәттән аерылып, иң зур, иң борынгы кабер ташы янына тезләнде. Шулчак, кабер ташы тавыш-тынсыз артка таба шуышып китте дә, аннан... таҗ сыман итеп эшләнгән биек кәләпүш, кәләпүш артыннан галәмәт олы баш күренде. Ул, җирдән бил тиңентен өскә күтәрелгәч, уң кулын сул күкрәгенә куйды да авызын ачты. Моңа кадәр тып-тын торган су асты патшалыгында яңгыраган мәгърур аваз барысын да өнсез калдырды. «Нинди гаҗәеп дөнья бу,— дип уйлады Ихтыяр.— Тереләрнең тавышы ишетелми, ә мәетләр рәхәтләнеп сөйләшә... Әллә соң... без... мәет булып, алар тере кешеләр микән? Үзебез дә күрмәгәндә, дөньяның асты өскә килде микән?»

Аның уйларын таҗ кәләпүшле башның кабер эченнән яңгыраган салкын һәм саллы тавышы бүлде...

— Әй, сез, угъланнар! Мин сезнең борынгы бабаларыгыз исеменнән, шушы патшалыкта гомер уздыручы туганнарыгыз исеменнән сөйлим... Без, якты дөньядан киткәндә, үзебез белән бер нәрсә дә алмыйча, сезгә җирдәге һәммә нәрсәне мирас итеп калдырган идек. Сез аларның барчасын да күз карасы кебек сакларсыз, безнең төс итеп кадерләп тотарсыз, ишәйтерсез, дип уйлаган идек. Вәләкин сез безнең ышанычыбызны акламадыгыз. Сез үткән буыннардан мирас булып калган иң зур байлыгыгызны — хәтерегезне җуйдыгыз, кирәк чакта безне яклап сүз әйтер тавышыгызны югалттыгыз. Сезнең хәзер авызларыгыз ачылса да, тавышыгыз ишетелми, теләгегез уянса да, кыюлыгыгыз җитми. Шуңа күрә без, үзебезне үзебез яклар өчен, туып-үскән җиребезне, үз Ватаныбызны саклар өчен, бу мәңгелек патшалыгыбызны ташлап, яңадан якты дөньяга кайтырга булдык.

Каберстан патшасы шушы сүзләрне әйтеп бетерүгә, зираттагы кабер ташлары берәм-берәм читкә шуышып, аннан баштанаяк акка төренгән төрле яшьтәге, төрле кыяфәттәге кеше гәүдәләре җанланып чыга башлады...

Ихтыяр Фаилне кочаклап алды да куркудан бар көченә кычкырып җибәрде һәм уянып китте. Бабасы сөяк-

ле куллары белән ашыга-ашыга аның битләреннән сыйпый, ә ул һаман коточкыч төшеннән арына алмыйча ыңгыраша иде.

Бу мәхшәрнең соңгы көннәрдә күңелендә җыелып килгән саташулы, мең борчулы уйлар нәтиҗәсе икәнен, бары тик куркыныч төш кенә икәнен аңласа да, уянып җиткәч ул кат-кат кычкырып, хәтта җырлап та карады. Һәм шунда гына бөтенләй айнып җитеп, үз тавышын беренче ишеткәндәй, сәерсенеп тыңлады. Тавышын югалтмавына бөтен күңеленнән сөенде. Тик Зыятдин карт кына Ихтыяр күңелендәге өермәләрне сизмәде, аны бер кайгысыз, бер борчусыз малайга санап, һаман үз уйлары эчендә әвәрә килүендә булды.

* * *

Кояш нурлары карга оялары арасыннан саркып үтеп, җылы куллары белән аның битенә кагылгач, ярым уяу килеш шактый вакыт кичәге хәлләрне, бер атна эчендә булып узган вакыйгаларны башыннан кичереп ятты Ихтыяр. Аннары иренеп кенә юрган астыннан чыкты да буялмаган такта идәнгә яланаяклары белән чәпелдәтеп баса-баса алгы якка узды. Өстәлдәге самавыр, менә-менә урыныннан кузгалырдай булып, пошкыра-пошкыра кайнап утыра. Бабасының урын-җире пөхтәләп җыештырылган, өстәл дә гадәттәгедән мулрак итеп, бәйрәмчә әзерләнгән.

Ишегалдына чыккач, лапаста агач ышкылаган тавыш ишетелде. Ихтыяр анда кереп тормады, туры тегермән янына төшеп китте. Бил тиңентен чишенеп, балакларын сызганды да иске тегермән ташы өстенә утырды. Тегермән ташының кытыршы өслеге гарәп хәрефләре белән чуарланган кабер ташына охшавын күреп, аны игътибар белән капшап карады. «Әллә бу чыннан да үткән буынның килер буыннарга язган хаты инде?» — дип уйлады ул. Ихтыяр ташны кузгатмакчы булды. Аның урыныннан кымшанырга теләмәвен күргәч, хәлсезләнеп өстенә утырды. Ул әле һаман кичәге уйларыннан арына алмый, бабасының фәлсәфә ташына әверелгән тегермән ташының эченә яшерелгән серне белмәк булып изалана иде. Кояшның инде шактый өскә күтәрелеп, үзенә көлемсерәп карап торуын күргәч, тал ботакларына тотына-тотына чишмә буена төште. Чокыр төбеннән тибеп торган чишмә суы баш миенә кереп оялаган бөтен бимазалы уйлар-

ны куып чыгарды. Салкын су белән битләрен чылаткач, аның уйлары гына түгел, күңеле дә чишмә суы сыман чистарып калды.

Атау итәгендәге алмагач бөреләреннән җанны кытыклый торган яз исе бөркелә. Ул аяк-кулларын кура җиләге куакларына сыдырта-сыдырта, тигәнәк чукмарларына сарылып бетеп, атау читеннән әйләнде һәм лапас янына килеп туктады.

Зыятдин карт болындай киң лапас уртасына бөкрәеп баскан да, бар дөньясын онытып, нәрсәдер эшләп маташа. Ихтыяр, аны эшеннән аерырга кыймыйча, шактый вакыт соклану һәм аптырау катыш күзләре белән лапас ягына карап тик торды. Як-ягын су баскан, элек гөрләп бәрәңге үскән бакчасын алабута, билчән, тигәнәк каплап киткән ярым ташландык атауда яшәүче какча гәүдәле картның, бернинди авыруга да, җанны талкый торган ялгызлыкка да бирешмәскә тырышып, теше-тырнагы белән тартыша-тартыша яшәп ятуы Ихтыяр өчен гаҗәп тә, сөенеч тә иде. Ул үзенең атна буе атауда ятуының котылгысыз хәл булуын аңласа да, күңеле барыбер бөтен күзәнәкләре белән инешнең аргы ягына — кешеләр янына, тормыш кайнап торган дөньяга тартканын сизеп торды. «Кешене кызганырга ярамый! Кызгану кешенең эчке горурлыгын җимерә, кызгану кешене кимсетә, мәсхәрә итә. Кешене бары тик яратырга гына кирәк!» — дип кабатлады ул үз-үзенә.

Ул, ниһаять, якын килеп, кулы белән бабасының җилкәсенә кагылды һәм верстак өстендә өр-яңа аэроплан күреп, ирексездән авыз тутырып елмайды:

— Очасы киләме, бабай?

— Һе-һем... Сине очыртырга бу. Үз канатларың шактый зәгыйфь күренә. Тордың дамыни?

— Әллә кайчан. Синең бөтен аэропланнарыңны җыйсаң, бер музей оештырып булыр иде инде.

— Минем үземне музейга куярлык инде хәзер. Нигә көләсең? Кырык-илле ел элек кигән чабаталарны, килекабаларны музейга җыялар бит хәзер. Без инде шул иске чабатадан да кирәксезрәк булып чыктыкмыни? Безгә дә тисен иде шул иске чабатага тигән кадер, безне дә шулай тел-теш, җил-яңгыр тидерми сакласыннар иде.

Зыятдин карт аэропланын күтәреп ишегалдына чыкты да өй кыегына сөялгән баскыч янына килде. Уң аягын баскыч аратасына куйгач, Ихтыярга борылып карады.

— Кая, бабай, үзем. Минем бер тапкыр да куеп караганым юк.

— Булдыра алырсыңмы соң? Аның үз җае бар бит. Куйдың да очты-китте түгел.

Ихтыяр аэропланны сул кулына тоткан килеш өскә күтәрде дә ике баскычны бер атлап түбәгә менеп китте. Аэропланны иплэп кенә өй кыегындагы агач ялгашка урнаштыргач, як-ягына борылып карады. Моннан басу уртасындагы шәһәр ачыграк күренә, ул үзенең кояшта балкыган ак йортлары белән чем-кара туфракны яктыртып, тирә-юньгә ямь биреп тора иде.

— Нәрсә дөньяңны оныттың? Бохар мәчесе төсле оеп утырма, төш,— дип кычкырды аңа бабасы.

— Тарт әйдә,— дип, авыз эченнән мыгырданды Ихтыяр. Аэропланга күңеле кинәт суынган иде аның.

— Үзең тарт. Синең өчен ясадым мин аны. Сине озатыр өчен. Бүтән ясамыйм. Соңгысы. Яраплан түгел, чардуган тактасы ясар чагың җиткән, диде этиең дә...

Бу минутта Зыятдин картның йөзенә сабыйлык төсе кергән иде. Ихтыяр аэроплан очырган көнне бабасының һәрчак шулай кинәт кенә яшәреп, гәүдәсе җиңеләеп китүен хәтерләде дә, аны бу соңгы шатлыгыннан мәхрүм итүдән куркып, баскычны сыгылдыра-сыгылдыра аска төште һәм, киерелеп, бауны тартып җибәрде. Аэроплан, мондый тупаслыкны көтмәгәндәй, борыны белән һаваны сөзеп кинәт кенә күккә күтәрелде, менеп җиткәч, беркавымга хәрәкәтсез калып, асылынып торды һәм аннары уктай аска атылып язгы ташкын суына утырды. Актарылып аккан кара су дулкыннары, көтелмәгән мондый табышка сөенгәндәй, бөтерелә-бөтерелә аның тирәсендә бии башладылар. Кара су өстендәге ап-ак аэроплан, канаты каерылып үлем белән тартышучы акчарлак кебек, кызганыч та, шул ук вакытта матур да иде.

Су өстендәге ак аэропланга карап өнсез калган сиксән яшьлек Зыятдин картның һәм әле яңа тормыш диңгезенә кереп чумарга җыенган Ихтыярның күзләрендә бу мәлдә бер үк сагыш, күңелләрендә бер үк моң иде.

Каршы як ярда машина гөрелтесе ишетүгә, алар икесе дәррәү күтәрелеп карадылар. Кабина түбәсендәге зәңгәр утын балкытып килеп туктаган кып-кызыл машинаны күргәч, Ихтыяр беразга аптырап калды. Машинадан төшкән ике кешенең берсе Фаил икәнне танып алгач, эшнең нәрсәдә икәнен аңышты.

— Көтә-көтә көтек булдыгызмы? — дип, бөтен инеш буен, бөтен атауны яңгыратып кычкырды Фаил.— Хәзер без аны...

Менә ул кабинага кереп утырды да машинаны улата башлады. Кабина өстендәге баскыч, һаман озынаеп, атау яры итәгендәге карт өянке ботагына барып терәлгәч, туктап калды.

— Талга мен, талга! — дип кычкырды Фаил. Үзе, яр буена чыгып басып, биленә таянды.

— Ут капмагандыр бит? Кая каударланасың болай? — Зыятдин картның атау тынычлыгын бозгангамы, әллә Ихтыярны җибәрәсе килмәүдәнме ачуы кузгалган иде.

Фаил аның сүзләрен ишетмәде, һаман кычкыруында булды:

— Артык юанып торырга вакыт юк! Халык җыела башлады. Ял көн дип тормый, иртә кузгала рабочий класс. Тугызда митинг башлана...

Шул арада Фаил баскыч буйлап мәче елгырлыгы белән үрмәли-үрмәли талга килеп җитте дә аска сикерде. Аягын авырттырды булса кирәк, Ихтыяр янына аксабрак килде.

Бераздан Ихтыяр җыенып бетте һәм ике кулын сузып бабасы белән саубуллашты да Фаилгә таба карап баш какты:

— Әйдә, киттек! Хуш, авылым!

Бу сүзләрне Фаил үзенең яңа кушаматы буларак кабул итсә, Зыятдин карт өчен ул үз язмышын хәл иткән хөкем карары сыман яңгырады.

Карт Ихтыяр белән Фаилнең баскыч буйлап теге як ярга үрмәләгәнен, кызыл машинаның саллы кузгалып, урам почмагында югалуын карап торды.

— Хуш, авылым...— дип гаҗәпләнеп үз эченнән кабатлады Зыятдин карт һәм, бу сүзләрнең мәгънәсенә әле генә төшенгәндәй, бөтен авылны күздән кичереп чыкты.— Хуш, авылым...

* * *

Алар килеп җиткәндә, тулай торак каршындагы машинаның әрҗәләрен ачып, әрҗә төбендәге чүп-чарны себереп маташалар иде. Машина янында җиде-сигез ир-ат тәмәке пыскыта, берничә егет тулай торак белән ике арада тыз-быз чаба.

— Стекольщиков егетләре кайда? — дип кычкырды Фаил, кабинадан сикереп төшү белән үк.

— Алар катнашмыйлар. Әле генә үзе янына кердем. Кемгә кирәк, шул тамак ертсын, ди Стекольщиков. Егетләре бригадирдан узып йөри алмый инде.

Кәефләре бик сүлпән күренсә дә, башлаган эшне ярты юлда калдырырга теләмичә, митингны үткәрергә булдылар. Башта озак итеп табигатьне саклау җәмгыятеннән чакырылган лектор экология мәсьәләләренә кагылышлы лекциягә охшаш сүз сөйләде. Аннары машина әрҗәсенә берәм-берәм менеп шофер егетләр, төзүчеләр сүз алды. Аларның сүзләрендә дәрт, хис, ачу ташып торса да, дәлилләре җитәрлек булмаганга, бу сүзләр, пафослы буш шигырь сыман, һавада бераз тирбәлеп торалар да оратор җиргә төшүгә үк онытылалар иде. Иң соңгы сүзне Ихтыярга бирделәр. Ул үткән төнне, ниләр сөйләргә икәнен уйлап, шактый йокламыйча яткан иде. Ләкин кичә башка килгән фикерләрнең бүгенге сүлпән митингны уята алмасын төшенеп, ул сүзне бөтенләй бүтәнчә, бүгенге көннән түгел, ә бик ерактан, бу якларның тарихыннан башларга булды.

— Ташлыяр, Акчишмә, Каенсар авыллары моннан биш гасыр чамасы элек Иван Грозный яуларыннан качып килгән бабаларыбыз тарафыннан салынган,— дип кабаланмый гына алып китте ул.— Чукынудан, патша әзәрлекләвеннән котылырга уйласалар да, миссионерлар моннан да эзләп тапкан аларны. Безнең бабайларны чукындырганнар, безнең авылларны кат-кат килеп талаганнар, ләкин халыкны бетерә алмаганнар. Шушы биш гасыр эчендә ничәмә-ничә ачлыкны, ничәмә-ничә янгынны күргән бу авыллар! — Ихтыяр атаудагы озын кичләрдә бабасы сөйләгән сүзләрнең шушы минутта кирәк булуына бераз гаҗәпләнеп тә, егетләрнең аны тын да алмыйча тыңлауларына ләззәтләнеп тә сөйли, сөйләгән саен аның үзенә ышанычы арта, сөйләгән саен аңа бу җирләр, бу авыллар тагын да якынрак тоела бара иде.— Биш гасыр буена патша ялчылары, ачлык-ялангачлык та бетерә алмаган авылны биш ел, юк, биш ай, биш атна эчендә без үз кулларыбыз белән юк итәбез! Бу бит варварлык, үзең утырган агачның тамырына балта белән чабу! Моның өчен безгә киләчәк буыннар каршында җавап бирергә туры киләчәк! Безне беркем дә гафу итмәячәк!

— Дөрес сөйлисең, егет! — дип куәтләп кычкырды

тулай торак ишегенә арка сөяп торган имән кискәсе сыман түгәрәк гәүдәле ир уртасы агай.

— Безгә түгел, начальникларга сөйләргә иде бу сүзләрне,— дип күрсенде аның янәшәсендәге күзлекле егет.

— Митингка җитәкчеләрне чакырмыйча дөрес итмәгәнсез,— дип, аның сүзен элдереп алды Ихтыяр.— Халык фикерен ишетергә тиеш алар.

— Чакырдык. Килмәделәр,— диде ачу белән Фаил.

— Димәк, чакыра белмәгәнсез.

Ихтыярның шулай җиңел генә гаеп ташлавы күңеленә кагылды, ахрысы, теге таза бәдәнле агай төксе генә сүз кыстырды:

— Читтән килеп өйрәтеп йөрергә барыбыз да оста. Үзең барып сөйләшеп кара алар белән.

Тирә-юне актарылып ташланган шыксыз тулай торак кырыенда җыйналган бер төркем ир-атның үзен шулкадәр таң калып тыңлавы Ихтыярга көч бирде, ул йодрыгын өскә күтәреп кычкырып ук җибәрде: — Кирәк икән, акыл да өйрәтербез, кирәк икән, җир җимертеп эшләрбез дә!

Митингтан соң машина белән китереп куярга теләсәләр дә, ул Ташлыярга җәяү генә кайтырга булды. Юлны аркылы чыгып, калкулык читендәге зиратка менде. Әтисе ягыннан бабасының гарәп хәрефләре белән ниндидер сүзләр язылган кабер ташын күргәч, чардуган кырыендагы утыргычка хәл алырга утырды. «Кабер ташындагы өч-дүрт сүзне дә укый алмыйбыз бит,— дип авыр итеп күрсенде ул.— Нинди надан без! Бабасы язганны оныгы укый алмасын инде! Ә үзебез һаман дөнья мәдәнияте, халыклар дуслыгы турында сөйләшәбез. Иң элек үз культурасын үзләштерергә, үз тарихының төбенә төшәргә тиеш кеше».

Ындыр артлатып кына ишегалдына кергәч, туктап калды. Бер атна элек иң беренче булып каршы алган олы гәүдәле ак тавык, башын кыңгыр салып, аңа карап тора иде. Тавыкның күңелен күрәсе килеп, Ихтыяр җим алырга келәткә керде. Караңгы келәттә кармалана-кармалана бодайлы капчык эзләгәндә, кулы ниндидер очлы тимергә кагылды. Үрелеп утны кабызса, бу тимер очлаеп килгән түгәрәк агач башына беркетелгән җиз ай булып чыкты. Үткән ел көчле давылда иске мәчетнең манара очы сынып төште, дип язган иде әнисе. Бу кайтуында ерактан ук мәчет башындагы ай ялтырап күренмәгәч,

авыл ничектер ят сыман тоелган иде аңа. «Айны ташламаганнар, югалтмаганнар... Әнкәй эшедер бу,— дип уйлады Ихтыяр.— Әткәй ничек чыгарып ташламады икән? Дин, мәчет, дигәндә, чәчләре үрә тора иде бит аның».

Бодай сибүгә, тавык бер бөртекне генә авыз итеп карады да, аның чыннан да бодай икәненә ышангач, сөенеченнән кыткылдап алды.

Әнисе Ихтыярны күрүгә беркавымга телсез калгандай булды. Чит кеше белән күрешкәндәй, алъяпкычы белән сөртә-сөртә ике кулын сузды.

— Иртән атау кырыена нинди күз күрмәгән машина килеп туктаган иде ул?— дип сүз башлады әнисе.— Тәрәзәдән күреп калдым. Атауга күпер салалармы әллә соң? Янына төшмәкче дә булган идем, мин җыенганчы китеп барган.

— Мине алырга килгәннәр иде. Шәһәргә бардым мин.

— Эш белештеңме әллә?

Әнисенең үзенә сак кына күз салуын күреп, Ихтыяр сүзне читкәрәк борырга булды.

— Бабай бөтенләй аякка басты. Егетләр шикелле йөри.

— Әллә нидә бер шулай йөрәк өянәге кузгала торган гадәте бар инде аның. Ярый, бу юлы да хәвефсез генә узды... Хәерлегә булсын. Шәһәрдә нишләдең соң, улым? — дип соравын икенче яктан килеп кабатлады әнисе.

— Митинг оештырганнар. Авылларны саклап калмакчы булалар.

— Нинди авылларны?

— Күп инде алар,— диде теләр-теләмәс кенә Ихтыяр.— Рәхәтләнеп бер зарланыштык.

— Син дә сөйләдеңме?

— Мин кемнән ким,— дип елмайды Ихтыяр.— Әни, үзегез ничек яшисез соң?

— Таң ата да кич була инде, улым. Аяк йөрткәндә йөрибез әле.

— Келәттәге айны кем алып кайтты?

Әнисе, аптырап, аңа карады:

— Каян күрдең әле? Мин алып кайттым аны. Төнлә... бәләкәй арбага салып...

— Әткәй ни ди соң?

— Капчык белән каплап куйган идем мин аны. Әллә күрми, әллә күреп тә күрмәгәнгә салыша. Аны аңламас-

сың бит. Бер вакыт табып, рәтләп куйсагыз иде шул манараны. Ае булмагач, әллә ничек, күрке юк бит. Бөтен авылга ямь биреп, әллә кайдан күренеп тора иде...

— Бу юлы булмас, әнкәй. Иртәгә юлга чыгарга кирәк миңа. Озакламый имтиханнар башлана.

— Зәлия дә югалткандыр инде үзеңне.

— Югалтса, кайтып төшәр иде. Өч сәгатьлек юл бит.

— Алай димә, хатын-кызның холкы бөтенләй бүтән аның. Тик торганда кузгалып китә алмый. Имтиханнарыгызны тапшыргач, икегез бергәләп кайтыгыз. Туйны да авылда гына ясарсыз...— дип, күзләрен Ихтыярдан алмыйча сөенеп карап торды әнисе.— Күңелегезгә ошап китсә, шушында гына торып калырсыз. Казанда да әзерләп куймаганнар...

Ихтыяр, урамда тавыш ишетеп, тәрәзәгә үрелде. Урамның аргы ягындагы кое буенда ике кыз көлешә-көлешә чиләкләренә су тутыра. Аларның янәшәсендә генә муеннарын сузып ике ата каз ысылдаша. Арырак, бөтен авыл өстеннән бер башка калкып, мәчетнең калай түбәсе һәм бер якка янтая төшкән айсыз манарасы күренә.

Тәлинкә белән яңа пешкән коймак күтәреп чыккан әнисе, улының тәрәзәгә карап өнсез торуын күргәч, кызыксынып, урамга күз салды.

— Ә-ә, Сәрбиназ кызлары,— диде ул балкып.— Бигрәк уңганнар инде. Үзебезнең авылда да менә дигән кызлар җитәрлек тә бит... Мәкәрҗәдәге бакыр алтын булып күренә, ди торган ие әбиең. Үзегез беләсездер инде...

Шулчак капканың ачылып ябылганы ишетелде. Ишегалдында әтисенең «мин кайттым» дигәнне аңлаткан тамак кыру тавышы яңгырады. Чыннан да, синме бу дигән сыман, Ихтыярның иңбашларыннан тотып селкеткәннән соң, Тимерхан агай, салам эшләпәсен чөйгә элеп, табын янына утырды.

— Картны аякка бастырдыкмы? — диде ул, самавырдан чәй агызган көйгә.— Дару кирәк түгел кешегә. Кешегә кеше кирәк.— Аннары, сүзне бүтәнгә борып, кинәт кенә сорап куйды: — Бүген шәһәрдә күргәннәр сине. Нинди йомыш төште? Әллә эш белешеп йөрүеңме?

— Юк, болай гына,— диде Ихтыяр. Бүгенге күңелсез һәм оешмаган митинг турында сөйләп, әтисеннән шелтә ишетәсе килми иде аның.

— Болай гына, дисеңме? Юкны сөйләмә. Икеләнеп-микеләнеп йөрмә, тот та шушында гына кайт! — дип кис-

терде этисе.— Бер хатын-кызны да кулга ала алмаган ир кешедән эш чыгармы! Җитмәсә, булачак хатынны әле! Әйдә, киттек, бергәләп басуларны әйләнербез.

Ихтыяр малай чактан ук этисе белән тарантаска утырып көннәр буе басуларда, урманнарда, болыннарда йөрергә күнеккән иде, бу тәкъдимгә бик теләп риза булды.

Арып-талып кич өйгә кайтып кергәндә, Ихтыярның йөзенә алсулык иңгән, бөтен өсте-башы тузанга баткан, кыскасы, ул яңадан Ташлыяр авылы кешесенә охшап калган иде.

* * *

Зәлия белән алар институт коридорында гел көтмәгәндә очраштылар. Ихтыяр, автобустан төшүгә, туп-туры институтка килгән иде. Эшен бетергәч, кайтышлый Зәлиягә шылтыратырмын, өйдә булса, кич янына сугылып чыгармын яисә берәр җиргә чакырырмын дип торганда, каршысына үзе килеп чыкты. Бөтен коридорны яңгыратып доцент Сарымсаков белән көлешә-көлешә атлыйлар. Ихтыярны күргәч, туктап калдылар.

— Кайчан килдең? — дип гаҗәпләнеп сорады Зәлия.— Бөтенләй килми микән әллә, дип уйлый башлаган идек инде...

Бабасының хәле турында да сорашмыйча, иң элек үзенең үпкәсен белдерергә ашыккан, иреннәрен турсайтып, әле Сарымсаковның ыспай һәм мәһабәт гәүдәсенә, әле Ихтыярның малайлык чыгып бетмәгән авылчарак кыяфәтенә карап торган Зәлия аңа ят та, ерак та булып тоелды.

— Карале, кадрлар бүлегеннән эзләгәннәр иде сине,— дип, Сарымсаков аларның икесен генә калдырып, кафедра бүлмәсенә кереп китте.

— Барысына да син гаепле...

Шулай диде дә Зәлия еламсырап стенага сөялде.

— Нәрсә булды? Нинди гаеп?

— Ирекле диплом алу өчен син аларга язылышу турында белешмә китереп бирергә тиеш идең бит. Иң кирәкле вакытта кайтып киттең. Ректор өстәмә приказ язган. Сине Ташлыяр шәһәренә җибәрәләр... Теләгеңә ирештең инде...

— Ә син? — дип, аның күзләренә карады Ихтыяр.

— Мин монда калам! — диде Зәлия һәм Ихтыярны кадрлар бүлеге ишеге төбендә калдырып китеп барды.

* * *

Юл читендәге актарылып ташланган кап-кара басу өстеннән, төнлә явып узган яңгырдан соң, күренер-күренмәс кенә бу күтәрелә. Баш очында сайраган тургай, кояш нурына асылынган кебек, шактый вакыт бер урында хәрәкәтсез тора да, кинәт кенә ычкынып, аска томырыла, аннары, тагын шул нур җебенә тагылып, өскә менеп китә.

Былтыр көз генә салынган бетон юл әле шомарып өлгермәгән, киресенчә, язгы суларда купшаклана гына төшкән, шуңа күрә өстендәге чуерташлары, тәгәрмәчләргә ияреп, чишмә суы сыман чылтырап бара.

Дөнья шулкадәр саф һәм риясыз, бу матурлыкны бары тик машиналардан калмый бөтерелеп барган тузан өермәләре генә бозып, нәрсәдер искәртә сыман.

Ихтыяр утырган йөк машинасы шәһәр төзү идарәсе янына туктагач, арттан калмыйча ияреп килгән тузан өермәсе, нәрсә булды дигәндәй, беркавым бөтерелеп торды да, хуҗасын көткән күндәм эт кебек, тынычланып, хәл җыярга юл читенә чыгып ятты.

Алгы бүлмәдә утыручы кыз, Ихтыярны күрүгә, кулындагы көзгесен өстәл тартмасына шудырып, үтә җитди кыяфәт белән аңа текәлде.

— Башлык урынындамы? — диде Ихтыяр һәм кесәсендәге документларны алырга да, алмаска да белмичә, капшап куйды.

— Кызганычка каршы, хәзергә юк.— Кыз үзе сөйли, үзе Ихтыярны энәсеннән җебенә кадәр өйрәнә. Әйтерсең ул эшкә алыр алдыннан һәркемне шулай үзенең рентген аппараты аша үткәрә иде.— Киңәшмә бара,— дип өстәде ул һәм, егетнең чыраенда бер үзгәреш тә күрмәгәч, игътибарын җәлеп итәргә теләгәндәй, өстәл тартмасын шапылдатып ябып куйды.

Ихтыяр, эшсезлектән туеп, инде, ниһаять, иркенләп сүз башларга җыенган кызның теләген аңламый, хәтта аны бөтенләй күрми дә иде. Ул, нәрсә эшләргә дә белмичә, бер урында таптанып торуында булды.

— Кирәк икән, утырып тора аласыз,— дип, секретарь кыз үз каршындагы урындыкка күрсәтте.

— Юк, рәхмәт. Күптән башландымы җыелышлары? Тиз бетәрме икән?

— Кем белгән аларны? Ә сез үзегез каян буласыз? Ни йомыш? Бәлки, мин генә хәл итәрдәй мәсьәләдер? Берен-

че күрүем дип әйтимме? — Секретарь кыз, нидер язарга җыенып, кулына ручка алды, чертләтеп аның кызыл төймәсенә басты.

— Эшкә килдем. Институт бетереп. Сезгә җибәрделәр. Сезгә дип... Үземнең туган якларга кайттым. Күрше авылдан мин. Ташлыярдан.

Ихтыяр, үзе дә сизмәстән ачылып сөйләшә башлавына кыенсынып, туктап калды.

— Алайса, җирле кадр булып чыгасыз инде. Кирәк андыйлар, бик кирәк безгә.

— Бик көтеп торган кеше күренми әле монда.— Хәзер инде ул, иләшә төшеп, кыз белән тыныч сөйләшә башлаган иде.

— Киңәшем шул — көтегез,— дип чытлыкланып җавап бирде аңа секретарь кыз һәм кулындагы ручкасын тагын чертләтте.

Шулчак өстенә күн пинжәк, аягына резин итек кигән кеше атыла-бәрелә килеп керде дә «Баш инженер» дип язылган ишеккә чумып югалды. Бераздан сулуы кабып кире әйләнеп чыкты, ашъяулык кадәр кулъяулык белән шактый ук зур борынын тәртипкә китергәч, шар күзләрен як-якка йөртеп, секретарь кыз өстәле янына килде.

— Теге, кичә баскан исемлекне таба алмыйм. Икенче данәсен бир әле,— дип, ягымлы итеп эндәште ул.

Шушы кадәр зур һәм килбәтсез гәүдәдән, балта белән юнып ясаган төсле тупас йөздән бу хәтле үк җылы сүз чыгар дип Ихтыяр башына да китермәгән иде. Ул, әллә бүлмәгә бүтән кеше кердеме икән, дип, тиз генә як-ягына каранып алды.

Кыз, үз дәрәҗәсен саклап, кабаланмыйча гына өстәл тартмасын ачты, ак тышлы папканы шактый актаргач, кулына бер бит кәгазь алды, күрдегезме безнең кем икәнне, баш инженер булып баш инженерга да исебез китми дигәндәй, Ихтыярга карап авыз тутырып елмайды.

— Менә безгә тагын бер кадр килде. Монысы, бәлки, алай бик тиз табан ялтыратмас. Шушы якныкы. Ташлыярдан...— Секретарь кыз сүзен әйтеп бетерүгә, телефон шылтырады.

Моны ишетеп торган баш инженерның йөзендә бер үзгәреш тә сизелмәде, ләкин бүлмәдән чыгып барышлый, Ихтыярның эшкә түгел, ә бәйрәмгә җыенгандай пөхтәләп үтүкләнгән аксыл костюмына, әле генә өйдә ялтыратып чыккан ботинкаларына, шәһәр аклыгы кунган йөзе-

нә, дугайланып килгән мыегына күз төшереп алды да, мул кашларын җыерып, гөргелдәп торган бөтенләй ят аваз чыгарды:

— Каян?

— Ташлыярдан.

— Анысын ишеттек.

— Төзелеш институтыннан сезгә җибәрделәр,— дип әйтергә ашыкты Ихтыяр, йөзе бер мизгелдә кызарып, тирләп чыкты.

— Әллә кайчан шулай диләр аны! Күптән көтәбез. Фамилиягез?

— Рәхмәт...

— Рәхмәтевмы?

— Юк ла! Батыршин Ихтыяр... Тимерхан улы.

— Колхоз председателе Тимерхан малаемы әллә?

— Әйе.

— Әтиегез принципиаль кеше. Чамасыз принципиаль... Монда кайтып бик дөрес иткәнсез. Әйдә, киттек. Иң элек киңәшмәдә чирканчык алып чыгыгыз. Нәкъ менә кадрлар мәсьәләсе турында чәч агартып утыра идек. Сезнең ишеләрне, яңа килгәннәрне дә җыйды бүген башлык.

Алар керүгә, залдагы утыз-кырык кешенең берничәсе дәррәү артка борылып карады. Ихтыяр, үзендә моңа кадәр булмаган каушау сизеп, тизрәк иң арттагы рәтләрнең берсенә, яшьрәкләр янына утырырга ашыкты. Баш инженер, каршыдагы өстәл янына килеп җиткәч, кулындагы кәгазен сузды һәм какча йөзен язгы җил ашаган, ачык зәңгәр күзле, кылыч борынлы, алҗыган кыяфәтле кешенең колагына нидер пышылдады. Ихтыяр турында әйтте булса кирәк, чөнки тегесе күтәрелеп арткы рәткә карады, кәгазь тоткан кулын алга сузып, торып басты.

— Иптәшләр, сүзем дәлилле булсын өчен саннар китереп сөйлим.— Шәһәр төзү идарәсе башлыгының (Ихтыяр аның башлык икәнен үз-үзен хуҗаларча иркен тотуыннан, өстәлнең кыл уртасында, графин каршында утыруыннан ук аңлады) сөйләгән саен гәүдәсе калкулана бара кебек иде.— Бүгенге көндә төзелештә барлыгы җиде мең дә алты йөз илле ике кеше эшли. Бу гаҗәеп зур сан, иптәшләр. Аларны ашатасы-эчертәсе, эш урыннарына илтеп куясы, алып кайтасы, барысына да фатир бирәсе, балаларын ясле, бакча, мәктәп белән тәэмин итәсе бар. Ә без әле шушы моментка боларның берсен дә тиешле дә-

рәҗәдә хәл кылдык, дип әйтә алмыйбыз. Яшәү шартларының канәгатьләнерлек булмавы эш процессына, аның нәтиҗәлелегенә турыдан-туры йогынты ясый, кире йогынты ясый...

Шулчак залдан яңгыраган тавыш аны ярты җөмләсеннән бүлде. Башлыкның моңа исе китмәде, ул баскан килеш сабыр гына аны тыңлап торды.

— Магнитканы, Днепрогэсны палаткаларда яшәп төзегәннәр. Без монда халыкны болай да иркәләп бетердек инде. Буыны сыекларны алмаска кирәк эшкә. Ятсыннар шунда җылы мич башларында көнбагыш ярып. Безнең монда — бөек төзелеш, үрнәк төзелеш. Безгә бөтенесенә әзер торган нык кешеләр, алтын куллы эшчеләр кирәк. Кешеләрне хәзердән үк сайлап җыйсак, киләчәктә мондагы шәһәр халкы да менә дигән булачак.

Урыныннан чәчрәп торып сүз башлаган кайнар канлы егетне төзелеш идарәсе башлыгы мыек астыннан көлемсерәп тыңлап торды да, ул сөйләп бетергәч, сүзен каударланмыйча гына, аталарча сабыр гына дәвам итте:

— Кешеләрнең иң әйбәтләрен сайлап кына җыярга, дисең инде алай булгач, иптәш Мелкумян. Ләкин менә монда мин аңлап бетермәгән бәләкәй генә нәрсә бар. Менә син үзең — югары белемле инженер — кешенең әйбәтме, начармы, кыюмы, куркакмы, тырышмы, ялкаумы икәнен бер карауда ук ничек ачыкларга уйлыйсың? Әллә күрәзәлек кыла беләсеңме? Синеңчә, без кадрлар бүлегенә күрәзәчеләр җыярга тиеш булабызмы?

— Кемнең кем икәнен бер карауда белеп була инде. Аннан... элеккеге эш урыныннан характеристика соратып алырга кирәк. Хезмәт кенәгәсендә нинди тамгалар бар, анысын карыйсың, сөйләштерәсең, сораштырасың.

Башлык, җитте, аңладык дигәндәй, имән бармагын тырпайтып, уң кулын өскә күтәрде.

— Әгәр дә аның элекке коллективка күңеле ятмаган, андагы эше ошамаган булса, әгәр дә ул монда килеп урнашкач, йөз дә сиксән градуска үзгәрсә?..

— Кеше йөз сиксән градуска үзгәрә алмый. Үзгәрсә, иң күбе, кырык градуска үзгәрә. Төзелешнең берничә еллык тәҗрибәсе шуны күрсәтә.

Кызу канлы егет бармагы белән тамак төбенә чиертте. Зал буйлап җиңелчә генә кеткелдәү дулкыны йөгереп узды. Егет, үз сүзеннән үзе читенсенеп, урынына утырырга ашыкты.

— Үзгәрә, ничек кенә үзгәрә әле. Тормыш үзгәртә ул...— дип, үзалдына сөйләнгән сыман бер үк сүзләрне кабатлап торды да башлык тиз генә җитди тонга күчте.— Кешеләрне сортларга бүлеп, беренче сортын үзебезгә сайлап, кибәген җилгә очырып утырырга хакыбыз юк безнең. Дөрес, гигант төзелештә, илебез мактанычы булачак бөек корылышта чиста куллы, чиста күңелле кешеләр эшләргә тиеш.

Ихтыяр, бу сүзләрне ишеткәч, ирексездән тураебрак утырды, чәчләрен артка таба сыйпап куйды.

— Ләкин безнең коллектив — төзелеш оешмасы гына түгел, ә тәрбия мәктәбе дә. Партоешма секретаре минем фикерне яклар дип уйлыйм.— Башлык янәшәсендәге күндәм кыяфәтле кешегә таба борылып карады, тегесе, аның сүзләрен җөпләп, баш какты.— Безгә ул һәйбәт кешеләрне, беренче сортлы тәүфыйк ияләрен, югары квалификацияле белгечләрне әллә каян җибәреп җиткерә алмаячаклар. Әйбәт кеше кайда да кадерле. Билгеле, баштарак безнең төп көчне читтән килгән кадрлар тәшкил итәчәк. Ә тора-бара без аларны үзебез тәрбияли, үзебез әзерли башларга тиеш булачакбыз.— Ул, туктап, графинадан су агызып эчте дә баш инженерга таба борылды:— Иптәш Шамкаев, әйт әле, быелның беренче кварталында кадрлар бүлеге аша ничә кеше үтте?

Баш инженер, борын өстенә иләмсез зур күзлек элеп, өстәлдәге кәгазьләрне кыштыр-кыштыр актарды да, аптыраган кыяфәт белән сорады:

— Кайсы якка?

— Ничек — кайсы якка?

— Керү ягынамы, чыгу ягынамы?

— Икесен дә әйт.

— Быелгысы елның беренче кварталында...— дип, бер көйгә суза-суза сөйләп китте баш инженер,— эшкә алуларын сорап кадрлар бүлегенә унике мең алты йөз кырык җиде гариза кергән. Шуларның унбер мең тугыз йөз илле дүрте канәгатьләндерелгән, димәк, гади тел белән әйтсәк, эшкә алынган.

— Ә китүчеләр? — Башлык әллә шушы саннарны ишетеп, әллә Шамкаевның искитмәс кыяфәт белән тәмләп-тәфсилләп сөйләвен ошатмыйча, кулындагы карандашын әйләндерә-әйләндерә аны ашыктырды: — Китүчеләр күпме?

— Эштән җибәрүләрен сорап сигез мең бер йөз унҗи-

де кеше гариза язган һәм барысының да үтенече канәгатьләндерелгән. Шулай итеп, безнең данлыклы коллектив бер кварталда гына да өч мең сигез йөз утыз җиде кешегә ишәйгән.

Башлык, хөкем залында утырган судья кебек, баш инженерга бер-бер артлы сораулар яудырырга тотынды:

— Январьда күпме киткән? Февральдә? Мартта? Кайсысы күпме эшләгән? Ни өчен киткәннәр? Эштән китүчеләр белән әңгәмә үткәрелгәнме? Үткәрелсә, анда кемнәр катнашкан?

Баш инженер, монысы инде минем эш түгел дигәндәй, иңбашларын җыерып, тик басып тора. Сораулар тәмамлангач та ул шактый вакыт ни әйтергә белмичә, кәгазен кат-кат әйләндереп карады. Аннары, мәсьәләсен чишкән укучы сыман шатланып, залга төртеп күрсәтте:

— Бу эш белән турыдан-туры социология бүлеге шөгыльләнә. Иптәш Фарукшин...

— Мөмкинме?

Зал уртасыннан яше утыз-утыз биш чамасыннан узмаса да, инде чәчләренә чал йөгерә башлаган, тере күзле, спортчыларныкы сыман тупырдап торган тыгыз бәдәнле кеше җәһәт кенә торып басты да җил-җил атлап түрдәге өстәл янына килде. Килә-килешкә тын алып та тормады, кәгазь-мазарга карамыйча гына, ике кулы белән күкрәген кочаклаган хәлдә, һәр сүзгә басым ясый-ясый сөйләргә тотынды:

— Киткән кешеләрнең алты проценты — югары белемле, алтмыш бер проценты — махсус урта һәм урта белемле, калганнары сигез яисә аннан да кимрәк класс бетергән. Милли составы — руслар, украиннар, чувашлар, марилар, удмуртлар, татарлар. Китүчеләр арасында җирле халык иң аз процент тәшкил итә. Барлыгы кырык өч милләт вәкиле. Яртысыннан күбрәге республикадан читкә китүчеләр. Уртача яшьләре — егерме дүрт. Китү сәбәпләре: торак кыенлыклары, транспорт өзеклеге, ашханәләрдәге су буе чират, гаилә низаглары, эчкечелек, җитәкчеләр белән конфликт, эштән соң ял итәр урын булмау. Болары — барысы өчен дә уртак сәбәпләр. Ләкин төрле категория эшчеләр өчен сәбәпләр төрлечә. Мәсәлән, ИТР составы күбрәк производство низаглары, коллективка берегә алмау, яшәү шартларының канәгатьләнерлек булмавы, рухи азык, культура-сәнгать учреждениеләре җитешмәүне сәбәп итеп куя, урта звено беренче

урынга торак булмауны, аннары эш шартлары авырлыкны, транспорт кыенлыкларын саный башлый, ә түбән звено, нигездә, торак җитмәү сәбәпле китәргә мәҗбүр була.

— Аңлашылды, иптәш Фарукшин. Ә калучылар нигә кала, аларын өйрәнмәдегезме? Ни әйтсәң дә, төзелештә җиде мең алты йөз илле ике кеше эшли һәм, белүемчә, күбесе бүген-иртәгә бу якларны ташлап китәргә җыенмый.

Фарукшин, анысы болай да билгеле, дигән сыман, иреннәрен бүлтәйтеп, иңбашларын җыерды.

Төзелеш идарәсе башлыгы, тавышын күтәрә төшеп, сүзен дәвам итте.

— Социология бүлегенең максаты коллективның кара ягын гына күреп, аның кимчелекләрен өйрәнеп утыруга гына кайтып калырга тиеш түгел. Сез, бүгенге обстановкага объектив бәя бирергә һәм шәһәр төзү идарәсенең, булачак шәһәрнең, гигант заводның, хәтта, әйтергә кирәк, бөтен илебезнең киләчәген күзаллап, шул киләчәкне ничек матуррак итү турында уйларга тиеш. Социологларның төп бурычы, иптәш Фарукшин, уңай факторларны табып алып, аларны җентекләп өйрәнү, аларны үстерү өчен кулдан килгәннәрнең барысын да эшләү, аларны үрнәк итеп, өлге итеп кешеләргә күрсәтә белү. Беренче кварталда әнә ул өч мең сигез йөз утыз җиде кеше нигә төзелештә калган, алары нигә китмәгән? Шартлар барысы өчен дә бер бит. Аларына да хан сарайларыннан фатир биргән кеше юк. Казыгач-казыгач, тирәннәнрәк казырга кирәк, иптәш социолог.

Социолог берничә тапкыр башлыкка каршы төшәргә тырышып карады:

— Без кимчелекләрне өйрәнеп... аларны киләчәктә булдырмау турында уйлыйбыз...— Ләкин ул, сүзен тәмамламыйча, ярты юлда туктап калырга мәҗбүр булды.

Фарукшинның, әле һаман килешергә теләмичә, үз сүзен куәтләргә тырышуы башлыкны бөтенләй чыгырыннан чыгарды.

— Тирес арасыннан алтын эзлисезме? — дип ярсыды ул.— Тирес арасында, тәти егетем, тирес корты гына була. Алтынны бүтән җирдәнрәк эзлиләр аны, чистарак җирдән. Шулай итсәгез, газет-журналларда да тирес исе аңкып торган мәкаләләр бастыру урынына, коллективның нинди зур авырлыкларны җиңеп яулаган уңышлары турында язар идегез.

Ихтыяр идарә башлыгының нигә бу кадәр чамадан чыгып кызуын аңламыйча тыңлаган иде, тора-бара ул хикмәтнең нәрсәдә икәненә төшенә башлагандай булды, ә инде аның соңгы сүзләрен ишеткәч, барысы да аермачык булып күз алдына килеп басты. «Эш болайрак икән монда. Начальникның серкәсе су күтәрми икән. Каршы әйткән бер кешенең башына сугып кына утыра. Нигә партоешма секретаре эндәшми? Ул барысын да күреп тора бит. Бик үк җиңел булмаячак монда»,— дип уйлады ул. Ләкин ул үз уйларына чумып онытылып утырган берничә минут вакыт эчендә башлык, берни булмагандай, бөтенләй тынычланган, ничек тиз кызып киткән булса, шулай ук тиз сүрелгән дә иде.

— Дүрт йөз вагонлы «Романтика» поселогы кору хәлне шактый җиңеләйтте,— дип дәвам итте ул.— Әмма ләкин килгән кешеләрне якын-тирә авылларга урнаштыру бик начар бара. Моның сәбәбе нәрсәдә, иптәш Шамкаев? Шуны тиз генә аңлатып бирегез әле безгә.

Шамкаев сүз әйтергә дип авызын ачты, ләкин аның җөмләсе әзер түгел иде, ахрысы: «Фарукшин...» — диде дә, каушап, күзләрен башлыкка төбәде.

— Нәрсә, барыгыз да Фарукшин авызына карап торырга калдыгызмыни инде хәзер? — Башлык тагын кабына башлады.— Әйдә, алай булгач, социолог әфәнде, рәхим итеп монысын да аңлатып күрсәт инде безгә. Ни өчен гомер-гомергә киң күңелле дип саналган авыл кешеләре шәрә басу уртасында өр-яңа шәһәр төзергә килгән изге теләкле, романтик җанлы хезмәт ияләрен үз бусагаларыннан кертергә җыенмыйлар? Сәбәбе нәрсәдә моның? Бусына да коллективтагы мораль климат гаеплеме?

Фарукшин ризасыз йөзен чытып кына торып басты. Теләр-теләмәс кенә сүз башлады:

— Төзелеш башланган беренче елда төзүчеләрне авылда бик теләп кабул иттеләр. Бу якларда яшәүче халык кеше хәленә керә торган, ил кайгысы, ил шатлыгы белән яши торган, сез әйтмешли, киң күңелле кунакчыл халык. Сугыш елларында Ленинградтан, Мәскәүдән эвакуацияләнеп килгән меңнәрчә кеше шушы як авылларына килеп сыенган. Ни авыр чакта да аларга караңгы йөз күрсәтүче булмаган. Әле бүген дә шул кешеләрдән рәхмәт хатлары килеп тора...

— Лирик чигенешләр ясамыйча гына сөйләп булмыймы? Утырмага җыелмадык без монда.

Идарә башлыгының атлаган саен Фарукшинны бүлдерүе, иркенләп сөйләргә ирек бирмәве залдагыларга ошамый башлады бугай, ара-тирә пышылдашып алганнары, канәгатьсез тамак кырып куйганнары ишетелде.

— Шуннан? — дип, Фарукшинга төбәлде башлык.

— Шуннан озакламый авыллар күчә башлады, зират урыннары, басулар, болыннар, урманнар су астында калды.— Сөйләгән саен, Фарукшинның сүзләренә куәт керә бара, йодрыгы өскәрәк күтәрелә иде.— Ә авыл халкы, шәһәрдән аермалы буларак, мондый мәсьәләләрдә бик бердәм ул. Бер кешегә кайгы килсә, авылы белән аңа ярдәмгә күтәрелә, янгын чыкса, безнең кебек, янгын машинасы улап чапканны тәрәзәдән карап калмый, дөньясын онытып шунда йөгерә.

— Шуннан?..

— Менә шуннан, үч итеп, килгән кешеләрне кертми башладылар. Аларның авылы да шул ук язмышка дучар булмас дип кем гарантия бирә ала агайларга? Шуңа да алар күрәләтә, аңлы рәвештә безнең юлга аркылы төшә, шулай итеп, беразга гына булса да, авылымның гомерен озайтам дип уйлый. Берәүнең дә үз үлемен ашыктырырга атлыгып торганы юк.

— Аңлашылды.— Идарә башлыгының тавышы йомшый төшкән иде.— Димәк, безгә шушы обстановкада нинди чаралар күрергә,ниләр эшләргә кирәк булып чыга инде? Килгән кешеләрне урамда калдырып булмый бит.

— Агитация чараларын көчәйтергә, аңлату эше алып барырга...

— Ничек итеп?

— Авылларга барып, һәр өй хуҗасы белән сөйләшеп чыгарга кирәк.

— Кемнәр барырга тиеш була анда?

— Без, барыбыз да...

Идарә башлыгы аскы иренен тешләп уйланып торды да кулындагы папкасын шапылдатып өстәлгә ташлады.

— Залда утыручылар арасында шушы тирәдә туып үскән кешеләр бармы?

Бары тик бер хатын гына торып баскач, башлык сорауны тагын кабатлады:

— Тагын кемнәр? Унҗиде яшь белгеч арасыннан берәү дә юкмы әллә?

Шунда Шамкаев Ихтыярга төртеп күрсәтте.

— Ә сез нигә басмыйсыз?

— Мин бит әле урнашып җитмәгән,— дип ык-мык итте Ихтыяр.

— Килгәч, урнаштың дигән сүз.— Идарә башлыгы Ихтыярга сынаулы караш ташлады.— Фамилиягез ничек?

— Батыршин.

— Кайсы авылдан?

— Ташлыярдан.

— Таныш фамилия,— дип, авыз чите белән көлемсерәде ул.— Исемегез?

— Ихтыяр.

— Менә нәрсә, Ихтыяр Батыршин иптәш... Бүгенге көндә бөтен ышаныч — синең кебек яшьләрдә. Безнең коллективта алтын куллы кешеләр дә, оста оештыручылар да, шәп ораторлар да җитәрлек. Ләкин әле төзелеш идарәсе коллективына үз максатларын ахырына кадәр башкарып чыгу өчен күп вакытта омтылыш һәм үз көченә ышану җитми.— Башлык бераз уйланып торды.— Ихтыяр, шушы минуттан үзеңне эшкә керештем дип сана. Иртәгә үк Ташлыярда һәр өйне йөреп чыгасың. Синең бурыч — бер атна эчендә кимендә өч-дүрт йөз кешене торак урынлы итү. Сорауларың булса, парткомга, баш инженерга мөрәҗәгать ит. Фарукшин, яшь иптәшкә инструктаж биру, коллектив белән таныштыру сиңа йөкләнә. Ләкин, кара аны, тирес башларын гына күрсәтеп йөрмә. Килгән көнне үк күңеле кайтырлык булмасын... Җыелыш бетүгә, партия оешмасы җитәкчелегендә,— ул янәшәсендәге пөхтә итеп өскә таралган чем-кара чәчле, коеп куйган төсле шома һәм чибәр йөзле ирнең иңенә кагылды,— тораксыз кешеләрне авылларда урнаштыру буенча штаб төзергә. Комсомолны, профсоюзны, кадрлар бүлеген чакырырга онытмагыз. Шушының белән производство киңәшмәсе тәмам. Безне главкадан килгән иптәшләр көтә. Сау булыгыз!..

* * *

Ихтыяр җыелыштан миңгерәп чыкты. Ул очсыз-кыйсыз уйлар, фикерләр эченә кереп чумган да шулардан котыла алмый иде. Бабасы атавыннан шулкадәр якты, шулкадәр матур булып күренгән ак каланың, әкият шәһәренең, күпме аһ-зары, күпме борчулары, хәл ителмәгән проблемалары булуын ул күз алдына да китермәгән иде. Биш ел буена институтта алар, чыннан да, ак

әкият дөньясында яшәгәннәр, биш ел буе ватман кәгазендә әкият сарайлары салганнар, артык беркатлы һәм якты хыяллар белән хыялланганнар икән. «Әкият сарае», «ак кала» дигән сүзләрне төзелеш сазына чумып карамаган кабинет геройлары уйлап чыгарганнар икән. Ул, әкият дөньясыннан чыгып, бүген тормыш чынбарлыгы белән күзгә-күз очрашты. Биш ел буе төзегән әкият шәһәрләре берничә сәгать эчендә җимерелеп төште, алда яп-якты булып балкып торган киләчәкне билгесезлекнең соры томаны каплады.

Урамга чыккач, күктәге кояшның элеккечә үк яктырып януына, бер сәбәпсезгә сөенүенә Ихтыяр шактый вакыт аптырап карап торды.

— Такси көтәсеңме?

Күтәрелеп караса, каршысында, көлемсерәп, Фарукшин басып тора.

— «Син» дигәнгә аптырама, шулай гадәткә кергән монда. Таныш булыйк, социолог Нурислам Салих углы Фарукшин.

— Ихтыяр.

— Әйдә, илтеп ташлыйм. Юл уңайлый гәпләшербез дә.

Ихтыяр, кыстаганны көтеп тормыйча, «Иж» мотоциклының арткы утыргычына менеп атланды. Бу кеше аңа беренче күрүендә үк кай ягы беләндер якын тоелды, аның белән сөйләшү күңелендәге уйларны таратыр кебек иде.

Нурислам мотоциклны бер тибүдә кабызды да бетон юлга чыкты. Ихтыяр юл уңайлый берничә тапкыр сүз башларга җыенып эндәшеп карады. Ләкин җил колакларга кереп сызгыра, борын тишекләрен кытыклый, күзне әчеттерә, авыздан чыккан сүзне җәһәт кенә эләктереп ала да әллә кая еракка очыртып китә. Җил икесенең дә чәчләрен туздыра иде.

— Нигә сөмсерең коелды? Ошамадымы әллә? — дип, артка борылып кычкырды Нурислам.— Исең китмәсен, көн саен шул ук сүз тегермәне ул бездә. Сөйләүчеләр күп, эшләүчеләр азрак.

Тегермән, дигәч, бабасы искә төшеп, аның йөрәге чәнчеп куйды.

Нурислам ялт итеп артка борылып карады.

— Бар белгәннәре — план да план! Ник дөньяларының асты өскә килми, тик планнары гына тулсын. Шуңа күрә дә эшләре бармый. «Давай», «ура» белән генә алды-

рып булмый хәзер. Тамагы туйган кеше зуррак нәрсәләр турында уйлый башлый ул. Моңа кадәр тамак кайгысы иң зур проблема иде.

Ихтыяр аңа җавап бирмәде. Җыелышта баш миенә кереп оялаган бал корты күчедәй гөжләү, авыл капкасына килеп җиткәндә, җил белән каядыр таралып беткән иде.

* * *

— Тукта әле,— дип, ул Нурисламның җилкәсенә сукты да бара-барышка ук мотоциклдан сикереп төште.

Урам читендә нидер көткәндәй басып торучы кеше боларга таба атлады.

— Батыршин түгелме соң? Әллә инде исәнләшмичә дә үтеп китәме дип торам. Теге вакытта ботаникадан берле куйганны һаман онытмыймы әллә, мин әйтәм.

Ихтыяр элек гаҗәеп мәһабәт һәм усал булып күренгән укытучысының кечерәеп, хәтта боегып һәм мескенләнеп калганын тойды. Мөхәммәт Закирович мәктәптә башка укытучылардан иң элек үзенең хәрбиләрчә төз гәүдәсе, команда биргәндәй кычкырыбрак сөйләшүе, кискенлеге белән аерылып тора иде. Ул бервакытта да укучыларның озаклап, тәфсилләп җавап бирүләрен яратмый, бераз ык-мык итә, белмәгәнен яшерү өчен, теленә килгән теләсә нинди сүзләрне әйтә башлауга ук урынга утырта иде. Әгәр дә ышанычлы итеп бер-ике җөмлә әйтсәң, артык сузып тормый, бишле куеп, көндәлегеңне суза, иңбашыңнан кагып, «гвардеец» дип елмая. Җавап бирә алмаганнарга бик рәхимсез, бары тик берле генә куя, өчле һәм дүртлеләр аның дәресләрендә бөтенләй юк иде. Һәр җәй саен укучыларны урманнарга алып чыга, алар белән бергәләп печән җыярга, чөгендер сирәкләргә бара, балык тотарга төшә.

Шушы мәһабәт гәүдәле, беркайчан да боегу, кайгыру белмәс Мөхәммәт Закировичка хәзер ул таныр-танымас карап торды. Аның күзләрендәге, йөзендәге ышаныч юкка чыккан, гәүдәсе шыксызланып калган иде.

— Әй, Мөхәммәт Закирович, сезгә нинди үпкәм булсын минем! — диде ул, аны юатырга, аның күңелен күтәрергә теләп.— Аттестатка барыбер бишле куйдыгыз бит.

— Сезнең класстан егерме өчегезнең унбере вузга керде... Ничек, абага яфрагының нинди икәнен беләсеңме

соң инде хәзер? Абага яфрагы нинди төр яфракларга керә, дигәч, нәрсә дигән идең әле?

— Яшел, дигән идем. Берле алгач, икенче көнне махсус урманга мендем. Яфрагының нинди икәнен беләм хәзер, чәчәген генә күргәнем юк әлегә...

— Әй-йе, абага яфрагы сыман катлаулы бу тормыш. Аннан да катлаулырак. Чәчәген дә табарсың. Менә безнең генә лимит чыккан... Кайтканда кергәләп йөр, югыйсә бөтенләй оныттың.

— Классташлар еш кайталардыр ич?

— Кайтуын кайталар... Коймак ашарга гына кайта бит алар монда. Мин дә, мәктәп тә, авыл да кирәк түгел аларга. Ә син бөтенләйгә кайттыңмы? Бик шәп, бик хуп! Әтиеңнең салам эшләпәсе күккә тигән инде болай булгач. Шәһәр төзибез, дисең инде алайса...— дип сузды Мөхәммәт Закирович һәм тирән итеп көрсенде. Аннары, мотоцикл янына килеп, Нурислам белән исәнләште.

Сөйләшергә сүз булмаса да, Ихтыяр тиз генә яңадан кузгалып китәргә кыймады, күңел өчен генә сораштыргандай итте:

— Каникулга чыктыгызмы?

— Быелгы язның рәте булмады бит. Кинәт җылытты да ташу суы бөтен җирне актарып ташлады. Бозып бетерделәр табигатьне. Җәе дә тернәкләнә алмый. Базга су төшкән иде, көне буе берүзем шуны түктем.

— Хәлимә апа кайда?

Укытучының иреннәре калтырап куйды, йөзе җыерылып килде:

— Ишетмәдеңмени? Декабрь аенда җирләдек бит Хәлимә апаңны. Каһәр төшкән рак...

Ихтыяр, ни әйтергә дә белмичә, шактый ара тын торды.

— Ялгыз гына яшисез инде, алайса,— дип сузды ул.

— Малайлардан да соңгы арада хәбәр-хәтер юк. Япаялгызым болын кадәр өйдә утырып калдым.

— Нигә фатирга кеше кертмисез соң? — дип кыяркыймас әйтте Ихтыяр.

— Кемне кертәсең? Шәһәрнекеләрнеме? Берничә көндә бөтен нигезеңне корытырлар. Әле авыл аша үткәнсүткәндә дә бакчаңны утамыйча китмиләр.

— Бакчага без дә керә идек. Малай-шалай эше генәдер анысы, ир-ат кеше койма башына үрмәләмәс.

— Күзләренә ак-кара күренми аларның. Сугышта, һөҗүмгә барыр алдыннан, безнең дә күңел шулай иләсләнә

торган иде. Янып калган авылларга да, хәтта кырыеңда егылып яткан иптәшләреңә дә карап торырга вакыт юк иде сугышта. Бары тик җиңү генә кирәк, җиңеп чыксаң, барысы да булыр, дип уйлыйсың. Болар да шулайрак...

— Хәлләр шактый мөшкел анда.

— Нәрсә булган тагын?

— Төзелешкә кеше килә тора, ә урнаштырырга урын юк. Окопта яши алмый бит инде алар.

— Тел төбеңне аңлыйм, Батыршин, әмма өемә чит кеше кертә алмыйм. Хәлимә апаң ничек җыештырып куйган булса, әле һаман әйберләр шулай тора.

— Сез укытучы кеше... Аннары, семьялы кешене керт-сәгез, үзегезгә дә эш җиңеләер. Гигант төзелешкә дә файдагыз тияр.

— Телең шактый шомарган, юкка укытмаганбыз икән үзеңне,— дип, койма буендагы утыргычка таба атлады Мөхәммәт Закирович.— Гигант төзелешкә сезне бирдек инде без. Аның өстенә, юл салабыз дип, ярты бакчаны сөреп ташладылар. Ике елдан соң гына акылларына килделәр: юл минем бакчага керми үтә икән.

Койма артыннан баш очларын чыгарып, сагаеп кына тыңлап торган яшел алмалы алмагачлар кинәт исеп киткән җилдән калтырап куйгандай булдылар.

— Борчыдык, гафу итегез...— дип кулын сузды Ихтыяр.— Киттек без.

— Аңлыйм мин сине, Ихтыяр. Эшчеләрне урнаштыру ягын кайгыртып йөрисең булса кирәк. Хәзергә миңа тими торыгыз. Авыр вакытым. Бераз тынычланыйм. Аннары, бәлки, үзем дә шәһәргә күчеп китәрмен. Менә бу сигезенчеләрне генә чыгарыйм да... Сез тимерче Габбасларга кереп карагыз. Элек-электән колхозга килгән кеше шуларга төшә иде бит.

Тимерче Габбасның хатыны аларны өйалды баскычында каршы алды.

— Юк, юк, шәһәрнекеләрне кертмим! — дип чәчрәп китте ул.— Әтиең Тимерхан кисәтеп куйды. Болай да кеше өзелми бездән.

Моңа кадәр сүзгә катнашмыйча мотоциклына таянып торган Нурислам, Ихтыяр борылып килгәч, көлемсерәп куйды:

— Көтеп торган кеше юкмы? Әллә безнең тактика дөрес түгелме? Әйдә, болай итеп карыйк әле. Эвакуация дәвам итә!..

Ул мотоциклын аягына бастырып куйды да боегыбрак утырган кечерәк йортның капкасын ачты.

— Монда, минем прогнозлар буенча, ялгыз карчык яшәргә тиеш.

— Каян беләсең?

— Йорт та, каралты да шактый таушалган.

— Бәлки, ялгыз карттыр?

— Ялгыз карт булса, капка төпләре себерелгән, койма буена утыргыч ясап куелган була. Шулай бит, әби?

Ишегалдында тавыкларга җим сибеп йөргән карчык үзе белән исәнләшәләр дип белде, ахрысы:

— Бер көе генә әле, биргәненә шөкер,— дип җавап кайтарды.

— Пенсияне вакытында китерәләрме, әби?

— Төрле чагы була инде. Пучты ташырга кеше юк бит. Сипкелле Сәлимә шәһәргә савыт-саба юарга барып кергән.

— Малайлардан хәбәр-хәтер киләме? Хат язалармы, дим?

— Онытканда бер килә. Донбасстагысыннан, Ислам улымнан гына хәбәр-хәтер юк.

— Ничек хәбәр-хәтер юк? — дип, Ихтыярга күз кысты Нурислам.— Ә безне нигә килгән дип уйлыйсың? Малаеңнан сәлам алып кайттык.

Карчык, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, аларга күтәрелеп карады. Күз читләрендә яшь бөртекләре ялтырап китте.

— Яшьләрне танымыйм да, кем балалары буласыз соң үзегез? Каян күрдегез минем Исламымны?

— Без күрмәдек, әби. Кичә генә малаең яныннан бергә эшләгән иптәшләре килеп төште. Бүген эшкә урнашып йөри әле алар. Шуңа күрә сөенче алырга ашыктык.

— И-и, миһербанлы балалар, аягыгыз-кулыгыз сызлаусыз булсын,— дип көйләде карчык.— Әйдәгез, нинди аяк өсте сөйләшү ди бу? Хәзер самавырымны яңартам.

Ихтыяр, нишләргә дә белмичә уңайсызланып, Нурисламга карый, ә тегесе күз генә кысып куя да һаман әби белән чөкердәшә бирә.

— «Сез кайтып урнаша торыгыз, киләсе җәйгә мин дә кузгалырга уйлап торам» дигән Ислам. Бүген кич үзләре дә килерләр әле. Барысын да сөйләрләр.

— Кайсы халыктан соң? Минем бер дә урысчам юк бит, улым.

— Күбәү алар, арада татарлары да бар.

— Килсеннәр, килсеннәр. Көздән кайнаткан варинҗәләрем дә исән, тозлаган казга да кагылыр кеше юк. Куна килсеннәр, иркенләп сөйләшеп утырырлык булсын.

— Әйтеп карармын. Әле торыр урыннары да юк аларның. Бүген дә конторада төн чыкканнар.

— И-и, адәм баласын шулай эт типкесендә йөртәләр димени? Урын тапканчы, монда гына яшәсеннәр, олы ягым барыбер буш тора. Исламны кайчан кайта дип әйткәннәр дисең әле?

— Озакламый, дигән...

Ихтыяр берничә тапкыр сүзгә кушылырга да талпынып караган иде, ләкин Нурислам аны әбидән җилкәсе белән каплады.

— Ярый, әби,— дип канатланып урамга таба атлады ул.— Кичкә кадәр сау булып тор!

— Чәй эчеп китәр идегез...

— Рәхмәт! Вакыт юк.

Сөмсере коелган Ихтыяр, мотоцикл янына килеп җитүгә, Нурисламга үпкәсен белдерергә ашыкты:

— Нигә алдадың инде Сания әбине? Хәзер Исламын уйлап, төннәр буе йокламаячак.

— Моңа кадәр дә йокламаган, барыбер уйлаган.

— Өч-дүрт кеше урнаштыру өчен — күпме ялган.

— Мин беркемне дә алдамадым. Малае барыбер, быел булмаса, киләсе елда әнисе янына кайтачак, аның төзелешкә урнашып калу ихтималы туксан тугыз процент. Килүчеләр арасында Донбасстан кешеләр юк дип уйлыйсыңмы әллә? Булмаса да куркыныч түгел. Ялгыз карчык янына урнашып, аның күңелен күрү начар нәрсәмени? Бераз гына фантазия... Кешеләрнең психологиясен аңларга кирәк. Ике капка төбеннән борылып киттек бит инде. Ә безгә бер атна эчендә дүрт йөз төзүчене урнаштырырга кирәк.

— Ләкин алдап-йолдап түгел.

— Мине процесс кызыксындырмый, нәтиҗә кирәк, нәтиҗә!

Бу капка төбеннән тизрәк китәсе килә иде Ихтыярның.

— Әйдә, өйдә көтә торганнардыр,— дип, мотоциклның арткы утыргычына менеп атланды ул.— Эчтә ач мәчеләр чиный.

— Ашыкмале!

Әле генә карчыкны күндерә алуыннан канатланып кит-

кән Нурислам каршы як йортның капка төбендә утыручы карт ягына таба ашыкты. Аякларына киез ката элдергән, өстенә ап-ак күлмәк, башына кара кәләпүш кигән түгәрәк сакаллы карт, аны зурлап, ике кулын биреп исәнләште.

— Утырабызмы, бабай? Безне көтәсеңме? — дип, сүзне шаянлап башлады Нурислам.

Солтан карт аптырап калмады, хәйләкәр итеп җавап бирде:

— Поезд көтеп утырам әле.

— Нинди поезд? Берәрсе кайтамы әллә? — дип чынга алды Нурислам.

— Ә-әнә тегендә барырга күптән билет алып куйган идем.— Ул, башын борып, авыл читендәге зиратка таба ишарәләде.— Инде ничә ел көтәм, килми дә килми.

— Зират шәһәр астында калачак. Каберләрне күчерәчәкләр, урынын тигезләячәкләр, өстенә бетон җәячәкләр. Юкка көтәсез поездны, район советы карары буенча, бүгенге көннән башлап Ташлыяр кешеләренә үлү...— ул, уңайсызланып, тавышын акрынайта төшеп дәвам итте,— катгый рәвештә тыела...

— Эһ-һем, алай икән...— дип сагаеп калды Солтан карт.

— Ышанмагыз аңа, юри сөйли ул,— диде ашыга-ашыга Ихтыяр.

— Район советыннан гына торса, анысын ничек тә җайлар идек, аннан тормый шул,— дип, таягына ике кулы белән таянды карт.— Мин генә түгел, бөтен авыл вокзалдагы кебек хәзер. Барысының да әйберләр төйнәлгән. Барысы да поезд көтә.

— Малайлардан хәбәр-хәтер юкмы? — дип, сүзне кирәкле җайга борырга булды Нурислам.

— Хәбәрләре дә, хәтерләре дә юк...— Карт иелә төште.— Өчесе тиң сугыштан кайтмады. Авылны тотып торган егетләр иде. Алар исән булса, болай капка төбендә каңгырап утыра торган кешеме соң мин? Күңел бит ышанмый, һаман кайтып килерләр сыман.

— Үз улларың шикелле әзмәвердәй ике-өч егетне фатирга кертмисеңме соң, бабай? Кадерләп түр башында гына утыртырлар үзеңне, йорт-кураны да карашырлар.

— Утыртырлар... төп башына. Инде күп утырттылар. Мал йөри торган бөтен болынны трактор белән таптатып бетергәннәр. Бөтен яктан кырып-бетереп киләләр, саран-

ча кебек. Инде зиратка да тотынмакчы булалар икән.— Ул тураеп басты, таягы белән каты итеп җиргә төртте.— Беткән идеме шәһәр салырга буш далалар?! Юри каныга алар монда, махсус монда сала. Беткән — бетсен, ди торганнардыр. Моңа кадәр бетмәгәнне, Аллаһы боерса, моннан соң да яшәрбез! Тиеп кенә карасыннар зиратка! Куллары корыр!

Солтан картның чыгырдан чыга башлаганын күреп, Ихтыяр читкәрәк китеп басты.

— Психологик экспериментлар барып чыкмадымы? — дип мыскыллы елмаеп каршы алды ул Нурисламны.— Со-ци-олог! Комганлы әбиләргә генә үтә икән бу алым...

— Алайса, әйдә, үзең сөйләш,— дип мыгырданды Нурислам.— Авызыңа су капкандай тик торасың. Кем авылы бу: синекеме, минекеме? Безнең авыл булса, сөйләшеп тә тормас идем мин.

— Әтәч кычкырмаса, таң атамы?

— Монысы тагын ни дигән сүз?

— Шулай булгач, кычкырма.

— Ярый, мин ләм-мим. Хәзер синең чират.

— Әйдә, әткәй янына кайтып киңәшик әле.

Нурислам мотоциклга тиз генә сикереп менмәкче иде, кабынмагач, иелеп актарынырга тотынды.

— Бензин беткән,— диде ул һәм ачу белән чертләтеп җиргә төкерде.— Шул гына җитмәгән иде.

— Таптың кайгырыр нәрсә. Киттек, әйдә, тот руленне.

Мотоциклны урам читендәге трактор янына куйгач, Ихтыяр, җил-җил атлап, чәчәкле-чуклы өр-яңа урыс капкага таба атлады.

— Яшьти! — дип кычкырды ул, капканы ачуга.— Яшьти, өйдәме син?

— Кайда булыйм тагын? Трактор өйдә булгач, мин дә өйдә инде,— дигән тавыш ишетелде.

Ишегалдында беркавым шау-гөр килеп алдылар да тагын тындылар.

Бераздан чиләге белән бензин күтәргән егет мотоцикл янына килде дә эшлекле кыяфәт белән Нурисламга эндәште:

— Ихтыяр чакыра, керә торыгыз, хәзер бугазыннан тутырып куям мин аны.

Егетнең күптәнге таныш кебек исе китмичә сөйләшүеннән, хәтта исемен әйтеп исәнләшеп тә тормавыннан хә-

тере калса да, Нурислам ишегалдына таба атлады. Капканы ачып керде дә шаккатып туктап калды. Ишегалды өстенә корылган киртә түбә аша төшкән кояш нурларыннан аяк астындагы ком, гәрәбәдәй сап-сары төскә кереп, күзләрне чагылдыра, түрдә яктырып-балкып өр-яңа мунча утыра, ишегалдының уң ягындагы бакчадан чәчәк исе килә. Бар җирдә пөхтәлек, чисталык, хәтта аяк басарга да куркып торырсың.

— Яши белә халык,— дип, лапас-кура арасыннан Ихтыяр килеп чыкты.— Минем яшьти бу, Әхмәт, бер класста укыдык.

— Авылда ничә классташың бар?

— Егерме өч иде. Хәзер бер Әхмәт кенә. Калганнары ил буйлап чәчелде...

— Чәчелсә, туганнары, әти-әниләре калгандыр бит? Димәк, алтмыш тугыз кеше.

— Нәрсә, нәрсә?

— Һәрберсенә өчәрне кертсәң, барлыгы алтмыш тугыз кеше була, дим. Моның белән артык сузып торма, турыдан-туры башла.

Ихтыяр, өйрәтмә дигәндәй, аңа кул селтәде.

— Ишегалдының яме юк әле, менә көз җиткәч күрерсез, бу киртәләрне үрмә гөлләр урап ала, бакчада алмагачлар сыгылып утыра. Әйдәгез, өйгә керәбез,— дип, Әхмәт болдыр баскычына килеп басты.— Әйдә, яшьти, кыста кунакны. Үзеңне күрмәгәнгә дә бишбылтыр.

— Без йомыш белән йөри идек. Вакыт ягы тар, башка чакта,— дип сөйләнде Ихтыяр.— Төзелешкә көне-төне кеше агыла, ә торыр урыннары юк.

— Мине дә чакырганнар иде. Өр-яңа бульдозерга утыртабыз, дип кызыктырып та маташтылар. Китсәм, әллә кайчан китә идем инде мин шәһәргә. Һава җитми анда, тын кысыла. Әйдәгез әле, түргә үтегез әле. Хәзер бер кызыл кикриккә Аллаһы әкбәр әйтәбез. Суыткычта ак алъяпкычлы түтәй дә көтеп утыра.

— Эшкә чыктым мин. Төшкә генә кайтып барыш. Ярамый. Кешеләрнең торыр урыны юк анда...

— Табылыр,— дип сузды Әхмәт.— Юкка кайгырасыз. Төзелеш тулы такта, бүрәнә,— йорт сал да кер. Хөкүмәт фатиры җитешкәнче ярап тора ул. Менә без бу мунчаны бер атнада өлгерттек.

— Авыл күчәргә тора, ә син һаман каралты-кура яңартасың,— дип гаҗәпләнде Ихтыяр.

— Син әйтте дип, алай тиз генә кубарылып китәргә исәп юк әле.— Әхмәт исе китмичә генә Ихтыярга сөзеп карады.— Без — крестьян халкы, тик торырга өйрәнмәгән. Эшләсәк, булсынга дип эшлибез, йорт салсак, мәңгелеккә салабыз.

— Җиргә генә мәңгелеккә килеп булмый.— Нурислам, сүзнең озынга китүен күреп, әңгәмәгә катнашырга булды.— Авыл күчәме-күчмиме, барыбер аңа шәһәр белән алыш-биреш ясап яшәргә туры киләчәк. Әллә бу дуслык элемтәләрен хәзер үк башлап җибәрикме, Әхмәт дус?

— Без болай да дошманнар түгел.

— Эшлекле элемтәләр турында бара сүз. Ягъни мәсәлән, сез хәзер берничә төзүчене үз куышыгызга аласыз, кыскасы, аларны фатирга кертәсез, ә киләчәктә шәһәр сезгә ярдәм кулы сузачак, теләсәгез, иң яхшы йортыннан менә дигән фатир бирәчәк.

— Юк инде, туган,— дип, тешләрен ялтыратып елмайды Әхмәт.— Кешеләрең дә, әбрәкәйле фатирың да кирәк түгел. Авылны күчерсәләр, язмыш икән, вакыты җиткәч, күчәрбез, яңа җирдә тормыш корырбыз, әмма ләкин шәһәрдә түгел. Унынчы катка менеп, саескан баласы шикелле, нишләп каңгырып утырыйм мин анда?! Бу сыер, бу сарыклар, каз, тавыклар кайда кала?! Иртән әтәч кычкырганга уянып, малларны көтүгә кумагач, кич аларны капка төбенә чыгып каршы алмагач, нинди тормыш ди ул?! Кибеттәге туң балыкка алданып, боларны ташлап китәмме соң!

— Ярый, ярый, сине шәһәргә күчәргә кыстаган кеше юк әле,— дип бүлдерде аны Ихтыяр.— Кистереп әйт, кертәсеңме кеше өеңә, юкмы?

— Керегез, дип чакырып торам ич. Кайчан килсәгез дә, сезгә ишегем ачык.

— Уенга борма. Кеше башына унбишәр сум түлибез. Дүрт кешегә — алтмыш көмеш. Эчеңне төртеп тишмәс.— Ихтыяр, Әхмәтнең акча ягына бик хирыс икәнен искә төшереп, шуның белән алдырып карамакчы булды.

— Хәзер акчага кытлык заман түгел. Безнең бар нәрсәбез дә җиту. Татарстанда беренче урынны алгач, «Жигули» да биреп куйдылар әле. Тимерхан абыйга рәхмәт, эшләгәнне күрә белә. Кемнәр акчага мохтаҗ, шулар кертсен әнә. Үзегез дә әйтеп торасыз, тагын күпме яшисе калгандыр бу нигездә... Үзебезчә яшәп калыйк әле.

— Бензин өчен рәхмәт! — дип саубуллашырга кул суз-

ды Ихтыяр.— Класссташ буларак, синнән моны көтмәгән идем. Миңа да йомышың төшәр, дөнья без уйлаганча ук киң түгел.

— Кешедән булдыра алганны, кулыннан килгән нәрсәне генә сорарга кирәк. Югыйсә аңа да уңайсыз, үзең дә кыен хәлдә каласың.

— Аңлашылды,— дип кырт кисте Нурислам.

Әхмәтнең аларны болай гына чыгарып җибәрәсе килми, егетләрнең үпкәләвеннән аның да җаны кыйнала башлаган иде.

— Мин берүзем генә түгел,— дип акланырга тотынды ул.— Әти-әни, намаз өстендәге әби. Шулар янына тагын өч бала. Һәр семьяның үз тәртибе, үз гадәтләре, үз законнары. Менә шунда күз күрмәгән чит кешеләр килеп керсен әле. Кунакларның телевизор карыйсы бар, дип, әбине намазлыгыннан куып төшерә алмыйм ла мин. Аннары өйдә табак-савыт та шалтырамыйча тормый, төрле чак була.

— Ярый, ярый, үз өеңдә үзең хуҗа була алмагач, синең белән артык сөйләшеп торудан файда юк,— дип, капканы шапылдатып япты Ихтыяр.— Чәберчек идең, һаман Чәберчек булып калгансың икән.

— Бәлки, хуҗа булганга шулай кыланамдыр,— дип кычкырды арттан Әхмәт.— Башта авылдан чыгып качалар да кайтып тагын шул авылга каныгалар. Киткәнсез икән, бөтенләйгә китегез! Йөрмәгез монда дөнья бутап!

Ихтыярның сөмсере коелып төшкән булса, Нурислам, киресенчә, тантана итә иде. Ул, бак кырыена түгелгән бензинны чүпрәк белән сөртә-сөртә, аны үртәп эндәште:

— Хәлләр ничек, агитатор? Синең метод яхшыракмы, минекеме?

— Яңа заман кулагы! Коймасы артына кереп бикләнгән дә крепостьтагы кебек качып ята. Штурм белән дә алырмын димә. Әллә бөтенесе җыелышып, сүз берләшкән инде болар...

Алар, мотоциклга атланып, бетон юл буйлап элдерделәр.

* * *

Зәңгәргә буялган урыс капка төбенә килеп туктагач, Нурислам кыстатып-ялындырып тормады, гомер буе шушында яшәгән кеше кебек, мотоциклын капка төбендәге

чатлы баганага сөяп куйды да Ихтыяр артыннан өйгә керде. Маһруй апа мич тирәсендә кайнаша иде, аларны күрүгә, каушап, нәрсә әйтергә белмичә, аптырап калды.

— Кайттыгызмы, улым? — дип, бераздан телгә килде ул.— Кунак та бар икән. Кем дип әйтим? Күз күргән кеше түгел, димме? И-и, өлгерә алмадым бит. Бәлешне яңа мичкә тыгып маташа идем. Әтиең сәгать берләрдә кайтам, дигән ие. Үзенә күрә бәйрәм бүген. Беренче көн эшкә чыктың. Исән-имин генә эшләргә язсын инде...

— Ярый, алайса, без капка төпләрен әйләнеп керәбез,— диде Ихтыяр.— Нурислам, син артык ашыкмыйсыңдыр бит?

— Идарә башлыгы синең янда булырга әмер бирде. Әле йөреп-йөреп тә эш кыра алган юк. Нидер уйларга кирәк, болай бармый...

Алар, лапаска кереп, беренче күргәндәй, яңа ярып өйгән утын исен иснәп тордылар, абзардагы ак маңгайлы сөзгәк кара бозауның башыннан сыйпадылар. Аннары алма бакчасы түрендәге мунча янында озаклап сөйләштеләр.

Маһруй апа мич каршында ыгы-зыгы килсә дә, күңеле белән алар янында иде. Ул әле һаман Ихтыярның авылга кайтуына, бигрәк тә бөтенләйгә кайтуына ышанып бетә алмый, менә-менә ниндидер сәбәп чыгар да, соңгы өметләре булган төпчек малайлары тиз генә җыенып китеп барыр сыман. Кеше ияртеп кайтуын да шуңа бик үк өнәп бетермәде. Бу ят кеше аны каядыр китәргә кыстап-кодалап йөридер, шуңа беренче көннән үк артыннан калмыйдыр кебек иде аңа. Ләкин Ихтыярның мал-туар, каралты-кура тирәсендә үз булып, күңеле ятып, рәхәтләнеп йөрүен күргәч, борчулары басыла төште.

Ишегалдын әйләнгәч, алар, эшлекле кыяфәт белән сөйләшә-сөйләшә, капка төбенә чыктылар. Каршыдагы коеның агач чиләген тутырып су алдылар, тешләрен камаштыра-камаштыра, көлешә-көлешә су эчтеләр. Читтән карап торганда, алар мәктәптән кайтып уйнарга чыккан авыл малайларын хәтерләтәләр иде.

Инеш буена җиткәч, Нурислам, атауга карап, тел шартлатып алды.

— Менә сиңа Робинзон утравы! Кем яши анда? Нинди бәхетлесе гомер сөрә?

Ихтыяр, әйтергә дә, әйтмәскә дә белмичә, беркавым кыенсынып торды, аннары теләр-теләмәс кенә:

— Безнең бабай...— дип куйды.

— Яшәп тә карыйлар кешеләр, да-а! — дип, аның саен гаҗәпләнә барды Нурислам.— Бер үзенә — бер утрау.

— Утрау түгел, атау ул. Җәй көне инешләрнең суы чыпчык тезеннән генә кала.

— Кем белән яши соң ул синең Робинзон бабаң?

Ихтыяр, бик теләмәсә дә, бабасы турында сөйләмичә булдыра алмады.

— Менә шулай...— дип, сүзен тәмамлады Ихтыяр.— Катмарлы кеше ул безнең бабай, роман герое булырлык.

— Эк-зем-пляр! — дип сызгырып җибәрде Нурислам.— Мондыйлар сирәк очрый хәзер.

— Сирәк, дип, һәр авылның бер сәер кешесе була инде ул. Аңламый башладым әле мин бабайны. Соңгы арада аралар суынды. Әллә нишләгән ул. Җанына урын таба алмый.— Ихтыяр, иелеп, җирдән таш алды да, бар көченә кизәнеп, инеш аръягына ыргытты. Таш тал кәүсәсенә килеп бәрелде.— Малай чакта атауны алышлы уйный идек. «Зимний» дип атый идек без аны.

— Алып була идеме соң «Зимний»ны?

Ихтыяр җавап бирмәде, таш алып, тагын атау ягына ыргытты.

Нурислам инеш кырыена ук килеп басты. Атау аны үзенә тарта, мөмкин булса, ул хәзер үк шунда йөгереп кереп китәр иде.

— Элек урам буйлап җырлап йөри идек. Хәзер җырлап кара, исерек, дип, гаҗәпләнеп калырлар... Бабаңның да бернинди сәер нәрсәсе юк. Дөнья үзгәрә, халык үзгәрә, ә ул һаман бертөсле, ә ул һаман үзгәрми. Шуңа сәер тоела.

— Ни өчен үзгәрми соң ул? Социолог буларак, син моны ничек аңлата алыр идең?

Ихтыярның инде атна буе күңелен борчып йөргән уйларны тизрәк очлап куясы, бу туйдырган темадан читкә китәсе килә иде.

— Катлаулы хәл,— дип, кашларын җыерды Нурислам,— берничә сүз белән генә җавап бирүе кыен. Ләкин бер нәрсә ачык: чорыбызның, дөресрәге, тарихның кискен борылышларында, җәмгыятьне баштанаяк үзгәртеп кору периодында килеп чыга торган котылгысыз хәлләрнең берсенә ачык мисал бу...— Нурислам, Атау Зыятдинның тормыш юлын берьюлы күз алдыннан кичерергә теләгәндәй, инеш аръягына карап, уйга чумып торды. Анда карга та-

вышларыннан башка бүтән бер өн дә ишетелмәгәч, җан иясе күренмәгәч, сүзен дәвам итте: — Без кайчакта, яңаны корабыз дип, искене төбе-тамыры белән чабып атарга ашыгабыз һәм бик ялгышабыз. Революциядән соңгы елларда «капитализм калдыгы» дип аталган күпме архитектура үрнәкләрен — мәчетләрне юкка чыгардык. Бу очракта табигатьтән өйрәнергә, аннан үрнәк алырга кирәк иде безгә. Менә син игътибар белән табигатькә кара әле. Табигатьтә бер нәрсә дә артык түгел бит. Карт агач корый икән, череп, ашлама була... Ә-әнә теге яр буендагы ауган тал кебек...

— Аның черегәнен көтеп торсаң,— дип бүлдерде Ихтыяр.

— Ә без көтеп тормыйбыз. Безнең сүз — закон! Безнеңчә уйламаган, безнеңчә яшәмәгән кеше — искелек калдыгы. Менә бу авыллар да искелек калдыгы.— Нурислам, кулы белән изәп, атауга, Ташлыярга күрсәтте.— Аның хәзер безгә кирәге бетте. Без аны төбе-тамыры белән себереп түгәбез дә тап-такыр мәйданда яңаны корып куябыз...

— Нәрсә? Ни дисең?

Ләкин Нурислам сорауны ишетмәдеме, әллә урынсыз сүз ычкындыруын аңладымы, җавап биреп тормады, тавышын бераз йомшарта төшеп дәвам итте:

— Чөнки такыр җирдә эшләү рәхәт, чөнки анда сиңа комачау итүче юк. Ләкин моның өчен табигать киләчәктә бездән үч алмасмы?

— Димәк, син табигатькә яраклашырга чакырасың.

— Яраклашырга түгел, аның белән дус яшәргә, аның законнары белән исәпләшергә кирәк.

— Табигатьтә үзгәреш бик акрын бара. Ә без бу темплар белән яши алмыйбыз. Әнә, имән меңәр ел яши, аның ашыгыр җире юк. Безнең гомер күз ачып йомганчы үтә дә китә. Шуңа ашыгабыз, шуңа вакытны ашыктырабыз.

— Ашыктырып пешергән ашның тәме булмый.

— Урынсыз чагыштыру. Табигать гомер-гомергә кешегә хезмәт итеп килгән, хәзер дә хезмәт итәргә тиеш. Без — табигать балалары, яңа буын. Ә яңа буын үткән буыннардан өлгеррәк тә, акыллырак та, куәтлерәк тә була. Бары тик шул чакта гына прогресска ирешәбез, бары тик шул чакта гына алга барабыз. Алга, дибез, алга, дибез, алга таба барабыз...

Нурисламның, тик торганда шулай бүленеп, җыр көй-

ли башлавы ничектер урынсыз тоела, Ихтыярның күңелен үрти иде.

— Без сыйныфсыз җәмгыять төзибез,— дип бүлдерде ул Нурисламны.— Бездә хуҗалар да, хезмәтчеләр дә булырга тиеш түгел. Бу нәрсә табигатькә дә кагыла.

— Дөрес уйлыйсың, егет, безнеңчә! Чыннан да, ни өчен дип табигать гел кешегә хезмәт итәргә тиеш, ни өчен ул үз мәнфәгатьләрен кайгырта алмый? Без артык эгоист, без Җир шарында үзебезне хуҗа дип саныйбыз, барысы да безнең теләккә буйсынырга тиеш, дип уйлыйбыз. Мәсәлән, бу атауларга, бу авылларга, конкрет килгәндә Ташлыярга, искелек калдыгы дип карарга кем рөхсәт биргән? Беркем дә бирмәде, һәм без ул рөхсәтне сорап та тормадык. Чөнки безгә шулай яхшы, безгә шулай кирәк һәм — вәссәлам! Ә калганнар ник кырылып китми шунда...

Ихтыяр да, аны җөпләп, сүзгә кушылды:

— Искелек дип түгел, ә кешелекнең гасырлар буе җыеп, саклап килгән тәҗрибәсе дип карарга кирәк аларга. Югыйсә без озакламый велосипед уйлап чыгарырга мәҗбүр булачакбыз.

— Һичшиксез, шулай. Искелек, син әйтмешли, кешелекнең тормыш итү тәҗрибәсе, органик төстә яңалык белән берләшергә, яңалык такыр җирдә түгел, шул тәҗрибә нигезе өстендә корылырга тиеш.

— Нәкъ минем бабай төсле сөйлисең син,— дип, атауга таба баш какты Ихтыяр.

Инеш буендагы өянкегә сөялеп сөйләшә торгач, алар бөтен дөньяларын оныттылар.

Дөресрәге, күбрәк Нурислам сөйләде, чөнки аның тормыш тәҗрибәсе дә баерак, әйтер сүзләре дә күбрәк, теле дә шомарганрак иде. Ихтыярга әле барысы да кызык, барысы да яңа. Үзе керәсе диңгезнең капитаны кебек рухланып сөйләүче Нурисламның бер сүзен дә читкә җибәрергә теләмичә, күңеленә сеңдереп тыңлый иде ул. Аның әңгәмәгә артык кушылып китмичә, читтән карап, онытылып торуын күргәч, Нурислам сорап куйды:

— Мин сөйлим дә сөйлим. Авызны томалаучы булмагач, бөтенләй иркенләп киттем. Алҗытып бетергәнмендер инде.

— Кая ул алҗыту! Яңабаштан институтта укый башлагандай булдым. Тормыш институтлары узам. Кайту белән бабайның кыска сроклы курсларында тарих һәм фәл-

сәфә дәресләрен тыңладым. Ә менә хәзер синең җитәкчелектә социология фәнен үзләштерәм.

— Көлүеңме бу?

— Юк, юк, чынлап әйтәм.— Ихтыярның чыраена җитди төс чыкты.— Җир шарында чирек гасыр яшәп, мондый сүзләр ишеткәнем юк иде әле минем. Бар икән күрәселәр, утларга керәселәр,— диде ул.

— Сөйләвеңә караганда, бабаң буш кеше түгел синең. Тик вакытында ачкыч таба белмәгәннәр аның күңеленә.— Нурислам чирәмгә утырды.— Ә хәзер соң инде. Карт өянкене бөгеп булмый, кисеп аударсаң гына...

Инеш буен тутырып, әнисенең тавышы ишетелде:

— У-у-лым, Ихтыяр! Керегез! Ризык суына. Әтиең дә кайтты. Тизрәк булыгыз!

Әтисе аларны болдыр башында көтеп тора иде.

— Сөйлә әйдә, эштә ничек каршы алдылар? Харрас Шәмгунович янына кердеңме?

— Эшне җыелыштан башладык әле, хәерлегә булсын,— дип көлемсерәде Ихтыяр.

— Нигә таныштырмыйсың? Кунак кем була?

— Нурислам Фарукшин. Төзелеш идарәсеннән, социолог.

Тимерханның йөзе кинәт кенә сүрәнләнеп китте, каш уртасыннан ике буразна аска таба ярылып төште. Ләкин ул, кәефе кырылганны сиздермәскә тырышып, сүзне уенга бормакчы булды:

— Безнеңчә итеп әйткәндә, Ташлыяр авылына кабер казучыларның берсе була инде.

Тимерханның сүзен уенга алучы булмады, киресенчә, өйдә авыр тынлык кына урнашты. Ул, авырткан җирен корт чаккан кебек, кинәт кенә тынычлыгын югалтты, урынында тик утыра алмыйча, боргалана башлады.

— Бусагаңны беренче атлап кергән кунакка алай каты бәрелмә әле, әтисе,— дип сүзгә катнашты Маһруй.— Дөнья кайгысы беркая да качмас, баскыч төбендә чыкканыңны сагалап торыр. Өстәл янында иркенләп утырыгыз. Бәлешнең кырын кисегез... и-и-и, алтмышны тутырып та кермәсә кермәс икән акыл...

Әнисе бүген Ихтыярга да, аның белән кайткан кунакка да авыр сүз әйттермәскә тырыша, әтисе алай-болай каты бәрелеп, төпчек улының туган йорттан, бу яклардан күңеле кайтыр дип шикләнә, шуңа күрә ирексездән шәһәрне якларга мәҗбүр була иде.

— Шәһәр ни дә авыл ни сиңа, казан астың исән булса, шул җиткән. Күпме чакырып күрше авылга да барганың юк бит, адәм көлкесе,— дип, Тимерхан аңа кырку гына җавап бирде.

— Мин бармасам, үзләре килеп торалар бит. Әнә, авылыбыз кырыена шәһәр булып шәһәр үзе килде, улыбызны да рәхмәте белән ияртеп кайтты. Тора да шул шәһәргә каныга! Синең белән миннән дә акылсызрак кешеләр уйлап тапмагандыр инде ул шәһәр дигән нәмәстәне, кирәкмәгәнгә тора салып басу уртасында кала корырга тотынмаганнардыр.

Бу уңайсыз хәлдән, авыр бәхәстән котылу өчен, сүзне тизрәк икенчегә борырга кирәк иде. Ихтыяр, әнисенең тукталганын гына көтеп торды да, ашыгып үз сүзен кыстырды:

— Туганнардан хат киләме?

Әтисе җавап бирмәде, бүлмә яктан тагын әнисенең тавышы ишетелде:

— Килгәненнән килә, килмәгәненнән юк инде. Кызлар артык зарыктырмый, айга — бер, кайда — бер дигәндәй, әле хатлары, әле күчтәнәчләре килеп тора, Аллага шөкер. Илфат белән Зөлфәт кенә онытты.

Сүз балаларга килеп терәлгәч, Тимерхан да йомшарды, җиңнәрен сызганып чәй ясады да, башын кыңгыр салып, Маһруена карады. Тегесе, иренең җылы карашын күргәч, янәшәсендәге урындыкка килеп утырды.

— Зөлфәт, үткән ел кайтып, сабантуй батыры булып китте,— диде Тимерхан.— Илфатыннан көзен бер хат килгән иде. Анысының җиде ел кайтканы юк бит инде. Һаман шул машина алабыз дип бетеренәләр. Чиратлары да килеп терәлгән бугай инде. И-и, гөнаһ шомлыгы, машинага җыям дип, юлга кайтырга акча жәлләп, тиен санап ят инде! Тфү! Кешедән оят! Чәберчек Әхмәт тә алды ул машинаны, эшли башлаганына биш ел гына югыйсә. Ничек кенә алды әле! Бүләк итеп бирдек! Әллә кайларга да китеп йөрмәде.

Әнисе аның сүзен ялгап алып китте:

— Быел җәй җыелышып сабан туена кайтырга ниятлиләр бугай. Яңа кала төзелә башлагач, безнең авылның илгә-җиргә таралган яшь-кыркыны яңадан бу якларга агыла башлады бит. Аллаһы боерса, бәлки, безнекеләр дә шушында ныгып калырлар әле.

Тимерхан Маһруйга сөзеп карап куйды, ләкин авыз

ачып әйтергә сүз тапмады бугай, шопырдатып чәй эчәргә тотынды.

Тамак ялгап алгач, өчәүләшеп койма буендагы имән бүрәнә өстенә тезелешеп утырдылар. Тимерхан кесәсеннән «Беломор» алып кабызды. Шактый тын утырдылар. Нурислам китәргә ниятләп калкына башлагач кына, Ихтыяр инде берничә сәгать буе миен бораулап йөргән уйны ачып салырга булды. Ул, соңгы батырлыгын җыеп, этисенә сүз катты:

— Әткәй, минем сиңа, дөресрәге, безнең сиңа бер үтенечебез, киңәш итәсе сүзебез бар иде.

Нурислам, эшнең нәрсәдә икәнен чамалап, яңадан бүрәнә өстенә утырды.

— Әйткәнемчә, идарәдә җыелыш булды бүген. Бару белән, баш инженер шунда җитәкләп алып керде. Төзелештә эшләр ал да гөл түгел икән. Җитәкчеләр дә Газраилгә охшамаган, нәкъ синең белән минем төсле кешеләр. Менә син Нурисламны «авылга кабер казучы» дип атадың. Ә ул — үзе авыл малае. Нигә үз-үзенә кабер казысын ди? Эш, син уйлаганга караганда, җитдирәк тора икән, әткәй. Киләчәктә ничек булыр, анысын күз күрер, ә менә бүгенге көндә шәһәр авылдан ярдәм сорый.

— Нинди ярдәм ул тагын? Сауган сөтнең тамчысын тамчыга аларга биреп барабыз, ит-майның бар булганы шунда китә, икмәкне әйткән дә юк. Шушыннан да зур ярдәм буламы? Шәһәр алдында, ил алдында йөзебез ак безнең. Колхозыбыз да төшеп калганнардан исәпләнми. Тик менә ашаган табагына төкерергә җыенучылар да бар.

— Кызма әле, әткәй. Кызган таш мунчада гына әйбәт. Шәһәр ярдәм кулын сузмаса, техникасын бирмәсә, кирәк чакта автобус-автобус кеше җибәрмәсә, әллә кая ерак китә алмас идең. Йоклаганда да шәһәргә арка куеп яту килешми.

Нурислам, Ихтыярның кирәкмәс бәхәс башлавын күреп, кулыннан тотты.

— Ихтыяр яңа кеше, төзелештәге хәлләрнең барысын да белеп бетерми,— дип, Тимерханны тынычландырырга ашыкты ул.— Нигә болай икәүләшеп аяз көнне каравыл кычкырырга гына торасыз соң әле? Йә, әйтегез, берәрегезнең «Ташлыяр авылын төбе-тамыры белән себереп түгәргә» дигән карар укыганы бармы? Тимерхан агай, кемкем, ә сез, мәсьәләнең асылын аңлагач кына, үзегезнең саллы сүзегезне әйтергә тиеш, минемчә.

«Әткәйнең салпы ягына, ай-һай, оста итеп салам кыстыра бу!» дип уйлады Ихтыяр.

Ләкин Тимерхан алай тиз генә егылып китә торганнардан түгел, Нурисламның шактый дәлилле сүзләренә чәчрәп чыгып каршы төшәргә җөрьәт итмәсә дә, үз фикереннән баш тартырга исәпләми иде. Ул, ашыкмыйча гына урыныннан торып, койма башына эленгән чиләктән тавыкларга җим сипте, җирдә яткан балтаны ачу белән бүрәнәгә чабып куйды.

— Нәрсә, Нурислам энекәш, генераль планга үзгәреш керттегезме әллә? — дип, хәйләкәр елмайды аннары.— Райкомда беренче секретарь Солтановның кабинетында үз күзем белән күрдем мин аны. Ташлыяр авылы урынына акка кара белән «Ял итү зонасы» дип язылган. Рәтрәт итеп шакмаклар тезелгән. Анысы сез төзисе йортлардыр инде, улым?

Ул Ихтыярга бераз инәлүле дә, бераз үпкәле дә караш ташлады.

— Ә авылны күчермичә генә ял зонасы ясап булмыймы? — дип, аннары Нурисламга борылды.

— Генераль план төзегәндә, безнең белән киңәшмәделәр бит,— диде Нурислам һәм аягына килеп сарылган ап-ак гәүдәле, кара башлы песинең сыртыннан сыйпады.— Генераль план буенча Ташлыяр шәһәр зонасына керә. Берничә елдан ул әкренләп бөтенләй шәһәр эчендә үк калачак. Шәһәр булгач, каз-үрдәк тотарга да, мал асрарга да рөхсәт ителми, бакча да бүлеп бирелми. Җирсез-малсыз авыл була алмый бит инде... Беркая да барып булмый, күчәргә туры киләчәк.

— Нигә күчерергә ди аны? Әле шушы арада бер журналда күрдем, шәһәр уртасына махсус берничә авыл өен күчереп салганнар. Шакмаклы, җансыз йортларга шул өйләр ямь биреп тора. Аннары, бер уйласаң, безнең авыл менә дигән ял итү урыны да бит ул. Урта Азиядә, Себердә, Донбасста яшәгән авылдашлар берсе дә диңгезгә бармый, ел саен монда ял итәргә кайта.

Ихтыяр, үзе дә көтмәгәндә-уйламаганда, күңелендә бер план тууына сөенеп, авызын ачып, тын торды. Ул, әле яңа гына туа башлаган хыялының сурәтен күрергә теләгәндәй, күзләрен йомды. Аннары кызып-кызып тагын сөйләп китте:

— Шушы өйләрне реставрацияләп, буяп-бизәп, каралты-кураларны төзекләндереп, урамнарга агачлар утыр-

тып, аяк астына ком белән чуерташ түшәп чыксаң, оҗмахка әйләнә бит безнең авыл! Шулаймы, социолог иптәш?

Һәм Нурисламның җилкәсенә шапылдатып ук сукты, тегесе авыртудан йөзен чытып куйды.

— Авыл язмышын бик җиңел генә хәл итмәк буласың әле син... Ә авыл халкын кая куймак буласың? — дип, үз сүзен китереп кыстырды Тимерхан.— Шәһәрнең тугыз катлы таш читлегенә шыплап тутырмакчы буласызмы? Рәхмәт! Андый акыллы тәкъдимнәр булды инде. Аннары безнең колхоз җирләрен кемгә бирерсез? Кем эшкәртер аларны? Кем иген игәр?

— Җирне хуҗасыз калдырмаслар,— диде Нурислам.

— Җир песи баласы түгел, теләсә кем башыннан сыйпаганга риза булып тормый! — Тимерхан аяк астында уралган песине кул аркасы белән читкә этәрде.— Һәр буразнасын, һәр үзәнен, һәр калкулыгын, һәр кишәрлеген беләм мин бу җирнең. Авылның һәр кешесе бу җирләрнең холкын белә. Чит кешегә тиз генә ияләшә алмый җир.

Тимерхан инде хәзер элеккечә үк кырыс сөйләшми, аның күзләрендә, сүрән генә булса да, очкыннар кабынган иде. Нурислам белән Ихтыярның каршы әйтергә базмыйча, тын гына тыңлауларын күргәч, ул тагын дәвам итте:

— Шәһәр йортларына күчкән кешене кырда эшләтә алмыйсың инде син. Барып чыкмаячак, бу вариант та барып чыкмаячак. Беренче секретарь шәһәрдә яшәтеп, авылда эшләтмәкче була безне. Яңа төр крәстиян барлыкка килә, ди. Килә, пычагым! Шәһәрдә яшәгән кеше җиргә төкереп кенә карый башлый ул. Психологиясе, холкы үзгәрә аның. Җирдән аерыла. Аягың җиргә тимәгәч, кендегең белән шул җиргә берекмәгәч, нинди крәстиян буласың ди син?! Берничә елдан таш йортларда яшәүче Ташлыяр кешеләренең шәһәр җилкуарларына әверелүенә иманым камил.

Шул сүзләрне әйтте дә, артык сөйләшүнең кирәген тапмагандай, Тимерхан кулын селтәде. Егетләрнең икесен генә калдырып, абзарга кереп китте.

— Ял итү зонасы да ял итү зонасы,— дип мыгырданды Нурислам.— Кешенең авырткан җиренә кагыласың. Врачлар да операция ясар алдыннан наркоз бирә. Авылның бетәргә тиеш икәнен үзе дә аңлый ул. Шуңа борчыла. Ә син аның ярасына тоз сибәсең. Әйбәтләп аңлат, кү-

целен күр. Ата белән ул булсагыз да, хәзер икегез ике лагерь кешесе сез. Шуны онытма. Бердәнбер юл — янәшә тыныч яшәү. Шуннан да әйбәт сәясәт юк.

— Үзең ничек яшисең соң? — диде аңа Ихтыяр һәм капка баганасына үрмәләүче песине куенына алып иркәләргә тотынды.— Бүгенге җыелышта бер дә янәшә тыныч яшәгәнгә охшамаган идең.

— Алар практиклар, бүгенге көн белән генә яшиләр. Зарплатадан зарплатага, кварталдан кварталга, премиядән премиягә кадәр. Алар үзләренең кабинетларыннан, ялтыравыклы өстәлләреннән башканы күрмиләр. Үзләрен дөнья тоткасы дип уйлыйлар. Әшли белү генә бик аз, уйлый белергә, гомумиләштерә, перспективаны күрә белергә кирәк бу заманда. Тагын берничә дистә елдан төзелештә дә, партия, дәүләт оешмаларында да эш башында социологлар, идеологлар утырачак! Шунсыз дөнья алга китә алмый. Эш түгел, идея йөртә кешене.

— Идарә башлыгы итеп куйсалар, риза булыр идеңме? — дип шаярып сорады Ихтыяр.

— Нигә көләсең? Булдыра алмас дип уйлыйсыңмы әллә?

— Райкомның беренче секретаре урынын тәкъдим итсәләр?

— Ашыкма, вакыты җиткәч, беренче дә булырбыз,— диде Нурислам.

Аның кысылган иреннәренә, җыерылган кашларына, кинәт кенә җитдиләнеп киткән йөзенә карагач, Ихтыярның елмаюы юкка чыкты.

Тимерхан алар янына килеп баскач, Нурислам сорау бирде:

— Тимерхан абый, әйт әле, сезнең авылда бүгенгесе көндә ничә йорт бар?

— Монысы нигә тагын? Йөз дә сиксән алты...

— Шуларның ничәсе буш тора?

— Ундүрт иде, ялгышмасам.

— Әй-йе... Пенсия яшендәге ничә ялгыз карт-карчык бар?

— Кырык өч.

— Аек акыл белән санап карасаң, авылның ничә гаиләсе бүгенге көндә шәһәр фатирына күчәргә атлыгып тора?

Урамда машина кычкырткан тавыш ишетелде. Тимерхан, капканы ачып, шофер егеткә бераз көтәргә кушты да, киредән егетләр янына килеп, әңгәмәне дәвам итте:

— Монысын төгәл генә беркем дә әйтә алмас. Кешенең күңелендә ни барын каян беләсең?

— Ну, чама белән, кара акыл белән исәпләгәндә, өчтән берсе риза булырмы?

— Шул чамага тартыр.

— Азрак,— дип офтанды Нурислам.

— Нәрсә — азрак? — Күкерт кебек кабынып китә торган Тимерхан лапастан алып чыккан сәнәкне ачу белән җиргә кадады.— Өч кешенең берсе — дезертир! Шушы да азмы? Әллә сез барлык кешенең дә авылны ташлап качуын телисезме? Шул яхшымы әллә сезгә?

— Азрак,— дип үҗәтләнеп кабатлады Нурислам.

Шулчак Ихтыяр сүзгә кушылырга булды. Ул күңеле белән этисен аңлый, аның хәленә керергә тырыша, ә акылы күбрәк Нурислам ягына тарта, тормыш дөреслегенең шул якта икәненә төшенә. Ләкин ул шушы минутта бу ике якның килешүен, аларның ямьсез һәм кирәксез бәхәскә кермәвен тели иде.

— Туктагыз әле, минем башка даһи уй килде,— дип, ярым шаяртып, ярым җитди итеп сүзгә кушылды ул.— Заманалар үзгәрде бит хәзер. Генераль планны эшләгән вакытта барсысын да уйлап утырырга вакытлары җитмәгәндер. Алар да кеше бит. Ә кешенең тормышы тоташ ялгышлардан һәм шул ялгышларны төзәтүдән тора, дигән бер акыл иясе. Бәлки, генераль планга төзәтмәләр кертеп булыр?

— Мондый мәсьәләләрне безнең ишегалдында түгел, Кремльдә хәл итәләр шул.

Этисенең үзенә малайсытып карап торуын күргәч, Ихтыяр кызып ук китте:

— Сезнең буын түрәләргә табынып өйрәнгән. Һәр нәрсәгә указ килүен көтеп ятсаң, ындыр артыннан ерак китә алмассың!

— Ярый, ярый, тынычлан, яшь этәч,— дип, этисе ягымлы итеп улына күз ташлады. Аннары папирос эзләп кесәләрен капшады. Тапмагач, өй ягына карап алды да, сүздән бүленергә теләмичә, ике кулы белән сәнәккә таянып, ияген йодрыклары өстенә куйды.— Безнең буынга кагылма син, улым. Безнең буынның илгә дә, көнгә дә яманлык кылганы булмады. Син әйтмешли, дөрес юлдан бармаган чакларыбыз да булгандыр. Әмма ләкин чын күңелдән яшәдек, чын күңелдән эшләдек. Ил алдында намусыбыз пакь, йөзебез чиста. Ә авыл халкын шәһәргә күче-

рү мәсьәләсенә килгәндә, турысын әйтәм, уйлап эшләнгән эш түгел бу. Теге вакытларда, мондый сүзләр сөйләгән өчен, стенага терәрләр иде. Шөкер, заманалар бүтән...

— Заманалар бүтән дә заманалар бүтән, дип кычкырабыз. Нәрсә үзгәрде соң? — дип, Нурислам чалбарын кагакага урыныннан торды.— Бернәрсә дә үзгәрмәде. Матуррак сөйләшергә, остарак итеп алдарга гына өйрәндек.

Тимерхан бу сүзләрне үзенә кабул итте, ахрысы, йөзен җыерды, тагын кесәсеннән тәмәке капшады.

— Сез ничектер, минем алдап-йолдап, хәйләләп яшәгәнем булмады,— диде ул.— Шуңа күрә хәзер дә турыдан ярам. Күчмим мин сезнең ул шәһәрегезгә, алтын таулары вәгъдә итсәләр дә, күчмим. Күрше урыс авылына көтүче булып керсәм керәм, әмма шәһәрдә яшәмим!

— Нигә Ташлыяр кешеләрен күчерергә соң әле? — дип, сак кына әйтте Ихтыяр.— Әгәр дә шәһәрдән читтәрәк, мәсәлән, югары басуның урманга уйдыкланып кергән урынында менә дигән йортлардан өр-яңа поселок салып куйсаң, шунда күчмәсләр дисеңме? Өч-дүрт бүлмәле кирпеч йорт, ишегалдында — сарае, келәте, мунчасы, абзарында — мал-туары, лапас артында җиләк-җимеш, бәрәңге бакчасы...

— Әкият... Кем төзи аны? Безнең колхозмы?

— Ә чыннан да шундый поселок төзи калсалар, күчәрләр идеме? — дип, Тимерхан каршына ук килеп басты Нурислам. Ихтыярның фикере аны да кызыксындыра башлаган, бу фикернең төбендә авыл белән шәһәрне килештерү, председатель Тимерханның, Ташлыяр кешеләренең борчулары белән исәпләшү, аларның кешелек горурлыгын санга сугу ятканын аңлый иде ул.— Күчәрләр дип уйлыйсыңмы?

— Белмим тагын... Председатель булсам да, бу мәсьәләдә бөтен авыл исеменнән сөйләргә кыенсынам... Башка чаралары калмаса, нишләп күчмәсләр икән? Янында каралты-курасы да булса! Тугыз катлы таш читлек кенә түгел инде ул.

— Монда ике генә вариант бар,— диде Ихтыяр.— Йә шәһәр фатирына күчәсең йә бөтен уңайлыклары булган авыл өенә. Өченчесе юк.

— Авыл, чыннан да, шулай тиз арада күчәмени инде? — Тимерхан бу сүзләрнең, бүгенге әңгәмәнең мәгънәсенә әле генә төшенгәндәй салмакланды, тагын кесәсеннән папирос эзләде.— Аңламыйм мин сезне. Башымны бутамагыз, турысын ярып әйтегез дә...

— Ашыкма әле, эткәй, үзең әйттең бит, райком секретаре бүлмәсендә Ташлыяр урынына «Ял зонасы» дип язып куйганнар, дидең. Шулай булгач...

— Ял итү зонасын читтәрәк салып булмый микәнни?

— Булмый шул,— диде Нурислам.— Ял зонасы эш урыныннан ерак булырга тиеш түгел. Кешеләр анда һәр көнне эштән соң барып хәл җыярга, ял көннәрендә кайтып-китеп йөрергә тиешләр. Ерак булса, артык мәшәкать. Бу ягын дөрес уйлаганнар аның.

Ихтыяр, үзенең фикерен тулысынча аңлатып бетерә алмагач, һаман тынычланмады.

— Мине Ташлыярның кешеләре генә түгел, йортлары да кызыксындыра.— Ул этисенең өйалдыннан тәмәке алып чыкканын көтеп торды да сүзен дәвам итте:— Яңа поселокка күчсә, авыл халкы сакланып кала, ә авыл үзе юкка чыга. Әгәр дә без Ташлыярның йортларын туздырмыйча, сүтмичә, шушы килеш шәһәр карамагына тапшырсак?.. Һәм шуның өчен алардан яңа поселок салуны сорасак? Шәһәрнең мөмкинлекләре зур, Ташлыярны яңадан туган кебек итәргә була! Рәссамнарны, реставраторларны чакырырга, үзебезнең авыл осталарын дәшәргә дә эшкә тотынырга! Әгәр дә шулай итсәң, менә дигән архитектура музеена охшап калачак безнең авыл! Шуннан, эткәй, үзең уйлап кара инде...

— Уйлыйм, уйлыйм... Ә сез җавап бирмәдегез бит әле: кем салып бирә безгә ул поселокны? Колхозның моңа көче җитмәячәк.

— Шәһәр салырга тиеш аны. Ихтыярның фикере дөрес.— Нурислам, китәргә вакыт җиткәнне аңлатып, бүрәнә өстенә салып куйган ботинкаларын киде.— Бергәләп тотынсак, ерып чыкмаслык эш түгел. Сез үз ягыгыздан кымтырыкласагыз, без дә кирәкле кешеләргә үз фикеребезне җиткерсәк... Җәмәгатьчелек фикере белән исәпләшмичә булдыра алмаслар. Өстә утыручылар да Ташлыяр кешеләренең дошманы түгел бит. Авызга су кабып утырмаска гына кирәк.

Нурисламның үз-үзенә ышаныч белән сөйләвен, этисенең дә бу фикергә ныклап каршы килмәвен күргәч, Ихтыярга канат үскәндәй булды.

— Бүген үк шәһәрнең баш архитекторы янына керик! Шуннан башлыйбыз! Ул хәл итмәсә, райкомга да, хәтта обкомына, Министрлар Советына да барып җитәрбез! Пролетариатның богавыннан башка югалтыр нәрсәсе юк, диме

әле Маркс? Ә безнең богавыбыз да юк! И-их! Күрегезче, реконструкцияләнгән, реставрацияләнгән өр-яңа Ташлыярны!

Аларның шулай очына-очына сөйләшүләренә, хыялланууларына карап тора торгач, Тимерхан үз күңеленең дә җиңеләеп, бушанып калганын, инде берничә ел буе борчуга салып, җанын кимереп йөргән авыр уйлардан әкренләп котыла баруын сизде. Ә Ихтыяр белән Нурислам, уенчык сарай төзегән хыялый малайлар кебек, Яңа Ташлыярда яши башлаганнар иде инде.

— Бер гаилә үзенең ял вакытында бер йортны арендага ала да ай буе шунда тора. Бәлеш пешерим дисә — миче бар, мунча керим дисә — мунчасы, бала-чагага да уйнарга урын җитәрлек. Кырым-Кавказларың бер якта торсын!

Нурислам, ял итәргә килгән кешедәй, ваемсыз кыяфәт белән бүрәнә буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Аның сүзләрен Ихтыяр элеп алып китте:

— Авыл кешеләренең дә күңеле кителмәде. Яңа җирдә тамыр җибәргәч, рәхмәт кенә укырлар әле. Яши торган йортлары — бер дигән, иске авыллары да үз урынында. Су астында кала торган авыллардагы иң матур йортларны да монда күчереп утыртырга була.

— Әй-әй, хыялый салам торханнар! — дип көлде Тимерхан һәм, әмер биргәндәй: — Әйдәгез, сезнең белән юкны бушка аударып, коры хыял белән хыялланып авыз коргаксыды,— диде.— Тагын бер чәйләп алыйк та, минем басуларны урап кайтасым бар. Болай торса,— ул, кулын каш өстенә куеп, кояшка карады,— уракка төшәргә дә күп көттермәс.

Өчәүләшеп шау-гөр килеп өйгә кергәч, Маһруй, нәрсә булган боларга, дип, бераз гаҗәпләнеп торды да, куанычын яшерә алмыйча, өстәл тирәли әйләнгәли башлады.

Чәен эчеп бетергәч, китәргә җыенып, Тимерхан урыныннан кузгалды, ишек янына килеп җитәрәк, нәрсәдер исенә төшеп, артка таба борылды.

— Шәһәр ярдәм сорый, дигән идегез. Ниндирәк ярдәм сорамак була соң ул бездән?

Ихтыяр үзләренең үтенечләрен ачып салырга һаман кыенсынып тора иде, шуңа кинәт кенә җай чыгуына сөенде. Әтисе дә онытмаган, барысын да хәтеренә салып барган икән.

— Төзелешкә эшкә килгән кешеләрнең торыр урыннары юк. Авыл кешеләре фатирга кертми,— дип аңла-

тырга тотынды Ихтыяр.— Шул сәбәпле күпләре төзелешне ташлап китәргә мәҗбүр була. Ә эшче көчләргә болай да кытлык зур чакта...

— Ничек кертми? — дип кырт кисте аны әтисе.— Алар белән юньләп сөйләшеп караган кеше бармы соң әле? «Мә, рәхим итеп кабул итеп ал!» дигәндәй, капка төбенә бер машина чит-ят кеше китереп ташласалар, үзең нишләр идең? Авыл кешесенең тиресе калын булса да, күңеле нечкә аның. Күңеленә кереп сөйләшкән кеше бармыни аларның?! И-их, сез калай сыбызгылар!

— Без сөйләшеп караган идек тә...

— Егылып китүче юкмы? Сезнең сөйләшү — бер нәрсә, сезне чит итә алар. Авыл кешесенең күңелен аңламыйсыз сез...

Тимерхан, тупсаны атлап чыккач, яңадан артка борылып әйтте:

— Бүген кич халыкны клубка җыеп сөйләшербез. Сез дә килегез. Миңа ниләр сөйләгән булсагыз, авыл халкына да шуларны аңлатырсыз. Яңа поселок турында да әйтерсез. Нурислам да килсен.

* * *

Ләкин эш алар уйлаганча ук гади булып чыкмады. Җыелыш җыеп, халык белән сөйләшкәннән соң, бер атна эчендә Ташлыярда дүрт йөздән артык кешене урнаштыруын урнаштырдылар, әмма, баш архитекторга барып, Ташлыярда ял зонасы ясау, шәһәрдәге тугыз катлы ике йорт урынына яңа поселок салу турында үз планнарын сөйләп биргәч, көймәләре комга терәлде.

— Шәһәрнең генераль планы расланган. Планны Мәскәүнең кырыктан артык проект институты эшләде. Минем аны үзгәртергә хакым юк. Әлегә башым ике түгел,— дип кырт кисте ул.

— Без бит генераль планны баштанаяк үзгәртү турында сүз алып бармыйбыз, шәһәрнең үзенә дә түгел, ә бер читтәге уч төбе кадәр ял итү зонасы өлешенә төзәтмә кертүне генә сорыйбыз. Ял зонасының урыны да күчми, элекке җирдә кала.

Баш архитектор Урмановның аяк терәп каршы торуын күргәч, Ихтыярның кәефе кырылды. Ләкин Нурислам, мондагы эш стиленең нindirәк икәнен белгән карт бүре буларак, һич тә чигенергә, бирелергә теләмәде. Ул,

өстәлдәге күрсәткеч таякны алып, тулы бер стенаны тутырып торган генераль план янына килде дә ашыкмыйча гына Ихтыярның сүзләренә аңлатма бирергә тотынды:

— Мәскәү проектчыларына рәхмәт: ял итү зонасының урыны бик уңышлы сайланган. Монда — елга, монда — инеш, монда — урман. Безнең дусның бабалары кайда төпләнергә белгәннәр,— дип, Ихтыярга таба карап елмайды ул.— Ләкин анда ял итәчәк кешеләрнең рухи ихтыяҗлары, гореф-гадәтләре, яшәеш формалары исәпкә алынганмы? Минемчә, бу өлкәдә әле уйлап бетерелмәгән нәрсәләр бик күп калган.

Баш архитектор каядыр ашыга иде бугай, сәгатенә карап алды да, сүзне шушының белән тәмамлаганга санап, урыныннан кузгалды.

— Генераль планны төзегән чакта әйтергә кирәк иде боларны. Сугыш беткәч, батырлар күбәя. Боларны миңа сөйләүдән ни файда? Генераль планны мин төземәдем, мин расламадым,— дип, өстәлдәге кәгазьләрне җыя-җыя, үзалдына илтифатсыз гына сөйләнде ул.

— Ә сез, Роберт Маратович, нәрсә генә эшләдегез соң? — Ихтыяр аңа ашардай булып карап куйды.

— Иптәш яшь белгеч, сорарга рөхсәт итегез, төзелешкә килгәнегезгә ничә көн булды сезнең? — дип, мыскыллы тонга күчте баш архитектор.— Нишләптер моңа кадәр күрмәдем кебек. Күргән булсам, һичшиксез, сезнең белән киңәшмичә калмас идем. Вак-төяк нәрсәләр белән киләчәктә миңа түгел, секретарь кызга мөрәҗәгать итә аласыз. Без бакыр булсак та, вакыт алтын. Ярый, хәзергә...

— Тыңлап бетерегез, зинһар! — дип үҗәтләнеп, инде саубуллашып өлгергән баш архитекторның каршына чыгып басты Нурислам.— Шәһәр төзелешендә эшләүче кешеләрнең социаль чыгыш картасын, аларның географиясен беләсезме сез? Кем каян килгән, кайсы катлаудан, нинди гаиләдән чыккан?

Роберт Маратовичның йөзенә канәгатьсезлек төсмере кунды, инде нокта куелды дип саналган сүзнең һаман дәвам ителүен күргәч, аның кәефе китә башлады.

— Моның белән ни әйтергә телисез? Мине дә, үз эшемне ташлап, социология белән шөгыльләнергә кодалыйсызмы?

— Начар булмас иде. Һәр җитәкче күпмедер дәрәҗә-

дә психолог, күпмедер дәрәҗәдә социолог та булырга тиеш дип уйлыйм мин.

— Тагынниләр уйлыйсыз? — Баш архитектор Урмановның алар белән җитди итеп сөйләшергә исәбе юклыгы күренеп тора иде.— Ә безне, һәр кеше үз эше белән шөгыльләнергә тиеш, дип өйрәттеләр.

Нурисламның да түземе төкәнеп килә иде. Ул уч төбе белән өстәлгә шапылдатты да лыпылдап архитектор каршындагы урындыкка утырды.

— Без уен уйнап йөрмибез. Сезнең янга үзебезнең шәхси йомышыбыз белән кермәдек.— Ул ишектән инде икенче мәртәбә башын тыгып караган секретарь кызга ымлады.— Әгәр секретарь кыз бик ашыктыра икән, барыгыз. Без монда көтеп торырбыз.

Роберт Маратович бераз күндәмләнә төшкәндәй булды, теләр-теләмәс кенә өстәл артына кереп утырды.

— Шәһәр төзелешендә ял итү зонасыннан да мөһимрәк нәрсә юк дип саныйсыз икән, әйдәгез, исбат итегез, тыңлыйм.

— Шәһәр төзелешендә мөһим булмаган нәрсә юк,— диде Ихтыяр.— Сез моны безгә караганда яхшырак беләсез. Песи белән тычкан уены уйнамагыз, миңа шулай кулайрак, минем үз өстемә мәшәкать алырга исәбем юк, дип турыдан ярып әйтегез.

— Моның белән нәрсә әйтергә телисез?

— Өстән кушканны гына көтеп утырмаска, үз фантазиягезне дә эшкә җигәргә кирәк, дим. Югыйсә без төзегән шәһәрнең җаны булмаячак, кешенең күңеле ятмаячак аңа.

— Яңа институт бетереп чыккан ярым студент, ярым инженердан да акыллырак кеше бармы икән дөньяда?!

— Юкны бушка аударып утырмыйк,— дип, Ихтыяргa баш какты Нурислам.— Үзегез ашыгасыз, үзегез һаман сузасыз.

Баш архитектор ике кулын күкрәгенә кушырып куйды да, мин сезне тыңларга әзер, сөйләгез дигәндәй, тәкәббер кыяфәт белән аларга елмайды.

— Безнең төзелештәге сигез меңгә якын кешенең алтмыш җиде проценты авылда туып үскән. Киләсе бишьеллыкта төзүчеләрнең саны җитмеш меңнән дә артып китәчәк. Социология бүлегенең прогнозларына караганда, киләсе бишьеллыкта да, алдагы унбиш-егерме елда да авылдан чыгучылар алтмыш-алтмыш биш процент тәшкил итәчәк.

— Бик әйбәт. Авыл халкы эштән курыкмый, кая кушсаң, шунда бара. Теләсә нинди шартларга тиз җайлаша.

Нурислам баш архитекторның бүлдерүенә игътибар итмәде:

— Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый. Шуның шикелле, якын киләчәктә шимбә-якшәмбе көннәрендә безнең булачак вокзаллар, булачак аэропортлар, пристаньнар...

Шулчак телефон аппаратының кызыл күзе кабынды. Роберт Маратович исе китмичә генә трубканы колак янына китерде.

— Тыңлыйм. Әйе, әйе. Истә. Булмый. Кайта алмыйм, дим. Кибеткә үзең кер, баланы да ал. Объект тапшырабыз. Көне, төне юк хәзер. Бер мин генә түгел. Ярый, ярый, киңәшмә бара монда. Хуш.

Ачкан авызын да япмыйча аның сөйләшеп бетерүен көткән Нурислам җөмләсен өзелгән урыннан ялгап алып китте:

— ...авыл юлын таптаучылар белән шыгрым тулачак.

— Нәрсә, нәрсә? Нинди авыл юлы? Нәрсә тулы булачак?

Архитектор әле телефон бозган тынычлыгын тәртипкә китерә алмаган, болай да көчкә түзеп тыңлаган әңгәмәнең очын югалткан иде. Нурислам аның бу халәтен сизә, сизгән саен тынычлыгын ныграк җуя, әмма түзә, хисләрен тышка чыгармаска тырыша иде.

— Хөрмәтле архитектор галиҗәнаплары! Без инде менә бер сәгатькә якын сезнең кабинетта утырабыз. Сөйләшү темабыз — авыл белән шәһәр арасындагы бәйләнешләр, ясалма төстә тудырылган кирәксез конфликт һәм шуны булдырмау чаралары... Миңа дәвам итәргә рөхсәтме? Шулай итеп, күпме генә тырышсаң да, авыл кешесеннән берничә елда чын пролетариат ясый алмыйсың. Авыл канына сеңгән инде аның, капка төбендәге бүрәнә өстенә утырып авыл агайлары белән бер махра тарту өчен, тау читендәге чишмәдән ятып су эчү өчен генә дә йөз чакрым юл узарга риза ул. Аның әле шәһәргә күңеле ятмаган, җаны берекмәгән. Димәк, әле ул ярым авыл, ярым шәһәр кешесе. Минем бабай әйтмешли, ни урталай, ни пултарай. Аның шулай ике арада каңгырып йөрүе эшкә тискәре йогынты ясый, коллективта нормаль климат урнашуга кыенлыклар тудыра. Дүшәмбедә иртә таңнан авылдан килгәч, әле ул кичкә кадәр үз эзенә төшә алмыйча йөри, күңеле авылда калган була аның. Ә җомга көн җит-

сә, иртә таңнан ук ничек эштән таярга чамалый башлый. Һәм җаен барыбер таба. Шулай итеп, биш көнлек эш атнасының ике көне бер көнеңә дә тормый булып чыга.

— Моның белән ни әйтергә телисез, иптәш социолог?

— Хәзер, тыңлап бетерегез.— Нурисламның борын өсләре тирләп чыкты. Ул, кесәсеннән кулъяулык алып, битен сөртте дә күрсәткеч таягын генераль планга таба суздьг.— Әгәр дә без, инде әйткәнемчә, менә монда, урман аръягында яңа типтагы поселок салып, Ташлыяр кешеләрен шунда күчерсәк һәм бушап калган авыл өйләрен реставрацияләп, оригиналь ял итү зонасы ясасак, теге алтмыш җиде процентның күңелен тынычландыра алыр идек. Теләгән кеше шимбә-якшәмбедә профкомнан путевка ала да авыл өендә бәлеш-коймак пешереп, күмерле самавырда чәй кайнатып үзенчә рәхәтләнеп ял итә. Ял вакытында бөтен гаиләсе белән бер айга да килә ала.

— Ә ул яңа типтагы поселокны сезгә Аллаһы Тәгалә үзе салып бирәме? Генераль планда каралмаган, проекты төзелмәгән, титулга кертелмәгән...

— Кертелмәсә, кертергә кирәк. Сорарга, таләп итәргә! — дип кызып китте Нурислам.— Ял итү зонасына дигән төзелеш материалларын тулысынча яңа поселок төзелешенә күчерергә! Проект төзеп торасы да юк, менә дигән типовой проектлар эшләнгән. Теләге булган кешегә көч җитмәс каршылык юк монда!

Нурислам, минем сүзем бетте, дигәнне белдереп, күрсәткеч таягын өстәлгә куйды да Ихтыяр янына килеп басты. Баш архитектор иң элек үзе сүз башлап та хәзер бер читтә сөмсере коелып торган Ихтыярга эндәште:

— Ә менә сез, яшь белгеч, моңа ничек карыйсыз? Әллә социологның иярчене булып кына йөрисезме? Карагыз әле, онытып торам, кандидатскиегыз ни хәлдә, Фарукшин? Эшләп бетергәч, иң элек миңа күрсәтәсез. Җитәкчегез сүзе бу, минем теләк түгел.

— Менә шушы инде минем кандидатлык диссертациям! — дип кызып китте Нурислам.— Күреп торасыз, иң беренче эш итеп сезнең янга баш орып килдем бит. Ә бу егеткә тимәгез. Ул минем шикелле сүз кешесе түгел, эш кешесе.

— Рөхсәт булса, бүгеннән үк Ташлыяр ял итү зонасының проектын эшли башларга әзер мин,— дип, Ихтыяр да сүзгә кушылды.— Рөхсәт кенә булсын.

— Әллә сез архитектура бүлеген тәмамладыгызмы?

— Юк. Төзелеш бүлеген.

— Алайса, юк нәрсә белән хыялланып та йөрмәгез. Могҗиза булып, рөхсәт биргән очракта да бу эшне сезгә тапшырмаячаклар. Һәр кеше аз гына булса да архитектордыр, беләм. Ләкин бездә аз гына җитми шул. Ничек уйлыйсыз, социолог, дөрес әйтәмме?

Нурислам аңа җавап бирмәде, иреннәрен генә бүлтәйтеп куйды да күзләрен Ихтыярга төбәде. Ә ул, беркатлы кыяфәт белән, баш архитекторга нидер аңлатырга, аны әле һаман үз ягына аударырга тырыша иде.

— Мин биш ел буе архитектура бүлегендә укучылар белән бер бүлмәдә яшәдем. Алар укыган китапларның берсен дә калдырмыйча укып бардым. Өченче курста архитектура бүлегенә күчәргә дә җыенган идем, буш урын гына булмады.

— Ха-ха-ха...— Баш архитектор, тыела алмыйча, көлеп җибәрде.— Мин опера җырчысы белән бергә балык тотарга йөрим, дип, Онегин партиясен үзенә бирүләрен сорап театрга килгән балыкчы шикеллерәк була инде бу...— Аннары, үзенең барасы җирен искә төшерепме, әллә дәрәҗәсен сакларга тырышыпмы, кулын кинәт өскә күтәрде: — Шаярыштык, көлештек. Сез сөйләдегез, мин тыңладым. Ике як та канәгать, шулаймы? Ярый, сау булыгыз! Энҗе, машина мондамы?

Ачык ишектән секретарь кызның гел елмаюдан гына торган мөлаем йөзе күренде. Ул, каядыр барырга җыенып, иңенә бәләкәй сумкасын аскан иде.

— Күптән монда. Сезне көтәбез.

* * *

Коридорга чыккач, Ихтыяр теш арасыннан сыгып, моңа кадәр булмаган усаллык белән үзалдына әйтеп куйды:

— Рөхсәт булмаса да, эшлим! Дөнья аңа гына терәлеп калмаган, акыллы кешеләр дә табылыр.

Пышылдап кына әйтсә дә, Нурислам аның сүзләрен ишеткән иде.

— Проектыңны әзерләп кулга гына тоттыр син минем. Хәзергә эскизларын гына булса да. Министрына кадәр барырмын, үз сүземне уздырмыйча туктамам!

Мотоциклы янына килеп җиткәч, Нурислам артта калган Ихтыярга кычкырды:

— Кая илтергә сине, начальник?

— Опера театрына.

— Әллә циркка яисә курчак театрына барыйк микән? Барыр җир күп булгач, сайланабыз-сайланабыз да, бер карарга килә алмыйча, өйгә кайтып егылабыз. Шәһәр түгел, галәмәт зур йокы бүлмәсе салабыз бугай без...

Әле урам кыяфәтенә керергә өлгермичә, як-якта чәчелеп яткан йортларга карап тордылар-тордылар да икесе дә көлеп җибәрделәр.

— Утыр әйдә, минем Сәбиләнең пилмән пешерә торган көне бүген,— дип, мотоциклын кабызды Нурислам.— Атна буе өйдән чыкмыйча ятып, эти-әниеңне дә туйдырып бетергәнсеңдер.

Ихтыяр, ризалыгын белдереп, баш селкеде. Алар, булачак урамның тузанын туздырып, булачак шәһәрнең булачак үзәгенә таба элдерттеләр.

Аяк йөзенә кадәр җитүле куе яшел төстәге халат кигән Сәбилә аларны ишек төбендә елмаеп каршы алды. Ул Нурисламның чит кеше белән кайтуына һич тә гаҗәпләнмәде, хәтта сөенгән кыяфәт белән яктырып исәнләште. Ихтыярны күптәнге танышы кебек кыстый-кыстый түргә чакырды. Мондый мөлаемлыкка күнекмәгән, тулай торактагы вахтерның нур качкан йөзенә карамас өчен, биш ел буе үз бүлмәсенә кеше чакырырга кыймыйча йөргән Ихтыяр өчен бу сәер дә, рәхәт тә иде. Ул, әллә шылтыратып хәбәр иттеме, кисәттеме икән, дип, күзләре белән телефон эзләде. Тапмагач, тагын да ныграк сәерсенеп түргә узды.

Түр бүлмәдәге сүс баудан үреп ясалган пәрдә артыннан саркып кына талгын музыка агыла. Ул диванга килеп утырды һәм шунда гына күңеле талкынудан, беренче мәртәбә уңышсызлыкка очраудан, очсыз-кырыйсыз лабиринтка охшаган төзелеш проблемалары эчендә буталып калуыннан гаҗиз булуын тойды. Тәрәзәдәге ачык яшел пәрдәләр, бөтенләе белән бер стенаны тутырып торган китаплар, талгын музыка аның күңелендәге уйларны әкрен-әкрен тарата, тынычландыра, аның шулай ләззәт кичеп утырасы, шушы рәхәт мизгелне куркытмыйча, тып-тын гына оеп рәхәтләнәсе килә иде.

Кулына тәлинкә тоткан килеш каршысында басып торган Сәбилә аңа үз хыялыннан йөзеп чыккан әкият кызы кебек тоелды. Ихтыяр аптыраулы карашы белән аның күзләренә күтәрелеп карады һәм тәне буйлап калтырау йөгереп узганын сизде. Моны күреп торган Ну-

рислам, Ихтыярны бу сәер халәтеннән чыгару өчен, сүз башларга ашыкты:

— Мин сезне таныштырырга да оныткпнмын бит әле. Безнең кунагыбыз — шәһәр төзелеш идарәсе инженеры Ихтыяр Батыршин булыр. Бүгенге көндә без аның белән бер төркем консерваторларга каршы аяусыз көрәшәбез. Һәм якын киләчәктә, һичшиксез, җиңәчәкбез. Мине бу бөек җиңүләргә рухландырып торучы алиһәм — район газетасы хезмәткәре һәм дә шуннан бушаган арада минем хәләл җефетем ролен башкаручы Сәбилә ханым Фарукшина.

Көлешеп алганнан соң, берсен берсе кысташа-кысташа, калак-чәнечкегә тотындылар.

Ихтыяр ашаган арада әле Нурисламга, әле Сәбиләгә күз төшереп ала да, әллә кайда еракта калып, әле генә хәтердә сурәте җанлана башлаган Зәлияне күз алдына китерергә тырыша. Ләкин күзләрен йомгач та, Зәлия урынына каршыда Сәбилә басып тора иде. Ул, аптырагач, башын як-якка селкеп куйды.

«Нәрсә булды миңа? Әллә галлюцинация башлана инде?» — дип уйлады Ихтыяр. Карале, бер атна буена төзелештәге әһәмиятле проблемаларны чишә алмыйча баш ватып йөри торгач, ул Зәлия турында бөтенләй диярлек уйлап та карамаган икән бит.

— Ай-һай! Табынга нәрсә җитми дим... Иң кирәген оныта язганбыз бит!

Нурислам сөйләнә-сөйләнә кухняга чыгып китте. Ихтыяр башын күтәрүгә, күз карашы тагын Сәбиләнең күзләре белән очрашты. «Зәлияне сагынам бугай мин, үзем дә сизмичә сагынам,— дип уйлады ул.— Хәзер менә Сәбиләдән аның чалымнарын эзлим. Бу дөньяда хатын-кыздан да серле, катлаулы һәм шул ук вакытта гүзәл җан иясе юк. Хатын-кыз булмаса, без инде әллә кайчан яңадан маймыл кыяфәтенә кайткан булыр идек. Маймылны хезмәт маймыллыктан чыгармагандыр, хатын-кыз, мәхәббәт кеше иткәндер...»

Нурислам, шешәсен ачып, рюмкаларга коньяк салды да бәллүр зыңы чыгарып чәкештерде.

— Дуслык өчен! Дөнья ваклыкларыннан өстен торырдай дуслык өчен!

Беренче рюмкадан ук Ихтыярның бөтен гәүдәсе җиңеләеп киткәндәй булды, бар борчулары каядыр юкка чыкты, аның бертуктаусыз сөйләшәсе, шаярасы, көләсе килә башлады.

Ихтыяр табын яныннан авырлык белән генә торып басты. Берничә сәгать эчендә ул бу йортка шулкадәр ияләшкән иде. Ничә еллар буе институт тулай торагында дүрт стенадан башка берни күрмәгән, сирәк-мирәк Зәлияләргә барганда да кайда утырырга белмичә аптыраган Ихтыяр өчен бу өй бары фәрештәләр генә яши торган оҗмах булып күренде. Монда Зыятдин бабай атавындагы уздырып булмый торган күңелсез көннәр дә, әтисе белән әнисенең мәңге бетмәс борчулары да, Зәлиләр өендәге суларга авыр тантаналы һава да, төзелеш идарәсе кабинетларындагы нәтиҗәсез ыгы-зыгы да юк иде.

Ихтыярның китәргә җыенып та, нәрсәсендер югалткан кебек арлы-бирле йөрүен күреп, Нурислам аны фатиры белән таныштырырга булды.

— Кешеләр, гадәттә, килгән кунакка үзләренең фатирларын күрсәтеп чыгалар бугай. Менә монысы — йокы бүлмәсе, без утырганы — зал, ә тегесе — бәләкәчләрнеке.

— Сезнең бәләкәчләр дә бармыни? Кайда соң алар?

— Йоклыйлар. Олысы беренче класста укый. Мәктәпне беренче чиратта салдык. Кирәк китереп терәсә, җиткерәсең ул. Безгә дә Ташлыярның кирәк икәнен аңлата, исбатлый белергә кирәк.— Нурислам балалар бүлмәсе ишеген ачып пышылдады.— Әнә алар. Түр караваттагысы — кечесе, Рәйханә исемле. Балалар бакчасына йөри, монысы — Ринат.

— Бай яшисез,— дип, ишекне ябарга кушып ымлады Ихтыяр.— Каян шулай барысына да өлгерәсез? Ничә яшь соң сиңа?

— Күрмисеңмени? Минем чәч тә өлгер бит, кешенекеннән алданрак агара. Егерме тугыз тулды, туган. Картаябыз. Киләсе елга — юбилей. Орден бирмәгәйләре,— дип, сүзне шаян тонга борды ул.

Саубуллашканда, Ихтыяр Сәбиләнең кулын катырак кысты. Тавыш-тынсыз изрәп йоклап яткан малай белән кызны күргәч, ул аларның әниләре Сәбилә булуына ышанып та җитмәгән иде. Менә хәзер генә Ихтыяр бу күзләрдәге мөлаемлык, җылылыкның бары тик аналарда гына була торган аерым бер сыйфат икәнен аңлады, хатын-кызның бәби тапкач кына ачылып китүе турында күп ишеткән булса да, бары тик бүген генә моңа үз күзе белән күреп ышанды. Әгәр дә янәшәдә Нурислам басып

тормаса, ул, үз-үзен тыя алмыйча, бу кечкенә һәм йомшак кулны уч төбенә салып, Сәбиләнең язмышын юрый башлар иде сыман.

Ихтыяр, башына берөзлексез килеп торган тилемсә уйлардан котылырга теләп, тиз-тиз генә саубуллашты да урамга чыкты.

— Хуш, авылым! — дип кычкырды ул балконнан кул изәп торучы Нурислам белән Сәбиләгә.

Ләкин җете зәңгәр күктәге чекерәйгән йолдызлар да, бөтен йөзен тутырып балкыган түгәрәк ай да аның күңелен тынычландыра алмады. Ул, бүген нәрсәдер тапканынмы әллә югалтканынмы аңлый алмыйча, шатланырга да, кайгырырга да белмичә, исәр кеше кебек барды да барды.

* * *

Әтисе Ихтыярны төксе кыяфәт белән каршы алды. Әнисе дә, әтисеннән узып сүз әйтергә кыймыйча, бүлмә якта тавышсыз-тынсыз йөри. Кич буе хыял дөньясында очып йөргән Ихтыяр шап итеп җиргә егылып төшкән кебек булды. Чәйне дә, әтисенең төксе кыяфәте белән кушып, сүзсез генә эчтеләр. Ләкин, вакыт-вакыт онытылып китеп, ул тагын татлы уйларга чума да, авызы үзеннән-үзе ерыла. Күз алдындагы аксыл томан эченнән, үпкәләгән сыман авызын турсайтып, әле Зәлия йөзеп үтә, әле янында гына Сәбиләнең җанны эретердәй ягымлы тавышы ишетелгәндәй тоела, әле Нурислам, кемгәдер нәрсәдер исбат итәргә тырышып, янып-ялкынланып сөйли иде.

— Нәрсә авызыңны ерып утырасың? Бу карт алашаны төп башына утырттык, дип сөенәсеңме?

Күз алдындагы томан кисәк кенә таралып, каршыда күгәреп утырган әтисе, самавырдан чәй агызып торучы әнисе күренде.

— Шәһәре белән, районы белән миңа ябырылулары аз иде, инде хәзер бу яшь чыпчык та әтисенең башына кәкәй итәргә булган, ә!

— Ни турында сөйлисең син, әткәй? Гадирәк итеп сөйләсәң, бәлки, мин дә аңлармын.

— Башыңны юләргә салып утырган булма. Мин карт юләрне котыртып җыелыш җыйдыручы кем? Теге шома авыз Нурислам белән син! Авыл халкын, төзүчеләрне фа-

тирга кертүләрен сорап, кодалап йөрүче кем? Алтмышка җитеп акыл кермәгән шушы исәр. Башта ук күңелем тартмаган иде. Авыл өчен кайгыртып йөримени алар? Үзләренең эш күрсәтәселәре килүдән койрык чәнчеп чабалар.

Ихтыяр шунда гына сүзнең нәрсә турында баруын аңлады. Ул инде бу хакта баш архитектордан чыккач та уйлаган иде, ләкин Нурисламнарга баргач, бөтенесе дә онытылды, дөнья аңа яшел пәрдәле бүлмә кебек тыныч һәм рәхәт, Сәбилә күзләре кебек нурлы һәм ягымлы булып күренде. Әтисенең сүзләреннән соң болар барысы да кинәт кенә чәлпәрәмә килеп, тирә-юнь язгы ташу сыман бөтерелә, актарыла, салкыная, шомлы һәм аңлаешсыз уйларга төренә башлады. Ул әтисенә ничек итеп мәсьәләнең асылын аңлату, аны ничек юату, тынычландыру чарасын таба алмый, шуңа үзенең көчсезлегеннән күңеле кыйнала иде.

Тимерхан һаман саен кыза гына барды.

— Авыл халкына нинди күз белән күреним мин хәзер? — дип ярсыды ул.— Шушы бала-чага сүзенә ышанып, халык алдында ыштыр биткә, ата ялганчыга әйләнеп калдым. Боларга нәрсә, боларның сырт койрыкта, бүген монда алар, иртәгә — тегендә. Җил катырак иссә, йомычка урынына очып китәргә генә торалар.

— Зинһар өчен, аңлатыбрак сөйлә, әткәй! — Ихтыяр аның бөтенләй ташып чыкмыйча ярсуы басылмавын белә, шуңа ялкынына ут өсти иде.

— Райком келәмендә сәгать буе басып торганың бармы синең, саламторхан?

— Райкомга чакырдылармыни?

— Күптән мунча кергән юк иде, сезнең фатиха белән рәхәтләнеп чабынып кайттым! Авыл халкы арасында ялган коткы таратып йөргән өчен икенче секретарь иманны укытты. Партизанщина белән шөгыльләнүдә гаепләде. Бөтен авыл яңа поселокка күчәбез, дип сөйли икән хәзер. Шул райкомга барып ирешкән...

— Беренче секретарь Солтанов кичә Нурислам белән мине чакырып сөйләште. Нининдидер аңлашылмаучылык килеп чыккан монда. Ул, киресенчә, төзүчеләрне Ташлыярда урнаштыруыбыз өчен рәхмәт әйтте. Бу тәҗрибәне тагын да үстерергә, күрше авылларга да чыгарга кушты. Иң элек председательләр белән элемтәгә керергә, парторглар белән киңәшергә кирәк, диде. Сүз уңаен-

да сине дә мактап телгә алды. Бөтен нәрсәне күреп-белеп тора икән.

— «Әткәйне бик җиңел төп башына утырттык та, андый җүләрләр бүтән очрар микән?» — дип әйтмәдеңме соң райком секретарена?

— Юкны сөйләмә әле! — Ихтыяр, чын-чынлап ачуы чыга башлаганын тоеп, үз-үзен тынычландырырга тырышты.— Син генә уйлыйсыңмы әллә Ташлыяр турында? Мин дә шунда туып-үскән кеше, сиңа кадерле булган кебек миңа да якын ла ул. Әгәр шәһәрнең баш архитекторы теше-тырнагы белән каршы килә икән, мин үземнең фикеремне аның миенә боргычлый алмыйм. Көтегез бераз, вакыт бирегез миңа. Архитектор егетләр белән сөйләштем. Булышырга вәгъдә иттеләр. Минем белән бергә укыган егетләр алар. Бергәләп тотынсак, көзгә Ташлыяр ял итү зонасының яңа проектын эшләп өлгертәчәкбез. Әле хәзергә безнең планны хуплаучылар юк диярлек. Әмма райком секретаре Рим Идиятович ап-ачык итеп әйтте, әгәр дә көзгә кадәр проектыгызны эшләп бетереп, Мәскәү архитекторларыннан раслата алсагыз, шәп булыр иде, диде. Яңа поселок турында Министрлар Советы белән киңәшмәкче була.

— Бик тә ачык итеп әйткән икән,— дип көлде Тимерхан.— Нәрсә, Мәскәү әйтмичә, аркылыны буйга да алып сала алмыйсызмыни инде сез хәзер? Беренче секретарь башыгыздан сыйпап-сылап чыгарган да шуңа куанып йөрисезме? Ә миңа бөтенләй икенче сүз әйтте. Мәскәү ә-әнә кайда ул! Бар син анда, беткән иде Мәскәү юлын таптаучылар.

— Эш анда түгел, әткәй. Генераль планны Мәскәү архитекторлары эшләде, димәк, шәһәрнең киләчәге өчен дә, аның матур һәм яшәргә уңайлы булуы өчен дә алар җавап бирә.

— Мәскәүдән торып, Гыйлаҗетдин картка нәрсә уңай да нәрсә кулай икәнне каян белә алар? Үзебезнең республика нәрсәгә авыз ачып карап тора? Казанда да проект институты бар. Андагы архитекторлар дуңгыз фермасы төзүдән башкага ярамыймыни? Нигә асрыйлар аларны?

— Дөньяга даны таралачак кала салабыз бит, әткәй, республиканың гына көче җитәрлек түгел аңа. Шуңа күрә бөтен ил белән тотындылар да. Дөрес әйтәсең, Мәскәү архитекторларының да ялгыш җибәрүе, бөтенесен дә искә алып бетерә алмавы бик мөмкин. Ләкин аларның мөмкин-

лекләре зуррак, алар илебездәге шәһәрләр төзү тәҗрибәсенә таянып эш итә, барысын да өр-яңадан уйлап чыгармый.

— Типовой проектлар белән эшләнгән йортларны үзләренчә тезеп чыгалар да, шуның белән — вәссәлам! Шәһәр төзелә торган җирнең үзенчәлеген, анда яшәгән халыкның гореф-гадәтләрен, еллар, гасырлар буена күз күнеккән, җан береккән архитектурасын исәпкә аламыни алар?!

— Ә без ни өчен?

Ихтыяр, үзен күрсәтергә теләгәндәй, калкына төшеп, чынаягын әнисенә сузды.

Маһруй, ирләр сүзенә кушылырга җөрьәт итмәсә дә, атасы белән малаеның артык кызып китеп, чамадан ашмауларына күз-колак булып тора, әле берсенә, әле икенчесенә карап, күз карашы белән тынычландырып ала иде.

— Кикрикне каты кабарттың син, малай!

Ихтыяр җавап биреп тормады, йөзен генә җыерды.

Маһруй, улының шулай кыдрачлануын күреп, авыз тутырып елмайды. Еллар үткән саен олыгая, үзеннән ераклаша барган улы бу мизгелдә кире балачагына — бары тик аларныкы гына булган чакка кайтып, кул сузымы җитәрлек арага якынайган иде.

— Көзгә Нурислам Мәскәүгә укырга бара,— дип дәвам итте Ихтыяр.— Мин килгәнче, ул анда юлларын өйрәнә, таныша тора. Проект әзер булгач, иске танышлар янына баргандай барып керәбез. Нурисламны белмисең әле син. Аның белән бергәләп тотынсак, Мәскәү архитекторларына гына түгел, Чәберчек Әхмәткә дә иман кертергә була. Нурислам минем ише генә түгел, тоткан җиреннән өзә торган егет ул! Аннары Мәскәүдә дә берни аңларга теләмәгән дошман кешеләр утырмыйдыр.

Тимерхан, түр якка узып, телевизорны кабызды. Ихтыяр әнисе янындагы урындыкка күчеп утырды. Өстәл артындагы мәче, аның аягына елышып, сырпалана башлады. Әнисе түр якка күз төшереп алды да, Ихтыярга таба иелә төшеп, пышылдады:

— Әтиеңә каты кагылма син. Холкы ул кадәр үк зыянлы түгел аның. Пырлый-пырлый да тынычлана. Эше шундый бит, мең кеше көен көйләп, үзе көйсезләнеп бетте инде.

Түр якта Илһам Шакировның күңел төбеннән, бик тирәннән күтәрелгән моңлы тавышы ишетелде.

Җыр тәмамлануга, Ихтыяр әнисеннән капыл гына сорап куйды:

— Син бәхетлеме, әнкәй?

— Иске авыздан яңа сүз, дип әйтимме. Нигә кирәк булды тагын монысы?

— Күптәннән сорыйсым килеп йөри иде.

— Ничек дим соң? Төрле чагы була торгандыр инде, улым. Менә хәзер син янымда утырганда — бәхетле. Ялгыз калган чакларда берәм-берәм барыгызны искә төшереп чыгам да, күзгә яшь килә. Җиде бала үстереп, олыгайган көнеңдә буш ояда икәвең генә утырып калгач, күңел нечкәрмәс җиреннән нечкәрә икән ул. Бер баласыз кешеләрдән көнләшеп куйган чакларым да була. Тфү, тфү!.. Алар гомере буе ялгыз яшәп күнеккән инде, аларның көтәр кешеләре юк, күңелләре тыныч. Көтүдән дә авыр газап юк бит, улым. Җитмәсә, әнә, бабагыз...— Әнисе дымланган күзләре белән тәрәзә артында каралып күренгән атауга үрелеп карап куйды.

— Элек бу тәрәзә юк иде безнең,— дип, сүзне икенчегә борырга тырышты Ихтыяр.

— Мин тиштердем аны. Кат-кат ялына торгач, этиеңне ризалаттым. Югыйсә башта: «Кеше көлдереп көннәр буе тәрәзәдән атау сагалап утырмакчы буласыңмы?» — дип авыз да ачтырмый иде. Бабаң белән һаман борчаклары пешми аларның. Икесе ике колхоз булып яшиләр. Тегесенең үз киресе кире, бер урында терәлгән дә каткан. Ә монысы үз дәрәҗәсен саклый, абруен төшерүдән курка, элекке ачуын онытып бетерә алмый.

— Ташлыярны күчергәч, бабайга барыбер китәргә туры киләчәк бит. Кая барыр икән ул? Аның үзенә генә берәү дә аерым йорт салып бирмәячәк. Шәһәр колхоз түгел, аның ай-ваена карап тормаячаклар...

— Белмим шул, улым, белмим. Тик күңелем сизә, этиең белән бер түбә астында сыеша алмаячаклар алар. Бу хәлдә сыеша алмаячаклар. Теге кайтуыңда атна буе шунда юангач, әллә инде сиңа ияреп чыгармы дигән идем. Бу кадәр дә үчләшсә үчләшер икән кеше! Картайгач йомшармы, күңеле сынармы дигән идем, юк, терәлгән дә каткан...

Маһруй чәчен каплап бәйләгән яулыгының очы белән күз читләрен сөртеп алды. Ихтыяр әнисенең моңсу күзләренә, түгәрәк йөзенә озаклап карап торды. «Әнкәй үзе өчен яшәми, ул үзен бөтенләй оныткан. Аның уенда бары тик без — балалары, бабай, әткәй»,— дип уйлады Ихтыяр.

Түр яктан агылып чыккан җыр моңы Ихтыярның да күңелен изрәткән иде, ул, күзләрен әнисенә күрсәтмәс

өчен, борылып, караңгы тәрәзә аша атаудагы бердәнбер сукыр утка карады.

— Газиз җиреннән берәүнең дә аерыласы килми шул,— диде әнисе.— Шушы Ташлыярдан китмәс өчен бабаң бөтен нәрсәсеннән ваз кичте.

— Нигә, аны каядыр җибәрмәкче дә булганнар идемени?

Бабасы авызыннан сүз уңаеннан гына ишеткәләгәне булса да, Ихтыярның бу турыда күбрәк беләсе килә иде. Зыятдин карт ул елларны артык искә алырга яратмый, искә ала башласа да, ярсып, чыгырыннан чыгарга гына тора.

— Ул «кулак» дигән сүзне кем уйлап тапты икән? — дип, шул кешене эзләгәндәй, озак итеп тәрәзә артындагы караңгы урамга карап торды Маһруй.— Авыл күрке иде бит ул бабаң! Кулыннан килмәгән эш юк иде. Талап-урлап, алдап-йолдап туплаган малы юк иде. Барысы да хәләл көче белән, маңгай тире белән туплаган мал.

— Алтын-көмеше күп идеме әллә?

Маһруй Ихтыярга аптырап карап алды.

— Нинди алтын булсын ди бездә? Бер ат, бер сыер, ун баш сарык та тавык-каз белән дистәләп күркә.

— Бүген Чәберчек Әхмәт тә безнең бабайдан баерак бит, алайса.

— Эшләгән кешегә кот куна ул. Шулай да булмаса, нигә бил бөгеп эшләп йөрергә? Элеккеге уй белән уйласаң, безнең авылның яртысын кулак ясарга була хәзер. Авылның иң булган кешеләрен, кулыннан эш килгән адәмнәрен Себергә сөреп бетерделәр бит.

Утызынчы еллардагы хәлләр турында Ихтыяр китаплардан укып белә, шуңа күрә үзен колхозлашу чорындагы вакыйгалардан шактый хәбәрдар саный һәм бу вакыйгаларны инде күптән онытылган, бүгенге көнгә катнашы да булмаган нәрсәгә исәпли иде. Әнисе сөйләгән саен, аның күз алдыннан әле «сәнәклеләр» йөгерешеп узды, әле арбага төялешеп, Себер китүче «кулак балалары»ның елашкан авазлары ишетелгәндәй булды. «Туган җирдән сөрү дигән җәзаны кем уйлап тапты икән? — дип уйлады ул.— Баланы анадан, кешене авылыннан, шәһәреннән, халыкларны туган җиреннән аерырга беркемнең дә хакы юк! Бу варварлардан калган йола!» Күпме генә баш ватса да, Ихтыяр әле һаман Зыятдин картның гаебе нидә икәнне төшенә алмый иде. Авыл кешеләренә дә, илгә дә аннан тырнак очы кадәр дә зыян тимәгән, киресенчә, бөтен тирә-юнь шу-

шы тегермән-яргычтан игелек күргән. Авыл белән җыелышып мәчет-мәдрәсә салырга ният иткәч тә иң беренче булып һәр җирдә ул башлап йөргән: бүрәнәсен ташышкан, атна саен өмәгә чыккан, манарасын күтәрергә осталар эзләп тапкан. Колхозлашу башлангач, башта сыерын алганнар, аннары атын үзе илтеп биргән, заем түләр өчен сарыкларын саткан. Тора-бара чират тегермән-яргычка да җиткән. Бар булган малын колхозга алганнар, тешен кысып булса да түзгән. Ә инде көннәрдән бер көнне Чатан Фәйзерахман белән Мичбаш Гаптери сәвит исеменнән йортын даулап килгәч, түземе беткән... Мылтык алып атау читенә чыгып баскан да: «Якын киләсе булмагыз! Әгәр берәрегез атау инешен атлап керсә, атам!» — дип кычкырган. Икенче көнне инештә су күтәрелеп, атау авылдан бүленеп калмаса, эшләр ничек беткән булыр иде, билгесез... Ике-өч атна вакыт үтеп, инеш үз эзенә төшкәндә, «күмхуҗлар»ның да, Зыятдин картның да күңеле урынына утырган була. Аны берничә тапкыр авыл советына чакырып сөйләшәләр дә, тегермәндә эшләргә бүтән кеше булмагач, тегермәнче табылганчы дип, авылда калдыралар. Ә тегермәнче, бәхеткә каршы, табылмый, табылса да, ул Зыятдин карт барда бу эшкә алынырга җөрьәт итмәс иде.

Әнисе берничә сүз әйтә дә көрсенә, әле түр бүлмә ишегенә, әле тәрәзә артындагы атау ягына карап куя. Улының бүген үзен бик тә бирелеп тыңлавы аның күңелен тәмам йомшаткан иде.

— Менә мин дә, буш вакытым чыкты исә, тәрәзә каршына киләм дә сәгатьләр буе шулай карап торам.— Әнисе тагын авыр итеп көрсенде.— Кич җитсә, уты кабынганны көтәм, кышын — морҗа башыннан төтен күренгәнне. Нәселдә булмаган хәл бит. Ата улдан, бала атадан читләшсен инде... Аңламассың бу адәм баласын...

— Утынны кем китерә соң аңа?

— Үткән җәйне Риян абыеңнар кайтып әзерләгәннәр иде. Аякка басып, кул астына керә башлагач, бабаң белән бер атауда сыеша алмыйча, Себергә киткәннәр иде бит алар. Бабаңны көчләп тә җибәрә алмаган Себергә үзләре теләп киттеләр. Аңламассың адәм баласын... Әллә бу якларга күңелләре тартмый инде, онытканда бер күренеп кенә китәләр. Алар кайтмаган елларда атау читендәге корыган талларны кисеп яга. Яз көне ташу суы урманнан агып төшкән агачларны ярга чыгарып ташлый. Җан биргәнгә җүн бирә, диләр бит. Ашарына үзем

пешереп кертәм. Элегрәк анысыннан да баш тарта иде әле. Керләрен юам.

Телевизордан концерт тәмамланды, ахрысы, түр якта ут сүнде. Тимерханның йокылы тавышы ишетелде:

— Иртәгә өчтә уят, әнисе. Печәнгә төшәбез.

* * *

Инде ничә сәгать борсаланып ятса да, Ихтыярның күзенә йокы кермәде. Әтисе белән булган бәхәс исенә төшеп күңелен тынгысызлый, әнисенең яшьле күзләрен уйлап борчыла, бабасы өчен җаны әрни, томан аша әле Зәлиягә, әле Сәбиләгә охшап күренгән шәүлә туктаусыз җанын кытыклап тора иде. Аларны берәм-берәм хыялында барлап, күңеленә килгән иксез-чиксез сорауларына җавап таба алмыйча газапланып ята торгач, кинәт кенә баш миеннән бер якты уй йөгереп узды. «Мин артык чәчеләм, кешеләр белән күбрәк аралашкан саен, фикерләрем таркаулана гына бара, берьюлы бик күп нәрсәгә тотынып, берсенең дә очына чыга алмыйм бугай,— диде ул күңеленнән.— Баштанаяк эшкә кереп чумарга кирәк. Эш белән генә үзеңнең кем икәнеңне исбат итеп була бу дөньяда. Эшләгәнне күрәләр. Беренче секретарь Рим Идиятович үзе чакырып сөйләште хәтта. Яңа килгән кешеләрне урнаштыруда Нурисламның өлеше зур, килгән көнне үк аның белән очрашмасам, шактый каңгырып йөрергә туры килгән булыр иде. Көне-төне эш турында гына уйларга, эш белән генә яшәргә кирәк. «Күп кытаклаган тавык йомырканы сирәк сала»,— дип дөрес әйтә әткәй. Әнә, шул ук Нурисламны гына кара. Кайчан барма, объектка эшчеләр янына киткән булыр, нинди генә җыелыш-киңәшмә булмасын, чәчрәп чыгып ул сөйләр, кайсы газетны ачып карама — аның мәкаләсе. Җитмәсә, көзгә кандидатлык диссертациясе якларга җыена. Кайчан өлгерә диген. Шулар өстенә — гаиләсе, ике баласы...»

Уйлары Нурисламга килеп терәлгәч, теге көнне рәхәтлектә оеп утырган диванны, җанны иркәләп агылган талгын музыканы, Сәбиләнең елмаюлы йөзен искә төшерә-төшерә йокыга талганын сизми дә калды. Йоклаганда да әле шактый вакыт аның иреннәреннән елмаю китмәде.

...Язгы кардан яңа ачылган басу буйлап тез тиңентен балчык яра-яра бара торгач, ул җеп өзәрлек тә хәле кал-

мас дәрәҗәдә арыды. Утырып ял итәр иде, тирә-юньдә уч төбе кадәр дә коры җир юк, җитмәсә, бер урында аз гына туктап хәрәкәтсез торсаң да, сазламык балчык күзгә күренеп үзенә суыра бара. Тирә-як — дөм караңгы, бары тик алда — бик еракта гына, ялгыз йолдыз кебек, үзенә чакырып ниндидер ут җемелди. Ихтыяр, соңгы көчен җыеп, шунда таба атлады. Якынайган саен утлар ишәйгәннән-ишәя барып, төзелеш мәйданы шәйләнә башлады. Менә ул, ниһаять, аякларын сөйрәп кирпеч өеме янына килеп җитте дә хәлсезләнеп бетон плитә өстенә ауды. Шулчак кемдер аны тупас итеп билбавыннан ыргакка эләктерде. «Вира!» дип кычкырган тавыш ишетелде һәм ул кранның ләкләк борыны артыннан өскә күтәрелә башлады. Ихтыяр хәлсезләнеп таш капчыкка әйләнгән гәүдәсенең кинәт кенә җиңеләйгәнен тойды һәм, аяк астындагы җирнең ерагая барганын күреп, як-ягына каранды. Аста бабасы, әтисе белән әнисе, Нурислам белән Сәбилә, Зәлия төрле җиргә сибелешеп басканнар да хор белән: «Вира!» — дип кычкыралар, көлә-көлә аңа кул болгыйлар иде. «Мине нишләтмәк була икән болар?» — дип уйлады ул һәм өстәге кранчы кызга йодрык янады, аска төшерергә кушып, бармагы белән әле үз гәүдәсенә, әле җиргә төртеп күрсәтте. Ләкин кранчы кызның йөзендә үзгәреш күренмәде, ул бары тик җирдәгеләрнең әмерен генә тыңлый, аны күрми дә, ишетми дә иде кебек.

Менә кран угы әллә ничә катлы биек йортның түбәсенә менеп җитте дә туктап калды, һәм Ихтыяр аякларының каты җиргә терәлгәнен сизеп сөенде. Өй түбәсе сумала белән сыланган тип-тигез туры почмактан гыйбарәт булып, аның кыл уртасында дүрт аякка утыртылып куелган сызым тактасы гына тора иде. Ихтыяр аңа аптыраган кыяфәт белән текәлеп карап торды да, кнопкалар белән беркетелгән ап-ак кәгазь өстендә аяк бөкләп утырган баш архитекторны күреп, курка-курка артка чигенде. Архитектор, ул читкәрәк киткән саен, кечерәя барды, берзаман бармак хәтле генә булып калды.

Ихтыяр кулына карандаш алды, аннары, башына ниндидер уй килеп, түбә читенә йөгереп барды, үрелеп аска карады. Яңадан ватман кәгазе янына килде, аяк астында яткан сүс бауның бер очын кулына урады да икенче очын аска ыргытты.

— Бәйләгез! Иң кырыйдагы йортны бәйләгез! — дип кычкырды ул.

Түбә читендә калкып торган стенага аяк терәп, көчәнә-көчәнә бауны тартырга тотынды, тирләп-пешеп чыкты. Ниһаять, бау очына бәйләнгән йортны түбә өстенә тартып менгерде. Нигәдер бәләкәйләнеп, уенчыкка охшап калган йортны күтәреп кәгазь өстенә китереп куйды.

Икенче йортны менгереп беренчесе янәшәсенә бастырып куйгач, урам башы хасил булгандай тоелды. Ашыга-ашыга өченче, дүртенче йортларны өскә күтәрде. Кәгазь өстендә йортлар тезелеп бетеп, чып-чын Ташлыяр авылы абайлангач, ул үз эшенә сокланып торды. Аннары, нидер исенә төшеп, аска карады.

— Менегез! — дип кычкырды ул астагыларга.

Ләкин аларның берсе дә бауга якын килмәде. Кинәт кенә аңа бик тә күңелсез һәм куркыныч булып китте. Ихтыяр, йорт түбәсенең читенә үк ятып, ярты гәүдәсе белән үрелеп, аска карады. Менә Зыятдин карт акрын гына бау янына килде дә нигәдер аны муенына урый башлады, бәйләп бетергәч, уң кулы белән күкрәгенә төртеп күрсәтте.

— Улым, төш! — дип инәлеп кычкырды шулчак әнисе.— Төш, берүзең генә нишлисең анда? Безнең янга төш!

Ихтыяр түбәне урап йөгереп чыкты, ләкин төшәрдәй урын күренмәде. Уртадагы подъезд капкачын болт белән беркетеп куйганнар иде. Ул, хәлсезләнеп, өметсез һәм кызганыч кыяфәт белән бер урында басып торуында булды. Әнә офык читенә сизелер-сизелмәс кенә алсулык йөгерде. Күк чите яктыра барган саен, астагылар да берәм-берәм каядыр китеп юкка чыкты. Таңның алсу диңгезе уртасында кораб мачтасына охшап күккә ашкан манара-йорт түбәсендәге Ихтыяр, бөтен командасы һәлак булган капитан сыман, берьялгызы торып калды.

Аста нәрсәдәр гөрселдәгән, шытырдаган тавышлар ишетелде. Караса, галәмәт зур трактор Зыятдин бабай атавын трос белән таккан да төбе-тамыры белән куптарып каядыр алып китеп бара. Тракторчы урынында — Нурислам. Ул авызын ерган, кабинадан сузылып аңа кул болгый, нидер кычкыра, ләкин сүзләре ишетелми.

* * *

Күзләрен ачкач, ул, шактый вакыт аңына килә алмыйча, як-ягына каранып торды.

— Бигрәк тынычсыз йокладың, улым. Яман төш күр-

деңме әллә? — дип эндәште аңа өстәл янында чәй әзерләп йөрүче әнисе.— Саташып, әлләниләр кычкырдың. Сәбилә, дип эндәштең. Анысы кем була аның?

Ихтыяр җавап бирмәде, юынып кергәч, майкадан гына өстәл янына килеп утырды.

— Яңа урында йокларга ияләшеп җитеп булмый,— дип, хәзер генә акланмакчы булды ул.

— Нинди яңа җир булсын ди бу сиңа! Армиягә киткәнче шул урында йокладың бит.

— Үзгәргән бугай минем урын. Хәер, безнең якта бөтен нәрсә үзгәргән. Әткәй тордымы?

— Эшләп аргандыр инде. Караңгылы-яктылыда ук чыгып китте. Алны да, ялны да белми бит. Дөнья рәхәтен татып та карамыйча картая шулай.— Әнисе чынаякка чәй ясады да Ихтыярга сорау бирде: — Зәлия кайтмаска булдымыни инде, улым?

Ихтыяр әнисенең инде күптән бу сорауны бирергә, бу сүзне кузгатырга җыенып та һич тә җай таба алмыйча, форсат чыкканны гына көтеп йөргәнен сизә иде. Шуңа күрә җавабы да күптән әзер иде.

— Космонавтларны күккә менгергәнче өч-дүрт ел җирдә сынап карыйлар, әнкәй. Физик яктан да, рухи яктан да сыныйлар. Без дә, гаилә корабына утырганчы, шундый сынау үтәргә булдык.

— Аңлаешлы гына итеп сөйлә әле, улым. Шулай да сыныкка сылтау гына эзлисең бугай син. Кайтырга риза булмагандыр әле. Безне ошатмагандыр. Үткән кайтуында да йөзен чытып кына йөргән иде.

— Ризасын риза да... Нигә ашыгырга? Әле аспирантура бетерәсе бар бит аның. Галим булам, ди.

— Зәлиянең нәрсә бетерәсе бардыр, анысы үзенә генә билгеле, улым. Тик менә болай дуадак каз сыман ялгыз яшәп, синең үзеңне бетерүең бик мөмкин. Шәһәрдә әллә кемнәр бардыр, башыңны әйләндергәннәрен үзең дә сизми калырсың. Зәлия дә җансыз кеше түгел. Япа-ялгыз яшәми. Аннары терсәгеңне тешләрдәй булырсың булуын...

Ихтыяр әнисенең әрләү сәбәбен аңламыйча торган иде, тәрәзә аша күренгән төзелеш краннарына күзе төшкәч: «Саташып, әллә нәрсәләр сөйләп ташламадыммы икән,— дип уйлады.— «Сәбилә» дигәнне ишетеп калган бит әнкәй. Тагын ниләр ычкындырдым икән?»

— Без барысын да киңәштек инде,— дип, уйларын-

нан котылырга теләгәндәй, уч төбе белән кат-кат башын сыпырды Ихтыяр.— Зәлиянең эти-әнисе дә шулай киңәш итте. Аспирантурасын тәмамласын, мин фатир алыйм, шәһәр дә азрак аякка бассын. Зәлия шәһәр кызы бит — «Зуля» дип чак кына ычкындырмады ул.

Ихтыяр сөйләгән саен, әнисенең йөзендәге нуры сүрелеп, күзләре төссезләнә барды. «Фатир алыйм» дип әйткәндә, Ихтыяр аның битләре тартышып куюын, чигәләре сулкылдый башлавын күрде.

— Безнең янда урын тармыни? — дип ишетелер-ишетелмәс тавыш белән сорады ул.— Безнең инде яшәгән кадәр яшисе калмаган. Кайтуыңны дүрт күз белән көтеп алып та... Соңгы өметебез синдә иде... Эшең дә бакча артында, янәшәдә генә.

— Анысын уйларбыз әле, әнкәй.

— Уйларбыз да уйларбыз. Нәрсә әйтсәң дә, һаман шул бер сүз: «уйларбыз». Бигрәк акыллы булып киттегез әле барыгыз да. Тәвәккәл таш яра, дигән борынгылар. Нәрсәсен уйлап торасың инде аның?! Егет кеше ике уйлап тормый, эчендә булганын яра да сала ул. Әнә этиең, холкы пырдымсыз булса да, эчендәге — тышында. Әйтсәм әйтим, охшасаң охшарсың икән бабаңа...

Әнисе, самавырын томалап, сөйләнә-сөйләнә ишегалдына чыгып китте.

* * *

Инде атнадан артык туктаусыз яңгыр коя. Төзелеш мәйданына бара торган юллар үтеп чыга алмаслык сазлыкка әйләнде. Шоферлар бетон юлдан читкә китәргә куркалар, кая карама, батып яткан машина, сүгенгән, кычкырышкан авазлар, арлы-бирле чабучы караңгы йөзле кешеләр.

Ихтыяр идарә ишеге төбендә яңгырдан ышыкланып торды да, автобус килгәнен күргәч, шуның каршына йөгерде.

Автобус су эченнән йөзә кебек иде. Тирә-юньдә бармак башы кадәр дә коры җир юк, бөтен дөнья яңгырдан, судан гына тора: автобусның тәрәзәсен ачсаң, аннан балыклар йөзеп керер сыман тоела. Шофер егет рульгә сөрлеккән дә яңгыр стенасын тишәрдәй булып алга карый, тирләгән тәрәзәне тырыша-тырыша чүпрәк белән сөртә.

«Романтиклар» поселогына җиткәч, автобус борылып туктады. Берничә карамчык бетон читендәге сукмакка

төшеп, яңгыр стенасы артына кереп югалды. Ихтыяр берүзе басып калды. Әле аягындагы ботинкасына, әле яңгыр боткасына әверелгән юлга карап аптырап торды. Тирә-юньдә ник бер җан иясе булсын, ник бер машина тавышы ишетелсен... Ә яңгыр һаман коя да коя, күзләрне әчеттерә, якадан агып кереп, тәнне калтырата, юеш кием авыраеп тәнгә ябыша. Ерак түгел соры йортлары белән җиргә сеңгән авыл күренә, карасу яшел арыш басуы артында аптыраудан башын күккә сузган озын борынлы краннар, җиргә төшеп кунаклаган ак болытларга охшаш йорт шәүләләре шәйләнә.

Ихтыярның инде чыланмаган җире калмады, бөтен тәнен калтырау алды, әмма тездән саз ярып төзелеш мәйданына якынлашкан саен, аның күңелендәге тискәрелек арта гына барды, йөрәге ярсыбрак типте, чигәләре кызышты. «Әйдә, әйдә, булдыра алган кадәр чылат, коендыр, ачы җилең белән җелеккә кадәр үт, ботинка эчен сыек сазың белән тутыр, ә мин барыбер туктамыйм, минем барыбер аз гына да кәефем төшми, чөнки үземне сынап карыйсым, шәһәр нигезен салучылар белән бергә буласым килә». Ихтыярның күңелендә кайнаган уйларны бүлеп, күк күкрәде, тирә-юньне яктыртып, яшен яшьнәде.

Чәчләре, битләре буйлап аккан яңгыр суыннан Ихтыярның уйлары да чистара, тәртипкә килә баргандай тоелды. Ул бүген беренче мәртәбә менә шушында, яңгырга коенып баткак юлдан барганда гына, үзенең чыннан да төзелештә эшли башлаганын, шәһәр салуның никадәр авыр, катлаулы һәм шулай ук кирәкле икәнен аңлады...

Кичә идарә башлыгы Харрас Шәмгунович аларның барысын да үз кабинетына җыйды. Йокысыз күзләре кызарып яшьләнгән, күз төпләреннән зәңгәрсу капчыклар асылынып төшкән, гәүдәсе дә авыраеп, хәлсезләнеп калган. Аның һәр хәрәкәте, һәр сүзе бүген эшнең никадәр җитди икәненә ишарә ясап, кабинетта утыручыларны да ирексездән җитдиләнергә мәҗбүр итә иде.

— Квартал азагы җиткәнне аңлатып тору кирәк түгелдер. План яна, кычкырып яна! — Ул тавышын күтәрә төште.— Ә без, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм көтеп, күккә карап утырабыз. Яңгыр түгел, таш яуса да, тапшырыласы объектларны тапшырып бетерергә — бездән бары менә шушы гына сорала.

— Айлар буе эленке-салынкы йөрибез дә, квартал азагы җитүгә тагын штурм башлана...

— Бу сүзне мин әйтергә тиеш идем сиңа, иптәш Фарукшин. Җыелыш саен күзгә кибәк җибәреп утырырга барыбыз да булдырабыз, ә эшкә килсәк, батырлар кими. Социология бүлегенең квартал планы юк, аның планы янмыймы? Ярый, без сине иртәгәдән үк Саттаров бригадасына беркетәбез. Җитте сезгә өстән карап утыру! Барыгыз, булышыгыз, нигә эшләре бармый, нигә көймәләре комга терәлгән, өйрәнегез, аңлатыгыз.

— Бәлки, социология бүлеген бөтенләй ябаргадыр?

— Анысын киләчәктә карарбыз. Ә хәзергә әйткәнне эшләгез.

Нурислам, авызында бүленеп калган җөмләсен йотып, йөзен чытты да ачу белән урынына утырды. Идарә башлыгы тынычлана төшеп дәвам итте:

— Иртәгә иртән СМУ начальникларын шушы бүлмәдә көтәм. Квартал планын үтәү өчен нинди чаралар күрергә уйлыйсыз? Кемгә нәрсә җитми, кемгә нәрсә комачаулый — барысын да сөйләрсез. Ай азагына кадәр һәр көнне иртәнге сәгать сигездә оперативка уздырабыз. Кичә эшләгән эшләргә хисап та бирерсез, алдагы көн турында да фикер алышырбыз...

— Ерак авылларда яшәүчеләрне алып килеп булмый, машиналар бата...

— Раствор җитми, юл юк...

— Насослар эшләми. Растворны бишенче катка носилка белән ташыйбыз.

— Беләм, барысын да беләм,— дип, берәм-берәм торып сөйли башлаган ораторларны туктатты Харрас Шәмгунович.— Иртәгәдән башлап идарәдә секретарь кыздан башка берәү дә калмый. Бөтен штатны тулысы белән төзелешкә җибәрәбез. Каршылар юкмы? Булмаса, бу турыда соңыннан Шамкаев тәфсилләп аңлатыр. Һәр бригадага эшлисе эш күләмен конкрет ачыкларга, материаллар белән тәэмин итүдә булышырга, аңлату эше алып барырга, коллективта мораль климатны яхшыртырга! Менә сезнең бурычлар шул. Һәр кеше үзенең бүген күпме эшләгәнен, иртәгә, берсекөнгә күпме эшләргә тиешлеген белсен. Һәм моның өчен күпме әҗер алачагын да исләренә төшерергә онытмагыз. Әлегә коммунизмда яшәмибез. Аккордный түләүне яңадан гамәлгә кертергә кирәк, үткән елның декабрендәге кебек. Смена заданиесен үтәмичә торып, беркем дә эш урынын ташлап китми! Аңлашылдымы?

...Ихтыярны уйларыннан бүлеп, артта машина үкергәне ишетелде. Ярты гәүдәсе белән саз ярып килгән «Урал»ның кабина ишеге ачылды.

— Туктасам, кузгалып булмый, барган шәпкә сикереп утыр! — дип кычкырды шофер.

Кабина эче җылы иде. Тирә-юньдә бертөзлексез яңгыр шаулап яугангамы, аңа монда шулкадәр рәхәт тоелды. Әкренләп калтыравы да кимеде, тәненә җылы йөгерде.

Машина яшел төстәге вагон янына туктагач, ул егетләрчә җәһәт кенә җиргә сикереп төште дә, тез тиңентен сазга чумып, җиргә таянды. Янәшәдән узып баручы кызларның көлүе ишетелде.

— Галстугыгыз кыйшайган, турылап куегыз, абый,— дип шаяртты аларның берсе.

— Чалбарыгызның үтүк эзе бозылмасын! — дип өстәде икенчесе.

— Контора күсесе! — дип, үз-үзен әрләп куйды Ихтыяр.— Кем инде мондый көнне ботинка киеп чыга? Ак перчатка киеп төземиләр шәһәрне...

— Нәрсә дисез, абый? Булышыйммы әллә үзегезгә?

— Беляшкина бригадасын каян табып була? — дип сорады ул, вагон түбәсеннән агып төшкән суда кулларын юа-юа.

— Әнә, тавышларын ишетмисезмени? — дип, бер-берсенә карашты кызлар.— Кәләшегезне эзләп килмәгәнсездер бит?

Ихтыяр җавап биреп тормады, ботинкасына ябышкан балчыкны каккалый-каккалый, җыр авазы ишетелгән вагонга таба китте. Ишек төбенә килеп җиткәч, бүлдерергә кыймыйча, туктап калды. Эчтән кемнеңдер уйчан һәм сагышлы авазы агыла иде:

Что было, то было,
Закат заалел...

Беляшкина бригадасының яманаты бөтен төзелешкә таралган иде. Эш хакы түбән, бригадада тәртип юк: әле кемдер авырып киткән, әле берсе ирсез генә декретка чыккан, монысын әниләре тиз генә чакыртып алган, тегесен тулай тораktан куганнар. Бригадада кырыктан артык хатын-кыз, кырыктан артык холык. Беляшкина аларның холкы белән артык санлашып тормый, турыдан яра, каршы әйткәнне яратмый, тозлап-борычлап туздырып ташларга да күп сорамый, диләр. Ә штукатур эше җи-

цел түгел, анда барырга атлыгып торган кеше юк. Шуңа күрә түзгәне түзә, түзмәгәне тизрәк табан ялтырату ягын карый. Төзелеш кибет түгел, теләгән әйберне тиз генә алып булмый, кешеләр белән аралаша белергә, кирәк чакта матур итеп елмаерга, урыны белән таләпләрне каты куярга туры килә. Ә Беляшкина ни балта осталары, ни ташчылар, ни транспортчылар белән рәтләп сөйләшә белми. Барысы белән ачуланышып, араны бозып бетергән.

Вагон эчендә җырны икенче бер кыз күтәреп алды:

Что было, то было,
Скрывать не могла...

Кинәт кенә Ихтыярның күңелен ут көйдереп алгандай булды. Хәзер вагон ишеген ачып керсә, аның каршысына Зәлия килеп чыгар, бу җырны ул җырлыйдыр сыман тоелды.

Актарылып ташланган басу уртасында, коеп яуган яңгыр астында бу җыр шулкадәр таныш та, якын да сыман, ул махсус шушындый көнне җырлау өчен генә язылгандыр кебек иде. Яңгыр астында басып торган саен, ул үзенең тынычлана барганын тойды, әле генә күңелендә баш калкытып куйган уйлар юкка чыкты. Ә җыр агылды да агылды. Әгәр дә вагон эчендәге кыз могҗиза белән Зәлия булып чыкса, Ихтыяр аны күрү белән кочаклап алыр да шушы мәхшәрле көнне өйләренә кадәр күтәреп кайтыр, моннан соң беркая да җибәрмәс, һәрчак үзе янында гына тотар кебек иде. Ләкин ул моның чынга ашмас коры хыял гына икәнен белә, шуңа ныграк төшенгән саен, Зәлия дә аннан ерагая бара иде.

Ихтыяр ишекне тартып ачуга, җыр өзелде. Стена буендагы эскәмияләргә тезелешеп утырган кызлар аның пычракка баткан чалбарына, су тамып торган плащына, ни әйтергә белмичә югалып калган кыяфәтенә карап, тик торуларында булдылар.

— Беляшкина кайда? — дип, ишек катында туктап калды ул.

— Ә сез кем буласыз соң? Күктән төштегезме әллә?

— Мин шәһәр төзү идарәсеннән. Кайсыгыз бригадир?

— Безгә бригадир нигә? Барыбер эшләмибез,— дип, баш күтәрмичә генә сүз ыргытты «Азат хатын» журналын актарып утыручы кыз.

— Нигә эшләмисез?

— Измә юк.

— Нишләп юк? Артыннан йөрдегезме? Белештегезме?

— Заводта бар. Ләкин монда китерергә вертолет бирмиләр. Машиналар бата.

— Бүтән бригадаларга измә китерәләр, сезгә юк. Димәк, сорый белмисез.

Шулчак кызларга җан кергәндәй булды, алар, берсен берсе уздыра-уздыра, аһ-зарларын сөйләргә тотындылар.

— Туктагыз! Зинһар өчен, туктагыз! — дип бүлдерде аларны Ихтыяр.— Барыгыз да бригадирны яманлыйсыз, ә боларны аның үзенә әйтеп караганыгыз бармы?

— Безнең аны юньләп күргәнебез дә юк.

— Егетеннән аерыла алмый.

— Кайда ул? Чакырыгыз әле.

Бригадир күрше вагонда гына икән, озакламыйча ул томырылып торган таза гәүдәсе белән ишекне тутырып килеп тә керде. Аның ышанычлы адымнар белән нык-нык басып ишекле-түрле йөрүен, чәнчеп карый торган усал күзләрен, кызларның шул арада шым булуын күргән Ихтыяр үзе дә югалып калды. Тиз генә исәнләшеп, үзенең кем икәнен, нигә килгәнен аңлатты.

— Безгә агитаторлар кирәкми, измә бирегез,— дип, төксе генә сүз башлады бригадир.

— Соңгы атнада күпме эш башкардыгыз? Нигә измә артыннан йөрмисез? Китереп биргәнне көтеп утырасызмы?

— Без — штукатурлар. Сазга чумып измә артыннан йөрү безнең эш түгел. Объектны вакытында тапшыртасылары килсә, измә белән тәэмин итсеннәр.

— Бульдозер, трактор сорап карадыгызмы?

— Хәзер, кара яңгыр астында чыгып йөгердем!

— Бәлки, яңгыр айлар буе туктамас. Сез һаман шулай көтеп утырырсызмы? Тик утырганга да нәрәт япмыйсыздыр бит?

«Азат хатын» укучы кыз башкалардан кыюрак иде бугай, сүзгә кушылырга булды:

— Шул да булдымы нәрәт ябу! Ике сум алтмыш тиеннән ябабыз! — дип, Ихтыярга күтәрелеп карады ул.

— Бу вагонда күпме кул кушырып утырырга була инде? — диде оялчан күзләрен челт-челт йомгалап утыручы җиңел гәүдәле, зәңгәр яулыклы кыз.

— Измә килмичә торып, урыннан кузгалу юк! — дип кырт кисте Беляшкина һәм өстәл янындагы аркасыз урындыкка лып итеп утырды.— Барыгыз, идарәгә түгел,

министрның үзенә җиткерегез! Өйрәтеп йөрүчеләр күп булыр...

Ихтыяр, нинди карарга килергә белмичә, беразга тын калып торды да кинәт кенә борылып ишек тоткасына ябышты.

— Мин берничә сәгатьтән килеп җитәм! — дип кычкырды ул чыга-чыгышка.— Китми торыгыз, көтегез!

Ләкин аның берничә сәгать дигәне озакка сузылды. Баткак юл буйлап бетонкага чыкканчы хәлдән таеп бетте.

Заводта измәгә кытлык юк иде. Диспетчер тәрәзәсенә башны тыгып, сулуы капканны басарга тырыша-тырыша хәлне аңлаткач, бетон торбага спираль урап ясалган җылыткычка аякларын терәп утырган сырма фуфайкалы, ирләрчә тупас кыяфәтле хатын кулларын җәеп куйды.

— Измә җитәрлек. Ташучы юк. Хет берьюлы ун машина алып кит! — Диспетчер хатын, авызын олы ачып иснәнә-иснәнә, Ихтыярга гамьсез генә күз ташлады.— Шоферлар кәрт суга. Минем сүз үтми. Үзең сөйләшеп кара,— диде ул һәм бүрәнәдәй балтырларын җылыткычка табарак сузды.

Вахта вагоны яңа яккан мунча кебек төтен белән тулган иде. Шоферлар өчен гүя яңгыр да, шул яңгырда манма чыланып утыручы йортлар да, вагонда измә көтүче кызлар да юк, алар уенга бирелеп, бөтен дөньяларын онытканнар, кычкырыша-кычкырыша, сүгенә-сүгенә кәрт сугалар.

— Егетләр! Измә юк. Кызлар измә көтә. Кем бара? — дип, ярым ялварып та, бераз ачуланган сыман да итеп эндәште аларга Ихтыяр. Ләкин аның сүзләренә игътибар итүче, хәтта борылып караучы да булмады.

Ул ярсып, кабынып китүдән үз-үзен тыярга тырышты, бер урында таптанып торды да кинәт ишек буендагы кара төймәгә басты. Болай да төтен эчендә шәйләнеп кенә күренгән гәүдәләр кинәт куе караңгылыкка чумды. Шулчак кемдер ачы итеп сызгырып җибәрде, вагонда пәри туе купкан сыман кычкырыша-шаулаша башладылар. Ихтыяр, арттырыбрак җибәрүен аңлап, утны кабызды. Вагон эче зәңгәрсу яктылык белән тулуга, кемдер аның якасына килеп ябышты. Биш катлы итеп сүгенгән аваз ишетелде.

— Чыгарып атыгыз үзен! Каян килгән бу хулиган?

— Бандит!

— Шпик!

Егетләр берсен-берсе уздырып кычкырыша башлагач, Ихтыяр алар белән артык сөйләшеп торуның мәгънәсезлеген аңлады, чыгарга җыенган иде дә таныш тавыш ишетеп туктап калды.

— Ихтыяр! Батыршин! Синме бу? Туктагыз әле, егетләр, минем ахир бит бу!

Каршысына Фаил килеп баскач, ул тынычлана төште.

— Утыр, әйдә! Мондый яңгырда бер эт тә урамда йөрми. Әйдә, кәрт сугабыз,— дип, Ихтыярны көчләп диярлек урындыкка китереп утыртты ул.

— Юк, вакытым юк минем,— диде аңа Ихтыяр күңелсез генә.— Кызлар көтә. Төзелештә эш бөтенләй туктаган бит. Ярый, сау бул! Мин киттем!

Ул ишеккә таба бара башлагач, Фаил дә урыныннан кузгалды.

— Тукта! Беткән баш беткән! Аллага тапшырдым мин, егетләр! — дип, ул Ихтыяр артыннан иярде.

Күптәнге дустын очраткандай, Фаил юл буе өрөзлексез сөйләнеп барды.

— Менә шулай, туган,— диде ул,— танышларсыз, дусларсыз беркая да барып булмый бу дөньяда.

— Теге вакытта юлда сине очратмаган булсам, сиңа утырып кайтмасам, язмыш мине, бәлки, бөтенләй бүтән тарафларга илтеп ташлар иде.

— Рәхмәт укырсыңмы миңа, әллә каргарсыңмы — вакыт күрсәтер.

— Рәхмәт! — дип елмайды Ихтыяр.— Син булмасаң, кызлар алдында хур була идем бит. Яңгыры да туктый белмәде.

— Мин ияләштем инде бу яңгырга. Кайчакта бернәрсәгә дә ис китми башлый. Бөтен дөньясын су басып китсә дә...

— Борыныңны салындырма! — Ихтыяр кесәсеннән бер кап тәмәке алып Фаилгә сузды.— Сиңа дип алып кайткан идем. Казан күчтәнәче. Инде ничә көн кесәдә йөртәм. Очрамыйсың да очрамыйсың.

— Чыланып беткән бит бу,— дип, тәмәке кабын әйләндерә-әйләндерә карады Фаил.— Ярый, киптереп тартырбыз. Рәхмәт. Онытмагансың.

— Кызлар кайтып китмәсә ярый инде,— дип, яңгыр пәрдәсе аша күрергә теләгәндәй, шәһәр ягына үрелеп карады Ихтыяр.— Вәгъдә бирдем бит.

— Вәгъдә — иман,— дип уйчанланып әйтеп куйды

Фаил.— Мин дә вәгъдә бирдем. Ике елдан өр-яңа фатирда туй ясарга. Менә ике ел тулып та килә. Бәлки, шушы йорттан бирерләр фатир. Өйләнгәч, башка чыгарга исәп.

Фаил, сикерергә әзерләнгән мәче сыман, җилкәләрен дугайландырып ике кулы белән рульгә чытырдатып ябышты да, машинасын бөтен көченә үкертеп, бетон юлдан сулга таба борылды. Баткаклы юлга керүгә, Ихтыярның башы әле кабина түбәсенә бәрелде, әле ул кабинадан очып чыгардай булып алга атылып китте. Машина як-якка чайкала да, чокырга төшеп чумам дигәндә генә, тагын алга ыргылып китә. Ләкин барган саен аның тизлеге кими иде. Менә ул бөтенләй туктап калды. Фаил арткы тизлеккә салды, тагын алга алдырып карады, әмма машинаның кымшанырга исәбе юк иде.

— Килеп җиттек! — дип, утыргыч аркасына терәлде Фаил.— Безнең вәгъдәне аңламады бу тимер алаша. Ярты юлны үткән идек югыйсә. Хәзер утыр инде менә...

Ихтыяр кабинадан сикереп төште дә сыек пычракны чупырдата-чупырдата бетон юлга таба атлады. Сәгатьтән артык яңгыр астында басып торса да, аларны тартып чыгарырлык транспорт күренмәде. Туңудан калтырап, тешләре тешкә тия башлагач, яңгыр суын чапылдата-чапылдата, бер урында сикергәләргә тотынды. Шулчак бетон юлның урман ягындагы башында ташбака сыман үрмәләүче трактор күренде. Ул килеп җиткәнче, Ихтыярның түземе калмады, кул болгый-болгый каршысына йөгерде. Кабинадан Чәберчек Әхмәтнең башы күренгәч, нишләргә белмичә, тораташтай катып калды. Аның әле теге көнне үзләрен борып чыгарганга үпкәсе бетмәгән, шуңа күрә тагын ярдәм сорап аңа мөрәҗәгать итәсе килми иде.

— Нишләп торасың? Чыланып беткәнсең, карар җирең дә калмаган. Утыр әйдә.

— Баттык без,— дип, авыз эченнән мыгырданды Ихтыяр, ләкин тракторга якын килмәде.

— Кайда баттыгыз? Утыр! Без аны... әби коймак пешергәнче...

Ихтыяр кабинага кереп утыруга, трактор җирне селкетеп алга ыргылды. Трос белән эләктереп машинаны йортлар янына кадәр тарттырып бардылар, измәне бушаткач, яңадан бетон юлга чыгарып куйдылар.

— Әйттем бит вәгъдәдә торырга кирәк, дип! — Фаилнең дә күзләрендә шатлык балкый, ул да Ихтыяр белән бергә сөенә иде.

— Рәхмәт, коткардың,— дип, Әхмәтнең кулын кысты Ихтыяр.— Син очрамасаң, ята идек күктән ярдәм көтеп. Каян килеп чыктың?!

— Булачак завод урынындагы урманны чыгарабыз. Көн саен дүрт-биш рейс ясыйм мин. Барганда буш барам. Вакытын чамалап килеп торсагыз, монда кадәр генә кертеп куюберни тормый миңа. Унбиш минутта әйләнеп чыктык бит.

Әхмәт һәм Фаил белән саубуллашып, кат-кат рәхмәт әйтеп, иртәгә иртәнге сигездә шушы юл чатында очрашырга сүз куешып, Ихтыяр атлый-чаба яшел вагон янына таба ашыкты. Килеп керсә, эш киемнәрен яхшыга алыштырып, кайтыр юлга таба карап торучы кызларны күрде дә шаккатып калды.

— Сез кая? — дип кенә әйтә алды ул, Беляшкинаның йөзенә туры карап.

— Эш вакыты чыкты. Унбиш минуттан вахта килә. Аннан калсак, төнне монда кунарга туры киләчәк.

— Ә измә?

— Сездән измә сораган кеше булмады. Үзегез алып килдегез, үзегез теләсә нәрсә эшләтегез!

Бригадир измә килүгә куанмады, аның ачуы кабарган, кызлары алдында дәрәҗәсе төшүеннән куркып, ул һөҗүмгә күчкән иде. Ихтыярның үзләренә бернинди катнашы юклыгын сиздерергә теләгәндәй, аңа җилкәсе белән борылды да кызлар белән шаяра-шаяра сөйләшә башлады.

— Ничек инде бу? Ни җаныгыз белән ташлап китмәкче буласыз?

Ихтыярның өзгәләнүен күргәч, кызлар, Беляшкинага карап, аптыраашта калдылар.

— Әллә калабызмы соң? — дип икеләнеп кенә әйтте арадан берсе.

— Бер машина измә күп нәрсә түгел инде,— дип өстәде икенчесе.

— Караңгы төшкәнче өлгерәбез...— дип, бераз сыегая башлаган болытларга күтәрелеп карады өченчесе.

Шул вакыт аларның икеләнүләренә чик куярга карар кылган бригадирның катгый авазы яңгырады:

— Бернинди калу юк! Бригада өчен мин җавап бирәм. Монда мин команда бирәм!

— Башта измә юк, дип утырдыгыз, хәзер нәрсә җитми сезгә? — дип ярсып кычкырды Ихтыяр.— Барыгыз, кайтыгыз, үзем генә эшлим!

Кызлар үзара чыш-пыш килеп алдылар. Брезент курткасының башлыгы астыннан сөзеп карап торган бригадир сүзгә катнашмады. Менә кызларның берсе, «Азат хатын» журналы укыганы булса кирәк, Ихтыяр янына килде.

— Вахта шоферы белән сөйләшә аласызмы? Ике-өч сәгатьтә юкка чыгарабыз ул измәне. Көтеп торса, калабыз.— Шулай диде дә, Ихтыярның җавап биргәнен дә көтеп тормыйча, артка борылып кул изәде: — Әйдәгез, кызлар!

Штукатурчы кызлар тиз-тиз генә өсләрен алыштырдылар да, тезелешеп, каршыдагы биш катлы йортка юнәлделәр. Вагон янында Ихтыяр, бригадир һәм тагын алты кыз басып калды.

— Монда килеп башбаштаклык белән шөгыльләнүегез турында иртәгә үк идарәгә хәбәр итәм! — дип зәһәрләнде Беляшкина.

— Иртәгә теләсә кая барыгыз. Тик менә хәзер бригададан аерылмаска иде сезгә. Бергә-бергә тизрәк тә булыр иде. Вахта барыбер бездән башка китмәячәк.

Ихтыяр инде тынычланган иде.

— Мин сезнең опекада эшләүдән баш тартам! — дип кырт кисте бригадир.

— Мин монда сезнең чакыру буенча килмәдем. Вакыты җиткәч, китәрмен. Хәзергә сез ял итә торыгыз, мин кызлар янына барам.

— Бригаданы үз кулыгызга аласызмы? Димәк, минем монда кирәгем калмады.

— Анысын үзегез чамалагыз инде. Дезертирлык белән шөгыльләнгән кеше бригадир була ала микән?

Беляшкина, үзе белән калган кызларны ияртеп, вагонга кереп китте, Ихтыяр, туктаусыз сибәләгән яңгырга йөзен куеп, төзелеш мәйданына таба атлады. Әйтерсең лә, җил катырак искән саен, аның күңел җилкәннәре ныграк киерелә дә йөрәге ярсыбрак тибә иде.

* * *

Икенче көнне Беляшкина эшкә чыкмады. Ихтыяр, измә төялгән машинадан сикереп төшүгә үк, вагон читенә тезелешеп баскан кызларның кичәгедән кычкырыбрак сөйләшүләрен, ничектер кыюланып китүләрен күреп бераз гаҗәпләнә дә калган иде. Бригадирның килмәвенә исе киткән кеше булмады. Өч ел буе студент

отрядларында эш башлап йөргән Ихтыярның тәҗрибәсе ярап куйды. Ул кызларга эш бүлеп бирде, күрше участокка барып, куәтле насос табып кайтты. Насосны хутка җибәреп, бишенче катка носилка белән измә ташу мәшәкатеннән котылгач, кызларның кәеф бөтенләй күтәрелде, көлешкән, шаярышкан авазлар да ешрак ишетелә башлады, кайберәүләре җырлап ук җибәрделәр.

Смена төгәлләнеп, бүген эшләгән эшләргә йомгак ясагач, кызларның кәефе яхшырды. Нәрәтне алар бүген җиде сум кырык тиеннән яптылар. Инде атналар буе ике сум алтмыш тиенгә эшләп йөргән кызлар өчен бу шатлык иде.

Ә кичен Ихтыярны идарәгә производство киңәшмәсенә чакырып алдылар һәм, «бригадирны эштән азат иткәне, бригадада конфликт тудырганы өчен» тозлап-борычлап сүккәннән соң, шелтә биреп чыгардылар.

— План үтәү — безнең өчен бердәнбер максат, төп максат түгел,— диде ахырдан идарә башлыгы Харрас Шәмгунович.— Без кирпеч, бетон, измә белән генә эшләмибез, иң мөһиме — кешеләр белән эшлибез. Беляшкина бригадага барудан баш тартты. Димәк, бригада таркалды...

— Таркалмады,— дип, каш астыннан гына карап ачулы җавап бирде Ихтыяр.— Беляшкинаның бригадада бернинди авторитеты юк. Ул китте, бригада калды. Бүген планны...

— Барысын да беләбез. Планны арттырып үтәвегезне дә. Әмма ләкин, иптәш Батыршин, бригадирны эштән куып кайтарырга сезнең бернинди хокукыгыз да юк. Бригадирлар болай да җитми. Менә хәзер каян алыйм мин сезгә бригадир? Җитмәсә, квартал азагы.

Идарә башлыгы ачуланып сөйләсә дә, аның тел төбендә аталарча кайгырту, ярдәм итәргә, эшне алга җибәрергә теләү ятканы сизелеп тора иде.

— Мөмкин булса, бригаданы вакытлыча миңа бирегез. Квартал азагына кадәр.

— Үзегез пешергән ботка, үзегез ашагыз. Барыгыз, эшләгез,— дип көлемсерәде идарә башлыгы.

* * *

Ихтыяр соргылт плащын иңбашына салган да, җилҗил атлап, бетон юл буйлап эшкә бара. Каршыга агылган машиналарның күбесе буш, шуңа күрә алар шал-

тыр-шолтыр килеп бар көченә чаба, шәһәргә таба баручылары исә, бетон плитәләрдән, озын субайлардан, таутау өелгән кирпечләрдән сыгылып, көчкә сөйрәләләр.

Ихтыяр бүген эшкә көндәгедән иртәрәк кузгалды. Инде ике айга якын бригадир вазифаларын үтәп, төзелеш сазында бата-чума йөри торгач, күңеле идарәдә өстәл артында утырып эшләүдән читләшкән иде. Бригадир булуның үз кыенлыклары бар барын. Кызлар арасында тавыш еш куба. Аларны хәл итү, эшне дөрес бүлү, измә юнәтү, нәрәт ябу, тәрбия эше алып бару — болар һәммәсе синең өстә.

Ике атна буе теңкәгә тигән яңгыр, ниһаять, туктады. Ике атна буена күренмәгән кояш кызлар сыман оялчан гына елмайды. Аннары, акланырга теләгәндәй, көн буе ал-ял белмичә кыздырырга тотынды.

Берничә көн эчендә юллар такырланды, төзелеш мәйданында тузан болытлары уйный башлады. Измә өзлексез килеп торгач, кызларның да сүзләре кимеде. Торабара алар нәрәтне сигезәр, тугызар, унар сумнан яба башладылар.

Үз күзе белән күреп ышанырга теләгәндерме, идарә башлыгы Харрас Шәмгунович беркөнне болар янына килеп чыкты. Мактый-мактый, башын чайкый-чайкый, этаждан этажга йөрде. Вагонга җыелышкач, удар айлыкта җиңеп чыкканнары өчен, бригадага күчмә вымпел тапшырды. Барысы да яңгыратып кул чаптылар. Бары тик почмакта сөмсере коелып утырган иң өлкән штукатурчы Мәрьям генә аларның шатлыгына кушылмады.

— Миңа вымпел кирәк түгел, фатир кирәк,— диде ул, идарә башлыгының үзенә карап торуын күргәч.— Күпме вәгъдә бирергә, күпме алдарга була?! Суык вагонда өч балам тиң авырып ята, корык та корык. Ирем, атна буе эшкә бармыйча, шулар белән утыра. Мине бригадир җибәрми, объектны тапшырмыйча торып, берегезгә беркая китү юк, ди. Идарәдән белешмә китереп тоттырды да иремне больничныйга утыртып куйды.

— Кайчаннан бирле эшлисез?

— Беренче көннән...

— Сезнең бригаданың элек нинди исәптә йөргәнен беләсездер бит? Квартирны иң әүвәл алдынгыларга бирдек. Бу айда сез дә эш күрсәттегез күрсәтүен. Ләкин бер ай гына бит ул. Уйлап карарга кирәк булыр... Тик менә өлгереп җиткән йортларга да кеше кертә алмый-

быз. Водозабор коеларыннан су киткән. Сусыз йортка ничек кеше кертәсең? Ул коеларны яңадан штукатурлаганчы тагын айга якын вакыт китәр. Җитмәсә, безнең төзелештә андый катлаулы эшне башкарырлык кешеләре дә юк икән...— Идарә башлыгы авыр итеп көрсенде.— Шамкаев шабашниклар чакырмакчы була инде. Аптырагач.

Күңелсезләнеп таралыштылар. Әле генә алар белән бергә шатланган кояш моңсу йөзле кызларга гаҗәпләнеп карап тора иде.

Ихтыяр эштән кайтышлый водозаборга сугылды. Тимер баскыч буйлап караңгы, юеш бетон коеларның төбенә төшеп карады, кешеләр белән сөйләште һәм идарә башлыгына шылтыратты.

— Харрас Шәмгунович, коеларны карадым. Рөхсәт итсәгез, тотынып карарга була.

Икенче көнне иртән Шамкаев аны мыскыллы елмаеп каршы алды.

— Батырлык кыласы киләме, Батыршин? Әйдә, әйдә, кыл, яшь кешегә дан кирәк. Идарә башлыгы белән киңәштек, ике коеның берсен менә бу унтер командага, икенчесен сезгә бирәбез. Ярышып эшләп карагыз.

Автобуска төялеп елга буена төштеләр. Бер кое янына гел егетләрдән генә торган бригада, икенчесе янына кызлар тезелешеп басты. Егетләрнең йөзләрендә елмаю иде.

— Ничә көн кирәк булыр? — дип, як-ягына каранды Шамкаев.

Егетләр, ике атнада бетерәбез, диделәр. Ихтыяр кызларга күз йөртеп чыкты, аннары, алардан сорагандай:

— Ун көн җитәрме? — дип куйды. Кызларның дәшми торуларын күргәч, Шамкаевка таба борылды.— Әгәр дә измә килү тоткарланмаса, әгәр дә балта осталары һәм электриклар белән тарткалашып юкка вакыт уздырырга туры килмәсә, ун көндә бетерербез.

Кызлар өч сменага бүленеп эшләргә булдылар. Өйләргә кайтып йөрмәс өчен, вагон тарттырып китерделәр. Хәлдән тайганчы эшлиләр дә, тамак ялгап алгач, йокларга яталар. Көндезге ашка коедан чыгып та тормыйлар, шунда гына утырышып тамак ялгыйлар, ял итәләр дә тагын тотыналар. Измә өстән шланг белән төшеп тора, аңа эретелгән пыяланы үзләре кушалар. Штукатурланган кое, галәмәт зур кувшинга охшап, ялтырап кала.

Шабашниклар беренче көннәрдә «кувшин» авызына

килеп үртәшеп киткәлиләр иде, кызларның баш күтәрмичә эшләгәннәрен күргәч, аларның тавышлары ишетелмәс булды.

Коеның өске өлешенә якынайган саен, эшләр катлаулана, баскычларга басып измә ыргыту кыенлаша, кызларның да көче кими иде. Җиденче тәүлеккә чыккач, Ихтыяр кызларның соңгы чиккә җитеп арыганнарын күреп эшне туктатты.

— Теләгән кешеләр генә калсын,— диде ул.

Ләкин водозабор коесын ташлап китүче булмады, тавышсыз-тынсыз гына, барысы да яңадан мастеркларына тотындылар.

Таң атканда коены штукатурлап бетерделәр. Ихтыяр, аякларын көчкә өстерәп, өскә чыгып басты, кызларның күбесен күтәреп менгерергә туры килде. Коедан чыккан берсе вагонга кереп идәндәге матраска ауды. Идарә җитәкчеләре килеп җиткәндә, алар сабый балалар кебек берберсен кочаклашып йокыга талганнар, бары тик Ихтыяр гына кое кырыенда һәйкәл сыман хәрәкәтсез басып тора иде.

Шабашниклар гарьлекләреннән бер көн эшкә чыкмаганнар, җыелышып эчкәннәр, дип сөйләделәр.

Мәрьямне яңа квартирына бөтен бригада белән күчерделәр. Өй туенда уен-көлкенең чиге булмады. Ихтыярга бик рәхәт тә, шулай ук гаҗәеп моңсу да иде. Ул мәҗлес беткәнне көтеп тормады, саубуллашып урамга чыкты. Якты тәрәзәдән ташыган җыр авазы аның күңелен үрти, адымнарын ешайтырга мәҗбүр итә. Ә кызлар аның саен кычкырыбрак, дәртләнебрәк җырлыйлар, алар Ихтыярның бөтенләе белән үзләреннән китеп баруын, иртәгә яңа бригадир киләсен белмиләр, рәхәтләнеп җырлыйлар да җырлыйлар иде.

...Янәшәсеннән генә машина узып киткәч, Ихтыяр кичә кызлар белән турысын әйтеп саубуллашмавына үкенеп куйды. Бүген яңа бригадир килгәч, алар аптырап калырлар, әйтми китүенә үпкәләрләр. «Нигә кешеләрнең йөзенә карап уйлаган уемны әйтә алмыйм мин? — дип, үз-үзенә сорау бирде ул.— Әллә һаман малайлыктан чыгып җитә алмыйммы? Әллә соң бу каты куллы әтисенең тәрбия нәтиҗәсеме? Татар авылында бала-чаганың башына сугып кына торалар бит. Тегене эшләмә, моны эшләмә. Ул олы кеше, аңа сүз әйтмә, монысы син-

нән кечерәк, кечеләргә кече була бел. Японнарда бала-чага унике яшькә хәтле үз иркендә йөри. Нишләсә дә рөхсәт, хет башыңа менеп атлансын. Бездә тыелмаган нәрсә юк. Шуңа күрә мокыт булып үсәбез, шуңа күрә соңга калып өлгерәбез, шуңа күрә безгә җаваплы эшләрне ышанып тапшырырга кыймыйлар...»

Ул, шәһәргә якынлашкан саен, адымнарын тизләтә төште, авыз эченнән сөйләнә-сөйләнә, үз-үзен, бөтен нәсел-нәсәбен әрләде. Шулай итеп, Ихтыяр бригада турында онытырга тели, идарәдә йомышчы ролендә йөргәнен әле генә аңлап, шуннан гарьләнә иде.

Идарәдә эшләвенең беренче атнасында ук йомшак ягын сизеп алдылар да хәзер аңа нинди дә булса өстәмә эш табып кына торалар. Әле бер комиссиягә әгъза итеп сайлап куялар, әле башкаладан килүче делегацияне каршыларга җибәрәләр. Ихтыяр беркемгә дә каршы сүз әйтми, кая кушсалар, шунда йөгерә. Кызлар белән хушлашып кайтканда, ул бары тик үз вазифалары белән генә шөгыльләнергә рөхсәт итүләрен сорарга карар кылды. Ихтыяр баш инженерга сөйлисе сүзләрен тәртипкә китереп барды: «Кесәмдә төзүче-инженер дипломы була торып, тәэминатчы-толкач ролендә йөри алмыйм бит инде мин. Һәркемнең — үз урыны».

Шәһәр төзелешенең беренче елларында сүз күбесенчә юл булмау, транспорт, төзелеш материаллары, торак мәсьәләсе, мәктәпләр һәм балалар бакчалары җитмәү, эшче көчләргә кытлык, яңа килүчеләрне урнаштыру турында барса, быелгысы язда проблемалар икеләтә-өчләтә ишәйде.

Калку басуда ай буе тынмыйча скреперлар, бульдозерлар үкергәннән соң, бер читеннән икенче чите күренмәс нигез урыннарына тау-тау булып бетон балкалар, плитәләр, металл конструкцияләр өелде. Шәһәрнең моңа кадәр дә аннан-моннан тартып-сузып җиткергән эшче көчләрен, техникасын теләсәң-теләмәсәң дә завод төзелеше белән бүлешергә туры килде. Шулай итеп, яңа корыла башлаган завод хәлне тагын да катлауландырды, болай да вакыты-вакыты белән очы югалып торган галәмәт зур йомгакны бөтенләйгә чуалтып ташлады. Торак йортлар тапшыру срогы өзелсә, шәһәр заводны гаепләде, планы тулмый калса, эшче көчләр җитмәсә, завод бөтен сәбәпләрне шәһәр төзелешенә бәйләп сөйләргә гадәтләнде. Шулай итеп, әкренләп, Ташлыяр авылы итәгендәге үзәндә бер-берсе белән ярышучы һәм кайчакта хәтта чәкәләшеп

алудан да тартынып тормаучы ике мөстәкыйль көндәш «дәүләт» — Шәһәр һәм Завод пәйда булды. Аларны килештереп эшләтү вазифасын партиянең район комитеты үз өстенә алды.

Ихтыяр ике «дәүләт»тән торган шушы гигант төзелеш машинасы каршында үзенең кинәт бәләкәйләнеп калуын, аның кечкенә бер шөребенә әйләнә баруын, бернәрсә дә хәл итмичә, бары тик кушканны гына эшләп йөрүен көннән-көн ачыграк күрә барып, кая сугылырга, кайсысына тотынырга белмичә җәфалана иде.

Шундый уйларга чумып, онытылып барганда, кинәт аның артында тормоз шыгырдаган тавыш ишетелде. Борылып караса — кабинада авызын ерып Фаил утыра.

— Утырыгыз! — дип кычкырды ул, тәрәзәдән башын тыгып. Ихтыяр аның әле «син» дип сөйләшүенә, әле «сез»гә күчүенә өйрәнгән иде инде. Салкын акыл белән уйлап сөйләшкәндә, ул рәсми тон алырга тырыша, ә кызып китеп онытылгач, авылча якын итә, үз тиңенә санап «син» ди башлый.

Ихтыяр кабинага кереп утыргач, Фаил, елмаюым сиңа да күчсен әле дигән шикелле, бөтен йөзе белән балкып, Ихтыярга карады. Ләкин аның һаман төксе кыяфәт белән утыруын күргәч, сүрелеп, сүзен дәвам итте:

— Заправкага барам мин. Бөтен шәһәргә бер заправка, тагын ярты көн сырт кыздырырга туры киләчәк. Шоферлар оҗмах бакчасы дип йөртәләр аны. Сезгә идарәгәдер бит?

— Әйе.— Ихтыяр үз уйларыннан арынып бетә алмаган иде әле. Сүзсез калмас өчен генә җавап бирде.— Каян беләсез? Йөземә чыккан мәллә?

— Кирәк икән, мин сезгә бөтен анкетагызны тутырып бирә алам. Сез идарәдә баш инженер кул астында гади инженер булып эшкә урнаштыгыз. Эш хакыгыз — йөз дә туксан сум. Өйләнмәгән. Хәзергә этиләрегез янында торасыз... Яңа килгән кешене үзебезнең җиз иләктән үткәрәбез без. Ә сез, бу як кешесе буларак,аерым хисапта. Измә ташый башлагач, штрафной батальонга эләккәнсез, дип уйлаган идем. Котылгансыз бугай. Шоферлар барысын да белеп тора монда,— дип, баш бармагы белән ачык күкрәгенә төртеп көлде ул.— Әгәр берәр нәрсә беләсең килсә, әллә кемнәр янына барып йөрмә, бездән генә сора. Шәһәр безнең кулда!

— Ә, чыннан да, каян белдең син минем инженер булып урнашканны? Эткәйдән сораштыңмы?

— Сорашырсың аңардан! Шәһәргә күчүчеләргә сәлам дә бирми ул. Берничә тапкыр колхозга эшкә дәшеп караган иде баштарак. Хәзер бөтенләй күрмәмешкә салына. Без монда йөреп каешланган бит инде. Кемнең кем икәнен әллә каян күреп торабыз. Институт тәмамлап кайткан яшь белгечләр, гадәттә, прораб яисә гади инженер булып урнаша. Прорабларны йөк машинасы йөртә: иртән өеннән килеп ала, кич китереп куя. Моның өчен ул шоферның нәрәтенә өстәп яза. Ә син иртә таңнан җәяү теркелдисең. Димәк, гади инженер. Безнең шәһәрдә гади инженерлар гына җәяү йөри. Эшчеләрне вахта йөртә, начальниклар «Волга»да җилдерә. Күч син безнең участокка прораб булып, үзем йөртермен. Шамкаев кул астында эшләп кеше булган адәмне күргән юк әле. Инженерларын үз йомышына җигә-җигә дә, аласын алып, сыгасын сыгып бетергәч, чыгарып ташлый. Аннары аның урынына тагын бер җитез аяклы малайны ала. Тыңла минем сүзне. Зарплатаң да бермә-бер арта. Миңа да файдаң тияр, бу калтырчаны яңага алыштырырга булышырсың. Ә-әй, яшәпләр күрсәтер идек без аннары!

— Шофер булып түгел, социолог булып эшләргә кирәк сиңа. Башың шактый йомры күренә. Телеңә дә шайтан төкергән бугай. Кадрлар әрәм була,— дип көрсенгәндәй итте Ихтыяр.

— Кем булып?

— Социолог булып. Нурислам Фарукшинны беләсеңме? Төзелеш идарәсенең баш социологын?

— Теге, резин итек киеп, галстук тагып йөрүченеме?

— Шуны инде.

— Аны белмәгән кеше бармыни бездә?! Телгә беткән нәмәрсә! Күпләрнең бәгыренә тоз салды, телен бер кыскартырлар әле үзенең. Әллә нәрсә кырган кебек, көннәр буе төзелеш буйлап чапкалый. Эшче халкының хаҗәтләрен өйрәнә, имеш. Чатыр чабып кына керерсең кеше күңеленә! Берәр ай гына шушы баранканы әйләндереп карасын иде ул. Теле дә бүтәнчәрәк әйләнә башлар иде. Соңгы арада гел авыл юлында күрәм әле мин аны. Тагын нинди этлек уйлап йөри икән инде? Кичә кул күтәргән иде, утыртмадым.— Фаил журналдан кисеп ябыштырган чая йөзле кызга карап кашын җыерды да аның белән киңәшкәндәй әйтеп куйды: — Килмешәкләр басты дөньяны, чибәркәй. Болының ни дә аларга, авылың ни...

«Пластинкасын һаман алыштырмаган икән әле бу,— дип уйлады Ихтыяр.— Әллә авыл кешеләре барысы да шулай үзсүзле, үҗәт була микән? Әллә бу кирелек түгел, ә туган җиргә бирелгәнлекме? Әллә туган җирне ярату шулай буламы, үз авылы өчен җан атып йөргән егетләр тора-бара туган ил өчен җаннарын бирергә әзер торган баһадирларга әвереләме? Битараф кешедән яхшы белгеч тә, батыр да чыкмый бит».

Фаил тормозга басуга, машина сөрлегеп туктады. Ихтыяр башы белән кабина тәрәзәсен сөзеп чыга язды.

— Килеп җиттек, иптәш начальник. Төзелешнең нәрсә икәнен яхшырак күрәсең килсә, безнең янга ешрак сугыл. Хәзергә сау бул!

— Хуш, авылым!

Тузан болытыннан качарга тырышып төзелешкә таба җан-фәрманга чабучы машина артыннан Ихтыяр шактый вакыт карап торды.

* * *

Кабинетта беркем дә юклыгын күргәч, ул, сөенеп, өстәл янына килеп утырды. Ашыгып, кәгазь-каләм алды. Каләме белән маңгаен ышкып торды да гариза яза башлады.

Гаризага ул үзенә йөкләтелгән эштән канәгать булмавын да, институт бетергән килеш йомышчы малай ролендә калырга теләмәвен дә, монда килеп урнашкач, бөтен планнары юкка чыгуын да язды. Азактан, Фаилнең сүзләрен искә төшереп: «Участокка прораб, һич булмаса, бригадир итеп күчерүегезне сорыйм»,— диде. Гаризасы бик озын һәм буталчык килеп чыкса да, күчереп яза башласам, йә кире уйлармын, тимерне кызуында сугарга кирәк, дип, идарә башлыгының кабул итү бүлмәсенә керде. Секретарь кыз әле килмәгән, күрәсең, урыны буш иде. Харрас Шәмгуновичның сәгать җидедә үк килеп утыруын белсә дә, алдан кисәтмичә керергә кыймады. Ул кире чыгарга гына торганда, сул яктагы ачык ишектән таныш тавыш ишетелде:

— Кем ул анда? Гүзәл, синме?

Ихтыяр, ни әйтергә дә белмичә, ачык ишек каршына килеп басты.

— Ә-ә, Батыршин, исәнме! Минем янга керә идеңме, әллә чибәр кыз үзе кирәк идеме? Әйдүк, түрдән уз. Кичә

кич күпме эзләтеп тә табып булмады үзеңне. Әллә миңа каршы диверсия әзерләп йөрисез инде анда мыштым гына? Фарукшинга иярсәң, нәрсә дә булса җимермичә туктамыйсыз инде. Ярый, анысы турында аерым бер иркенләп сөйләшербез. Матур сүзләр сөйләшергә белә, ә эшкә дисәң, шундук койрыгын сыртка сала. Эш күрсәткән егетләрне яратам мин... Без сине, Беляшкина бригадасына җибәргәндә, мондый эшләр майтарып чыга алырсың дип уйламаган да идек. Икенче көнне үк шелтә дә чәпәдек түгелме соң әле үзеңә? Ә синең шома авыз Фарукшиның сүз сөйләп йөрүдән уздыра алмады, бер атнадан бригадага кул селтәп китеп тә барды. Кулыңа мастерок та тота белмәгәч, кеше өйрәтеп йөреп кенә булмый шул.

Харрас Шәмгуновичның шулай дустанә, ягымлы итеп сүз башлавына башта Ихтыярның күңеле эресә дә, сүз Нурисламга килеп терәлгәч, ул сагаеп калды.

Идарә башлыгы кәгазьдән башын күтәрмичә нидер яза. Әйтерсең ул бер минутка гына үзенең буй җитмәс тәхетеннән түбән төшеп торган да, тагын яңадан шунда күтәрелеп, кешеләрне күрмәс булган иде.

— Харрас Шәмгунович... минем сезгә...

Башлык хәзер бетерәм, бүлдермә, дигәнне аңлатып ишарәләде.

Ихтыяр, ул язган арада, кабинетка күз йөртеп чыкты.

Өстәл артында, стена куентыгындагы киштәдә, үрелеп буй җитәрлек кенә җирдә китаплар тезелеп тора. Иң өстә — куе зәңгәр тышлы Ленин томнары, астарак Толстой һәм Чехов әсәрләре, иң астагы рәттә — соңгы елларда чыккан татар һәм рус язучыларының китаплары. Сул як стенада — шәһәрнең генераль планы. Ул, баш архитектор кабинетындагыдан аермалы буларак, кызыл, сары, зәңгәр төсләр белән чуарланган. Кызыл төстәгеләре инде тапшырылган объектлар, сарылары — быел, зәңгәрләре бишьеллык дәвамында сафка кертелергә тиешле объектлар, ә буямаганнары киләсе бишьеллыкны көтә. Уң яктагы тәрәзә төбендә яран гөлләре чәчәк атып утыра. Кечкенә генә өстәл өстендә телевизор, аның янәшәсендәге шундый ук өстәлгә аскы яктан беркетеп рамы белән кәрәзле бал утыртылган.

Идарә башлыгының тамак төбеннән чыккан карлыккан тавышын ишеткәч, ул, аны танымыйча, сискәнеп китте.

— Кичә райкомда зур киңәшмә булганын ишеткән-

сеңдер инде,— дип башлады ул сүзен һәм, җавап көтмичә, җай белән дәвам итте: — Барыгыз өчен дә утлы табага бастырып кыздырдылар без фәкыйрегезне. Мактау сүзе азрак булса да, хакыйкатьне күзгә туры карап әйткәч, сезнең баш архитекторыгыз кебек, арттан чыш-пыш килеп йөрмәгәч, ачы тәнкыйть тә йөрәккә таш булып ятмады...

«Баш архитектор Урманов минем Нурислам белән үз янына кергәнне, ял итү зонасы турында бәхәс куптарганны, димәк, райкомга да ирештергән, идарә башлыгына да әйткән,— дип уйлады Ихтыяр.— Хәзер китәчәк инде сүз, кирәкмәгән җиргә кысылып йөрисез, беткән иде болай да безнең проблемалар, дип вәгазь укый башлаячак». Һәм ул язулы ягы белән аска каплап куелган гаризасын кул астынарак шудырып китерде.

Идарә башлыгы урыныннан торып ишекне ябып килде дә Ихтыярга карамыйча сөйләде:

— Бүгенге темплар белән барганда, без завод төзелешеннән бик тиз артта калачакбыз, эшчеләрне, төзүчеләрне торак йортлар, культура-көнкүреш объектлары белән тәэмин итә алмаячакбыз. Шуңа күрә безнең шәһәрнең төзү идарәсен эреләндерү, аны тамырдан үзгәртеп кору мәсьәләсе котылгысыз проблема булып алга килеп басты. Партия өлкә комитетында да бу турыда сүз булган. Кичәге киңәшмәдә обком вәкиле дә бар иде. Якын киләчәктә безнең базага нигезләнеп, производство берләшмәсе оештырырга ниятлиләр. Озын сүзнең кыскасы шул, Ихтыяр Тимерханович, бетон заводында баш инженер урынына вакансия бар. Бу инде заводның бөтен кан тамырлары тоташкан урын. Бүгенгесе көндә, үзең күреп торасың, бетон заводы — безнең иң авырткан җиребез. Нинди генә эшкә тотынсак та, шул заводка килеп төртеләбез.

Ихтыяр, боларны нигә миңа сөйлисез дигәндәй, башлыкка күтәрелеп карады. Харрас Шәмгунович, аның хәлен аңлап, сүзне аныклый төшәргә булды:

— Уйладык-киңәштек тә бу урынга сезне тәкъдим итәргә булдык,— дип, аңа сынаулы караш ташлады.— Тәҗрибәгез җитенкерәмәвен дә беләбез. Ә эш башлаганда кемнең тәҗрибәсе була? Суга кермичә, йөзәргә өйрәнгән кешене күргәнем юк әле минем. Аннары, мин сезне бик яшь дип тә әйтмәс идем. Утызны куалап киләсездер инде?

— Егерме биш тулды.

— Шулай булгач соң! Безнең төзелештә эшләүчеләрнең дә уртача яше — егерме дүрт. Менә дигән кандидатура! Эшли башлагач, өйрәнерсез. Директор дөнья күргән кеше, өйрәтер. Райкомда сезнең кандидатураны хупладылар. Оештыру сәләтегез барлыгын күрдек... Институтта группа старостасы итеп сайлаганнар. Армиядә комсорг булып йөргәнсез. Студент отрядларында — бригадир. Монда килгәч тә югалып калмадың... Шамкаев булып Шамкаевның борынына чирттең, шелтәсен кире алдырдың бит.

Ихтыяр, башлыкның да нәкъ Фаил кебек әле «сез»не кушып, әле «син»гә күчеп сөйләшүен күреп: «Карале, болар барысы да бертөсле икән монда,— дип уйлап куйды.— Яңа төзелә башлаган шәһәрләрнең үзенчәлегедер, ахрысы, бу. Сүзгә түгел, күбрәк эшкә китә аларның игътибарлары, шуңа күрә, ничек кенә мөрәҗәгать итсәләр дә, килешә үзләренә. Якын күрә икән, турыдан-туры «син» дип ярып сала, ара калдырып, ерактанрак торып сөйләшсә, шундук «сез»гә күчә».

Катлаулы проблемаларны шулай кешечә, мөлаем итеп аңлата алуы, үз-үзен югары куймыйча, тиң күреп каравы белән идарә башлыгы Ихтыярны гаҗәпкә калдырды. Җыелышларда кырыс һәм вакыты белән шактый тупас күренгән Харрас Шәмгунович бергә-бер генә сөйләшкәндә, эш башындагы түрә икәнен онытып, бары тик кеше булып кына калган, әйтерсең ул үзенең кабыгын салган иде. Аның бар нәрсәдән хәбәрдар икәнен белгәч, Ихтыяр бары тик:

— Мин... Ташлыярда... ял итү зонасы...— дип кенә әйтә алды.

Харрас Шәмгунович, монда да үзенең хәбәрдар икәнен яшереп тормыйча, барысын да ачыктан-ачык әйтеп салды:

— Ишеттек, барысын да ишеттек,— диде ул.— Баш архитектор Урманов генераль план белән риза булмавыгызны райкомның төзелеш бүлегенә җиткергән иде. Һаман шул Фарукшин йогынтысыннан арына алмыйсың. Ләкин монысы — икенче мәсьәлә. Хәзергә әле безнең ял турында уйларга вакытыбыз юк. Эш сорыйлар бездән, эш! Бугаздан алып сорыйлар!

Идарә башлыгы, урыныннан торып, кулын сузды.

— Димәк, без сезгә баш инженер урынын тәкъдим итәбез. Ышанычны акларсыз, дип уйлыйм. Сораулар юк-

мы? Булмаса, дүшәмбедән эшне кабул итә башлый аласыз. Сау булыгыз!

Ихтыяр, ишек төбенә килеп җиткәч, кырт кына борылды да, өстәлдә онытылып калган гаризасын алып, атлый-йөгерә кабинеттан чыгып китте. Секретарь кыз, килеп, бүлмә җилләтергә тәрәзәсен ачып куйган, көзге каршында бизәнеп-төзәтенеп тора иде. Ихтыяр аны күрүгә ишек тоткасын кулдан ычкындырды, тәрәзәдән кергән җил агымы ишекне шапылдатып ябып куйды, идарә башлыгы кабинетында нәрсәнеңдер гөрселдәп ауганы ишетелде. Ихтыяр ишекнең җилдән шулай каты ябылуын кереп әйтмәкче, гафу үтенмәкче булган иде, никтер кире уйлады, Нурислам янына йөгерде.

* * *

Эш кабул итеп, завод белән танышып арлы-бирле чаба торгач, бер атна вакытның узганы сизелмәде дә.

Дүшәмбедә, директор кабинетындагы кыска гына әңгәмәдән соң, ул үз бүлмәсенә керде һәм, эшне нидән башларга белмичә, ишекле-түрле йөренергә тотынды. Аннары үзенә элекке баш инженердан мирас булып өстәлдә тау-тау өелеп калган папкаларны актара башлады. Төшкә кадәр кәгазьләргә чумып утыра торгач, башы тубал булды, завод турындагы болай да буталчык фикерләре һаман саен чуала гына барды. Кәгазьдәге саннар белән генә мәсьәләнең асылын аңлап булмас, дип уйлады ул һәм, төшке ашка киткәндә, секретарь кызга, сәгать икегә урта һәм башлангыч звено җитәкчеләрен чакырырга кушып, исемлек бирде.

— Барысын да берьюлы чакырмагыз. Аерым-аерым сөйләшергә телим мин алар белән,— диде ул.

Төзелешнең беренче көннәрендә үк башка чара булмаганлыктан һәм ашык-пошык салынганга күрә, заводның корпусы да, техникасы да кулга иң беренче эләккән нәрсәләрдән генә оештырылган, бөтен җирдә тузан, пычрак, капка төбендәге сазлыкта машиналар батып ята, цехларда суларлык түгел, куркынычсызлык чаралары тупас төстә бозыла. Болары Ихтыяр күзенә ташланган, иң өстә яткан нәрсәләр генә иде әле. Ә инде кабинетына кергән кешеләр бер-бер артлы үзләренең аһ-зарларын сөйли, таләпләрен куя башлагач, хәлнең никадәр катлаулы булуы тагын да ныграк ачыклана төште.

— Цементның сыйфаты начар, маркасы туры килми.

— Юллар машина йөрерлек түгел, трактор белән тарттырабыз.

— Әзер продукция складын су баскан.

— Вентиляция эшләми.

— Эшче көчләр җитми.

Ихтыяр аларның һәммәсен игътибар белән тыңлады, фикерләрен кәгазьгә терки барды. Беркемне дә сүзеннән бүлдермәскә тырышты, шулай да сорауларны күп бирде.

Кояш завод коймасы артына төшкәч, ул, ниһаять, эштән арынып, телефон трубкасын алды. Атна буе җыелган меңнәрчә сораулар, проблемалар, аның күңеленә тынгылык бирмичә, төн йокыларын качыра башлаган иде инде. Бүген — җомга көн, атна азагы, Нурислам белән күрешеп сөйләшергә иде, дип уйлады ул. Ләкин Нурисламның телефоны җавап бирмәде. Трубканы куюга, сискәндереп, гадәттәгедән катырак итеп, телефон үзе шылтырады. Трубкада Зәлиянең тавышын ишеткәч, ул башта, ни әйтергә дә белмичә, аптырап торды.

— Ничек монда шылтыратырга булдың? Телефонны каян белдең? — дип гаҗәпләнеп сорады ул.

— Идарәгә шылтыраткан идем, шунда әйттеләр. И-их, син, начальник булгач, эреләнгәнсең, шылтырату-нитү юк.

— Юкны сөйләмә әле. Нинди начальник ди? Җимерек цемент базына китереп тыктылар.

— Кайчан булды соң әле бу хәл? Ничек алай бик тиз?

— Монда бөтен нәрсә шулай тиз эшләнә. Шәһәр бәләкәй бит, бүтән юләр таба алмаганнар да менә миңа китереп сыладылар. Килеп күрсәң, таный да алмассың мине.

— Безне танысаң, ярый инде.

— Кем ул «безне»? — дип көнләшкәндәй итте Ихтыяр.— Кияүгә чыкмагансыңдыр ла?

— Кияүнең өйләнергә түгел, хат язарга да вакыты юк. Хәзер инде борын бөтенләй күтәрелер. Шәп яңгырый: заводның баш инженеры! Директорыгыз нindирәк кеше? Ничә яшьләрдә?

— Анысы нигә кирәк булды тагын? Кайчан пенсиягә китәсен беләсең киләме?

— Болай гына соравым.

— Танышканга өч ел узып, синең әле болай гына сорау биргәнең юк иде.

— Ярый, ярый, начальник булуның беренче көненнән үк артык җитдиләнеп китмә әле. Ихтыяр, син ничек уйлыйсың, баш инженерга хатынлыкка ярыйммы икән мин?

— Менә монысы, чыннан да, җитди мәсьәлә. Уйлап карарга кирәк булыр.

— Җыелыш җыеп, тиз генә шул мәсьәләне хәл итегез әле. Юкса ир-атның түземе өч айдан артмый, диләр.

— Шаяртма әле, Зәлия. Болай да баш каткан.— Ихтыярның нигәдер сүзне дәвам иттерәсе килми, Зәлиянең уенчак сүзләре нигәдер аның күңелен үрти иде.— Килергә исәбең юктыр бит? — диде ул, салкын гына.

— Ай-һай нык кыстыйсың син!.. Болай булгач, чыннан да, килмичә булмас. Карале, фатир ягы ничегрәк синең анда? Һаман да шул авылда...

— Ул турыда уйларга вакыт юк! Ярый, сау бул! Таныш-белешләргә сәлам әйт! — дип, коры гына бүлдерде аны Ихтыяр һәм трубканы куйды.

* * *

Әллә инде беренче күрешүдә үк үзен артык өнәмичә, төксе кыяфәт белән каршы алгангамы, әллә болай, вакыты чыкмыйча гынамы, Ихтыяр беренче атнада директор янына зур эше төшмәгәндә кермәскә тырышты. Җыелыш беткәч тә, ул иң алдан торып чыгып китә, юлда очрашканда да рәсми генә исәнләшә. Директорның Ихтыярны өнәмәве, ләкин моны сиздермәскә тырышуы ирексездән йөзенә чыга, ул аны әллә яшерә алмый, әллә инде яшерергә дә теләми иде. Ихтыяр өчен монда әле бар нәрсә дә яңа, шуңа күрә ул күбрәк кешеләрне тыңларга, заводтагы хәл-әхвәлне төпченергә тырышты.

Идарәдә эшләгән чакта ук аңа бетон заводы директорын шактый еш күрергә туры килә иде. Эмиль Яковлевич, ишекне ачып, галәмәт зур күгәрчен кебек гөрләп килеп керүгә, хатын-кызларның йөзе яктырып китә. Керә-керешкә үк ул, үзенең бер балагыннан гадәти кешегә ике костюм тегәрлек чалбарына кулларын сөртә-сөртә, кесәсенә тыгыла да аннан учы белән өстәлгә конфет чыгарып сала.

— Каян алдыгыз бу затлы конфетларны?

— Мәскәүски!

— Хәзер чәй куябыз, Эмиль Яковлевич.

Хатын-кыз, ду кубып, күгәрчен балалары сыман, аның тирәсендә бөтерелә башлый. Ә ул, алтын тешләрен күрсәтеп канәгать елмая да, төрекмән кавынына охшаган зур һәм озынча башын иеп, күрше бүлмәгә кереп китә.

«Кемнең күңелен ничек күрергә икәнен яхшы белә бу,— дип уйлый иде Ихтыяр, һаман тынычлана алмаган хатын-кыз төркеменә карап.— Боларына конфет өләшсә, бүтәннәренең күңелен бүтәнчә таба торгандыр. Әнә, шул бер уч конфет аркасында кызлар үз кулларыннан килгән кадәр бетон заводына игътибарлырак булырга, заводка кагылышлы кәгазьләрне тизрәк үткәреп җибәрергә, мәсьәләләрне тизрәк хәл итәргә тырышалар. Идарә утырышларында да нигәдер Эмиль Яковлевичка каты кагылмыйлар, план үтәлмәгәндә дә күбрәк баш инженерны орышалар яисә ниндидер объектив сәбәп табалар».

Заводта эшли башлагач, Ихтыяр Эмиль Яковлевичның бөтенләй бүтән кеше икәнен, кирәкле кешеләр белән очрашканда, аның ясалма елмаю битлеге кигәнен, үзенә буйсынган белгечләр белән тупас һәм өстән торып сөйләшкәнен күреп аптыраште калды. Ә Ихтыяр белән ул бөтенләй санлашмаска тырыша, мөмкинлек чыккан саен, аны кешеләр алдында уңайсыз хәлгә куярга гына тора иде.

Бүген дә ул Ихтыярның исәнләшүенә баш кагып кына җавап бирде.

— Цехларны өйрәнеп бетергән булсагыз кирәк, килүегезгә атнадан артык вакыт узды,— дип, аңа күтәрелеп карамыйча гына тәмәке көлен кага-кага, сүз башлады директор. Тәрәзәдәге кондиционерданмы, әллә инде директорның үзеннәнме салкынлык бөркелеп тора иде.— Яңа күзгә күп күренергә тиеш... Нинди планнарыгыз, нинди исәпләрегез бар? Эшкә тотынырга вакыт җиткәндер.

— Кешеләр белән таныштым.

— Нәрсә? Җитәкчеләрдән зарланалармы?

— Күбесенең фикере бер — заводка реконструкция ясарга кирәк.

— Тавык кетәгеннән алтынга төрсәң дә, тавык кетәге булып кала,— дип, мыскыллы кыяфәт белән бүлдерде аны директор.— Яңа завод төзергә кирәк безгә, искене ямап вакыт уздырмаска...

— Төзелеш зурая, ә завод һаман шул килеш... Яңасы кайчан була әле? Нигезен дә кора башламаган!

Шулчак телефон шылтырады. Директорның көрәктәй кулында трубка бөтенләй югалып калды. Ул, Ихтыяр кинолардан күреп белгән блиндаждагы командир сыман, карлыккан тавыш белән бар көченә кычкырып җибәрде:

— Ничә тапкыр әйтергә була сезгә? Төнлә бетон булмый. Заводта цемент юк. Бу мәсьәлә буенча миңа түгел, баш инженерга шылтыратыгыз.

Ихтыяр телефонга сузылды, ләкин директор аңа утырырга ымлады һәм трубканы аппарат өстенә куйды.

— Әле генә состав килде,— дип, урынына кире утырды Ихтыяр.

— Егерме вагонмы? Алтмыш икешәр тонналы егерме вагон. Бер куб бетонга өчәр йөз килодан күпме чыга? Тәүлеклек план алты мең куб та, аңа кушып аяк астыннан җыйганны, бункер читләренә ябышып калганын да санасак, егерме вагоның бер тәүлеккә дә җитми безгә.

— Ә цемент шулкадәр дефицитмыни? Күбрәк сорарга кирәк.

— Күбрәк! Күбрәк! Кая барсаң да, шушы сүз. Заводны тәүлек буе туктатмыйча эшләтүнең әйбәт икәнен барысы да белә, бер директор гына белми. Каян җиткерәсең ул тәүлек буе эшләргә кешене? Әллә син аны төзелеш дип белдеңме? Төзелештә генә ул: сәнәк тота белдеңме — өченче разряд, көрәк тә тота белсәң — югары квалификацияле кадровый эшче! Завод бу, энекәшем, завод...

— Шуңа күрә үзгәртеп корырга кирәк тә аны.

— Заводка түгел, сезнең үзегезгә үзгәрергә туры килмәсен!

Урамга чыккач, Ихтыяр сәгатенә карады һәм, берничә көн элек кенә булган вакыйганы искә төшереп, кашларын җыерды.

Эшли башлавына өченчеме, дүртенчеме көн иде, завод ихатасында аңа Сәбилә очрады.

— Нишләп йөрисез бу тузан арасында? — дип шаккатты Ихтыяр.

— Җитәкченең бер көне турында репортаж язмакчы идем. Директорыгызның вакыт ягы бик кысан икән. Әле заводка керергә дә көчкә рөхсәт алдым.

— Репортаж геройларын бүтән җирдән эзләгез,— дип, Сәбиләне тизрәк тузанлы цехтан алып чыгып китәргә тырышты Ихтыяр.

— Мактап язам, дигәнем юк бит әле.

— Алайса, мине эзләп килгәнсез инде. «Ихтыяр Батыршинның бушка узган бер көне». Юк, юк. «Ихтыяр Батыршинның коры хыяллар белән бушка узган гомере». Болай тагын да яхшырак була. Анысы зурракка, повестька ук тарта. Ихтыяр берәүне ярата, ә ул кияүдә. Ихтыярның ярәш-

кән кызы бар. Кыз Ихтыярның үзеннән читләшә башлаганын сизә дә көннәрдән бер көнне асылына... Аптырамагыз, элеккечә бау белән түгел, Ихтыярның муенына асылына.

Сәбилә уңайсызланып кына көлде, Ихтыяр сүзен дәвам итте:

— Ләкин Ихтыяр ныклы карарга килә — ул теге берәү белән булачак. Шул вакыт берәүнең ире Ихтыярның кәләше белән берләшеп заговор оештыралар...

— Өйләнешәләрме?

— Анысын ук белмим, әмма заговор оештырганнарын чамалыйм.

— Юкны сөйләмәгез әле. Гел шулай юк нәрсәләр уйлап йөрсәгез, вакытыгыз бушка узар, билгеле.

— Бүген бушка узмады, сезне күрдем,— дип, һаман шаяртуга борды Ихтыяр.

— Чыннан да, бүгенге көнегез ничек үтте? Шуны сөйләп күрсәтегез әле.

Ихтыяр, җитдиләнеп, бармагын бөгә-бөгә санарга тотынды:

— Идарәдәге һәм заводтагы киңәшмәләрдә — алты сәгать, юлга чама белән сәгать ярым, оештыру мәсьәләләренә — сәгать ярым, объектларда йөрү — ярты сәгать һәм менә... сезнең белән сөйләшеп тору...

— Унбиш минут,— дип бүлдерде Сәбилә.

— Ялгышасыз, егерме минут,— дип төзәтте Ихтыяр.— Шулай итеп, барлыгы тугыз сәгать тә илле минут. Минем эш көне тугыз сум илле тиен торса... Хәзер, хәзер исәпләп чыгарабыз. Баш инженерның төп вазифаларына объектив килеп, эш хакын шуннан чыгып исәпләсәк, миңа чиста көмеш белән бары тик бер сум илле тиенләп акча түләргә тиешләр. Ә мин аны тулысы белән каерып алам, минем тегермән ташы көннең-көн буе диярлек бушка әйләнә.

Берничә көннән район гәзитендә үзенең уйнап кына сөйләшкән сүзләре ташка басылып чыккач, Ихтыяр, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, Сәбиләнең мәкаләсен кат-кат укыды. Заводта район гәзитен алдыручылар сирәк булып, күрми калулары, күреп тә игътибар итмәүләре мөмкин иде. Ләкин директорның бу мәкаләне укымый калуын, аңа тиешле бәя бирмәвен Ихтыяр күз алдына да китермәде. Чөнки ул һәр иртәне иң беренче эш итеп гәзитләрне карап чыга, шуннан соң гына кешеләр кабул итәргә, производство белән шөгыльләнергә тоты-

на. Эмиль Яковлевичның белеп тә белмәгәнгә салынуында астыртын хәйлә күрде ул. Чөнки бу бер Ихтыярның гына эш көне түгел, ә бөтен администрациянең эш көне, бер Ихтыярның гына күп вакытын бушка уздыруына түгел, бөтен заводтагы тәртипкә ишарә иде. Ихтыяр мәкалә турында производство киңәшмәсендә сүз булыр, һич югында, директор чакырып сөйләшер, дип уйлады, ләкин моны кузгатырга җыенган кеше күренмәде. Тора-бара моны Ихтыяр да онытты, көндәлек мәшәкатьләргә чумган көннәр берәм-берәм ага тордылар.

Менә бүген директор белән чәкәләшеп чыкканнан соң, кинәт кенә тагын шул мәкалә исенә төште, һәм күңелендә урнашкан тынычлык тагын әллә кая юкка чыкты. Кинәт ул маңгаена шапылдатып сугып куйды. Бүген Сәбиләнең туган көне бит... Дөрес, Сәбиләнең бу турыда сүз кузгатканы булмады. Нурислам кичә шылтыраткан иде. Бераз кызмача, ахрысы, кәефе күтәренке, тавышы да шактый көр яңгырый. «Сәбилә туган көненә чакырырга кушты»,— дип, сәер итеп көлә башлады ул. «Нигә, үзең чакырмыйсыңмыни?» — дигәч, «Безнең өйдә Сәбилә хуҗа. Аннары, туган көн аныкы бит, минеке түгел»,— дип аклангандай итте. Нишләргә? Барса, Нурисламның көннән-көн авырая барган холкын, кирәккәндә-кирәкмәгәндә дә сүзләренә катлы-катлы мәгънә салып, төрттереп сөйләшүен өнәми. Ә бармый калса, Сәбиләдән уңайсыз. Юк, бүген аның Сәбиләне күрәсе, Сәбиләнең күз нурларында коенасы, борчулардан арынып юанасы, сөенәсе килә!

Ихтыяр завод коймасы буендагы тузанга баткан кара ромашкаларга күз төшерде. Күз күреме җитәр җирдә, басу уртасында сөрмичә калдырылган яшел уйдыкта, зәңгәр кыр чәчәкләре күргәч, Сәбиләнең зәңгәр бизәкләр төшкән яшел күлмәге чагылып киткәндәй булды. Кинәт аңа дөнья гаҗәеп матур, әйләнә-тирәдәге бар нәрсә экиятләрдә генә була торган манзарага охшап калды. Ул, әле офык читендә кызгылт кояш нурларына төренеп утырган авыл өйләренә, әле көнбатыш якта алсу өрфиягә уранган сихри шәһәр йортларына карый-карый, басу өсләтеп зәңгәр чәчәкле яшел уйдыкка таба китте. Берничә адым атлауга, аның ботинкаларына туфрак тулды. Зәңгәр чәчәк утравына җиткәч, ботинкасын салып, балакларын сызганды. Бу минутта ул үзенең кыяфәте белән дә, акылы белән дә хыялый малай чагына әйләнеп кайткан иде.

Кочагы белән зәңгәр чәчәк җыйгач, бер-берсенә бәйләнгән ботинкаларын җилкәсенә салды да җырлый-җырлый кузгалды: «Хуш, авылым, сау бул...»

Фаилдән отып калган бу җыр соңгы айларда аның күңеленнән китми иде.

Тәрәзәләре балкып, кичке эңгер эченнән көлеп торган шәһәргә якынлашкан саен, ул үзенең тәнендә көч арта барганын тоя, ул кемнедер ачуланып кычкыра, аннары шашкан кешедәй көлеп җибәрә: табигатьме, зәңгәр чәчәкләрме, әллә башка берәр хисме бүген аңа канат куйган иде.

Ишекне ачкач, Сәбилә кочагы белән чәчәк күтәргән Ихтыярны танымыйча торды. Чәчәкләрне рәхәтләнеп, күзләрен йомып иснәде.

— Рәхмәт, гомеремдә миңа бу кадәр чәчәк бүләк иткән кеше юк иде әле.

Сәбиләнең күзләре дымланган иде.

— Нурислам өйдә юкмы әллә? — дип сорады Ихтыяр, әле генә үзенең кайда икәнен аңлагандай итеп һәм якягына каранып алды.— Мондый көнне кайда йөри ул?

— Җомга көн соңлый торган гадәте бар аның. Соңгы араларда бик диндарланып китте әле. Берәр җирдә тагын җыелышып намаз укыйлардыр.

— Берәр сюрприз әзерләп йөридер әле туган көнгә.

— Вакыты җиткәч кайтыр.

Сәбилә, Ихтыярга икеләнергә урын калдырмыйча, өстәлгә тәлинкәләр тезә башлады, музыка куйды. Ул тавыш-тынсыз гына кухняга йөзеп кереп китә дә шулай ук сиздермичә генә тагын килеп чыга. Ул гүя атлап йөрми, ә йөзә, өстәл әзерләми, ә күңеленә иң якын бер илаһи эш белән шөгыльләнә иде.

Өйдә Нурислам булмауданмы, Ихтыяр үзен бик уңайсыз хис итә, бер урында элеккечә тыныч кына утырып тора алмый иде. Ул, аптыраганнан, диванда яткан журналларны актарып чыкты, гәзитләргә күз йөгертте, киштәдәге китапларга озаклап карап торды да түр бүлмәдә чыр-чу килгән малай белән кыз янына керде. Ят абыйны күргәч, алар, аптырап, тын калдылар. Ләкин бу уңайсыз тынлык озакка бармады, аксыл чәчле кыз, зәңгәр күзләрен челт-челт йома-йома, Ихтыярга төртеп күрсәтте:

— Ә без сезнең исемне беләбез: Их-ты-яр,— дип сузып әйтте Рәйханә һәм, оялып, абыйсы артына яшеренде.

— Мин дә сезнекен беләм,— дип, идәнгә чүгәләде Их-

тыяр.— Ринат беренчедә укый, Рәйханәгә озакламый биш тула. Шулаймы?

Икесе дә баш селкеделәр.

— Ә минем исемне каян беләсез? — дип кызыксынды Ихтыяр.

— Әни әйтте. Әти белән гел сезнең турында сөйләшә алар. Әни гел мактый сезне. Әтине ачулана да ачулана. Беркөнне әни үз бүлмәсенә кереп елады...

Ринат, боларны сөйләргә ярамаганны белдереп, Рәйханәнең җиңеннән тартты.

— Сез әтинең дусты бит, әйеме? — дип, олыларча сорап куйды ул аннары.

— Әйе. Ә монысын каян белдең?

— Әни әйтте.

Ихтыяр, Ринатның сүзләренә җавап таба алмыйча, елмаеп, аның башыннан сыйпады. Ишектән Сәбилә күренде дә керә-керешкә үк балаларны яратып кына орыша башлады:

— Балалы өйдә сер тормас, дип дөрес әйткәннәр икән. Бөтен серне сөйләп бетерәсез бит инде Ихтыяр абыегызга.— Ул, колак очларына кадәр кызарган йөзен күрсәтмәс өчен, тиз генә балаларга бармак янады.

Ихтыяр балалар бүлмәсеннән чыккач, ризыктан сыгылып торган табынга карап шаккатты.

— Кай арада өлгерттең әле моны? — диде ул, соклануын яшерә алмыйча.

— Табын хәзерләү хатын-кыз өчен эш түгел, бәйрәм бит ул. Өстәл янында кара-каршы утырып сөйләшер кешесе булса, икеләтә бәйрәм. Әйдә, якынрак килеп утыр.

— Хуҗа һаман кайтып җитә алмый әле,— дип, Ихтыяр тәрәзә аша урамга үрелеп карады.— Яңгыр да төшкәләп тора. Өйгә хуҗа булгансың, дип әрләмәсә ярый.— Һәм: — Редакциягә яңа бина сала башладылармы әле? — дип, Сәбиләнең дә хәлен сораштырырга, сүзне аңа күчерергә булды ул.— Бигрәк беткән бит, адәм көлкесе. Редакторыгыз кунак каршы алып, кунак озатудан бушамый. Чибәр хатын-кызны эш башына куйсаң, шул була инде ул.

— Без аны күрмибез дә. Файдасын көткән юк, зыяны тимәгәнгә мең рәхмәт инде.

— Булганга гына шөкер итеп утырсагыз, гомердә дә яңа бина күрмәячәксез.

— Бинасы булыр, оятларына көч килә башлагач, сал-

мыйча хәлләре булмас, анысы өчен артык кайгырган юк. Төзүче булгач, синең өчен бинадан да мөһимрәк нәрсә юк инде, аңлыйм,— дип, исе китмичә сөйләнде Сәбилә.— Журналистның өстәл артында утырып эшләргә вакыты калмый аның. Иртәдән кичкә кадәр бата-чума объекттан объектка чабабыз.

— Язар нәрсә күп инде ул бездә, Нурислам әйтмешли, һәр кеше — үзе бер роман.

— Күбен күп тә, күңел теләгәнне язып кына булмый.

— Нәрсә, өстән кысалармы?

— Төрлесе була инде. Мактап язсаң, болай үзләре яраталар яратуын, үткән-сүткәндә начальниклар да сәлам бирә, бәйрәмнәрдә открыткалар да җибәрәләр хәтта. Ләкин бәләкәй генә бер кимчелекләрен күреп яза башласаң, сырт йоннары кабара. Серкәсе су күтәрми безнең башлыкларның. «Кимчелекне күргәнсең икән, кил дә үзебезгә әйт, чарасын күрербез, хәлне төзәтербез. Нигә өйдәге чүпне урамга чыгарып түгәргә?!» — диләр. Уттан курыккан кебек куркалар инде тәнкыйтьтән.

— Сезнең дә үз проблемаларыгыз бар икән,— диде Ихтыяр.— Ә мин журналистларга читтән генә көнләшеп йөри идем. Нәрсә теләсәләр, шуны язалар, беркемгә дә карап тормыйлар, дип уйлый идем.

— Туктале, Нурислам гына түгел, үзем дә онытып торам бит туган көнне! — Сәбилә урыныннан сикереп торды да, стенадагы мини-барны ачып, шампанский шешәсе алды.

— Нурислам кайтканны көтик...— дип, шешәне өстәлгә куйды Ихтыяр.

— Әллә син аны коры килеш кайтыр дип уйлыйсыңмы?

Ихтыяр тәрәзәгә бәреп яуган яңгырга карады да:

— Әйе шул, коя гына,— дип, сүзне уенга борды.

Яңгыр шавы арасыннан ишектәге кыңгырау авазы ишетелгәндәй булды. Ринат белән Рәйханә бүлмәләреннән атылып чыктылар да ишек янына йөгерделәр.

Ихтыярны күргәч, Нурисламның йөзе сүрәнләнде.

— Сәлам, начальник! — дип, кулын шапылдатып исәнләште, ачы итеп елмайды.

Атлаган саен «иптәш начальник» дип мыскыллаган сыман эндәшүләренә болай да кәефе китеп йөргән Ихтыяр, Нурисламнан да шул сүзләрне ишеткәч, җитмәсә, аның шактый ук кызмача икәнен дә күргәч, кинәт кенә кәефсезләнеп калды, теләр-теләмәс кенә яңадан түргә узып,

диванга утырды. Ваннада Нурисламның шапыр-шопыр юынганы ишетелде.

Киенеп өстәл янына чыкканда, Нурислам инде шактый айныган иде. Ул, өйдә кунак барын әле яңа күргәндәй, йөзе ачылып, шампанский шешәсенә үрелде.

— Сәбилә! — дип, ниндидер ят тавыш белән эндәште ул.— Чык әйдә! Бик беләсең килсә, бүген шәһәр тормышында бик зур вакыйга булды. Бүген синең иреңә тормышында беренче мәртәбә каты шелтә чәпәделәр... Дезорганизация белән шөгыльләнеп, эшчеләр белән җитәкчеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кискенләштерүгә зур өлеш керткәне һәм коллективның рухи ихтыяҗларына объектив бәя бирә алмыйча, бары тик кара якларга гына игътибар иткәне өчен, Нурислам Миңсалих улы Фарукшинга каты кисәтү ясап, шелтә белдерергә, ягъни мәсәлән. Әгәр дә киләчәктә кылган гөнаһларына тиешле нәтиҗә ясап, яхшы якка үзгәрмәсә, эштән азат итү мәсьәләсен күтәрергә... Әмер шундый булды.

Ихтыяр, бу очракта үзен ничек тотарга да белмичә, бер агарды, бер кызарды, аптырап, әле Сәбиләгә, әле Нурисламга карады да бокалын күтәрде.

— Мин Сәбиләнең туган көне өчен тост күтәрәм. Дөньяда кеше туудан да зуррак могҗиза, зуррак бәйрәм юк! Безнең вакытлы уңышсызлыкларыбыз, кәефсезләнүләребез, кеше туу белән, туган көн белән чагыштырганда, бик бәләкәй нәрсә. Сәбилә өчен!

Бокаллар зеңгелдәвенә кушылып, Нурисламның кеткелдәгәне ишетелде.

— Туу белән үлем,— дип, юләр кеше сыман көлде ул,— һәрчак җитәкләшеп йөри. Шатлык белән кайгы, мәхәббәт белән нәфрәт тә шулай ук. Сәбилә белән без дә. Сәбилә шатлык өчен, бәхет, мәхәббәт өчен яратылган, ә мин кешеләргә бары тик кайгы гына китерәм...

— Кирегә сөреп утырма әле,— дип яратып кына ачуланды Сәбилә. Аның Ихтыяр алдында уңайсызланганы күренеп тора иде.

— Ярый, булды, булды, Сәбилә, туган көнең котлы булсын! Гомер буе кайгы синнән читтә йөрсен!

— Һәркемнең кайгысы да, шатлыгы да үзе белән,— дип, Нурисламның ниндидер киная салган сүзләренә каршы төште Ихтыяр.— Гел кайгыдан яисә гел шатлыктан гына торган кеше булмый. Ләкин берәү дә бу турыда урамга чыгып кычкырып йөрми.

— Егетләр! Производство киңәшмәсенә түгел, бәлеш ашарга җыелдык без бүген! — Сәбилә сүзнең кирәкмәс якка кереп китүен теләми, бүген аның бары тик сөенәсе килә иде.

— О-о! — дип, өстәлдәге зур бәллүр вазадагы зәңгәр чәчәкләргә кулын сузды Нурислам.— Кыр чәчәкләре! Романтика... Синең эшме, Ихтыяр? Хәтерлисеңме, Сәбилә, туй мәҗлесе көнне мин сине кыр чәчәкләренә күмгән идем.

— Беренчесе дә, соңгысы да шул булды. Чәчәкләргә исең китми бит синең,— диде аңа Сәбилә.— Мин Ихтыярның уңышлары өчен тост тәкъдим итәргә җыенган идем...— Сәбилә Нурисламга күз ташлады да, аның йөзендәге салкынлыкны күреп, бокалга үрелгән кулын кире тартып алды.

— Ихтыярны кызык иттеләр,— дип кеткелдәде Нурислам.— Азрак кына башын күтәрә, күкрәген киерә башлаган иде, тоттылар да цемент чокырына ыргыттылар. Әгәр дә шунда тончыгып үлмәсә, тынычлангач, бәлки, якты дөньяга да чыгарырлар үзен. Түземлекләре өчен, бигрәк тә өстәгеләргә комачау итмәве өчен, күкрәгенә берәр значок-мазар да тагып куярлар. Ләкин зур эшләр майтару өчен теләсә кемнең якасына ябышырга торган егетебез ул чакта тәүфыйклы песигә әйләнеп калган булыр. Әйдәгез, Ихтыяр өчен күтәрик әле!

Нурислам бокалны каплап куйды. Сәбилә белән Ихтыяр иреннәрен генә тидерделәр.

Ихтыяр йөрәге ярсуын, күңел түрендә ачу кайнавын сизсә дә, Нурисламга күтәрелеп бәрелүдән тыелды. Ул аның ни өчен өзгәләнгәнен аңлый, шуңа күрә дорфалыкларын да кичерә, бүтән җирдә булса, башкачарак та сөйләшкән булыр иде, ә Сәбилә алдында, аның туган көнендә тавыш чыгарасы килми.

— Тагын шул баш инженер белән бәхәскә кердеңме? — дип, Нурисламга кызганып карады Сәбилә.

— Бәхәскә кереп тормадым, үземнең фикерләр белән генә уртаклаштым. Әйтмичә түзәрлек тә түгел: бөтен төзелешкә — кара мунча хәтле кирпеч заводы. Бетон җитми, плитәләр җитми, измә җитми, юллар юк, квартир кытлыгы турында әйтеп тә тормыйм. Шундый шартларда коллективта нинди тәртип, нинди мораль климат урнашсын ди? Нәрсә белән кызыктыра алабыз соң без халыкны? Акча беләнме? Акча — зур стимул, ләкин акчага

күбрәк өлкәннәр хирыс. Яшьләргә күбрәк нәрсә кирәк? Яшьләргә кызык дөнья кирәк. Әгәр дә эшләгән эшенең нәтиҗәсен үз күзләре белән күрмәсә, алда перспектива тоймаса, аркан белән дә бәйләп тота алмыйсың аларны төзелештә.

— Фикерләрең, бик үк яңа булмаса да, дөрес,— дип, тәлинкәләргә аш бүлә-бүлә, сүзне ялгап китте Сәбилә.— Ләкин аларны нигә урам буйлап кычкырып йөрергә? Кандидатскиеңны яз, якла. Аннан соң синең белән исәпләшә башларлар. Ә болай бармак белән басып сытарлар, үзең дә сизмәссең.

Ихтыяр, әле Сәбиләгә, әле Нурисламга карап, сүзгә кушылырга кыймыйча уңайсызланып утырды. Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Ул бүгенге күңелсез сөйләшүнең сәбәпчесе итеп үзен, үзенең менә шулай кинәттән килеп керүен санап, тизрәк моннан чыгып китәргә җай эзли башлаган иде. Ләкин Сәбилә моны сизмәде, турсаеп утырган Нурисламга:

— Тотасың да шул баш инженерга барып каныгасың,— диде.— Кем белән нәрсә сөйләшергә икәнне белергә вакыт. Ул сиңа баш архитектор яисә идарә начальнигы ише генә түгел. Алары — конкрет эш кешесе. Эш кешесе эш кешесен ничек тә аңлый ул, ялгышларын да кичерә. Сезнең ул Шамкаевыгызның үз фикере, үз инициативасы юк — бөтен бәла шунда. Кеше эшләгәнне папкага теркәп, сводка чыгарып утыра. Производство белән бөтенләй шөгыльләнми, шөгыльләнергә дә теләми.

— Болары һәммәбезгә дә билгеле...— Ихтыярның түземе бетә башлаган, аның тизрәк бу әңгәмәгә чик куеп, сүзне күңеллерәк темага күчерәсе килә иде.— Барыбыз да беләбез, ә авыз күтәреп турысын әйткән кеше юк. Сәбилә ханым, нигә боларның барысын да нигезләп, үзенең алтын каләме белән гәзиткә язып чыкмый? Бәлки, шуннан соң дөнья үзгәрер иде.

— Теге вакытта язган идем, ничек, Батыршинның бер көне үзгәрдеме шуннан соң?

— Сезгә сүз әйтүе дә куркыныч, язасыз да бастырып чыгарасыз.

Нурислам Ихтыярга күтәрелеп карады, нишләргә белмәгәннән, шешәгә үрелде, аны тагын кире куйды.

Туган көн мәҗлесендә сүзнең Сәбилә тирәсендә йөрмичә, күбрәк эш турында, производство хакында баруы шулкадәр урынсыз, кирәксез иде, әйтерсең алар нинди-

дер олы серләрен ачарга курыккандай, юри аны читләтеп йөриләр, телгә иң беренче килгән, иң өстә яткан сүзләрне сөйләшәләр. Бәлки егетләр икәве генә булса, инде күптән онытылып әллә кайларга кереп китәрләр иде. Ләкин Сәбилә аларны күренмәс җепләр белән урыннарына бәйләп куйган да үзе теләгәнчә хәрәкәтләндерә, үзе теләгәнчә сөйләштерә, үзе теләгәнчә хисләндерә.

— Кулымнан килсә, төзелештәге бөтен администрацияне яңадан җыяр идем. Безнең бетон заводын гына кара, ун кешегә бригадир булып та эшли алмастай егетләргә йөзәр кешелек цехларны ышанып тапшырганнар...

— Ышаныч — иң зур стимул,— дип өстәде Нурислам.— Менә синең үзеңне дә, эшли башламас борын, баш инженер ясадылар. Җитәкче булу өчен аерым талант кирәк, анысын беләм. Ә талантлылар җитмәсә нишләргә? Кадрлар мобиль булырга тиеш. Аларны төрле җирдә сынап карарга кирәк. Бәлки, аның күңеле монда түгел, тегендә ята төшәдер. Бәлки, ул бүтән шартларда ачылып китәр?

— Безнең җитәкчеләр арасында шундый когорта урнашып килә,— дип, кухнядан тәлинкәләр күтәреп чыккан Сәбилә сүзгә кушылып китте.— Эштән дә куып чыгарып булмый аларны, үзләрен эшләтеп тә булмый. Киресенчә, андыйларга ничек тә эш кушмаска тырышалар. Чөнки эшләгән эшенең барыбер рәте булмый, бөтен нәрсәне бутап кына бетерә ул. Безнең редактор шикелле. Ул да йөри бит әнә тәти уенчык булып, бар кешегә елмаеп. Эшләмәгәч, ялгышмый да. Җитмәсә, эшләгән кешеләрнең вак-төяк ялгышларыннан үзенә рухи капитал җыя. Андый кешеләр белән көрәшү — мәгънәсез. Андыйлардан сак булырга кирәк.

— Нурислам дөрес эшли. Андыйларның көенә җайлашып йөри башласаң, баскан урыныңнан бер адым да алга китә алмаячаксың. Сазлык, баткаклык...— дип йөзен чытты Ихтыяр.— Андыйларны төбе-тамыры белән себереп түгәргә генә кала!

— Кизәнүен каты кизәнәсең,— дип мыскыллы караш ташлады Нурислам.— Тик сугуың гына ничек булыр? Кесәдә йодрык үстереп йөрүчеләр күп бездә.— Һәм ул, кинәт кенә дустанә тонга күчеп, кулын Ихтыярның җилкәсенә салды.— Заводта хәлләр ничек соң? Акаеп карама әле. Чынлап әйтәм, хәлләрең шәптән үк түгелдер...

— Урамга чыгып каравыл кычкырырлык та түгел.

Иялəшеп килəм бугай инде əкренлəп. Əйе, хəллəр шəптəн түгел, лəкин балавыз сыгарга да җыенмыйм. Шəһəр төзү идарəсен производство берлəшмəсе итеп зурайтырга, үзгəртеп корырга уйлыйлар бит, үзең белəсең. Менə шул форсаттан файдаланып, заводка тулысынча реконструкция ясарга иде. Директор теше-тырнагы белəн каршы. Райком белəн киңəштек, министрлыкта да каршы килмəслəр дип уйлыйм. Бер ишектəн борып чыгарсалар, икенчесенə керербез, туры юлны япсалар, əйлəнеп үтəрбез.

— Зурдан купкансың син, егет. Һəм дөрес эшлисең! Заводка башаяк кереп чумдым, дисең, алайса.— Нурислам, ияге белəн учына таянып, шактый ара уйчан торды, аннары башын күтəрде.— Ə Ташлыярны нишлəтəсең? Аны кемгə калдырасың? Шамкаев этлəренə талатыргамы?

— Теге вакытта архитектура бүлегендəге таныш егетлəр белəн сөйлəштем, дигəн идем бит. Алар кич калып та эшлилəр, шимбə-якшəмбедə дə килəлəр. Мин дə көн аралаш кереп йөрим... Телисеңме, иртəгə бергə барабыз? Егетлəр яшь, идея кирəк аларга, кыю фикер кирəк... Мин үземнекелəрне өлəшеп бетердем бугай инде. Синең баш энциклопедия кебек бит.

...Утыра торгач, вакыт узганы сизелмəгəн, сəгать төнге икене сукканны ишеткəч, Ихтыяр сискəнеп куйды да урыныннан торып китəргə җыена башлады.

— Беркая да китү юк,— дип кырт кисте аны Нурислам.— Соңгы арада əллə ничə егетне тотып тəпəлəделəр. Беркөнне минем каршыга да чыкканнар иде, дружиначылар гына коткарып калды. Иртəгə иртəн архитекторлар янына бергə барырбыз.

— Өйдəгелəр көтəдер...

— Елап утырган балаң, ажгырып торган хатының юк. Кайда барсаң, шунда — үз өең.

Ихтыярны залдагы диванга яткыргач, утны сүндерделəр.

Нурислам, моңа кадəр булмаганча назлы итеп, Сəбилəне биленнəн кочты, чəчлəреннəн сыйпады һəм, күрəсеңме дигəндəй, култыклап йокы бүлмəсенə алып кереп китте.

Ихтыяр бик озак йокыга китə алмыйча ятты. Нигəдер аңа бүген бүлмəнең һавасы сулап булмас дəрəҗəдə авыр тоелды. Аптырагач, балконга да чыгып керде, киштəдəге китапларны да санап карады, əмма күңеле, урынына утыра алмыйча, торган саен тынгысызлана гына

бара иде. Күрше бүлмәдә Нурисламның өзлексез чыш-пыш килүе, Сәбиләнең вакыт-вакыт әкрен генә көлеп куюы колагын кытыклый, күңелен кымырҗыта иде. Ул, монда калуына мең дә беренче тапкыр үкенеп, тешләрен шыгырдатты, бер нәрсә дә ишетмәс өчен, юрганын баштанаяк бөркәнеп ятты.

* * *

Соңгы арада Ихтыяр бөтенләе белән завод мәшәкатьләренә кереп чумды. Ул иртәнге җидедән үк заводка килеп җитә, караңгы төшкәч кенә кайтыр юлга чыга. Моңарчы тыныч кына йөргән салмак холыклы егетне әйтерсең алыштырып куйдылар: Ихтыяр әле берсе белән кызып-кызып бәхәсләшә, икенчесен әрли, өченчесен күккә чөеп мактый, кемгәдер нәрсәдер исбат итә, кыскасы, үз сүзен сүз итмичә туктамый иде. Директор еш кына хастаханәдә ятканлыктан, бөтен эш аның өстенә төшә. Идарәгә дә, райкомга да ул чаба. Казанына, Мәскәвенә дә ул бара. Хәзер инде аны бөтен җирдә дә беләләр. Ул институтта укыганда ук партиягә кергән иде, монда парткомга сайлап куйдылар. Ихтыярның эше алга киткәнен, үзенең дә ныгып, төпле җитәкче булып өлгереп килгәнен тоеп, дәртләндереп торучылар шактый күренсә дә, көнләшеп, тәгәрмәчкә таяк тыгарга җай гына көтеп йөрүчеләр дә юк түгел иде.

Инде берничә ел буе Нурисламның канына тоз салган Шамкаев Ихтыярны да үз җәтмәсенә эләктерергә тырышып карады. Шәһәр төзү идарәсе производство берләшмәсе итеп зурайтылгач, масштаблар бермә-бер артты, йортлар төзү комбинаты оештырылды. Баштарак төрле сүзләр, имеш-мимешләр йөрсә дә, көне килеп җиткәч, Шамкаев бернинди гаугасыз-нисез шул комбинатның баш инженеры булып эшли башлады. Бетон заводы шушы комбинат карамагына кергәнлектән, Ихтыяр турыдан-туры Шамкаевка буйсына иде.

Заводны реконструкцияләү чорында продукция бирү күзгә күренеп кимеде. Көзге яңгырлар башланганчы эшне төгәлләү өчен, сменадан соң калулар ешая барды. Ихтыяр бригадирлар белән киңәшә дә, аларның ризалыгын алгач, бу турыда өстәге башлыкларга хәбәр итеп тә тормый иде. Шамкаев моны каяндыр белеп алган. Администрация белән партком бергә җыелышып, ике сәгать

буе Шамкаев куйган мәсьәләне тикшерделәр. Вакытлыча директор вазифаларын башкаручы баш инженерның «башбаштаклык белән шөгыльләнүе, үз белдеге белән тулы бер цехны эштән туктатуы һәм эшчеләрне сменадан соң калырга мәҗбүр итүе» турында Шамкаев төкерек чәчә-чәчә сөйләсә дә, аны күтәреп алучы булмады. Нәтиҗәдә «Бетон заводы эшенә контрольне көчәйтергә» дигән карар чыгарып таралыштылар.

Ләкин Шамкаевның моның белән генә тынычланмасын, туктап калмасын Ихтыяр белә иде. Күңеле дөрес сизенгән икән, икенче көнне ул аны үзен генә чакыртты. Берни булмагандай елмаеп каршы алды, шактый борычлы яңа мәзәк сөйләп көлде, аннары гына төп сүзгә күчте.

— Ихтыяр Тимерханович,— дип, рәсми төстә башлады ул,— кичәге җыелыштан тиешле нәтиҗә ясагансыздырмы-юктырмы, белмим, әмма сезнең язмыш мине, төзелеш ветераны буларак та, дөнья күргән кеше күзлегеннән караганда да, шактый нык борчый. Кичәге җыелыш та нәкъ менә шул максаттан чыгып үткәрелгән иде. Күргәнегезчә, сезгә беребез дә каты кагылмады, бары тик олыларча киңәшләр генә бирдек, мәсьәләгә ачыклык кына керттек. Ә теләгән булсам, зурга да җибәрергә мөмкин иде бит бу эшне. Әйе, сез энергияле, шактый төпле белемле, оештыру сәләтенә ия булган перспективалы белгечләрдән саналасыз хәзер. Ләкин болар барысы да якынча һәм абстракт төшенчәләр. Нигә шундый сез? Җавабы бик гади: чөнки без шулай саныйбыз, бүтәннәргә дә шулай дип әйтәбез. Идарә утырышында яисә райком киңәшмәсендә конкрет фактларга нигезләнеп бер тәнкыйть итеп чыгу җитә, һәм сез икенче көнне үк гап-гади бер эш атына әйләнеп каласыз. Әйткәнемчә, әлегә сез перспективалы белгечләрдән саналасыз.— Ул «әлегә» сүзенә аеруча басым ясап, шул төштә бармагын күтәреп әйтте.— Ләкин үзегездәге уңай сыйфатларга дөрес юнәлеш бирә белмәвегез аркасында, артык еш ялгышасыз, һәм киләчәктә бу ялгышлар сезнең башыгызга тимер таяк булып килеп төшәчәк.

Ихтыяр аны керфек тә какмыйча тыңлап утырды.

— Сезнең төп ялгышыгыз өч көнлек план, өч көнлек фәлсәфә белән яшәвегездә,— дип дәвам итте Шамкаев.— Алдан күрүчәнлек, еракка карый белү җитми сезгә.

«Бу инде берләшмә башлыгы да, Фаил дә түгел, «син» белән «сез»не бутамый» дип уйлады Ихтыяр.

Баш инженер аталарча кайгырткан кыяфәттә һаман сөйли иде:

— Аңлыйм, хәлегезне дә, теләгегезне дә яхшы аңлыйм. Йөз метр араны тизрәк узып, финишка беренче җитәсегез, медаль аласыгыз килә сезнең. Яшь чакта үзем дә шундый идем. Тора-бара өйрәндем, медальсез яшәргә дә күнектем. Без эшлибез, бүтәннәр рәхәтен күрә. Әмма болар барысы да вакытлы тәтиләр генә. Тормыш спорт түгел, аңа йөз метрга йөгерүчеләр кирәкми. Тормыш итү, яшәү — марафонга йөгерү ул, гомер буе йөгерү. Ә сез, болай барсагыз, озакламый янып егылачаксыз.

— Ялкау алаша кебек гомереңбуе терек-терек барганчы, сабан туе аргамагы сыман беренче килеп, янып егылуың яхшырак түгелме?

— Бик беркатлы фикер йөртәсез, иптәш Батыршин! Батырлык белән әтәчлекне аера белергә вакыт инде сезгә! Комбинатның таләбе шул: иртәгәдән үк завод планда каралган продукцияне йөз проценты белән чыгара башларга тиеш!

— Реаль булмаган таләпләрне үтәргә вәгъдә бирә алмыйм.

— Ул очракта парткомда сезнең персональ эшне куячакбыз! Сезнең аркада без төзелешне туктатып тора алмыйбыз. Сезгә дан өчен завод реконструкцияләү, әтиегез өчен җимерелергә торган Ташлыяр авылы кирәк булса, безгә йортлар кирәк, безгә таш шәһәр кирәк! Аңладыгызмы, шәһәр кирәк! Завод кирәк!

— Заводны реконструкцияләү миңа түгел, шәһәргә кирәк. Ташлыярга да юкка каныгасыз. Иң авыр чакта ничә йөз эшчене кем үз куенына сыендырды? Ташлыяр. Үлгән кешеләрне әле һаман кая күмәбез? Ташлыяр зиратына. Продуктлар белән шәһәрне кем тәэмин итә? «Уңыш» колхозы, шул ук Ташлыяр кешеләре.

— Бездән Ташлыяр турында сорамыйлар, план сорыйлар, торак йорт сорыйлар!

— Әллә сез шәһәрне торак йортлардан гына гыйбарәт дип уйлыйсызмы? Археологлар борынгы шәһәрләрне эзләгәндә, иң элек нәрсәгә игътибар итәләр? Чүлмәк ватыкларына, каберлекләргә. Без монда чүлмәкне күп ваттык ватуын, күршеләрдән бурычка алган чүлмәкне. Инде ничә ел буе күршеләрдән плитә, субай ташыйбыз. Үзебездә эшләп булмый идемени аларны? Төзелеш башланганда ук боларның барысын да искә алган булсагыз, хәзер заводны реконструкцияләп торыр идекме?

— Авызыгызда сөт кипмәгән килеш, акыл өйрәтеп утырасыз! — дип кычкырды Шамкаев.— Бала-чаганы эш башына утыртсаң, шул булыр инде ул.— Ул, кызып киткәнен чамалап, тавышын йомшарта төште.— Мин археолог түгел, төзүче, һәм шуңа күрә иң элек төзелеш турында уйларга тиешмен. Аннары... үләргә җыенып торган кеше күренми әле монда, барысы да теше-тырнагы белән яшәргә тырыша. Үлә-нитә калсак, урын табылыр. Ә хәзергә зират турында уйлап утырырга вакыт юк, алга барырга кирәк. Поезд көтми.

— Шуңа күрә поездда яшәгән сыман яшибез дә. Ярты шәһәр вагоннардан гыйбарәт. Кая барып җитәрбез болай булса, шунысы гына билгеле түгел.

— Шуңа күрә дә иртәгәдән йөз процент план булырга тиеш, аңлашылдымы? Поезддан төшеп, шәһәрдә яши башлау өчен.

— Бүгенге темп белән эшләсәк, сентябрьгә реконструкцияне төгәллибез.— Ихтыяр һаман баш инженерны ышандырырга тырыша иде.— Аннары продукция бирү өч тапкырга артачак. Күршеләргә йөз ертып барулар да кимиячәк, күпме машина бушаячак. Әгәр көзгә кадәр өлгермәсәк, яңгырлар, суыклар башлангач, тагын өстәмә кыенлыклар килеп чыгачак. Аннары язга кадәр сузылачак ул.

— Теләсә нәрсә эшләгез, ләкин квартал планын өзәргә беркемнең дә хакы юк! Бер Батыршинның сүзе — сүз, эше эш булсын, дип, меңләгән кешене премиясез калдыра алмыйбыз.

Ихтыяр урыныннан сикереп диярлек торды да, саубуллашмыйча, кабинеттан чыгып китте.

Урамда кояш нурларыннан күзләр чагыла, тирә-юнь рәшә дулкынында тирбәлә иде. Ул шактый вакыт, тәгаен бер карарга килә алмыйча, кая барырга белмичә, урам читендә таптанып торды. Аннары сәгатенә карап алды да олы-олы адымнар белән, әтисе кебек ике кулын артка куеп, райком бинасына таба атлады.

Райкомның төзелеш бүлеге мөдире аны игътибар белән тыңлады. «Мәсьәлә, чыннан да, катлаулы икән»,— дип, кат-кат башын селкеде дә, бераз көтеп торырга кушып, кабинеттан чыкты. Ун минуттан ул кабаланып керде һәм, каушаган тавыш белән ярым пышылдап:

— Сезне Беренче чакыра,— диде.

Ихтыяр,ниләр сөйләргә, сүзне нидән башларга белмичә, борчыла-борчыла, баскычтан икенче катка күтә-

релде. «Иң элек заводтагы обстановканы аңлатам, бүгенге хәлен һәм перспективасын сөйлим, аннары конфликтларга күчәм»,— дип уйлады ул һәм кара күн белән тышланган калын ишекне сак кына ачты.

— Кәефләр ничек? Кайда торасың? — дип сорау бирүдән башлады беренче секретарь сүзен.

— Әйбәт. Хәзергә әтиләр белән яшим, Ташлыярда.

— Ә-ә, әйе, син Ташлыяр кешесе бит әле, бу якларның хуҗасы. Туйны кайчан ясыйбыз соң?

— Анысы миннән генә тормый,— дип, Ихтыяр бурлаттай кызарды.

Беренче, кәнәфигә аркасын терәп, хәйләкәр елмайды.

— Кемнән тора соң? Без сиңа ничәмә йөз кеше эшли торган заводны ышанып тапшырдык, әтиләре бер бөртек кызларын бирергә дә икеләнәме? Бирмәсәләр, каерып алырга кирәк! Шамкаев булып Шамкаевка баш бирмәгәнне, яраткан кызыңны үз яныңа килергә күндерә алмыйсыңмы? Килсен, аңа да эш табарбыз.

Туп кебек түгәрәк һәм җитез гәүдәле, ачуланып сөйләшкәндә дә иреннәннән елмаю китми торган якты йөзле, тере күзле бу кеше аның бар фикерләрен, уй-хыялларын да белеп торадыр кебек. Ихтыяр кабинеттагы бер нәрсәне дә күрми, бары тик Рим Идиятовичны гына тыңлый, аны гына күрә иде.

— Заводны реконструкцияләп бетергәч, туеңа чакырасың! Килештекме?

— Шамкаев мине тиз генә өйләндерергә уйламый әле...

— Йөксез ат ыграк чапканны белә ул,— дип, тагын балкып елмайды Рим Идиятович һәм сиздермичә генә төп темага күчте: — Соңгы айда планны ничә процентка үтәдегез?

— Алтмыш бер...

— Бу айда күпме булыр?

— Илле-алтмыш тирәсе...

— Димәк, төзүчеләр юкка чаң сукмый. Димәк, план кычкырып яна, дигән сүз. Болай эшләсәк, озакламый завод белән шәһәрне сугыштыра башлыйбыз. Китүчеләр армиясе дә ишәячәк. Реконструкцияне кайчан тәмамларга уйлыйсыз?

— Бер айдан, иң күбе — ай ярымнан... Сентябрьдә. Билгеле, әгәр дә бүгенге темп белән эшләсәк һәм комачаулаучы булмаса.

— Комачау итүчеләр булыр. Аларны җиңә белергә ки-

рәк. Бер нәрсәне дә тәлинкәгә салып китереп бирмиләр. Аңлат, ышандыр!

Ихтыяр Беренче янына нигә кергәненә үкенә башлады, «Кая барсаң да, шул бер сүз,— дип уйлады ул.— Бөтенесе дә кайгырта, бөтенесе дә синең кәеф белән, язмыш белән кызыксына, конкрет ярдәм күрсәткән кеше генә юк».

— Стенага китереп терәдең. Идарәне дә, заводны да. Нишләргә? Ничек бу хәлдән котылырга? — Рим Идиятович, пеләшен кулъяулыгы белән сыпыра-сыпыра, кабинет буйлап йөри. Менә ул барган җирдән кинәт кенә туктады да уң кулын югары күтәрде.— Димәк, бүгенге көндә ике төзелеш оешмасы, заводка реконструкция ясалганны көтеп, сырт кыздыра. Болай булмый. Булмый!

— Реконструкция беткәч, эш күләме күзгә күренеп артачак.

— Беткәч, артыр артуын. Ә менә хәзер нишләп тик ята алар?

— Тик ятмасыннар. Безнең заводка килсеннәр. Бездә эш җитәрлек,— диде Ихтыяр һәм, Беренченең җавабын көтеп, тын калды.

— Монда нидер бар. Үзем дә, шулай уйлап, икеләнебрәк тора идем. Димәк, синең фикер дә шундый. Ә түләү мәсьәләсен ничек хәл итәсез?

— Анысын килешербез. Ләкин моның белән генә тупиктан чыга алмыйбыз. Төзелешне бөтенләй туктатырга ярамый, кешеләр фатир көтә, завод нигезенә субайлар кирәк.

— Ике көймәнең койрыгын берьюлы тотмакчы буласың инде. Хәйләкәр, болай барсаң, атаңнан да уздырырсың. Төзелеш тә туктамасын, заводка реконструкция дә ясалсын, җитмәсә, өстәмә көчләр дә ярдәмгә килсен. Әйбәт, әйбәт! — дип, өстәл артына кереп утырды Беренче.— Тәртәне оста каерасың.

— Бетон заводы — төзелешнең йөрәге бит ул, аннан башка беркая барып булмый.

— Яшьлекнең ялгышы да, көче дә шундадыр инде. Бары тик яшьләр эшләгән эш кенә мөһим, бары тик алар гына дөнья кендеге! — Беренченең сүзләрендә кайгырту да, шелтәгә охшаш киная дә бар иде.— Ә бүтәннәр вак-төяк белән шөгыльләнә, алар көтеп торса да ярый. Үз-үзеңне хөрмәт итү, үз эшеңне ярату — яхшы нәрсә, әмма күршеләрне дә онытырга ярамый. Тирә-юнен хәерче баскан байның беркайчан да мантымаганын беләсеңме син? Иртәме-соңмы шул хәерчелек аңа да йога. Чөн-

ки тегеләр моны куралмый башлый, аяк чала, тегендә-монда йолыккаларга гына тора. Үзеңне яратырга, күршеләрне хөрмәт итәргә кирәк, ди торган иде бер кеше.— Рим Идиятович җиңел хәрәкәт белән кызыл телефон трубкасын күтәрде.— Сеңелем, тиз генә күршеләрне тоташтыр әле,— диде ул һәм шунда ук Ихтыярга сорау бирде: — Сентябрь — реаль срокмы?

— Әшкә аяк чалмасалар, реаль.

— Һаман шул сүз. Шамкаевны әйтәсеңме? Ул да үзенчә хаклы. Аңа план кирәк. Без аңардан таләп итәбез, ә ул — сездән. Ләкин коры таләп итү генә аз, бергәләп хәл итәргә кирәк проблемаларны. Ал-ло, ал-ло! — Ул, каршысына иң якын кешесе килеп баскандай, телефон трубкасына елмайды.— Исмәгыйль Гәрәевичмы? Хәлләрегез ничек? Безнең дә түзәрлек. Ләкин түземнең чиге була бит. Безнең хәлне тагын да яхшырту өчен, сезнең ярдәм кирәк. Әйе, әйе, көймә комга терәлде. Бетон заводын яңартабыз. Күптән кул җитми тора иде. Төзелеш туктады. Субайлар җитми. План кычкырып яна! Беләм, үзегезнең хәлләрнең дә җиңелдән түгел икәнен беләм, ләкин безнеке архикатлаулы. Безгә әле бергә яшисе. Йомышыгыз төшкәндә, сезне дә борып җибәрмәбез. Бер айга гына. Сентябрьдә өлгертәбез. Ярый, алайса, иртәгә баш инженер Батыршинны җибәрәбез. Директор больницада. Авыртмаган җире юк аның... Рәхмәт сезгә, коткардыгыз.

Трубканы куюга, Беренче, җиңел сулап, Ихтыярга карады. Ул елмая иде.

— Аңлашылдымы? Иртәгә иртүк күршеләргә барасың, үзеңә кирәкне алмыйча кайтма. Калганы синнән тора.

Кабул итү бүлмәсендә утыручылар, Ихтыярның тир бәргән алсу йөзенә, колак читләренә кадәр ерылган авызына карап, сәерсенеп пышылдаша калдылар, ул абынасөртенә коридорга чыкты да хәлсезләнеп тәрәзә яңагына барып сөялде.

Әле генә төрлесе төрле якта тәртипсез чәчелешеп яткан йортлар хәзер аңа кул сузымы җитәрлек арада якынайганнар да, бергә җыелып, тирәсендә әйлән-бәйлән уйныйлар кебек тоелды. Ул аяк астыннан шуышырга маташкан җиргә ныграк басарга тырышып атлый, каядыр барырга, кемгәдер шатлыгын сөйләргә ашыга, аның күңеле ашкына, аның бар хисләре урыныннан купкан иде.

Ихтыяр, тынычланырга тырышып, елга буена төште, чүгәләп битен юды, су коенырга уйлаган иде, нидер исе-

нә килде, ахрысы, дулкын ярып барган «Метеор»ны күзеннән уздырып җибәрде дә ашыга-ашыга идарәгә таба китте.

Шамкаев аның ишек шакып та тормыйча, атыла-бәрелә килеп керүенә гаҗәпләнмәде, башын күтәреп, урындыкка күрсәтте.

— Август ае өчен төзелешкә нинди материаллар һәм күпме кирәк булачак? — дип, рәсми тон белән сүз башлады Ихтыяр.

Шамкаевның йөзе үзгәрмәде, хәрәкәтләре дә һәрвакыттагыча салмак һәм илтифатсыз иде.

— Менә монда барысы да язылган,— диде ул.— Артыгын сорамыйбыз.

— Мин иртәгә күршеләргә барам.

— Беләм,— диде башын күтәрмичә генә Шамкаев.— Яхшы хәбәр тиз йөри бездә. Күршедән хәер сорарга калдык. Ярый, сезнеңчә булсын.

Бу сүзләрне ул теш арасыннан сыгып, зәһәрен кушып әйтте, үзенчә эшли алмавына, шушы ять-яшь егетнең өстен чыгуына җаны әрни, кимсетелгән горурлыгы күңелен талкый иде аның.

* * *

Иртән эшкә килүгә, кабул итү бүлмәсендә иңнәренә фотоаппаратлар, кинокамералар, төрле сумкалар аскан кешеләрне күргәч, Ихтыяр уңайсызланып калды. Кичә аңа республика телевидениесеннән корреспондентлар киләсен хәбәр иткәннәр иде. Ул ризалык бирмәде, әлегә мактанырлык нәрсә юк, дип, трубканы куйган иде.

— Килгәнсез икән, керегез,— дип, ишекне киереп ачты ул.— Узыгыз.

Күн пинҗәк кигән ике ир, өстәлнең як-ягына утырып, сүзсез генә сумкаларын ачтылар, аппаратларын көйли, яктырткычларын куя башладылар.

— Телсезләр өчен тапшыру әзерләмисездер бит? — диде Ихтыяр һәм, тегеләрнең җавап кайтармауларын күргәч, бер читтә уңайсызланып басып торган кызга күз ташлады. Сабыйлык чыгып бетмәгән йөзенә, нидән сүз башларга белмичә, күлмәк төймәсен боргалап торуына караганда, ул телевидениедән түгел, күршедән йомыш белән кергәнгә охшабрак тора иде.

Ниһаять, кыз телгә килде.

— Сезнең заводның бүгенгесе һәм киләчәге турында тапшыру эшләргә уйлыйбыз,— дип оялып кына сүз башлады ул.— Бүген түгел, бүген интервью гына алабыз. Безнеңчә әйткәндә, пробная съемка була. Разведка.

— Разведкага батырларны гына җибәрәләр,— дип, өстәл артына барып утырды Ихтыяр.

— Бу әле минем беренче тапшыруым. Гаҗәпләнмәгез, зинһар.

Ихтыярга кыен булып китте, ул, ияге белән учына таянып, кызыксынып карады.

— Без сезгә сораулар бирербез, дөресрәге, мин сорау бирермен, сез завод турында сөйләрсез. Әзерме? — дип, күн пинжәклеләргә карады кыз.— Әзер булсагыз, башлыйбыз. Иптәш...— Ул иелеп, уч төбендәге кәгазьгә карады.— Иптәш Батыршин, сез заводның директоры буларак...

— ...баш инженеры буларак,— дип төзәтте аны Ихтыяр.

— Иптәш Батыршин, сез заводның баш инженеры буларак,— дип яңадан башлады хәбәрче,— үзегезнең төп вазифагызны нәрсәдә күрәсез?

Ихтыяр уйланып та тормады, ятлаган текстны сөйләгән кебек, тиз-тиз генә тезеп китте:

— Исәнмесез, хөрмәтле тамашачылар! Бетон заводыннан тапшыруыбызны башлыйбыз...

— Ә-әй, бөтенләй истән чыккан, боларын мин әйтергә тиеш идем,— дип уңайсызланды кыз.

Кыз соравын кабатлады. Ихтыяр, инициативаны үз кулына алмаса, болардан көне буе котыла алмасын аңлап, җитдиләнгән иде.

— Теләсә кайсы предприятие, завод өчен иң мөһиме — коллектив, аның кешеләре. Коллективны оештыра белү, һәркемнең нәрсәгә сәләтле икәнен ачыклау — мин үземнең төп бурычымны шулай аңлыйм.

— Сезнең заводта реконструкция эшләре бара. Сез җиһазларны гына яңартырга уйлыйсызмы, әллә коллективны да яңабаштан җыярга исәплисезме? Яңа техника белгечләрдән өстәмә белем, эшкә яңача караш, яңа психология таләп итәчәк. Бу проблеманы ничек хәл итәргә җыенасыз?

— Беренчедән, заводны эшчеләр үзләре яңарта, яңа технология белән танышып, аңа ияләшеп өлгерә, реконструкция чорында ук белемен күтәрә, икенче төрле итеп әйткәндә, кыска сроклы курслар үткән сыман була.

— Димәк, сез производство мәйданнарын киңәйтү хисабына продукция бирүне арттырырга уйлыйсыз?

— Ул гына түгел,— Ихтыяр чәчен артка сыйпап куйды.— Иске технологияне яңага алыштыру, тулысынча диярлек автоматикага күчү, эшчеләрнең хезмәт шартларын яхшырту, производство белән идарә итүне камилләштерү...

— Сез авыл төзелешен дә материаллар белән тәэмин итәргә тиешме? Авыл төзелеше ничә процент тәшкил итә?

— Кызганычка каршы, бер процент та тәшкил итми. Без аларга неликвидларны, димәк, кондициягә җитмәгән продукцияне генә җибәрәбез. Ә үзебез алардан иң югары сортлы продукция таләп итәбез. Киләчәктә авыл тулысы белән безнең карамакка күчәргә, шәһәрнең азыктөлек фабрикасына әйләнергә тиеш.

Корреспондент кыз, Ихтыярның тавышы күтәрелгәнне сизеп, микрофонны читкәрәк күчерде дә, аны бүлдереп сорау бирде:

— Без темадан бераз читкә киттек. Тагын завод цехларына әйләнеп кайтыйк әле.

Ихтыяр сәгатенә карады да, тизрәк бу әңгәмәнең очына чыгарга уйлап, ашыга-ашыга сөйләргә тотынды. Ул сөйләгән саен, хәбәрче кызның кыюсызлыгы кими, аның кыюсызлыгы кимегән саен, Ихтыярның да тавышы көрәя бара иде.

— Соңгы сорау,— диде, ниһаять, кыз, вакытлары чыкканга ишарә ясап.— Димәк, шушы завод шәһәрне төзегән, шушы завод кешеләре бүген дә шәһәрнең нигезен кора, стеналарын күтәрә һәм, иң мөһиме, ул киләчәктә тагын да зурая, яңара. Заводның киләчәге турында берничә сүз әйтә алмассызмы?

— Заводның киләчәге турында мин әйтеп үттем инде. Безнең завод белән кызыксынган кешеләрне үзебезгә чакырабыз. Килсеннәр, күрсеннәр, ошатсалар, бәлки, бөтенләйгә монда калырлар. Бүгенге тапшыру ничек килеп чыккандыр, белмим, әмма шуны яхшы беләм һәм чын күңелдән ышанып әйтәм: завод менә дигән булачак!

Соңгы сүзләрен әйткәндә, Ихтыяр, уң кулын югары күтәреп, баш бармагын тырпайтканын сизмичә дә калды.

— Егерме бишенче августта заводны җибәрергә уйлыйбыз. Рәхим итегез! — дип, кабул итү бүлмәсенә кадәр корреспондентларны озата чыкты. Караса, креслода Нурислам утыра.

— Ашыгыч эш бар,— диде ул исәнләшүгә үк, ләкин кабинетка кергәч, нәрсәдән башларга белмичә, бер ноктага текәлеп тик утыруында булды. Ул озын юл үтеп хәлдән тайган юлаучыга охшый иде.

— Йә, сөйлә, нәрсә булды?

— Китәм мин, Ихтыяр,— дип авыр сулады ул.— Булмый монда. Кая барма — бүрегә караган шикелле карыйлар. Арыдым мин.

Ихтыяр, аның шешенке күз кабакларына, күмгәкләнә башлаган йөзенә, өстәл өстендә бертуктаусыз тыпырдаган бармакларына карап, беркавым тын торды.

— Менә сиңа иске авыздан яңа сүз! Ай-һай, бик иртә корал ташлыйсың,— дип кыза барды ул.— Кая китмәкче инде исәбең!

— Үзем укыган институтка аспирантурага чакыралар. Яклый алмыйм мин монда кандидатскийны. Яклатмыйлар аны миңа монда. Ничәмә-ничә мең эшче, инженер арасында бердәнбер кешенең фән белән шөгыльләнеп, югары материяләр турында фәлсәфә сатуы ят та, чит тә, кирәксез дә тоела аларга. Сарык көтүенә ялгыш килеп эләккән кәҗә кебек аптырап йөрим шунда.

— Әле барысы да әйбәт кенә барган сымак иде бит. Кайсысы тешләде?

— Баш архитектор диссертациягә кара мөһерен суккан, бөтенләй җимереп, туздырып рецензия язган.

— Син моңа башта ук әзер булырга тиеш идең. Тапкансың шаккатыр нәрсә! Берәү каршы икән, унысы яклап чыгар. Бу турыда җитәкчең беләме?

— Юк. Рецензияне кичә генә күрдем. Барыбер китәргә кирәк миңа. Өйдәгеләр дә бераз хәл алыр.

— Нигә дип җебеп төштең әле син? Кемгә кемгә, әсиңа һич тә килешми. Кая китмәкче буласың? Ә Ташлыяр, ял зонасы нишли? Минем берүземә ташлап калдырасыңмы аларны? Сәбилә нәрсә ди? Сәбиләгә әйттеңме соң әле бу турыда?

— Үзем дә рецензия турында кичә генә белдем... Өйдә кунмадым мин бүген. Кайтсаң, тагын тавыш, тагын күз яшьләре... Әйдә, бергәләп кайтыйк әле, син барда, алай күтәрелеп бәрелә алмас.

Нурислам, аның күңелендәге бар уйларын белергә теләгәндәй, сөзеп карап торды.

— Юк, бара алмыйм,— диде Ихтыяр.— Берничә көннән заводны җибәрергә исәплибез. Көн дә, төн дә эшли-

без. Гафу ит, башка вакытта. Бу юлы үзең генә ерып чыгарга тырыш. Мин үзем бернинди трагедия дә күрмим монда, чыннан да, арыгансыңдыр син, кайтып ял ит.

— Трагедия...— дип авыз эченнән мыгырданды Нурислам.— Трагедия, кара атка атланып, каршыга чабып килми ул, трагедия күренмичә йөри. Шуңа күрә аның белән көрәшү дә авыр. Трагедияне чит-ят кеше китерми, синең авырткан җиреңне яхшы белгән кеше китерә.

— Үз гаебеңне кешедән эзләмә. Кешенең бәхете дә, хәсрәте дә үз кулында.— Сәбилә үзенең туган көнендә шушы ук сүзләрне әйткәнне искә төшерде Ихтыяр.

— Сиңа рәхәт, синең акылың һәрчак аек, барыр юлың туры. Ярый, сау бул! Мин сиңа бөтенләй бүтән мәсьәлә белән кергән идем, анысы турында башка вакытта сөйләшербез.

Нурислам, башын иеп, салмак кына атлап чыгып китте, Ихтыяр аны туктатмады: беренчедән, әгәр дә сүз озынга сузылса, бу күңелсез әңгәмәнең ахыры тагын да күңелсезрәк бетәсен сизә, икенчедән, өсте-өстенә өелгән эшләр көтеп тора иде.

Ләкин ул әле, шактый вакыт күңелен тәртипкә китерә алмыйча, кабинет буйлап арлы-бирле йөрде, әйтерсең Нурислам махсус аның тынычлыгын алырга кергән, үзенең бөтен борчуларын аңа калдырып киткән иде.

Соңгы арада Ихтыяр үз-үзен кулга алырга, хисләрен тыя төшеп, Нурислам әйтмешли, аек акыл белән яшәргә тырыша иде. Сәбиләнең туган көнендә куна калып, төне буе күзенә йокы кермичә, газаплы уйлар белән борсаланып ятканнан соң, аларның өенә булдыра алганча сирәгрәк йөрергә карар кылды ул. Барган чакта да хәл-әхвәл сорашып бераз гына утыра да балалар бүлмәсенә кереп китә. Ринат белән Рәйханә, аның килүен генә көтеп торгандай, куана-куана сикерешергә тотыналар, муенына килеп сарылалар. Ул, уңайсызланып, алар белән олыларча җитди итеп сөйләшергә тырыша. Ләкин балаларның моңа исе дә китми. Сәбилә аларны бераз орышып та карый, үзенә игътибар итүче кеше күрмәгәч:

— Сез бала-чага белән сөйләшеп торган мин җүләр,— дип, кул селтәп чыгып китә.

Күрше бүлмәдә аның үзалдына сөйләнгәнен ишетеп, Ихтыяр сагаеп кала:

— Көне буе Ринаты өйдә берүзе, эштән караңгы төшкәч кенә кайтабыз, ә ул, ут яндырырга куркып, караңгы-

да утыра. Кеше күрергә зарыгып беткән инде алар. Нурисламны да атнага бер-ике генә күрәләр. Кайда йөри торгандыр...

Нурислам соңгы айларда танымаслык булып үзгәрде. Ул киңәшмәләр вакытында Ихтыярны читләбрәк йөрергә тырыша, очрашканда, салкын гына исәнләшә. Башка кешеләр белән дә элеккечә ачылып китеп аралашмый, сүз чыга-нитә калса, гел кирегә сөрергә генә тора. Кичке якларда һәрчак кызмача була, ә инде салып алгач, батыраеп китеп, бөтенесен сүгәргә тотына. Шәһәр башлыкларын, төзелеш җитәкчеләрен берәм-берәм әрләп чыккач, чират Ихтыярга җитә.

— Барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән! — дип мыскыллап көлә ул.— Акча исе, дан исе сизеп, балга җыелган чебен кебек җыелгансыз сез монда. Әллә синең шәһәрең, заводың кирәкме хәзерге заман чегәннәренә? Бик исләре китә! Саклык кенәгәләре шыплап тулгач, күкрәккә бер-ике рәт матур значоклар таккач, тагын ары китеп баралар. Чөнки тагын да зуррак акча исе тарта...

Ихтыяр гадәттә аны сабыр гына тыңларга, сүзләрен күп чакта уенга борып җибәрергә тырыша иде. Бу юлы түзмәде, уң кулы белән җиңеннән тартып туктатты да сул кулын кош канаты сыман җәеп җибәрде:

— Ә бу йортларны кем салды, бу шәһәрне кем төзи, бу заводның нигезенә кем субай суга? Син дә мин, Мөхәммәт Әминме? Бар да син теләгәнчә үк яхшы түгелдер түгелен. Ләкин шәһәр төзелә, кыенлыклар, йокысыз төннәр, безнең, аларның нервылары хакына төзелә!

— Ә син бу шәһәрнең үз йөзе, үз төсе булыр дип уйлыйсыңмы? Борын-борыннан күчмә халыклар шәһәр кормаган, тирмәдә яшәгән алар. Безнең төзүчеләр — күчмә халык. Гомерле булмаячак алар салган шәһәр, кешеләрнең күңеле ятмаячак аңа. Менә син үзең дә шәһәргә күчәргә уйламыйсың, һаман Ташлыяр ягына каерасың. Җитәкчеләр өчен шәһәр читендә аерым коттеджлар төзибез. Нигә үзләре төзегән шәһәрдә яшиселәре килми аларның? Беләм мин аларны, бик яхшы аңлыйм. Акча булсын да хур кызлары тулы бакча булсын. Шамкаев кочкан кызлар синең төшеңә дә кермидер.

— Йозак тишегеннән карап торганым юк.

— Нигә йозак тишегеннән карарга? Бу турыда бөтен шәһәр сөйли, ә син белмәгәнгә салышасың. Бәлки, син аларның баш архитектор белән бергәләп карурман уртасында-

гы пионер лагеренда менә дигән сауна салып куйганнарын да белмисеңдер? Дөрес эшлисең, белмәгәннең беләге авыртмый. Үзләре парлап-парлап шунда йөри, ә безне җыелышларда гына мунча кертәләр. Шәһәр халкы өчен мунча салу турында уйлап караган кеше дә юк. Болай тәртипле генә йөрсәң, кирәкмәгәнне күрмәсәң, озакламыйча син дә шул мунчага йөрү дәрәҗәсенә ирешерсең әле. Хәзергә чакырмыйлардыр. Погоныңдагы йолдызлар бәләкәйрәк. Түз, түз, күп көтәсе калмады. И-их, туган! Ә мин сиңа ышанган идем. Шул яэҗүҗ-мәэҗүҗләрдән туган ягыңны пычраттырмас өчен, аның матурлыгын, тарихын, хәтерен саклар өчен кайткансыңдыр дип уйлаган идем.

— Туган якның хәтере — без ул, үзебезне үзебез сакларга, кешеләрне сакларга кирәк. Югыйсә юл башында ук хәлдән таеп егылуың мөмкин.

— Әле кайчан гына бүтән җырлар җырлый идең. Максималист Ихтыярның да куыгын шиңдергәннәр.

— Моның белән нәрсә әйтергә телисең син, Нурислам? Гомумән, нишләмәкче буласың? Бар дөньяны сүгәсең. Берәр конкрет тәкъдимең бармы соң синең? Нигә ярып салмыйсың шуны? Күңелеңдә иярләнгән тай ята, ә сүзләрең кигәвен кебек кенә. Тешли дә тагын очып китә. Файдасы юк, ачуны гына чыгара.

— Минем башта фикер ярала. Юк, мин сезнең белән тешләшмим, ялгышмагыз, мин бары тик кычкырып уйлыйм гына. Тыңласагыз — тыңлагыз, тыңламасагыз — юк. Фикер — миннән, тәкъдим — сездән. Сез — практиклар, мин — теоретик.

* * *

...Ихтыяр, завод капкасыннан чыгып, кара «Волга»га утырганда, радиодан татарча концерт башланган иде.

— Сәгать сигез тула,— дип, радионы көчәйтеп куйды шофер.— Бүген иртәләдегез.

— Аяк өстендә килеш йокыга китә башладым. Бераз ял итәргә кирәк.

— Ташлыяргамы?

— Әйе. Яңгыр килә,— диде Ихтыяр, шәһәр өстендә куерып торган болытларга карап һәм шулчак йөрәгенең чәнчеп куйганын сизде.

«Юк, өйгә кайтып кына тынычланып булмас»,— дип уйлады ул һәм шоферга:

— Башта шәһәргә сугылып чыгыйк,— дип эндәште.

Заводны тапшырганнан соң, бераз эч бушатып утырасы, ниһаять, Нурислам белән аңлашасы, икеле-микеле уйларына чик куясы килә иде аның. Ишекне Сәбилә ачты. «Нурислам өйдәме?» — дигәч, җавап бирмәде. Ихтыяр аларны шимбә көнгә кунакка килергә чакырды да, чыгарга дип, ишек тоткасына үрелде. Нидер сизеп, артка борылып карады һәм, Сәбиләнең ялварулы күзләрен күреп, ирексездән туктап калды. Сәбилә яшьле күзләрен куллары белән каплады да кухняга кереп китте.

Түр бүлмәдән Нурисламның үзалдына сөйләшкәне, кемнедер пыр туздырып сүккәне ишетелде. Аның исерек тавышы яңгыраган саен, Сәбилә дерт итеп куя иде.

— Нәрсә булды Нурисламга? Тик торганда нигә болай эчүгә сабышты ул? — дип сорады Ихтыяр.— Әле яз көне генә андый гадәте сизелми иде бит.

— Көнчелек бетерә аны,— дип пышылдады Сәбилә.— Институтта укыганда ук кем дә булса үзеннән уздырып берәр нәрсә эшләсә, төн йокылары кача иде. Үзеннән яхшырак, үзеннән акыллырак кешеләр белән гомерендә аралашмаска тырышты, аларны якын итмәде.

«Димәк, мине дә башта үзеннән түбән санаган икән»,— дип уйлап куйды Ихтыяр.

— Кияүгә чыкканчы ук көнләп, теңкәмә тия иде. Анары көнләшмәс булган иде. Хәзер тагын шул чире кузгала башлады.

— Кемнән көнләргә тиеш ди әле ул?

Сәбилә йөзен читкә борды. Ихтыяр аның иреннәрендә ниндидер кадерле, ләззәтле сүзне әйтергә торган хисле калтырану күрде. Ул, аның бөтен матурлыгы, бөтен мөлаемлыгы, бөтен ярешен серләре иреннәренә җыелган икәнен бары тик шушы мизгелдә беренче тапкыр аңлап, бөтен барлыгы белән аңа таба тартылды. Сәбилә Ихтыярның сүзсез калып еш-еш сулавын сизде һәм, кинәт борылды да:

— Синнән...— диде.

Ихтыярның тәне буйлап җиңелчә калтырау йөгереп узды, моны сиздермәс өчен ул сәер генә елмайды, ыкмык килеп торды да сүзне уенга борырга булды:

— Каяле, көнчелеген сыгып чыгарыйм әле мин аның!

Ләкин ул, сүзләренең урынсыз икәнен аңлап, аптыраганнан гына ишек ягына бармак селкеде. Сәбиләнең иреннәре хәрәкәтсез катып, агарып калганын күреп, күтәргән

кулын акрын гына аска төшерде, аннары, үз-үзенә хисап бирмичә, ниндидер ярамаган эш кылып ташлаудан куркып, китәргә булды. Шулай да ишек төбендә туфлиләрен кигәч, бераз таптанып торды, тирә-юньдәге шомлы тынлыкка сәерсенеп, Нурислам бүлмәсенә таба атлады. Нурислам, авызы ачык килеш, чалкан ятып йокыга талган иде. Ихтыяр саубуллашмыйча гына чыгып китте.

* * *

— Улым, уян инде, уян!

Ихтыяр, күз кабакларын көчкә ачып, беркавым аңына килә алмыйча, түшәмгә карап ятты. Әнисенең тавышы тагын ишетелгәч, сикереп торды.

— Сәгать ничә? — дип кычкырды ул, йокылы-уяулы тавыш белән.

— Дүртенче китте...

— Нәрсә? Нигә бик иртә уяттың?

— Әтиең дәшә. Сүзе бардырмы? Ишегалдында әтиең.

Әтисе ишегалды себерә иде. Ихтыяр эскәмиядә торган сулы чиләкне өскә күтәрде дә башына койды. Аннары пуф-пуф килеп сөртенде, бер урында сикергәләп алды.

— Киен. Яңа нигезне күрсәтергә барам.

— Нинди яңа нигез? Яңа поселокмы? Ю-ук, вакыт юк! Заводны тапшыргач, рәхәтләнеп барам. Хәзер булмый.

— Берәр сәгатьтән урап кайтабыз. Эшеңә дә соңламыйсың,— дип, икеләнергә урын калдырмыйча, кырт кисте әтисе.

— Нигә шулай ашыгыч?

— Баргач күрерсең.

Берничә минуттан алар капка төбендәге «УАЗ»га утырдылар да, авыл этләрен йокыларыннан уята-уята, югары очка менеп киттеләр.

Басу капкасын чыккач, Ихтыяр әтисенә күтәрелеп карады, аның үз уйларына чумып баруын күреп, тәрәзә кырыена таянды. Әле генә алтынсу күлмәкләрен салып, шәрәләнеп калган кырлар ят та, шыксыз да булып күренде аңа. Әллә инде йокыдан иртә уятканга, әллә әтисенең шулай серле төстә алып чыгып китүенә, әллә алда торган мәшәкатьләр күплегеннән — ул кәефсез иде.

Яңа поселок читендә туктадылар.

— Килеп җиттек,— дип, яшьләрчә җәһәт кенә сике-

реп төште Тимерхан.— Соңгы тапкыр кайчан булдың монда?

— Үткән ай азагында.

— Үзгәреш сизеләме?

— Канау казыганнар...

— Канау түгел, ай буе танау казый инде алар. Иске Ташлыярдан ярты авыл шәһәргә качып бетте, монысының очы-кырые күренми!

— Материаллар җитми, эткәй, шәһәргә дә күршеләрдән ташыйлар.

— Башта нәрсә карадыгыз? Җитәрлек булмагач, нигә тотындыгыз яңа поселокка?

— Әкренләп барысы да булыр.

— Безгә әкренләп кирәк түгел! Авыл артык күтә алмый. Ул хәзер түшәк өстендәге хаста кебек. Кислород мендәрләре, вак-төяк укол белән генә саклап калып булмый аны. Операция кирәк! Ә без һаман аның баш очында матур сүзләр сөйләп юатып утырабыз. Әнә, кара, сыер абзарларының нигезе казылган килеш ята, йортларның стеналарын күтәрделәр дә туктадылар, су кертелмәгән, юл юк. Эшләр болай барса, ярты елда колхозны таратып бетерергә туры килә. Шәһәрдә нәрсә ашап яшәргә уйлыйлар соң?

Тәртипсез төстә чәчелеп яткан торбаларга, аркылы-торкылы казылган канауларга, әле анда, әле монда таутау өелгән балчык өемнәренә күз йөртеп чыккач, Ихтыяр этисенең ни өчен шулкадәр өзгәләнүен, ни өчен иртә таңнан монда алып килүе сәбәбен аңлый башлады. Этисе, һәрвакыттагыча, суккач суккач, чаңның зурысын сугарга кирәк дип саный, шулай итмәсәң, авыр кыймылдый торган саллы гәүдәле җитәкчеләрне кузгатып булмаганын яхшы белә ул. Ләкин боларны нигә аңа сөйли, нигә аның болай да мең борчулы күңелен вакытсыз һәм урынсыз сораулар биреп тинтерәтә? Ихтыяр болай да барысын белеп, күреп тора лабаса. Быел колхоз уңышны былтыргыдан бер ярым мәртәбә артык алды. Бәрәңгене үткән елгыдан алты тапкыр күбрәк сатты, сөт планын да арттырып үтәп баралар. Шәһәр кибетләрендәге кыяр, суган, помидор да «Уңыш» колхозы теплицасында үскән. Дөрес, кадрлар, эшче көчләр мәсьәләсе көннән-көн катлаулана бара, урып-җыю чорында да ике комбайнның берсенә шефлар утырды. Аннары азык-төлек проблемасын хәл итәсе бар. Хәзергә әле малларга ризык җитә, ә

яңа комплекс өлгергәч, нишләрләр? Сыерлар саны өч мәртәбә арта, шулар янына ике мең баш сарык өстәлә, ә басу-кырлар, болыннар, киресенчә, кими. Нишләргә?

Ихтыяр, этисенең көн дә табын янында сөйли торган борчулы уйларын яңабаштан кичерә-кичерә, Яңа Ташлыярның булачак урамы буйлап атлады. Хәзергә алты йорттан торган «урамның» аргы башына чыккач, Тимерхан салына башлаган йорт нигезенә утырды.

— Кил,— диде ул Ихтыярга,— булачак йортыңның нигез ташына утырып хәл ал бераз. Бәхетле нигез булсын дисәң, борынгылар шикелле нигезенә көмеш тәңкә салып калдыр.

— Көмеш тәңкә генә түгел, яшьлегеңне салып калдырырга туры киләчәк әле монда. Нигезе генә бәхетле булсын,— дип, офык читен яктыртып торган Яңа шәһәргә ымлады Ихтыяр.

— Безнең ата-баба нигезе моңа кадәр бәхетле нигез иде,— дип, кул астындагы кирпечләрне сыйпап куйды этисе.

Кайтыр юлга борылгач, алар сүзсез генә атладылар. Тынлыкны Тимерхан бозды.

— Менә, улым,— дип әкрен генә, моңсу гына башлап китте ул,— син яшьлегең турында кайгыртасың. Яшьлекне генә түгел, бөтен гомерне бирдек без шушы яклар өчен. Яшь чакта мин дә сезнең шикелле авылның беренче егете идем. Михнәт муенга менеп атлангач, кырысланырга, тупасланырга, усалланырга туры килде.

— Нәрсә булды сиңа бүген, эткәй? — дип гаҗәпләнеп аңа карады Ихтыяр.

— Бүлдермә, тыңлап бетер! Сугышта без хәле беткән атларны атып калдыра идек. Ат елый, күңеле белән сизә малкай, күзләреннән мөлдерәп яшьләр ага, аңа кушылып үзең дә елыйсың. Ә барыбер атарга туры килә. Мин дә менә...— Ул, эллә инде сугыштагы атларны искә төшереп, эллә болай күңеле тулудан, күзләренә тыгылган яшьләрне җиңе белән сөртеп алды.— Күңелем сизә, артык тарта алмыйм мин. Шушы бомба чокырларына караган саен, йөрәгем әрни.— Ул экскаватор казып ташлаган канауларга, котлованнарга күрсәтте.— Үземнең көчсезлегемнән, кемгәдер бәйле булуымнан җиргә ятып елардай булам...

Моңа кадәр күңеле йомшау түгел, пышылдап сөйләшә дә белмәгән этисенең шулай кинәт кенә җебеп төшүе

Ихтыярның җанын актарып ташлагандай булды. Ул аны юатырга да, оялтырга да белмәде. Әтисе туктады да аңа кәгазь сузды:

— Мә, укы.

Ихтыяр, дүрткә бөкләнгән кәгазьне саклык белән генә алып, бер кәгазьгә, бер әтисенә карады.

— Укы!

*«КПСС райкомына Беренче секретарьга*

*Мин инде 1942 елдан бирле «Уңыш» колхозына җитәкчелек итәм. Бу чорда колхозның төрле чагы булгандыр, әмма ул беркайчан да төшеп калганнардан исәпләнмәде. 1955 елда миңа Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирелде, бүгенге көндә колхозда бер Ленин ордены кавалеры, ике атказанган механизатор, бер атказанган агроном эшләве үзләре генә дә начар түгел, минемчә.*

*Ләкин колхоз янәшәсендә, өлешчә колхоз җирендә шәһәр салына башлагач, безнең хәлләр бик нык катлауланды. Дөрес, шефлар безгә һәрчак ярдәм итеп тора, техникасын да, эшче көчләрен дә кызганмый. Ләкин атка күпме генә солы бирсәң дә, ул барыбер машина хәтле тарта алмаячак. Безгә хәзер иң беренче чиратта игенчелек технологиясен яңабаштан үзгәртеп корырга, терлекчелекне тулысынча механикалаштырырга, яшелчә, җиләк-җимеш үстерү өчен ныклы база булдырырга кирәк. Бездән күп нәрсә сорала. Ләкин сорау гына аз. Без үз эшебезне планлы төстә алып бара алмыйбыз. Подрядчылар вәгъдә итә — эшләми, төзелеш материалы сорап барабыз — ишек төбеннән борып җибәрәләр. Авылдан кеше кача. Әгәр дә болай барса, яңа поселок төзелеп бетүгә, анда күчәр кеше калмаячак.*

*Мин боларның барысы турында да райбашкарма җитәкчеләренә һәм райкомга күп мәртәбәләр әйттем, әмма бернинди нәтиҗәгә дә ирешә алмадым. Миңа алтмыш яшь тулуны һәм тагын башка сәбәпләрне дә искә алып, үз теләгем белән эштән азат итүегезне сорыйм. Минем бу соңгы үтенечемне канәгатьләндерерсез дип уйлыйм.*

*Батыршин».*

Ихтыяр, беренче тапкыр күргәндәй, әтисенә озак кына карап торды, караган саен аның йөзе яктыра, күзләре балкый бара иде.

— Оста язылган,— дип көлемсерәде ул.— Башта ситуацияне аңлата, аннары проблемалар куя, ә иң соңыннан гына

ультиматум. Шушы хатны тотып беренче секретарь янына бармакчы буласыңмы? Беләсеңме, нәрсә диячәк ул сиңа?

— Мине аның ни диюе кызыксындырмый. Йә колхозга, авылларга үги бала итеп караудан туктыйлар, йә озакламыйча үзләре дә төп башына утырып калалар.

— «Паникер!» дип куып чыгарачак ул сине. Үзең әле генә сугыш турында, ата-баба нигезе турында сөйләдең... Аңламассың сине, эткәй. Ертып атыйммы хатыңны?

Ихтыяр этисенең җавап биргәнен дә көтеп тормады, гаризаны вак кисәкләргәерткалап, басу өстенә чәчеп җибәрде.

— Нишлисең син? — дип, аның кулын шытырдатып кысты этисе.

— Бу турыда райкомга берничә мәртәбә мөрәҗәгать иттем, дисең бит. Нигә тагын ботинка туздырып барып йөрергә? Миңа райком юл уңайлый, эшкә барышлый кереп чыгармын. Төзелеш бүлегенә йомышым да бар иде.

— Синең керүеңнән миңа ни файда?

— Хәзер үк вәгъдә итә алмыйм... Без заводны пландагыдан биш көнгә алдан тапшырабыз. Шул биш көнне авыл төзелешенә багышласак, күп нәрсә майтарачакбыз. Шулай да хәйләкәр кеше син, эткәй, мәсьәләне кабыргасы белән куя беләсең! Әле беркөнне Нурислам сөйләгән нәрсә искә төште. Ике көтүче була. Берсе тырыш, берсе хәйләкәр икән боларның. Берзаманны яңгыр килә башлый, давыл чыга. Тырышы көтүне авылга куа, батыпчумып, мең үлемнән калып, сарыкларны коткара. Ә икенчесе, давыл киләсен алдан ук чамалап, сарыкларны давылга кадәр үк кайтарып җиткергән була. Беренчесенә, авырлыкларны җиңеп чыгып, көтүне саклап калганы өчен бүләк бирәләр...

— Икенчесен нишләтәләр? — дип кызыксынды Тимерхан.

— Икенчесен капка төбендә калдыралар да китеп баралар,— дип, Ихтыяр өйләре янына килеп туктаган машинадан төште дә үзен көтеп торган «Волга»га таба атлады.

— Чәй эчмисеңмени?

— Миндә дә Батыршиннар каны бит: эшне эшләмичә табын янына утырмыйм. Киттек!

Тимерхан, улының чын ир булып өлгереп килүен аңлап, өйгә керергә ашыкмыйча, капка төбендәге эскәмиядә уйларына чумып озак утырды.

* * *

Шимбә көнгә Нурислам белән Сәбиләне кунакка дәшүенә инде үкенә башлаган иде Ихтыяр. Зыятдин карт гомер-гомергә мәҗлес җыюга хирыс булмаганга, ул иртән бабасы янына икеләнеп кенә кергән иде. Бабасын бөтенләй үгетләп торасы да булмады, ул шундук ризалашты, хәтта эчтән генә сөенеп тә куйды бугай әле.

— Ниятегез чын булса, килегез, урын иркен,— диде ул Ихтыярга.

Әтисе атауга кунак чакыруны хупламаса да, әллә инде әнисенең сүзе тәэсир итте, әллә инде теге... гаризасын ертып аткан көннән Ихтыярга хөрмәте арткан идеме — вакыты килеп терәлгәч, авыз ачып сүз әйтмәде. Гомумән, соңгы көннәрдә ул алыштырып куйгандай булды: кинәт кенә яшәреп киткәндәй тоелды, элеккечә җиргә иелеп түгел, башны күтәребрәк йөри башлады, вакчыллыгы да кими төште. Элек күбрәк зарлану, сукрану белән алдыра торган булса, хәзер кешеләрне мактап, дәртләндереп эшләтә, эчтән генә үз сүзен сүз итүенә куанып йөри, күңел түреннән боларның барысы өчен Ихтыярга рәхмәт укыса да, нигәдер әле аңа сагаеп, икеләнеп карый, бу бергәлекнең, бу уртак җиңүләрнең һәрчак шулай дәвам итүенә ышанып бетә алмый иде.

Ихтыяр иртәдән башлап атауга азык-төлек, савыт-саба ташыды. Әйтерсең мәҗлескә ул Сәбилә белән Нурисламны гына түгел, ә бөтен авылны җыярга уйлый иде.

Очраган кешеләр:

— Әллә туй уйнарга әзерләнәсеңме, Ихтыяр? — дип кызыксынып сораштылар.

Укулар башланганчы кайтып кит, дип, Зәлиягә дә күптән язган иде, ләкин аннан һаман хәбәр-хәтер юк. Әнисе телеграмма сугарга кирәк, дип кат-кат әйтсә дә, Ихтыярның Зәлиягә хәтере калган иде, аннары соңгы арада ыгы-зыгылар күбәйде, почтага бара алмады.

Кояш төшлеккә күтәрелеп җиткәндә, мотоциклының артына Сәбиләне утыртып, Нурислам килеп төште. Икесенең дә авызы ерык, Сәбиләнең йокысызлыктан, Нурисламның төрле борчулардан һәм махмырдан таушалган йөзе бүген балкып тора — танымассың да. Ихтыяр аларга кушылып елмайса да, аның күңелен бик эчтән нәрсәдер тырнап, авырттырып куйды.

Инеш буен тутырып шаулый-гөрли өч кеше килеп ке-

рүгә, карга каркылдавыннан башка тавыш ишетмәгән атау йокысыннан уянды. Бүген анда кошлар да ныграк чыркылдаша, өстәл өстендәге самавыр да ныграк тавышлана, Зыятдин карт та дәртләнебрәк теркелди иде. Ул нафталин исе бөркеп торган күлмәк-чалбар киеп алган, башында — өр-яңа кәләпүш, аякларында — галош киертелгән күн читек. Үзе бер урында озак тора алмый, әле өйгә йөгереп кереп, болай да шыгрым тулы өстәлгә тагын нидер китереп куя, әле ишегалдына чыгып, арлыбирле йөренә.

Өстәл янына җыелышкач та күңеле басылмады аның, самавыр каршына елышып утырган да үзе чәй ясый, үзе бертуктаусыз сөйләнә:

— Иртән генә әйтте бит Ихтыяр. Алданрак белгән булсам, болай гына әзерләнер идекмени?! — дип, уңайсызланып, як-ягына карана.

— Безгә шушыннан артык берни дә кирәк түгел,— дип юата аны Нурислам.— Якты йөзең, такта чәең булса, шул җиткән.— Ул Ихтыярга күз кысып алды.— Такта чәй дигәннән, катырак чәең дә бардыр бит, Ихтыяр? Су тегермәнне дә вата, диләр, әйеме, бабай? Кстати, тегермәнне кайчан күрсәтәсең?

«Тегермән» сүзен ишеткәч, Зыятдин карт, сагаеп, колакларын шомрайтты.

— Бар, бөтен нәрсә дә бар, ашыктырма гына,— дип җавап бирде Ихтыяр һәм Сәбиләгә сораулы караш ташлады, тегесе иңбашларын җыерып куйды.— Әле монысы чабыш алдыннан аяк кыздыру, чәйләп алу гына иде бит.

— Аякны чәй белән кыздырып буламыни? Шулай бит, бабай? Бәйрәм булгач, бәйрәм булсын! Көн саен завод директорында кунакта булмыйбыз ла без...

— Баш инженерда,— дип төзәтте Ихтыяр.

— Башлы инженерда...— дип куйды Нурислам.

Ихтыяр рюмкаларга салгач, Нурислам җитдиләнеп торып басты. Аның иңенә кулын куйды.

— Ихтыяр дус,— дип башлады ул уйчан гына,— мин инде сине елдан артык беләм. Бер ел Зыятдин бабай өчен, бәлки, бик аз тоеладыр, ә безгә, кабаланып яшәүче буынга, бик күп вакыт ул. Шул бер ел эчендә син үзеңнең кем икәнеңне күрсәтергә өлгердең һәм бик күпләрнең борынына чиерттең. Сине идарәгә килү белән күреп алдылар, сиңа ышандылар, җаваплы эшкә җиктеләр. Ни өчен ышандылар сиңа? Кайберәүләр әйтмешли, нәсел агачы гы-

на сәбәпчеме монда? Юк, һич тә алай түгел. Оясында ни күрсә, очканда шул була, диләрме әле, Зыятдин бабай? Ләкин бу мәкаль искерде хәзер, балалар белән аталар арасында күпер өзелде, юкка чыкты. Хәзер һәркем үзенә үзе юл сала. Менә шуның бер мисалы — син, Ихтыяр. Кайберәүләрдән аермалы буларак, син бүгенге эш стилен күңелең белән тоя беләсең. Көчең җитмәс нәрсәгә тотынып, шау-шу куптармыйсың, төрле җиргә чәчелеп, төп эшеңне онытмыйсың. Төрле фикердәге кешеләр белән уртак тел таба беләсең...

— Тукта инде...— Ихтыяр, кызарынып, аңа карады.— Боларын пенсиягә озатканда сөйләрсең.

— Туктамыйм! — дип бармак янады Нурислам.— Теләсә кемгә мәдхия җырлап йөри торган кеше түгел мин. Әйе, үпкәләмәсәң, бер әйтер сүзем бар сиңа, Ихтыяр.

— Ярып сал эчеңдәгене! Кемнән тартынып торасың? — дип егетләнде Ихтыяр.

— Артык туры юлдан барасың, Ихтыяр дус...

Сәбилә шелтәле караш белән Нурисламга күтәрелеп карады, сүзнең артыкка китә башлавын искәртергә теләп, тамак кырып куйды. Ә Нурислам берни булмагандай дәвам итте:

— Акыллы кеше икеләнергә тиеш. Ул һәр вакыйганың, һәр сүзнең, һәр гамәлнең, иң мөһиме — һәр кешенең ике яклы булуын, ике генә түгел, өч, дүрт, биш яклы булуын — катлаулы булуын бер чакта да истән чыгармаска тиеш. Икеләнмәгән кеше бу дөньяда бер ачыш та ясамый, бүтәннәр уйлап тапкан тәгәрмәчне генә тәгәрәтә. Ахыр чиктә, икеләнмәгән кеше мин-минлек белән авырый башлый.

— Бу рюмканы эчәргәме-юкмы дип икеләнеп утырмыйсыңдыр бит? — Ихтыярга сүзнең гел үзе тирәсендә генә бөтерелүе ошап җитми, бүген аның бөтен җитдилекне, рәсмилекне онытып шаярасы, көләсе килә иде.

— Алайса, сүзем бетте. Синең беренче җиңүләрең өчен! — дип, Нурислам рюмкадагы аракыны бер йотуда эчеп бетерде.

Ихтыяр кунакларны хәл алып керергә чакырды.

— Учакны кайда ягарбыз икән, бабай? — дип, Зыятдин карттан сорады ул.— Шашлык кыздырырга иде исәп.

Зыятдин карт атауга күз йөгертеп чыкты да таягы белән төртеп күрсәтте:

— Без яшь чакта ә-әнә теге эче куыш карт өянке тө-

бенә казан аса торган идек. Анда суы да якын, яңгыр ява башласа, кереп ышыкланырга тегермән дә янәшә генә.

Нурисламның йөзе аракыдан алсуланып чыкты, теле ачылып, кыяфәтенә кинаяле төс керде, сүзләре тагын да чәнечкеләнә төште. Ләкин Ихтыяр аның төрткеле сүзләренә игътибар итмәскә тырышты, башын аска игән килеш, ара-тирә уен сүзләр кыстырып, шашлык белән әвәрә килүендә булды. Итен турап, өстенә тоз, борыч сипте, суган белән уксус салды да әйбәтләп болгатты. Аннары савыт өстенә тәлинкә каплады һәм өстенә таш бастырып куйды. Шампурлар алырга дип өйгә кергәч, Сәбиләне көзге каршында күреп, бусагада тукталып калды. Ихтыяр Сәбиләнең тәненә сыланып торган аксыл зәңгәр күлмәгенә, шәрә балтырларына, ачык иңнәренә карап, шактый ара өнсез торды. Бу минутта ул аның ике бала анасы икәнен дә, көйсез Нурислам белән изаланучы гаилә җанлы хатын булуын да истән чыгарган, әкияти алиһәне күргәндәй, бар дөньясын оныткан иде. Әгәр дә хәзер авыз ачып бер сүз әйтсә, бу матур төш кинәт кенә юкка чыгар, Сусылу Сәбилә инешкә сикереп төшәр дә йөзеп китәр сыман тоелды. Шулчак Сәбилә урыныннан кузгалып куйды һәм аларның күзләре көзгедә очраштылар. Сәбилә карашын яшермәде, киресенчә, онытылып, карап торуында булды. Менә, әкренләп, Ихтыярның соклану тулы күзләрендәге тылсым аның күзләренә дә күчте, икесенең дә битләре алсуланып, уттай кызышты. Ихтыяр, бу әсирлектән ничек чыгарга белмичә, тилмереп, изаланып торганда, тыштан Нурисламның кычкырганы ишетелде:

— Ихтыяр, кая олактың анда? Киттек су буена!

Ихтыяр шунда гына аңына килеп, сүз әйтергә дип авызын ачты, ләкин Нурисламга җавап бирү урынына, ул Сәбиләгә сүз кушты:

— Безне чакыралар, Сәбилә...

— Безне түгел, сине.

— Учак янында утырырга яратасыңмы?

— Эчендә ялкыны булган кешеләр белән утырырга яратам.

— Нурисламдагы ут бәгыреңне өтеп алырлык...

Ихтыяр, кирәкмәс сүз ычкындырганын сизеп, туктап калды. Сәбилә алдында мондый сүз әйтергә, Нурисламга тел тидерергә үзенең хакы юклыгын ул яхшы аңлый, ләкин тыела алмый, эчтәге ниндидер җен аны һәрчак

үчекли, котырта иде. Ләкин Сәбиләнең моңа аз гына да исе китмәде, киресенчә, ул Ихтыярның сүзен җөпләп куйды:

— Бәгырьне көйдерерлек шул. Ә хатын-кызга әллә нигә бер ялкын бөркеп торган вулкан кирәк түгел. Һәр көнне, һәр минутта ир-ат җылысын, яраткан кешесенең җылысын тоеп яшисе килә аның.

— Гомер буе чыш-пыш килеп көйрәп яшәгәнче, бер тапкыр вулкан булып атылуың яхшы түгелмени?

— Хәзерге ирләрнең бөтен энергиясен, бөтен вакытын, матур хыялларын, хәтта бөтен батырлыгын эш алып бетерә. Эштә вулкан кебек кайный ул, ә өйгә вулканның көле генә очып кайта. Менә шул сүнгән вулкан белән яшәп кара инде... Гаилә арткы планга күчте хәзер. Өй хәзер йокы бүлмәсенә генә әйләнеп бара.

Ихтыяр, тыңлаган саен, Сәбиләнең үзенә якыная төшкәнен күңеле белән тоя, ниндидер ярамаган эш эшләгәнен, тыелган җиргә кереп барганын аңлап, җаны бәргәләнә иде. Аның Сәбиләнең күзләренә текәлеп карыйсы, чәчләреннән иркәләп сыйпыйсы, сер тулы иреннәренә кагыласы килә иде...

— Их-тыяр! Чыгасыңмы, юкмы? Сәбиләне дә чакыр.

Нурислам аларның икәве генә өйдә булуларына эче пошып бимазалана, ләкин яшертен бер горурлык аны өйгә керүдән тыеп тора иде. Уңайсыз хәлдән, шаукымлы уйлардан коткарганы өчен, Ихтыяр Нурисламга эчтән генә рәхмәт әйтте, шалтыр-шолтыр китереп, чөйдәге шампурларны алды. Кырыс булырга тырышып, Сәбиләгә эндәште:

— Чакыралар. Киттек. Су буена төшәбез.

Нурислам Ихтыярның күңелендәге үзгәрешне сиздеме, әллә болай гынамы — аңа сынап карады, ләкин сүз әйтмәде.

— Кая куалыйсың? Шашлык янмыйдыр бит әле,— дип елмайды Ихтыяр.

— Янмый шул,— дип, ниһаять, телгә килде Нурислам.— Әйдә, тизрәк ягып җибәрик учакны. Без монда Зыятдин бабай белән Ташлыярның бер ташын да урынында калдырмадык инде... Рәхәтләнеп эчләрне бушаттык. Менә кем аңлый ул дөньяны! — Ул авызын бөрештереп сызгырып куйды.— Менә кем күргән дөньяны! Менә кайда ул социология!.. Кешене тыңлый беләсезмени соң сез, кешене аңлый беләсезмени? Чыш-пыш белән, кети-мети белән генә ерак китеп булмый...

Нурисламның шактый ук кызмача икәнен Ихтыяр шунда гына аңлады.

— Эчне бушатмагансың, киресенчә, тутыргансың бугай син,— дип төрттерде Сәбилә, тумран башындагы буш шешә белән стаканга күрсәтеп.— Шешәнең эче бушаган, анысы күренеп тора.

— Бу нәмәрсә кайгыны бушатмый, ишәйтә генә,— дип, Зыятдин карт түгәрәк сакалын уңайсызланып кына сыпырды.— Борчулары хәтсез икән Нурисламның...

Ихтыяр аракы турындагы сүзнең артык куерып китүен теләми иде, Нурисламга итле табакны китереп тоттырды, бабасына шампурларын бирде дә лапастан кочагы белән утын алып чыкты.

— Мәҗлес дәвам итә! — дип яңгыратып кычкырды һәм йөгерә-йөгерә тегермән буена төшеп китте.

Сәбилә, өйдәге ризыкларны алып килеп, иске тегермән ташы өстенә табын әзерләде. Ә ир-ат учакны дөрләтеп җибәргән иде.

— Кил, син дә безнең янга елыш,— дип, Сәбиләгә эндәште Зыятдин карт.— Бу атауга, әбиегез вафат булганнан бирле, хатын-кыз сирәк аяк баса.

— Ә әнкәй? — дип сорады Ихтыяр.

— Әниең йөгереп керә дә йөгереп чыгып китә ул. Атаңның холкы бик кырку бит.

Сәбилә учак янында бераз гына басып торды да тагын табын янына китте, тегермән тирәләрен әйләнде. Йөзен нindидер аңлатып булмый торган якты моңсулык сарган иде аның.

Ихтыяр, шампурга ит киертә-киертә, исе китмичә тыныч кына сүз башлады:

— Бер-ике елдан бу тирәләр танымаслык булачак. Киләсе язда Ташлыяр халкын күчерә башлаячаклар. Урман буенда яңа поселок төзелә инде.

— Ә монда нәрсә булачак? — дип сагаеп сорады Зыятдин карт.

— Сиңа әйтмәдеммени әле? Ял зонасы.

— Ә-ә, колагыма нидер чалынган иде шул. Тик ял итәргә бер дә кулай урын түгел бит бу, улым. Гомер-гомергә иртә таңнан кичке караңгыга кадәр эш дип яшәде авыл халкы. Монда һәр карыш җир безнең маңгай тире белән сугарылган. Ялга Кырым, Кавказ якларына бара түгелме соң халык?..

Сүзгә Нурислам кушылды:

— Шаяртма, бабай! Менә рәхәтләнеп ял итеп утырабыз бит әле. Кырымнан кай төше ким?

— Авылны кучермичә генә салып булмый микәнни соң ул шәһәрне?

— Шәһәр эчендә кала ул, бабай. Сукыр эчәк шикелле кисеп атмак булалар аны,— диде Ихтыяр.

— Ә син нәрсә дисең, Нурислам улым? Сукыр эчәкне түгел, кешеләрнең бәгырен кисеп ташларга җыеналар түгелме?

Зыятдин карт, бу турыда Ихтыярга сүз кушып та аңардан юньле фикер ишетмәгәнгә күрә, хәзер аңа мөрәҗәгать итми, син, бәлки, бер-бер юлын табарсың, менә-менә өскә аварга торган афәттән коткару юлын күрсәтерсең дигәндәй, Нурисламга йотылып карап тора, аның белән генә сөйләшә иде.

— Дөньядан артта каласың, бабай! — дип, Нурислам яткан җиреннән торып утырды.— Бу турыда Ихтыяр белән бер ел тел тегермәне тартабыз инде без. Шуны сөйлисөйли агарды минем бу чәчләр. Авыл калачак, Нурислам әйткән иде диярсез, калачак! Менә бу йортларда,— ул кулы белән авыл өстен айкап чыкты,— бөтен Рәсәй авылларыннан җыелган яшь-җилкенчәк туган авылын, туган йортын табачак, сагынуын, моң-зарын басачак. Шәһәрне шәһәр халкы төземи, бабай, авыл кешесе төзи. Күңеле ятмый крәстияннең шәһәргә, аңа һаман авыл кирәк.

— Син үзең дә авылныкы мәллә соң, улым? — дип сорап куйды Зыятдин карт.— Бик моңлы бала күренәсең.

— А-выл-дан. Авылдан булмасам, болай иттереп йөрер идеммени мин?! Инде күптән кандидатскийны яклап, университетта укытыр идем. Ә миңа һаман шушы читән казыклары, чүплек башлары кирәк. Күңелем шунда тарткач, нишлим? Авыл белән шәһәр арасындагы бәйләнеш, бердәмлек һәм каршылык проблемалары кызыксындыра мине. Буш проблема, әйе бит, бабай? Кирәксез проблема. Авыл кайчандыр барыбер бетәчәк, шәһәрләр үсәчәк, аларның саны көн саен арта барачак. Баш архитектор да, бүтәннәре дә көн саен шул сүзне колакка тукый. Ә миңа — алар белән яшисе. Баш архитектор Урманов — минем оппонент. Урындагы материалны, проблемаларны б-и-ик яхшы белүче кеше буларак, ВАКта аның сүзе күп нәрсәне хәл итәчәк. Ә ул миңа каршы чыгачак. Аңлыйсыңмы, бабай, каршы чыгачак. Менә шулай итеп мин фәннәр кандидатына кандидат булып кала

бирәм. Бернәрсә дә кыра алмаячагыңны белгән килеш, дошманнарың белән көрәшкәнең булдымы синең, бабай?

Зыятдин учакны болгатты да тирән итеп көрсенде, туры җавап кайтармады.

— Без күргәнне дошманыңа күрсәтмәсен, улым. Баш исәнгә сөенеп үтте инде безнең бөтен гомер. Син әле яши генә башлыйсың, синең әле барысы да алда...

— Алда... алда...— дип, ачулы мыгырданды Нурислам.— Алда диеп күп алдадылар инде безне. Аңламыйсыз ла сез мине! Сәбилә булып Сәбилә...— Ул, сүзен әйтеп бетермичә, ярты җөмләдә өзелеп калды.

Зыятдин карт каралып яткан кисәүгә таягы белән сугып куйды. Атау өстенә сиздермичә генә агылып төшкән эңгер көлтә булып күтәрелгән елгыр очкыннарны ымсындырып өскә алып менеп китте дә кочагына кысып сүндерде.

— Менә бу атауда һәммә нәрсә җиңел аңлашыла. Күч соң монда, бергә яшәрбез.— Зыятдин карт Нурисламга хәйләкәр караш ташлады.— Кем тыя сине?

— Юк. Бу бәләкәй генә атауга бер бәхетсез философ җитеп ашкан... Аннары киләсе язда барыбер китәргә туры киләчәк моннан.

— Ничек китәргә? — Зыятдин карт, үзе дә сизмәстән, кычкырып җибәрде.

— Ташлыяр халкын яңа җиргә күчерәләр, дип әйттек түгелме соң?

— Ташлыяр халкы күчсен. Минем аларга ни катнашым бар? Ташлыяр — үзенә, мин — үземә. Мин колхозга кермәдем бит. Мин атаудан башка яши алмыйм.

— Хәзерге заманда үзең генә яшәп булмый,— дип сүзгә кушылырга булды Ихтыяр.

— Яшим бит әле. Моннан ары да яшәрмен.

Ихтыяр аның теләсә дә, теләмәсә дә яз көне барыбер моннан күчәргә мәҗбүр булачагын, үз проектлары расланмаган очракта да, барыбер атауның ял зонасына кергәнен бабасына әйтергә теле, ләкин болай да яралы күңеленә тоз салудан, соңгы ышанычын тартып алып, бөтенләй өметсезлеккә төшерүдән курка иде. Зыятдин карт үзе дә атауның соңгы көннәре якынлашканны күңеленнән сизә, тик аны үҗәтлек пәрдәсе артында качырып тота. Аларның шулай, качышлы уйнагандай, бу теманы читләтергә тырышуларын күреп торган Нурислам, итагатьмазар тотмыйча, һаман шул турыда сөйли, авырткан җиргә кагылудан ләззәт таба иде.

— Безнең проект буенча атауда нәрсәләр каралган әле? — дип, Ихтыярга сорау бирде ул.— Хәтерем ялгышмаса, тегермәнне ресторан итеп көйләмәкчеләр. Билгеле, аны чистартырлар, кырыена терәп яңа бина салырлар. «Иске тегермән» рестораны! Шәп яңгырый бит! — Нурислам яр читенә килеп басты да, кулы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, кызып сөйләргә тотынды:— Яргычны сыра яратучыларга бирәбез. Элек аның теге түгәрәк идәнен ике үгез әйләндерә иде, диденме әле, бабай? Шул түгәрәк идәнгә өстәлләр тезеп куясың да электр моторы белән әйләндерәсең. Останкино манарасындагы ресторанның бер кырыйда торсын! Сушилкаңны да буш калдырмыйбыз, бабай, борчылма. Сувенирлар кибете булыр анда. Аның җиз иләк төсле идәне үзе генә дә ни тора!

— Мәкәрҗә ярминкәсеннән кырык пот тары ярмасына алыштырып кайттым мин аны! — Зыятдин картның тавышында бу юлы ачыну сизелмәде.

Ул, учак янында утырганын онытып, хыялында үзенең егет чакларына әйләнеп кайттымы, әллә инде атауның котылгысыз язмышы белән килештеме — кинәт кенә сабырланды. Гүяки Зыятдин карт моннан илле еллар элеккеге борчу-мәшәкатьләр, кайгы-шатлыклар белән яшәгән-яшәгән дә, кинәт кенә күзе ачылып китеп, үзенең хәзерге халәтен аңлаган, көрәшеп маташуның мәгънәсез икәнен төшенгән һәм каршысында торган котылгысыз ачы хакыйкатьне чарасыз кабул иткән иде.

Менә ул авырлык белән урыныннан торып тегермән ягына таба китте. Тал башындагы каргалар каркылдашуын шомланып тыңлады, яргыч ишеген шыгырдатып ачып япты, сушилканың күгәргән йозагын тотып карады. Ихтыяр исә күмер өстендәге шашлыкны әйләндерә-әйләндерә аның һәр хәрәкәтен күзәтте. Нурислам да тынып калган, аның йөзе учактагы күмер яктысыннан куркыныч кызыл төскә кергән иде. Зыятдин картның исә күңеле чынлап торып кузгалган, ул, җанына тынгылык таба алмыйча, кая бәрелергә белми йөри дә йөри. Ниһаять, ул учак янына килеп туктады да Нурисламның җилкәсенә таяк очы белән кагылды.

— Тегермәнгә, яргычка урын тапкансыз. Башыгыз эшли икән, булдыргансыз. Мине кая куярга булдыгыз соң? — Аның еламсырап чыккан әрнүле тавышында үпкә дә, рәнҗү дә бар иде.— Ресторан төбен каравылларга куясызмы?

— Анысы өчен кайгырма, бабай. Урамда калмассың,— дип тынычландырырга ашыкты аны Ихтыяр.

— Әтиең белән бер түбә астында яши алмыйм мин. Теләсә нәрсә эшләтегез, әмма аның сүзен җөпләп утыра алмыйм.

— Ә минем белән? — дип сак кына сорады Ихтыяр.

— Ә син үзең кайда яшәмәкче буласың?

— Анысын күз күрер.

— Күз күрер дә күз күрер! — Зыятдин карт ачуын Ихтыярга күчерде.— Әтиең сүзеннән чыга аласыңмы соң?

— Язга миңа фатир бирергә вәгъдә иттеләр. Күчәсеңме минем янга, бабай?

— Әтиең үз яныннан җибәрми сине. Әниең дә кайтуыңа сөенеп бетә алмый. Килен нәрсә дияр бит?

— Әгәр дә аларны ризалатсам?

— Күз күрер әле...

— Һем...

Дүртәүләшеп, тал башындагы каргалар куркырлык итеп көлеп җибәрделәр.

Бабасының кистереп каршы булмавын, әгәр дә нык-лап кыстаса, күндерә алуын күңеле белән сизеп сөенде Ихтыяр. Ул аны атаудан китәргә теше-тырнагы белән каршы төшәр дип уйлаган, шуңа күрә бу сүзне кузгатырга кыймыйча йөргән иде. Күңеленә тулган сөенечне тыя алмыйча, ул, арадагы иң мул шампурларны ут өстеннән алып, берсен бабасына, икенчесен Сәбиләгә тоттырды.

Сәбилә, шампур тимерен очлы башы белән җиргә кадап, ике кулы белән тезләрен кочаклады. Кисәк искән җил учактагы күмерләрне кызарткан саен, аның күзләрендә дә шомлы кызыллык кабына иде.

— Тешем юк бит минем, үзегез генә ашагыз,— дип кеткелдәде Зыятдин карт.— Әллә миңа әнә теге чәйнәми йота торганны әзрәк кенә тамызасыңмы соң, улым? Беткән баш беткән, егерме ел тоткан уразаны бозыйм әле. Мондый егетләр, кызлар белән әллә тагын утырырга туры килә, әллә юк...

— Дөр-рес әйтәсең, бабай! — дип куәтләде аны Нурислам.— Болай булса, утырабыз әле синең белән! Ләкин бу атауда түгел, бүтән җирдә, шәһәрдә.

— И-их, имансызлар,— дип сузды Зыятдин карт һәм, йөзен бераз чытып торгач, рюмканы төбенә кадәр бушатып куйды.

Сөйләшеп, үпкәләшеп, бәхәсләшеп, тагын килешеп утыра торгач, бөтенләй башка уйлар, башка хыяллар белән янып яшәгән, дөньядан уен-кызык, көлке-кәмит эзләп кенә түгел, ә җир кайгысын, ил кайгысын кайгыртып борчылган шушы ямь-яшь кешеләрнең дәрте аңа йога башлаган кебек булды. Ул, авыл белән, колхоз белән көрәшеп үткән елларын кызганып, бүгеннән үк башкача яши башларга, хәтта хәзердән үк шәһәргә күчеп китәргә ризалашыр сыман тоелды. Менә Зыятдин карт, аякларын ипле итеп бөкләп, чирәмгә утырды да калтыравык тавыш белән җыр башлады. Аннары, күңеле тулуданмы, әллә тыны бетепме, кинәт туктады, «и-их!» дип тирән итеп көрсенде. Аның күзләрендә яшь бөртекләрен күреп, Нурислам нишләргә белмичә, янынарак елышып утырды, кулы белән шешәгә үрелде.

— Юк, миңа җитте. Шунысы да каткан күңелне җебетте. Эчтәге бөтен нәрсәне урыныннан кузгатты,— дип сөйләнде Зыятдин карт.

Нурислам үз рюмкасын тутырды да ашыгып эчеп җибәрде. Ихтыяр, чирәмгә чалкан ятып, күзләрен күккә текәде. Йолдызлар, берсен берсе уздырырга теләгәндәй, торган саен яктыра баралар, ай гына, алар янында үзенең зурлыгыннан оялгандай, кая кереп яшеренер урын таба алмыйча, як-ягына карана иде. Югары очта бер этнең бүредәй улаганы ишетелде. «Эт хәвеф килгәндә генә улый. Әллә Ташлыярның күченәсен белә микән?» — дип уйлады Ихтыяр.

Эт улавыннан өркепме, үзара гауга чыгыпмы, тал башындагы карга көтүе, зират каргаларына охшатып, дәррәү каркылдап алды. Ерактан, атау түреннән килгән кебек, Нурисламның аңлаешсыз җөмләләр тезгәне ишетелде. Сәбиләнең генә тавышы чыкмый, ул һаман сүзгә кушылмыйча, утлы күмергә карап онытылып утыра иде. Нурислам бераз сөйләнә дә, башкаларны көтеп тормыйча, үзенә-үзе салып эчә, эчкән саен сүзчәнләнә бара, әле Зыятдин бабайны мактый-мактый кочаклап үбәргә маташа, әле Сәбиләгә карап кычкыра:

— Нигә сөмсерең коелды? Ихтыяр үпкәләтте мәллә? Исең китмәсен өч көнлек завод директоры сүзләренә! Без аның янына килмәдек, Зыятдин бабай янына килдек. Ул — буйдак, аның шул цемент чокырыннан башка бер нәрсәсе дә юк. Кеше белән аралашмый, ачылып сөйләшми. Чөнки алай яшәве уңайлырак. Кеше белән дуслашсаң, ул сиңа

өстәмә мәшәкать тудыра бит. Аның турында уйларга, кайгыртырга кирәк була. Ә үзең генә — хөррият! Дуслар да юк, дошман да юк. Бары тик — үзең. Үзең, үзең!

— Кайтыйк инде, балалар көтеп арыганнардыр,— дип, Сәбилә аның терсәгенә кагылды, ләкин ире борылып та карамады, Зыятдин бабайга нидер сөйләвендә булды...

— Ба-бай, син... ге-ни-аль-ный кеше! Мин синең турында китап язам... Юк, докторлык диссертациясе язам! «Атау теориясе» дип аталачак ул... Сине мин ачтым, бабай... Яңа теория... Атауизм...

Нурислам Зыятдин картка таба кулларын сузып торырга маташты да капчык кебек яңадан җиргә авып төште.

— Арыган ул... Өйгә алып кереп яткырырга кирәк,— дип, Зыятдин карт Нурисламның башыннан сыйпады, уятырга тырышып, иңнәреннән селекте.

Ихтыяр аны култык асларыннан тотып торгызды да кочаклап өйгә кадәр алып менде, чишендереп караватка яткырды, эчәсе килеп уянса дип, янына кружка белән су куйды. Аннары, утны сүндереп, ишегалдына чыкты, атлый-йөгерә тегермән янына төште. Бабасы хәлсезләнгән учакка карап берүзе моңаеп утыра иде.

— Сәбилә кайда? — дип кабаланып сорады Ихтыяр һәм яр буена йөгереп килде.

— Кайтып китте ул. Балалар өйдә үзләре генә калды, ди. Нурисламның җебеп төшүенә дә гарьләнде. Кич буена бер җылы сүз дә әйтмәде бит ул аңа. Акыллы гына егет үзе. Бөтен дөньяны кайгыртып сөйләшә, янәшәсендәге хатынының күңелен күрергә оныта. Хатын-кызның күңеле өрфия калынлыгы гына бит аның. Сәгать ничә әле, улым? Уникене уздымы? Нишләптер Чулак Хәйретдиннәрнең әтәчләре кычкырмады... Төнге уникедә шәрран ярып кикрикүк әйтә торган гадәте бар иде. Әллә суйдылар инде. Әхмәт көндез инешнең теге ягыннан пычак тотып узды. Клубта да пәри туе ясамадылар бугай бүген шәһәрнекеләр. Төнге берләрсез туктамыйлар иде бүтән көннәрне. Ә-ә, Саимәне кияүгә чыга, дигәннәр иде. Мөшкә Фәйзи кызын. Шул бит хәзер завклуб. Ачмагандыр.

— Сәгать беренче киткән,— дип көрсенде Ихтыяр.

— Сәбилә өчен борчылып торам әле. Юкка җибәрдем. Ерак китмәгәндер. Әллә артыннан барасыңмы соң, улым? Төн уртасында кыз бала юлына кем очрамас. Яңа шәһәрдә кешенең төрлесе бардыр.

Ихтыяр үзе дә Сәбилә артыннан йөгерергә атлыга, ләкин нәрсәдер аны тыеп, туктатып тора иде. Бабасының сүзләрен ишеткәч, ул кинәт кенә җиңеләеп киткәндәй булды һәм, инешне чыгып, юлга туры кистереп йөгерде. Атау өстендә аның: «Киттем!» — дигән авазы гына эленеп калды.

Авыл башына чыгып җиткәндә, аны фараларын сүндергән машина узып китте дә күз күреме җитәрлек ара узгач туктады. Кабина ишеге ачылып, машинага кемдер утырды. «Сәбилә» дип уйлады Ихтыяр һәм аякларын өстери-атлап бара башлады. Кинәт кенә аңа бөтен дөнья бушап калган, мәгънәсен югалткан кебек тоелды. Машина озак бармады, басу уртасында туктады. Ихтыяр җанфәрманга шунда таба йөгерде. Килеп җитәм дигәндә генә, машина әрҗәсеннән ике егет сикереп төште дә аңа ташланды. Берсе йодрыгы белән ияк астына китереп кундырды, икенчесе, кизәнеп, эченә сукты. Ихтыярның күз алдыннан утлы шәүләләр йөгереп узды, һәм ул йөзе белән бетон юлга капланды.

Аңына килгәндә, ул машина кабинасында утыра, Сәбилә йомшак куллары белән аның битендәге тузанны сөртә иде. Шоферны танып алгач, ул кан саркыган иреннәрен авырлык белән ачып елмайгандай итте.

— Фаил,— дип шатланып пышылдады ул.— Син каян килеп чыктың?

Фаил нәрсәдер урлап тотылган кеше шикелле кызарынды-бүртенде, ләкин авызында аңлаешлы сүз әвәли алмады. Аның өчен Сәбилә җавап бирде.

— Син аны беләсеңмени? Теге бандитларны шушы шофер алып килгән инде.

— Нинди бандитларны? — дип сорады Ихтыяр. Ул әле һаман тулысынча аңына килеп җитә алмаган иде.

— Сине кыйнаган...

Ихтыяр шунда гына теге ике егетне искә төшерде, аптырап Фаилгә күтәрелеп карады.

— Кайда соң алар?

— Качтылар,— дип җавап бирде Сәбилә.

— Минем ни кирәгем чыкты икән соң аларга? Юлларына кайда аркылы төшкәнем булды икән?

— Белмим...

— Сезнең ирегез белән бутаганнар аны...— Фаил, йөзен яшерергә теләгәндәй, шакмаклы фуражкасын кашларына кадәр батырып киде, авызындагы кабызырга өл-

гермәгән сигаретын урталай сындырып тәрәзәдән ыргытты.

— Ә минем ирем нигә кирәк булган?

Ихтыяр, эшнең нәрсәдә икәнен бераз гына төшенә башлап, Фаилгә ярсып җикерде:

— Туктат машинаңны!

Машина теләр-теләмәс кенә туктап, мотор тавышы тынып калуга, ул Сәбиләне тупас кына читкә этәрде дә, Фаилнең якасыннан тотып, йөзенә китереп сукты.

— Сезмени әле ул Каенсар патриотлары? — дип ешеш сулап, тагын кизәнергә маташты ул.

Сәбилә аны шытырдатып кочагына алды да ычкындырмый торды. Ихтыяр, кочакта эреп, тынычланды. Сәбилә аннары, юри тупас кыланып, көч белән урынына утыртып куйды. Фаил башта нишләргә белмичә тик утырды, аннан авызындагы канны тәрәзәдән түкерде дә, Сәбилә аша үрелеп, Ихтыярның якасыннан урап алды, шактый вакыт яканы җибәрми тотты, әмма сукмады. Яканы кулыннан ычкындыргач, ул еламсырап такмаклый-такмаклый сөйләргә тотынды:

— Нигә безнең авылны гына суга батырдыгыз? Нигә Сосновканы дамба корып саклыйсыз? Нигә Ташлыярны күчермиләр? Чөнки Сосновкада министрның әти-әнисе яши. Зиратларында министрның әби-бабасы күмелгән. Ә безнең әби-бабага сан юк. Ташлыярны күчертмәү — Нурислам белән сезнең эш. Авызын төясе бар әле ул елан телнең! Бәхете, бүген юлга чыкмаган. Сезгә дә чират җитәсе иде...

— Мин чиратны үткәрдем инде, алайса,— диде Ихтыяр.— Ә нигә бу турыда баштарак әйтмәдең? Авызыңа су кабып йөрдең? Алабута орлыгы кебек, кая барма, шунда күзгә керәсең бит үзең.

— Башта без бөтен авылларны да бер язмыш көтәдер дип уйлаган идек. Соңыннан гына белдек: хәзер кешеләрне генә түгел, авылларны да аералар икән.

— Ә синеңчә, бөтенесе дә су астында калса, бөтен нәрсә берьюлы кырылып бетсә, яхшы буласы икән. И-их, Фаил,— дип, якаларын төзәткәләде Ихтыяр.— Аңлыйм мин синең хәлне, ләкин детектив кинодагы шикелле авыл үчен кешедән алып йөрүең белән килешә алмыйм. Нишләсәң дә кайтмый инде хәзер Каенсар. Калганнарын саклау турында уйларга кирәк. Кызган баштан нәрсә эшләмәс кеше. Бер тотынгач, уптым илаһи рәттән кырып ба-

рырга өйрәнгән бит безнең халык. Ә Каенсарның язмышына ни катнашы бар Нурисламның?

— Ул моннан берничә ел элек, төзелеш башлануның беренче көннәрендә үк, перспективалы һәм перспективасыз авыллар турында газетада мәкалә бастырган иде. Шул мәкаләсендә безнең авылны «перспективасыз» дип атаган. Егетләр җыелышып клубта укыдык без аны. Шул көнне кул астына эләккән булса, күрер иде күрмәгәнен... Кем хокук биргән аңа безнең авылны хөкем итәргә? Нинди җинаять эшләгән әле безнең авыл? Каян килгән прокурор ул?

— Каенсар зиратын сөрдерткән бульдозеристны да сез тәпәләдегезме? Тагын кемнәрдән үч алмакчы буласың инде, исемлегегез зурмы? — дип сорады Ихтыяр.

Фаил җавап бирмәде, Ихтыяр соравын кабатлады.

— Ул үзе гаепле...— дип, авыз эченнән генә мыгырданды Фаил.— Тимәсен иде Хәйретдин бабайга...

— Бабайга нәрсә булган?

— Хәйретдин бабай айга якын зираттан чыкмый яшәде. Туксанның аръягында инде ул, акылы җиңеләя башлаганмы — «Авыл күчә» дигәнне зиратка күчә дип аңлаган бугай. Алдан ук үзенә урын алып куярга булган, ахры.— Фаил каш астыннан гына Ихтыярга астыртын караш ташлады.— Бульдозер килгәнне күрүгә, каршысына чыгып баскан. Трактор уңга борыла — ул да уңга, трактор сулга каермак була — ул да сулга атлый. Шактый шулай бер-берсен үртәшеп бөтерелеп йөргән болар. Бульдозерчы егет түзмәгән, кабинадан сикереп төшкән дә бабайны күтәреп алып зират читенә чыгарып куйган. Ул кабинасына менеп утырганчы, Хәйретдин бабай үрмәләп килеп бульдозер алдына чыгып яткан. Егет, бабайны куркытырга теләп, моторын үкертә-үкертә килә икән. Бабайга килеп җитәргә берничә сантиметр гына калгач, аның хәрәкәтсез ятуын күргән дә шыгырдатып тормозга баскан. Сикереп төшеп караса, Хәйретдин бабай үлгән.

— Ай буе нишләп зиратта йөрттеләр икән аны? Туганнары нәрсә караган?

— Ялгыз карт иде ул. Аннары күчәсе авылда кемнең кемдә кайгысы бар? Ата улны, ана кызны белмәде соңгы көннәрдә. Сугыш чыккан, диярсең. Халык ерткычланды. Хәйретдин бабайның үлүе турында кемдер урамга чыгып кычкырган да, бөтен авыл белән зиратка йөгерде-

ләр. Шәһәрдән милиция килеп өлгермәсә, белмим, исән калган булыр идеме икән ул егет.

— Тапкансыз үч алыр кеше. Аңа кушканнар. Сиңа кушсалар, син дә барыр идең.

— Юк, мин зиратка тия алмыйм. Куркам мин аннан, бернәрсәдән курыкмыйм, ә зираттан куркам.

— Яшисең килә синең, шуңа куркасың, зираттан түгел, үлемнән куркасың. Урам хулиганнары сез! Бандитлар!

— Мин — пас,— дип, ике кулын як-якка җәйде Фаил.— Башкалар өчен җавап бирмим, һәркемнең үз акылы. Ә мин уеннан чыгам...

— Әйдә, кабыз машинаңны, син урлап китәргә җыенган кәләшне өенә илтеп куябыз,— дип, бер ачусыз гына эндәште Ихтыяр.

Машина туктауга, Ихтыяр Фаилгә кулын сузды.

— Егет сүзе бер булсын, моннан ары партизанлыгыңны ташлыйсың! — диде ул кистереп.— Гаврикларыңа да әйт. Ишетсен колагың! Ярый әле миңа эләктең. Нурислам булса, күрсәтер иде күрмәгәнеңне! Бу якларны сагынып хатлар гына язар идең аннары.

Фаил моңсу гына елмайды. Ихтыяр Сәбилә артыннан сикереп төште дә тузан туздырып китеп баручы машина артыннан йодрык күрсәтеп кычкырып калды...

— Кара син аны, ә... Хуш, авылым!

— Ә син нигә төштең? — дип сорады аннан Сәбилә, подъезд төбенә килеп җиткәч.— Хәзер нәрсә белән кайтасың инде?

— Белмим.

— Әйдә, керик, алайса. Бу килеш кеше күзенә күренсәң, Сәбилә өчен сугышкан, дип, иртәгә үк бөтен шәһәр күзеңне ачтырмас.

Ихтыяр бары шунда гына бөтен киеменең тузанга батканын, чалбарының тез турыннан ертылып чыкканын күрде. Ярылган ирене авырттырып тартыша, сөйләшергә комачаулый иде.

— Төнлә... кем күрсен... Өйгә кайткач, карармын...— дип авыз эченнән мыгырданды ул.

— Минем аркада шундый хәлгә калгансың икән, үзем кеше итәм инде сине,— диде дә Сәбилә аны җитәкләп икенче катка алып менде.

Аяк очларына гына басып аргы бүлмәгә уздылар. Сәбилә Ихтыярга Нурисламның халатын китереп тоттырды да балалар бүлмәсенә кереп китте.

Өй тып-тын, бары тик тәрәзә артында тонык гүләү авазы ишетелә һәм йолдызлы күк фонында төзелеш утлары күренә. Ихтыяр әле үзенең тузанга баткан киемнәренә, әле Нурисламның халатына карап миңгерәп торды. Моңа кадәр һәрчак үзенә тартып торган бу фатир аңа ят та, салкын да булып тоелды. Ул, ниндидер ярамаган эш эшләгән кеше сыман, үзеннән-үзе тартына, ләкин ни кылырга, ни чара күрергә белмичә, башын иеп диванда икеләнеп утыра иде.

— Китим мин,— дип арыган тавыш белән эндәште ул Сәбиләгә.— Никтер күңел тыныч түгел.

— Син түгел, әле һаман мин тынычлана алмыйм,— диде дә Сәбилә аның янәшәсенә диванга килеп утырды. Кулындагы кәгазь тартманы ачып, дарулар актарырга тотынды.— Нәрсә уйлап тапканнар бит, ә! Кино карау файдасы инде бу. Аларның авылын Нурислам белән син су астына җибәргән дип уйларсың... Милиция нәрсә карыйдыр? Әллә төнлә урамга чыгарга шүрли инде алар?..

— Алар да үзләренчә хаклы инде.— Ихтыяр, төшендә күргән су асты авылын хәтерләп, тынып калды. Сәбиләгә бу турыда сөйләргә дә, сөйләмәскә дә белмичә, беркавым икеләнеп торды.— ГЭС салмыйча, бу шәһәрне, төзелешне энергия белән тәэмин итеп булмаганны аңларга да теләми алар. Су бастырмыйча гына төзи алмыйбыз шул әле. Алай төзергә өйрәнмәгән. Ашыгабыз, кабаланабыз. Бу егетләр түгел, утыз елдан артык колхоз председателе булып эшләгән әткәй дә кабул итә алмый әле ул ГЭСны. Җай чыккан саен гел шуңа каныга. «Сугыш вакытында утын булмагач, бөтен каралты-кураны, хәтта өйдәге җиһазларны да ягып җылынды халык. Бөтен дөньясы шып-шыр калсын, тик исән генә булсын, тик дошманга гына җиңелмәсен. Без дә хәзер иң уңдырышлы басуларны, билдән печәнле болыннарны ягып җылынабыз түгелме икән?» — дип сорады ул беркөнне миннән.

Төн уртасында икәүдән-икәү генә калып, шундый сүзләр тыңлап утыру Сәбиләгә гаҗәп тә, мәзәк тә тоела иде.

— Болай булсаң, утыз яшь тулганда беренче инфарктны алачаксың син...— Сәбилә, аның сүзен бүлдерергә теләгәндәй, юеш мамык белән Ихтыярның иреннәрен чылатты.— Каяле, берәр матуррак сүз чыкмас микән бу авыздан. Нурислам да төннәр буе фәнни трактатлары белән саташып тилмертә. Барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән икән сез.

Сәбилә шулкадәр ягымлы итеп, күңелне иркәләп ачулана иде, Ихтыяр аны рәхәтләнеп тыңлады. Ул әкренләп үз гәүдәсенең җиңеләя баруын тойды, тәнен кызыштырып бер-бер артлы кайнар дулкыннар йөгереп уза башлады, куллары, аңа буйсынмыйча, ирексездән алга тартылды. Шулчак күрше бүлмәдә Рәйхананеңме, Ринатныңмы саташып нидер кычкырганы ишетелде. Тавыш тынгач, икесе дә, суларга курыккандай шактый ара хәрәкәтсез утырдылар. Ихтыяр, гаепле кыяфәт белән сәер елмаеп, Сәбиләнең күзләренә карады. Куе коңгырт күз карашында бераз курку да, гаҗәпләнү дә, менә-менә ташып чыгарга торган тыелгысыз хис тә, аңлатып һәм аңлап булмый торган астыртын киная дә бар иде сыман. Ихтыяр, баш әйләндергеч бу караштан качарга уйлап, күзләрен аның кулларына күчерде. Сәбилә, күңелне оета торган хәрәкәтсез тынлыктан котылырга теләп, кабаланып, аның иреннәренә йодлы мамык каплады. Ихтыяр сискәнеп китте, әчетүдән йөзе җыерылып килде. Ул Сәбиләнең кулын шытырдатып кысты да йодлы иреннәре белән сак кына бармакларыннан үпте. Сәбилә бөтен тәне белән калтыранды, беразга югалып калды һәм, бик тиз һушына килеп, кулын кисәк кенә тартып алды.

— Нурислам...— дип пышылдады Сәбилә.

— Ихтыяр минем исем...

— Беләм, беләм... Мин ул турыда түгел... Нурислам...— дип йотлыга-йотлыга нидер әйтергә маташты Сәбилә, ләкин тамак төбенә килеп терәлгән төер ирек бирмәде.

— Мин китим, алайса,— дип тагын торып басты Ихтыяр.— Көтәләрдер, борчылып торалардыр.

— Кем көтсен сине бу вакытта?! Бөтен дөнья йоклый хәзер. Теге бандитлар көтсә генә инде. Юк, юк, бу вакытта урамга чыгарып җибәреп, төне буе ут йотып чыгасым килми...

— Ә Нурислам? Ул нәрсә уйлар? — дип, кырыс кына сорады Ихтыяр.— Болай да...

— Уйласа, кайтсын иде. Ул анда бер кайгысыз йоклап ята. Ә син аның өчен җәфа чигеп йөрисең.

— Нинди җәфа булсын! Бәлки, миңа шулай рәхәттер? Бәлки, мин махсус синең арттан килгәнмендер...

Сәбилә аңа җавап бирмәде, тавышсыз-тынсыз гына күрше бүлмәгә кереп китте.

Ихтыяр залдагы диванга сузылып ятты да, ике кулын баш астына куеп, уйга чумды. Бүгенге көн аңа ел

кебек озын булып тоелды. «Мәҗлес мин теләгәнчә барып чыкмады,— дип уйлады ул.— Бәйрәм ясый белмим икән мин кешегә. Эшләргә, эшләтергә өйрәнеп киләбез, ә бәйрәм ясарга маһирлык юк. Мәҗлестә дә гел эш турында сөйләшәбез. Димәк, авыллык чыгып бетми һәм бетмәс тә инде. Авыл халкы беркайчан да ял итә белми бит ул. Гомер-гомергә бөтен бәйрәмнәре эш белән бергә узган аларның. Каз өмәсендә иртәдән кичкә кадәр каз йолыкканнар, кич утырганда тула басканнар, җеп эрләгәннәр, челтәр бәйләгәннәр, аулак өйдә бөтен өйне җыештырганнар. Бәлки, дөрес эшләгәннәрдер? Эштән кызык тапкан алар, эштән бәйрәм ясаган. Ә без хәзер эшсезлектән бәйрәм ясыйбыз».

— Будильник куярга кирәк түгелме? — Күрше бүлмәдән Сәбиләнең тавышы ишетелде. Ул Ихтыярның борсаланып ятуын ишеткән, йокыга китә алмавын сизгән иде.

— Кирәкми, болай да уяныРмын. Йокыга китеп булса.

— Кайчандыр булган иң-иң рәхәт бер вакыйганы уйла да кымшанмыйча тик ят. Йокыга киткәнеңне сизмәссең дә. Мин гел шулай итәм.

— Сер булмаса, нindирәк иде соң ул синең иң-иң рәхәт чагың?

Сәбилә, әйтергәме, әйтмәскәме дигәндәй, шактый сүзсез торды.

— Урынсыз сорау бирдем бугай.

— Ир-ат аңлый торган нәрсә түгел ул. Ринатны тапкач, иң беренче тапкыр миңа күрсәткән чак. Андагы рәхәтне сүз белән генә аңлатып бетерерлек түгел. Шуңа кадәр бер атна йокламаган идем. Хәлсезлек белән рәхәтлек икесе бергә килеп кушылгач, күңел кошы күккә күтәрелеп очып китә икән. Ә син иң рәхәт чагыңны хәтерлисеңме?

— Әйе...

— Кайчан булды соң ул? Кайда булды?

— Бүген. Хәзер. Монда...— дип пышылдады Ихтыяр.

Шулчак аның бөтен тәне, әле моннан берничә минут элек кенә булганча, рәхәт кымырҗып китте, күз алдына Сәбиләнең күккә күтәрелгән кошы килеп басты да галәмәт зур канатларын җилпи-җилпи аны да үз артыннан ияртте. Шул кош канатларында тирбәлеп бара торгач, ул йокыга талды.

Ниндидер сәер тавышка уянып китте Ихтыяр, сулышын тыеп, әле үзенең кайда икәнен дә аңламыйча, сага-

еп калды. Бала елаганга охшаган өзек-өзек тавыш күрше бүлмәдән килә иде. Ихтыяр, Рәйханә саташадыр, дип уйлап, урыныннан торды да ишек катына килде. Караңгыда кармалана-кармалана түргәрәк узды һәм, эшнең нәрсәдә икәнен төшенеп, баскан урыныннан кузгала алмыйча, бер урында катып калды. Сәбилә баштанаяк юрганга төренгән дә туктый алмыйча үкси иде...

* * *

...Ихтыяр уянганда, кояш инде уналты катлы йортлардан да югарырак күтәрелеп, сынаулы караш белән аның күзләренә карап тора иде.

Ул, урындык башында эленеп торган киемнәрен алып, ашыга-ашыга киенде. Киенеп бетергәч кенә, аларның чипчиста һәм үтүкләнгән икәнен күреп, аптыраган кыяфәт белән як-ягына каранды. Кухняда таба чыжлаган тавыш ишетелә, бөтен өйгә тамак төбен кытыклый торган коймак исе таралган. Юынырга дип ванна бүлмәсенә үтеп барганда, ул әле йокыдан уянып җитмәгән карлыгулы ят тавыш белән Сәбиләгә эндәште:

— Хәерле иртә!

Эндәште дә, үзенең тупас тавышыннан үзе оялып, кыяр-кыймас кына аңа күтәрелеп карады. Сәбиләнең йөзе бөтен кухняга, кухняга гына түгел, бар дөньяга нур тараткандай, балкый иде.

— Хәерле көн, дисәң дә була инде.

— Шулай икән шул. Нигә уятмадың? Балалар кайда?

— Йоклыйлар. Шулкадәр рәхәт итеп йоклый идең. Уятырга кызгандым. Нәкъ сабый бала кебек инде, гөнаһсыз сабый бала кебек.

— Син кызгангансың да, өйдәгеләр кызганыр микән менә. Минем турында ни уйларга да белмиләрдер инде.

— Бераз башларын ватсалар да ярар. Кадерең генә артыр. Әнә, Нурислам кайта да бугай...

«Нурислам кайта» дигән сүзләрне ишетүгә, ул кинәт кенә тынычсызлана, борсалана башлады. Сәбиләнең, аз гына да исе китмичә, һаман шулай кухняда тыныч кына эвәрә килүенә аптырап, кая сугылырга белмичә әле тәрәзә каршына барды, әле күлмәк якаларын бер әләктереп, бер ычкындырды.

— Өч чакрымнан ишетелә аның мотоциклы тавышы. Бала-чага сыман шул кәҗә тәкәсенә атланып йөрүен кай-

чан ташлар инде. Кешеләр янәшәңнән «Волга»да җилдереп үткәндә, тыр-пыр килеп тузан эчендә мотоциклда чап-чап та, аннары үзеңне хөрмәт итүләрен, синең белән хисаплашуларын көт.

Сәбилә, Нурисламның кайтуын өнәмәгәндәй, табадагы коймагын әйләндергән җайга үзалдына сөйләнде. Ихтыяр аның сүзләрен ахырына кадәр тыңлап бетермәде, балконга чыкты. Буш юл буйлап җан-фәрманга чабып килгән мотоцикл, өй каршына җитәргә берничә метр калгач, кисәк кенә туктады да, тирә-юнь яңадан тынлыкка чумды. Нурисламның шешенгән кызыл йөзенә карап, Ихтыяр арткы утыргычтагы кешегә игътибар итмәгән иде, аны күреп, танып алгач, йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды һәм, аптырап, сүлпән генә кулын селкеде:

— Зәлия...

Ул Зәлияне күрүенә шатлана да, куана да алмый, аның шулай көтмәгәндә килүенә шаккатып, гаҗәпләнеп тик басып тора иде. Нурисламның, мотоциклын аягына бастырган арада, янтаеп, балконга күз төшергәнен күргәч, ул, аңардан качкандай, кухняга таба китте.

— Нурислам кайтты. Зәлия килгән,— диде ул, ниндидер зур бәла турындагы авыр хәбәрне җиткергән аваз белән.

Сәбилә, исе китмичә генә, табадагы коймакларны әйләндерүендә булды. Ләкин Ихтыяр аның күңеле эчтән актарылганын, менә-менә ычкынып китәргә торган пружинага охшап, бар хисләре тартылганын, күзләрендә кырыс һәм тәкәббер чаткылар кабынганын күрде. Ул аңа яратып һәм өзгәләнеп карап торды да артка чигенә-чигенә коридорга чыкты, авырлык белән генә тышкы ишекне ачты.

Зәлия баскычтан мышный-мышный йөгереп менде. Ихтыяр Зәлияне уңайсызланып кына, теләмичә генә кочагына кысты, бит очларына иреннәрен тидереп алды.

— Миннән качып котыла алмассың! — дип көлде Зәлия һәм бармагы белән Ихтыярның борынына авырттырып басты.— Конспиратив квартирадан гына түгел, җир тишегеннән дә табармын мин сине! Каяле, шома егет, иреңә нәрсә булды синең?

Ишек катында сөмсере коелып басып торган Нурислам ялт итеп Ихтыярның иреннәренә карап куйды.

— Булды инде хәлләр. Соңыннан сөйләрмен,— дип акланырга ашыкты Ихтыяр.

— Юк, юк, соңыннан солы боткасы ашарбыз, ә хәзер миңа, алдарга өйрәнгәнче, чын дөресен сөйлә. Кем тешләде иренеңне? — Зәлия әллә инде Ихтыяр белән күрешүенә чынлап торып сөенә, әллә инде тырышып-тырышып уйный гына иде — моны сизүче булмады. Менә аның түгәрәк йөзе елмаю белән тулды, ул бер сәбәпсезгә көлә, шаяра башлады. Ләкин үзенең ясалма шуклыкларына, шаяруларына кушылучы булмавын, Ихтыяр белән Нурисламның да, беренче тапкыр күрешкәндәй, аптырап сүзсез торуларын күргәч, ул сабырланып калды һәм кухняга кереп китте.

— Без килүне көткәннәр монда!..— дип, Сәбилә белән барып күрешкәч, гомер буе шушы фатирда яшәгән кеше сыман, бөтен бүлмәләрне йөреп чыкты, йоклап яткан балаларның башларыннан сыйпады, киштәдәге китапларны берәм-берәм алып карады. Үзе һаман сөйләнде:— Кичә килә алмадым. Самолетка билетлар булмады. Бүген дә әле көчкә биш тә кырык биштәге почта самолеты белән очтым. Ярый, таныш стюардесса туры килде. Килеп җитсәм, син өйдә юк. Атауга керсәм, анда ике буйдак каңгырап утыра... Поезддан калган пассажирлар диярсең. Минем Ихтыярым сыната торганнардан түгел, берәр юньлерәк җиргә барып оялагандыр, мин әйтәм. Чыннан да шулай булып чыкты.

Ихтыярның Зәлия сөйләгән саен ачуы чыга, йөзе карала бара, бу кирәкмәс һәм урынсыз сүзләрне ишетмәс өчен, ул ванна бүлмәсенә дә, балалар янына да кереп карый, ләкин чәрелдек тавыш аны кайда да куып җитә иде.

Табын янында да берөзлексез Зәлия авазы гына яңгырап торды. Ихтыяр, бу уңайсыз хәлдән котылу өчен, сүзне бүтәнгә борырга тырышып карады, ләкин аны күтәреп алучы булмады, сүзе һавада эленеп калды. Аптырагач, ул Зәлия сүзенә катнашырга булды.

— Кичә кайтсаң, бергәләп бәйрәм иткән булыр идек.

— Кичә килгән булсаң, кунып китәр идең, диләрме әле? — Зәлия бүлмәне яңгыратып көлде.— Зыян юк. Үткән эшкә — салават. Безнең бәйрәмнәр алда әле.

— Нинди бәйрәм ул тагын? — дип, кәефсез генә сорады Ихтыяр.

— Гомердә бер тапкыр гына була торган бәйрәм. Нәрсә, тел яшергән килен сыман утырма инде!

Моңа кадәр сөмсере коелып утырган Нурислам кинәт кенә уянып киткәндәй булды.

— Ай-һай, егетләр-кызлар! — дип торып басты ул.— Ялгышмасам, туй турында сүз бара бугай монда. Ыкмык итеп утырма, егет! Туй булгач туй!

— Туктагыз әле... Нинди туй ди әле ул? Зәлия — анда, мин — монда. Фатир да юк. Эш муеннан, борылырга да вакыт юк.

— Туй булгач, барысы да булыр! — дип кулларын шапылдатты Нурислам. Аның сүрелгән күзләрендә очкыннар кабынды.

Ихтыяр, күзләрен тутырып, башта Нурисламга, аннары Сәбиләгә карады. Сәбиләнең йөзе тартышып куйды, шулай да ул елмаеп сүзгә кушылды:

— Мин шаһит булырга риза! Нигә сөмсерегез коелды әле? Шундый зур вакыйганы, кешеләрнең иң бәхетле, иң рәхәт чагын...— ул Ихтыярга яшен тизлеге белән карап алды,— билгеләп үтәргә кирәк! Юк, болай гына ярамый... Завод реконструкцияләү генә түгел инде бу сезгә! Мәхәббәт...

Сәбилә мини-бардан шәраб шешәсе алды, аны Ихтыяр алдына куйды.

— Ач әйдә, кияү!

Сәбилә гомер булмаганча усалланган, ярсыган иде.

Ихтыяр сул кулы белән яңагына таянды да, шешәгә караган хәлдә, бер хәрәкәтсез тик утыруында булды.

— Кир-рәкми! — дип кулларын җәйде Зәлия.— Һәр нәрсәнең үз вакыты.

Ул исе китмәгән кыяфәт белән җырлагандай итте:

Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану сылуым-иркәм...

— Беркемнән дә качканым юк,— дип башын күтәрде Ихтыяр. Җыр сүзләрен үзенә кабул иткән иде ул.— Качсам да, үземнән генә качам. Качарга тырышам. Ә үзеңнән качып булмый. Зинһар өчен, тимәгез миңа! Бу дөньяда болай да адым саен кеше кушканны гына эшләп йөрим! Башкода булуың өчен рәхмәт, Нурислам! Ләкин юкка тырышасың! Бу мәсьәләне ничек тә үзем хәл итәрмен. Киттек, Зәлия!

Нурислам аңа ашардай итеп карады да, бокалны тутырып шәраб эчеп куйды. Аннары, китегез, дигәнне аңлатып, өстәлгә капланып учлары белән башын кочаклады. Ул хәзер беркемне күрми дә һәм күрергә дә теләми иде.

* * *

Завод реконструкцияләнеп, эшләр үз эзенә төшкәч, Ихтыярның күңеле дә урынына утырган кебек булды. Ул инде хәзер элеккеге кебек төзелешнең бер башыннан икенче башына, бер цехтан икенче цехка, кечкенә генә мәсьәләне хәл итү өчен дә бер башлыктан икенче башлыкка чабып вакыт уздырмый, Казанга, Мәскәүгә дә элеккечә еш бармый. Ихтыяр тәҗрибәле җитәкчеләрдән күреп, үзенең көнен, эш атнасын планлаштырырга өйрәнде. Болай иткәч, мәшәкатьләре дә кимеде, вакыты, киресенчә, иркенәйде. Эмиль Яковлевич больницадан чыккач, үзе икенче планга күчеп, хокуклары шактый чикләнүгә эче пошкан иде, тора-бара анысына да күнекте. Ул кешеләр белән артык якынаймаска тырыша, күпмедер дәрәҗәдә ара саклый, Нурисламнан моның өчен шактый борычлы сүзләр ишетсә дә, үзен хаклы саный иде. Эштә ул һәммәсе белән ачык йөз күрсәтеп сөйләшә, әмма, күпме чакырсалар да, кешегә кунакка йөрми, ара-тирә оештырыла торган аяк өсте мәҗлесләреннән качарга җай таба.

Завод директоры Эмиль Яковлевич боларның барысын да күреп-сизеп, эченә җыеп йөргән икән. Беркөнне эш азагында ул Ихтыярны үз бүлмәсенә чакырып кертте. Сүзне бик ерактан башлады, эш турында сорашты, озаклап гаилә хәлләрен төпченде. Аннары гына күңелендәге уйларны ачып салырга булды.

— Сезне,— дип тынып торды ул бераз,— үзен коллективтан аерып куя, кешеләрдән читләшә, дип әйтәләр. Чынмы бу? — Эмиль Яковлевич бүлмәгә тәмәке төтене бөрки-бөрки кәнәфигә кырын утырып сөйләшә иде.

Ихтыяр җавап бирмәде, әйдә, сөйлә, тыңлап карыйк дигәндәй, сораулы караш белән аңа текәлде.

— Завод капкасыннан чыгуга ук, имеш, сез кешеләрне танымый башлыйсыз. Бер коллективта эшләгәч, эше дә, ялы да бергә булырга тиеш, Ихтыяр Тимерханович.

— Завком рәисе Сәлимов әйттеме? Әйе, мин аның хатынының туган көненә бара алмадым. Ләкин туган көн мәҗлесе бер нәрсә, эшчеләргә дигән льготалы путевкаларны дус-иш, туган-тумача арасында бүлү — бөтенләй башка нәрсә. Аларның икесен бергә бутамаска булдым мин.

— Сез һаман үткән профсоюз җыелышында сөйләгән чыгышыгызны китерәсез дә кыстырасыз. Дөрес, булган андый хәл, кеше ялгышкан. Кирәгеннән артык юмарт-

ланып киткән. Аңа кисәтү ясалды бит инде, ә сез һаман тынычлана алмыйсыз. Цех начальнигы Кривошеин өй туена чакыргач та, бара алмыйм, дип кырт кискәнсез. Килешми, Ихтыяр Тимерханович, завод кадәр заводның баш инженерына килешә торган нәрсә түгел бу. Үзегез кешеләрдән яхшы мөгамәлә таләп итәсез, ә үзегез юкка-барга борын чөясез, кешеләрне санга сукмыйсыз.

— Гомумән, мәҗлесләргә йөрергә яратмыйм мин. Туйган ул исерек мактанышулардан. Завод буенча, конкрет эш буенча претензияләрегез юкмы?

— Завод буенча да барысы да ал да гөл дип уйламагыз. Райкомда башыгыздан сыйпап кайтаргач та, артык үсенеп киттегез бугай. Райком гел уңайга гына сыпырып тормас ул. Болай әтәчләнеп йөрсәгез, шундый итеп тез астыгызга китереп сугарлар, кемгә барып сыенырга белмичә тилмерерсез аннары. Менә шул чакта кирәк булыр кешеләр, менә шул чакта чакырган бер җиргә йөгереп барырдай булырсыз, ләкин чакырмаслар. Әлегә безнең шәһәрдә күңел җылысы табар җир икәү генә: эш һәм өй. Бергәләп театрларга, циркка, зоопаркка, концерт залларына культпоходлар ясар көннәр җиткәнче, безгә бер-беребезнең өендә җыелышып күңел юатырга, бер-беребезнең борчуын уртаклашырга, шатлыгын бүлешергә туры киләчәк. Иңгә-иң торып эшләүче иптәшеңнең өенә кереп хәл-әхвәл белешү, минем үземә калса, һич тә гөнаһ түгел. Эчмәгән кешене яткырып авызына салганны күргәнем юк әле минем. Утыр, сөйләш, көлеш, җырлаш та матур гына саубуллашып чыгып кит.

— Алай йөрергә минем вакытым юк,— дип, ышанычсыз гына әйтте Ихтыяр.

— Үзегез өйләнмәгән кеше. Кичләрен, эштән соң кайда буласыз соң?

— Ял зонасының проекты белән маташабыз бит.

— Ишеттем. Ләкин, күңелегезгә авыр алсагыз алырсыз, дөресен әйтим: юк эш белән шөгыльләнәсез. Перспективасыз эш. Кем дә кем үзенең ванналы, туалетлы, балконлы, газлы җылы өен ташлап, сезнең тавык кетәгегезгә барсын инде?!

— Бүтән шәһәрләрдә дачага йөриләр бит әле.

— Пәри башка, җен башка. Дача бөтенләй бүтән нәрсә ул. Дача аның үзенеке. Ә үзеңнеке һәрчак үзәктә була. Сәлимов ни өчен иң беренче чиратта иң яхшы йорттан иң кәттә фатирны Кривошеинга биргән? Яхшы җи-

тәкче булганы, эше гөрләп барганы өченме? Юк, туган, Кривошеиннан шәбрәк белгечләр су буе чиратта сабыр гына көтеп утыра.

— Монысын барыбыз да беләбез. Сәлимов әшнәлек белән шөгыльләнә, Кривошеинга баҗасы булганы өчен дүрт бүлмәле фатир бирде, дип, җыелышта йөзенә бәреп әйттеләр. Ә сез аны кабинетка чакырып сөйләштегез дә, шуның белән вәссәлам.

— Кешенең ялгышын күрү, кешегә акыл өйрәтүдән дә җиңел нәрсә юк. Менә шул Сәлимовның инде ничә айлар буе эшчеләргә дача салу өчен җир даулап йөргәнен кем белә? Министрлар Советына кадәр барып җитте. Монысына нәрсә дисез? Монысы инде өстәгеләр алдында яхшы атлы булам дип, шау-шу куптарып завод сүтә башлау гына түгел. Монысы инде эшче сыйныф турында чын-чынлап кайгырту.

— Теләсә нәрсә әйтегез, ә завод эшли, элеккегә караганда өч тапкырга артык продукция чыгара, ассортимент күзгә күренеп артты. Ә Сәлимовның җире кайда, дачалары кайда? Булмаган бүрәнәдән бура бурап булмый, диләр безнең авылда.

— Җир булыр. Бер Сәлимовка гына салынып утырганчы, менә шул дачаларга җир алу артыннан йөрергә кирәк безгә.

— Булган очракта да, барыбер һәркем дача салмаячак. Беренчедән, моның өчен җир җитмәячәк, икенчедән, теләсә кемнең кулыннан килә торган эш тә түгел ул. Материалны каян тапсын алар? Менә китәчәк инде аннан урлашу, завод машинасында кача-поса дачага материал ташу. Ә бәхетле киләчәктә яшәргә тиешле яшь буын шушыларны күреп үсәчәк. Хөррият! Ташлыярга тимәгез сез. Күрерсез, Ташлыяр ял зонасы берничә елдан бу якларда мактаулы урыннарның берсе булачак. Халык осталары музеена әйләндерәбез аны,— дип, кызып-кызып сөйләвендә булды Ихтыяр. Ул, бөтен мәшәкатьләрен онытып, тагын Ташлыярның киләчәге белән яши башлаган иде.— Саф һава, парлы мунча...

— Ярый, ярый,— дип бүлдерде аны Эмиль Яковлевич.— Йә тумаган тайның билен сындырырсыз. Сүзем бүтән иде минем. Ял зонасы турында шулай кайгыртып та йөргәч, ял итүнең нәрсә икәнен яхшы белергә тиеш инде сез. Главкадан килгән комиссия иртәгә эшен төгәлли. Төштән соң аларның биш-алты сәгать буш вакытла-

ры кала. Менә шул биш-алты сәгатьне бик тә интенсив төстә ял иттерергә иде. Кунаклар бик дәрәҗәле, дөнья күргән кешеләр. Барысын да уйладык та бу эшне сезгә ышанып тапшырырга булдык. Үзем дә бик теләп барыр идем, сырхаулап торам, бөтен ялларының ямен генә җибәрермен, дип куркам. Нинди тәкъдимнәрегез бар?

Ихтыяр шунда гына директорның ничек оста итеп үзен стенага китереп терәгәнен аңлады. Аның хәйләсенә каршы шундый ук осталык белән җавап бирергә тырышып уйланып торды, ләкин кирәкле сүз таба алмады да, барысына кулын селтәп, турыдан ярырга булды.

— Килгән кунакларны пикникларга алып чыгу, комиссияләрнең җайлап-майлап күңелләрен күрү турында райсовет сессиясендә дә, райком пленумында да бик ачык итеп әйттеләр,— дип, сүзне югарыдан башлады ул.

— Барысын да беләбез. Ләкин монысы бөтенләй бүтән нәрсә бит. Без бит завод исеменнән мәҗлес үткәрергә җыенмыйбыз. Уйлагыз, уйлагыз, нинди тәкъдимнәрегез бар?

— Су буена алып төшәргә. Урманга алып чыгарга.

— Анда нишләтмәкче буласыз аларны?

— Су коенырлар. Гөмбә җыярлар.

— Бала-чагамыни алар су коенып, гөмбә җыеп йөрергә? — дип, өстәлгә уч төбе белән шапылдатып сукты директор. Аннары басынкылана төште.— Без аларны пикникка да алып чыкмыйбыз, майлап-җайлап җибәрергә дә уйламыйбыз. Ике атна завод тузаны эчкәннән соң, табигать кочагына чакырырга, бөтен шәһәрнең горурлыгы булган пионер лагерен күрсәтергә хакыбыз бардыр ла соң безнең? Бу турыда махсус инструкция чыкмады бугай әле. Каен урманы эчендәге пионер лагерен беләсезме? Хәзер үк шунда барып килегез. Азык-төлекне сез яраткан Сәлимов юнәтер, анысы өчен борчылмагыз. Мунчаны ташы шартларлык итеп яксыннар.

— Мин заводның баш инженеры һәм баш инженер вазифаларын үтәүне генә үз өстемә ала алам. Гомеремдә мунча якканым булмады. Безнең өйдә әнкәй шөгыльләнә ул эш белән. Ә мин рәтен белмим,— диде дә ул, директорның ярсыган күзләренә күтәрелеп тә карамыйча, саубуллашып чыгып китте.

«Әллә соң артыграк кыздыммы? Пионер лагеренда барысын да әзерләп куярга да, үземә бармый калырга гына иде. Әллә соң әнкәйгә мунча яктырып, үзебезгә чакы-

рырга кирәк булдымы икән? Ни әйтсәң дә, комиссия членнары гына түгел, читтән килгән кунаклар бит әле алар. Бу як кешеләре бигрәк тар күңелле, дип китмәсләрме? Кунакчыллык борынгыдан килгән гадәт бит инде»,— дип, юл буе үзен талкып кайтты ул.

Өйгә керсә, тагын бер борчу көтеп тора — Ихтыярны судка чакырып повестка килгән иде. Әнисе, нәрсә уйларга да белмичә, аны көтә-көтә кара көеп беткән.

— Юкка кайгырма, әнкәй, шаһит итеп кенә чакыралар мине,— дип тынычландырырга тырышса да, Маһруй апа һаман нәрсәдәндер шикләнә иде.

Ихтыярга суд булачагы турында инде күптән әйтеп куйдылар. Ул, прокуратурага кереп, бу эшне туктатып калырга да тырышып карады, ләкин барып чыкмады. Атаудагы мәҗлестән соң булган хәлләрне Нурислам милициягә хәбәр иткән. Ул моны нинди максат белән эшләгәндер, Ихтыяр күңеле белән сизенсә дә, барыбер аны ахырына кадәр аңлап бетерә алмады. Әгәр дә кирәк санаган булса, бу турыда Ихтыяр милициягә үзе хәбәр иткән булыр иде.

Берничә көн үтүгә, ул инде әлеге хәлләрне бөтенләй оныткан, иренендәге яра да төзәлеп өлгергән иде. Ә Нурислам, бер зыян күрмәгән булса да, онытмаган, теге егетләрне җавапка тарттыруларын сорап, гариза язган. Ихтыярның моны ишеткәч бик тә хәтере калды. Үзенең исемен «суд», «милиция» дигән төшенчәләрдән читтәрәк тоту максатыннан гына чыгып уйламый, егетләрнең яшьлек юләрлегенә, күңелләре рәнҗүдән туган хисләр коткысына бәйләп аңлата иде ул теге төнне булып узган бәрелешне. Судьяга да шуларны түкми-чәчми сөйләде. «Фаилдән аерылгач, сез кая киттегез?» — дигән сорау ишеткәч кенә, дорфа итеп: «Анысының алда сөйләнгән вакыйгага бер катнашы да юк!» — дип сүзен төгәлләргә ашыкты.

...Егетләрнең эш урыннарыннан яхшы характеристика биргәннәр. Ихтыярның да, зыян күргән кеше буларак, үтенечен исәпкә алганнар, ахрысы: егетләргә кисәтү ясадылар да эшләрен иптәшләр судына тапшырырга карар кылып, чыгарып җибәрделәр. Шуларның барысын да Сәбиләгә сөйләргә җыенып телефонга үрелүгә, аның бүлмәсенә Эмиль Яковлевич килеп керде.

— Ихтыяр Тимерханович,— дип, төче елмаеп күреште ул.— Кичәге хәлләрне ишеткәнсездер бит.

— Кичә мин көне буе судта булдым.

— Нәрсә? Судта? Нигә анда? — дип, шикле генә карап куйды директор.

— Шаһит итеп чакырганнар. Беркөнне хулиганнарга юлыккан идем,— дип, директорның күзләренә туры карады ул.— Кичә нәрсә булган? Мин партоешма секретарена шылтыратып судка баруымны әйткән идем. Сезгә җиткермәдемени?

— Мин кичә сырхаулап тордым. Шуңа эшкә чыга алмаган идем. Булган анда хәлләр...— дип авыр сулады Эмиль Яковлевич.— Киреләнмичә үз кулыгызга алсагыз, боларның берсе дә булмый кала иде бит. Хәзер хурлыгын барыбер бөтен завод белән күтәрәбез.

— Аңлатыбрак сөйләгез әле,— дип, өстәл артыннан аның ягына чыгып утырды Ихтыяр.— Лагерьда бер-бер хәл булмагандыр бит?

— Бөтен шәһәр шуны сөйли, ә сез белмәгәнгә салышып утырасыз,— дип кашларын җыерды Эмиль Яковлевич.— Нәрсә булган да нәрсә булган! Нәрсә булсын: мунчаны исле килеш томалаганнар да комиссия җитәкчесенә, главканың бүлек мөдире урынбасарына ис тигән. Мунчада аңын югалткан. Тотарга да тиз генә машинага салып, больницага илтергә иде бит үзен. Ә бу күчән башлар мунчага «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырткannар. Кайсысының акылы җиткән диген. Шамкаев үз исеменнән кунакларның күңелен күрү өчен, баш архитектор Урмановны кодалаган булган. Янәсе, андый мәсьәләләрдә шомарган кеше. Ә тегесенең хатыны «скорый»да врач булып эшли икән, каһәр. Әллә инде иренең шунда булуын чамалап, әллә карурман мунчасын күрәсе килеп, диспетчердан чиратсыз заявка алып, үз теләге белән чыгып чаба бу лагерьга. Билгеле, килеп җитүгә үк, капка төбендә иренең машинасын күреп ала. Мунчаның алдагы ял бүлмәсендә комиссия җитәкчесенә ашыгыч ярдәм күрсәтә дә ире турында сораша. Барысы, куркышып, иңбашларын гына җыерып куялар. Моның күңеленә шик төшә дә Сәлимовтан ирен таптыра башлый. Әгәр кайда икәнен әйтмәсәгез, иртәгә үк бу хәлләрнең барысын да райкомга җиткерәм, дип, санитарка белән шоферны да шаһит буларак банкет залына чакырып кертә. Ә Сәлимовка шул җитә кала, коты ботына төшә мескеннең. И-их, теге чакта сезнең сүзне тыңлап, персональ эшен парткомга куясы калган... Бу җебегән авыз Урмановның хатынына серне чишә. Хатын истерикага бирелә, алан чи-

тендәге әкият йортына барып, теге тавык тәпиендә утыра торган бәләкәй йортка, ишек дөбердәтә башлый. Ачып җибәрсәләр, эчтә — Роберт Маратович үзенең секретаршасы белән... Калганын үзең күз алдына китерә аласың инде. Әйе, әйе, чынлап та хатыны боларның араларын элек тә сизенеп йөргән, шуңа махсус килгән ул. Тик менә лагерьга бару турында кем җиткерде икән аңа? Бу хакта мин сездән башка бүтән кешегә әйтмәдем...— Эмиль Яковлевич, сул кулы белән өстәлгә таянып, Ихтыярга төбәлде.— Шул-лай... иренең яңагына китереп сылый да, мунчадагы җитәкчебезне бик матур итеп больницага алып та китәләр. Шундый-шундый хәлләр, иптәш Батыршин. Бәладән башаяк, дип сөенәсезме?..

— Әллә миңа берәр шигегез төштеме? — дип мыскыллы елмайды Ихтыяр.— Мунча ягудан баш тартсам да, завод өстенә төтен җибәрергә җыенганым юк әле.

Эмиль Яковлевич кинәт кенә мескенләнеп калган, аның элекке горур кыяфәте, тамак төбеннән ургылып чыккан гөбердек тавышы танымаслык булып үзгәргән иде.

— Мине хәзер райкомга чакыралар,— дип тагын да бөрешеп төште ул.— Сезгә бердәнбер үтенечем бар: өченче көн пикникка чыгарга кодалавымны икәү генә белсәк иде. Аннары тагын казыну китәр, сездән сораша башларлар. Ә безгә әле киләчәктә бергә эшлисе. Килештекме? — Ул Ихтыярга сузмак булып кулын күтәрә башлаган иде, ләкин никтер кире уйлады бугай, күтәрелгән кулының аркасы белән маңгай тирен сөртте дә аһылдап алды: — Шамкаев белән бәйләнмәскә ничә тапкыр ант иттем инде. Ул да тапкан җибәрер кеше! Урманов безнең заводның кара дошманы бит ул. «Архитекторлар көне-төне шәһәр матур булсын дип тырыша, ә завод безнең таләпләрне искә алмый, бизәк-орнаментларны, архитектура элементларын эшләүдән баш тарта»,— дип, җыелыш саен ул төкерек чәчә.

«Шамкаев заводны реконструкцияләүгә каршы идеме? Берничә елдан яңа завод сала башлыйбыз, искегә тимәгез, исегез китәр, дип, безнең эшкә ул каршы төшеп йөрдеме? Баш архитекторны да комиссия белән завод арасындагы алыш-бирешкә күз-колак булу өчен җибәргән ул. Ә тегесе азрак онытылып киткән, бетон-цементка караганда, мәхәббәтне өстенрәк күргән... һәм... дөрес эшләгән дә...» — дип уйга калып торды Ихтыяр. Кинәт кенә Сәбиләнең калтыранулы иреннәре, өмет тулы якты күзләре исенә төште дә башы әйләнеп китте.

Эмиль Яковлевич һаман үзен кулга ала алмый, нишләргә белмичә өзгәләнә, вакыт-вакыт, нидер көткәндәй, Ихтыярга карап куя.

— Мин кичә авыру идем. Бәлки, райкомга сез...— дип сүзеннән өзелеп калды ул. Ихтыярның ачудан күзләре кызара баруын күреп, сүзне кирегә борырга ашыкты: — Сынар өчен генә әйткән идем. Завод өстенә төтен җибәрергә җыенмавыгыз хакмы икәнне генә тикшереп каравым. Райкомда ничек тә җавабын табармын. Беренчедән, мин лагерьда да, мунчада да булмаган, аларның мәҗлесенә катнашмаган. Икенчедән, бу эшләргә администрациянең бернинди мөнәсәбәте дә юк, моның белән бары тик завком гына шөгыльләнгән. Билгеле, урманга, табигать кочагына алып чыгу турында әйтеп куйган булуыбыз мөмкин. Ләкин бу бит әле мунча ягарга, банкет оештырырга кушу дигән сүз түгел. Акча Сәлимовтан чыккан икән, җавабын да ул бирсен. Гаепне безгә аудара алмый ул, койрыгы безга каткан. Әгәр без казына башласак, ай-һай!..

Ихтыяр директорга ачуланып карады.

— Шулай булгач, үзегезгә тел тиярлек булмагач, нигә борчыласыз? — дип сорады ул.

— Урмановның ярсыган хатыны бүген иртүк редакциягә барысы турында да язып керткән. Ә безнең системада һәр язылган белибердага да җавап бирү мәҗбүри. Әле генә миңа редактор шылтыратты. Билгеле, ач эт сөяккә ташланган кебек, мондый калҗаны кулдан ычкындырмый инде ул журналист халкы. Шәп калҗа бит! Сенсация! Газетаның тиражы артачак инде моннан соң. Бу эшне өйрәнеп, газетага материал хәзерләүне корреспондент Фарукшинага тапшырганнар.

— Сәбиләгәме? — дип кычкырып ук әйтте Ихтыяр һәм, үзенең сабыйларча беркатлылыгыннан оялып, иреннәрен тешләде.

— Әйе, Фарукшинның хатынына. Белгәнемчә, сез аларның гаиләсе белән яхшы таныш. Йөрешәсез дә бугай. Кичә судта да бергә булгансыз. Ялгышмасам. Фарукшинаны озата кайтканда бәйләнгәннәр түгелме соң сезгә? Алай ук ямьсез итеп карамагыз, монда бернинди криминал да юк. Булган — беткән.

— Минем арттан гайбәт җыеп йөргәнче, үзләренең вазифалары белән шөгыльләнсәләр, башларына мунча исе капмас иде.

— Ярсымагыз, тынычрак. Бернинди гайбәт тә түгел,

моны белү өчен телефоннан бер шылтырату җитә. Җитмәсә, үзегез үк әйттегез бит әле. Ярый, булган — беткән, дип әйттем бит инде. Менә шул. Сезнең танышыгыз Фарукшина иптәш белән ничек тә уртак тел табарга, кыскасы, бу эшне йомып калырга кирәк. Әгәр дә матбугатта чыгып, меңләгән тираж белән халыкка таралса, кире җыеп алырмын димә. Заводның да даны китә, безнең күзне дә ачырмыйлар аннары. Сезне мин заводның патриоты дип беләм.

— Эшләр катлаулы икән...— Ихтыяр, тәрәзә янына килеп, урамдагы арлы-бирле чапкан машиналарга карап торды. Башында ниндидер фикер туып, директорга таба борылды да сәер итеп кеткелдәде һәм, уң кулын өскә күтәреп, сүзен дәвам итте: — Бер мәзәк сөйлимме?..

— Сөйләгез,— дип битараф караш ташлады аңа директор.

— Шулай көннәрдән бер көнне инде төрле җирләрдә, төрле җаваплы эшләрдә хезмәт иткән тәҗрибәле һәм карт бер куянны урман патшасы итеп билгеләгәннәр. Әй йөри, ди, бу урман буйлап кукыраеп, и бирә, ди, бөтен җәнлек-җанварның кирәген, күрсәтә, ди, күрмәгәннәрен! Моның каршына очраган арысланнар җиргә тезләнә, аның каршына аюлар бүләк күтәреп чыга, ди. Шулай итми хәлең юк, ни әйтсәң дә, гади куян гына түгел, Куян-патша бит! Шулай барчасының котын алып, урманны бер әйләнгән бу, ике әйләнгән. Очраган берсе, моны күрүгә: «Патша килә!» — дип йөзтүбән каплана икән. Йөри торгач, Куян-патша төлке өне янына килеп җиткән дә, тегенең исе китмичә генә ятуын күреп, борынына китереп типкән. Ә бу яшь төлке, әле генә чит урманнан күчеп килгәнлектән, куянның патша итеп билгеләнүен белми икән. Авырткан борынын бераз кашып торган да бу, Куян-патша өстенә ташланган һәм аны җиргә сузып та салган...

— Шуннан нәрсә булган? Төлкене патша итеп сайлаганнармы?

— Шуннан шул булган... Урманда гаделлек урнашкан.

— Мәзәгегезне аңламадым.

— Монда аңламастай бернәрсә дә юк.

Ихтыяр, сез дә шул Куян-патша кебек, үз урыныгызда түгел, дип турыдан-туры әйтергә базмады. Директор Ихтыярга сәерсенеп карап торды да, ике кулын хуҗаларча артка куеп, кабинеттан чыгып китте.

Сәбиләгә шылтыратырга җыенып, Ихтыяр берничә тапкыр телефон трубкасын да алды, ләкин тыелып калды. Ул көн саен диярлек аның белән телефон аша сөйләшә, бары тик тавышын ишетү, исәнлеген белү өчен генә иң тыгыз чакларында да моның өчен вакыт таба иде. Сәбилә үзе турында бөтенләй сөйләми, бары тик аның хәлләрен сораша, саубуллашканда һәрчак: «Ә син бәхетлеме?» — дип сорау бирә дә, җавап көтеп тормыйча гына, трубканы куя иде.

Икенче көнне дә шылтыратмады ул аңа, өченче көнне дә хәлен белешмәде. Сәбиләнең беркайчан да беренче булып үзе шылтыратмасын белсә дә, күңеле һаман нидер көтә, икеләнә иде.

Ул район гәзитәсенең һәр санына ашыга-ашыга күз йөртеп чыга. Ләкин бер атнадан да, ике атнадан соң да әлеге мәкалә күренмәде. Мунча вакыйгасын артык зурга җибәрмәделәр, завком председателе Сәлимовны эшеннән азат иттеләр дә шуның белән тынычландылар. Директор, гәзитәдә мәкалә чыкмауда Ихтыярның кулы уйнаган дип уйлап, ахрысы, аңа мөгамәләсен яхшыртты, элекке кискенлеге юкка чыкты.

Сәбиләләрдә куна калган саташулы-уяулы төннән соң, Ихтыяр бүтән аларга бармаска сүз биргән иде. Сентябрь башында Нурислам Мәскәүгә кандидатлык диссертациясен эшләп бетерергә киткәч, ул үзен тагын да ялгызрак хис итә башлады. Өйләренә бармаса да, алар сирәк-мирәк төрле оешмаларда очрашалар, бергәләп архитектор егетләр янына йөргәлиләр иде. Ихтыяр белән Нурислам, очрашкач, элеккечә үк онытылып сөйләшмәсәләр дә, барыбер бер-берсенә карата җылылык, хөрмәт саклыйлар, бик күп нәрсәләрдә уртак фикергә киләләр, теләсә нинди ситуациядән чыгу юлын табалар, шәһәрдәге һәр вакыйга, төзелештәге болгавырлык хакында икесе дә бертигез борчылалар, әмма ләкин Сәбилә турында сүз кузгатудан, хәтта аның исемен әйтүдән дә куркалар иде. Мәскәүгә китәр алдыннан, соңгы арада Нурислам бик еш чыгырыннан чыга, гел көтелмәгән ахмаклыклар эшләп ташлый башлады. Моның өчен Ихтыярның җаны әрни, барысы өчен дә пыр туздырып сүгәм, дип янына ярсып бара да, үзен күргәч, тагын тынычланып кала иде. Никадәр генә гаугалы һәм җайсыз кеше булса да, Ихтыярга аның белән рәхәт иде. Чөнки Нурислам бүтәннәр күрмәгәнне күрә, бүтәннәр ишетмәгәнне ишетә белә. Ул

бернәрсәгә дә битараф түгел, ул гаҗәеп хисчән, нечкә күңелле һәм шул ук вакытта искиткеч дорфа да була ала иде.

Мәскәүгә китәр алдыннан Нурислам мотоциклын пырылдатып Ташлыярга килеп төште.

— Әйдә, безгә барып утырыйк әле. Миндә — аулак өй. Сәбилә балалар белән кунакка китте. Сөйләшәсе сүзләр дә бар,— диде ул.

— Юньләп өйдә булган юк. Әткәйне күрмәгәнгә дә бер ай туладыр. Мин кайтканда, ул йоклый, ул эшкә киткәндә, мин йоклап калам,— дип акланды Ихтыяр.— Ул сүзләрне бездә генә сөйләшеп булмыймы соң? Бездә дә аулак бит, әткәй белән әнкәйдән башка кеше юк.

Нурислам бу тәкъдимгә сөенде генә бугай, бик тиз ризалашты.

Өстәл янында, берсе дә сүз башларга кыймыйча, тыныч кына утырдылар. Маһруй апа кыстый-кыстый өстәлгә ризык ташый торды, Тимерхан абый егетләргә сынаулы караш ташлап алды. Нурислам килсә, Тимерханның ниндидер бәхәс чыгармыйча калмаганын белгәнгә күрә, барысы да беренче сүзне аңардан көтә иде. Ниһаять, Тимерхан көлемсерәп кенә сорау бирде:

— Әйт әле, Нурислам, әгәр дә дөньяга килү белән сиңа, менә син шушы елның шушы аенда, шушы көнендә үләсең, дип әйтсәләр, таныклыгыңа туган елың белән янәшә үләсе елыңны да язып куйсалар, нишләр идең?

— Белмим. Кызык нәрсә бу. Ләкин минем ул турыда уйлаганым булмады.

— Шул шул менә! Ә син, капкадан керүгә, авызыңны ерып, хәлләр ничек, дисең. Безнең хәлләрне күреп торасың бит: бер аяк — түрдә, бер аяк — гүрдә...

Нурислам капка төбендә Тимерханның исәнләшмичә, сүзсез генә борылып киткәнен, хәзер менә шуны искә төшереп, тагын бер кат чеметүен аңлады.

— Күчәсен белгәч, күңеле сынды авыл халкының.— Тимерхан өстәл астында мияулап торган песигә калҗа бирде.— Яңа поселок әйбәт нәрсә әйбәтен. Тик менә гомер иткән нигезеңне ташлап китү, ай-һай, кыен. Халык бөтенләй чыгырдан чыкканчы күчеп буламы инде. Авыл ташландык хәлгә калып бара бит. Йорт-җирне, каралты-кураны карамыйлар. Кул селтәде дөньяга халык.

— Күп көтәсе калмаган,— дип, тыныч кына җавап бирде аңа Нурислам.— Шулаймы, Ихтыяр?

— Тагын бер айдан, ай ярымнан ял итү зонасы проектын тәмамлыйбыз. Әгәр дә Мәскәүдә раслата алсак, ел азагында, яңа ел башларында, бәлки, райком бюросына да куеп булыр. Поселок язмышы шуңа бәйләнгән бит. Проектны раслатсак, эшләр гөрләп китәчәк. Баш архитекторның да кикриге бераз шиңгәндер, ул кадәр үк очып куна алмас.

Ишегалдына чыгып, бүрәнә өстенә утыргач кына, Нурислам тагын тынгысызлана башлады. Ул бернәрсә турында сөйләргә тотына да, азагына җитмичә, кинәт кенә туктап кала, аннары бөтенләй бүтән нәрсә хакында сөйли. Ихтыяр аның нәрсәдер әйтергә теләп тә шул сүзгә барып җитә алмыйча изалануын күреп тора иде.

Болай гына кыюлыгы җитмәвен аңлады бугай Нурислам, мотоциклы янына чыгып, аракы алып керде.

— Саубуллашу хөрмәтенә бераз кабып алыйк әле,— дип, бүрәнә өстенә шешә белән стакан куйды ул.

— Синең мотоциклда кайтасың бар бит. Мин дә эчмим, атауда утырган көннән бирле авызга да алган юк. Анысы өчен дә шактый сүз ишетергә туры килде. Судка илткән язуыңда бөтенесен дә бик тәфсилләгәнсең бит. Минем салмыш булуны да әйтергә онытмагансың.

Нурислам соңгы сүзләрне ишетмәмешкә салынды, шешәнең бөкесен ачуында булды.

— Әй, төкергән ул кәҗә тәкәсенә! Кандидатскийны яклагач, чүплеккә ташлыйм мин аны,— дип сөйләнде ул.

Ихтыяр аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды, әтисенең өйдән чыгып килүен күргәч, гәүдәсе белән шешәне каплады. Нурислам ләззәт белән голт-голт китереп ярты стакан аракы салды да эчеп куйды, тагын салып, Ихтыярга сузды. Ул иренен дә тидермичә стаканны бүрәнәгә куйды.

Чынлап та, бераздан Нурисламның теле ачылды, кыюлыгы артты, йөзенә нур кергәндәй булды. Ул, тагын кыюлык өстәргә җыенып, стаканга үрелгән иде, кулыннан шешәне Ихтыяр тартып алды.

— Җитте! Фәннәр кандидаты була алмыйча, гап-гади Фарукшин килеш ычкынуың бар. Кәҗә тәкәсе — бик пырдымсыз хайван ул.

— Әүлия! — дип мыгырданды Нурислам.— Бер рәхәтләнеп утырып та булмый синең белән.

Ул, холыксызланып, урыныннан сикереп торды да җил-җил атлап капкага таба китте. Ихтыяр аның ар-

тыннан иярде. Капка төбенә җиткәч, Нурислам Ихтыярның иценә кулын куйды.

— Ташлама син мине,— дип, Ихтыярга инәлеп карады ул.— Ялгыз мин бу дөньяда. Бик ялгыз. Синнән башка беркемем дә юк минем. Сәбиләне дә тилмертеп бетердем. Янәшәмдә ул да булмаса, күптән чыгырдан чыгар идем инде. Тимә син... Сәбиләгә...

Шул сүзләрне әйтте дә, күзләренә килеп бөялгән яшьләрне күрсәтмәс өчен, тиз генә борылып мотоциклына атланды һәм ыргылып кузгалып китте.

Ихтыяр бары тик шунда гына Нурисламның ни өчен килгәнен аңлады. Өч айга Мәскәүгә китәсе булганга, аның күңеле урыныннан купкан, ул Сәбилә өчен борчыла, Сәбиләне бөтенләй югалтудан курка иде, күрәсең.

* * *

Нурислам Мәскәүдән атна саен хат язып торды. Хатларында күбрәк үзе турында, Мәскәү яңалыклары турында язса да, ял итү зонасының проектын сорашса да, аның бөтенләй бүтән нәрсә өчен борчылуы һәр сүзеннән, һәр җөмләсеннән сизелә иде. Ихтыяр бөтен хатларга да җавап биреп барды, завод, төзелеш хәлләрен энәсеннән җебенә кадәр тезгәннән соң, иң азакта, сүз арасында гына, эше күплеген, беркемне дә күрмәвен әйтә. Шулай итеп, ул Нурисламның күңелен тынычландырырга тырыша, шулай итеп алар, бер-берсеннән тел яшергән кешеләр кебек, сүзсез генә аңлашалар иде.

Ә аның чынлап та үз борчулары муеннан. Заводтагы эш, проект артыннан чабулар янына соңгы арада туй мәшәкатьләре дә өстәлде. Ул әле һаман туй буласына ышанып җитми, Зәлиянең сүзләре, әти-әнисенең үгетнәсихәтләре һәрдаим колак төбендә яңгырап, күңелен тынгысызлап торса да, алар турында уйламаска тырыша иде. Әйтерсең шулай итеп аны бөтенләй онытырга тели, көне-төне туй мәшәкатьләре артыннан чапса да, аның мәгънәсенә төшенмичә эшли, әйтерсең үз туена түгел, ә ниндидер бер якын кешесенең туена әзерләнә, шуның хәстәрен күрә иде.

Үткән айда Зәлия туйга аласы әйберләр исемлеген калдырып китте. Бер дәфтәр тутырып язган бу исемлеккә дөньяда булырга мөмкин әйберләрнең берсе дә кермичә калмагандыр. Ләкин иң катлаулысы алда булган икән

әле. Туйга кемнәрне чакыру турында сүз чыккач, чак кына сүзгә килми калдылар.

— Беренчеләрнең барысын да чакырабыз,— дип, хуҗаларча саный башлады Зәлия.— Аннары килеп...

— Нинди беренчеләрне ул тагын?..

— Билгеле, беренче класс укучыларын түгел. Аңламаганга салышып утырма,— дип, дилбегәне кулга алды Зәлия.

— Күңелемә якын булмаган кешеләрне чакыра алмыйм мин,— дип каршы төшәргә тырышып карады Ихтыяр.

— Күңелеңә берни дә булмас, биш-алты сәгатькә түзәр. Туй синеке генә түгел, икебезнеке дә,— дип кырт кисте Зәлия һәм үзенең кай арададыр әзерләгән исемлеген өстәлгә китереп салды.— Аннары чиннары «баш» дип башланганнарын чакырабыз. Баш бухгалтер, баш экономист, баш инженер...

Ихтыяр аның кулындагы дәфтәрне ачу белән тартып алды да исемлектәге кешеләрне берәм-берәм сызарга тотынды.

— Баш инженер Шамкаев әфәнденең Ташлыяр авылы исеннән күңеле болгана. Баш архитектор Урмановның башы әйләнгән чак...— дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә исемлекнең яртысыннан күбрәген сызып ташлады ул. Исемлекнең ахырына җиткәч, аптыраган күзләре белән Зәлиягә күтәрелеп карады.— Башкалада торып, бу кешеләрне каян белеп бетердең? Мин үзем дә кайчакта бутыйм әле аларны...

— Ерактан яхшырак күренә, дип әйткәнме әле бер шагыйрь. Син генә ул, кеше белән кешене аера белмичә, һаман шул исерек Нурислам артыннан тагылып йөрисең.

— Аларны нигә исемлеккә кертмәдең? — дип, дәфтәрне актара башлады Ихтыяр.— Нурислам белән Сәбилә кайда?

— Нурислам да Нурислам! Бик якын итәсең икән, соңыннан үзләрен генә аерым чакырырсың. Әллә эчеп мәҗлеснең ямен җибәрүен телисеңме? Бөтен кешегә бәйләнеп, үз сүзен генә куәтләп утырачак бит ул анда. Айнык чагын күргәнем юк әле аның.

— Нурисламның әле беркемгә дә хаксызга бәйләнгәне юк. Эчү ягын да туктаткан, авызына да алмый хәзер.

— Каян беләсең? Сөекле хатынын бер ялгызы калдырып, Мәскәүгә китте түгелме соң ул?

— Хатында язган, «баштанаяк эшкә чумдым, вак-төяк низаглардан, арзанлы интригалардан котылгач, күңелем тынычланып калды» дигән.

— Имидән аерганнар икән баланы! — Зәлия рәхәтләнеп кеткелдәп алды.— Тукран тәүбәсе. Аракының тәмен бер татыган кеше гомер буе туктый алмый ул.

— Эш аракыда гынамы монда, әллә...— диде дә Ихтыяр телен тешләде. Ул чак кына «Сәбиләдәме» дип әйтмичә калды.

Ләкин Зәлиянең сизгер карашы барысын да үтәли күреп, сизеп торган диярсең, ул үзенең сүзен нәкъ шуңа китереп ялгады:

— Хатынын да сөймим. Теге көнне, син анда кунып калган көнне өенә кергәч, елмаеп бер сүз әйтмәде бит, хурлыгыннан егылып үләрсең. Мине елап җибәрер дип уйлагандыр әле. Исем китте иске чикмәнгә, сер биреп торам ди шул кәгазь кортларына. Мин булачак ирем янына кунакка киләм, ә ул авызына су капкандай бер сүзсез күзен тозландырып карап тора. Рентген аппараты диярсең. Аяк тырнагымнан чәч бөртекләремә кадәр тикшереп чыкты. Яратмыйм шул журналист халкын, җенем сөйми. Кешедән гаеп эзләргә генә торалар.

Ихтыяр күңелендәге үзгәрешләрне, кичерешләрне Зәлиянең сизеп торганын, шуңа күрә Нурисламга да, Сәбиләгә дә мөмкин кадәр күбрәк кара ягарга, алардан үзен читләштерергә тырышуын аңлады. Ләкин ул Зәлиянең ай-ваена карап тормады, Нурисламга чакырып телеграмма сукты, Сәбиләгә открытка җибәрде.

* * *

Нурислам, Октябрь бәйрәмен дә сылтау итеп, өч көн алдан кайтып төште, Ихтыяр моңа икеләтә сөенде, чөнки ял итү зонасының проекты, ниһаять, эшләнеп бетеп, аны иң элек урындагы җитәкчеләргә күрсәтергә кирәк иде.

Икенче көнне үк, проектны күтәреп, баш архитектор янына керделәр. Ихтыяр кергәндә үк кабул итү бүлмәсендәге секретарь кыз урыны буш икәненә игътибар итте.

Роберт Маратович гаугалы хәлләрдән соң аз гына да үзгәрмәгән, элеккечә һавалы һәм тәкәббер сөйләшә, бары тик эчкә баткан күзләрендә генә тирән бер сагыш уелып калган һәм йөзе бераз суырылып, чәчләрендәге ак бөртекләр ишәя төшкән иде.

Ул проектка бик озак карап торды, һәр детален игътибар белән өйрәнде, аңламаган урыннарда сораулар бирде һәм, кашларын җыерып, яңадан өстәл артындагы урындыгына барып утырды. Нәрсәдән башларга икәнен белмичә, сосискага охшаган бармакларын өстәлдә тыпырдатып алды.

— Шактый зур эш башкарылган,— дип, проектны алдынарак тартты ул.— Күргәнемчә, бу сезнең эш кенә түгел, коллектив эше булса кирәк. Профессиональ кул сизелә монда. Икеләтә кызганыч, бик кызганыч...

— Нәрсәсе кызганыч? — дип сорады Нурислам.

— Чөнки сез ничәмә-ничә кешенең күпме вакытын әрәмгә сарыф иткәнсез.

— Конкретрак сөйли алмассызмы? — дип, Ихтыяр урындыгын Урмановка таба шуыштырды.

— Проектның нигезе, идеясе үк реаль түгел. Проектның асылын арзанлы романтика тәшкил итә. Аңлагыз мине, тагын бер тапкыр кабатлап әйтәм: кем ял итәргә теләсен сезнең ул чүплек башыгызда: абзар исен, тирес исен бетерү өчен генә дә берничә дистә ел җилләтергә кирәк Ташлыярны.

— Бу бүлмәдән дә тынчурак түгел Ташлыярда,— дип төрттерде Ихтыяр.— Тәмәке исенә суларлык түгел монда. Форточкаларны ачып булмас микән?

— Күңелегез болганса, ачыгыз.

Нурисламның чыгырыннан чыгарга да, үртәшеп утырырга да исәбе юк иде, ул эшлекле кыяфәт белән сүзгә кушылды.

— Бүгенге көндә шәһәр һәм завод төзүчеләрнең, белгәнегезчә, якынча алтмыш биш процентын авылда туып-үскән кешеләр тәшкил итә.

— Менә шул шул. Авылдан гарык булып, аннан чыгып качкан кешеләр. Авылдан болай да туйган инде алар. Театр, цирк, филармония, күргәзмә заллары, музейлар кирәк аларга.

— Кирәк булгач, нигә төземибез соң? — Ихтыярның күңеле кайнаса да, ул мөмкин кадәр тыныч булырга тырышты.— Шәһәрдә бүгенге көндә өч ресторан, биш кафе, дүрт аракы кибете бар. Аларына материал да, акча да таптык бит.

— Чөнки алар ачылган көннән үк табыш...— Роберт Маратович уң кулының өч бармагын ышкып күрсәтте,— акча бирә башлый. Ә театр нәрсә бирә? Беләм, рухи бай-

лык та бик кирәк. Анысына да җитешербез. Материя беренчел, дип кем әйткән әле?

— Без монда демагогия белән шөгыльләнергә кермәдек,— дип, Ихтыяр өстәлдәге проектны калкытып куйды.— Нинди конкрет фикерләрегез бар? Шуларны әйтегез.

— Ультиматум дип аңларгамы моны? Тагын райкомга чапмакчы буласызмы? Анда да туеп беткәннәр инде сездән, ничек котылырга гына белмиләр.

— Кая барсак та, безнең эш! — Нурислам Ихтыяр белән баш архитектор арасында басып тора иде.

— Беренчедән,— дип, тавышын йомшарта төшеп дәвам итте Роберт Маратович,— проектыгызда ял итү зонасы өчен, һичшиксез, кирәкле булган нәрсәләр күздә тотылмаган. Җылы су, канализация һәм ашханә турында бөтенләй оныткансыз.

— Без аны авыл шартларына якынайту өчен махсус шулай эшләдек. Юынасың килсә, ике йортның берсендә мунча бар, авыл өенә бәдрәф ясау, минемчә, ятыша торган нәрсә түгел. Продуктларны янәшәдәге кибеттән махсус талоннар буенча алырга була. Авыл мичен ягып җибәр дә җаның ни тели — шуны пешереп аша. Пешерәсең килми икән, «Иске тегермән» ресторанына рәхим ит. Көндез гади ашханә шикелле эшли ул.

— Бүлдермәгез әле,— дип, өстәлгә карандаш белән шакылдатты Роберт Маратович.— Боларны миңа түгел, комиссиягә аңлатырсыз. Аларның — үз таләпләре. Кыскасы, мин сезнең бу проектыгызны хуплый алмыйм. Барыгыз, жалоба бирегез. Мин күнеккән инде.

Баш архитектор, проектны Ихтыярга таба этәреп, урыныннан торды, сигарет кабызырга дип зажигалкасына үрелде, ләкин кабызмады, шапылдатып өстәлгә куйды.

Ихтыярның болай тиз генә бирешергә исәбе юк иде, ул урындыгыннан кузгалмыйча, Роберт Маратовичка карап, сүзен дәвам итте:

— Безнең райбашкарма рәисенең дә фикерен беләсебез килә. Сез моңа каршы килмәссездер.

— Һич тә каршы түгел. Ләкин, кызганычка каршы, ул командировкада. Бәйрәмнән соң гына эшкә чыга.

— Аның урынбасары?

— Телисез икән, министрга кадәр барып җитә аласыз. Ләкин безнең кулда дәүләт комиссиясе раслаган проект булуын һәм киләсе язда ул проектның гамәлгә ашы-

рыла башлаячагын онытмагыз. Сүзнең нәрсә турында барганын, шәт, аңлата алганмындыр дип уйлыйм. Уңышлар телим сезгә! Хушыгыз!

Ул аларны, ике кулын алга кушырган хәлдә, елмаеп озатып калды.

Баш архитекторның астыртын елмаюы сәбәбен райбашкарма рәисе урынбасары Чугунов аларга озаклап, тәфсилләп аңлатты. Ул инде баш архитектор сыман турыга ярмый, бишектә тирбәткәндәй бер көйгә чайкала-чайкала тәмләп сөйли, тәмле теле белән күңелдәге бөтен бозларны эретә иде.

— Идеягез әйбәт, әмма хөкүмәт акчасын әрәм-шәрәм итәргә бирәү дә юл куймаячак! — Аның саубуллашкандагы соңгы сүзләре Ихтыяр белән Нурисламны тагын уйга салды.

...Райкомның беренче секретаре Рим Идиятович Солтанов, әле стенадагы генеральный план янына килеп, әле ял итү зонасы проектына карап, алар белән шактый озак сөйләште. Баш архитектор Урмановка, райбашкарма рәисе урынбасары Чугуновка шылтыратты, тиз генә номер җыеп, республика госпланы белән дә киңәшеп алды.

— Беркем дә үз өстенә алырга теләми.

Ул, тәрәзә янына килеп, яңгыр пәрдәсе сарган урамга, юл буйлап пычрак чәчрәтеп чабучы машиналарга карап торды. Аннары, капыл гына борылып, күзләрен хәйләкәр кыскалап алды да пышылдап диярлек әйтте:

— Хәзер бер эксперимент ясыйбыз, егетләр. Беткән баш — беткән!

Ул телефон трубкасын алып номерны җыйды.

— Фәүзия, синме әле бу? — дип, гадәттәгедән дә ягымлырак башлады Рим Идиятович үзенең сүзен.— Суытып җибәрде бит әле, минем эчкә салкын төште. И-их, авыл өендә мич каршында утырырга иде хәзер, ә?! Юк белән хыялланма, дисеңме? — Ул егетләргә карап күз кысып куйды.— Тукта әле. Ташлыярдагы иясез йортларны арендага алдык бит. Ишетмәдеңмени? Әйдә, шимбә-якшәмбедә шунда барабыз. Мич ягып җибәрербез, бәлеш пешерербез. Син пешергән бәлеш бигрәк тәмле була иде бит. Килештекме? Калганын кич сөйләшербез.

Рим Идиятович, куанып, кулларын угалады, аның биек маңгае тирләп, кызарып чыкты.

— Эксперимент уңышлы булырга охшый, егетләр. Хаклык, бәлки, сезнең яктадыр. Фәүзия апагыз — авыл кы-

зы. Ул хуплагач, бүтәннәр дә хуплый дигән сүз. Эшегез барып чыга, болай булса. Академикка шылтыратып куярмын.

— Безнең аркада Фәүзия апа алдында уңайсыз хәлдә калдыгыз,— дип, тартынып кына әйтте Ихтыяр. Аның авызы, тыела алмыйча, елмаерга гына тора, йөрәге бөтен кабинетка ишетелердәй булып тибә иде.

— Яхшы эш өчен җан фида.

— Әгәр дә без сезне, Фәүзия апа белән икегезне, шундый ук авыл өенә кунакка чакырсак, туйга, каршы килмәссезме? — Ихтыяр, бурлаттай кызарып, чакыру билеты сузды.

— Менә монысын булдыргансың! Дөрес эшләгәнсең! Андый-мондый ашыгыч эш чыкмаса, һичшиксез, килергә тырышырбыз. Син әйтмешли, Фәүзия апагыз алдында да йөзем ак булыр.

* * *

Туй мәҗлесе шаулап-гөрләп, бөтен авыл халкы өчен гомер буена истә калырлык булып узды. Картлар да бу кадәр олы мәҗлесне, күңелле бәйрәмне хәтерләмәүләрен әйттеләр.

Соңгы көннәрдә Ихтыяр үзе дә туйны түземсезлек белән көтә башлады. Вакыты килеп җиткәч, инде чирканчык алган кеше сыман, ул беркавымга тынычланды, капка төбенә чыгып, килгән кунакларны каршы алды. Ишегалдына полиэтилен пленкадан түбә корып, йөздән артык урын ясаганнар иде, хәтта анда да сыеша алмадылар. Урын җитмәгәннәр дә үпкәләп кайтып китмәде, өстәл тирәсендә эвәрә килде, әле урам якта да кешеләр күп иде.

Туй мәҗлесе таң беленә башлаганчы дәвам итте. Бу төнне авылда ут сүндереп йокларга яткан кеше булмады бугай. Әйтерсең кешеләр Ихтыяр белән Зәлия туена гына килмәгәннәр, әйтерсең алар шулай итеп Ташлыяр авылы белән саубуллашалар, карчыклар үзләренең яшь чакларын искә төшереп яшь сыкмыйлар, ә туган-үскән нигезләре белән хушлашып елыйлар, картлар башка киткән хәмер кызуыннан биемиләр, ә туган туфрак җылысын ныграк тоеп калырга теләгәндәй, катырак басарга тырышалар иде.

Ихтыяр кешеләргә кушылып көлде, алар белән бергә хәлдән тайганчы биеде, тамагы карлыкканчы җырлады.

Ул, шушы көннең бар шатлыгын күңеленә җыеп, кешеләр йөзендә балкыган нурларны җанына сеңдереп калырга тели иде. Аңа бүген һәркем якын, аның бүген мондагы һәркемне кочагына аласы килә. Ихтыяр, елмаюлы карашлар арасында адашып, бераз онытылып тора да кинәт кенә айнып киткәндәй дерелдәп куя. Мәҗлес ахырында бөтенләй арып, Зәлиягә текәлеп утырганда, күңеленең тыныч түгеллеген сизде. Йөзләгән күзләр арасында Сәбиләнең чәнечкеле күз карашын күреп, хәрәкәтсез калды. Нурислам, Ихтыярның үзләренә карап торуын күргәч, авызын ерып, кул болгады, Сәбилә дә, аңа кушылып, кул селтәде. Аларның кул болгавы Ихтыярга саубуллашу кебек тоелды. Әйтерсең Нурислам белән Сәбилә, бөтенләйгә хушлашып, аны билгесез ерак юлга озаталар, Ихтыярдан мәңгегә аерылалар иде.

* * *

Туйдан соң Октябрь бәйрәме башланды. Бәйрәм үтүгә үк, Ихтыяр Нурислам белән Мәскәүгә китеп барды.

Башкаланың шау-шулы вокзалына килеп төшүгә үк, мондагы мәһабәт йортлар, мондагы ыгы-зыгы арасында Ихтыярның уйлары, хыяллары кинәт кенә бәләкәйләнеп калгандай булды, аларның зурдан кубып, айлар буе төн йокыларын калдырып йөрүләре мәгънәсез эш булып тоела башлады. Ләкин бераз күз ияләшә, колак күнегә башлагач, әкренләп элекке ышаныч та кайтты, институт янына килеп туктаганда, алар инде онытылып сөйләшәләр иде.

Проект институтында үзләренең кайсы шәһәрдән килүләрен, кем икәнлекләрен, ни йомыш белән йөрүләрен әйткәч, аларны туп-туры директор янына алып керделәр. Олпат кыяфәтле, ялтыратып кырылган башлы, эре сөякле академик Староверов ачык йөз белән каршы алды, өстәл артыннан чыгып исәнләште. Төзелештәге хәлләрне, яңалыкларны сорашкач, төп сүзгә күчте. Академик, аларны бүлдермичә, игътибар белән тыңлады, проектны карандаш йөртә-йөртә җентекләп карады. Аның йөзендә бер үзгәреш тә күренмәгәч, Ихтыяр инде эшне барып чыкмаганга саный башлаган иде, шулчак академик кинәт кенә яктырып китте дә, яннарына килеп, җилкәләреннән кагып куйды, каты итеп берәм-берәм кулларын кысты.

— Әйттем бит, әйттем бит мин аларга! — дип, дулкынланудан ашыга-ашыга сөйләп китте ул.— Талантларны читтән, провинциядән эзләргә кирәк, дип әйттем. Генпланны эшләгәндә, урындагы архитекторларның киңәшләренә колак салыгыз, шәһәрдә яшәячәк халыкның рухи ихтыяҗларын өйрәнегез, дидем. Булдыргансыз, егетләр! Иртәгә безнең институтта киңәшмә була. Шунда үзегезнең проектыгыз турында сөйләрсез. Ун минут вакыт җитәме сезгә? Проектыгызны калдырыгыз. Безнең иптәшләр иртәгәгә кадәр таныша торырлар.

Нурислам белән Ихтыяр академикка рәхмәт тә әйтә алмадылар, җавап урынына икесе тиң баш селкеделәр дә ишеккә таба атладылар.

Урамга чыккач, Нурислам Ихтыярны, кулыннан тотып, ресторанга сөйри башлады.

— Әйдә! Кәҗәләнмә! Мондый җиңүне һәйбәтләп юмыйча булмый! — дип, урам яңгыратып көлде, ресторан вестибюлендә хәтта тыпырдап биеп тә алды.

Шампанскийдан башлаганнар иде, анысы бушагач, Нурислам коньяк китертте. Ихтыяр аны күпме генә тыярга тырышып караса да, Нурисламның бүген бернәрсәгә дә исе китми, сала да эчә, эчә дә сөйли, сөйли дә тыела алмыйча туктаусыз көлә иде. Тора-бара ул сүзенең очын югалта башлады, мәгънәсез мыгырданды. Ихтыяр аптырата торгач, ниһаять, моннан китәргә булдылар. Нурислам, кесәсенә тыгылып, учы белән акча чыгарды да өстәлгә чәчеп ыргытты.

— Мәскәү сәүдәгәре шикелле кыланма әле,— дип, Ихтыяр аның акчаларын җыйды да яңадан кесәсенә салып куйды.— Ярлы интеллигент икәнеңне истән чыгарма. Иртәгә урам чатында утырмассың бит.

— Интеллигенция! Интеллигенция... Юк ул бездә интеллигенция! Безнең халыкта интеллигенция була алмый. Интеллигент түгел мин, сәүдәгәр. Дөрес әйттең, сәүдәгәр. Акылымны сатам, фикерләрем белән сәүдә итәм. Ә минем Ринат кем булыр? Туган телен белми, гореф-гадәтләрен әйткән дә юк. Бабасын бер тапкыр да кайтып күргәне юк... Ә син «интеллигенция» дисең. Җиде буын бабаңны белергә тиеш син иң элек. Сыер-сарык арасыннан чыгып, институтка барып укыйсың да интеллигент буласың, имеш. Булырсың, пычагым! Җиде буының интеллигент булу кирәк аңа. Ә безнеке бер буыннан өзелә... Балалар бездән китә, аларны без түгел, мәктәп тәрбияли,

дәүләт тәрбияли. Бер буынлы интеллигент... Ха-ха... Нурислам Фарукшин — бер буынлы интеллигент, амеба-интеллигент. Бер буынлы ракета ерак китә алмый...

Нурислам, бушаган шешәне күтәреп, аңа гаҗәпләнеп карады да тагын кесәсеннән акча чыгарды. Ихтыяр аларны җыеп үз сумкасына эшереп төшерде, кесәсеннән иллелек чыгарып, официантканы чакырды.

— Нәрсә, синең акча чистаракмы әллә? — дип бәйләнүендә булды Нурислам.— Син баеракмы әллә? Беләбез, архитектор егетләргә дә проект эшләгән өчен үз кесәңнән түләгәнне беләбез...

Ихтыярның башына кан йөгергәндәй булды.

— Кем әйтте? — дип, Нурисламның йөзенә текәлеп карады ул.

— Сүз иясе беләп йөрми.— Нурислам очкылык тота-тота кеткелдәгәндәй итте.— Әллә үзеңне бөтен кешедән дә акыллырак дип уйлыйсыңмы? Барсын да беләбез. Буш ведомость табып исемнәрен язып куйганыңны да, зарплата алган кебек иттереп, акчаны кул куйдырып алдырганыңны да беләбез. Койрыкны җыеп йөрисең, афәрин.

Ихтыяр, түземлеге бетеп, официантканы ашыктырырга тотынды. Нурисламны гына урыныннан кузгату авыр булды, ул тагын аракы китертергә маташты: «Ышанма хатын-кызга»,— дип, официанткадан акчаны кат-кат санаттырды.

Метрога килеп җиткәч, Нурислам Ихтыярны бөтенләй кире якка сөйри башлады. Кул күтәреп, такси туктатты.

— Әйдә, кызлар янына алып барам! — дип кычкырды ул, таксига кереп утыргач.— Үкенмәссең.

— Нинди кызлар ул тагын? — Ихтыяр аны шаярта дип уйлый иде, кара аны дигәндәй, бармак янады.

— Минем белән бергә укыган кызлар. И-их, аларның фатирларын күрсәң! Әйдә, Ташлыяр бозавы шикелле басып торма! Әллә хатының Казанда ике ел буе тик ятар дип уйлыйсыңмы? Шиш! Тик яткырырсың аларны! Синең белән кочаклашып ятканда да этлек уйлап ята алар! Әйдә!..

Ул такси ишеген кат-кат ачып кычкырды. Ихтыяр аңа аптырап һәм кызганып карап торды да, кырт борылып, метрога төшеп китте.

Икенче көнне Нурислам проект институтына киңәшмәгә килмәде. Ләкин нигәдер Ихтыярның моңа артык

исе китмәде. Ахрысы, кичәге хәлләрдән соң Нурисламга күңеле суынган иде аның.

Гыйльми секретарь аны бик коры каршы алды. Пуля үткәрми торган пыялага охшаган калын линзалы күзлеге артына качып, ул, исе китмичә генә, Ихтыярга урын күрсәтте. Өстәл өстендәге кәгазьләрне озаклап актарганнан соң, тәмләп кенә сүз башлады:

— Мәскәү хәтле Мәскәүгә килеп академикларны борчып йөрисез, ә үзегез, бала-чага кебек, көнгә кырык мәртәбә үзгәрәсез.

Ихтыяр, нәрсә әйтергә белмичә, аптырап калды, бөтен тәне кызышты, маңгаена бөрчек-бөрчек тирләр бәреп чыкты.

— Әле генә Фарукшин шылтыратты. Ул килә алмый. Аның соавторлык дәрәҗәсе күпме бу эштә?

— Белмим...— дип, көчкә телен әйләндерде Ихтыяр.— Идея — минеке, проектны группа белән эшләдек, аңлатмаларны һәм кереш сүзләрне ул язды.

— Әгәр дә проектыгызны киләсе киңәшмәдә карасыннар, дисәгез, бер генә юл кала: утырасыз да аңлатмаларны, кереш сүзне яңабаштан үзегез язасыз. Академикның фикере шулай.

Институттан чыккач, Ихтыяр Мәскәү урамнарының елга кебек тоташ агылган халык ташкыны арасында үзенең кая барганын, нигә барганын да белмичә йомычка сыман акты да акты. Ул Нурисламның иң соңгы чиккә җиткәч ташлап качуын, хыянәтен берничек аңлый да, аклый да алмый иде.

Ихтыяр телеграфка кереп, үзенең берничә көнгә тоткарлануы турында заводына телеграмма сукты да кунакханәгә кайтып егылды.

* * *

Завод директоры Эмиль Яковлевич аны төкерекләрен чәчә-чәчә каршы алды.

— Әгәр дә эшлим дисәгез, заводта гына эшләгез, йә булмаса, баш архитектор Урманов артыннан китегез. Елларны оештыру буенча ул мастер иде бит,— дип ташланды директор Ихтыярга.— Мәскәүдән телеграмма биргән, имеш, каян килгән министр! Мәскәүдән генә идарә итеп ята. Монда план кычкырып яна, ел азагы якынлашып килә, ә сезнең һаман бәйрәмнән башыгыз чыкмый. Ярты

ел буе реконструкция дигән булып, меңләгән кешенең башын әйләндереп, әйбәт кенә эшләп килгән заводны эздән чыгардыгыз! Менә хәзер сезнең хәер-фатиха белән планны өч мәртәбә арттырдылар. Ә ул, эшне беткәнгә санап, ике кулын кесәгә тыгып, үз тормышын көйләп, үз тормышын реконструкцияләп йөри.

Директор белән бәхәсләшеп торуның мәгънәсез икәнен, бу сөйләшүнең бары тик аклануга яисә тагын пычакка-пычак килүгә генә кайтып каласын белгәнгә, ул күтәрелеп сүз әйтмәде, ахырына кадәр тыңлап бетерде дә, заводтагы хәлләрне үз күзләре белән күрергә ниятләп, цехлар буйлап китте.

Ихтыяр Эмиль Яковлевичның завод өчен борчылып та, Мәскәүдә тоткарлануына ачуы чыгып та дуламаганын, монда башка сәбәп барлыгын сизә, шуңа күрә аны юри үртәгәндәй, сабырлык, салкын канлылык күрсәтә, дәлилле аргументлар китереп бары тик эш турында гына сөйләргә тырыша иде.

Зәлия белән туйга чакырыласы кешеләр исемлеген карап утырганда, ул аның исемен сызмаса да, барыбер килә алмый, дип, больницага чакыру илтеп тормады. Директор, савыгып чыккач, бу турыда сүз кузгатмады, әмма аны котларга да онытты. Туйда шәһәрнең күренекле кешеләре булып та үзенә чакыру җибәрмәүләре, читләтүләре өчен рәнҗегән иде ул.

«Дөнья ваклыклардан тора. Шул ваклыкларны җиңел кичерә алмасаң, сине адым саен кечкенә трагедия сагалаячак. Директорның чәче менә ни өчен агарган икән...» — дип уйлады Ихтыяр һәм, очраган кешеләр белән сүз алыша-алыша, бер цехтан икенче цехка йөрде.

Ел азагы якынлашканга күрә, план тутырабыз, дип, төзүчеләр алны-ялны белми эшлиләр, шуңа күрә заводка да, алардан калышмас өчен, бөтен көченә җигелергә, ел башында күз алдына да китереп булмый торган күләмдә продукция чыгарырга туры килә иде.

Атна буе цехтан цехка, объекттан объектка чабып, план куалап йөри торгач, көннәрнең үткәне сизелмәде, хәтта Сәбиләгә шылтыратырга да онытты ул. Үтеп барышлый гына кабинетына кергән иде — телефон шылтырады. Трубкада Рим Идиятович тавышын ишеткәч, ул беразга каушап калды.

— Мәскәүне яулап кайткансың, ә тавыш-тының юк. Беренче секретарьның артык кирәге калмадымыни? Мәс-

кәү хуплады да шуның белән эш бетте дип уйлыйсыңмы?

— Проектны хуплауларын беренче булып сездән ишетәм! — дип сөенде Ихтыяр.— Мин аны калдырып кайткан идем бит. Раслаганнармы? Чынмы? — Ул, аяк буыннарының йомшаганын сизеп, урындыкка утырды.

— Проектыңның копиясен хәзер үк райбашкармага, архитектура бүлегенә илтеп тапшыр. Институттан хәбәр килгән, димәк, расланган экземпляры да берничә көннән килеп җитәр, өйрәнә торсыннар. Сессиядә раслатасы бар әле аны. Өйләнү белән эшләр алга тәгәри башлады синең,— дип шаяртуга күчте секретарь.— Котлыйм үзеңне, кияү! Уңышлардан башың әйләнмәсен. Монысы — башы гынадыр, дип уйлыйм. Харрас Шәмгунович әйтмешли, төзелешкә ике генә нәрсә кирәк: төзү материалы һәм ихтыяр көче. Синең кулда икесе дә бар хәзер. Сау бул!

Рим Идиятовичның сүзләрендә киная дә булуын сизеп, Ихтыяр җитдиләнеп китте. «Моны инструктор аша гына да әйттерә ала иде бит ул. Димәк, ял зонасын, чыннан да, бик мөһим нәрсәгә саный, үзе борчыла»,— дип уйлады.

Проектны тотып баш архитектор янына кереп барганда, аны райбашкарма рәисе урынбасары Чугунов туктатты.

— Котлыйм, Батыршин! Тәки үзегезнекен иттегез бит,— дип, ерактан ук күреп алып сүз башлады ул. Йөзендә элекке салкынлыкның әсәре дә калмаган, уртак эш эшләгән, уртак сөенеч бүлешкән кебек сөйләшә. Әйтерсең бу проектка аның да өлеше кергән, әйтерсең проект турында ул һәрдаим кайгыртып торган.— Әйдәгез, миңа керәбез.

— Баш архитекторга тапшырыйм дигән идем.

— Юк инде ул. Китте... Алдыннан арты хәерле...

«Нәрсә булды, кая китте?» дип сорашса да, урынбасар ишетмәмешкә салындымы, җавап бирмичә генә сүзне икенчегә борды.

Ләкин баш архитекторның язмышы нигәдер аны борчый, тынгылык бирми иде. Кайтыр юлга чыккач, бу турыда шофердан сорашырга булды. Шикләнүе дөрес икән: Роберт Маратович, гаиләсен һәм эшен ташлап, секретаршасы белән каядыр Себердә төзелә торган химия комбинатына китеп барган. Беркем белән саубуллашмыйча, беркемгә бер сүз әйтмичә, чыккан да киткән. Эштән азат итүләрен сорап, өстәлендә гариза гына калдырган.

Шәһәр читенә җитәрәк, шофер машинасын туктатты.

— Карагыз әле, нәрсә салдырып китте Урманов,— дип төртеп күрсәтте ул.

Юл буенда төрле төстәге ташлар белән бизәп эшләнгән галәмәт зур әкәм-төкәм оясына да, диңгез кабырчыгына да охшаган корылма тора иде.

— Нәрсә бу? — дип гаҗәпләнеп сорады Ихтыяр.

— Мәхәббәткә һәйкәл...

— Нәрсә, нәрсә?

— Тукталыш...— дип елмайды шофер.— Автобус тукталышы. «Энҗе» дип атала. Күрәсезме, өстенә «Энҗе» дип язып та куелган. Секретаршасы Энҗе исемле иде аның. Шуның хөрмәтенә эшләткән.

Ихтыяр бу гаҗәеп тукталыштан күзен ала алмыйча карап торды. Ул, чыннан да, энҗе кабырчыгына искиткеч нык охшаган, бары тик эче генә буш иде.

«Бу тукталышка кереп сыенган кеше читтән энҗегә охшап күренәдер»,— дип уйлады ул.

— Бөтен тукталышлар да шулай булса иде! — Шофер юл читенә тагын бер каерылып карады да машинасын кузгатты.— Киткән бер кеше шундый берәр әйбер калдырса, безнең шәһәр күптән шәһәргә охшаган булыр иде.

Ихтыяр Роберт Маратовичның зур өстәл артында искитмәс кыяфәт белән басып торуын күз алдына китерде. Җыелышларда аны инициативасызлыкта, үз фикере, фантазиясе булмауда гаепләп сөйләгән сүзләрне искә төшерде. Баш архитекторның үз урынында утырмавы, сәләтсезлеге турында соңгы арада еш ишетергә туры килгәнлектән, аның китүе бер дә гаҗәп хәл түгел иде. Ихтыяр, каерылып, арткы тәрәзә аша инде ераклаша баручы тукталышка карады һәм, җиңел сулап, үзалдына гына әйтеп куйды:

— Яратсаң, эшләп була икән...

— Нәрсә дисез?

— Бөтен нәрсәнең башы мәхәббәттә, туган,— дип елмайды Ихтыяр.— Мәхәббәт булмаса, матурлык та, чуртым да юк! — Һәм ул, йөрәге чәнчешкәнне тоеп, кулын күкрәгенә куйды.

— Секретаршасын яраткандыр, дип уйлыйсызмы? Аның ире, баласы бар бит. Вәт юләр!

Ихтыяр тамак төбенә төер килеп утырганны сизде, аның битләре ут яна башлады. Шофер егетнең күзләренә туры карарга кыймыйча, ул тәрәзәгә таба борылып утырды.

— Картаеп беткәч, нинди мәхәббәт инде ул? — дип,

тагын артка борылып карады шофер.— Менә сиңа Таһир белән Зөһрә, ә?

— Белмим... Мәхәббәтнең акылы булмый бит аның, йөрәге генә була...— диде уйчан гына Ихтыяр.— Яратмаса, андый тукталыш эшләтмәс иде. Һәр йортны, һәр урамны, бөтен шәһәрне шулай яратса иде кешеләр... Роберт Маратовичны хөрмәт итә башладым бугай мин. Егет кеше булып чыкты ул.

Ихтыяр сүзен әйтеп бетерә алмады, нәрсәдер гөрселдәде, кинәт кенә күз аллары караңгыланды да машина упкынга төшеп киткәндәй булды.

Аңына килгәч кенә белде: шофер, арттагы тукталышка карап бара торгач, каршыга килүче машинаны шәйләмәгән дә, туп-туры аның маңгаена китереп бәргән иде. Ярый әлә әкрен барганнар, югыйсә ком төягән «КРАЗ» өсләреннән чыгып китәсе булган. Ихтыярның бер кабыргасы сынган, битенә пыяла ярып кергән иде.

Ул, дүрт көн дигәндә, хастаханәдән чыкты. Дару исе аның күңелен укшыта, ак төс күзләрен ялыктыра иде, сорый торгач, өенә кайтарып җибәрделәр. Дөресрәге, Ихтыяр иртәдән кичкә кадәр хәл белешергә килүче, ризык-мазар ташучы кешеләрдән ялыкты. Үзенең хәле ул кадәр үк борчылырлык түгеллеген, ашарга бернәрсә дә кирәкмәвен әйтә-әйтә, бер үк сүзләрне сөйли-сөйли туйгач, ул инде килүчеләрдән качып йөри башлаган иде. Кичкырын ап-ак чәчәкләр күтәреп, ап-ак халаттан Сәбилә килеп керде. Бүтәннәр шикелле хәлен сорашмады, артык төпченеп тормады.

— Нәрсә булды? — диде.

— Мәхәббәт корбаны булдым,— дип шаярып җавап бирде ул.

— Гашыйк булдыңмы әллә?

— Гашыйк булсам, бөтенләй баш бетәр иде...— Ул, күз чите белән Сәбиләгә карап, чәчәкләрне иснәде.— Гашыйкларга карап та бер кабыргасыз калдым әле. «Энҗе» тукталышына карап хыялланып бара идек, шалт — килдек тә бәрелдек.

— Синең ул кабыргаңнан би-ик гүзәл бер алиһә ясыйлардыр әле. Энҗедән дә гүзәлрәкне.

— Син аны белә идеңмени?

— Журналист халкының белмәгәне була димени?

— Ә теге вакытта Урманов турында нигә язмадың син? — дип, Сәбиләнең йөзенә текәлде ул. — Шамкаев үтендеме?

— Мәхәббәт хакына... Мәхәббәткә каршы кул күтәрә алмадым,— диде Сәбилә һәм Ихтыярның маңгаендагы ярасын сыпырып куйды.— Минем уйлар дөрес булып чыкты. Энҗене алып китеп барган бит. Яратам егет кешеләрне. Мәхәббәттә, карак кәҗә кебек, кеше күрмәгәндә чемченеп йөргәнче, шундый юләрлек эшләвең — мең артык.

Ихтыяр аның сүзләрен артык тыңлап тора алмады. Сәбиләне кочып иркәлисе килде аның.

— Сөйләмә, Сәбилә! Бүтән бер сүз дә әйтмә! — дип пышылдады ул.

* * *

Авыл күчәсе көн якынлашкан саен, Тимерханның тынгысызлыгы арта барды. Күченүне июнь аена ниятләгән булсалар да, сабан туена кадәр яңа урынга урнашып бетик, дип, апрель азагында ук кузгала башларга булдылар. Күченүчеләр өчен колхозның бөтен техникасын җиктеләр, шәһәр дә сораган кадәр тракторын, машинасын бирде.

Урман куенындагы яңа поселокта инде йортлар әзер булып хуҗалары килгәнне көтә иде. Икешәр катлы уналтышар фатирлы өч йортка яшьләрне, караучысыз калган карт-корыны һәм читтән килгән белгечләрне урнаштырырга булдылар. Зур гаиләләргә янында бакчасы, каралты-курасы терәлеп торган өчәр-дүртәр бүлмәле кирпеч өйләрне бирделәр.

Әле иртән эшкә киткәндә генә авыл йокылы кыяфәт белән оеп утыра иде, кичен кайтканда Ихтыяр, үз күзләренә үзе ышанмыйча, гаҗәпләнеп тә, хәтта куркып та, авыл башында ук туктап калды.

Авыл туздырып ташлаган кырмыска оясы шикелле ыгы-зыгы килә. Кешеләр янгын чыккандагы кебек, үзләрен үзләре белештермичә, арлы-бирле чаба. Бөтен урам буеннан-буена өй җиһазлары, түшәк-ястык, савыт-саба, иләк-чиләк белән тулган. Хатын-кызлар чәрелдәп кычкыра, бала-чага берни дә аңламыйча, бәйрәм көнендәге сыман, дөньясын онытып йөгерешә, ирләр акыра-җикерә, этләр аптырап туктаусыз өрә, песиләр капка башларыннан, койма өсләреннән сәерсенеп карап тора, казлар тилгән килгәндәге кебек, шомланып каңгылдаша.

Бары тик башларына кара түбәтәй кигән картлар белән ак шәл бөркәнгән карчыклар гына, бу мәхшәргә бернинди катнашлары юк кешеләр сыман, койма буендагы

утыргычларга тезелешеп утырганнар да, җай гына башларын селкеп, урамдагы хәлләрне тамаша кылалар.

Тимерхан авылның бер башыннан икенче башына туктаусыз чаба, кирәксә дә, кирәкмәсә дә сүзгә катнаша, кешеләргә тиккә дә җикеренеп кычкыра.

— Яңа йортка шушы сәләмәләреңне төяп барасыңмы? Ташла, күзем күрмәсен! — дип ачулана ул берсен.

— Кемгә әйтәм мин, иң элек механизаторлар күчә, дип! Аларның бүген-иртәгә чәчүгә төшәсе... Ә сиңа су буена бәбкә куасы...— дип, юл уңайлый туздырып ташлый икенчесен.

Ихтыяр авыл капкасы төбендә башын иеп басып торды-торды да, яңадан машинага кереп утырды һәм шоферга кире борылырга кушты. Авылга керә калса, йөзенә таш белән бәрерләр, барысы да аны каргарга тотынырлар кебек тоелды аңа.

— Заводка...— диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

Бу минутта Ихтыяр Ташлыярның шулай пыран-заран килүенә нигәдер үзен гаепле саный, бүтәнчә эшләп булмаганга, шушы авылны саклап калу өчен үзенең күпме көч түккәнен яхшы белсә дә, күңеле әрни иде. Авылның буш өйләре утырып калудан гына Ташлыярның инде беркайчан да элекке Ташлыяр була алмасын, авылны өйләр, каралты-куралар, кое-чишмәләр, тал-тирәкләр генә авыл итмәгәнен, кешеләр авыл иткәнен Ихтыяр әле менә яңа аңлагандай булды.

— Ташлыяр юлына егерме машина куегыз. Төнгә кадәр, смена беткәнче ташысыннар! — диде ул завод капкасы төбендәге будкада утыручы диспетчерга.— Шәһәр бүгенгә түзеп торыр. Ташлыяр түзә алмый! Ташлыярга юл кирәк, бетон кирәк!

Кичкә Ташлыяр, әле генә дошман явы үтеп киткән төсле, бушап, шыксызланып калган иде. Урам буйлап бары тик чүп-чар очып йөри дә иясез калган этләрнең сирәк-мирәк үзәк өзгеч итеп улаганы ишетелә. Капка төбендә мәче баласы нәзек тавыш белән елап утыра. Ихтыяр, машинадан төшеп, аны кулына алды да нәни башыннан сыйпады.

Дөм караңгы авыл уртасында тәрәзәләре ялтырап торган йорт янына килеп туктагач, Ихтыярның эченә бераз җылы керде. Әтисенең иң соңгы кеше булып иртәгә төштән соң күчәсен белсә дә, ул якты тәрәзәләргә карап сокланды. Тәрәзә пәрдәләренең кулдан бәйләнгән челтәрлә-

рен, чигешләрен беренче тапкыр күргәндәй, гаҗәпләнеп күзәтте.

Капка келәсен сак кына күтәреп, ишегалдына кергәч, абзардагы сарыклар, нәрсәдер сизенеп, бәэлдәшеп алды, лапастагы казлар елак аваз белән каңгылдадылар.

Әнисе өстәл янында уч төбенә ияген куеп, моңсу гына утыра иде. Өстәлдәге яртылаш бушаган аракы шешәсен күргәч, Ихтыяр аптырап китте.

— Кунаклар булдымы әллә? — дип сорады ул.

— Нинди кунак булсын мондыйда?

— Өстәлдә бу нәрсә булганга әйтәм.

— Ә-ә... Әтиең берүзе утырып эчте аны. Гомер булмаганны! Чәй эчәсеңме, улым?

— Кайнар булса, яса.

Алар, бер-берсеннән кыенсынган кешеләр кебек, ачылып китә алмыйча, өзек-өзек җөмләләр белән генә сөйләшәләр, бер-берсенең күзенә күтәрелеп карарга кыймыйлар иде.

— Иртәгә күчәсезме? — дип әкрен генә сорады Ихтыяр.

Әнисе җавап бирмәде, битен яулык чите белән каплап, түр якка кереп китте.

— Күчсәгез, булышырмын дигән идем...— Ихтыярның кинәт кенә бар нәрсәгә ачуы килә башлады.— Әнкәй! — дип кычкырып әйтте ул.— Миңа фатир бирделәр.

Әнисе тагын эндәшмәде.

Ихтыяр ишегалдына чыкты, лапаска керде, сыер алдына кочагы белән печән салды. Бәрәңге бакчасы башындагы түтәлгә барып, кузгалак өзде. Авыл гаҗәеп тын, бу тынлыкта теш шыгырдаган тавыш аңа бөтен урамга яңгырап ишетеләдер кебек тоелды. Күктәге түгәрәк ай, туздырып ташланган Ташлыярны күрмәскә теләгәндәй, болыт артына кереп посты да, кызыксынуын җиңә алмыйча, тагын ялтырап килеп чыкты.

Бакчаның аргы башындагы арыш уҗымы читендә кымшанган карамчыкны күреп, Ихтыяр шунда таба атлады. Килеп җиткәч кенә ул читән казыгына сөялеп утырган кеше гәүдәсен күреп туктады. Менә аның сирәк-сирәк кенә сулкылдап куйганы ишетелде. Ихтыяр сагаеп калды, әкрен генә атлап читән буена ук килде. Читән казыгын кочаклап утырган кешене танып алгач, ул бөтен буыннарына хәлсезлек йөгергәнен сизде һәм аның теленнән ыңгырашуга охшаш сүз өзелеп төште:

— Әт-кәй...

Әтисе калтыраудан туктады, ләкин ул Ихтыярга күтәрелеп карамады, шул килеш өнсез утыруында булды.

— Кит моннан! — дип, җан ачысы белән кинәт кычкырып җибәрде ул.— Кит моннан! Күземә күренмә!

Ихтыяр бит очлары уттай кызыша башлавын сизде, ул, тамак төбенә килеп терәлгән төерне йотып җибәрә алмыйча, бакча уртасыннан өйләренә таба йөгерде. Күзенә ак-кара күренмәде, бәрелә-сугыла ишегалдына керде, урамга чыкты, ташу суы басылган инешнең тез тиңентен сазын ярып, мышный-мышный атауга менде. Тәрәзә дөбердәтүгә, эчтән бабасының баздан чыккан кебек тонык авазы ишетелде:

— Кайсы вакытсызы анда?

— Мин! Ихтыяр...

— Котырды бугай бүген Ташлыяр халкы,— дип сөйләнә-сөйләнә бабасы озаклап ишекне ачты.

Өйгә кергәч, Ихтыяр, сүзен әйтә алмыйча, шактый вакыт башын аска иеп утырды.

— Чыраең качкан, чыланып беткәнсең. Нәрсә булды, улым? — дип, тыныч, йомшак кына итеп сорады бабасы.— Юлыңа бандитлар очрамагандыр бит тагын?

— Әти елый...

Ихтыяр, бабасының елмаюын күреп, аптырап калды, чынмы бу дигәндәй, күзләрен челт-челт йомгалады.

— Еларсың да шул! — дип, Зыятдин карт җәһәт торып басты. Кинәт кенә аның бөтен җыерчыклары язылган, йөзе яшәргән кебек тоелды, кыяфәтенә үҗәтлек катыш горурлык кайтты.— Еламый хәлең юк. Заманында безне дә елаттылар. Гомер буе корган нигезеңне көпәкөндез тартып ала башласалар, еламас җиреңнән еларсың! Үзе төзегән, үзе аякка бастырган колхоз шул. Уртак булса да, кадерле. Сөйләве, читтән акыл өйрәтеп торуы гына ансат ул. Үзеңә килеп кагылгач, аңлый башлыйсың да... Әйдә еласын, елаган җанда иман була. Елый алган кеше бәхетле ул. Мин менә хәзер елый алмыйм.

Бабасының тынычлыгы Ихтыярга да күчә башлады бугай, ул, нәрсәдер әйтергә җыенып, авызын ачты, ләкин туктап калды. Зыятдин карт чөйгә эленгән мылтыкны алып маташа иде.

— Мә, улым, сиңа бүләгем булсын,— дип, ике көпшәле мылтыкны Ихтыярга сузды.— Нәзер әйткән идем...

Ал, ал, минем төсем итеп сакларсың. Миңа кирәге юк инде аның хәзер.

Ихтыяр мылтыкны, көпшәсеннән тотып, караватн кырыена сөяп куйды.

— Сиңа әйтәсе сүзем бар, бабай,— диде дә күзләрен Зыятдин карт кебек кыскалап куйды ул.

— Әйт соң.

— Иртәгә күчәбез, бабай.

— Күчегез. Хәерле сәфәр сезгә!

— Юк ла, аңламадың. Мин фатир алдым. Ике бүлмәле. Берсе — синеке. Күчәбезме шунда?

— Зәлия килен нәрсә ди?

— Аның үз фатиры бар. Аның өчен борчылма,— диде Ихтыяр, исе китмичә генә.

— Нинди башка фатир ул тагын?

— Аерылышабыз без аның белән... Күптән түгел хаты килде. Казанга баргач, Нурислам барысын да сөйләгән аңа...

— Нәрсә сөйләгән? Нәрсәнең барысын да сөйләгән?

— Яңа йортка күчкәч, иркенләп, озаклап сөйләрмен, бабай.

— Һе-ем,— дип, озак итеп сузып торды Зыятдин карт.— Беренче күрүдә үк сәеррәк тоелган иде шул килен. Ялгыз калдым, дисең инде алайса. Ялгызлыкның ни икәнен аңламыйсың әле син, улым. Ярый алайса, күчәргә икән, күчәргә!

Зыятдин карт бүген гомер булмаганча тыныч һәм ипле сөйләшә, аның элекке тискәрелеге әйтерсең Ташлыяр кешеләре белән бергә күченеп киткән, аның Ташлыяр кешеләренә булган үпкәсе, ниһаять, басылган иде.

* * *

Сабан туена кайтырга чакырып, Ихтыяр бөтен туганнарына да телеграмма сукты. Инде күптән җиде туган бергә җыелырга җай чыкмый иде, бу юлы әллә Яңа Ташлыярны күрәсе килүдән, әллә инде сагынулары тулып ташудан берәм-берәм кайта да башладылар. Бары тик Ташкенттагы олы апаларыннан гына хәбәр-хәтер юк иде.

Иң беренче булып, ялтырап торган өр-яңа зәңгәр «Москвич»ка гаиләсе белән төялеп олы абыйсы Илфат кайтып төште. Туган-тумача белән капка төбендә ашыкпошык исәнләште дә кое төбенә барып машина юарга

тотынды. Чәй эчәргә чакырып та кермәде, юып бетергәч, җиргә брезент җәеп, машина астына ук кереп ятты.

— Илфат улым, качмас машинаң, иртәгә иркенләп карарсың. Җиде ел йөзеңне күргәнем юк бит, чык аннан,— дип такмаклады әнисе.

Илфат машина астыннан майга, балчыкка буялып беткән йөзен чыгарды да эре тешләрен күрсәтеп рәхәтләнеп көлде.

— Күрдеңме инде, әнкәй? Таныйсыңмы олы малаеңны? Хәзер, хәзер, айн момент! Глушитель ычкынган, юлларыгыз чокыр да чакыр. Җиде ел эчендә шул юлны да рәтләмәгәнсез. Минем машина аласын белә идегез бит.

— Абый, кеше алдында уңайсыз бит, керик инде,— дип тагын чакырып карады аны Ихтыяр.

— Без — эш кешесе. Эшне эшләми — ат та кешнәми, ди торган иде без бәләкәй чакта бабай. Бир әле ундүртле ачкычны. Машина, кызлар кебек, сыйпап торганны ярата. Җиде ел көттерде ул мине. Ә хатын миңа кияүгә чыгарга бер кичтә ризалашкан иде. Үзең шуннан уйлап кара инде, кайсысы кадерлерәк миңа! Машина алу уен эш түгел. Карале, машинага чират зурмы монда?

— Хәстәренә кергәнем юк. Төзүчеләр ике-өч елдан алалар бугай.

— Китче! Шыттырма! Булмаганны!

— Нигә шаккаттың? Ике кешенең берсендә машина бит хәзер. Чәберчек Әхмәт тә алтынчы марка «Жигули» алды. Безнең белән укыган Әхмәт.

— Төзелештәмени ул да?

— Юк. Авылда эшли, тракторчы.

— Авылда да машина ала башладылармыни?

— Ташлыярда җиде «Жигули», дүрт «Москвич» бар дип санап утыра иде беркөнне әткәй. Комбайнчы Чутыр Миннәхмәтне беләсеңме? Ул узган көзне егерме дүртенче маркалы «Волга» алды.

Машина астында нәрсәдер чылтырады, Илфатның кулыннан ачкычы төшеп китте бугай. Ул сүгенә-сүгенә үрмәләп чыкты да кое суы белән башын юарга тотынды.

— Кадалып китмәс әле,— дип, ачу белән тәгәрмәчкә тибеп куйды ул.— Әйдә, керик, картларның хәлен сорашыйк.

— Иртәгә Әхмәткә әйтербез, минут эчендә эшләп бирә ул аны,— дип, абыйсын юатты Ихтыяр.

Чәй эчкәч, тагын кое янына чыктылар. Ак кирпеч белән кызыл кирпечне аралаштырып, чәчәкләп төзелгән йорт

стеналарына, яран гөлләр балкып утырган якты һәм киң тәрәзәләргә, күзне чагылдырган ялтыравык калайлы өй түбәсенә карап, шактый вакыт машинага сөялеп тордылар.

— Әткәйнең йорты кәттә булган! — дип, яңа күргәндәй, тел шартлатты Илфат.— Бөтәйгән авыл халкы, аякка баскан.

Авыл тормышына гаҗәпләнеп сөйләнсә дә, нигәдер күзләрендә сөенеч уты юк иде аның. Җиде җир читләренә барып, көн-төн маңгай тире түгә-түгә син машина ал, шатлыгыңны уртаклашам, дип, атыла-атыла чабып иң беренче монда кайт, ә алар беркая китмичә, шушы Ташлыярда торып «Волга» алсыннар, синнән дә уздырып яшәп ятсыннар... Илфатның шуңа җаны әрни, шуңа бәгыре телгәләнә иде.

Абыйсының бөтенләй сөмсере коелуын күреп, Ихтыяр аның хәлләрен, юл мәшәкатьләрен сораша башлады.

— Алты тәүлек кайттык. Машина түгел, зверь бу! — дип тагын ачылып китте абыйсы.

— Әллә шул зверең белән тиз генә бабайны күчереп кайтабызмы?

— Кая күчерәбез?

— Мин фатир алдым. Бабай шунда күчә. Киттекме?

Зыятдин карт үзенең вак-төяген җыйнап, бер төенчеккә төйнәде. Калган әйберләрне йөк машинасы белән килеп алырга булдылар. Өчәүләшеп беркавым тын гына утыргач, ишегалдына чыктылар. Ихтыяр ике бармагын авызына капты да әче итеп сызгырып җибәрде. Өянке башындагы каргалар, Зыятдин карт белән саубуллашкандай, атау өстендә бөтерелә башладылар.

— Атауның җеннәрен качырасыңмы әллә? — диде Илфат.

— Аның җене берәү генә иде. Анысы да җүнле җен булып чыкты,— дип, бабасын кочаклады Ихтыяр.

Ташлыяр урамының шәһәргә чыга торган очында, буш урамны иңләп, «ДТ» тракторы килгәне күренде. Трактор урамның әле бер читенә чыга, әле урынында бөтерелеп тора, әле барган җирдән туктап кала. Илфат машинасын юл читенә борды да, моторын сүндереп, машинадан чыкты. Ихтыяр да урам уртасына басты.

— Әхмәт бу. Салган. Андый гадәте юк иде,— дип, тракторга каршы атлады ул.

Әхмәт аның өстенә килүендә булды. Үзе тракторын үкертә, үзе бөтен көченә кычкырып җырлый.

Карурманны чыккан чакта,
Уңга каерылгач та...
Их, дускаем, рәхәт яшә,
Миннән аерылгач та.

Трактор килеп җитүгә, Ихтыяр бер читкә сикереп калды, Илфат, күзләрен зур ачып, машинасына текәлде. Әхмәт үкертеп газга басты да машинага ышкылып дөбердәп узып китте.

Икәүләшеп йөгереп барып машинаны капшарга тотындылар. Бәхеткә каршы: трактор ышкылып кына узган, бер җирен дә яньчемәгән, азрак буявын гына сыдырган иде.

Янәшәсендә Зыятдин карт утыруга карамастан, Илфат һаман сүгенүендә булды. Басуга чыгып, зират турына җиткәч, бабасы аңа каты итеп төртте дә башы белән шул якка ымлады.

— Тәмсез авызланма, кайнарыңны бас. Баш бәласе түгел,— диде ул.

Шәһәр урамына сүзсез генә килеп керделәр. Ихтыяр һәр йортның салыну тарихын, кайсы йортта кемнәр яшәвен сөйләп бара башлаган иде, абыйсының әле һаман үз борчуларыннан арына алмаганын күреп, туктап калды.

— Сөйлә, улым, барысын да рәттән сөйлә,— дип куәтләде аны Зыятдин карт.— Миңа кызык болар, мин монда яшисе бит.

— Менә бу ике катлы бина райком булыр, монысы — загс, бусы — милиция, әнә теге искерәге — редакция... Абый, туктат әле!

Ул урам чите буйлап атлый-йөгерә баручы Сәбиләне күреп алды. Сәбиләнең хәрәкәтләре ышанычсыз, йөзе борчулы, ә күзләре беркемне дә күрми сыман иде. Үз исемен ишеткәч, ул, аптырап, күтәрелеп карады да сүлпән генә елмайды.

— Кая чабасың болай? Таптап китә яздың бит,— диде Ихтыяр.

— Бакчага, балаларны алырга.

— Мин сиңа атна буе шылтыраттым. Телефоның җавап бирми.

— Эшкә чыкмадым мин. Авырдым.

Ихтыяр шунда гына аның эчкә баткан күзләрен, суырылган яңакларын, элекке алсулыгын югалткан иреннәрен күрде.

— Шылтыратасың калган. Хәл белергә килгән булыр идем.

Сәбилә җавап бирмәде, иреннәрен каты итеп тешләде дә ашыгып башын селкеде. Ихтыяр беркавымга югалып калды, теленә килгән иң беренче сүзен әйтергә ашыкты:

— Нурисламнан хәбәр юкмы? Мине бөтенләй онытты ул...

— Онытты...— дип авыр итеп сузды Сәбилә һәм аның күзләреннән ике бөртек яшь тәгәрәп төште.— Күптән түгел хаты килде. Кандидатскиен яклаган. Максатына ирешкән. Шул кандидатскийдан башка бернәрсә дә кирәк түгел иде бит аңа. Шәһәре дә, эше дә, дуслары да шул кандидатский яклаганчыга чаклы гына кирәк иде. Яклады да онытты. Хәзер инде мин дә артык. Мин аңардан башка да яшәрмен. Балалар...

Сәбилә бераздан мөлаем һәм серле кыяфәтенә кайтты. Ләкин Ихтыяр, күпме генә тырышса да, үзен кулга ала алмады. Сәбиләнең күзләрендә яшь күргәч, бу хәлләрнең барысына да үзен гаепле санап, йөрәге урыныннан купты. Илфатның машина кычкырткан авазы аны айнытып җибәрде.

— Хәзер нишләргә уйлыйсың соң? — диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп, һәм Сәбиләнең кулларын кысты.

— Белмим... Син нәрсә киңәш итәсең соң?

— Мондый эштә киңәш сорамыйлар.

— Киңәш сорамыйлар...— дип, үз-үзе белән сөйләшкәндәй әйтеп куйды Сәбилә, аннары Ихтыярга күтәрелеп карады.— Ә минем киңәш сорыйсым, кемнеңдер сүзен тыңлыйсым, кемгәдер буйсынасым килә. Арыдым мин, бар нәрсәне дә берүзем генә хәл итеп арыдым.

Ихтыяр машина тәрәзәсеннән үзенә кул болгаган Илфатка карап алды да Сәбиләнең кулларын тагын да катырак итеп кысты.

— Без күченәбез. Мин фатир алдым,— диде ул.— Сезнең күршедәге йорттан. Балконга чыксаң, сезнең тәрәзә күренеп тора.

— Яхшы булган.

— Яңа фатирда Нурислам белән, синең белән, дуслар белән җыелышып утырырбыз дигән идем...

— Нурислам хәзер башка җирдә башка кешеләр белән утырадыр инде.— Бу сүзләрне әйткәндә Сәбиләнең йөзендә мыскыллы елмаю йөгереп узды.— Ә син Нурисламның кайда эшләгәнен беләсеңме соң? — диде ул кинәт кенә.

— Юк.

— Зәлия белән бергә алар... Бер кафедрада. Шәп компания! Зәлиянең Сарымсаковка кияүгә чыгарга йөргәнен дә белмисеңме?

— Минем өчен кемгә чыкса да барыбер,— диде Ихтыяр. Ләкин бу турыда беренче мәртәбә Сәбиләдән ишетү аңа уңайсыз иде.— Без аның белән туйдан соң бүтән очрашмадык бит. Туйның икенче көнендә үк өйдә тавыш куптарды ул. Башта Нурислам белән сине чакырган өчен бәйләнде. Аннары, шушы да булдымы туй, авыз ачып юньле сүз дә әйтә белмиләр, дип, кичкә кадәр сукранды. Әткәй белән сөйләшү түгел, исәнләшмәс үк булды. Казаннан үзенең дус-ишләрен туйга чакырган булган. Вакыты килеп терәлгәч кенә әйтте: аларны барып алырга кирәк икән. Баштарак белсәм, берәр транспорт тапкан булыр идем. Әткәйдән колхоз автобусын сорадым. Ә ул: «Уттай эш өстендә автобусны эштән аера алмыйм. Көненә өч мәртәбә сыер савучыларны җәйләүгә төшерәсе бар»,— дип кырт кисте. Шуннан китте тавыш, китте тавыш. Туй алдыннан көчкә тынычландырдым Зәлияне. Икенче көнне тагын тотынды. Бөтенләй истерикага бирелде. Безнең әткәйнең талканы коры: «Бүтән җирдә теләсә нәрсә эшләгез, ә минем йортта бүтән болай юккабарга тавыш чыгарасы булсагыз, тупсамны атлап кермәгез!» — дип, ишекне шапылдатып чыгып китте. Зәлия саубуллашкан чакта: «Минем бу йортка аяк басасым юк. Яшисең килсә, Казанга кил. Йә әтиең, йә мин»,— дип ультиматум куйды.

— Минем кебек җебегән түгел ул, югалып калмаган,— диде Сәбилә, Зәлияне яклаган сыман.

Өзек-өзек итеп озаклап, Илфат тагын машинасын кычкыртты.

— Кая ашыгасыз? Анда көтеп торган кеше юк! — дип кычкырды аларга Ихтыяр. Аннары Сәбиләгә карады: — Машинада бабай да утыра. Аның сүзен тыңласам, күптән акыллы баш була идем инде. Туй ясар алдыннан: «Ашыгасың бугай, улым, күңелгә ята торган кешегә охшамаган бу килен буласы кешең»,— дигән иде.

— Үзенең хатынын яманлаган ир кешене аңламыйм мин,— диде Сәбилә.— Үткәнгә түгел, киләчәккә карап яшәргә тиеш ир-ат.

— Киләчәктә — билгесезлек...

— Ярый, мин киттем,— дип, Ихтыярның учларыннан үзенең кулларын тартып алды Сәбилә.

— Әйдә безгә! — дип, малайларча ялварып, Ихтыяр аның күзләренә текәлде.— Уйныйбыз, җырлыйбыз! Өй туе ясыйбыз!

— Синең туйларның ахыры начар бетә бит...

— Ә монысы алай булмас! — Ихтыяр учлары белән Сәбиләнең битен кысты.— Әйдә безгә! Бөтенләйгә! Мин инде бу сүзне күптән әйтергә җыенып йөри идем. Нурислам аркасында әйтмәдем. Ә хәзер...

Сәбилә кинәт кенә хәлсезләнеп киткәндәй булды, ул башын Ихтыярның иңенә куеп пышылдады:

— Шаяртуыңмы бу? Ә Ринат? Рәйханә?

— Син Ринат белән Рәйханәне аласың! Мин — бабайны! Көт! Килеп алырмын!

Сәбилә, үксеп җибәрүдән көчкә тыелып, кырт кына борылды да урам буйлап ашыгып китеп барды.

— Кем ул? — дип сорады Илфат, машина кузгалгач.

Ихтыяр эндәшмәде. Бабасы Сәбиләне таныганын аңлатып, мәгънәле итеп тамак кырып куйды.

Икенче катка менеп, ишек янына килүгә, аларны комбинезон кигән егет кычкырып сәламләде.

— Фатирыгыз котлы булсын! — дип, подъездны яңгыратты ул.

— Кая ташыйсыз моны? — дип, аның сәламенә сорау белән җавап бирде Ихтыяр һәм ишек төбенә өелеп торган җылыткыч батареяларга күрсәтте.

— Теләгән кешеләргә иң беренче ярдәм күрсәтеп йөрибез. Кыш җиткәч, соң була ул. Мәшәкате дә, бәясе дә икеләтә артык, суны агызып эшлисе.

— Берни аңламыйм, нәрсә сөйли бу, абый?

— Батареялар өстәмәкче була. Шунсыз кыш катып үләсең син. Институт бетереп шуны да белмисеңме?

Ишекне ачып кергәч, Илфат тәрәзә астына куелган батареяга төртеп күрсәтте.

— Ничә секция булырга тиеш монда, инженер?

— Сигез.

— Ә ничәү куелган?

— Өч...— дип сузды Ихтыяр.— Нигә сигезне куймаганнар? Дәүләт комиссиясе ничек кабул иткән моны?

— Кабул иткән, димәк, җиткәнгә санаган,— дип сүзгә кушылды комбинезонлы егет.

— Бу батареяларны каян алдыгыз? — дип кызыксынды Ихтыяр.

— Монысы сер инде,— диде дә егет, кирәк булмаса,

киттем, дигәндәй, ишекне ача башлады.— Мин сезне күрмәдем, сез — мине.

— Тукта! Тукта,— дип, җиңеннән тотты аның Илфат.— Барыбер куйдырасы инде аны. Керт батареяларыңны да эшкә тотын. Хакы ничегрәк сездә?

Егет ике бармагын тырпайтты.

— Берсе ике тәңкә, димәк.

Бабасына урын-җир җәеп, күрше кибеттән азык-төлек алып чыктылар да, аны слесарь егет белән калдырып, Яңа Ташлыярга киттеләр.

— Чыннан да, каян алалар икән ул батареяларны? Кибеттә сатылмый бит,— дип, юл уңайлый тагын теге егетне искә төшерде Ихтыяр.

— Каян булсын? Яңа төзелә торган йорттан.

— Анысына тагын бу егетләр батарея куеп йөриме соңыннан?

— Менә бит, үзең дә аңлый башладың. Акыл бар синдә, юкка баш инженер булып йөрисең. Бу егетләр белән компаниягә керсәң, аена өч йөз иллене түгел, меңне каерыр идең.

— Шулай бер йорттан икенчесенә батарея күчерә-күчерә кешеләрдән күпме акча талыйлар, ә?!

— Кеше талаумыни бу? Егерме-утыз тәңкәңне чыгарып саласың да рәхәтләнеп җылыда утырасың.

— Аны әйтмим әле мин. Бөтен төзелеш алыш-биреш системасына корылган бит безнең. Материалны әрәм-шәрәм итеп бетерәбез дә салынасы йортлар, алдагы еллар хисабына эшли башлыйбыз. Илне алдыйбыз, дәүләтне талыйбыз. Райком пленумында шуларның барысын да чыгып сөйлим, йөзләренә бәреп сөйлим!

— Илфат абый өйрәтте, дип кенә әйтә күрмә.

Редакция янына җитәрәк, Ихтыяр урамдагы кешеләргә йотылып карады, ләкин йөзләгән кеше арасында Сәбиләне күрмәде. Әйтерсең Сәбилә кешеләр ташкыны арасында эреп юкка чыккан иде.

— Нигә өстерәләсең? Ку, әйдә! — дип кычкырды ул абыйсына һәм, күзләрен йомып, маңгаен ишек пыяласына терәде.

Илфат аңа сәерсенеп карады һәм газга басты.

Шәһәрне чыгып киткәндә, Ихтыяр абыйсының җиңенә кагылды да кулын рульгә куйды.

— Туктат әле,— диде ул.

Башка сүз әйтмәде, машинадан чыкты да урам читен

тутырып килүче кешеләрне ера-ера агымга каршы йөгерде.

— Менә юләр! — дип куйды Илфат һәм, Ихтыярның кирегә борылырга уйламавын күреп, кузгалып китте.— Башы әйләнгән энекәшнең!

* * *

Ихтыяр Яңа Ташлыярга икенче көнне иртән генә кайтты.

— Шушындый матур көнне ничек итеп өйдә сөрсеп утырасыз? Әйдәгез, урман буйларын әйләнеп төшәбез дә бабай янына элдертәбез,— дип, өйдәгеләрне ашыктырды Ихтыяр.

Илфатны, ай-ваена карамыйча, аягыннан тотып машина астыннан сөйрәп чыгардылар да урам иңләп авыл очына менеп киттеләр. Балачак истәлекләрен яңартаяңарта, инеш буйларында йөрделәр, урманга менделәр, аннары, җыелышып, Ташлыярга төштеләр.

Зират тынлыгы иңгән авыл, алар килеп кергәч, сискәнеп уянгандай булды. Урамның аргы башына чыкканчы берсе дә авыз ачып сүз әйтергә кыймады. Гүяки алар туып-үскән авыллары буйлап түгел, ә үзләренең балачаклары, риясыз еллары күмелгән каберлек аша үтеп баралар иде.

Авыл белән шәһәр арасындагы басуга чыккач кына, бераз җиңел сулап куйган кебек булдылар.

— Менә, менә, шушы төштә бәрдереп китте машинаны,— дип, иң беренче Илфат телгә килде.— Авызын чабата хәтле ерган, күзләре акайган, үзе тамагын ертаерта җырлаган була. Әрәм итте өр-яңа машинаны, күзенә кылчык кадалгыры!

Ләкин хатыны Миңзифадан башка аңа кушылучы, аның сүзен куәтләүче булмады.

Офык читендә кинәт кенә калкып чыккан ак каланы күреп, берсен-берсе уздыра-уздыра, Ихтыярга сораулар яудырырга тотындылар.

— Ә-әнә теге иң биеге ничә катлы? Безнең Ижауда да юк андый йортлар...— диде Илсөяр апасы.

— «Каенсар» дип атала ул йорт. Уналты катлы. Гел Каенсар авылыннан күчкән кешеләр генә яши анда. Беренче секретарь идеясе. Гомер-гомергә бергә яшәгәннәр, хәзер дә бергә булсыннар, дип, барысын да бер йортка

керттерде. Су баскач, төрлесе төрле якка таралып бетә язганнар иде, менә тагын бер нигезгә җыелдылар. Бер йортта — бер авыл. Кызык бит, ә?

— Масш-та-аб,— дип сузды Уфадан кайткан Гөлсинә апасының ире.

— Бездә күп хәзер андый йортлар,— дип сүзен дәвам итте Ихтыяр.— «Кушнарат» дигәне дә, «Акчишмә» исемлесе дә бар.

— Димәк, авыллар бетә...— Алма-Атадагы Мәдинә апасы авыр итеп көрсенде.— Берничек тә саклап булмыймыни соң аларны? Кунакка кайтулар бигрәк рәхәт бит авылга...

Инде урам булып оешып килгән йортлар арасыннан үтеп, озын-озын тәпиләргә менеп кунаклаган тугыз катлы йорт каршына килеп туктадылар.

— Атау Зыятдины менә шушында яши,— диде дә Ихтыяр подъезд ишеген киереп ачты.— Ихтыяр Батыршин фатирына — Ташлыяр авылы илчелегенә рәхим итегез!

Кулына түгәрәк ипи тоткан Тимерхан иң беренче булып тупсаны атлап керде.

— Хәерлегә булсын! Бу бусагадан кайгы-хәсрәт йөрмәсен! — диде ул.— Шушы йортта озак һәм тигез гомер итәргә язсын!

Ихтыяр кичә Сәбилә белән очрашканнан соң, өй туен беразга кичектерергә уйлаган иде. Ул үзенең Зәлия белән булган мөнәсәбәтләре, дөресрәге, бу мөнәсәбәтләрнең ничек башланган булса, шулай кинәт кенә өзелүе турында туганнарына сөйләргә кыенсына, ә иң мөһиме, Сәбиләне ничек итеп аларга күрсәтергә, ничек итеп үзенең яңа тормыш башларга җыенуын аңлатырга белми иде. Җитмәсә, кичә яңа фатирга күчү белән бабасы да авыраеп китте.

— Нәрсәгәдер йөрәгем чәнчеп, күз кабакларым тартышып тора әле,— диде ул һәм түр бүлмәгә кереп ятты. Шул ятуыннан әле менә бүгенгә кадәр кузгалмады.

Ихтыяр аның аяк очына утырып, кыенсына-кыенсына гына сүз башлады.

— Теге вакытта атауда утырган идек, хәтерлисеңме? — диде ул, бабасының юрганын рәтли-рәтли...— Нурислам белән... Ул аерылган бит, хатынын ташлап киткән. Казанда яши. Зәлия белән бергә эшли.

— Табышканнар икән,— дип сукранды карт.

— Зәлия аңа түгел, үзенең җитәкчесенә кияүгә чыккан.

— Аңлыйм, улым, тел төбеңә төшенәм. Рәт чыкмады

ул Нурисламнан. Күп сөйләшкән бәндә кешене дә бутый, үзе дә бутала ул.

— Мин Сәбиләне үзебезгә алып кайтмакчы идем.

— Балаларына әти була алырсыңмы соң? Шунысын уйла.

— Уйладым, бабай...

— Үзеңә кара. Соңыннан үкенерлек булмасын.

Кич Сәбилә аларга табын әзерләшергә килде. Ул Зыятдин карт белән исәнләшеп кенә чыкты да, аңа күренергә кыенсыныпмы, әллә авыру кешене борчырга теләмичәме, төнгә чаклы кухняда булды. Ихтыяр аның янына тиз генә чыгып керә дә яңадан бабасы кырына килеп утыра. Бер төн эчендә Зыятдин карт ябыгып калды, күзләре эчкә батып, болай да юка борыны кылыч кебек тырпаеп чыкты.

— Мылтыкны... кая... куйдың? — дип өзеп-өзеп сорады ул Ихтыярдан.— Алып кил аны монда.

Ихтыяр куш көпшәле мылтыкны шкафтан алып бабасына бирде.

— Ә хәзер кадак белән чүкеч ал да баш очыма элеп куй. Гомер буе минем баш очында эленеп торды ул. Миннән түгел, шул мылтыктан куркып кермиләр иде атауга. Шушы мылтык аркасында тегермән дә, яргыч та, сушилка да исән калды. Сүз белән, закон белән яклый алмадым мин үз-үземне. Нишлисең, заманасы шундый иде. Законым да, сүзем дә шушы булды. Дошманнарым шушы мылтыктан курыктылар. Кирәк чакта аның атмый калмасын белеп тордылар. Үзен яклый белергә, саклый белергә тиеш кеше. Ныклыгың юк әле синең, улым. Сындыра күрмәсеннәр. Сәбиләне какма. Күзләре моңлы кеше бәхетен тиз җуя торган була. Сакла син аны. Теге вакытта атауга килгәндә үк сизгән идем мин сезнең араны. Ялгызлыктан да авыр хәсрәт юк. Үзең дә ялгыз калма, бүтәннәрне дә ялгыз итмә.

Зыятдин карт кытыршы һәм салкын куллары белән Ихтыярның иелгән башыннан сыйпады.

Таң атканда, бабасы йокыга китте. Ихтыяр Сәбиләне озатып куйды да туганнарын алырга Ташлыярга юл тотты. Алар әйләнеп кайтканда, Зыятдин карт уянган, аның төс-кыяфәте кичәгегә караганда яхшыра төшкән иде.

— Әллә фатирны бутадык, әллә күршеләргә килеп кердек! — дип шаккатты Илфат, өстәл тулы сый-нигъмәтне күргәч.— Әле кичә кич кенә шып-шыр иде монда...

Маһруй белән Тимерхан да аптырашып бер-берсенә карашып куйдылар.

— Табынга рәхим итегез! — диде Ихтыяр.

— Барыбер ышанмыйм! Ир кешенең шушындый сыйнигъмәт әзерли алуына ышанмыйм! — дип, һаман сөйләнүендә булды Алма-Атадан кайткан Мәдинә апасы. Ул янәшәсендә кысык күзләрен йомгалап утырган иренә төртеп алды.— Безнең Артыкбай, ашханәдә эшләсә дә, бишбармактан башка нәрсә пешерә белми...

— Өй булгач, хуҗасы да, килене дә — барысы да булыр, шаккатмагыз,— диде Ихтыяр.— Әйдәгез, бер рәхәтләнеп гөрләшеп утырыйк әле! Кош балалары сыман бөтен илгә таралышып беттек бит!

— Татарга кая барса да үз ватаны,— дип, җитди кыяфәт белән ялгап китте Илфат.— Япон утравыннан Балтыйк диңгезенә хәтле таралган бит безнең халык.

Зыятдин карт чакырып та чыкмады. Оныклары, аның караваты кырыена утырып, маңгаен тоткалап карадылар, кулларыннан сыйпадылар, олы бүлмәгә чыгып, өстәл тирәли түгәрәкләнеп утырдылар.

— Миңа карамагыз, рәхәтләнеп көлешегез, җырлашыгыз. Тагын кайчан болай җыелышасыз? Сезне күргәч, әйбәтләнебрәк киткәндәй булды әле хәлем. Болай барса, Аллага тапшырып, иртәгә аякка да басармын, шәт.

Зыятдин бабай тырышып елмайгандай итте, ләкин аның елмаюы иреннәрендә генә торып калды, битләренә, күзләренә күчә алмады. Ул, хәлсезләнеп, тагын урынына ятты.

Мәҗлес бик сүрән генә башланып киткән иде, торабара өстәлгә җан керде. Күрше бүлмәнең ачык ишегенә карый-карый пышылдап сөйләшергә тырышсалар да, утыра торгач, телләр чишелде. Ә инде һәркем үз тормышы, үз гаиләсе, үз хәле турында сөйли башлагач, Зыятдин картның авыруы бөтенләй исләреннән чыкты.

— Кайда да бер тормыштыр инде,— дип, аларны тынычландырырга тырышты Ихтыяр.— Анда да шәһәр, монда да шул ук шакмаклы йортлар!

— Монда... тагын да... сезнең... заманчарак... төзелә йортлар,— дип, җөмләсен көчкә ерып чыкты Рязаньда яшәүче Илгизә апалары. Аның маңгаеннан хәтта бөрчек-бөрчек тирләр бәрде.

— Ничек сезнең? — дип кабынды Ихтыяр.— Безнең, дияргә кирәк. Үзебезнең шәһәр бу.

— Шәһәрне мактыйсың мактавын, машиналар да күп, дисең, ә менә запчасть сата торган кибетегез дә юк икән.—

Илфат сүзне тагын үз ягына борды.— Сыдырылган ишек белән йөри алмыйм бит инде мин. Ничек кайтып күренмәк кирәк мондый машина белән? Буямасаң, хәзер күгәреп чыга ул. Сиптереп буятырга кирәк.

— Әйттем бит мин сиңа поезд белән генә кайтыйк, дип! — Илфатның хатыны Миңзифа аңа ашардай булып, текәлеп карады.— Авыл халкын шаккатыра, имеш. Юри көнләшеп бәрдергән ул тракторчың.

— Аның үзенең дә «Жигули»е бар,— дип юашланды Илфат.

— Юкка бетеренмәгез, иртәгә үк машинаң заводтан яңа чыккандай булачак! — Ихтыяр һәрберсенең үз кайгысын кайгыртып утыруына борчыла, аның шушы табын артында туганнарын бергә укмаштырасы, аларның бер шатлык белән шатланганнарын, бер борчу белән борчылганнарын күрәсе килә иде.

Әтисе, сүзгә кушылмыйча, ачык балкон ишегенә таянган да берөзлексез сигарет пыскыта. Аның бүген бөтен борчулары басылган, ул әле балконнан күренеп торган Яңа Ташлыяр авылына, күз күреме колачлый алган кадәр җиргә җәелгән басуларга, әле өстәл тирәсендә түгәрәкләнеп утырган балаларына карап, шатлыгын яшерә алмый, йөзе дә яз кояшы кебек балкый иде.

Әниләре күбрәк кухня тирәсендә кайнаша.

— Инде машиналы да булгансыз, нәрсә җитми сезгә? Тотыгыз да кайтыгыз,— дип, яннарына чыккан арада сүз кыстырып куйды ул.— Безгә дә күңелле булыр иде. Кешенекеләр кайта бит.

— Кайтырбыз да...— Илфат үзенең олы малай икәнен искә төшерде булса кирәк. Хуҗаларча кыю гына торып басты да рюмкаларны тутырды.— Әйдәгез, туган як өчен, туганнар өчен күтәреп куйыйк әле. Яңа Ташлыяр өчен! Яңа шәһәр өчен! Һәрберебезнең исәнлеге өчен!

— Утыр, әткәй! — дип, Илфат балконга чыкты.— Күпме пыскытырга була ул тәмәкене? Машина аласы булгач, ташладым мин ул кесә кортын. Яңа Ташлыярга карап торасыңмы? Карарлык та шул! Күз тимәсен. Иске Ташлыярны шәһәр йотты, дисең инде алайса. Кызганыч, әмма факт, ди безнең бригадир. Синең Ташлыярыңны гына түгел, ярты республикаңны йотачак әле ул!

— Артыгын йота алмас, тамагына тыгылыр,— дип көлемсерәде Тимерхан. Бүген аның кәефен бернәрсә дә боза алмас кебек иде.— Әнә, күрәсеңме? Ә-әнә, сөзәк кал-

кулыкта җир буе корпуслар күренәме? Завод төзиләр анда, синең төшеңә дә керми торган мировой завод!

— Төзесеннәр.

— Авыллар арткы планга күчәчәк хәзер. Шәһәр белән завод көрәшә башлаячак. Мәйдан тар, кешеләр җитми. Олы яланга җыелган ике гаскәр кебек алар хәзер. Йә сугышып китәләр, йә бергә кушылып, бер йодрык булып эшли башлыйлар. Карап-карап торам да, бер дә кушылырга торганнары күренми, һаман икесе ике якка тарта.

Бераз кызып алгач, Илфат Ихтыярдан гармун таптыра башлады.

— Гармун юк. Аннары бабай да...

— Гармунсыз өй буламыни?! Ташлыярдагы өйдә гармун бар иде бит безнең,— диде Илфат.

— Ташлыярныкы Ташлыярда калды,— дип, балконнан эндәште этиләре.

— Алайса, күршеләреңнән алып чык.

— Аларның да юктыр. Мин аларны белмим дә әле.

— Авылда туып-үсеп тә өеңдә гармун тотмаган кешене кешегә санамыйм да мин.

— Санамасаң санамассың инде. Әнә радиола бар. Пластинка куй да тыңла...— Ихтыярга, өй хуҗасы буларак, уңайсыз да, аның бабасын да борчыйсы килми иде, шул ук вакытта ул кунакларның күңелен күрергә дә тели иде. Абыйсының бәйләнүенә аның ачуы ук чыга башлады.

— Татар пластинкаларың бармы? — Илфат теләмичә генә радиоланы кабызды.

— Күп. Әнә. Тик бабай...— Ихтыяр абыйсы янәшәсенә килеп басты да ялварулы күзләре белән аңа күтәрелеп карады.

Шулчак сүзгә этиләре кушылырга булды.

— Җибәр әйдә берәр моңлы көй! — дип, егетләрчә дәрт белән балконнан аваз салды ул һәм, җил-җил атлап, өстәл янына килеп утырды.— Күрсеннәр Тимерханныкыларны! Шәһәрегезне гөрләтеп үзебезчә җырлап утырыйк әле бер! Яшибез әле болай булгач, яшибез!

Тимерхан, улларының, кызларының иңнәреннән кага-кага, башларыннан сыйпый-сыйпый, өстәл тирәсен берничә тапкыр урап чыкты.

Ихтыяр радиолага пластинка куйды да үпкәләгән кыяфәт белән урынына килеп утырды.

Җырның беренче сүзләре яңгырауга ук, аны күтәреп алдылар. Башта авыз эченнән генә, һәркем үзенең уйла-

рын, үзенең үткәннәрен хәтереннән кичереп, әкрен генә җырлады. Ләкин моңланган саен, җыр сүзләренең мәгънәсенә ныграк төшенә барган саен, күңелдә еллар буе яшеренеп яткан хисләр ургып ташый, хисләр ташыган саен, өзгәләнебрәк җырлыйсы килә.

Әниләре, бер-берсенә сыенышып, күңел моңы, җан ачысы белән җырлаучы балаларына яратып та, шомланып та карап торды да, бүлдерүдән куркып, тавышсыз гына түр бүлмәгә узды һәм әкрен генә үзе артыннан ишекне япты.

Хуш, авылым, сау бул, сәламнәр көт...

Бу җыр мәңге туктамас, аның ахыры булмас, моңы беркайчан да бетмәс кебек иде.

Ихтыяр түр бүлмә ишеге ачылганны шәйләде. Аннан әнисенең агарынган йөзе күренде. Ул, сүзен әйтә алмыйча, өнсез басып тора иде. Ихтыяр, күңелендәге шомны башкаларга сиздермәскә тырышып, урыныннан торды, абына-сөртенә әнисе янына килде.

— Бабаң үлгән...— дип үксеп җибәрде әнисе.

Ихтыяр бабасына карады. Зыятдин картның йөзендә сүрән елмаю катып калган иде. Күзләренә тыгылган яшьләрне тыя алмыйча, Ихтыяр тәрәзәнең салкын пыяласына маңгаен куйды.

Кап-кара басу өстенә чәчелгән ап-ак йортлар кинәт кенә җыелышып тәрәзә каршына килеп баскан кебек тоелды аңа. Офык читенә кадәр сузылган юл буйлап чабучы машиналар да, бу куркыныч хәбәрне ишетеп, җан-фәрманга монда ашыгалар сыман иде. Урамдагы гүләү, көчәя барып, аның колакларын тондырды, чигәләрен кысты. Ләкин ул, күзләрен тәрәзәдән алмыйча, бөтен дөньяга үче бар кеше кебек, тешләрен кысып, урамга карап торуында булды. Ихтыяр, олы дөнья шау-шуыннан аерылып, кайгылы бүлмәгә — бабасы янына керсә, күңеле йомшап үксе башласын сизә иде. Ихтыярда бабасының үҗәтлеге, бабасының холкы — бу минутта ул берьялгызы сыкрана, берьялгызы күңелен бушата, берьялгызы кайгыра иде.

Машина тавышларына, балаларның кычкырып көлешкән авазларына, төзелеш шавына кушылып, күңелләрне сыкратып, күрше бүлмәдән моңлы җыр агыла да агыла...

Хуш, авылым, сау бул...

*1983*

# *ПОВЕСТЬЛАР*

# Эт кояшы

Ма фәгалтум би Йосыф* ?

Гүя ул гомере буе яшәмәгән, гүя ул гомере буе йоклаган да менә бүген кинәт кенә уянып киткән. Гомере буе акылын бутап, фикерен адаштырып килгән уйлар бүген кинәт кенә бер җепкә тезелгән кебек булдылар. Дөнья аңа бик тә гади булып тоелды. Тирә-юньдәге кул чабуларга, соклану авазларына аз гына да игътибар итмичә, ул башны чәнчеп, авырттырып, мине кайнатып агылучы уйлар ташкынына иярде. Тора-бара уйлар белән баш мие тулыр да баш сөяге, урталай ярылып, ике карбыз кисәге кебек идәнгә тәгәрәп төшеп китәр сыман. Ә уйлар һаман килделәр дә килделәр...

Кеше рәхимсез. Бик рәхимсез! Нигә кирәк булды бу су кызларын, урман егетләрен уч төбе кадәр мәйданга менгереп, мәгънәсез сикерүләр, бил бөгүләр, баш чөюләр, кул болгаулар, йөзгә, меңгә сыгылулар аша табигатьне кабатларга тырышып тамаша куеп азапланырга? Минем ярага тоз салыр өченме? Илаһи, тиңе булмаган бөек табигатьтән көлү, аны мәсхәрә итү бит бу. Хәзер кычкырам: «Туктатыгыз бу мәхшәрне, кешеләр! Акылыгызга килегез!» — дип кычкырам. Нигә, нигә, нигә? Әле көндез генә урмандагы иң зифа каенны эһ тә итмичә җиргә егып салган агай, кич театрга килеп, каен булып бизәнгән, чибәр дигән аты да чыкмаган кызның уйнавына сокланып, нигә суган суы сыгып утыра? Ә бу меңләгән тамашачы арасында кош ите ашамаган, каен себеркесе белән арка чапмаган, нарат тупсага аяк ышкымаган бер генә кеше бармы икән?

Әнә, кайбер илләрдә ана карынында баланы төреп, балага җан өртеп торган соңгылыктан, бала туганнан соң, шул ук хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясыйлар. Ачлык елны өенә бикләнеп, кача-поса соңгы кисәк икмә-

---

* Йосыфны нишләттегез? *(Гарәпчә.)*

ген ашап исән калган бәндәләр бүген тарих дәреслеге, фән үсеше, кешелеклелек турында мемуарлар язалар, чикләвек агачыннан ясалган кафедралардан озын-озын нотыклар укыйлар, акчасы беткәч, вагон бушатырга барып, дәрес калдырган шәкерткә каш җыералар, йөз каралталар...

Тукта, нигә болай фәлсәфә сатам әле мин? Соң үзем дә шул кеше дип атала торган гыйфритләр рәтенә керәм түгелме соң? О-о-о, юк! Алар гыйффәтле гыйфритләр. Ә мин? Мин — юк! Алар үзләренең чын йөзләрен яшерәләр, һәм шуңа күрә, бер генә минутка булса да бу түбәнлекләрен онытып тору өчен, сәнгать, әдәбият, музыка дигән матур исемнәр астында яңа дөнья, яңа кеше яратмак булалар, шул уйдырма дөньяга, уйдырма геройларга табыналар, үзләрен Аллага саныйлар, даһи дип атыйлар. Ә кем соң ул даһи? Барысыннан да түбәнрәк, барысыннан да ерткычрак кеше. Ул хәтта күп вакытта законнар белән дә исәпләшми, гаилә тормышын, җәмәгатьчелек фикерен санга сукмый, бары үзе, үзенең эше, әсәре турында гына кайгыртып, үз рәхәте өчен генә яши. Әйе-әйе, үз рәхәте өчен. Чөнки көне-төне өстәлгә кадакланып утыру, ашказанын санга сукмау, янәшәсендә сәгать саен үсә баручы кәгазь өемен күрү — аның өчен иң зур ләззәт. Ас, кис, ашханә мөдире дә, архив башлыгы да булмый ул!

...Ха-ха-ха. Кул чабалар. Монда утыручыларның берсе дә бу нәрсәләрне күрмиләр, аңламыйлар микәнни? Аңламыйлар, билгеле, аңламыйлар. Берсе дә аңламый. Кичә минем нервлар белән бик кызыксынган врач та аңламый. Ул эченнән: «Бу егет акылдан язган»,— дип уйлый, ә үзе, һаман юатып: «Нервлар какшаган, нервлар. Бераз ял итеп алу комачауламас иде»,— дигән була. Дипломат, янәсе, гөмбә баш. Ә күрше хатын әйтте, йөзгә бәреп әйтте: «Дурак, юләр, алты-биш!» — диде. Югыйсә мин аңа: «Нигә ул яңа туган мәче балаларын суга салып үтердегез, бу бит вәхшилек, ерткычлык, моны Берләшкән Милләтләр Оешмасына язып җибәрсәм, сезне Җир шарыннан сөрәләр»,— дип кенә әйткән идем. Ул бот чаба-чаба көлде. Җитмәсә, «юләр» дип атады. «Юләр» бик якынча төшенчә бит ул. Әйтик, җирдә яшәүче дүрт миллиард кешенең өч миллиард тугыз йөз миллионы акылдан язган, ә калган өлеше гадәти, ди. Бик тиз арада, хәтта бер мизгелдә, шул акылдан язганнары акыллы, эта-

лон кешеләр булып, азчылык йөз миллион акылсыз булып санала башлар иде. Эш көчтә, санда бит! Ә менә болар шуны да белмиләр, ха-ха-ха... Хәзер торып басам да залны тутырып кычкырам! Миңа ышанырлармы икән соң? Алар күбрәк бит. Ә-әй, хәзер басам да: «Иптәшләр, тыңлагыз, сезнең алдыгызда — Шекспир!» — дип кычкырам. Ул вакытта ышанырлар, ышанмый хәлләре юк. Кая, күршедә утыручыларга да әйтим әле, өйләренә кайткач, кем белән янәшә утырганнарын сөйләрләр. Көләләр. Ха-ха-ха!.. Хәзер менә мин сездән көләрмен! Тыңлагыз!!!

* * *

Бу хәл шәһәр театрында булды. Балет карарга килгән тамашачылар белән зал тулы иде. Иң алгы рәттә, сәхнәгә таба бераз иелә төшеп, томырылып карап утыручы егет баштарак беркемнең дә игътибарын җәлеп итмәде. Төймәләре ычкындырылган пинжәге, кызыл балчыккамы, кангамы — ниндидер кызыл төскә буялган ак күлмәге, бер якка кыйшайган галстугы егеткә сәер төс биреп тора. Тора-бара ул тынычсызлана, вакыты-вакыты белән аякларын бер-берсенә бәргәли, кулларын шапылдатып куя башлады. Аның йөзенә ниндидер сәер елмаю җәелде, күзләре, ничектер йөз гармониясенә кушылмыйча, күз кабакларына буйсынырга теләмичә, тәннән аерылырга хокук дәгъвалаган кебек, каядыр еракка төбәлделәр. Куркыныч иде бу күзләр. Менә-менә тәгәрәп төшәрләр дә идәнгә бәрелеп чәлпәрәмә килерләр кебек. Ул авыз эченнән нәрсәдер сөйләнә, тыелып кына көлеп тә куя. Вакыт үткән саен, аның җанлануы арта барды, хәтта берничә тапкыр урыныннан сикереп торырга талпынып та карады. Тирә-юньдә утыручылар аңа гаҗәпләнделәр, тик бераздан, йә чит тел өйрәнүче студенттыр, йә азрак төшереп алгандыр, дип уйлап, бөтенләй оныттылар, тамаша ләззәтенә чумдылар. Сәхнәдәге кызлар биеделәр дә биеделәр. Ә ул аның саен тынычсызлана, канәгатьсезлек авазлары да чыгаргалап куя, кеше кул чапканда, кычкырып көлә, үзалдына нидер сөйләнә башлады. Һәм, кинәт урыныннан сикереп торып, бөтен залны тутырып: «Иптәшләр, тыңлагыз! Мин — Шекспир!» — дип кычкырды, аннары карлыккан тавыш белән шар-

кылдады. Ул көлә-көлә сәхнәгә таба атылды. Илһамланып кул болгаучы дирижерның таягын тартып алды да залга таба борылып, нәзакәтле генә баш игәч, шашынып, бөтен гәүдәсе белән калтырап, ике кулын да селтәргә тотынды. Оркестр, кылыч белән чабып өзгән кебек, капыл туктады. Тик, бар дөньясын онытып, ноталарга да, дирижерга да карамыйча, күзләрен чытырдатып йомып, музыка тылсымына бирелгән карт скрипкачы гына берни дә сизмәде. Бер мәлгә параличланып калган зал өстенә актарыла-актарыла скрипканың күңелне өшетә, йөрәктәге сагышны суырып чыгара, бәгырьне телә торган үткен, кара, суык музыкасы акты. Берәү дә скрипкачыга дәшәргә кыймады. Тамашачылар арасында милиционер табылмады. Егетне театр директоры һәм тагын берничә сәхнә эшчесе алып чыгып киттеләр. Карт скрипкачы, бары шунда гына аңына килеп, уйнаудан туктады.

* * *

Алты ай тулар-тулмас аны больницадан чыгардылар. Барыр кешесе юк, дусларыннан тартына, туганнар — авылда, шуңа күрә турыдан-туры кунакханәгә китте. Анда урын юк, диделәр, кичкә кырын килергә куштылар. Башта томан. Аяклар ирексездән трамвай тукталышына таба атладылар.

Зират аны сүзсез каршы алды. Юл кырыенда гарәп хәрефләре белән матур итеп нидер язылган биек-биек ташлар чагылды. Ул барды да барды. Ирек үзе эзли торган кабернең кайда икәнен анык белми, шуңа күрә һәр кабер янында тукталып торды. Зур ташлар, кечкенә ташлар, башына ай, йолдыз куйганнары — барысы аның миендә буталды, күзләре ташлардагы язуларны аера алмады. Ә ул һаман саен үҗәтләнеп, киреләнеп эзләде. Зират каравылчысыннан барып сорау аңа бик зур тупаслык, күз алдына китерә алмаслык дорфалык булып тоелды.

Әле кызгылт-көрән балчыгы өстенә юньләп үлән дә үсәргә өлгермәгән, гади генә тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган кабер янына килеп җиткәндә, Ирекнең аяклары көчкә сөйрәлә иде. Ул бераз вакыт тимер рәшәткәгә тотынып торды. Куллары хәлсезләнеп салынып төште, ул әкрен генә җиргә утырды һәм шыпырт кына елап җибәрде. Зиратның кайсыдыр башында ябалак кыч-

кырып куйды. Җир куенына сеңгән кешеләрне тамырлары белән кочаклап утыручы мәһабәт каеннар шомлы караңгылыкка чумдылар. Күктә, куе болытларны ерып, бөтен зират өстенә ай калыкты.

Кунакханәдә, Ирек килүгә, урын бушаган иде. Аны дүрт кешелек бүлмәгә керттеләр. Бүлмәдәшләр бик ачык, сүзчән кешеләр булып чыкты. Алар авылдан сугым мал куып килгәннәр икән. Төн уртасына кадәр мал сую урыны турында сөйләшеп утырдылар. Бер яктан алыптай сыер тере килеш кереп китә, ә икенче яктан башы башлай, эче эчләй, каны тагын үз аеры килеп чыга, имеш. Заманны, техниканы мактадылар. Ирек аларны уңайсызланып, сүз кыстырырга кыймыйча тыңлап утырды. Нәрсәнедер искә төшерә, аның күңел ярасына кагыла иде агайларның сөйләшүе.

Одеал астында тезен кочаклап, үткән тормышын, больницаны, югалган алты аен барлап, хәтере аша үткәреп ятты. Теге вакытта зиратка барганга кадәр булган барлык вакыйгаларны да хәтерли иде ул. Хәтернең ерак бер почмагында сәхнәдә кызлар биюе дә чагылып калган. Аның больницага керүенә зиратмы, әллә балетмы гаепле икән? Ник кенә дип шул балетка барды икән соң ул? Атаклы «Аккош күле» шул. Ул яраткан «Аккош күле». Бәләкәй аккошлар ничек матур итеп биегәннәр иде. Бөтенесенә теге скрипканың кара музыкасы гына гаепле. Кара музыкадан башка тагын ниләр булды соң әле анда? Ә-ә-ә, аккошлар... Аккошлардан соң — больница. Хәтердә больница, бөтен тормышыннан аерылып, ап-ак булып калкып тора. Ак бина, ак халатлар, ак урын-җир, ак пәрдә, ак түшәм, ак йөзләр, ак чәчләр, ак, ак, ак... Кызык. Бүген кунакханәгә килгәндә, җиргә беренче кар төште, ап-ак кар. Моңа кадәр аның бервакытта да беренче кар төшүен күргәне юк иде. Бәлки, күреп тә игътибар итмичә йөргәндер. Беренче кар бик тә ак була икән ул. Башта аңа хәтта артыннан больница ияреп чыккан, бөтен дөнья, больницага охшап, акка әйләнгән кебек тоелган иде. Тизрәк авылга кайтып, киерелә-киерелә коймa буйларына ак кар өясе, кар атышып уйныйсы, чын кар буранын күрәсе иде. Табиблар да авылга кайтырга киңәш бирделәр.

Кинәт кенә аның күңеленә инде күптән онытылган шигырь юллары килде.

Җиргә тагын карлар ява инде...

Ул, башын югары чөеп, бөтерелә-бөтерелә, кайный-кайный яуган ак кар өермәсенә текәлде. Кар бөртекләре белән җиргә моңсу яктылык, талгын рәхәтлек тә иңә иде кебек.

Җиргә тагын карлар ява инде,
Җир төренә тагын аклыкка.
Җир яшерә үзенең гөнаһларын,
Җир күмелә сафлык, пакьлеккә.

Миндә нигә кышлар булмый икән? —
Күңелемдә һаман көз генә...
Гөнаһларым җирнекеннән күбрәк, —
Карый алмыйм хәтта көзгегә.

Кайгыларым карлар басар иде,
Охшап калыр идем болытка.
Кешеләр кышка керә, ә мин янам
Көз калдырган моңсу бу утта.

Ак-ак карлар гүя шәфкать кызы.
Ап-ак карлар җирне дәвалый.
Ә мин янам, ә мин һаман янам, —
Мин әйтерсең көзнең дәвамы.

Йокы тынычсыз булды. Төне буе саташып чыкты, әллә нинди төшләр күреп бетерде. Төшендә буранда адашып, гаҗизләнеп йөрде. Кемнәндер язны китермәвен, җирне ап-ак килеш кенә тотуын ялварды. Имеш, ак төс гел яхшылыкка гына өндәп, чакырып тора, ә төсләрне алмаштыруы белән табигать үзенең тотрыксызлыгын күрсәтә, безне дә шуңа әйди. Больницада шуңа күрә һәрвакыт бөтен нәрсә дә ак, имеш. Йокыдан арып-талып, авыр эштән котылган кебек торды. Агайлар гырлап йоклыйлар. Бар байлыгын — кечкенә сумкасын тотып урамга чыккач, дөньяның аклыгына күзе чагылып, һушсыз калып торды.

Бәхеткә, кассада билетлар бар икән. Самолетта бер ноктага карап барсаң, күңел болгана, нәрсә турында булса да уйларга тырышырга, үзеңнең күктә, һавада икәнеңне онытырга кирәк. Югыйсә эшең харап.

Ирек күзләрен йоммады, уйландырырлык, хәзерге халәтен оныттырырлык истәлекләре болай да күп иде аның.

...Үткән гомер. Шул кыска гына вакыт эчендә күпме нәрсә күрелгән. Үткән гомер, гомеремнең нинди — бәхетлеме, кайгылымы өлеше син?! Чирек гасыр җирдә яшәлгән, тормышның чирегe үтелгән. Тагын бер сәгать-

тән самолет туган туфракка алып төшәчәк. Бер сәгать. Чирек гасыр үткән юлны кире якка бер сәгатьтә кайтам. Чирек гасыр һәм бер сәгать...

* * *

...Авылда һәр малайның үзенә генә аерым, үзенә генә хас балачагы булмый. Авылда — бөтен малайларга, кызларга уртак бер балачак. Бер инеш, бер урман, бер күк, бер җир... Тәпи йөри башлау белән бәбкә артыннан чабарга тотынасың, биш-алты елдан сыер-сарыгын да сиңа тапшыралар, ә аннары — мәктәп. Ләкин иң кызыгы болар түгел. Иң кызыгы — ыштан балагы белән маймыч сөзү һәм, арыгач чалкан ятып, болытлар арасыннан балык сырты кебек ялтырап-ялтырап кына китүче елгыр кояшка: «Эт кояшы, кит, кит, Җир кояшы, чык, чык!» — дип тамак карлыкканчы кычкыру иде.

Башка малайлардан бер нәрсә белән аерылмасам да, мине нишләптер «сәер малай» дип атадылар. Тавык-каз суйганда да кызганып елый, этине такмаклый-такмаклый каргый идем. Ә миннән көләләр, сабый шул, әле бернәрсә дә аңламый, диләр. Дөрес, кайчагында минем үземә башкаларга охшамаган сәер малай булу ошап та куя иде. Бабай әйтмешли, ни өчен кешеләр инкубатор чебиләре кебек бер-берсенә охшарга тиеш ди әле.

Мәктәптә шигырьләр язып маташтым. Әмма, күпме тырышсам да, район гәзитеннән ары китә алмадым. Анысы балачакта шигырь язып карамаган кеше бик сирәктер инде ул. Балачакның сафлыгы, самимилеге, фикер кыюлыгы — үзе чын шигырь бит. Ә шагыйрьләр — гомерләре буе сабый булып кала алган кешеләр. Тик акыллы сабый булып.

Эт кояшын куып, Җир кояшын чакырып уйнаудан башка минем күңелдә ул вакытлардан тагын ике хатирә ачык булып уелып калган.

Көн саен иртәнге дүртләрдә кысталып йокыдан уяна торган идем. Бик иренеп кенә торып, теләр-теләмәс кенә ишегалдына чыгып хаҗәтне үтәгәч, беравык, кире кермичә, тирә-юньне тамаша кылам. Авыл инде уянган була. Әтәчләрнең кычкыра-кычкыра тамаклары карлыккан, агайларның кар көрәп куллары талган. Юк, болар кызыктырмый иде мине. Мин, онытылып, морҗаның ак торба-

сыннан ургыла-ургыла чыгучы күксел төтеннең бөтерелә-бөтерелә күккә күтәрелүен күзәтә идем. Бабай, әнә шул морҗадан чыккан төтеннәр бөтенесе бергә җыелып, күктә болытлар ясала, дип сөйли иде. Ә мин болытлы көннәрне бер дә яратмыйм, безнең авыл өстендә, басуда, урманда — бөтен җирдә гел аяз булуын гына тели идем. «Эх, тагын өй саен мичкә якканнар, тагын көн болытлы була икән»,— дип уйлап, кәефем кырылып өйгә кереп китә идем. «Соң шул мичкә якмасалар, ни була инде? Толыпка төренеп утырып та туңмас идек әле»,— дип уйлый иде минем сабый күңел. Янәсе, һәркем, үз җылысы турында кайгыртып, бөтен кешеләргә начарлык эшли, уртак кояшны каплый. Бу фәлсәфәне, билгеле, үсә төшкәчрәк уйлап чыгардым.

Гомумән, балачакны искә төшереп ләззәтләнергә, балачак истәлекләреннән зур фәлсәфәләр табып юанырга ярата идем мин. Тик менә инде күптән, шул ук малай чакта булган бер вакыйгага гына һаман да фәлсәфә чыгара алганым юк әле. Шуңа күрәдерме ул мине, бөтен хатирәләремнән дә битәр борчып, һәрвакыт уйланырга мәҗбүр итеп тора.

Теге вакытта сәхнәдә биегән нәни аккошлар белән генә нindидер уртаклыгы бар бугай ул гади каз бәбкәсенең. Шул каз бәбкәсе инде мине иң беренче тапкыр тормыш белән күзгә-күз очраштырды. Мин тормышның ашау-эчү, кар көрәү, маймыч сөзү, таң ату һәм кич булу кебек хәлләрдән генә тормавын, дөньяда боларның барысыннан да өстенрәк һәм аңлаешсыз нindидер нәрсә булуын тойдым.

Ул язда безнең ала каз ундүрт бәбкә чыгарды. Ундүртен дә исән-сау көзгә кадәр үстерсәң, мамыгыннан үзеңә мендәр ясарбыз, дигән иде әнкәй. Сүзендә торды әнкәй, тик мин генә үз вазифамны җиренә җиткереп үти алмадым.

Җәй урталарында безнең иң котырынып балык тоткан, көннәр буе чыкмый су коенган чак. Инде бәбкәләр дә үсеп килә, тилгән күтәреп китә алмас, дип, аларны гел оныттык. Тик дөньяда без көтмәгән хәлләр дә була икән. Кинәт казлар инеш буен тутырып каңгылдаша башладылар. Без ыштаннарны кулга тотып йөгереп килеп җиткәндә, иләмсез зур тилгән тал биеклеге күтәрелгән иде инде. Аның тырнакларында элекке сарылыгын югалтып, инде алара башлаган бәбкә тыпырчына. Без кычкыра-

кычкыра, таш ата-ата аның артыннан чаптык. Тилгән биеклеккә күтәрелә алмый, инде берәр атнадан каз дип атала башларлык олы бәбкә авырлыгы аны әкренләп җиргә сөйри. Ул озын канатларын күпме генә тырышып җилпемәсен, барыбер җирдән ераклашмый. Менә-менә төшеп җитәм дигәндә, бар көче белән талпынып, тагын бераз күтәрелде һәм, көче бетүен сизеп, ахры, ачы тавыш белән каркылдап җибәрде, бәбкә, аның тырнакларыннан ычкынып, шапылдап җиргә килеп төште.

Шул көннән башлап инеш буена унөч бәбкә генә йөри башлады. Ундүртенче бәбкәне: «Барыбер яшәмәс, тилмермә аның белән»,— дисәләр дә, карадым, сынган аягына дару сөрттем, каерылган канатларын, җиргә сөйрәлеп йөрмәсен өчен, җыеп бәйләп куйдым.

Көзгә таба бәбкә гел савыгып җитте. Бераз аксаклап булса да, ул туганнары артыннан йөри, алар белән бергә ашый, йоклый, бергә каңгылдаша. Туганнары да аны үз итүдән туктамадылар, арып арткарак калса, көтеп алдылар, тапкан җимне бүлештеләр. Ләкин ул һаман да үз ишләреннән гәүдәгә дә кечкенәрәк, төскә дә боеграк булып калды.

Инде берничә атнадан каз өмәләре башланырга тиеш иде. Әнкәй: «Ул бәбкәне суеп маташмабыз, улым, бик тилмереп үстердең, аннан, әллә ни ите дә булмас»,— дип әйткән иде.

Беркөнне бәләкәч басудан кайтмады. Күпме эзләсәк тә таба алмадык аны. Төнлә күрше Шәйхулла абый уятып кереп әйтте: «Урманга утынга барганда күрдем. Теге аксак бәбкәгез чишмә чокырына төшеп үлгән»,— диде.

Урылган җир өстендә җим чүпләп йөргәндә, урман ягыннан килеп чыгып, бер төлке безнең казларны куа башлаган. Казлар йөгерешеп барганнар да канатларын җилпеп күккә күтәрелеп киткәннәр, ә бәләкәч калган. Ул да аксаклый-аксаклый туганнары артыннан озак йөгергән, сынык канатлары белән җилпенеп, күтәрелергә талпынып караган, тик җир аны үзеннән аермаган. Ул тагын йөгергән, тагын талпынган. Төлке менә-менә куып җитәм дигәндә генә, чишмә чокырының упкын кебек текә ярыннан аска тәгәрәгән.

Икенче көнне көрәк алып барып, бәләкәчне чишмә чокыры янына җирләдек.

Каз булып җиткән унөч бәбкәнең мамыгыннан әнкәй миңа мендәр тутырып бирде. Авылдан киткәнче шул мендәргә башны куеп йокладым.

Аннары бәбкәләр кебек бер-берсенә охшаган мәктәп еллары башланды. Мәктәптә ярыйсы гына укыдым. Институтка керү дә әллә ни кыен булмады. Кергәндә авыр булгандыр да инде, хәзер онытылды. Алмасалар, Себергә китәргә уйлаган идем. Алдылар. Тулай торакта урын да бирделәр.

Бүлмәгә биш малай урнаштык. Беребез — элеп киптергән балык кебек юка йөзле, иләмсез күзлекле мишәр малае, бүлмә җитәкчесе булып та алды, иң түрдә, батарея янындагы караватны та аңа эләкте. Аның белән янәшә урынга биографиясе дә, туган елы да, исеме дә безгә анык билгеле булмаган, тарих бүлегендә укучы 30–35 яшьләрдәге бер мәзәк кенә кеше кунаклады. Ике ел бергә яшәп, ул, күпме тырышса да, безнең исемнәрне хәтерендә калдыра алмады. Соңрак, Достоевскийны укый башлагач, аңа Идиот кушаматы тактык. Ул беркайчан да үпкәли белми, нәрсә әйтсәң дә, елмая гына иде. Калган өч урынны француз комигы Фернандельгә охшаган, ләкин бик оялчан типтәр малае, тагын гадәттән тыш тыныч, тәртипле, безнең арада иң төпле саналган Казан арты егете һәм мин — өчәү бүлештек.

Яши башладык. Башлар күктә иде. Унсигез ел буе сыер койрыгына карап дөнья турында фәлсәфә саткан авыл малайлары кулына Шекспирлар, Бальзаклар, Руссолар эләккәч, күккә тияр дә шул. Иске кумирлар онытылды, көн саен яңалары туа торды. Тик озын авыл кышы буена бер баз бәрәңге эшкәртергә өйрәнгән ашказаннары гына бу тормышка ияләшә алмыйча тилмерделәр. Стипендия ашауга да тартып-сузып җитә иде. Ә кино, театр, кәгазь-каләм, өс-баш турында онытыбрак торасың. Алары — эти казнасыннан.

Кесә буш булгач, горурлык та, үз-үзеңә ышаныч та юк. Шуңа күрә кызларның да безнең кебек йолкышларга әллә ни исләре китмәде. Тар балаклар модада иде ул заманда. Үзебезнең ишләр дип, баштарак авыл хуҗалыгы институтыныкылар янына йөргәләдек, ләкин анда тиз туйдырды. Көндез — лекциядә, кичләрен сирәк-мирәк кинода, ә калган вакытны бүлмәдә үткәрә торган идек. Бер зур вакыйгага чаклы шулай үзебезчә әкрен генә яшәдек.

Ул көнне институт гөр килде. Барысының да йөзе тынычсыз, барысы да кемгәдер нәфрәт белдерә, кемнедер кызгана, кемнедер каргый иде. Студентлар актлар залы-

на агыла башладылар. Бер нәрсә аңламасам да, этеләтөртелә мин дә шунда үттем. Студентлар, укытучылар бер-берсен бүлә-бүләниләрдер сөйлиләр, нидер исбат итәләр, кемгәдер төртеп күрсәтәләр.

— Аның безнең белән яшәргә хакы юк, институттан сөрергә кирәк аны!

— Садизмның иң соңгы чиге бит бу!

— Моңа кадәр аны ничек кеше дип атадык икән?!

Озак тырыша торгач, институтның комсомол секретаре, ниһаять, залда тынычлык урнаштырды.

— Иптәшләр, туктагыз, барысын да аек акыл белән хәл итәргә кирәк.

Аны бүлеп, залдан тагын кычкырдылар:

— Болгар дәүләте чорында мондый нәрсә өчен кешене, тураклап, агач башына элеп куя торган булганнар.

— Монда сөйләшеп торасы да юк!..

Ниһаять, зал, кычкырынуның файдасыз икәнен аңлап, ахрысы, тынды.

Комсомол секретаре тагын сүз башлады:

— Иптәшләр, бәлки, барысын да яңабаштан сөйләп чыгар өчен сүзне Фаяз Сәлимҗановка бирербез?

Ул тиз-тиз атлап алга чыгып басты. Яхшы оратор кебек, бераз вакыт залның тынуын көтеп, өстән аска карап торды да сөйләргә керešте:

— Без кешелекнең матди һәм рухи яктан яңадан туу чорында, егерменче гасырда яшибез.

— Кыска тот сүзеңне! — дип кычкырды кемдер залдан.

— Берничә гасыр элек кешенең башына да килә алмаган ачышлар, атом бомбасы, айга очу чорында яшибез. Әйе, без техник яктан гына түгел, рухи яктан да үсәбез. Без инде хәзер, әби-баба йолалары дип, бары үткәнгә генә карап яши алмыйбыз. Без барлык йолалардан, богаулардан азат булган ирекле җәмгыять төзибез. Фрейдизм, Эдип комплексы кебек теорияләрне...

Зал тагын шаулый башлады. Ул, залга мыскыллы караш ташлап, иреннәрен юкартып елмаеп куйды. Инде, залны бүтән тынычландырып булмасына ышанып, ахрысы, тавышларны басарга тырышып, ярым кыргый тавыш белән кычкырырга тотынды:

— Сез, ярлы шәкертләр һәм тук профессорлар, бүген кешелек дөньясындагы иң зур җинаятькә шаһит булабыз дип, монда җыелдыгыз. Ә кем, үзегез кемнәр соң сез? Әнә, теге почмактагы инде ничә ай стипендия ал-

маган студент янында утыручы профессор кесәсендәге биш йөз сум хезмәт хакын капшый. Белә, күршесендәге студентның сукыр тиене юк икәнен белә бит ул. Нигә аны ашханәгә чакырмый яисә, һич югында, берничә сум бирми? Югыйсә ул бит кичә генә безгә уналтынчы йөз әдәбияты, гуманизм турында ничек дәртләнеп сөйләгән иде. Кайда соң монда дөреслек? Миллионлаган кешеләрне үтерүче Чыңгыз ханнарны, Наполеоннарны бөек дип атаучылар әле генә миңа иң пычрак сүзләр кычкырдылар, нәфрәтләнделәр. Кайда соң монда дөреслек, кайда?

Аңа артык сөйләргә ирек бирмәделәр.

Беренче рәттә утыручы кыз залга да, егеткә дә күтәрелеп карамады, бертуктаусыз үкседе дә үкседе. Аңа хәзер нәрсә сөйләсәләр дә — барыбер, хәтта бу гөнаһны күтәрә алмыйча, барысын бергә җир йотса да, шаккатмас иде ул.

Егетне институттан кудылар. Озакламыйча суд аны ирегеннән мәхрүм итте.

Ул төнне мин йокламадым. Каз бәбкәсе белән булган фаҗигадән соң, мин менә тагын икенче тапкыр тормыш бөтерчегенә эләктем. Егет сүзләре йөрәкне тетрәткән, бөтен мускуллар тартылганнар. Күз алдында — калтыранып, яшьсез елап утыручы кара кыз. Ул бит егеткә ышанган булгандыр. Югыйсә туган көненә чакырмас, аның белән икәүдән-икәү генә калмас иде. Хәзер барысы үткән инде. Кыз алданган, мәсхәрәләнгән, егет төрмәдә. Ул вакытын тутырып кайтып та җитәр, хәтта өйләнер, балалары булыр, эшләр, көләр, елар. Җәза алганнан соң, җинаятьне күңел аклый. Кыз җинаять тә эшләмәде, җәза да алмады. Аны таптап, изеп үттеләр. Ул нишләр?

Икенче көнне ул институтка килмәде. Кызлардан сорап, кайда торганын белдем. Исеме Әминә икән. Матур, йомшак исем. Минем ничек тә аны күрәсем, тау кебек кайгысының кечкенә генә булса да бер өлешен үземә аласым килә, ләкин моны ничек эшләргә кирәк икәнен белмәүдән гаҗиз идем.

Тулай торакка кайткач, ни тырышсам да, бүлмәсенә керергә кыюлыгым җитмәде. «Юатырга килдеңме, кешелекле булып кыланасыңмы, беләбез без сезнең кебекләрне!» — дип әйтер, көләр, куып чыгарыр кебек тоелды. Ишекләре төбеннән кире борылдым.

Икенче көнне көтмәгәндә урамда үзе очрады. Ләкин сүз ката алмадым. Кыюлык җитмәде. «Тупас, мужик, бозау»,— дип, үз-үземне битәрләдем. Файдасыз.

Ике көн үткәч тә, дүрт-биш көннән дә, бер айдан соң да килмәде әле ул кыюлык миңа. Тулай торакта, ашханәдә, институтта һәрвакыт күзләр аны эзли, аяклар ихтыярсыз ул йөргән юлдан йөри башлады. Ничә тапкыр, сагалап торып, каршысына чыктым, ничә тапкыр аның артыннан кинога, театрга бардым... Ә ул миңа аз гына да игътибар итми, минем дөньяда яшәвемне, өзгәләнүемне тоймый, башын аска игән килеш йөри дә йөри. Тора-бара үз-үземә бикләндем, уйчанландым. Серемне француз комигы Фернандельгә охшаган Фәриткә генә чишә идем. Ул тыңлый, өметләндерә, юата, минем белән килешә, ләкин тегеләй ит, болай ит, дип, төгәл бер киңәш бирми иде. Гомумән, бик гаҗәп егет иде ул. Бер карауга, мокыт кына, оялчан, мескен генә, ә икенче караганда, инде бөтенләй үзгәрә, һич көтмәгән җирдә кинәт кенә әллә нинди яңа, ишетмәгән үткер мәзәк әйтеп куя — эчеңне тот та сәгать буе көл. Ул инде күптәннән Иделнең аръягына аулак бер җиргә чыгып кармак салырга, йолдыз санап, учак ягып ятарга хыяллана иде. Май бәйрәмендә өч көн ял бирүләрен белгәч, Фәриткә хыялын искә төшердем. Дүрт куллап риза. Ул риза булыр, тик менә ничек итеп Әминәгә әйтергә, ничек итеп аны үзебез белән ияртергә? Юк, балык тотарга да, учак ягарга да ул хәтле ашкынып тормыйм мин. Ничек тә Әминә белән сөйләшәсе, аңлашасы иде. Идел ярларын, кара каргаларны, сыерчыкларны күрсәтәсем, әле яңа уянып килүче җир өстеннән аның белән янәшә йөгереп йөрисем килә иде. Бу манзараны күргәч, бәлки, аның күңелендәге шиңгән гөлләр терелерләр, аның йөзенә дә, ниһаять, елмаю чыгар иде.

Барып танышырга, дәшәргә кыюлык җитмәгәч, берничә тапкыр хат та язып карадым. Җибәрмәдем, мужиклык, бюрократлык бит бу, дип ертып аттым. Кич урамда тагын аның үзен очраттым. Туп-туры карап каршыга килә. Авызны ачтым, ләкин сүз чыкмады. Үтеп китте. Йортлар артыннан кача-поса йөгереп, ураудан тагын алдына чыктым. Тагын туп-туры карап килә. Көлемсери! «Беткән-бетсен, кешеләр үлемгә дә кергәннәр бит әле!» — дидем дә, бөтен кыюлыгымны җыеп, авызымны ачтым:

— Әминә!..

Ул, бер мәлгә аптырап, туктап калды.

— Мин сезне белмим.

— Мин — Ирек, сезнең белән бер институттан, филология факультетыннан, сездән бер этаж гына астарак яшим, егерме җиденче бүлмәдә. Без...

Мин кабаланып, сүзләрне йота-йота сөйләдем дә сөйләдем. Аның белән янәшә басып тору, аның күзләрен, чәч толымнарын, иреннәрен якыннан күрү миңа шулкадәр рәхәт иде! Миңа, хәзер нәрсә сөйләсәм дә, барыбер, бары ул гына минем белән янәшә торсын, сагышлы күзләрен читкә бормасын. Сүзләрнең мәгънәсе югалды, алар үзләреннән-үзләре агыла тордылар. Беразга ул да югалып калды, ахрысы, бер сүз дәшми, моңсу күзләрен тутырып, тавыш-тынсыз миңа карап торды. Әкренләп йөзенә җиңелчә алсулык йөгерде һәм, кинәт уянып киткән кебек дерт итеп куйгач:

— Нинди йомышыгыз төште миңа? — диде.

— Без Фәрит белән бәйрәмдә Идел буена төшмәкче булабыз. Учак ягарга, балык тотарга...

Минем сүзләр шулкадәр урынсыз, мәгънәсез килеп чыкты, «йолдызлар санарга» дип әйтергә авыз ачкач, туктап калдым.

— Барыгыз соң, бәхетле юл сезгә. Минем ни катнашым бар монда? — диде ул, аптыраган тавыш белән.

— Без, ни, сезне дә чакырмакчы булган идек, анда көймә... чатыр корырбыз... йолдызлар...

Әминәнең битенә кинәт кызыллык бәреп чыкты, иреннәре тетрәнеп куйды, йөзе әкренләп караңгыланды, иреннәре дә катып, агарып калдылар.

— Сез нәрсә, сез көпә-көндез урам уртасында миннән көләргә уйладыгызмы? Сез оятсыз! Мине кем дип белдегез?!

Ул, куллары белән битен каплап, атылып тулай торакка кереп китте. Мин дә аның артыннан йөгердем. Ләкин бүлмә ишеген күпме шакысам да ачылмады. Эчтә аның үксүе, үксегән саен күңелне чәнчеп, карават шыгырдавы гына ишетелде.

Кич буе Фәрит белән үзебезне итагать белмәвебез, беркатлылыгыбыз өчен битәрләп утырдык. Бүлмәдә икәү генә калдык, бүтәннәр бәйрәмгә кайтып киттеләр. Мин, урынга сузылып ятып, башымны кочакладым, Фәрит Ремарк романына иелде.

Төнге унике. Ул һаман да елый микән әле? Нәрсә белән үпкәләттем, нинди ярасына кагылдым икән аның? Аның ярасы берәү генә инде... Ярый, тупас та булганмын ди, дәшә белеп тә дәшмәгәнмендер. Тик нигә сәгать буе шакып та ишеген ачмады, һич булмаса, ачуланып, куып җибәрмәде? Ишеген генә ачсын иде, ничек тә сүз табар, тезләнер, ялварыр, барыбер ышандырыр, безнең белән барырга күндерер идем!

Уйларымны ишек шаку тавышы бүлде. Шул Мирзадыр, акчасын эчеп бетергәндер дә хәзер чирек ипи алырга дүрт тиен теләнеп йөри торгандыр, дип ачмаска булдык. Тапкан йөрер вакыт. Азрак торгач, тагын шакылдаттылар, тагын, тагын, тагын... Усаллык белән сикереп торып, ишекне каерып ачып җибәрдем. Беттем! Ачу да, нәфрәт тә, горурлык та — барысы да бетте. Мин егет түгел, чыпчык, бәбкә, чебен...

— Ирек, мин артык тупас булдым бугай. Мин... әллә ничек кенә килеп чыкты шунда... Кичерегез мине... мин...

Аның елап шешенгән күзләре тагын дымландылар. Күз яше күргәчме, әллә болай аңыма килеп өлгердемме, мин өзелә-өзелә гафу үтенергә, аның гаепсез икәнен исбатларга тырыша-тырыша, ниләрдер сөйләргә тотындым, аны җитәкләп, хәтта көчләп диярлек, түрдәге урындыкка алып килеп утырттым. Нәрсәдер әйтәсе, аңлатасы, ачыласы, бернинди яман уй да юк икәнен күрсәтү өчен, күкрәктән йөрәкне суырып алып бирәсе килә... Ләкин авыздан «соң», «бит» кебек кирәксез сүзләрдән башка берни дә чыкмый. Фәрит Ремаркны онытты. Ул да каушый, иңбашларын сикертеп куя, маңгаенда — тир бөртекләре. Миңа ни әйтсәм дә, мәгънәсез булыр кебек, шуңа тынып калдым. Әминә, китәргә җыенып, торып басты. Фәрит, соңгы мизгелне ычкындырмаска тырышып, ахрысы, тәвәккәлләргә булды.

— Әминә, таныш булыйк, мин Фәрит булам, Ирекнең курсташы. Кичә Иделдә боз китте,— дип, тотлыга-тотлыга, җөмләсен ерып чыкты.

Әминә ишеккә таба атларга торган җиреннән туктап калды.

— Әйе, радиодан сөйләгәннәр иде, ләкин үзем күрә алмадым шул. Яз бик матур, диләр, быел, тик минем чыгып караганым юк әле.

Әминәнең ачылуын, сөйләшә башлавын күреп, икебез дә кыюланып киттек.

— Кара әле, быел яз барыбер килде бит, югыйсә, кисәтеп, гәзитләрдә дә язмаганнар иде.

Фәрит үзе дә көтмәгәндә әйтеп ташлаган мәзәк җөмләсеннән кызарып куйды. Әминәнең иреннәренә җылы йөгерде, җылы әкренләп елмаюга әйләнде.

Берничә минуттан без көлешә-көлешә сөйләшеп утыра идек инде.

* * *

Иделгә өчәү бардык.

Көн җылы, кояшлы иде. Электричкада кеше күп булды, төшкәч, аякларны язар өчен урманга кадәр йөгердек. Өчебез дә чалбардан, курткадан, өчебез дә шат. Тик Әминәнең тавышы яңгыраурак иде.

Иң беренче эш итеп, чыбык-чабык җыеп, учак яктык. Коры каен шәп яна, юеш җирдән бу күтәрелә, тамак төбен бөре исе кытыклый. Рәхәт! Күк зәңгәрлегенә күзләрне талдырганчы карап яткач, чатыр кора башладык.

Фәрит белән икәү генә булсак, урманны яңгыратып сызгырыр, агач башларына үрмәләр идек. Әминә булгач, никтер тартындыра. Малай чакта мондый тартыну булмый торган иде. Соң, Илаһым, без дә егет булдык микәнни?

Фәрит, кармаклар тотып, су буена төшеп китте. Без учакка коры-сары җыя башладык. Әминә тагын моңсуланды. Бертуктаусыз ниндидер миңа таныш булмаган көйне көйли.

— Ирек, бер мәзәк сөйлимме? — диде ул, кинәт туктalып.

— Сөйлә, билгеле, сөйлә!

— Юк, ул мәзәк тә түгел, ул бик кыска гына, әллә нәрсә генә инде ул.

Аның йөзе тагын уйчанланды, күзләрендәге очкын сүнеп юкка чыкты, иреннәре кысылдылар.

— Әйдә, Әминә, сөйлә, сөйлә,— дидем мин, аны ашыктырып.

— Бәлки, синең аны ишеткәнең дә бардыр. Иске мәзәк инде ул. Бер алдакчы агай турында. Күршесеннән көләргә теләп, төн уртасы җитте исә, ишегалдына чыга да: «Бүре бар, күрше, тор, бүре!» — дип кычкыра икән. Күршесе бер чыккан, ике чыккан, ләкин бүре күрмичә,

сукрана-сукрана кереп ята торган булган. Һәм бер көнне, чынлап та, абзарлар артына бер көтү бүре килгән. Бу агай кычкырган, ярдәмгә кешеләр чакырган, ләкин күршесе, тагын алдыйдыр бу, дип чыкмаган. Бүреләр малларны буып киткәннәр...

— Бабайның сөйләгәнен ишеткәнем бар иде.

Әминә тынып калды. Мин аның тел төбен аңлыйм, ләкин каршы төшәргә, бу мәзәкнең безгә бернинди дә катнашы, охшашлыгы булмавын аңлатырга сүз, дәлил таба алмыйм. Әйе, аның ышанмаска, шикләнергә хакы бар. Юк, алай гына түгел, ул, әлбәттә, һичшиксез ышанмаска, беркемгә дә ышанмаска тиеш. Теге егет тә нәкъ минем кебек үк ике аяклы, ике куллы, зачеткалы студент булган бит. Ул да минем кебек дуслык тәкъдим иткән, аның белән бергәләп, бәлки, шушы урманда уйнапкөлеп йөргәндер.

Башка күңелсез уйлар килә әле. Барысын да онытырга, аңа да оныттырырга, үземә дә онытылырга кирәк. Ә ничек?

Урман буш. Ни гөмбә, ни җиләк, ни чәчәк юк. Бупбуш. Барысы да кышның аргы ягында калган. Агачлар шәрә. Алар шулкадәр миһербансыз кыштан соң күтәрелеп китүләренә, яфрак җибәрүләренә ышана алмый торалардыр кебек. Кочакка алып җылытасы, иркәлисе иде аларны.

— Әминә...

Уйларымны аңа җиткерәсем килеп эндәшсәм, Әминә юк. Әле генә менә шушында борын төртеп килүче яшел кыякка карап тора иде бит. Кая китте?! Әллә саташаммы мин? Әллә бу төш кенә идеме? Бернинди Әминә дә, яшел кыяк та, шәрә агачлар да юк идеме? Бар, барысы да бар! Әминә генә юк. Агачлар артында күз күреме җитмәслек булып җәелеп агучы кара, шомлы Идел ягына карыйм. Юк, ул якта да күренми. Күңелгә шик йөгерә, моңа кадәр сихергә, тылсымга ышанмаган йөрәкне нидер тырный.

— Ә-ә-ми-и-нә-ә-ә-әү-ү!

Буш урман минем тавыш белән тула. Бер секундтан ул тавыш җилдә тирбәлә-тирбәлә кире кайта. Кайтавыздан куркам мин, балачактан ук куркам. Кайтаваз миңа моңа кадәр үлгән кешеләрнең җир куеныннан биргән тавышы, тарих тавышы кебек тоела. Кеше күп җирдә — урамда, базарда, кибеттә кайтаваз булмый бит. Ә инде

урманда, таулар арасында, аз гына кычкырыбрак сөйләшсәң дә, таулар шомлы тавыш белән сиңа җавап кайтаралар. «Курыкма, без синең белән»,— дип кисәтеп торалар кебек алар.

Карт имән артыннан, урманны яңгыратып көлә-көлә, Әминә килеп чыга. Мин, үземне дә белештермичә йөгереп килеп, аны күкрәгемә кысам: «Синме бу, югалмадыңмы?» — дип, битләренә, күзләренә йотылып карыйм, ул уңайсызлана, читкә тартыла, каушый, бәләкәйләнеп, йомарланып кала, ә мин сөенәм, сөенәм!

— Нигә шулай каты кычкырдың? — ди ул миңа пышылдап.

— Курыктым, югалгансыңдыр, карурманга кереп югалгансыңдыр, адашкансыңдыр дип курыктым!

Аның чәчләреннән ылыс исе килә.

— Әминә, син тылсымга, сихергә ышанасыңмы? — дип, аның колагына пышылдыйм.

— Бәләкәй чакта ышана идем, хәзер юк. Әкиятләр укыганда гына азрак ышанып куям.

«Нигә сорыйсың инде моны?» — дигән кебек, ул аптырап карап куя.

— Ә миңа ышанасыңмы? Менә хәзер, әйдә, Әминә, җир читенә китик, бергәләп сахралар, ком чүлләре, диңгезләр кичик, дисәм, ышанып, минем белән китәр идеңме?

— Белмим...

— Ышанмыйсың?

— Белмим...

— Менә хәзер шушы бозлы Иделдә су коенсам, ышанырсыңмы?

— Белмим, Ирек, белмим...

— Ышанмыйсың?!

Мин, Әминәне ташлап, барган уңайга күлмәкне, чалбарны сала-сала, су буена йөгерәм. Күзгә бөтерелеп аккан бозлар да, су да күренми. Алда бары Идел, чиксезлеккә кадәр җәелгән, билгесез бер илаһи көч — Идел. Яр буена килеп җитә алмадым.

— Ирек, юләрләнмә. Ирек, акылыңа кил, ышанам, ышанам! — дигән ачы тавышка карурман тетрәп куйды.

Мин туктадым...

Фәрит бер балык та тота алмаган. Болганчык суда кармакка эләкми икән. Шуны да белмәгәнбез. Ятьмә белән сөзүче агайлардан сатып алып, балык шулпасы пешердек.

Аштан соң, курткаларны җиргә җәеп, ял итәргә яттык. Күккә, мәңге яшел нарат ябалдашларына карап, мин Такташның «Урман кызы»н сөйли башладым.

Син ал инде, ал ул күзләреңне,
Алар шундый, шундый караңгы...
Үле тынлык анда, саф мәхәббәт
Исереп йоклый әле...

Мин туктагач, Фәрит мәзәк сөйләп көлдереп алды. Әминә Есенинны бик ярата икән, аның шигырьләрен искә төшерде.

...Грубым дается радость,
Нежным дается печаль.
Мне ничего не надо,
Мне ничего не жаль...

Йолдызларга озак карап ята алмадык. Дымлы җир суык иде. Тизрәк чыршы ылысыннан түшәлгән урыннарыбызга кереп кунакладык. Бераз сөйләшкәч, тынып калдык. Һәркем үз уен уйлый. Һәркем үз фәлсәфәсе белән дөньяны, тагын бер кат барлап, үз үлчәме белән үлчәп чыга. Шулай хыялланып, әле яңа гына булган хәлләрне үткән тормыш белән үреп, дөнья мантыйгына буйсындырырга тырышып ята торгач, йокыга киткәнбез.

Кич Әминә: «Син егерменче гасыр Дон Кихоты»,— дигән иде. Төштә Дон Кихотны күрдем. Башта озаклап испан җирләрендә йөрдек. Испанияне аркылыга-буйга үткәч, бергәләп безнең якка, Идел буйларына килдек. Идел белән Чулман кушылган урында туктап, тирә-юньгә озак карап торгач, Дон Кихот, озын сөңгесенә таянып: «Монда миңа эш күп икән әле»,— диде. Ат эчертергә су таба алмыйча, бик озак йөрдек. Иделнең нефтьле суын Дон Кихотның аты иснәп тә карамады. Атларга атланып алга киттек. Ләкин күпме эзләсәк тә, җил тегермәнен дә, сарык көтүен дә таба алмадык. Беренче очраган дуңгыз көтүенә ташланып, аны кырып аттык. Дон Кихот, көнетөне селкенеп, нефть суырып утыручы көянтәгә охшаган нәрсәгә асылынып, берничә мәртәбә егылып та төште. Арып хәлдән тайгач, Идел буена төшеп, бозлы суда коендык.

Иртән туңып-калтырап уяндым. Әминә, инде торып, учак ягып җибәргән иде. Азрак җылынып алгач, әйберләрне җыештырдык, учакны сүндердек тә тимер юлга таба кузгалдык. Ике мәһабәт нарат уртасында, караеп, безнең чатыр торып калды.

Электричкада кеше аз иде. Суыктан бөрешеп, дерелди-дерелди, сөйләшмичә генә кайттык. Кичәге хәлләрдән, үз-үземне тотышымнан никтер ояла идем. Аның белән танышканга нибары өч көн үтте. Ә кичә мин аңа ниләр генә сөйләмәдем, ниләр генә вәгъдә итмәдем. Әйтерсең без шулкадәр якын, әйтерсең туганнан бирле гел бергә үскәнбез, Фәрит бер-ике тапкыр үзенең мәзәге белән ялтырарга тырышып карады да, безгә җан кертүдән өмет өзеп, ахры, тынып калды. Әминә тәрәзәгә башын куйган да каршына йөгерүче агачларга карап уйга чумган.

Әминәне ишек төбенә кадәр озата бардым. Кич кинога чакырдым. Моңсу иде ул. Баш кагып кына риза икәнен белдерде, баш кагып кына саубуллашты.

Кинога килде тагын. Берничә сүз белән хәл-әхвәл сораштык.

— Юк, юк, ашамыйм,— диде ул, минем мороженое күтәреп килүемне күргәч.— Гомеремдә төче һәм баллы әйбер яратмадым.

Сәгать ярымлык киноны әйләндереп бетергәннәрен сизмичә калдым. Нәрсә турында булганын да анык хәтерләмим. Детектив иде бугай.

Урамга чыктык. Күктә бөтерелә-бөтерелә болытлар уйный. Ай күренми, ай юк. Тар гына агач күпернең уртасына җитеп туктадык. Аста, чокыр төбендә — тимер юл. Ялтырап яткан ике ак рельс. Бигрәк күп инде дөньяда парлы әйберләр. Хайваннар, кошлар, кешеләр, тагын әллә нинди без исемен белмәгән җан ияләре — барысы да парлы булырга омтылалар. Нигә алай икән ул? Нәсел калдырыр өчен генәме? Күптән түгел генә гәзиттән укыдым. Франциядә бер рельслы тимер юллар сала башлаганнар, ди. Алай поездлар тизрәк йөриләр, имеш. Мөмкин, бик мөмкин. Тик тиз йөрүдә генәмени эш?!

— Ирек, мин инде әллә ничә тапкыр берүзем генә төннәр буе шушы күпер өстендә тордым,— дип, салмак, йомшак, моңсу тавыш белән Әминә сөйли башлады.— Поезд астына ташланмакчы булган идем. Курыктым, туры сикерә алмам да үлми калырмын дип курыктым. Гариплек күңелемә шом сала минем. Бер эшкә ярамыйча, кешеләрнең күз карашын укып яту коточкычтыр. Кайберәүләр кебек шигырь язарга да талантым юк бит. Менә шуңа күрә курыктым да исән калдым. Мин беркемгә дә

тимим, комачауламыйм бит. Әйдә, яшәгән булыйм әле. Тик миңа кагылмасыннар.

Аның сүзләре миңа төбәп әйтелгән кебек. Мин үземне аның өчен кирәксез, артык кеше итеп тоям. Күңелдә буылып торган үпкә сүзләрен иреккә чыгарасы, сөйлисе, ярсый-ярсый, елый-елый аңа барысын да сөйлисе килә.

Уйлар өзелде. Ачы чыелдап, яктырып, өстерәлеп туннельдән поезд килеп чыкты. Мин, бөтен дөньяны онытып, вагоннар саный башладым. Бер, ике, өч, дүрт, биш... ун... уналты... Вагоннарның һичшиксез унбиш йә уналты буласын беләм, ләкин барыбер саныйм. Шулай очраган бар нәрсәне саный торган гадәтем бар инде. Бик читен ул. Санамаска, онытырга тырышып, күзләрне дә йомасың, колакка бармак тыгасың — барыбер файдасыз. Баш чыңлый, күз чәнчи башлаганчы саныйсың. Менә бу юлы да уналты вагон үтте. Гап-гади сан бит. Ә һаман да санамыйча түзеп булмый. Әминә дә авыз эченнән «уналты» ди, ул да саный, ахрысы. Әгәр дә, чыннан да, ул шушы поезд астына ташланган булса, мин нишләгән булыр идем икән? Артыннан сикерергә кыюлыгым җитәр идеме, әллә поезд киткәнен көтеп торып, соңыннан аның гәүдәсенә ятып елаган булыр идемме? Үлем — мәгънәсезлек, көчсезлек, куркаклык дип уйлыйм мин. Шуңа күрә, бәлки, икенчесен сайлаган булыр идем. Кем белә, бәлки, боргалана-боргалана, ажгырып килүче поезд астына очучы Әминәне күргәч, тыелып кала алмаган булыр идем. Бигрәк аек акыллы инде мин. Нинди ике төрле фикер булырга тиеш ди монда? Һичшиксез, сикергән булыр идем!

Соңгы көннәрдә нишләп аны бик еш уйлый башладым әле? Көне-төне күз алдында гөр килеп торучы зал, тавышсыз, күз яшьсез калтыранып елап утыручы кара кыз. Аңа ярдәм итәсе, аны коткарасы, кайгысын оныттырасы килә. Яратаммы мин аны, әллә кызганам гынамы? Моңсу тавыш белән Есенинны укыган, имән артына кереп качкан, урман аланы буйлап куышып-йөгерешеп йөргән Әминәне яратам бугай. Актлар залында елап утырган Әминәне кызганам. Алар икесе ике Әминә түгел бит. Әйе, берьюлы яратам да, кызганам да бугай мин аны. Кешене башта кызганып, аннан соң яратып була микәнни? Кызганган өчен генә яратырга тырышу булып чыкмыймы соң бу?

Поезд борылмага кереп югалды. Тәгәрмәчләр текелдәве ераклашкан саен, йөрәк тә әкренләп тынычлана бар-

ды. Әйтерсең поезд чокыр буйлап түгел, йөрәк аша үтеп киткән. Мин сүзгә бик бай түгел, Әминә дә тынлык саклый. Тизрәк моннан китәсе, рельслардан, поездлардан читкәрәк качасы килә. Югыйсә тагын килерләр, тагын йөрәкне таптап китәрләр.

— Әйдә, паркка барабыз, Әминә.

— Әйдә...

Киттек.

Парк, төрле төсләрдәге утларга чумып, бала-чага чырчуына күмелеп, гөрләп тора. Вакыт соң булса да, малай-кызларны, әти-әниләрне төягән карусельләр әйләнә, самолетлар оча, таганнар атына. Халык бар дөньясын онытып күңел ача. Мин дә Әминәне карусельләргә таба барырга өндәдем.

— Әйдә, Әминә, бер генә очып менеп төшик инде. Бөтен дөньясына өстән карыйк әле.

— Юк, юк, башым әйләнә минем. Биеккә менәргә ярамый миңа. Монда, түбәндә, җирдә дә әйбәт.

Артык кыстамадым. Ихтыярына буйсынып, аның артыннан атладым.

Әминә, мине кулымнан җитәкләп, парк түрендәге каберлеккә алып керде. Башта бер сүз сөйләшмичә генә туганнар каберлегендәге ташларны укып йөрдек. Такташ кабере янына килеп туктадык. Мин эчтән генә «Такташ үлде» шигырен укып чыктым.

Казансу елгасы ярына төштек. Әле һаман чирәм чыкмаган. Җир юеш. Такта кисәге табып, бер-беребезгә сыенып утырдык.

— Әминә, нәрсә булса да сөйлә әле. Югыйсә минем елыйсы килә...

Ул кинәт миңа таба борылды.

— Борын-борын заманда, кәҗә команда...

— Юк, уенга алма син.

— Нәрсә сөйлим соң?

— Үзең турында. Мин сине бөтенләй белмим бит әле.

— Бәлки, шулай яхшырактыр да.

— Юк, юк...

— Тыңла алай булгач, сөйлим. Ләкин тормышым кызык түгел минем.

— Сөйлә, Әминә, сөйлә!

— Исемем Әминә. Фамилиям Урусова. Кызык фамилия, әйеме?

Мин, «әйе» дә, «юк» та дип әйтергә белмичә, сүзсез утыруымда булдым.

— Бабам Ибрайдан башланган бу фамилия. Безнең нәселне әле хәзер дә «урысныкылар» дип йөриләр. Нишлисең, шулай килеп чыккан, хәзер без генә үзгәртә алмыйбыз инде аны. Моннан дүрт гасыр чамасы элек хәзерге авылыбыз урынына чукындырудан качып килеп утырган кешеләрдән башланып киткән безнең нәсел. Гәрәй бабай сөйли иде моны...

Әминәнең тавышы өзелде, сүзләре калтырап чыга башлады.

— Нәрсә булды, Әминә? Нигә елыйсың?

— Юк, еламыйм, болай гына. Бабай искә төште.

— Кайсы бабай?

— Шул Урыс Ибрае дип йөртелгән бабай. Бетте, бетте, башка еламыйм...

Ул елый, ул, туктый алмыйча, яшьсез елый, инде ничә айлар буе шулай елый. Аның йөзе ачык күренми, ләкин ешрак сулавыннан, битенең кулларны яндырырлык булып кызышуыннан аның елаганы сизелә иде.

— Гәрәй бабай нәрсә сөйли иде?

Ул сүзен башлый алмыйча тилмерде.

— Бабам... Урыс Ибрае... Бабам дөньяда булмаган әле... Безнең авылны көчләп чукындырмакчы булганнар. Халык баш күтәргән.

Ул елаудан туктады, ахрысы, тавышы кинәт кырысланып китте.

— Бөтен авыл җыелып, поп белән берничә түрәне, солдатларны үтереп ташлаганнар. Бер айдан авылга «обжор командасы» килеп төшкән. Шул көннән асу, кисү, талау башланган. Ирләрнең күбесен төрмәгә, каторгага озатканнар, хатыннарны, кызларны мәсхәрәләгәннәр.

Ул тагын сөйләвеннән туктады. Озак кына тамак төбенә килеп төртелгән төерне йотып җибәрә алмыйча торды.

— Шул вакытта дөньяга килгән инде минем бабам. Туганнары аны суга да салмакчы булганнар, тик әнисе бирмәгән, төнлә баласын күкрәгенә кысып, авылдан качып чыгып киткән. Баланың исемен Ибраһим дип кушканнар, ә фамилиясе юк. Әнисеннән: «Кем малае, әтисе кем?» — дип сорыйлар икән. Ул курыккан. Үзен мәсхәрәләгән солдатның Ибан атлы икәнен әйтмәгән, малаена да Ибан исеме бирерләр дип курыккан. Соңрак барыбер

белгәннәр инде. Ниндидер бер озын теллесе җиткергән бугай. Шуннан бабайга Урусов фамилиясе такканнар. Әй, нигә боларны сөйләп торам инде мин? Мондый тарихларны сөйләп, мәктәптә дә туйдырып бетергәннәрдер инде.

— Мәктәптә мондый нәрсәләр сөйләмәделәр безгә. Мәктәп программасыннан хәтердә бернәрсә дә калмаган минем.Укытучы апа кулына күрсәткеч таягын тотып керә иде дә Җир шарын әле тегеләйгә, әле болайга әйләндереп сөйләргә тотына иде. Аның сөйләвеннән бары берничә җөмлә: «Укучылар, тарих ул гел үсештә. Нинди генә тарихи фактны алсагыз да, аны шушы күзлектән карарга тырышыгыз»,— дигән сүзләр генә истә калган. Әйдә, сөйлә, Әминә! Мин сине бүлдердем бугай.

— Үз-үземне аклар өчен сөйлим мин боларны. Син югыйсә нишләп үзенең туган телен вата-җимерә сөйли икән бу, дип аптырыйсыңдыр.

— Нишләп аптырыйм ди? Хәзер күпләр шулай бит инде.

— Мин күпләр турында түгел, үз язмышым турында сөйлим.

Аның тавышы кырысланды. Минем сүзләргә үпкәләде бугай ул.

— Кызык булмаса да сөйлим әле.

Миңа уңайсыз булып китте. Авыздан, үзең дә көтмәгән урында, мәгънәсез, кирәксез сүз ычкынса, һәрвакыт шулай була. Елгага таба күзләрне текәп, тын калдым.

— Әнием мәктәптә рус телен укыта минем. Ни авыл түгел, ни шәһәр булып җитмәгән район үзәгендә яшәүче укытучыларны беләсеңдер инде. Утызынчы елларның күптән артта калганын, егерменче гасыр азагына якынлашып килүләрен һаман аңларга теләмиләр әле алар. Әниемнән зарланмыйм мин. Юк. Ашатты, эчертте, киендерде, җылытты ул мине. Үзенчә заман кешесе итәргә тырышты. Бабам Алпамшалар, Сүбүдай баһадирлар, Алып батырлар турында әкиятләр сөйли башласа, аны ачулана: «Егерменче гасырда яшәп, һаман шул уйдырмаларыңнан, комганыңнан аерыла алмыйсың!» — дип битәрли иде. Әтиемнең миңа Сөембикә исеме кушасы килгән булган. Әни, аварга торган манара исеме куйдыртасым юк, минем кызым озын гомерле, тулы бәхетле булырга тиеш, дип кырт кискән. Мин дә күңелем белән әнине яклый идем. Менә институтта тарих бүлегендә укый баш-

лагач кына нәрсәдер төшенә башладым... Нигә боларны сөйлим инде мин, нигә акланам?

Әминә сөйли. Елга агуыннан туктады. Елга тик тора, ә мин салкын яр белән югарыга таба агам да агам. Минем белән бергә суыктан туңган таллар, соры йортлар, тонык фонарьлар ага. Агабыз. Әминә таңга кадәр сөйләсен, елга шулай тын гына торсын иде. Яр белән агып, кояш каршына чыгар идек. Таң тизрәк атар иде. Юкса суык. Әминәгә бигрәк тә суыктыр. Ул юка күлмәктән генә.

— Ирек, син мине тыңламыйсың бугай.

Елга шаулап агып китте. Яр туктады.

— Мин... мин тыңлыйм. Без актык...

— Синең йокың килә бугай, кайтыйк.

Мин, чытырдап, аның кулларына ябыштым. Хәзер менә шушы елга буеннан китәрбез дә бөтенесе бетәр, бу якынлык юкка чыгар кебек иде.

— Нигә? Юк! Кайтмыйк! Нинди йокы ул? Синнән башка бик кыен миңа...

Кремльнең ак стеналары аермачык булып күренә башлады. Мәһабәт бер кара җәнлек кебек, хәятны каплап торган төн үлде. Аның ярасыннан аккан кан, көнчыгышка җыела барып, берничә минуттан кып-кызыл төскә керде. Бу кызыллык Әминәнең битенә дә төште.

— Көлмә син, Әминә, көлмә... Инде ничәмә-ничә төннәр буе синең һәр хәрәкәтеңне искә төшереп, үткәнеңне, киләчәгеңне уйлап, күңелемнән фал ачып ятам. Бик авыр ләззәт ул. Егетләр көлә. Шуңа күрә алардан читләштем, хәзер Фәрит белән генә ачылып сөйләшәм. Мин аны үземә тиңләп, үземә охшаган, фикерләребез уртак булган өчен якын күрәм. Ә сине... Син бүтән... Кичә бик сәер төш күрдем. Без өйләнешкәнбез, имеш. Музыка, шау-шу, көлешү, котлаулар, тостлар. Безнең икебезгә дә шәраб белән тулы бокаллар бирәләр. Хор белән «ачы» дип кычкыралар. Син дә башта аларга кушылып көлдең, тик кулыңа бокал тоткач, йөзең туй күлмәге кебек агарды, иреннәрең калтырый башладылар һәм, кинәт бөтен залны яңгыратып: «Ирек, эчмә, алар безгә агу бирделәр!» — дип кычкырдың.

Шунда мин уянып киттем. Малайлар торганнар. Идиот кушаматлы егетебез аларны туберкулез диспансерында ятучы авырулар янына концерт куярга барырга димләп утыра. Мин дә барырга булдым. Чөнки шигырьне бөтен

тирәнлеге, нечкәлеге белән аңлаучылар — авыру кешеләр. Алар тормышның бөтен вак-төякләреннән азат, алар могҗиза көтәләр, алар могҗизага ышаналар. Ә шигырь — могҗиза ул.

Әминә тыңлый. (Ул да, мин сөйләгәндә, шулай яр белән өскә таба агамы икән?) Аның иреннәре зәңгәрләнгән. Суык.

— Әминә, ә син могҗизага ышанасыңмы?

— Юк. Хәзер минем өчен дөньяда могҗиза юк. Барысы гадәти, тормыштагы һәр нәрсә үз законы белән хәрәкәт итә. Шуңа күрә нәрсәгәдер каршы килеп маташуны мәгънәсез эш дип саныйм. Тормыш агымына ияргә булдым.

— Менә хәзер, әйдә, Әминә, бүген үк өйләнешәбез, дисәм, сиңа бу да гап-гади, гадәти нәрсә булып тоелыр идеме?! Әллә... Көлмә, мин чынлап!

— Син тагын төш күрәсең бугай, Ирек...

* * *

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Ике ел эчендә Әминә белән без йөрмәгән урам, тыкрык, сукмак калмагандыр.

Ул театр ярата. Мин — чеп-чи авыл малае. Минем «Тәфтиләү», «Гөлҗамал»ларга җайлашкан колак Бетховен, Чайковский, Яруллиннарга ияләшә алмыйча иза чикте. Әминә, аларны аңлап, акылы белән яхшысын-яманын үлчәп тыңлый. Ә минем баш катнашмый. Бары йөрәк, күңел, җан... Музыка тыңлаганда, мин югалам, онытылам, адашам. Минем алда — биек ком тавы. Үрмәлим, үрмәлим, шуып кире төшеп китәм. Тагын үрмәлим. Ком бөртекләре таныш та кебек. Ләкин тавы — моңа кадәр мин күрмәгән тау. Тагын үрмәлим, уртасына җитәм, әнә, инде түбәсе дә күренә, һәм, ком ишелеп, тагын аска очам. Зал аякка басып кул чаба башлаганчы, тирләп-пешеп төшә идем.

Миңа кино ошый. Анда барысы да гади, аңлаешлы. Әминә, киресенчә, кинону бик өнәп бетерми. Бик нык чакыргач, берничә тапкыр барды шулай да. Аның белән соңгы тапкыр кино каравым әле һаман да күз алдында тора.

Стипендия алган көн, шуңамы кәеф тә бик күтәренке иде. Трамвайга утырып тормадык, тулай торакка җәяү

генә кайтып киттек. Кинотеатр яныннан үткәндә, минем күңел түзмәде, ризалык-мазар сорап тормыйча, Әминәне җитәкләп алып кереп киттем. Киноның исемен дә сорап тормадык, тиз генә билет алып, залга кереп тә утырдык.

Кино алданган, мәсхәрәләнгән кыз язмышы турында иде. Әминә кино башлану белән торып чыгып киткән. Мин тамашага бирелеп сизмичә калганмын, янәшәмдә аның юклыгын күрү белән, артыннан чыгып йөгердем. Чокыр аркылы салынган агач күпер янында куып җиттем.

— Әминә...

Ул, теге суд вакытындагы кебек, калтыранып, яшьсез елый. Күтәрелеп тә карамады, җавап та бирмәде.

Шул кичне көтелмәгән хәл булды. Кинодан кайтып, берничә сәгать үтүгә, Әминә безнең бүлмәгә үзе килде. Күзләре кызарынып, шешенеп беткән, чәчләре, тузынып, иреннәрен каплаганнар. Урамга чыктык. Сөйләшмичә йөрдек. Күпер уртасына кереп җиткәч, ул кинәт миңа таба борылды.

— Ирек, мин сиңа кияүгә чыгарга булдым. Менә бүген үк, хәзер үк.

Минем баш әйләнеп китте, чокыр төбендәге ике ак рельс, кушылып, бер булып күренә башлады. Тел кипте, авыз корыды. Иң кирәкле сүзләр чыга алмыйча, кытыршы авызда уралып калды.

— ...

Мин аны кочагыма кысып, беренче тапкыр озак итеп иреннәреннән үптем.

Төне буе ничек туй ясау, кайда ничек яшәү турында сөйләшеп, хыялланып йөрдек.

Икенче көнне загска гариза яздык. Хәер-фатыйха сорап, икебезнең дә эти-әниләргә хат юлладык.

Озак көттек без җавапны. Ниһаять, килде. Хатны Әминәнең әнисе язган иде. Өйләнешкәнчегә кадәр, башта укуны бетерү хәерлерәк булыр иде, ләкин, ярар инде, яшьләр тормышына киртә була алмыйм, дигән. Озын итеп чын совет гаиләсе коруның авырлыгы, коммунизм төзүдә хәзерге яшьләрнең тоткан роле турында язган. Иң мөһиме — риза! Күккә сикердек ул көнне.

Икенче көнне иртән кәефләр болытланды. Безнекеләрдән хат бар иде. Әткәй, коры, боеру тоны белән: «Әле бу турыда уйларга иртәрәк»,— дип кырт кискән. Әминә

мине: «Институт бетерергә күп калмады бит, көтик, ике ел күпмени ул?» — дип юатырга тырыша. Минем башта мең төрле уй кайный. «Әллә өйләнергәме? Алай итсәм, эткәйләрне бөтенләйгә үпкәләтмәмме? Әллә, чыннан да, институтны бетергәнче көтәргәме? Әллә тиз генә кайтып, үзләре белән сөйләшеп килергәме?»

Хатны тотып, шул көнне үк авылга кайтып төштем. Ничек тә аңлатырга, ризалык алырга иде. Мин ялгышмыйм, мин барысын да уйлап, үз акылым белән үлчәп чыктым инде. Ничек тә монда мәхәббәт, ярату гына түгеллекне, мәхәббәттән дә өстенрәк, югарырак нәрсә бар икәнен аңлатырга иде.

Автобустан төшкәч, Шәйхулла абый очрады. Йөзләрендәге буразналар тагын да ныграк тирәнәйгәннәр. Күпме көтсә дә, хатыны бала таба алмады аның. Кырык яшькә чаклы гомерләре бер врачтан икенчесенә йөреп үтте, дип сөйли иде әнкәй. Элеккечә башын аска иеп, аяк очларына карап, нидер уйлап бара. Картайган.

— Саумы, Шәйхулла абый!

Ул кинәт башын күтәрде, хәтта башындагы эшләпәсе аз гына төшеп китмичә калды.

— Ә-әй, Ирек, синмени бу? Әйбәт, әйбәт. Биргәненә шөкер итеп, әкрен генә йөрибед әле, күрше. Үдеңнең хәлләр ничек соң? Кунакка кайтып килешеңме?

— Юк, болай гына. Эш чыкты әле,— дидем мин аңа. Ни өчен кайтканымны сөйләп бирергә кыймадым.

— Ә, ярый, ярый, бик хуш.

— Авылда нинди яңалыклар бар соң, Шәйхулла абый? Безнекеләр ни хәлдә?

— Барысы да исән-саулар иде әле. Әниең бу арада пенсиягә чыгып йөрде әле. Колхозд эшләгән кешегә пенсия бирә бит хәдер. Тормышлар әйбәтләнә башлады, күрше, авыл халкы баеды соңгы елларда. Еллар гына имин була күрсен инде берүк. Яңалык дип, монда әллә ни яңалык юк инде ул. Барысы да элеккечә. Теге түбән оч Зиннур гына көтмәгәндә үлеп китте. Каты гына эчеп алган да басуга чыгып йоклаган. Кыш суык килде бит быел. Иртән тапканда, тәне суынган булган инде. Адәм баласының язмышы, диген. Мулла малае иде бит югыйсә. Бу елларда халык эчүгә сабышты бит. Умырып акча ала да бар алганын эчеп бетерә. Әй, бед яшь чакта...

Сүзен шул турыда өзеп, ул тын калды. Нәрсә әйтергә теләгәндер, алар яшь чакта әйбәт булганмы, начармы —

белә алмадым. Безнең өй турына кадәр сөйләшмичә генә кайттык. Урыс капканы шыгырдатып ачып, ишегалдына кердем. Ишегалды гадәттәгечә чиста итеп себерелгән. Түрдә, мунча янында, киселгән-ярылган утын өелеп куелган. Лапас-кура да нәкъ элеккечә. Тик түбәләрдәге такта урынына шифер менеп утырган.

Өйдә әнкәй генә иде. Онлы кулларын күрешергә сузып, каршыга йөгереп чыкты.

— Әй, улым, балакаем, кайтып төштеңмени? Әй, хәерлегә булсын инде. Әле кичәгенәк кенә сине телгә алып утырган идек. Гомерле бала булырсың,— дип сөйләнде-сөйләнде дә, күзләрендәге яшьне сөртә-сөртә, кабаланып яңадан өйгә кереп китте.

Чирек сәгатьтән, кара-каршы утырып, икәүдән-икәү генә чәй эчә идек инде.

— Атаң колхоз эшенә киткән ие әле. Әрәмәләрне кырып, болыннарны сөреп, иген басуы ясыйлар бит. Шуңа дәшкәннәр ие.

Минем хат турында ләм-мим. Үзем сүз кузгатканны көтә, ахрысы.

— Безнең хатны алдыгызмы, әнкәй? — дип сүз башладым мин, «безнең» сүзенә аеруча басым ясап.

— Алуын алдык та, улым. Атаң бит. Алар үдләре генә барыбер яши алмыйлар, булышырга беднең хәл җитми, ди. Әйтеп тә караганием инде үденә... Бу турыда ишетәсем дә килми, ди. Юкса үдем дә пенсия алам хәдер. Адрак җибәргәләп, ярдәм итеп торган булыр иек әле. Илдә чыпчык үлә димени...

Өйалдында тавыш ишетелде. Таякка таянып, ишектән бабай килеп керде. Мин, чынаякны куеп, аңа каршы атладым.

— Исәнме, бабай!

— Ә-ә-ә, кем, улым. Ирек улым, синме бу?

— Әйе, бабай, мин бу, мин.

— Әссәламегаләйкем, кайттыңмы, улым? Бик шөкер, бик шөкер.

Чәйне өчәүләп эчә башладык. Бабай, миңа сөйләргә дә ирек бирмичә, сорау артыннан сорау яудырырга тотынды:

— Ә-әй, пишкадәм булдың инде. Мәдрәсәгеддә ни хәлләр бар соң? Хәлфәләр бик теңкәгә тимиме? Мин мәдрәсәдә укыганда, мантыйк буенча дәрес бирүче хәлфә теңкәмә тиеп җәфалаган ие. «Менә, шәкерт, шушы сорауга

җавап бир әле, ди бу көннәрдән бер көнне миңа. Малае этисе янына килә дә болай ди: «Эти, әбине өйдән куып чыгарыйммы?» «Ни дигән сүз бу, телең коргыры!» — дип, этисе моның якасыннан эләктереп ала. «Син минем әнине аерып җибәрдең бит. Өйдән куып чыгардың. Мин синең әниеңне дә шулай итәм»,— ди малай. «Йә, әйтегез әле, малай хаклымы монда?» — дип сорый иде хәлфә. Ә бед тотына идек бәхәсләшергә, тотына идек берберебедне уддырып кычкырышырга. Кыдып киткәч, сугышып та китә идек. Мантыйк өчен шулай шактый борын канаттык бед, улым, әй, бар иде яшь чаклар,— дип елмайды.

Күпме көтсәм дә, минем хат турында башлап сүз кузгатмады. Икесе дә эткәйне көтәләр иде бугай алар. Әнкәй, бәлеш пешерергә җыенып, мичкә ягып җибәрде.

Эткәй соң гына кайтты. Мине күргәч, кәефе беразга гына күтәрелеп алды да тагын сүрелде. Батырлыкны җыеп, әкрен генә сүз башладым. Аның йөзе мин сөйләгән саен караңгылана барды.

— Юк, улым, сөйләп тә торма. Мин сиңа хатта ачык язган идем инде,— дип кырт кисте.

Әнкәй яклап та, каршы килеп тә сүз әйтмәде. Эткәйнең холкын бик яхшы белә иде ул. Мин тагын ялынырга, ялварырга тотындым. Йомшамады барыбер.

— Ник дөньясы җимерелми шунда, ләкин институт бетереп, диплом алмыйча, гаилә корып, хәерче арттырып ятарга хәер-фатыйха бирәсем юк! — дип авызны томалады.— Мәхәббәт тамак туйдырмый.

Әнкәйнең пешергән бәлешен дә ашап тормыйча, ишекне шапылдатып ябып чыгып киттем. Әнкәй арттан елап калды. Эткәй дәшмәде. Бабай, мамык түшәк өстендә мәңгелек дисбесен тартып, иелә-иелә нидер укуын дәвам итте. Мин чыгып барганда, күтәрелеп тә карамады. Аның соңгы сүзләре генә колакка кереп калды. Автобуска кадәр дә, автобуста да мәгънәсе миңа билгеле булмаган шул сүзләрне ирексездән кабатлап бардым: «Ля хәйре фиһүннә вә ля буддә минһүннә!»*, «Ля хәйре фиһүннә вә ля буддә минһүннә!»...

---

* «Алардан һичбер яхшылык та юк, тик алардан башка яшәү мөмкин түгел» *(гарәпчәдән)*. (Хатыннар турында әйтелә торган гыйбарә.)

* * *

Авылдан килеп, бер ай үткәч, туй ясадык. Студент туйлары барысы да диярлек бертөсле була. Чөнки, барыбызның да диярлек, бөтен байлык — стипендия, дуслар — уртак, уен-көлке — бергә, сыйнфый көрәш юк дигәндәй. Хәер, безнең туй башкалардан бераз үзгәрәк булды бугай. Әминәне, моңа кадәр булган кәләшләргә караганда, ныграк иркәләделәр, ныграк назладылар. Мине дә никтер артык күп, артык төче котладылар. Кафедра мөдире, килеп, гомер булмаганча мөлаем итеп сөйләште, «Тормышыңда бик дөрес, бик яхшы адымың бу»,— дип тәбрикләде. Берничә көн алдан декан, үз бүлмәсенә чакырып, тантаналы төстә кулны кысты, минем Әминәгә өйләнүне никтер «батырлыкка» тиңләде. Коридорда танышы да, таныш булмаганы да туктап исәнләшә башлады. Мин институтның игътибар үзәгенә әйләндем. Бу уңайсызландыра, минем дә бүтәннәр кебек гадәти кешечә, студентча йөрисем килә. Ә алар, мин тартынган саен, ныграк мактыйлар, «тыйнак», «әдәпле» дип атыйлар.

Шулай да туй күңелле үтте безнең. Институт ашханәсе дуслар, танышлар белән шыгрым тулы иде. Җырга, биюгә, уен-көлкегә кытлык булмады. Әминә белән бокаллар чәкештергәндә, инде күптән күргән төшем искә төшеп, елмаеп куйдым. Ул да хәтерләде, ахрысы, иреннәреннән елмаю йөгереп үтте. Туй азагына кадәр, зал шаушуыннан аерылып, Әминәнең яңгыравыклы көлү тавышы ишетелеп торды. Аның кәефе күтәренке, тик, артык күп көлүдәнме, әллә башка сәбәп беләнме, күзләре генә юеш иде.

Әткәйләр, күпме чакырып та, туйга килмәделәр.

* * *

Яши башладык. Эзли торгач, Казансу елгасы буендагы урамда бер бүлмә кисәге таптым. Хуҗабыз — сиксәннең аргы ягына чыккан, фани дөньядан өмет өзгән карчык. Аның инде балалары үсеп, кайсы кай якка таралып беткәннәр. Хатлары да оныткanda бер генә килгәли. Ул аларны ачулана да белми: «Шулай инде, шулай, борынгылар белми әйтмәгәннәр... Ана күңеле — балада, бала

күңеле — далада. Ә-әй...» — дип офтанып куя да озак кына сүзсез уйланып тора.

Безнең бүлмә бик зурдан түгел, түрдә чүп тулы ишегалдына карый торган бер тәрәзәсе бар. Өстәл-урындыкны дуслар җыелышып бүләк иттеләр. Түр почмакка әбинең кайсы гасыр истәлеге икәнлеге анык билгеле булмаган караватын кертеп куйдык. Кәеф күтәренке. Әминә бик йорт җанлы булып чыкты. Бүлмәдә һәрвакыт чисталык, тәртип, ашау ягына да артык аптырамадык. Ул, ничектер җаен табып, стипендияне тарта-суза ай азагына кадәр җиткерә иде. Көндезләрен вакыт институтта үтә, кичләрен, тарихи караватның ике башына икебез утырып, имтиханнарга хәзерләнәбез, сирәк-мирәк театрларга йөргәлибез. Барысы да без көткәнчә, барысы да әйбәт бара иде.

Фәрит көнаралаш диярлек килеп йөри. Әминә, яраткан сәйлүн чәен мактый-мактый, тулай торак яңалыкларын сөйли. Соңгы арада сүз күбрәк туберкулез диспансерындагы кичә турында була иде.

Җырлап, шигырь укып, сөйләп арыгач, кайтып китәргә торганда, бер кыз туктаткан иде анда безне. Ул инде туганнан бирле больницада ятуын, әле гомерендә беренче тапкыр сәламәт кеше авызыннан җыр, шигырь ишетүен әйтте. Ашыгып сөйләүдән аның сары йөзенә сизелер-сизелмәс кенә кызыллык йөгерде, моңсу күзләрендә хәлсез очкыннар күренеп китте.

— Җил исүен тоясым килә,— диде ул безнең белән саубуллашканда.— Бик тә тоясым килә.

Шул көннән Фәрит белән ул кыз янына йөри башладык. Китаплар алып барабыз, институт, студентлар тормышы турында сөйлибез. Ул безнең сүзләрнең мәгънәсен генә түгел, хәтта моңын, яңгырашын, борылышларын да йотылып тыңлый, озатканда, һәрвакыт: «Җил искәнен тойган кебек булдым, рәхмәт сезгә»,— дип әйтә иде. Баштарак Әминә безнең бу эшне хуплады. Ләкин тора-бара без больницага барган көнне кәефсез йөри, тиз ачуы чыга, юктан гына әйткәләшеп китә башлады. Беркөнне ризасызлыгын ачыктан-ачык сиздерергә уйлады бугай, ишектән керүгә үк, безне мыскыллы елмаю белән каршы алды.

— Кызыгыз янына барып, җилләнеп кайттыгызмы?

Аның сүзләре әллә минем башка барып җитмәде, әллә артык көтелмәгән булды, җавап бирергә өлгермәдем.

— Кызганырга тагын бер объект таптыңмы?

— Әминә, нишләдең син?! Нинди тупаслык бу?

— Тупаслык, имеш! Ни өчен йөрисең син ул кыз янына? Фәриткә иярмә, ул өйләнмәгән егет. Нәрсә калган сиңа анда?

— Әминә, тукта әле, син авырмыйсыңдыр бит?!

— Авыруым да бик мөмкин! Туберкулез йогышлы бит.

— Ни сөйлисең, акылыңдамы син?

— Бик акылымда! Менә шул акылымда булганга күрә дә моннан соң мин сине әллә нинди кызлар янына җибәрмәячәкмен! Нигә егетләр йә карт-карчыклар янына йөрмисез? Авырулар күп бит анда. Картларның да җил исүен тоясылары килә торгандыр.

— Әминә, тукта! Югыйсә...

— Куркытма, Ирек, куркытма!

— Әминә, син... син оятсыз!.. Син...

— Нә-ә-әрсә? Син әйтәсеңме бу сүзне? Кешелекле, нечкә күңелле, имеш. Беләбез без синең ишеләрне! Юньле булсаң, үлем йортына җил ташып йөрмәс, берәр җиргә эшкә урнашып, акча табар идең!

Түземем бетте. Кинәт кенә чыкылдап торган чит, ят, салкын сүзләрне ишеткәч, соңгы түземем бетте.

— Ту-у-ук-та!

Тәрәзә рамында тын гына утыручы ябык чебен, ачы тавыштан куркып, башы белән пыялага бәрелә-бәрелә безелди башлады. Фәрит, бераз ык-мык итеп торгач, артка чигенә-чигенә, башын иеп чыгып китте. Колакка катырак әби шыгырдавык ишекне ачты.

— Нәрсә булды, балакайларым? Мине чакырган идегезме әллә? Ә-әй, тагын акчагыз бетеп киткәндер, аңлыйм инде, аңлыйм, шәкертләр шул. Менә иртәгә пенсия алам, бирермен, бирермен...— дип сөйләнде дә, җавап бирүче булмагач, әле тезен кочаклап караватта утыручы Әминәгә, әле миңа сәерсенеп карый-карый, кире чыгып китте.

Иске пальтоны җәеп, идәнгә яттым. Утны Әминә сүндерде. Күзгә йокы керми... «Көнләшү шушы микәнни инде? Үзеңә тиң йә үзеңнән өстен кешене генә көнләп була бит. Ә Гөлнурдан, соңгы көннәрен санап ятучы, сез килгәч, бугаздан алган туберкулез бармакларын бераз бушаткан кебек була, дип ятучы гөнаһсыз Гөлнурдан көнләргә буламы соң?»

Чебен тәрәзәгә бәрелә-сугыла безли. «Җылы өйдән кая чыгып китәргә уйлый ул? Тәрәзә артындагы тонык йол-

дызларгамы? Безелдәмә, туган, безелдәмә! Әткәй әйтмешли, йолдыз тамак туйдырмый ул... (Ул «мәхәббәт» диде бугай). Әйдә йоклыйк... Бер, ике, өч сәгать үтте. Чебен безелдәүдән туктамады. Уйлар белән тулган саен, баш авыртып киңәя бара. Киңәер-киңәер дә шартлар кебек. Йокысызлык — минем өчен иң авыр җәза. Секунд саен күтәрелеп, түшәмгә карыйм. Менә-менә түшәм ишелеп төшәр дә Әминәне дә, чебенне дә, мине дә изәр кебек. Әминә йоклый. Матур йоклый ул. Теге вакытта урманда, югалттым дип, ничек курыккан идем. Югалтудан куркам мин аны. Кайчагында кинәт кенә башка тиле уйлар килә. Кибеткә йә институтка барган җирдән кайтмый калыр, каядыр китәр, югалыр кебек тоела ул миңа. Менә хәзер иңнәренә кагылып уятасы һәм: «Әминә, кичер мине, аңла! Мин Гөлнурны кызганам гына, ә сине кызганам да, яратам да!» — диясе иде. Юк, «кызганам» сүзен әйтмичә, «сине генә яратам» дияр идем. Аннары утны кабызыр, ишекне ачып, чебенне урамга чыгарып җибәрер идем.

— Әминә...

Ул уянмый. Мин, торып, пальтоны иңгә эләм. Урамда суык. Урамның каршы ягында төрмә сөрәеп тора. Ак төскә буялган стеналары аңа тагын да суыграк, шомлырак төс бирә. «Ул егет монда утырамы икән?» Башка килгән күңелсез уйларны куа-куа, шәһәр үзәгенә таба киттем. Ирек мәйданындагы эскәмиядә утырырга уңайлы. (Мәйдан белән без адаш икән. Моңа кадәр шуны да белмичә йөргәнмен. Кызык.) Каршыда бик олы соры йорт. Архитектор бу йортны биегрәк итеп салмакчы булган, дип сөйләгән иде кемдер. Ләкин җиткерә башлагач, ниндидер бер түрә: «Шушы биеклек тә бик җиткән»,— дип, төзелешне туктаткан. Архитекторның анда-монда чабуы, ялынуы-ялваруы да ярдәм итмәгән, шул төштән түбәсен ябып та куйганнар. Мин утырган эскәмия астыннан берничә эт башын чыгарып карады. Урам этләре. Ышыграк, җылырак урын эзләргә кирәк иде аларга. Нигә инде мәйдан уртасына чыгып ятарга? Утыра торгач, йокыга талганмын. Туңып уяндым. Өйгә кайтып йөрүне кирәк тапмадым, берничә сәгать буе киләп саргач, институтка киттем.

Фәрит уңайсызлана. Шулай да, берничә мәзәк әйтеп, күңелне күтәреп алды. Юмор-сатира турында бүген төнлә генә ачкан теориясен сөйләде. Үзең белән чагыштырганда бик түбән булган яисә түбән дип уйлаган әйбердән

көлү юмор була, имеш. Ә сатира — үзеңә тиң кешедән көлү. Сатирада нәфрәт була, ә юморда — юк. Мисал итеп ул чебенне китерде. Без чебеннән көлә алабыз, нәфрәтләнә алмыйбыз. Бу — юмор. Мин каршы килдем. «Чебенгә дә нәфрәт белән карап була»,— дидем. «Димәк, ул чагында без үзебез дә чебен дәрәҗәсенә төшәбез. Чебенне бер нәрсә дә эшләтә алмыйбыз икән, димәк, без үзебез дә чебен. Менә шулай, философ Шиһабетдин Мәрҗани»,— дип, иңбашыма сугып алды да, кулдан җитәкләп, коридор буйлап алып китте.

— Декан чакырды сине. Ирекнең колагына гына әйтәсе сүзем бар, ди.

Деканатның ишеге төбендә, шау-гөр килеп, бер төркем студентлар басып тора иде. Алар берсен-берсе уздыра-уздыра кычкырышалар, кемнәндер зарланалар, үпкә белдерәләр.

— Минем әнкәй берүзе генә яши, утын әзерләшәсе бар аңа.

— Минем бабай үләргә ята. Менә кичә генә телеграмма алдым. Тиз кайтып җит, дигәннәр.

— Бездән башка демонстрациягә кеше беткәнмени?

Этелә-төртелә үтеп, ишекне ачтым.

— Исәнмесез!

— Һо-о! Ирек Гыйльметдинов! Әйдүк, әйдүк! Ничек анда, гаилә хәлләре ничек, сөйләп җибәр!

— Әйбәт, хәзергә әйбәт әле, Вафа Нуриевич.

— Нишләп «хәзергә»? Мәңгегә, кем әйтмешли, якты киләчәккә кадәр әйбәт булсын инде ул. Озын сүзнең кыскасы шул, Ирек. Сезнең гаризаны карадык. Курсыгыздан бер сезгә бәйрәм демонстрациясеннән китәргә рөхсәт бирдек. Ни әйтсәң дә, сез гаилә кешесе. Авылга кайтасызмы? Их, каз өмәләре башланыр чаклар җитә инде хәзер! Теләсәгез, Әминә белән кайтыгыз. Аңа да рөхсәт бирербез. Бераз ял итеп алу зыян итмәс аңа. Гариза язып кертсен.

— Вафа Нуриевич, ни... Башкалар кайтмагач... миңа гына...

— Дөрес сөйлисең, тыйнаклык кешене бизи. Ләкин артык тыйнак булу да ярап бетми. Яшәргә, көрәшергә кирәк! Ярый, сау бул. Әти-әниеңнәргә сәлам әйт,— дип кулны кысып, ишеккә кадәр озатып куйды.

Коридорга чыгу белән студентлар: «Ирек, ник чакырган?» — дип, мине урап алдылар.

— Бәйрәмдә кайтырга рөхсәт биргәннәр миңа...

Минем тавышта аз гына да шатлану билгесе юк иде. Кемдер: «Менә бәхетле»,— дип куйды. Кайберәүләр дәшмичә борылып киттеләр. Калганнары түшенке тавыш белән генә үз кайгыларын сөйли башладылар.

— Әнкәй чирләп тора минем,— диде боегып кына почмакта басып торучы бер студент.

— Белешмәң бармы соң?

— Юк шул...

— Әнә, Иректне кәгазьсез дә кайтаралар бит.

— Һе, таптың чагыштырыр нәрсә! Ирек өйләнгән кеше. Гаилә башлыгы.

— Ник соң син дә өйләнмәдең?!

Миңа алар юри мыскыллыйлар, көләләр төсле тоела башлады. «Чыннан да, алардан ни артык җирем бар соң минем? Өйләнгән булуыммы? Бер мизгелдә йодрыклар чытырдап кысылды, йөрәк дөп-дөп типте. Әнисе чирли торган егетнең кулыннан кысып тоттым да җилтерәтеп декан янына кереп киттем.

— Вафа Нуриевич, Вафа Нуриевич, мин кайтмыйм. Минем урынга менә аны кайтарыгыз. Льготалар кирәк түгел миңа,— дидем дә, тамак төбенә килеп төртелгән төерне көчкә тыеп, чыгып йөгердем.

Институттан кайтуга, бүлмә буш иде. Беренче эш итеп, тәрәзәне ачып, чебенне ирекккә чыгарып җибәрдем. Аннары чишенмичә генә караватка сузылып яттым... Йомшак тавышка уянып киттем. Каршымда Әминә басып тора. Кичәге ачуыннан җилләр искән, елмая. Үрелеп, түгәрәкләнә башлаган биленнән кочакладым. Тартылмады да, китмәде дә.

— Әминә, мин институтта булдым.

— Мин дә. Тик иртән йоклап калганмын, син уятмагансың.

Мәйданда йоклаганны әйтеп тормадым. Декан белән булган хәлләрне дә сөйләмәдем. Иске ярасына кагылырмын, тагын үпкәләтермен дип курыктым.

— Бик матур йоклый идең, кызгандым, уятырга кызгандым,— дидем.

Аның йөзе тагын караңгыланды. «Кызгандым» дигән сүзне яратмый, ахрысы, ул. Мин, ашыгып:

— Ә юк, ә... нәрсә... рәхәтләнеп йокласын,— дип өстәп куйдым.

Ләкин соң иде инде. Ул көнне Әминә тагын кәефсез йөрде.

* * *

Кояш безнең тәрәзәгә сирәк төшә. Шуңа күрә радионы бер дә туктатмыйбыз, кояшлы көн вәгъдә итеп, сөендерүен көтәбез. Шулай да көннәр күбесенчә болытлы була. Кышкы төн озын, көне дә караңгы, әллә бүтән бүлмә эзләп карыйбызмы, дип, Әминәгә әйтеп караган идем, риза булмады. Моннан да очсызрагын таба алмабыз, диде. Башка бу турыда сүз кузгатмадым.

Кышкы сессия бетеп килә. Тик каникулны кайда үткәрергә генә төгәл бер фикергә килә алмыйча аптырадык. Бергәләп безгә кайтып булмый. Әткәй, бабай... Әминәләргә никтер минем күңел тартмый. Югыйсә чакырып хат та язганнар иде. Мин — үзебезгә, ул үзләренә кайтырга булды.

Әткәй беренче көннәрдә минем белән сөйләшмәде. Эштән соң кайта, ашап ала да телевизорны тоташтырып куя. Гадәттә, татарча тапшырулар бер-ике сәгатьтән артык булмый. Шул бер-ике сәгатьне күзен текәп, бирелеп карап утыра да, Казаннан тапшыру беткәч, телевизорны сүндереп, йокларга ята. Бабай намазлыктан төшми. Ул да минем белән бик теләп сөйләшми. Кайткан көнне: «Ата-баба йоласын бозддың, улым, тыңламадың, беднең нәселдә булмаган эшне эшләдең»,— дип ачуланып куйган иде. Бүтән орышып та, күңелне күтәреп тә сүз әйтмәде. Мине күргәч, бер-ике сүз генә кушып ала да, читкә китеп бара. Әле дә күңелсез иде, кәеф тагын да ныграк җимерелде. Көн саен әнкәй бүлмә якка кереп, яулык очына елаштыра башлагач кына, әткәй йомшый башлады: «Нәрсә сөмсереңне коеп йөрисең, атаң үлдеме әллә?» — дип, беренче тапкыр сүз катты.

Авылга студентлар күп кайткан. Җыелышып, каникул азагында клубта концерт сымаграк нәрсә оештырырга булдык. Шуңа әзерләнеп, шигырь ятлап, яңа җырлар өйрәнеп йөри торгач, ике атна үткән дә киткән.

Халык күп килгән иде. Мин, гадәттәгечә, Такташны укыдым. «Җир уллары трагедиясе» сукачы малайларга, сыер савучы кызларга, көтүче агайларга бу кадәр үк тәэсир итәр дип уйламаган идем. Сорап, ике кабат укыттылар.

Клубтан бала чактан бирле бергә уйнап үскән күрше кызы белән кайттык. Ул көлә-көлә яланаякны чакларны искә төшерде.

— Ә син теге чакта көне буе елаганыңны хәтерлисеңме? — дип сорап куйдым мин кинәт кенә.— Бүре Вәгыйз кыйнаган иде сине. Мин юаткан булдым. Аннары кичкә кадәр: «Эт кояшы, кит, кит, Җир кояшы, чык, чык», — дип кычкырган идек.

— Җир кояшы барыбер чыкмаган иде. Әй, бар иде инде юләр чаклар! Минем хәзер ул кояшка исем дә китми. Этнеке ни дә, Җирнеке ни... Яңгыр булса, плащ бөркәнәсең, буран булса — тун. Син бүген Һади Такташны бигрәкләр матур итеп укыдың. Мәктәптә «Мокамай»ны өйрәнгән идек. Такташның шуннан башка шигырьләре онытылган. Бүген тыңлагач, елыйсылар килеп китте.

— Димәк, барыбер түгел икән әле.

Ул мин нәрсә әйтергә теләгәнне аңламады, ахрысы, сүзләремне җавапсыз калдырды.

— Ирек, мин сиңа хат язсам, ачуланмассыңмы? Ник дәшмисең? Студент кеше шул сез, шәһәр кешеләре, укыган кешеләр, эреләнәсез. Без монда тирескә чумып йөрибез. Кем дә булса саварга тиеш бит инде ул сыерларны. Әллә кызлар белән хат язышасың, дип, хатының ачуланудан куркасыңмы? Өйләнгән кеше шул син. Мин болай гына, кызлар алдында студент белән хат алышам, дип мактаныр өчен генә...

Мин кызарындым. Тәнгә җылы йөгерде. Күктә ай да, йолдызлар да юк. Яратмыйм мин болытлы төнне. Үземнең җиргә бәйләнгәнемне, канатсыз икәнемне ныграк сизә, оп-олы җирнең бәләкәй генә кешесе булуыма тагын да ныграк инана, шуларны ачыграк күрә башладым бугай.

— Соң, яз. Нигә язмаска? Аның белән бергә укырбыз.

Ул җавап кайтармады. Сүзсез генә саубуллаштык. Капка тоткасына кулын куйгач, туктап калды. Мин үзебезнең өй ягына таба киттем. Арттан аның:

— Ирек, теге аксак бәбкәне күмгән җиргә мин каен утырттым,— дигәне һәм шапылдап капка ябылганы ишетелде.

Ничек истән чыгарганмын әле мин моны?! Ике атна яшәп, чишмә чокырына барып карау башка да килмәде. Ә ул онытмаган, каен утырткан. Борылып, авыл читенә, чишмә ягына таба киттем.

Соң ятсам да, тиз генә йокыга китә алмадым. Тәрәзә артында буран елавы, өйдә морҗа сызгыруы, чикерткәләр сайравы ниндидер серлелек бирә, үзеңне әкият дөньясындагы кебек хис итәсең. Башка әллә нинди тузга яз-

маган уйлар килә. Түшәмнән курка башладым. Такта түшәм генә бит, әллә ни авыр түгел, өскә җимерелеп төшсә дә измәс, дип, үземне юатып ята торгач, таң алдыннан йокыга киткәнмен.

Әнкәй бик иртә уятты. Поездга җитешергә кирәк иде. Һәр өй морҗасыннан күккә сузылган ап-ак, төп-төз төтен баганалары авылны сихри патшалыкка охшатып торалар. Балачакта мин болытларны шул төтен баганаларыннан ясала дип уйлый идем...

* * *

Килүемә мине яңалык көтеп тора иде. «Кибетләрдән вак-төяк нәрсәләр дә аласым бар, кияүне дә күреп китәрмен»,— дип, Әминәнең әнисе килгән. Исәнләшер алдыннан озаклап сөзеп, сынап карап торды. Авыл хәлләрен, туган-тумачаларның исәнлек-саулыгын сорашты. Мин аңа өзек-өзек җаваплар бирә тордым.

— Ни... ә-ә... әйбәтләр, әйбәтләр, барысы да исән-саулар. Тик юл гына бераз ялыктырды. Берөзлексез шакылдап, тәгәрмәчләр генә теңкәгә тиде...

— Булгандыр, булгандыр. Менә хәзер ашап-эчеп алырбыз да ятып ял итәрсең. Бар, кызым, кибеткә чыгып кер әле...

Бүлмәдә аның белән икәү генә калдык. Ул, сүз башларга уйлап, берничә тапкыр тамак та кырып куйды, ләкин минем йөздә кызыксыну да, җәелеп сөйләшерлек теләк тә күрмәде, ахрысы, дәшмәде. Тынлык. Миңа сулыш алуы да уңайсыз, бүлмәдәге бар һаваны ул сулап тора кебек. Теге чебен дә юк, ичмасам. Аның истәлеге булып тәрәзәдә соргылт таплар гына калган. Барыбыз да шул чебен кебек киләбез дә эз калдырып китеп барабыз инде.

— Ирек!.. Ирек димме, кияү димме инде?

— Ничек дисәгез дә ярый.

— Менә, Ирек, сезнең тормышыгызны күреп китим, дип килгән идем әле. Әминә бик мактады үзеңне, бик кешелекле, бик нечкә күңелле, диде. Бик рәхмәт. Әминәнең күңеле яралы икәнен беләсең, кадерләп яшәргә кирәк аны. Яхшылык онытылмый ул, яхшы булырга кирәк. Коммунизм ишеген шакыган чорда шулай булмыйча ярыймы соң? Әминәнең әтисе мәрхүм әйтә торган иде...

Ул сөйли. Бер сүз әйткән саен, каты күзләре белән чәнчеп, үлчәп карап куя. Мичкә күмер аткан саен, градусникны тикшереп торган кочегар кебек. Бу караш минем хәлне тагын да ныграк авырайта, башка әллә нинди уйлар төшә. «Нигә сөйли инде бу сүзләрне? Шундый нечкә, изге хисләр турында шулай тыныч кына итеп, салкын тон белән сөйләргә ярыймыни? Тупаслык бит бу». Бөтенесен ташлап, урамга йөгереп чыгасы, үпкәләр шартлаганчы саф һава сулыйсы килә.

— ...Туберкулезниклар янына гына еш йөргәли, дип әйтте беркөнне. Дөрес, авыру кеше бала кебек ул. Карарга, юатырга кирәк аны. Ә туберкулезниклар дөньядан өмет өзгән кешеләр алар. Бу дөньядан берни дә — синең юатуың да, шигырьләрең дә кирәк түгел инде аларга. Җитмәсә, бигрәк тә йогышлы чир бит. Әле Әминә әйткәч, брошюралар укыган идем. Ниләр генә язмыйлар анда! Котың очарлык. Терелгән очраклары да була икән булуын. Шулай да сак булырга кирәк, бик куркыныч... Концерт куябыз, дисәң, авырулар күп бит, йогышсызлары да аз түгел. Әминә бик мактады үзеңне, шигырьләрне бик матур итеп укый, диде. Эчләре авыртучыларны, имгәнгәннәрне дәвалый торган больницалар...

— Юләрләр йорты...

Ул кинәт туктап калды. Күзләре, гаҗәпләнүдән, зур булып ачылдылар. Миңа барлык сүзләр, барлык әйберләр — бөтен дөнья мәгънәсез булып күренде. Ычкынды, кирәксез, урынсыз сүз ычкынды авыздан. Күпме түзеп, әдәп сакларга тырышып утырган идем бит югыйсә. Булмады, түзеп булмады. Каян башка килде тагын ул юләрләр йорты? Юктан гына түгелдер... Соңгы көннәрдә нишләптер акылдан язган кешеләр турында күп уйлый башладым.

Әминә кайтты. Аның йомшак иреннәрен, көлеп торган күзләрен күргәч, күпмедер вакытка авыр уйлардан һәм әнисенең түзеп булмаслык карашыннан котылдым. Рәхмәт сиңа, Әминә!

Өстәлне җыештыргач, бераз йөреп керик дип, урамга чыктык. Аяк астында, бихисап энҗе-мәрҗәннәр кебек, кар бөртекләре ялтырый. Таптап йөрергә дә кызганыч аларны. Дөнья шундый матур! Әминәнең иреннәрен эзләп таптым. Тик күзләре күренми иде. Ул ычкынып китте дә, йөгереп барып, кар өеме өстенә менеп басты, һәм урамны яңгыратып көлә-көлә шигырь укый башлады:

Ты сказала, что Саади
Целовал лишь только в грудь.
Подожди ты, бога ради,
Обучусь когда-нибудь...

— Әгәр Есенин татар кызын сөйгән булса, бу шигырен бүтәнчәрәк язган булыр иде,— дидем мин, ул туктагач.

— Татар ни дә урыс ни, кайры ни дә курыс ни, дия иде безнең бабай. Мәхәббәткә милләтнең катнашы бармыни?

— Бетте, бетте. Югыйсә син мине хәзер милләтчелектә гаепләп ташлавың мөмкин. Беләсеңме, Әминә?.. Урмандагы һәр агач үз ишләре белән бергә, бер тирәгә җыелып үсә. Бер төрлеләре — үзән урынны, икенче төрлеләре — таулыкны, өченчеләре — коры җирне, дүртенчеләре диңгез буен яраталар. Юк, яраталар гына түгел, шул урыннан күчерсәң, тамыр җәя алмыйча газап чигәләр, хәтта корыйлар. Агачларны милләтчелектә гаепләргә җыенмыйсыңдыр бит син...

— Әй, тагын башладың инде!

— Алайса, Есенинның татарча язган шигырен укыйм мин сиңа.

— Юкны сөйләмә...

Син әйтәсең: «Сәгыйдулла
Тик күкрәктән үбә иде».
Алла хакы өчен түзче,
Өйрәнермен әле мин дә.

Ул, буш урамны тутырып, тагын көлеп җибәрде.

— Шаярта белә дип уйламый идем мин сине!

Бүлмәдә өч кешелек урын юк, булса да, әнисе янында йокларга тартыныр идем. Соңгы арада төннәр буе саташып чыгам, әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән җан ияләреннән качып, шулардан котылырга маташып, бастырылып бетәм.

Рельслар өстендә атынып, бөтен гәүдәсе белән калтырап, шалтырап килүче трамвайга сикереп утырдым да тулай торакка киттем.

Малайлар йоклый. Утны кабызып тормадым. Милләт йоклый, дип, авыз эченнән мыгырдана-мыгырдана, Фәрит янына барып аудым.

* * *

Бер атна чамасы үткәч, күрше кызыннан хат килде. *«Теге кичне син бик тә яхшы идең, укыган шигырьләрең әле һаман да колакта яңгырап тора»,*— дигән, авыл яңалыкларын, безнекеләрнең исәнлек-саулыгын язган. Үзем укып чыккач, хатны Әминәгә бирдем. Күзләре кысылдылар, иреннәре юкарды, бит алмаларындагы алсулык бер мизгелдә юкка чыкты. Хатны йомарлап, караватка менеп тезләнде дә мендәргә башын куйды. Карават шыгырдап алды да тынды. Фәриткә: «Гади карават түгел, тарихи карават, тарихның үзе бу»,— дип әйткәнем бар иде. Шул искә төште. Чыннан да, кемнәр генә менми аңа, кемнәр генә төшми. Барысы онытыла, ә карават һаман исән. Тәхет кебек. Соңгы арада мин артык күп фәлсәфә сатам бугай. Карават тагын шыгырдый... Уйлардан бүленеп, кинәт айнып калдым. Әминә куллары белән башын кысып тоткан, иңбашлары бер күтәрелә, бер аска төшә. Карават шыгырдый... Ул елый, тилереп, инәлеп, яшьсез елый.

— Әминә, кирәк түгел, Әминә, зинһар өчен, елама, тукта инде. Әминә...

Ул, мөлдерәмә күзләрен күтәреп, миңа карады.

— Нигә, әйтче, нигә кирәк ул кызлар сиңа?! Минем ни гаебем бар, минем дә алар кебек буласым, бөтенләй синеке буласым килмимени? И Ходаем, нигә көлделәр миннән, ник мәсхәрә иттеләр мине?!

— Әминә, миңа артык бер нәрсә дә кирәк түгел. Шушы килеш яратам мин сине, бары шушы килеш!

Ул, калтыраудан туктап, торып утырды. Тавышы да бераз тынычлана төште. Йөзендә елмаю төсмере чагылып китте.

— Юк, Ирек, яратмыйсың син мине. Син мине бары кызганасың гына. Кызганып таныштың, кызганып йөрдең, кызганып өйләндең. Менә инде хәзер кызганып яшисең. Син мине берни дә аңламый дип уйлыйсыңдыр инде. Ялгышасың, бик каты ялгышасың. Ул кызлар белән ни өчен йөргәнеңне бик яхшы аңлыйм бит мин. Миндә булмаган нәрсәне аласың килә синең алардан. Яз көне беркем дә таптамаган чирәмдә ятып ауныйсым килә, җәен кеше кулы тимәгән җиләк аланында буласым килә, көзен урман буйлап саф, чиста яфраклар ерып йөрер идем, дип авыз корытып сөйләгән сүзләреңнең төбендә ни ятканын бик аңлыйм мин...

— Мин сөйләдемме бу сүзләрне?! Ялгышасыңдыр, Әминә, ялгыш ишеткәнсеңдер син.

— Ялгышмыйм, китапханәдән алып кайткан китапларыңның, караган киноларыңның күбесе алданган кызлар турында икәнен дә беләм. Ялгышмыйм. Кирәк түгел миңа кешелекле булып кылануыгыз! Кызгануыгыз да кирәк түгел! Калдырыгыз, үземне генә калдырыгыз! Кызганмагыз мине!

Ул, бөтенләй тыныч тавыш белән, миннән өстәрәк торып, мыскыллы тавыш белән сөйли. Минем, ак җәймә өстенә ятып, тулган күңел бушанганчы елыйсы килә.

* * *

Игезәкләр кебек бер-берсенә охшаш көннәр үтә торды. Әминә белән әйбәт кенә сөйләшәбез, хәтта кайвакытта, кызык сүзләр әйтеп, көлешеп тә алабыз. Ул әкренләп тагын гадәти хәленә кайтты бугай. Тик мин генә соңгы ачуланышудан тернәкләнә алмадым. Ул минем бөтен чынбарлыгымнан, рухи халәтемнән, өметләремнән, яшәешемнең мәгънәсеннән көлде. Кешене чокырдан тартып чыгардым, кешене коткардым, дип уйлап, тормыштан кызык табып, очып, янып яшәгәндә, кинәт бетеп, бушап калдым. Ул чокырга хәзер мин төштем. Иң авыры — хәзер минем үземә дә ниндидер бик зур гаебем бардыр, тормышта ниндидер төзәтеп булмаслык зур ялгышлык кылганмындыр кебек тоела башлады. Һәр җинаятьченең җинаятен аклый торган үз фәлсәфәсе була. Шуннан башка ул яши алмас, вөҗдан газабыннан үләр йә акылдан язар иде. Мин исә гаебемнең нәрсәдә икәнен дә белмим, шуңа күрә аклану да таба алмыйм. Ләкин хәзергә үлмәдем дә, акылдан да язмадым әле.

Фәрит нидер сизенә, миңа ярдәм итәргә тырыша. Акча бетә башлаганны белсә, азык-төлек күтәреп килеп җитә. Циркка, кинога, театрга чакыра, «Тизрәк ял җитсен иде, тагын өчәүләшеп Идел буена барыр идек»,— дип юатырга, өметләндерергә маташа. Нәрсәдер сөйләттерәсе, хәлебезгә керәсе, булышасы килә аның безгә. Мин аңа бөтенләй кирәксез сүзләр сөйлим, чөнки үземә нәрсә кирәк булганын үзем дә тәгаен белмим.

Март аенда, без өйләнешкәннән соң беренче тапкыр,

эткәйдән хат килде. *«Ярый, тормыш коргансыз икән, бергә-бергә тату итеп гомер итегез, бездән хәер-фатыйха шул»* дигән. Бергәләп җәйге каникулга кайтырга чакырган. Хатны укып чыккач, тешләрне кысып елмайдым. Рәхмәт әйтеп хат яздым.

Әминәгә ял бирделәр. Ул, үзенең түгәрәкләнгән гәүдәсеннән оялып, көннәр буе беркая чыкмыйча өйдә утыра. Соңгы көннәрдә бөтенләй диярлек сөйләшми, тәрәзә янына килеп баса да, сәгатьләр буе маңгаен пыялага терәп, хәрәкәтсез тора. Мин институттан кайтканда, күзләре, елаудан, ахрысы, кызарып, шешенеп беткән була.

* * *

Ул көнне институтка барасым килмәгән иде. Күңел сизенгән. Азакка кадәр утыра алмадым, соңгы лекциягә кермичә, ашыга-ашыга кайтып киттем. Үземне сүгә-сүгә, йөгерә-йөгерә кайттым. «Вакыты җитеп килә иде бит инде. Кадерләп, саклап кына торырга кирәк иде». Бәрелә-сугыла баскычтан менеп, ишекне ачтым. Бүлмә буш. Киткән, алып киткәннәр! Йөрәк кысылып, чикләвек кадәр генә булып калды. Дөбердәп әби янына кердем.

— Әби, Әминә кайда ул?

— Борчылма, улым. Тынычсызлана башлагач, шылтыраткан идем. Минутында килеп алып киттеләр.

Якындагы бала табу йортына йөгердем. «Монда юк»,— диделәр. Телефоннан шылтырата торгач, таптым. Әллә кая еракка илтеп салганнар икән. «Янәшәдә генә бала табу йорты була торып, ни пычагыма анда алып киттегез?» — дип кычкырдым да, трубканы ташлап, шунда йөгердем.

— Әлегә билгесез, бүген булмас, иртәгә килегез, шылтыратып торыгыз,— диделәр. Телефоннан да төне буе шул сүзләрне кабатладылар.

Йокы качты, ашау онытылды. Китап укырга тырышып карадым. Бер җөмлә уку белән тотып аттым. Ул тузгып караватка килеп төште, битләре таралды. Ачык конвертлы хат, китап эченнән чыгып, кыйгачлап очып барды да карават астына төшеп китте. «Ул миңа язып калдыргандыр»,— дигән уй баштан йөгереп узды. Хатны алдым. Карандаш белән язылган түгәрәк, симез хәрефләр. Кем бу, нәрсә бу?..

*«Саумы, Әминә?!*

*Сиңа әллә ничә тапкыр язарга уйлаган идем инде, тик нигәдер язмадым. Мин әйбәт яшим. Эшлибез, йоклыйбыз, мәзәкләр сөйлибез. Тик сагындырып куя... Актлар залында синең ничек утыруың күз алдыннан китми. Бик романтик кыяфәттә идең син.*

*Син ничек уйлыйсыңдыр, белмим, мин үземне аз гына да гаепле санамыйм. «Көчләү» дип әллә нинди гаеп тагуларына да исем китми. Ул кичне мин аз гына да көч кулланмаган идем бит. Коньякны да сиңа көчләп эчермәдем. Аларның ни эшләре бар, бәлки, мин сиңа өйләнгән дә булыр идем. Әллә бар кеше дә ератышып кына өйләнешә дип уйлыйсыңмы? Мәхәббәт мәңгелек двигатель түгел. Җил тегермәне кебек ул. Аның җиле — вакыт. Тора-бара бер-беребезгә ияләшкән булыр идек әле. «Әминә белән булдым»,— дип сөйләп йөргәнмен, имеш. Сөйләсә соң! Дөресен сөйләгән бит, алдамаган. Ярый, бу турыда җитеп торыр.*

*Син ничек яшисең? Кияүгә чыккансың дип ишеттем. Котлыйм, уңышлар телим. Мине дә онытып бетермә. «Мин беренче чәчәкләрне эзлим» дигән җырның сүзләрен язып җибәр әле. Нигәдер шул искә төште. Ә сүзләре онытылган.*

*Сәлам белән Фаяз.*
*11 апрель».*

...Нәрсә уйларга белмәдем. Инде ике атна элек килгән булган. Ә миңа күрсәтмәгән. Эченә җыйган, яшергән. Һәр җинаятьченең үз фәлсәфәсе булуы турында ничек дөрес уйлаганмын. Кабахәт кеше тагын да кабахәтрәк итеп аклана... Тагын әллә нинди уйлар килде бугай ул чак башка. Онытылган. Хатны атып бәрдем. Кинәт тартудан, ишек тоткасы суырылып чыкты. Аны идәнгә томырдым. Бар ачуны ишектән алырга теләгәндәй, аны каерып ачтым да бөтен көч белән шапылдатып ябып җибәрдем. Ишек ябылу тавышына агач өй дерелдәп куйды, бүлмәдә нәрсәдер гөрселдәде. Кабат борылып, ишекне киереп ачтым. Каты тартудан, бу яктагы тотка да суырылып чыкты. Бүлмәнең элек тә чак кына эләгеп торган штукатуркасы кубып төшкән. Тузан аша бер нәрсә дә күренми... Чыгып йөгердем. Бала табу йортына килеп җиткәч, беренче очраган ак халатлы кешенең кулларыннан эләктереп алып: «Нишләттегез Әминәне, Әминәне кая

куйдыгыз, ник әйтмисез?!» —дип, кыргый тавыш белән кычкырып җибәрдем. Ул куркып артка чигенә башлады, мин дә үземнең ачы тавыштан бераз айнып киттем. Кулда һаман ишек тоткасы тотып торам икән, оялып, аны артка яшердем.

— Иптәш, сез тынычланыгыз... сез... Хатыныгыз исәнсау. Тик эшләр бераз катлауланды гына... Барысы да әйбәт булыр... Өегезгә кайтыгыз... Шылтыратыгыз...

Башны иеп чыгып киттем. «Нигә күрсәтмиләр аны, нигә яшерәләр? Мине күргәч, нигә куркып калдылар алар? Сизәм бит, барыбер сизәм, нигә яшерәләр, нигә тилмертәләр мине?!» Кич телефон аша әйттеләр. Көндез үземә әйтергә курыкканнар, имеш. Барыбер әйттеләр бит югыйсә. Иртән-иртүк: «Сезнең хатыныгыз Әминә бала тапканда үлде»,— дип гап-гади итеп әйтергә кирәк иде. Нигә кешене газапларга? Менә хәзер барысы да билгеле. Авыр да, җиңел дә түгел... Авыздан тоз тәме килә. Ә-ә, яшь икән, күз яше...

Икенче көнне килеп әйттеләр: «Күмәргә кирәк»,— диделәр. Нигә әйттеләр, нигә инде мондый кирәксез сүзләр? Кирәк икәнен үзем дә белмиммени мин?!

...Яратам шушы татар зиратын. Тып-тын... Артык бизәкләр дә, гәүдәне басып торучы авыр һәйкәлләр дә юк. Хәтта үләсе килеп куя... Әминәгә каберне артык тирән казыганнар бугай... Алып киләләр...

* * *

Самолет, болытларны ергалый-ергалый, җиргә якынлаша башлады. Кояш өстә калды, кояш югалды. Аста беренче кар төшкән җир агарып күренде. Самолет селкетүдән Ирекнең күңеле болгана башлады. Ул инде сәгать буе үзен җәфалаган уйлардан арынуына сөенеп куйды. Хәер, аның гомере дә шул төштә өзелә, истәлекләр бетә иде инде. Калганын ул хәтерләми, кайдадыр аккошлар күргәнен һәм бик моңлы итеп скрипка уйнаганын ишеткән кебек булса да, аларның төштәме, өндәме икәнен төгәл белми иде.

...Әминәне күтәреп алып килгәндә дә, кабергә төшерер алдыннан да аның йөзенә кайгы төсмере чыкмады, киресенчә, ул елмая кебек иде. Укытучылар, туганнар,

студентлар берәм-берәм чыгып мәрсия сөйләгәндә дә йөзе үзгәрмәде аның. Ике баштан ике тасма белән дүрт кеше ап-ак кәфенгә төрелгән Әминәне кабергә төшерделәр. Кемдер (зират эшчесе булса кирәк) сары нарат такталар белән ләхетне каплады. Башлар иелде. Салкын җиргә кайнар яшьләр тамды, бер хатын үксеп елап җибәрде. Барысы да, берәр уч балчык алып, кабергә ташладылар. Каты балчык кисәкләре тактага бәрелеп шакылдады, тагын шакылдады, тагын, тагын... Ирек, кинәт зират тынлыгын тавыш белән тутырып: «Туктагыз, туктагыз, ул шакый, әнә, ләхет тактасына шакылдата, чыгарыгыз аны!» — дип кычкырды һәм, үзен тотарга маташкан куллардан ычкынып, кабергә сикерде. Ашыга-ашыга такталарны алып өскә ыргытты һәм ак кәфенгә төрелгән мәетне, суырып чыгарып, бастырып куйды. Аны кочакларга, сыйпый-сыйпый үбәргә, «Мин ул хатны укымадым, Әминә. Укымадым, син дә укымадың!» дип сөйләнә-сөйләнә юатырга тотынды. Өстә торучылардан бер хатын: «Башы аста бит, башына бастырган бит»,— дип чәрелдәп кычкырып җибәрде һәм, һуштан язып, кабер туфрагына капланды. Ирекнең соңгы көннәрдә ачлыктан, йокысызлыктан хәлсезләнгән аяклары сыгылдылар, куллары бушады. Һәм ул гөрселдәп кабер эченә егылды. Мәет аның өстенә ауды. Ул нәрсә булганын әле генә аңлады, ахрысы, Әминәне бер кырыйга этәреп, кабердән сикереп чыкты да, бар көченә кычкыра-кычкыра, урамга таба йөгерде. Аны куып җитә алмадылар.

Ирек көне буе җәяүләп шәһәр буйлап йөрде. Ул Әминә белән нәрсәдер булганын белә, ләкин төгәл нәрсә икәнен хәтерли алмыйча тилмерә иде. Йөри торгач, ул белдерүләр янына килеп туктады. «Аккош күле». «Таптым, Әминә менә ни өчен бүген актан киенгән икән. Ул бүген аккош, ап-ак аккош булып биергә җыена». Белдерүдәге аккошларны күреп, шушы ачышны ясагач, аңа җиңел булып китте. Ул сәбәпсезгә борчылып йөри. Барысы да әйбәт икән ләбаса...

Шәһәр читенә чыгып җиткәндә, ул бөтенләй тынычланган, уйлары да тәртипкә салына башлаган иде. Чирәмгә сузылып ятып, мәңгелек болытлар артыннан бер мизгелгә генә күренгәләп китүче кояшка: «Эт кояшы, кит, кит, Җир кояшы, чык, чык!» — дип кычкырып карады. Ләкин кояш аны тыңламады, кояш чыкмады.

Ул уянганда, караңгыланып килә иде инде. Торып өсләрен каккалады. Башы авырта, башында берөзлексез ниндидер шау ишетелеп тора.

Шәһәр үзәгенә баручы трамвайга кереп утыргач кына, ул үзенең бүген бик каты авырганын искә төшерде, инде терелеп килүенә сөенеп куйды.

Трамвай театр янына килеп туктады. Урам халык белән тулы. «Театрга киләләрдер. Бүген нәрсә була икән?.. «Аккош күле»... Әминә ярата аны. Тагын бер тапкыр карыйм әле, больницадан чыккач, син яраткан «Аккош күле»ндә булдым, дип сөйләрмен үзенә».

Ул Әминәнең бала табу йортында ятканын да, үзенең авырып киткәнен дә аз гына төсмерли, ләкин зиратта булган хәлләрне хәтерләми иде.

Кассада билетлар беткән. Көтә торгач, артык билетын сатучы табылды тагын. Залда ут сүнгән. Ул кармаланып урынына барып утыргач, дирижер, кинәт һаваны кисеп, кулын селтәп җибәрде. Әллә кайдан, еракта, залга музыка агылып керә башлады, музыка агымына ияреп, сәхнәгә аккошлар агып чыкты. Аккошлар... Кайда күрде ул аккошларны? Ниндидер бик куркыныч җирдә күргән иде бугай... Кайда икән, кайда?

Кайда күргәнен төгәл белмәсә дә, ниндидер бик куркыныч җирдә икәнен күңеле белән сизә иде ул. Бу музыка, бу аккошлар аның күңелендәге шомны көчәйтәләр, «бис» кычкыручы, кул чабучы тамашачылар аңа үзеннән көләләр кебек иде. Аның: «Көлмәгез миннән, мыскыл итмәгез, арыдым мин!» — дип кычкырасы, үтенәсе, ялварасы килә, ләкин, аңа борылып та карамыйча, һаман кул чабуларын күргән саен, ачуы көчәя бара. Нигә аның хәлен белмиләр, кайгысын уртаклашмыйлар, нигә үртиләр аны?!

Самолет, чыдатырмы икән дигән сыман, тәгәрмәчләрен бер-ике тапкыр тигезеп карады да, ныклыгына ышангач, җир буйлап йөгереп китте.

Автобус килеп җитмәгән икән. Аэропорт болын кебек тигез мәйданнан һәм авыл мунчасыдай кечкенә генә йорттан гыйбарәт. Баскыч төбендә бер хатын, тал чыбыгы белән кизәнә-кизәнә, мәче кыйнап маташа. Мәче чиный, ычкынырга тырыша. Аэропорт читендәге чирәмлектә хыялый йөзле малай су буена карый-карый каңгылдаучы ялгыз казны куып бара. Ирек, үзенең балачагы белән

очрашудан куркып, күзләрен йомды. «Тизрәк автобус килсен иде»,— дип уйлады ул.

...Ирекнең улын күрәсе килә, мең газаплар белән дөньяга килгән малаен. Үзенең улы барлыгын ул больницада гына белде. Әминә турында да шунда әйттеләр...

Ник килми инде бу автобус? Малае янына, төтен баганалары белән күкне терәп торучы авылына тизрәк кайтасы иде...

*1968*

# *Иске сәгать дөрес йөри*

## ЮЛ АЗАГЫ — ЮЛ БАШЫ

Стенадагы иске сәгать, ютәленнән буылган карт сыман, озак гыжылдап, иртәнге алтыны сукты. «Вакыт галиҗәнабләренә суык тигән,— дип уйлады Искәндәр.— Суык тигән».

Шулчак аның тәне буйлап салкын тәпиле кырмыскалар йөгереп узгандай булды. Ул юрганын башына ук тартып китерде, җылы эзләп, аякларын арлы-бирле йөртте. Аннары шактый вакыт, кымшанмыйча, күзләрен түшәмгә төбәп ятты. Нәрсә турындадыр уйлыйсы, хыялланасы — шулай итеп иртәнге авыр хисләрдән котыласы килә иде аның. Ләкин, уч иткәндәй, башына бер уй да килми. Әйтерсең ул белгән-күргән нәрсәләр барысы да кара төн пәрдәсе артында бүленеп калган, әйтерсең ул үткәнгә җилкәсе белән борылып утырган да киләчәкнең буп-буш чиксезлегенә күзләрен төбәп онытылган иде.

Тәрәзәдән агып кергән сүрән яктылык, ишәйгәннәнишәя барып, озакламый бөтен бүлмәне тутырды. Караңгылык әкренләп почмакларга сыенды, пәрдә артларына үрмәләде, анда да сыенып урын таба алмагач, идән ярыкларына саркып юкка чыкты. Идәндә, төн диңгезе ярга чыгарып ыргыткан ватык кораб калдыкларына охшап, бер пар чүәк, уч төбе хәтле келәм, урындык башыннан шуып төшкән чуар сөлге генә ятып калды.

Искәндәр кинәт кенә юрганын тибеп очырды да, тезләрен кочаклап, торып утырды. Бармаклары белән чәчен артка сыпырып куйды, күзләрен уды. Инде тагын нишлим дигәндәй, як-ягына карангач, стенада асылынып торган җепне тартты, брадагы лампочка иртәнге яктылыкка куәт өсти алмады, Искәндәр, җепне янә тартып, утны сүндерде. Аннары иплән кенә караваттан шуышып төште дә, аякларына чүәк элеп, лаштыр-лоштыр бүлмә буйлап атлап китте. Кухняга керде. Өстәлдә инде атна буе

юылмаган тәлинкәләр өелеп тора. Иренеп кенә кранны борды,— тагын җылы су юк. Савыт-саба юмаска сәбәп чыгуына сөенгәндәй, теләр-теләмәс кенә сукранып, кранны ябып куйды.

«Элек тә җылы су сирәк килә иде. Ә савыт-саба гел чиста тора иде. Ничек юды икән ул аларны? Салкын су беләнме?»

Өйдә аның юньләп ашаганы да юк бит. Иртән бер чынаяк чәй эчә дә чыгып йөгерә, көндез кайда туры килсә, шунда ашый, ә кич... кич кайтканда, күп чагында алар йоклаган була.

Кофе банкасы эзләп шкафта актарынганда, аның күзе стенадагы календарьга төште. Күкрәкләренә кадәр суга кергән озын кара чәчле кыз артка каерылып караган да, үзенә төбәлгән чит карашны күреп, бер мәлгә югалып калган. Менә ул, исенә килеп, алга ташланыр да тар бүлмәне яңгыратып көлә-көлә диңгез эченә йөзеп кереп китәр... «Ерак китә алмассың,— дип елмайды Искәндәр.— Гомерең аз калган». Ул, су кызының кызыктыргыч шәрәлегеннән котылырга теләгәндәй, календарьның соңгы битен әйләндереп куйды. Куйды да, арткы яктагы «Котлы булсын Яңа ел!» дигән сүзләрне күргәч, сәерсенеп озак карап торды. Бүген утыз беренче декабрь, елның соңгы көне. Ә ул бернәрсә дә әзерләмәгән, аның бернәрсәсе дә юк. Өе ташландык абзар сыман, тәм-том да, аракы-шәраб та алмаган, чыршы хәстәре дә күрелмәгән. Ул бит Яңа елны каршы алырга әзер түгел. Өе генә түгел, аның уйлары, хисләре, хыяллары — гомумән, ул үзе Яңа елга керергә әзер түгел.

Шулчак стенадагы иске сәгать, гыжылдап, озак итеп бер тапкыр ютәлләп куйды. «Вакытка суык тигән»,— дип, ачу белән иреннәрен тешләп кабатлады ул. Инде ничә тапкыр шул сәгатьне антиквар кибетенә илтергә җыенды. Һаман вакыт тими. Бабайдан калган истәлек дип тота. Бабасы күптән дөнья куйды инде. Ә сәгать һаман йөри. Гүя ул әле һаман бабасы вакытын санап йөри, гүя ул әле һаман бабасы ютәле белән ютәлли, бабасы өчен ютәлли... «Вакытка суык тигән...»

* * *

...Ул көннән соң аның өчен дөньядагы бар нәрсәнең мәгънәсе үзгәргән кебек булды, җансыз әйберләргә җан керде, бүлмәсе көннән-көн зурая барган сыман тоелды, ә тирә-юньдәге түгәрәк дөнья күзгә күренеп кечерәйде. Ул көннәр буе шәһәр ыгы-зыгысына ияреп ихтыярсыз йөри-йөри дә, тын култыкка кайтып сыенган нәни каек сыман, аптырап-сәерсенеп бик озак бүлмәсе уртасында басып тора. Гасырлар артыннан килгән күкрәү авазына охшатып иске сәгать суга башлагач кына, яңадан аңына килгәндәй була. Ул инде ничә еллар буе шушы сәгать белән сөйләшеп, бәхәсләшеп яши. Кайвакытта, бигрәк тә ялгыз калган чакта, борынгы сәгать янында ул үзенең бик кечкенә, уйларының да бик вак икәненә төшенеп гарьләнеп тә куя. Тора-бара сәгатькә ул җанлы әйбергә караган сыман карарга гадәтләнде. Иртәнге алтыда радиодан гимн яңгырый башлагач, иң беренче эш итеп әле кулындагы бүләк сәгатькә, әле стенадагы борынгы сәгатькә карый. Үз кулындагы сәгатьнең дөрес йөргәнен күргәч, сабый бала кебек сөенә. Иреннәрен түгәрәкләп, стенадагы сәгатьне үчекли, ярый инде, миннән булсын яхшылык дигәндәй, диванга басып, телләрен күчерә.

Искәндәр тәрәзә төбендә яткан сәгатен әйләндереп карый-карый кулына такты. Аннары кабалана-кабалана киенде дә идән себеркесе эзли башлады. Ләкин — һәй, гөнаһ шомлыгы — өйдә себерке юк иде. Соң, моңа кадәр булгандыр бит инде ул? Хатыны себеркене дә үзе белән алып китмәгәндер... Искәндәр аның идән себергән чагын хәтерләргә тырышты, ләкин исенә төшерә алмады. Зәңгәр джинсы чалбар киеп, тузгыган коңгырт чәчләрен артка ташлый-ташлый идән юганын хәтерли, ә менә идән себергән чагын — юк. Әллә идәнне ул бер дә себермәде микән? Көн саен югач, себереп торуның кирәге дә калмый. Мүкәли-мүкәли килеп, башы белән пианинога бәрелгәч кенә, үзенең гел кирәксез нәрсәләр турында уйлаганын аңлап, башын түбән иде.

Тезләрен юешли-юешли күпме тырышса да, идән чистармады, киресенчә, пычрагы буй-буй булып җәелеп кенә калды. Кул селтәп, юлбарыс тиресенә охшап калган идәнгә караңгы бүлмәдәге иске паласны чыгарып каплады. Шул арада кухняда кофе ташый башлады. Йөге-

реп барып газны сүндерде дә, кофега ике шакмак шикәр салгач, озак итеп аның ак күбекләре сүнгәнне карап торды.

Каядыр ашыккан, кабаланган кебек тиз генә юынып алгач, яңадан кухняга чыгып, авызын пешерә-пешерә кофе эчте. Эчеп бетергәч, бөтен эше тәмам булган кебек, тагын туктап калды.

«Нишләргә? Бүген нишләргә? Нинди эшләр бар бүген? — дип, үз-үзенә сорау бирде ул.— Беренчедән, өйне тәртипкә китерергә. Аннары, кибеттән кирәк-ярак ташып, бәйрәм өстәле әзерләргә. Чыршы табарга. Уенчык элмәсәң дә ярый, бала-чага юк...— Ул, чыннан да бала-чага юклыгына ышанырга теләгәндәй, як-ягына каранды.— Чыршы кыяфәте булгач, исе аңкып торгач, шул җиткән. Тагын нишләргә? Ә-ә-ә... Ә кунаклар?! Күптән дәшеп куйган кунаклары бар бит аның. Бүген тагын бер тапкыр исләренә төшерергә кирәк булыр. Инде күптән берсен дә күргәне юк. Телефоны булганнарына шылтыратыр, Ислам белән Шәүкәтләрнең өйләренә кереп чыксаң да була».

Искәндәр почмактагы тумбочка өстендә торучы телефонга күз ташлады. Куе кызыл төстәге телефон иртәнге эңгердә менә-менә сүнеп килүче олы бер утлы күмергә охшап тора. Соңгы арада нигәдер берәү дә шылтыратмый әле аңа. Баштарак, алар киткән көннәрдә, берничә көн телефон тынып тормады. Аны сорап шылтыраттылар, кызының классташлары шылтыратты. Ул, нигә аны миннән сорыйсыз дигән сыман, өзек-өзек кенә җаваплар кайтарды: «Китте ул, китте. Белмим, белмим. Бөтенләйгә китте. Белмим, белмим... Кайтмаска китте... Нишләп шаяртыйм ди инде... Шулай килеп чыкты инде... Берберебезне аңламаганбыздыр. Үтсә үткән инде, нишлисең. Ун елны түгел, бөтен гомерен суга салган кешеләр дә бар бит. Хәерлегә булсын... Юк, юк, үкенмим... Үкенмәм. Сөенмим дә... Күптән шулай булырга тиеш иде. Шулай кирәк иде... Җае чыкмый торды. Менә, ниһаять, җепне өзәргә булдык... Аңа да яхшы...»

Искәндәр телефон трубкасын кулга алып бераз әйләндергәләп торды да беренче булып хәтергә килгән номерны җыя башлады. Озак җавап бирми тордылар. Искәндәрнең трубка тоткан кулы тирләп чыкты. Ниһаять, колакны кытыклап торган озын гүләү авазын бүлеп, телефоннан таныш тавыш ишетелде:

— Тыңлыйм сезне...

Искәндәр шатлыгыннан кычкырып җибәргәнен дә сизми калды:

— Ә-әй! Хәмит дус! Йоклап ятасың мәллә? Шылтыратам, шылтыратам — җавап бирмисең. Бәйрәм көнне йоклап яту килешми.

— Т-с-с! Кычкырма шулкадәр. Балаларны уятасың. Сәгать ничә икәнне беләсеңме соң син?

Искәндәр, аптырап, әле кулындагы сәгатькә, әле стенадагы сәгатькә карады:

— Беләм...

— Бу вакытта авылдагы карт әтәчләр белән шәһәрдәге карт буйдаклар гына тора...

— Бәйрәм бит...

— Бәйрәм нәрсә өчен? Бәйрәм ул, туган, халык йокласын өчен. Рәхәтләнеп, бөтен кайгыларыңны онытып йоклар өчен ул бәйрәм...

Искәндәр, Хәмитнең шулай акыл өйрәткән тон белән сөйләвенә сәерсенеп, телсез калды. «Нәрсә булган моңа? Иртәнге җиденче яртыда түгел, төн урталарында шылтыратканы булды — алай кырт кисеп сүз кайтармый иде».

— Йокыңны бүлгән булсам, гафу ит. Кичкә безгә киләсеңне тагын бер тапкыр исеңә төшермәкче генә идем...

Телефон тынып калды, бераздан кыштыр-кыштыр килде. Ерактан тонык кына булып хатын-кыз тавышы ишетелде: «Бармыйбыз да, килмибез дә». Телефон тагын шытырдап алды. Хәмит аны уалырдай итеп учына кыса иде, ахрысы. Ниһаять, ул телгә килде. Тавышы, әле генә бозлы судан чыккан сыман, салкын һәм калтыраулы иде:

— Искәндәр... малай... безнең планнар үзгәреп тора бит әле. Хатын бит... Яңа ел ул гаилә бәйрәме, аны һәркем үз өендә йә туганнарында уткәрергә тиеш, ди. Үзең беләсең, хатын-кызга аңлатып буламыни? Үпкәләмә, малай, без этиләргә барырга булган идек. Нигә эндәшмисең? Иртәгә үзең безгә килеп чык. Барыбер бер ялгызың. Үзеңә генә күңелсез булыр. Сөйләшеп утырырбыз. Хатын син яраткан пәрәмәчне дә пешерер...

Телефон трубкасы Искәндәрнең кулын пешерә башлагандай тоелды. Ул аны шапылдатып куйды да ике кулы белән тәрәзә төбенә килеп таянды. «Әйе! — Тәрәзә пәрдәләрен җәһәт кенә ике якка аерып ачып җибәрде.— Әйе! Димәк, бөҗра, чыннан да, кысыла башлады. Исем-

лектән бер кешене сызып ыргыттык. Дуслар исемлегеннән. Хәмит, Хәмит... Без синең белән биш ел буе бергәләп юкка гына студент шулпасы эчтек микәнни? Биш ел буе бер бүлмәдә яшәп, болай да кыска гына гомернең биш елын уртак кайгылар, уртак шатлыклар белән уздырдык...»

Сөмбелнең бер кичне әйткән сүзләре кылт итеп аның исенә төште... «Әллә син үзеңне берәр кешегә кирәкмен дип уйлыйсыңмы? Чыгарып ташла башыңнан ул беркатлы уйларыңны. Кеше үз-үзен яратса, шул бик җиткән. Әллә син үзеңне берәр кеше үлә-бетә ярата, синең өчен җанын бирергә әзер тора дип беләсеңме? Шулай булмый торсын. Әгәр дә берәрсе сиңа якты йөз күрсәтә икән, белеп тор, димәк, аңа синнән нидер кирәк, яисә, һич югында, аңа шулай яхшы, аның синең белән уйнап аласы, үзенең шатлыгын сиңа күрсәтеп, бер ялтырыйсы килә. Шулай итмәсәң, шатлык шатлык булмый бит, җир астына күмелгән хәзинә була».

Искәндәр, гадәтенчә, аны бүлдермичә генә тыңлап утырды, кайтарып сүз әйтмәде. Шулай итсәң, сүзен тизрәк очлыйсын яхшы белә иде ул.

* * *

Төнге сәгать унберләрдә, көтмәгәндә, Хәмит килеп кергән иде. Йөзе әле генә мунча чыккан төсле алсуланып киткән, бүреге, гадәттәгедән арткарак шуышып, тәбәнәк маңгаен биегәйтеп җибәргән. Түргә узып тормадылар, кухняга кереп утырдылар. Сүзне Хәмит башлады:

— Малай, хәлләр хөрти бит әле минем,— диде ул, еламсырак тавыш белән.— Хөрти, малай, эшләр...

— Нәрсә булды тагын? Милиция-мазарга эләкмәгәнсеңдер бит. Шуннан да зур трагедия юк бүгенге көндә.— Сүзне уенга борырга, Хәмитнең көнаралаш табылып торган борчуларын бүгенге сүз үзәгенә алмаска иде аның исәбе.

— Анысы юк ла... баш ике түгел... Хатын әллә нишләде... Кичә бөтенләй өйгә дә кайтмады. Кайдадыр кунып калган. Кайтуына бугазына ябыштым. Күзгә караган да тик тора. Исерек кеше шикелле елмая. Бер кул белән якасыннан тотып, икенче йодрыкны йомарлап тордым-тордым да үзем дә сизмәстән елап җибәрдем. Суга

алмадым. Балалар куркыр, дидем. Ә ул, берни булмагандай, чишенде дә малай белән кыз арасына кереп ятты. Шуннан соң гына теле ачылды.

— Кайда йөрдең, эттән туган нәрсә?— мин әйтәм.— Балаларың төне буе тәрәзә төбен саклап чыкты.

— Син төннәр буе кайтмыйсың бит әле,— ди.— Син кайда йөрсәң, шунда.

— И-их, шунда күлмәген күтәреп каеш белән ярасы килде! И-их! Соң мин... Минем белән чагыштыра бит үзен. Мин нәрсә, калсам, шул дуслар белән сөйләшеп калам. Әллә кайда эт типкесендә йөрмим бит. Дуслар очрый. «Әйдә, сөйләшеп утырыйк, күрешмәгәнгә бишбылтыр»,— диләр. Шунда аларга: «Хәзер мин йөгереп кенә хатыннан рөхсәт сорап киләм. Җибәрсә, утырырбыз»,— дип әйтә алмыйм бит инде. Үзең күреп торасың, Искәндәр, шулай каткан күңелне җебетеп, җанны бушатып утыра торгач, таң атканнары сизелми дә кала. Бер сөйләшүе бер гомер бит ул андый чакларны. Ә өйдә нишлим мин? Фатирын алып биргән, мебелен тезеп куйган, зарплатасын тиенен тиенгә кайтарып җиткергән. Тагын ни кирәк аларга? Дуслар белән әллә нигә бер рәхәтләнеп күңел бушатып утырырга гына хакым бардыр бит инде минем, ә?

— Үзенә шулай дип әйттеңме соң?

— Әйттем, әйтмәгән кая?

— Нәрсә ди?

— Мин дә нәкъ синең сыман эшлим. Квартираны сиңа гына түгел, семьяга бирделәр, мебельгә минем дә өлешем керде. Телисең икән, претензиясез генә шушында яшә, теләмәсәң, дүрт ягың кыйбла, ди.

— Ә күңел турында, күңел турында аңлатып әйттеңме соң?

— Күңел нәрсә? Күңел ул миндә дә бар, ди.

— Дуслардан башка, кешеләрдән башка, җәмгыятьтән башка яшәп булмаганын, кешенең кешесез тормыш итә алмаганын төшендерергә иде аңа.

— Һәй, малай, бар сүзеңә дә җавабы әзер бит аның. Нәрсә, хатын сиңа дус түгелмени? Хатын сиңа дошманмыни, ди. Сиңа бәгыреннән өзеп балалар тапкан, егерме ел җыеп килгән иң яшерен хисләрен бүләк иткән хатының сиңа ятмыни? Син иң элек аны аңларга тиеш. Бер хатыныңны да аңламагач, аны юата, аның күңелен күрә белмәгәч, нинди дуслар, нинди җәмгыять турында

авыз ачып сөйләшергә мөмкин, ди. Син башта хатының-ның күңелен күр, шуннан соң башкалар турында уйла, ди.

— Ә нигә, моңа кадәр әйбәт кенә тора идегез бит әле. Минем Сөмбел сезне гел мактап сөйли иде. Хәмит тыныш, Хәмит йорт җанлы. Хәмит юк-бар белән баш катырмый. Ә мин ялкау, мин булдыксыз, мин өй турында кайгыртмыйм, мин буш куык, мин, юк нәрсә турында хыялланып, гомеремне уздырам...

...Искәндәр, кызып китеп, тавышын чамасыз күтәрә төште бугай, сөйләнә-сөйләнә, кухняга Сөмбел килеп керде:

— Нәрсә мактанасың, нәрсә әтәчләнәсең тагын?

— Хәмит белән менә бар дөньяны сүгеп утыра идек әле.

— Дөньяны сүкмәгез сез, шул дөньяда яши белмәгән өчен, үзегезне сүгегез. Дөнья нәрсә? Дөньяның гаебе юк. Ул мең ел элек тә шулай булган, мең елдан соң да шулай булачак. Ә менә кеше үзгәрә, кешеләр үзгәрә, халык үзгәрә.

— Кеше белән бергә дөнья да үзгәрә инде...— Хәмит коңгырт күзләрен челт-челт йомып куйды, бумеранг сыман уртадан кырт бөгелеп төшкән мул кашлары турайды.

— О-о! Юк! Пәри башка, җен башка. Бутамагыз әле сез, егетләр. Табигатьнең — үз законы, кешенең — үз законы. Табигатькә кеше кирәк түгел, ә кеше табигатьсез яши алмый. Җәнлек-җанварларны гына карагыз сез: алар табигать законнары буенча яши, алардан табигатькә бер зыян да юк. Ә кеше? Кеше кыра, җимерә, елгаларны туктата, урманнарны кисә, һавага күпме агу очыра... Табигатьнең үз баласы булса, үзен тудырган дөньяга шулай карамас иде ул. Димәк, кеше — табигатьнең үги баласы...

Искәндәр, Сөмбелнең сүзне бөтенләй бүтән якка борып җибәрүенә уңайсызланып, Хәмиткә карап куйды. Хәмит тырпаеп торган тыңлаусыз кара чәчләрен бармаклары белән аралаган да идән ярыгына карап уйга чумган. Искәндәрнең нидер әйтергә җыенганын күреп, Сөмбел озынча йөзен күтәрә төште. Юка иреннәренең сул почмагына мыскыллы елмаю саркып җыелды.

— Космологик теорияләрең белән Хәмитнең башын катырма әле. Менә сезнең аркада, хатын-кыз аркасында, җирнең үги улы булып беттек тә инде... Җәнлекне ник

ата кеше — хатын-кызга затлы тун, энҗе-мәрҗән кирәккә. Урманны нигә кисә кеше — хатын-кызлар берберсен уздырып мебель даулаганга. Сугышлар нигә чыга — хатын-кыз аркасында... Безне менә шушылай начар итеп кем тәрбияли — хатын-кыз тәрбияли...— Боларның барысы өчен дә син гаепле дигән сыман, Искәндәр Сөмбелгә карап алды.— Бүген нинди тузга язмаган мәкалә укыдың тагын? Үзең җир, җир дисең, үзең һаман күктә йөзәсең...

Сөмбел тыела алмыйча көлеп җибәрде. Аның тавышы, йолдыз чыңына охшап, бик тирәннән, ерактан килә иде.

— Мин күккә синең янга менәм бит,— дип башлады ул, көлүеннән тыела алмыйча.— Эштән соң сәгать буе чиратта торып, сетка тутырып азык-төлек төяп кайтам.— Аның тавышы, торган саен кырыслана барып, шырпы кабына ябылган кигәвен быжлавына охшый башлады.— Барын-югын әтмәлләп ашарга әзерлим, табак-савыт юам, өйне җыештырам. Аннары сине эзлим. Син өйдә бар да кебек, юк та кебек. Гәүдәң бар, үзең юк. Аягың — җирдә, башың — күктә. Каяле, мин әйтәм, бу илаһи затны — сөекле иремне күреп төшим әле, дим дә күккә менәм. Ни әйтсәң дә, безнең гаилә члены, кызыбызның атасы бит ул.

— Ярый, Сөмбел, җитте, арттырыбрак җибәрәсең. Хәмитнең үз борчуы үзенә җиткән.

Хәмит ашыкмыйча гына тураеп басты да ишеккә таба атлады.

— Гафу итегез. Мин болай гына, үтеп барышлый гына кергән идем, гаепләп калмагыз.

Искәндәр, киенеп, аны озата чыкты.

* * *

Урамда ишеп-ишеп кар ява. Кар иреннәргә төшеп эри, муеннарга тула, керфекләргә куна.

— Күптән урамга чыгасы калган,— дип, үзалдына гына әйтеп куйды Искәндәр.— Юк белән баш катырып утырабыз шунда. Без күк белән җир турында фәлсәфә сатып утырабыз, ә монда дөньяның асты өскә килгән, күк белән җир тоташкан. Йә, әйтеп кара, кайда җир дә, кайда күк монда хәзер?

— Әй-йе,— дип көрсенде Хәмит. Ул әле һаман үз уйларыннан арына алмый иде, ахрысы.

— Җир, күк, табигать, кеше турында фәлсәфә кору — бөтенләй кирәксез нәрсә. Аңа карап дөнья үзгәрми ул, агай-эне. Аристотельләр, Гегельләр, Платоннар безгә караганда күпкә акыллырак булган. Алар дөньяны аңларга һәм аңлатырга тырышканнар. Ну, аңлаттылар да ди. Шуннан дөнья үзгәрәме? Юк, юк! Кояш мең ел элек тә көнчыгыштан чыккан, хәзер дә шуннан чыга. Агачларның яфрагы элек тә яшел булган, хәзер дә яшел. Элек тә җирдә яхшы-яман булган, хәзер дә бар.

— Коперниклар булмаса, син мескен әле һаман да Кояш Җир тирәли әйләнә дип йөрер идең...

Искәндәр Хәмитне җиңеннән тартып туктатты.

— Әйләнсен! Миңа димәгәе, Кояш гел синең заводың тирәли әйләнсен. Аңа карап дөнья үзгәрми бит. Безнең ничек уйлаганга карап дөнья үзгәрми. Кояшның ничек әйләнү-әйләнмәве мине тамчы да кызыксындырмый. Кеше акылында Кояш — Кояш булып урын алган. Минем өчен аның яктыртуы, җирне җылытуы, көнчыгыштан чыгып көнбатышта баюы кыйммәт.

— Син, Искәндәр, борынгы муллалар шикеллерәк фикер йөртәсең. Табигать законнарын белми торып, бүгенге фән казанышларына ирешеп булмаганын, менә бу багана башындагы лампочка да янмаганын аңлыйсыңдыр инде, шәт. Галәмгә очу, Айга менү турында әйткән дә юк...

— Ә миңа синең галәмеңнең кирәге шулкадәр генә бит, Хәмит. Миңа шушы бәләкәй генә Җир шары да җиткән. Нәрсә калган анда миңа?

Искәндәр озак итеп күккә карап торды.

— Җирнең ресурслары чикләнгән.

— Чикләнсә... Булганы җитәр безгә. Чамалап тотарга кирәк. Ерак юлга чыгам дип, өйдәге бөтен ризыкны биштәргә тутырмыйлар бит инде. Юлга чыксаң, юлда тап. Бер галәм корабына киткән энергия хисабына бер бәләкәй шәһәр ел буе яши алыр иде. Ә без аны һавага очырабыз. Кадерен белмибез. Кая ашыгабыз, белмим. Ашыккан ашка пешкән, ди иде безнең бабай.

— Син, Искәндәр, җир дә җир дисең, ә үзең бер дә җир кешесенә охшамагансың. Менә җир өчен, табигать өчен нәрсә эшләдең син? Берәр агач утырттыңмы?

— Һәр елны Кызыл шимбәдә урам себерәм.

— Синең ул урам себерүең шимбәгә әзерләгән көрәк бәясен дә капламый бит.

— Анысы минем эш түгел. Кушсалар, зуррак эшне дә эшләрбез.

— Ә нигә кушканны көтеп ятарга?

Искәндәр аңа җавап биреп тормады, иелеп кулына кар алды да йомарлап күккә ыргытты. Кар йомарламы аларның каршына ук төшеп чәлпәрәмә килде.

— Күрдеңме? — Ул Хәмиткә күтәрелеп карады.— Җир җибәрми безне, малай. Җирдә туган җан иясе җирдә яшәргә тиеш. Күккә хыял белән генә менәргә кирәк, күңел белән, җан белән генә. Шекспирлар, Бетховеннар кебек. Галәмгә синең гәүдәң түгел, рухың кирәк. Тимер-бетон йортларга караганда, җан җылысы күбрәк кирәк кешеләргә. Кеше барыбер урамда яшәми ул, бер алачык булса да салып керә. Ә менә күңелне тәртипкә китерү кыенрак. Кеше иң элек үз күңеленең ап-ак өен салырга тиеш.

— Телиме-теләмиме, кешенең хыялы ахыр чиктә материаль төс ала, чынга аша бит. Кайчандыр оча торган келәм турында хыялланганнар, менә без хәзер самолетта очабыз. Элек тау артындагы кешене күрү турында язганнар, без хәзер телевизор карыйбыз...

— Бу өлкәдә безнең Сөмбел специалист инде. Аның белән килешер идегез сез. Аныңча, без барыбыз да чит планетадан Җиргә эксперимент ясар өчен китереп ташланган җан ияләре бит. Шуңа күрә җирнең кадерен белмибез, аның байлыкларын, сандыкларга төяп, үз йортыбызга алып китәргә җыенгандай яшибез. Кешеләр арасындагы дошманлык, җир бүлү, канкойгыч сугышлар да шул чит планетадан килүебезнең сәбәбе, дип аңлата ул. Аныңча, без — Җирнең үги баласы.

— Кем ничектер, минем әле җирдә бер явызлык та, бер зыян эш тә кылганым юк. Күпме алсам, шулкадәр бирәм. Димәк, бурычым да юк.

— Җиргәме, хатыныңамы? Хатыныңа зарплата кайтарып бирү белән җиргә әҗәт түләүне бутама син, Хәмит. Җиргә без һәрберебез бурычлы. Менә кеше шул бурычны түләргә өйрәнгәч, җирдә гармония булачак.

— Хатынга күпме бирсәң дә аз...— Хәмит сүзне уенга борырга уйлады, ахрысы.— Ә безгә үзебезгә дә яшәргә кирәк. Син әйтмешли, күңелнең ак өен корырга кирәк. Аннары, күңел белән генә дә яшәп булмый бит әле. Кешеләр үзләре күккә очканда, син хыялыңда гына күккә

ашып утырсаң, ерак китә алмассың. Сөмбел дөрес әйтә ул, без — Җирнең үги баласы. Шуңа күрә аны ташлап, үз туган анабыз янына кайтырга омтылабыз без. Инстинкт буенча омтылабыз без күккә.

— Берәр тапкыр үз әниең янына кайтканың бармы соң?

— Нигә? Монысы ни дигән сүз тагын? Әни үткән ел гына өч ай бездә торып китте бит...

— Ә үзеңнең кайтканың бармы? Әллә кайдагы планетаны туган йортыбыз дип, шунда кан тарта дип шапырынабыз, акыллы сүзләр сөйлибез, ә үзебезнең ындыр артындагы әниләребез янына кайту турында исебезгә дә кереп карамый.

Хәмит бармак калынлыгы булып өелгән карны сыпырып төшерде дә якасын күтәреп куйды. Искәндәр, аңа карамыйча гына, сүзен дәвам итте:

— Беләсеңме, Хәмит, соңгы арада бик сәер төшләр күрәм әле мин. Йокыга китүгә, колагыма бик сәер музыка авазы ишетелә башлый. Ул якынайганнан-якыная бара... Карасам, алдымда — фаэтонга җигелгән канатлы ак ат. Үзе күзләрен тутырып миңа карый, карашы шундый ягымлы, шундый таныш. Фаэтонга менеп утырам да һавага күтәрелеп китәм. Очам, очам, әлеге музыка мине һаман озата бара. Бу бит — минем музыка, мин гомерем буе язарга хыялланган музыка. Ул көчәйгәннән-көчәя бара, мин, фаэтонга басып, барабан таяклары белән әле бер йолдызга, әле икенчесенә сугам, йолдызлардан музыка яңгырап түгел, агылып чыга. Мин сабый бала кебек бар галәмне яңгыратып көләм... Минем тагын да югарырак менәсем, яңа йолдызларга кагыласым, тагын да серлерәк музыка авазлары ишетәсем килә. Канатлы атны куаларга теләп, бар көчемә аңа сыдырам. Ак атның җилкәсендә кып-кызыл камчы эзе сызылып ала, менә ул эздән кан тамчылары чәчрәп чыга, канатлы ак ат әкренәкрен генә алсу төскә керә, минем күзләрне кызыл элпә каплап ала. Музыка тына, һәм мин бар көчемә кычкырып җибәрәм. Уянып китсәм, бүлмә тып-тын, тәрәзә пәрдәләре генә, иртәнге кояш нурларыннан алсу төскә кереп, шомлы төшне искә төшереп тора. Ул канатлы ат турында да озак уйладым мин. Әле беркөнне альбом актарып утырганда, әнкәйнең күзләрен күреп шаккаттым. Нәкъ төштәге күзләр. Нәрсәгә юрарга икән бу төшне?

— Сөмбелгә сөйләгәнең бармы соң?

— Аңа сөйләдең ни дә сөйләмәдең ни. Аннары сирәк күрешәбез бит без. Сөйләшергә вакыт та юк. Ул көндез эштә, ә мин — кич... Минем хыялый дөньяма бик үк керәсе дә килми бугай аның. Мине бөтенләй буш куыкка саный кебек ул. Кайчан бер җиргә төшәрсең инде син, дип көрсенә дә тагын үз дөньясына кереп чума.

— Соң, үзе дә чит планеталар, оча торган тәлинкәләр белән җенләнә түгелме соң?

— Соңгы арада бөтен укыганы шул турыда. Синең янга күккә менәсем килә, шуңа укыйм, ди. Үзең ишетеп тордың бит.

— Җирдә күрешә алмасагыз, күктә бер очрашып сөйләшер, аңлашыр идегез.

— Аның оча торган тәлинкәсе минем хыялый ак йортны күрми, минем хыял аның тәлинкәсенә керә алмый, ахрысы. Йөрибез шулай тегендә-монда очып. Ә гомер уза, заяга уза.

— Менә кайтып та җиттек,— диде Хәмит.

Искәндәр, сүзеннән бүленеп, капыл туктап калды.

Кар туктаган. Күк йөзе күтәрелеп, биегәеп киткән. Соры болытлар фонында җир илаһи бер төскә кереп калган. Әйтерсең җир белән күкнең урынын алмаштырып куйганнар. Күк шундый да гадәти, ә җир — саф, җир ак экияткә төренгән, җиргә аяк белән басарга түгел, кул белән кагылырга да кыймассың.

Искәндәр, шушы матурлыкны гомерендә беренче тапкыр күргәндәй, сак кына басып подъездга керде. Җиңен кайтарып, сәгатенә күз салды.

— Кара син, икенче киткән бит, малай. Тагын эләгә инде сиңа хатыныңнан. Кереп аңлатыйммы? Икәү булгач, бәлки, сүз әйтмәс.

— Кирәк түгел. Күп аңлаштык инде аның белән. Мин сиңа аһ-зарымны сөйләрмен, дип килгән идем, үзегезнең исәбегез үзегездән артып ашкан икән. Бер уйлаганда, минем хәл җиңелрәк тә әле. Мин — җир кешесе. Хатын да миннән ерак китмәгән. Җирдәге хәлләрне ничек тә ерып чыгарга тырышырбыз. Ә менә сезнең хәлләр катлаулырак. Сез икегез дә — күктә. Күктәгеләргә аңлашу авыррак. Аллалар сөйләшми бит, ым кагып кына аңлаша. И-их, сезне! Бер-берегезгә юл куярга кирәк иде азрак. Ярый, сезгә акыл җыярга дип барып, үзем акыл өйрәтә башладым бугай. Әле үзегездә кунып калмакчы да булган идем. Хатынга үч итеп.

— Хатының да, синә үч итеп, берәр иптәш кызы янында кунып кайткандыр әле. Йөрисез шунда качышлы уйнап, кеше башы катырып.— Искәндәрнең чынчынлап ачуы чыга башлаган иде. Ул подъезд ишеген шапылдатып япты.— Керсәң кер, кермәсәң, әйдә безгә!..

— Сезнең йолдызлы өйдә урын булмас миңа. Үз өемдә, ни әйтсәң дә, җылырак икән. Хуш, тәмле йокы!

— Сәлам әйт. Вакыт бик соң. Тавыш-фәлән чыгара күрмә тагын.

— Әбиеңне өйрәт.

Хәмит авыз тутырып елмайды да, кырт борылып, баскычтан менеп китте.

* * *

Искәндәр, сәгать суккан тавышка сискәнеп, башын чайкап куйды. Иртән-иртүк әллә нинди авыр уйлар килә әле бүген. Вакыт та гадәттәгедән акрынрак уза. Хәзер нишләргә инде? Ул бүлмәгә күз йөртеп чыкты да бер баштан икенче башка арлы-бирле йөренергә тотынды. Юл уңайлый гына урын-җирне җыеп куйды, урындыкларны стена кырыена тезеп чыкты, шифоньер астында күзенә нидер чалынган иде, тезләнде дә, кулы белән үрелеп, шуны тартып чыгарды. Кызына былтыр алып кайткан сары толымлы курчак икән. Бер кулы юк. Курчакны алгаартка аударып карады, ыгы-ыгы килеп елый, тик күзләре генә элеккечә йомылмый, гел ачык тора. Ул, курчакны кая куярга белмичә, бермәл уйланып торды, тәрәзә төбенә утырткан иде, авып төште, өстәлгә дә, урындыкка да, шифоньер башына да куеп карады, ләкин бер кулсыз курчак кызы кайда да ятышмый сыман иде. Йомылмый торган зәңгәр күзләрен тутырган да гел аңа карап тора. Аптырагач, курчакны шифоньер тартмасына салды да өстенә чүпрәк каплап куйды.

Инде нишләргә? Берничә мәртәбә телефон янына да килеп карады. Трубкага тотынырга кыймады. Хәмит белән сөйләшкәннән соң, телефон аппараты кызыл тәнле салкын бака төсле тоела башлады аңа. Трубканы алсаң, бак-бак дип кычкырыр сыман. Пианиноның буявы куба башлаган капкачын күтәреп, озак кына аклы-каралы клавишларга карап торды. Бүлмә эче шулкадәр тын иде, шул

тынлыкны бозып, көй уйнарга җөрьәт итмәде. Йә күршеләр кереп җитәр дип уйлады. Моңа кадәр болай ук кыюсыз түгел иде бит ул. Кызы иртүк пианино «дыңгырдата» башлауга, күршеләре йөгереп керсә дә, сүзне уенга борып кына җибәрә иде. Шушы микәнни инде аның ун ел буе көрәшеп алган җан тынычлыгы, шушы микәнни аның күңел хөрлеге, уй бөтенлеге, шушы микәнни аның иҗат иреге?! Алар киткәнгә иртәгә бер ай тула, шул арада нәрсә кырды ул? Әйе, сырты сызлый башлаганчы урында ауный, теләгән вакытта тора, теләгән вакытта ашый, кая теләсә — шунда бара. Ләкин болар гына аз бит. Аның тормышында нидер тамырдан үзгәрергә, ул бөтенләй яңача яши башларга тиеш иде бит. Кайда ул үзгәреш? Элек аның бар уңышсызлыкларына ул, бары ул гына гаепле кебек тоела иде. Костюмы үтүкләнмәгән булса да, эштә кәефен кырсалар да — нишләсә дә — ул гаепле. Музыка яза алмыйча газаплануына да бары ул, бары тик ул гына гаепле, ул гына сәбәпче иде.

Искәндәр, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кабаланып пианино янына килде дә клавишларга ачу белән суга-суга уйный башлады. Куәтле аккордлардан бүлмә сискәнеп уянгандай булды, стеналар калтыранып куйды. Ул музыка язачак! Аңа үч итеп, бөтен дөньяга үч итеп язачак! Ул ансыз яши ала, ә музыкадан башка яши алмый, ул бары тик музыка өчен генә яши. Хәзер аның үз иреге булачак. Аннан хәзер «ресторан даһие» дип көлмәячәкләр. Аның хәзер иң якын дуслардан гына торган даирәсе булачак. Ул, кич белән ресторанга барып, берничә сәгать кенә уйнап кайтачак та көннәр буе өйдә бикләнеп музыка язачак. Заяга узган ун ел вакыты турында уйлыйуйлый шашып язачак. Аннары язганнарын тыңларга дусларын чакырачак. Җитте, җитте, ресторан сандугачы булып йөрү җитте. Ул үзенең кем икәнен күрсәтергә тиеш. Юкка гына пединститутның музыка факультетын тәмамламады бит. Югары белемле музыкантның ресторанга нигә керәге бар? Ресторан белән араны өзәргә! Мәктәптә укытуын укыта алмас. Дүрт мәктәптән китәргә туры килде инде, директорлар белән килешә алмады. Аның музыка иҗат итәсе килә, балаларга да музыканың ничек дөньяга килүе, иҗат газаплары турында сөйлисе килә. Ә мәктәпкә программа кирәк. Аптырагач, ресторанга барып керде. Мәктәптә аның көйләрен тыңлаган кеше дә юк иде. Григка, Равельга иярәсең, шулар йогынтысыннан

чыга алмыйсың, дип теңкәсенә тиделәр. Монда рәхәт. Монда сүз дә әйтмиләр, кемгәдер иярүдә дә гаепләмиләр. Уйна да уйна гына. Бииләр, җырлыйлар, кул чабалар. Монда Григ та, Равель да, «Бони М» да, «АББА» да, Искәндәр дә бар. Барысына да урын җитә, барысын да тыңлыйлар, барысына да бииләр — уйна да уйна гына. Искәндәргә бу тигезлек яшерен бер эчке ләззәт бирә, үз музыкасының бөтен дөньяга танылган композиторлар әсәре белән янәшә яңгыравы, ресторан халкының аны шул бөекләр белән тиң күрүе күңелендә татлы ышаныч уята иде.

Пианинодагы музыка авазына телефон шылтыравы кушылды. Ул, теләмичә генә куптарылып, трубканы алды.

— Әл-лү... Кем анда?

— Интизар бу, Интизар абыең.

— Абый сиңа тагын...

— Нәрсә, кәефең юкмы әллә? Кая, мин әйтәм, таң сандугачы чыгып киткәнче шылтыратып алыйм әле, дим. Ни эш кырып ята идең?

— Болай гына, буш күңелне музыка белән тутырып утыра идем...

— Синең эшләр хутта хәзер. Хөррият! Без генә монда бала-чага чүпрәге арасында әвәрә киләбез. Әле хатын белән чүт әйткәләшеп китмәдек. Салатка бәрәңге әрче, ди. Кичә кич буе кишер туратты, дөге чүпләтте, бүген тагын — бәрәңге...

Искәндәрнең кинәт кенә, кухня өстәле артына утырып, кишер кырасы килеп китте. Йөзенә, кетер-кетер кишер кимергәндәге сыман, рәхәт бер ваемсызлык төсмере чыкты. Ул арада телефондагы тавыш кырысланды:

— Әллә берәрсе бармы анда?

— Юк ла, Робинзон кебек япа-ялгызым... Кая әзерләнәсез ул кадәр? Кишерне әйтәм, күп турыйсыз. Туй булмыйдыр лабаса?

— Туй дип, безнең туган-тумача Чыңгыз хан чирүе кебек бит. Җыелып килсәләр, мирең белән корытырлар...

Искәндәрнең трубкалы кулы салынып төште, болай да базык гәүдәсе тагын да бөкрәебрәк, бәләкәйләнебрәк киткәндәй булды, диңгез төсендәге күзләре сүрәнләнә төште, соргылт кашлары бер-берсенә якынаеп кушыла язды. Трубкадан Интизарның туктамыйча сөйләгәне ишетелә. Искәндәр аскы иренен тешләп бераз торды да телефонга эндәште:

— Безгә килмәскә булдыгызмыни?

— Нәрсә? Ничек сезгә? Сөмбел китте түгелме соң?

— Октябрь бәйрәмендә үк килешкән идек бит... Яңа елны быел бездә каршы алабыз, дип.

— Соң, туган, килешүче якларның сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрүе сәбәпле, килешү шартларын үтәү дә һәр якның үз ирегендә кала. Чынлап әйтим, сиңа, ялгыз кешегә, ничек итеп семья белән барып керәсең инде? Теге чакта, сөйләшкән чакта, Сөмбел дә бар иде бит.

— Ә мин?..

— Син — минем дус. Ләкин, дус дип, семьяны ташлап китә алмыйм бит инде.

— Нигә ташлап китәргә? Парлап чакырдык... чакырдым... бит мин сезне.

— Булмый инде, Искәндәр, ачуланма.

— Һич югында, берәр генә сәгать утырырсыз да китәрсез.

— Булмас инде, булмас, гаеп итмә. Елга бер килгән олы бәйрәмне өйдә үткәрик инде. Ә син миңа үпкәләмә, аңла. Кешеләрне аңламасаң, ничек музыка язарсың син... Ярый, хуш иттек.

Интизарның тавышы өзелүгә, телефоннан, колакны үртәп, өзек-өзек авазлар ишетелә башлады: «Көт-көт, кит-кит, көт-көт, кит-кит»,— дип кабатлый сыман иде телефон.

«Монысы читләп-сипләп тормады, кибетче малае икәне әллә каян күренеп тора, счет төймәсе тарткан кебек, сүзләрне чалт-чолт кына тарткалап куйды да — вәссәлам! — дип уйлады Искәндәр.— Димәк, бүгенге базарда минем бәя шактый төшкән икән. Ярый, бераз гына вакыт бирегез, кемнең күпме торганын күрсәтермен әле мин сезгә...»

Ул, шифоньерны ачып, үтүкләнгән күлмәк эзләргә тотынды. Актарына торгач, күлмәкләр арасыннан сары чәчле курчак кызы килеп чыкты. Зәңгәр күзләрен чекерәйткән дә туп-туры аңа карап тик ята. Искәндәр нигәдер бу карашны күтәрә алмады, күзләрен читкә борды. Курчак өстенә чүпрәк каплады да, күлмәк якасын төймәли-төймәли, көзге каршына килеп басты. Картаелган. Борын яфраклары яныннан ирен читләренә сызылып киткән ике сызык тагын да тирәнәя төшкән, элек алсуланып торган иреннәргә дә тутык кунган сыман, чигә чәчләренә тагын берничә ак төк өстәлгән, болай да биек маңгае башның яртысын диярлек яулап ала язган. Картаела...

Өскә мул якалы кышкы пальто киеп, башны бүрек белән каплагач, гомер-рәссам утыз биш ел буе тырыша-тырыша ясаган рәсем-сурәтләр юкка чыккандай булды. Бары тик йөзендәге ике тирән буразна гына, мине беркая да яшерә алмассың дигәндәй, астыртын бер көлү белән көлә.

* * *

Почта әрҗәсе шыгрым тулы иде. Гәзитләрне карап тормады, хатларны учлап кесәгә тыкты да иң элек открыткаларны укырга булды. Кинәт кенә аңа рәхәт булып китте. Күңел түрендә посып яткан, инде онытылып килгән горурлык хисе баш калкытып куйды. «Әле дөньяда мин дә бар, мин әле кемгәдер кирәк, минем турыда уйлыйлар, кайгырталар»,— дия иде кебек ул хис.

Энисе бәйрәм белән котлаган. Открыткаңны алдым, онытмавың өчен рәхмәт, дигән. Ерак җир түгел бит, бәйрәм арасында ник бер әйләнеп китмисез, дигән. Иң аска, хәрефләрне балаларча бөтерә-бөтерә, тигез юллар белән бер куплет шигырь язып куйган:

Кайтсаң иде кеше улы кебек,
Япсаң иде лапас түбәсен.
Өйләндең дә, көйләндең дә, ахры,
Минем һаман килә күрәсем.

«Их, энкәй, энкәй, нигә шулкадәр беркатлы син,— дип уйлады Искәндәр.— Лапас кайгыларымыни соң минем башта? Акчасын җибәрермен, менә дигән итеп ябып куярлар. Әйе, кайтып, эни кешенең күңелен күрергә кирәк, бик кирәк анысы. Ә вакытны каян алыйм? Һәр көн эштә. Бәйрәмдә... дус-иш белән... җыелып утырасың.— Искәндәр авыр итеп көрсенде. Энисенең йөзен күрергә теләгәндәй, күз карашы белән буш стеналар буйлап йөгереп узды һәм өендәге сырлап-бизәкләп эшләнгән борынгы сәгатьне уйлап тагын онытылды. Шушы борынгы сәгать аны үткәннәр белән: үзенең нәсел-нәсәбе, туганнары, туган җире, буыннан буынга килгән гореф-гадәтләре, алай гына да түгел, бөтен дөнья белән тоташтырып торучы бердәнбер тылсым булып тоелды. Борынгы сәгать вакытны гына күрсәтми, ә кешеләрнең кайгы-шатлыгын, халыклар һәм илләр язмышын, тарих агышын

күрсәтә, шулар хисабын да алып бара иде. Шулчак Искәндәрнең кулындагы сәгать каешы авырттырып беләзеген кыса башлады. Сәгатен салып, аңа бераз карап торды да колагына якын китерде. Ул текелди, ул бары тик аның вакытын гына саный иде. Әйтерсең Искәндәрнең алдына: «Менә синең бөтен гомерең, аның белән теләсә нишли аласың»,— дип, бер өем алтынсу бөртек куйганнар. Ә ул бүгенге көнгә кадәр шул бөртекләрнең әле берсен дә авыз итеп карамаган, тик шулай да көшел шактый кимегән. Алтын бөртекләрне, тек-тек итеп, көне-төне бер нәни генә карак кошчык — аның сәгате чүпли дә чүпли, чүпли дә чүпли...

— Бәйрәм, дуслар...— дип сузып-сузып кабатлады ул.— Шунсыз булмый, алар белән гомер итәсе, яшисе бар бит әле миңа. Арбадан бер төшеп калсаң, әйдә утыр, дип, кулыңнан тартып менгерүче юк монда. Авыл түгел бу. Егылганны торгызучы, абынганны юатучы юк. Их, әнкәй, әнкәй! Әйе, хәлеңне аңлыйм. Бер ялгызыңа рәхәт түгеллеген аңлыйм. Чакырдым бит, монда яшәргә кил, дидем, риза булмадың, ата-баба нигезен ташлап китә алмыйм, дидең. Ә мин анда, ике-өч көнгә кайтып, нишли алам инде? Синең тәмле-томлыңны ашап, йөрәгеңдәге онытылып торган яраңа тоз салып кына китәм. Бер уйласаң, күрешмичә тору яхшырактыр да әле. Ни әйтсәң дә, син анда үз нигезеңдә: күрше-күлән, туган-тумача бар. Ә минем монда кемем бар? Авыр чакта кемгә барып башымны салыйм мин? Шушы диңгез хәтле олы шәһәрдә бер йомычка шикелле бәргәләнеп йөрисең... Берәүнең абыйсы министр, икенчесенең туганы профессор, өченчесе этиәнисе белән яши — тумыштан шәһәр егете. Ә мин бу шәһәрдә үги бала кебек.— Искәндәрнең күз алдыннан яшен тизлеге белән таныш елмаю чагылып узды. Сөмбелнең бераз мыскыл катыш кинаяле елмаюы иде бу.— Менә бүгенге дәрәҗәгә җитәр өчен генә дә күпме көч түгәргә туры килде миңа. Авылдан иске чемодан күтәреп килеп төшкән малай бит мин. Шәһәргә килгән беренче көнемне әле бүгенгедәй хәтерлим: урам уртасында калдым да, кая барырга белми, тик басып торам. Кузгалсам, як-якка агылучы машиналар изеп-сытып узар кебек. Ярты сәгатьләп торганмындыр, ниһаять, бер милиционер, җитәкләп, тротуарга чыгарып куйды. Машиналар бер хәл, аларына тиз ияләштем, тик менә кешеләргә ияләшү генә авырга туры килде. Чөнки минем беркемем дә, бернәр-

сәм дә юк иде бит, әнкәй. Минем һәр адымым, һәр уңышым крепость яулап алуга тиң иде. Институтка керү, мең бәла белән тулай торактан урын алу, имтиханнар тапшыру, үтүкли торгач, күзгә кебек ялтырый башлаган бердәнбер костюмны киеп кичәләргә йөрү, шунда Сөмбел белән танышу, өйләнү, туй ясау, диплом яклау, эшкә урнашу, фатир алу... Менә шуларны эшләү өчен генә дә күпме көч киткән, күпме җан кыйналган. Ә берәүләр тормышның бу өлешен, бу чорын бөтенләй үтеп тә тормый бит. Алар мин бүген басып торган урыннан, шушы биеклектән старт ала. Ә синең улың, ошбу нәрсәләргә ирешкәнче, ярты картайды.

Сөмбелне дә гаепләмим мин. Аның — үз фәлсәфәсе, минем — үземнеке. Бары шул гына. Ул — шәһәр кызы. Ул дөньяга аек акыл, якты күз белән карый. Институт тәмамлагансың икән, бик яхшы, аны азмы-күпме акылы булган һәркем тәмамларга тиеш, ди. Ә миңа институт тәмамлау илаһи бер нәрсә булып күренә иде. Дөрес, хәзер алай ук түгел инде. Ләкин барыбер аның битараф горурлыгына җитү өчен миңа күп кирәк әле. Бала туу да, фатир алу да аның өчен гадәти бер нәрсә. Чөнки ул — бөтен кеше дә эшли торган һәм эшләргә тиешле эшләр. Ә миннән һаман авыл чыгып бетмәгән, бала — минем өчен шәҗәрә агачының бер ботагы, нәсел дәвамы, Бикмурзиннар нәселен дәвам итүче, киләчәккә алып баручы. Ә фатир алу — йорт салып керүгә бәрабәр. Үзең беләсең, авылда йорт салу — егет кеше өчен иң зур, иң мәртәбәле эш. Егете нинди булса, йорты да шундый була. Сине яшәгән йортыңа карап бәялиләр. Ә монда нәрсә?.. Мең газаплар белән фатирга ирешеп, кош тоткандай, ордер күтәреп кайткач та исе китмәде Сөмбелнең. «Кешеләр, әнә, өчәрдүртәр бүлмәлене дә алалар, исләре дә китми»,— дип кенә куйды. Менә шул көнне, беренче тапкыр аптырап, сәерсенеп, озак карап тордым мин аңа. Инде фани дөнья мәшәкатьләреннән бераз котылдым, хәзер үз уйларым, үз хыялларым белән иркендә яшәрмен, эшли башлаган эшләремне төгәлләрмен, рәхәтләнеп иҗат итәрмен, күңелдә талпынып яткан көйләрне язармын, дип кенә йөргәндә, канатларым янә салынып төште. Кайгыны ничек тә эчкә йотарга, авыздагы канны төкермичә түзәргә була. Ә менә синең сөенечең белән сөенүче, синең уңышларыңны күреп куанучы кешең булмавы бик авыр, гаҗәп авыр, әнкәй...

Хәзер мин дә нәкъ синең кебек ялгыз. Кайчагында, әллә авылга кайтып, клуб мөдире булып эшкә керимме дип тә уйлап куям. Авылдашлар аңламас, институтларда укып йөреп тә бернәрсә майтара алмады, дип әйтер кебек. Авыл халкы үзенә кирәк чагында бик зәһәр телле дә бит ул. Аннары минем үз хыялларым бар бит, әнкәй. Гомеремнең мәгънәсе, бөтен максатым шул хыялга бәйле. Мин бу шәһәргә өйләнер-көйләнер өчен генә килмәдем. Мин музыка язарга тиеш. Авылның беренче баянчысы гына булып каласым килми минем. Нигә сиңа сөйлим әле боларны? Үз кайгың үзеңә җиткәнне дә белләм югыйсә, бүтән сөйләр кешем булмаганга сөйлим. Шулай булмаса, борчып торыр идеммени? Аңласаң, мине бары син генә аңлыйсың. Сөмбел аңламады. Аңларга да теләмәде. Ул минем төннәр буе нота кәгазьләре белән утыруымнан, яңа көй яздым, дип, төн урталарында аны уятып, кеше ишетмәсен өчен, акрын гына пианинода уйнауларымнан көлде генә. «Ташла, җүләр, маташма юк белән. Бетховеннар, Чайковскийлар, Сәйдәшевләрдән соң нәрсәдер язарга, иҗат итәргә маташу — мәгънәсез эш. Әнә, берәр музыка мәктәбенә урнаш та балалар укыт. Җитәкчеләр белән телгә килмәсәң, юк-бар белән балаларның башын катырмасаң, ярыйсы гына укытучы чыгачак синнән. Үзеңә дә, кешегә дә файдаң тияр. Семьяң да тыныч яшәр. Күңелең утырса, бәлки, безне дә күрә башларсың. Юкса хәләл хатыныңны да айга берничә мәртәбә генә күрәсең бит син. Кызыңның ничәнче класста укыганын да чамалап, яшен санап кына беләсең. Балага әти кирәк, хатынга ир кирәк, шуны аңлыйсыңмы син? Хыялый Камыр батыр түгел, авыр чакта таянырлык, эч серемне уртаклашырлык чын ир кирәк миңа...»

Шулай, әнкәй, синең анда ялгыз башыңа — ялгыз кайгы. Бүгенге көнең ул кадәр куанырлык булмаса да, искә төшереп юанырлык үткәнең бар әле синең. Карт кешеләргә шунысы җиңел: киләчәк турында уйлап, артык баш катырмый алар... Ә минем нәрсә? Сабантуй алдыннан икеөч атна ял биреп, ат чабышына алып чыккан яшь алаша кебек, нәселле юртаклар артыннан калмыйм, дип, тыным буылганчы чаптым-чаптым да хәлдән таеп туктап калдым. Миңа хәзер ял кирәк, миңа башымнан сыйпап сөюче, җылы сүз әйтеп юатучы кирәк. Кайда ул кеше? Сөмбел дә китте. Ул барда бөтен уңышсызлыкларымны аңа сылтый, бар кайгы-хәсрәтемнең сәбәбен аннан күрә идем.

Аның китүенә бер ай вакыт узды, дөньям үзгәрмәде, күңелем баемады. Киресенчә, бушап кына калды. Хәтерлисеңме, син миңа бер әкият сөйләгән идең?.. Бер патша, дөнья тыныч вакытта да тик тормасыннар дип, сугыш атларын тегермән әйләндерергә куя. Атлар, бер-бер артлы тезелешеп, айлар-еллар буе түгәрәк буйлап аркан тарталар. Шулай берзаман сугыш башланган хәбәр килә. Сугышчылар атларга менеп атланалар да дошманга каршы ташланмак булалар. Ләкин, ни гаҗәп, атлар алга чапмый, түгәрәк буйлап тик әйләнеп йөри икән. Билгеле, дошман боларны күз ачып йомганчы кырып кына салган инде...

Менә мин дә, әнкәй, үземне шундыйрак хәлдә итеп сизәм. Гомер буе өй — кибет — эш, өй — кибет — эш арасында йөгереп йөреп, шул тегермән атына охшап беткәнмен сыман. Әле Сөмбел киткәч тә шул түгәрәктән чыга алганым юк. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә өйгә кайтам, эшкә йөрим, кибеткә барам...»

* * *

Искәндәр, милиция сыбызгысы чырылдавына сискәнеп, уянып киткәндәй булды. Караса, бер кулына открытка тоткан килеш, урам уртасында басып тора. Тирә-яктан, яңа сөреп ташлаган кара җир өстендәге кортлар сыман, төрле төстәге машиналар чаба. Ничек машина астына килеп кермәгән ул? Болай йөрсәң, коймак ясап куюлары да бар. Милиционер: «Бәйрәм көн булмаса, штраф чәпи идем, ярый, бу юлга калып торсын, миннән булсын яхшылык»,— дигәндәй елмаеп, бармак янады. Искәндәр дә аңа каршы сүрән генә елмайды.

Вак-төякләр белән сумканы шыплап тутырып, ике шешә азәрбайҗан коньягы да алгач, тагын нәрсә кирәк икән дип, кибет киштәләренә күз йөгертеп чыкты. «Ә-ә, шампанский! Шампанскийсыз Яңа ел Яңа ел була димени?!» Үз-үзенә яңалык ачкандай, ул ашыга-кабалана касса янына килде.

— Ике шешә шампанский сугып бирсәгезче, чибәрем.

— Беренчедән, мин сезнең чибәрегез түгел, икенчедән, шампанскийны әчетеп өлгермәдем. Яңа елның Яңа елына, бәлки, әзер булыр, килерсез.

Кибетче кыз, бик тә үткен сүз әйткән шикелле, калын

иреннәрен чәй тәлинкәсе хәтле җәеп елмайды да, алтын тешләрен балкыта-балкыта, бөтен гәүдәсе белән дерелдәп, тиз генә, ашыгыч кына көлеп алды. Озаклап көләргә вакыты юк, чөнки чиратта бүтән кешеләр көтә иде.

— Әнә, алма суы ал.

— Бәйрәм бит, затлырак әйбер кирәк иде.

— Кешедән артык җирең юктыр. Әнә, бар халык шуны эчә, өзелеп төшкән җирләре юк. Әйдә, әйдә, копченый колбаса шикелле серәеп торма, юлыңда бул, чират көтә.

— Кеше алдына моны куеп булмый бит инде. Алар бик нәзберек халык. Яхшырагын... Бер генә шешә булса да...

— Әллә бүген тудыңмы? — Сатучы, шаяруын онытып, чын-чынлап ачуланырга тотынды.— Юньле кеше бәйрәм хәстәрен ярты ел алдан күреп куя. Киләчәккә карап яшәргә кирәк... Үзең белмәсәң, хатының әйтергә тиеш иде. Дөнья хатын-кыз кулында хәзер.

Искәндәр, дәресен әзерләп килмичә, икеле алган малай кебек, башын аска иеп чыгып китте. Чираттагы кешеләр аңа сәерсенеп карап калдылар. «Инде кибетчеләр дә ничек яшәргә кирәген өйрәтә башлады,— дип мыгырданды ул.— Кая барып кагылма, шунда акыл сата башлыйлар». Ныклап уйласаң, аларда да хаклык бар кебек анысы. Көне җиткәч кенә бәйрәмгә әзерләнә башламыйлар бит инде.

* * *

Сөмбел киткәч, ай буе үз-үзен кая куярга белмичә, ике тәрәзә арасына эләккән чебен сыман, арлы-бирле бәргәләнеп йөрде ул. Эшкә гадәттәгедән алдан килеп, сәгатьләр буе оркестрантларны көтеп утыра, ә алар, киресенчә, соңга калып килә. Керә-керешкә үк чишенеп аталар да, ваемсыз гына кулга инструмент алып, эстрадага чыгып утыралар. Йөзләре чытык, әйтерсең музыка белән кеше күңелен күтәрергә түгел, ә суган әрчергә утырганнар. Тора-бара йөзләре ачыла үзләренең. Башта программа буенча «Ай былбылым»ны уйныйлар. Кайсыберсе, туктап торган арада, якындагы өстәл янына барып, кояшлы Грузия исәнлегенә чәкештереп тә килә.

Шуннан соң башлана «Лезгинка»лар, башлана юмарт табигатьле Кавказ ритмнары. Колагың гына чыдасын. Ба-

рабанчы Альфред соңгы чиккә җитеп шаша, Искәндәрнең пианино авазы тау елгасына килеп кушылган кечкенә чишмә кебек югалып кала. Альфред, аның саен котырынып, эреле-ваклы барабаннарын кыйный, әйтерсең, шулай итеп, гомер буе җыелып килгән бар үч-ачуларын чыгара, шуның белән ләззәтләнә иде. Барабанчы булса да, нигәдер башкаларга караганда саграк күңелле сыман ул. Искәндәр ансамбльдә бары тик аның белән генә уртак тел таба, кайтканда да аның белән янәшә булырга тырыша. Ә ул, Искәндәрнең үзен якын иткәнен сизепме, әллә чын күңелдәнме, программадагы көйләрне уйнап бетергәч, юмартланып киткән кунакларның заказларын да башкаргач, аңа баш кага. «Әйдә, Искәндәр, синең көйне уйныйбыз!» — дигән сүз инде монысы. Альфредны ансамбль егетләре сүзсез аңларга өйрәнгән, аннары Искәндәр боларын уйламый, ул залдагы ярым исерек кунакларны да, рюмкалар чәкешкән, кычкырып-кычкырып сөйләшкән тавышларны да ишетми, аның өчен хәзер галәмәт зур базарга охшаган шәһәр дә, адым саен ачы сүз кыстырып сөйләшә торган дус-ишләр дә, фатир да, Сөмбел дә — берсе-бер юк. Коңгырт чәчләре тузгып як-якка таралган, кашлары, очарга җыенган кош канаты сыман, өскә талпынган, күзләре — чиксез моң һәм дәрт тулы күзләре — кешеләргә түгел, ә эчкә, үзенең эчке илаһи дөньясына төбәлгән кебек. Ул беркемне дә күрми, бернәрсә дә ишетми. Ул гомере буе шушы мизгелне көткән, ул гомере буе шушы мизгел өчен генә яшәгән диярсең.

Көй тәмамлангач, ул башын кисәк кенә артка таба селкеп куя да, беренче тапкыр күргәндәй, залга карый. Башта берара аңышмыйча тора. Ул үзенең ресторанда икәнен оныткан, ул гүя сәхнәдә, меңләгән тамашачылар алдында. Искәндәрнең күз алдыннан бер-бер артлы нигъмәт тулы өстәлләр йөзеп китә, арадан сирәк-мирәк кенә кул чапкан тавышлар ишетелә. Ул ихтыярсыз торып баса да, гаепле кеше сыман, озак итеп баш ия.

Урамга чыккач, Альфред белән озак кына сүзсез атлыйлар. Сүзне гадәттә Альфред башлап җибәрә.

— Туйдым...— була аның беренче сүзе.— Туйдым бу бака туеннан... Туйдым бу кабак җырчысы булып йөрүдән. Китәм. Иртәгә үк китәм!

Искәндәр аны тыңламый, чөнки көн саен кабатланган бу сүзләрнең төн үтүгә истән чыгасын, иртәгә кичке җидедә Альфредның барабан артына чыгып басасын, дүрт

сәгать онытылып торганнан соң, кайтканда тагын шул ук сүзләрне кабатлыйсын яхшы беләә иде ул.

— Китеп кая барасың? Бәлки, монда яхшырактыр да әле. Тикшергән, бәйләнгән кеше юк, тамашачы күңелле халык — нәрсә уйнасаң да ярый.

— Чын тамашачы алдында уйныйсым килә минем, Искәндәр. Гомеремдә бер генә тапкыр булса да. Батам, бетәм бит мин бу сазлыкта. Шушы ресторанга килеп эләкмәгән булсам, күптән консерватория бетергән идем бит. Мин хәзер кем? Сазлык бакасы. Кит син моннан, Искәндәр, яхшы чакта кит.

— Китеп, кая барасың? Үз-үзеңнән качып булмый.

— Син талантлы бит. Менә дигән көйләр язасың. Һич югында, өйдә ят, эшләмә. Музыка яз, иҗат ит. Берзаман таныйлар, аңларлар.

— Дворян нәселеннән түгел шул мин. Бабайдан калган мирас та бик зур түгел — ике иске чабата белән бер кәкре шөшле генә. Эшләми яшәп булмый хәзерге заманда.

— Ә иҗат эш түгелмени?

— Эшен эш тә, аның белән тамак туймый шул.

— Моцартлар, Шубертлар, Глинкалар беркайда да эшләмәгән, шулай да менә дигән итеп яшәгәннәр, иҗат иткәннәр.

— Таптың чагыштырыр нәрсә...

— Дөрес, безнең чорны алар заманы белән чагыштырып булмый, бездә — иҗат иреге, бездә — хөррият.

— Салулама, егет, читкә каерма. Аңлыйм, тел төбеңне бик яхшы аңлыйм. Ботинкаң тар булганга, дөнья тар, дип зарланма, ди торган иде безнең бабай. Башта эш күрсәт, аннан аяк терәп сөйләш, таләп ит. Һәрбер чебешкә каз оясы ясап булмый бит инде. Әй, каз оясының нәрсә икәнен дә аңламыйсыңдыр әле син. Шәһәр малае... Мин шәһәрдә туып үскән булсам, синең шикелле мәми авызланып йөрмәс идем. Үзебезнең авылда булсаммы? Билләһи, дип әйтәм, бу консерваторияләр, театрлар, концерт заллары безнең авылда булса, мин шуларда, ыштан балагы белән инештә маймыч тоткан кебек, үз малай булып үссәм, кем чыгар иде миннән! И-их! Камыры йомшак шәһәр кешеләренең, оеткысы төче. Авылда без кермәгән кыяр түтәле, без тузгытмаган карга оясы, без төшмәгән кар базы юк иде! Менә синең, Альфред, берәр тапкыр шәһәрдәге иң биек агач башына яисә иң биек өй түбәсенә менгәнең бармы? Юк шул, юк! Хәчтерүшләр сез.

— Нигә авылда гына яшәмисең соң? Кайт та мәдәният йорты директоры булып урнаш. Оркестр оештыр, хор оештыр, ансамбль оештыр, үзешчәннәрне күтәр.

— Оештыру сәләте юк миндә. Минем бары тик музыка гына язасым килә. Кешенең үзе теләгән эшне эшләргә хакы бардыр бит...

— Ә нигә язмыйсың соң? Тот та яз, кеше башы катырып йөрмә.

— Ничек дип аңлатырга? Күңел тынычлыгы юк. Эштә, үзең беләсең... Өйдә — хатын-кыз. Аннары, Альфред дус, бу дөньяда мине аңлаган бер генә кеше дә юк. Аңларга теләүче дә күренми.

— Ә синең үзеңнең берәр кешене аңларга теләп караганың бармы соң?

— Белмим...

— Димәк, үтә чыккан эгоист син. Нигә дип бөтен халык сине генә аңларга тиеш әле? Һәркемнең — үз кайгысы, үз борчуы, үз дөньясы... Бәләкәй генә булса да — үз дөньясы.

— Син иҗат кешесе бит. Аңларга тиеш. Нечкә күңелле кеше. Менә хатын мәктәптән укытып кайтты, ди. Алты сәгать укыткан, ничәдер балага бишле, ничәсенәдер дүртле, өчле, икеле куйган. Юк нәрсәне бар итеп, шуларны сораштырып утырыйммы инде аннан? Сорамыйча да шулай икәнен беләм бит мин аның.

— Ялгышасың, Искәндәр, бик нык ялгышасың. Мин дә элегрәк шулай уйлый идем. Хатын минем өчен йорт җәнлеге шикелле генә иде. Кер юа, ашарга пешерә, теләгән чакта башыннан сыйпап куясың, теләмәсәң, җилкәң белән борылып ятасың...

— Урта гасырда яшәгәнсең бугай. Хәзерге хатыннар...

— Бүлдермә әле. Хатыннар кайчан да бер үк хатыннар алар. Матриархат чорында да үзләренең нәфислекләрен саклап кала алганнар. Менә син хатыныңа юри генә бер җылы сүз әйтеп кара әле. Юри генә башыннан сыйпа, юри генә иркәлә, назла.

— Юри генә булдыра алмыйм мин.

— Соң, агач түгелсеңдер лә...

— Ул мине аңламый, минем тормышның, минем хыялымның мәгънәсен аңламый. Минем нәрсәдер иҗат итә алуыма ышанмый.

— Ышанмый икән, ышандыр. Ышандыра алмасаң, син, димәк, иҗат кешесе түгел. Ә ничек итеп залдагы

меңләгән тамашачыны әсир итә, ышандыра алырсың син? Тормыш, яшәү — үзе иҗат ул. Музыка язу гына иҗат түгел... Берәр көеңне уйнап караганың бармы соң аңа?

— Язган берсен уйныйм, ичмасам, ник бер чәч бөртеге кыймылдап карасын!

— Тагын яз, тагын уйна.

— Булмас, ахрысы. Без аның белән аерылышырбыз кебек.

— Юләр син, Искәндәр. Мин дә аерылыштым. Гомерем буе хыялланган хөррияткә ия булдым. Читлектә яшәргә өйрәнгән арысланга ирек зыянлы гына ул. Яши алмый ул иректә, һәлак була. Читлеккә кергәнсең икән, үзеңне шул читлектә ирекле хис итәргә өйрән. Синең фантазияң җитәрлек бит...

— Һе-һе...

— Аерылышсаң — бетәсең, малай. Бетәсең. Буының сыек синең. Үзеңнән дә кеше чыкмый, иҗатың да...

— Ә ул миңа барыбер иҗат кешесе дип карамый.

— Ә син аңа иҗат кешесе дип карыйсыңмы соң?

— Ул бит...

— Ул бит гади укытучы гына, дисеңме? Һәр эш — иҗат ул, Искәндәр. Ә дөнья — базар. Сату-алу, алыш-биреш... Син нинди товар бирсәң, шул ук бәяне кайтаралар. Дөньяның алыш-биреше бик гадел аның. Беркемне дә алдый алмыйсың. Син аңа бер яхшылык кылсаң, ул да сиңа шуның белән җавап бирә, син аңа бер җылы сүз әйтсәң, ул да җылы сүз таба, күңел төбеннән актарып, кырып-себереп булса да таба, бурычлы калмый. Менә шул нәрсәне колагыңа киртләп куй, Искәндәр.

Ул төнне алар таңга кадәр шәһәр урамы буйлап онытылып сөйләшеп йөрделәр. Бу вакытта борчып тормыйм дип, Искәндәр өенә кайтмады, Альфредта йоклап калды.

* * *

Йокыдан уянганда, көндезге өч тулып килә иде. Торып берәр чынаяк кофе эчтеләр дә ул өенә кайтып китте. Кызы бу вакытта мәктәптән кайткан булырга тиеш иде. Гаепле кыяфәт белән, ишекне сак кына ачып, өйгә керде. Коридорда ук ул өйдә ниндидер үзгәреш булганын сизгән иде. Чишенмичә генә түргә узды.

Шифоньер ишеге шар ачык, элгечтә аның берничә күлмәгеннән башка кием-салым күренми, стенадагы икесе бергә төшкән портрет урыны аксылланып калган, түрдәге келәм урыныңдагы обой чәчәкләре, куптарып ташланган таш астындагы сыек яшел үләннәр сыман, яктырып тора. Бүлмә уртасындагы өстәлдә шакмаклы дәфтәр битендә эре-эре хәрефләр ярылып ята. Җинаять өстендә тотылудан курыккан кеше сыман ашыгып язган.

*«Искәндәр!*

*Сау бул! Рәхәт яшә. Без монда һәрчак артык булдык. Бездән башка иркенләп тормыш ит. Бәлки, кайчан да булса акылыңа килерсең әле. Без сиңа беркайчан да начарлык теләмәдек. Синең ордым-бәрдем сүзләреңә, җен алыштырган кеше кебек иләс-миләс йөрүләреңә күп түздек, күрмәмешкә салыштык. Ә син һаман безне гаепләдең, безнең һәр хәрәкәтебез сине чыгырдан чыгара иде. Имеш, без сиңа иҗат итәргә шартлар тудырмыйбыз, сиңа гел комачау гына итәбез. Әйдә, рәхәтләнеп иҗат ит әле бер. Атаклы композитор булгач, концертыңа чакырырга онытма. Иске дус итеп тыңларга, синең уңышларыңа сөенергә килербез. Хуш. Без поездга киттек... Безне эзләмә, безнең өчен борчылма, югалмабыз. Хәер, синең борчылганың да булмады инде. Ярый, хәерлегә булсын...*

*Сөмбел, Ләйсән».*

* * *

Паровоз пошылдаулары чыгарып, бар бүлмәне гөрселдәтеп иске сәгать сугуга, Искәндәрнең күз аллары караңгыланып китте. Ул күзләрен чытырдатып йомды. Паровоз тагын, тагын уһылдады, кузгалырга рөхсәт биреп, ачы итеп сыбызгы чырылдады. Искәндәр, бөтен гәүдәсе белән суырылып, поездга омтылды. Менә гаҗәп: яшел вагоннар урынына рәт-рәт парталар тезелгән, һәр партада — аның Ләйсәненә охшаган балалар, ә иң алда, паровоз урынында, аларның борынгы сәгате. Сөмбел паровоз-сәгать тәрәзәсеннән кул болгады да, поезд тавышсыз гына кузгалып китте. Ул, алга сөрлегеп, чак кына егылмыйча калды...

* * *

Азык-төлекне бушатып, кисеп-турап, өстәлгә тезә башлагач, табынның бик ярлы икәне күренде. Бу табынга кеше чакырырлык түгел иде. Нәрсәдер уйларга, хәстәрен табарга кирәк. Искәндәр, маңгаен җыерып, күзләрен йомып, үзенең таныш-белешләрен хәтердән үткәреп чыкты. Монысы музыка училищесында укыта, тегесе — мәктәптә... Танышлар арасында аңа ярдәм итә алырдай кеше күренми. Туктале, Фиданны кафега склад мөдире булып урнашты, дигәннәр иде. Шуңа барып карасам? Әйе, шунда барырга кирәк, ул борып җибәрмәс.

Кулына сумка тотты да ике-өч баскыч аша сикерәсикерә урамга чыкты. Фидан искә төшүгә үк күңеле үсеп киткәндәй булды аның. Фидан егет кеше, ул институтта укыганда ук арада бөтенесеннән аерылып тора иде. Артыгын сөйләшмәс, кирәкмәгән җиргә тыгылмас, ә үз эшен барыбер эшләр. Дөрес, музыкага бер кәсеп итеп кенә карый иде ул. «Музыка — бәйрәм ул, ә бәйрәм көн саен килми. Көн саен аның кирәге дә юк! Кеше бәйрәм итәргә килми, яшәргә килә!» Музыка турында сүз чыкса, шушы бердәнбер фәлсәфәсен ярып сала да, миннән көлмиләрме икән дигәндәй, мәче елгырлыгы белән, астан гына һәркемне карашы белән сөзеп чыга.

— Сәлам, Искәндәр!

Башын күтәреп караса, каршысында Рүдәл тора. Бүрек колакчынын төшереп куйган, күзлек пыялалары тирләп, йөзенә сукыр кеше кыяфәте кerткән, бит очлары, кершән яккан кызларныкы кебек, уч төбе хәтле генә алсуланып чыккан.

— Кая юл тоту болай?

— Бәйрәм хәстәрен күреп йөрү иде әле... Берни табып булмый.

— Шаяртма. Беләбез сине. Ресторанга барып, бер сызгырсаң, хәзер төяп китерәләр сиңа.

— Мин анда беркемне дә белмим бит. Музыкантларны гына...

— Шаяртма. Эшнең кәттәсенә урнаштың инде. Безнең шикелле тугыздан алтыга тигез була йөз дә егерме тәңкә мәсьәләсен чишеп ятмыйсың.

— Ә мин туксан сум алам...

— Шаяртма! Таммаса да, агуын ага инде анда. «Маэс-

тро! «Лезгинка»ны җибәр әле! Шәмәхә кәгазь — бездән, музыка— сездән!»

Рүдәл, аяк очларына басып, кулларын кош канаты сыман җәеп, бер урында тыпырдап алды.

— Ташла шул кешедән көлүеңне.

— Туры әйткән туганына ярамаган, диләр. Мин бит гаеп итеп әйтмим. Нишлисең, тормышта — һәркемнең үз юлы. Талант булса, мин дә музыка факультетына керер идем. Колагыңа сыер типкән булгач, кая барасың — тарих факультетына. Сез бүгенге белән яшисез, ә без — үткәндә. Теге патша теге патша белән ни өчен сугышкан, бу патшаның күпме байлыгы булган, ыруглык чорында безнең бабаларыбыз нинди ыштан киеп йөргән, урта гасырда сөңге белән сугышканнармы, кылыч беләнме? Без менә шулар белән яшибез. Ә сезнең — көн дә бәйрәм, көн дә туй. Музыка, бис, браво, афәрин! Тормыш түгел, тоташ фейерверк!

Искәндәр теләмичә генә, аның сүзләренең дөреслеген шик астына алу өчен генә тырышып көлгәндәй итте. Тамак төбенә төер тыгылып, буыла-буыла ютәлләргә тотынды. Рүдәл шап-шоп итеп аның җилкәсенә сукты. Ул ничектер кызганмыйча, үч алырга теләгәндәй авырттырып суга иде.

— Дөрес сүзгә җавап юк! Бөтенегез җылы җирләргә урнашып беттегез инде, мин генә калдым бер кырыйда аксак чәүкә сыман. Хәмит — заводта цех башлыгы, Интизар — әтисенең җылы кочагында. Күр дә тор, кибет директоры булып урнашачак ул. Әле генә Фиданны күрдем, юньләп сәлам дә бирми. Нәрсә булган соң, мин әйтәм. Гомер буе бот белән ыштан шикелле яшәгән идек бит. Карасам, егетебез склад мөдире булып урнашкан икән. Кереп чык, дип тә әйтмәде.

«Сине чакырсаң, бәладән башаяк,— дип уйлады Искәндәр.— Юкны бар итеп, бөтен шәһәрне сасытыр идең».

— Ярый, мин ашыгам. Төш җитеп килә инде. Ә минем бернәрсә әзер түгел,— дип кулын сузды Рүдәл.

— Син дә эреләндең, кунакка да чакырмыйсың.

— Соң, үзең дә буйдак түгелме соң хәзер? Әллә Сөмбел кайттымы?

— Кунакларны без инде әллә кайчан, аның белән бергә чакырып куйган идек.

— Хәзер ул юк бит инде. Аның китүен, бәхетле, бәйсез көннәрең башлануын бәйрәм итмәкче буласыңмы?

— Яңа ел барыбер килә бит ул, Сөмбел китте дип, вакыт туктамый.— Искәндәр, җиңен кайтарып, сәгатенә күз ташлады. Секунд теле, тегермән әйләндерүче миңгерәүләнгән ат кебек, түгәрәк буйлап җан-фәрманга чаба иде. Ул Рүдәл каршында сәгатькә карап торуына уңайсызланып көлемсерәде дә сүзен дәвам итте: — Вакыт поезд кебек бит ул, пассажирлар һәрберсе үз станциясендә төшеп кала,— ә ул бара да бара.

— Ә Сөмбел кая китте соң?

— Белмим, поезд белән киткән...

Рүдәлнең күзләре, кысылып, кара сызыкка әйләнде.

— Сөмбел төшеп калды, ә мин алга киттем, димәкче буласыңмы?

— Киресенчә...

— Шаяртма. Ашыкмый тор. Бәлки, ул чыннан да алга киткәндер, ә син төшеп калгансыңдыр.

— Калсам калырмын, синең эшең түгел.

— Рестораның белән ерак китә алмассың, әнә, «Аҗаган» ресторанындагы шайканы да таратканнар. Директорына унбиш ел биргәннәр, музыкантлары да буш калмаган, ди. Кара аны, юкка чәбәләнәсең, егет. Койрыгыңа ут капкач, күрерсең, без дә кирәк булырбыз. Ул бәйрәмдә без түрдә утырырбыз.

Рүдәл бүреген тагы да батырыбрак киде дә кырт борылып китеп барды. Искәндәр шулчак, нидер сизеп, ихтыярсыз бүреген салды. Бүреге өстендә бәләкәй генә ак өем агарып тора. Башына күгәрчен пәп итеп киткән. Аяк астында буталып йөрүче кызыл томшыклы, түгәрәк бүксәле ваемсыз күгәрченнәр бөтен кыяфәте белән Рүдәлгә охшап күренделәр аңа.

Аның башына да әле генә күгәрчен түгел, ә ул пәп итеп киткән сыман тоелды. Һәр җирдә тыгылып, һәр җыелышта иң элек сүз алып, һәркемнән гаеп табып йөргәнгәдерме, Рүдәлне, институтта укыганда, Казый дип йөртәләр иде. Ул бер кешенең дә шатлыгын күтәрә алмый, һәр сөенечкә дегет тамчысы булып тама да төшә. Аның бу гадәтен юрист егетләр инде күптән белгәннәр, шуңа якын китермиләр, ә ул, моны сизеп, күбрәк Искәндәрләр группасы тирәсендә чуала. Көннәр буе кызлар бүлмәсеннән чыкмый утыра. Кызлар аны вак-төяк алырга кибеткә җибәрәләр, йомышка йөртәләр. Ул сеткага буш сөт шешәләре тутыра да, бик зур эш кырган кыяфәт белән, шалтыр-шолтыр коридор буйлап китә. Кызлар аның ар-

тыннан пырхылдап көлеп калалар. Сөмбел генә көлми, ул аны кызгана, аның мәхлуклыгына сабыйларча гаҗәпләнеп карый иде бугай. Искәндәргә кияүгә чыккач та, сүз кузгала-нитә калса, Рүдәлгә тел тидерттерми иде. Искәндәргә кайчакта алар арасында ниндидер уртаклык та бар сыман тоела иде. Андый вакытта ул Сөмбел белән танышуына, аны Рүдәлдән тартып алуына үкенеп тә куя. Бер-берсенә менә дигән пар чыгар иде алардан.

Искәндәр белән Сөмбел өйләнешкәч, Рүдәл бөтенләй күзгә күренмәс булды. Шактый вакыт узгач, аны институт коридорында очратты да таң калды Искәндәр. Ул нигәдәр аны инде кайгыдан суырылып беткәндер, сары йотып йөри-йөри, коры сөяккә калгандыр дип уйлый иде. Ә Рүдәл, киресенчә, тулыланып киткән, бит алмалары йодрыктай бүртеп чыккан, борын яфраклары тырпайган, корсагы, түм-түгәрәк булып, зәңгәрсу пиджагын тартып тора. Койган да куйган урам күгәрчене инде. Тора-бара аның Казый кушаматы да онытылды. Әллә инде төс-кыяфәте, әллә инде очраган бер кешенең башына бәләкәй генә итеп, сиздермичә генә пәп итеп йөргәне өченме, әллә бөтенләй бүтән сәбәп беләндерме, аны Күгәрчен дип атап йөри башладылар. Сөйләшкәндә дә ул, күгәрчен тавышына охшатып, гөр-гөр килеп тора, артык каты куптарылып орылмый, ирененнән беркайчан да елмаю китмәс — суйган да каплаган күгәрчен инде.

Искәндәрнең Рүдәлгә артык исе китми иде, тик менә Сөмбел генә... Алар һәрчак бер-берсен яклыйлар, бер-берсенә сүз әйттермиләр иде. Бу нәрсә Искәндәрнең җанын борчый, ул моңа чыгырыннан чыгардай булып үртәлә.

Әле бүген дә аның авызыннан Сөмбел турында ишеткәч, йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Ул Сөмбелнең киткәненә, аны ташлап киткәненә сөенеп бетә алмый кебек иде. «Әгәр дә ул Сөмбелне эзләп барса?» — дип уйлады Искәндәр кинәт кенә. Искәндәр Сөмбелнең аныкы булуын күтәрә алмаячак. Теләсә кая китсен, теләсә кем белән яшәсен, бары тик аныкы гына булмасын. Бу аның бәгырен изәчәк, горурлыгын аяк астына салып таптаячак. Ун ел элек аның кулыннан тартып ал да: «Мин аңа лаек түгел, ул синеке булырга тиеш»,— дип, кире кайтар, имеш. Юк, болай булмас. Нигә дип аның поезд белән китүен әйттем соң әле? Хәзер ул аның бөтен туган-тумачасын белешәчәк, эт шикелле иснәнеп эзләп

табачак. Аның каршына махсус чыгып торган ул, кая киткәнен белер өчен махсус сөйләштергән.

Ә мин беркатлы... Искәндәр авыр итеп ыңгырашып сулап куйды: «Их, елан, их, Казый!»

* * *

Кафе бөтенләй буш диярлек иде. Почмактагы ике өстәлдә генә кызыл йөзле өчәр-өчәр егет утыра. Кәбестә салаты алганнар да, шуңа карап, тирән уйга калганнар. Җыештыручы түр ишектән кереп китүгә, берсе түш кесәсеннән ялт кына шешә чыгарды да икенче кесәсеннән стакан алып, мөлдерәмә тутырды. Каршыдагы егет аны күз ачып йомганчы каплап та куйды. Шешә иясе стаканны янә тутырды. Анысы да яшен тизлеге белән юкка чыкты. Өченче стаканны хуҗа үзе каплады да, шешәне өстәл аягы янына куеп, торып басты. Йөзләре тагын да алсулана төшкән, тирләп-пешеп чыккан өч егет дәррәү ишеккә таба атладылар. Җыештыручы хатын, шуны гына көтеп торгандай, лаштыр-лоштыр атлап килде дә шешәне җәһәт кенә алъяпкычы итәге астына яшерде. Аны фанер стена артына илтеп куйгач, Искәндәр янына килде.

— Нишләп утырасың монда?! Үзең белән алып килдеңме? Берүзеңә бер ярты эчеп, егылып ятма тагын. Туйган монда исерек ташып.

Искәндәрнең шулчак борып-борып эче авыртырга тотынды, кичәге төш турыннан бирле ашамаганы исенә төште.

— Тамак ялгап алмакчы идем. Берәр нәрсә китермәсләрме? Официантка...

Җыештыручы хатын, буш шешәләр шылтыраган тавыш чыгарып, шаркылдап көлеп җибәрде.

— Каян килгән культурный. Официант кирәк булса, ресторанга бар. Бездә — демократия. Һәркем үзе барып ала, илтеп куя.

Искәндәр, поднос тотып, касса янына килеп басты. Касса артындагы йөзе таушалган сары кәгазьгә охшаган әби — пенсионерка булса кирәк — аңа йокылы-уяулы караш ташлады да хәлсез башы тагын аска бөгелеп төште.

— Аш кирәк иде...

— Әле пешмәгән, төшкә генә әзер була.

— Ит юкмы?

— Котлет кына. Сугыйммы?

— Кирәк түгел. Итле салат юкмы?

— Салат ишедән кәбестә, кишер, чөгендер.

— Авызга алырдай берәр нәрсә бармы соң сездә? — Искәндәр чынлап чыгырдан чыга башлаган иде.

— Булганына шөкер ит. Сугыш вакытында бер телем ипи өчен көннәр буе чират тора идек. Симереп сикерәсез. Хәзерге яшьләр дөнья күргәнмени алар...

Әби сөйли калды, Искәндәр, подносын кулына тоткан килеш, читкәрәк китте. Бу әби кафега шулкадәр ятыша иде, гүя аны озак сайлап, конкурслар үткәреп махсус алганнар.

— Сездә Фидан дигән егет эшлиме? — Искәндәр моны теләр-теләмәс кенә, икеләнеп кенә әйтте. Мондый шыпшыр кафеның склады да, шул складның мөдире булуын да ул берничек күз алдына китерә алмый башлаган иде.

— Юк, белмим, андый кешене белмим. Кыяфәте ниндирәк?

— Тазарак кына, озын буйлы, түгәрәк йөзле, чәчен артка тарап йөри. Боксерга охшаган.

— Кем булып эшли соң ул?

— Склад мөдире...

— Ә-әй, Федяны әйтәсеңме? Күптән шулай диләр аны. Әллә нинди Фиданнарың белән баш катырасың. Эшли, эшли, нишләп эшләмәсен ди. Алтын егет ул безнең...

Кассир әби шул арада балкып китте.

— Ә син аның кеме буласың соң?

— Бергә укыган идек... Дусты... Иптәше...

— Нигә аны баштук шулай димисең? Кадерсез кунак сыман... Әйдәле, алып керим әле янына.

Искәндәр кассир әби артыннан иярде.

Стена кырыена тау-тау өелгән әрҗәләр арасыннан боргалана-боргалана шактый бардылар. Кассир әби әрҗәләр өеме арасындагы сейфка охшаган ак калай тышлы ишекне сак кына, яратып кына шакыды.

— Кем бар анда? — дигән калын тавыш ишетелде эчтән. Искәндәр Фиданның бәрхет тавышын шундук таныды.

— Мин бу, Федя. Сине сорыйлар, дустың, диме шунда...

— Хәзер, безнең бераз эш чыкты әле монда, көтегез.

Искәндәр, шушы буш һәм салкын бинада җылы сүзләр ишетүенә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, бер-

кавымга югалып калды. Ул арада кассир әби аякларын чаж-чож сөйрәп китеп тә барды. Әрҗә таулары арасындагы лабиринтның әле бер почмагыннан, әле икенче чатыннан кемдер килеп чыга да, өскә күтәрелеп карамыйча гына, култык астындагы төенчеген чытырдатып кыскан килеш, аның янынннан үтеп китә. Кеше узган саен, ул тимер ишеккә елыша, ә эчтә нидер пышылдашып алалар да тагы әлеге кыйммәтле бәрхет аваз ишетелә:

— Чак кына көтегез инде, хәзер...

Ниһаять, ишек шалтырап ачылды. Искәндәрнең борын төбеннән генә мәче елгырлыгы белән ике кеше чагылып узды. Ул аларның ирме-хатынмы икәнен дә абайлый алмады, бары тик кулларындагы буаз сумкаларын гына күреп калды.

— О-о-о! Кемне күрәм мин?! Искәндәр галиҗәнабләре түгелме соң бу?

Искәндәр, ни әйтергә дә белмичә, каккан казык кебек бер урында тик басып торды.

— Уз, әйдә, түрдән уз. Мондый кунак киләсен белгән булсам, юлга келәмнәр җәеп куйган булыр идем.

Искәндәрнең боеккан күңеленә шушы мизгелдә ясалма кунакчыллык та хуш килде. Күптәннән җылы сүз ишеткәне булмагангадырмы, аңа монда гаҗәеп рәхәт булып китте. Түшәмгә кадәр өелгән әрҗәләр, капчыклар, почмактагы мичкәләр, баш очындагы шәрә лампочка, кулдан ясалган гади өстәл, артсыз урындык та шулкадәр якын, үз тоелды.

— Минем монда икәнне каян белдең? Ничек таптың?

— Бөтен шәһәр синең турында гына сөйли хәзер. Фидан тегеләй дә, Фидан болай, диләр.

— Анысын арттырасың инде. Шәһәр читендәге бер Алла каргаган урынга урнашкан булдым.— Ул, үзең күрәсең дигәндәй, башы белән әрҗәләргә ымлап күрсәтте.— Литр, килограмм, пачка, әрҗә, мичкә, капчык — шушы инде безнең тормыш. Кая, нишләп сүз белән сыйлыйм әле сине? Һәй, Шамка, башыңны тык әле монда!

Ишектән, күзләрен челт-челт йома-йома, кызгылт-зәңгәр йөзле, искергән борынлы берәү күренде. Ул авыз ачып сүз әйтмәде, кая кушсаң — шунда чабам, дигән күндәм кыяфәт белән тик кенә тора бирде. Фидан ялт итеп ике бармагын өскә күтәрде:

— Ике персонага! Беренче класс!..

Тегесе, була ул дигәнне аңлатып, рәттән тиз-тиз генә

биш-алты мәртәбә күзләрен межелдәтеп куйды да җир астына төшеп киткәндәй юкка чыкты. Фидан, җитди кыяфәт алып, Искәндәргә таба борылды.

— Йә, сөйләп җибәр әле, маэстро, ниләр бар синең дөньяда? Сөмбел киткән дип ишеттек. Бик алай бетеренмә. Табылыр, яхшырагы табылыр, орлыклары Бохарада түгел. Тартылып киткәнсең, дип әйтимме? Аптырама юкка, кеше китә — көшел кала, дип җырлый торган иде безнең бер күрше. Үз көеңне үзең көйлә, үз җаеңа яшә.

Искәндәр Фидан янында сабый бала кебек югалып калды. Ул Фиданның арбадан төшеп кала торган егетләрдән түгел икәнлеген моңа кадәр дә белә, ләкин аның бу кадәр үк үз-үзенә ышаныч, вәкарь белән сөйләгәнен күргәне юк иде.

— Мин кайгырмыйм да. Әле ияләшеп җитеп кенә булмый. Бүлмә дә, күңел дә бушап калган кебек. Нидер җитми. Элек артык сыман иде, хәзер җитми.

— Синдә буш булса, миндә шыгрым тулы. Аз гына кәефең булмадымы, монда кил. Сөйләшербез, күңел бушатырбыз. Телисеңме, кафега музыкант итеп урнаштырам үзеңне.

— Мин эшлим бит инде. Ресторанда. Анда да син урнаштырган идең.

— Монда да эшләрсең. Эчеңне төртеп тишмәс.

— Монда сезнең... бөтенләй кеше йөрми бугай бит. Тамак ялгап алмакчы булган идем. Бер кабым әйбер таба алмадылар. Нәрсә белән сату итәсез соң сез? Ничек тоталар сезне монда?

— Синең баш җитәрлек нәрсә түгел ул. Стаккато методы белән эшлибез без.

— Анысы ничек була тагын?

— Минһаҗев дигән композиторны хәтерлисеңме? Бездә гармонияне укытып йөргән иде. Менә шул композиторның биш симфониясе, өчме-дүртме концерты, әллә ничә балеты бар, диләр. Ә берәрсен ишеткәнең бармы? Шиш, фуга! Ә беләсең килсә, барысы да радиога, телевидениегә, театрларга сатылган, акчасы алынган. Композитор дигән вывеска бармы? Бар. Партитура бармы? — Фидан өстәлдә яткан кәгазь өемен күтәреп, бераз селкеп торды да шапылдатып яңадан өстәлгә ташлады.— Бар! Дебит, кредит һәм дә фуга! Композитор бар, әле ничек кенә бар! Синең белән миңа караганда мең мәртәбә яхшырак яши. Ә музыка? Музыка бар да, юк та. Исәпкә бар, санга юк.

Без дә менә шушы музыкаль метод белән эш итәбез. Безнең монда үз гармониябез бар. Ярый, монысы безнең өлкәгә нәни генә экскурсия булды. Хәзер, хәзер...— Ул, коридордагы аяк тавышларын ишетеп, сүзен бүлде.— Хәзер төп эшкә тотынабыз.

Тимер ишекне аягы белән этеп ачып, бүлмәгә поднос күтәргән кеше килеп керде. Подноска тезелгән шешәләр, азык-төлек, нигъмәт артыннан аның шәлперәйгән иске борыны гына күренеп тора. Ул сүзсез генә подносны өстәлгә куйды да, кулларын чалбар балагына ышкый-ышкый, ишек катына килеп басты.

— Мә, үз өлешеңне! — Фидан шалт итеп бер шешәне ачты да, ярты стакан чамасы салып, аңа сузды. Теге, мескен, бүреген йомарлап учына кысты, күзләре рәттән берничә залп биреп алды, борынына җан кергән сыман булды.

— Сузма!

Фиданның кырыс тавышы аны сискәндереп җибәрде, калтыраган кулындагы стаканы чак кына төшеп китмәде. Ул тешләренә шакылдатып бәрә-бәрә эчеп бетерде дә, стаканны үрелеп әрҗә өстенә куйгач, авызын бүреге белән каплап чыгып китте.

— Менә шушылар белән эшлибез инде.

— Нигә тотасың соң андыйларны? Бу бәндә нинди эш майтара алсын?

— Шул ук музыкаль метод. Ул кеше бар да, юк та монда. Күр, дисәң — күрә, күрмә, дисәң — күрми, ишет, дисәң — ишетә, ишетмә, дисәң — чукракка әйләнә.

— Нинди музыкаль метод булсын? Кешеләрне роботка әйләндереп бетерәсез бит сез монда.

— Ул бит үзе теләп шуңа бара. Кусаң да, китми ул моннан. Аның өенә кереп кара син. Башың әйләнер. Аныкы төсле мебельне төшеңдә дә күрә алмыйсың. Каян таба — бер Алла гына белә. Һәр кибеттә, һәр кафе-ресторанда аның ишләре бар. Алар бер-берсе белән элемтәдә торалар. Теге кибеттә шушы минутта нәрсә бар, теге кафега иртәгә нәрсә китерәчәкләр — барысын да энәсеннән җебенә кадәр белеп тора алар. Шулардан башка эш тә алып барып булмый. Хәзер төшеп каласың.

— Болай яшәгәнче, яшәмәвең мең артык.

— Туктале, тыпырчынма. Менә, әйтик, бүген синең бәйрәм өстәлеңдә ни була? — Фидан аның эчендәге бар уйларын белеп-күреп тора кебек иде. Искәндәр үзен урам уртасында анадан тума ялангач калган кебек хис итте.

Фидан торган саен кыза барды. Аның алдына кара һәм кызыл уылдыклы ике консерв банкасы ачып куйды, калын-калын телемнәр белән кызыл балык кисәргә тотынды. Искәндәр алдына әфлисун, мандарин, лимон өелде. Өстәл уртасына әрмән коньягы белән шампанский шартлап килеп утырды.

— Синең тырнагыңа да тормаган шул роботларның өстәлендә бүген боларның барысы да өелеп торачак. Гаҗәпләнгән булма, монысында түгел,— ул, җирәнеп кенә ишек артына таба карап, йөз җыерды,— монысы калдык-постык җыючы гына аның. Тегеләре Алла кебек: үзләре күренми, эшләгән эшләре буенча гына дөньяда барлыкларына ышанасың. Менә шуннан балык мичкәсе өстенә утырып уйлап кара инде... Син, төннәр буе йокламыйча, алар өчен музыка язасың, аларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү турында уйлыйсың.

— Мин алар өчен язмыйм.

— Кем өчен язасың соң?

— Үзем өчен.

— Хе-хе-хе... Болай булсаң, ерак китә алмассың син, Искәндәр. Теге, мескен, йомран шикелле кул астына эләккән бар нәрсәне өенә ташый, монысы, үз мәнфәгатен кайгыртып, склад мөдире булып урнашкан. Ә миңа нигә үзем өчен язмаска, дисең инде. Мин дә кеше бит! Шулаймы?

— Шулай да булсын ди. Ә мин йомран шикелле үз өемә ташымыйм, үз күңелемдә, үз хәзинәмдә булган белән үземне юатам. Бары шул гына.

— Натураль хуҗалык була инде бу. Артта калгансың син, егет, дөньядан шактый артта калгансың. Безгә хәзер мәми авызлар түгел, тоткан җиреннән өзә торган егетләр кирәк.

— Син бу айсбергың белән бер бик каты барып бәреләсең әле, Фидан.

— Нинди айсберг ул?

— Һич югы, шушы кафең белән. Музыкаль метод түгел бу, айсберг теориясе белән эш итәсез сез монда. Кафеның кеше күрә торган алгы ягында чебен күзенә кырып салырлык та ризык юк, ә аста — айсберг. Җыештыручы өстәл астындагы шешәләрне җыеп көн күрә. Үзең белгәнеңчә, аның кереме көннән-көн арта гына бара — шуның белән аның авызы йомык, ул шуңа канәгать, кассир әби пенсиясе янына тагын ничәдер сум өстәлүенә сөе-

неп бетә алмый, шуңа мәрткә китеп утыра. Пешекчеләр пешереп тормый, товарны шул килеш кенә уңга-сулга җибәрә. Эш бара, план тула, үзең әйтмешли, партитура языла, ә музыка юк.

— Бик тирәнгә керә башладың, алай-болай ОБХССтан түгелдерсең бит? Әйдә, юк белән баш катырганчы, яшь чакларны искә төшереп, күңелне җылытып куйыйк әле бер.

Фидан хрусталь рюмканы яңгыратып чәкештерде дә бер сулыштан йотып куйды. Искәндәр, эчәргәме-эчмәскәме дигәндәй, рюмкага карап калды.

— Әйдә, күрешү хөрмәтенә! Яңа ел бит бүген, бәйрәм!

— Шуңа икеләнеп торам әле. Кунаклар килергә тиеш.

— Һә-әй, кунак килер алдыннан йөз граммны кабыпмы-кабып куярга кирәк тә инде ул.— Фидан профессиональ осталык белән әфлисунны кабыгынан чишендереп куйды. Бу минутта ул теләсә кемне шулай тиз генә чишендереп ташлый алыр кебек иде.— Кунак килгәндә, хуҗаның күңеле хуш, авызы ерык булырга тиеш.

Искәндәр, ни булса, шул булыр, дип, коньякны төбенә кадәр эчеп куйды.

— Менә син безне эт итеп сүктең. Белмичә сүктең. Бүген син төн буе уйнап-җырлап бәйрәм итәчәксең, ә мин дежурда булам. Теләсәм дә, сиңа бара алмыйм. Бүген төнлә безгә вагон килергә тиеш, шунсыз план тулмый. Ул вагонны быелгы елга кертеп калдырырга кирәк. «Вакыт» төшенчәсен без сезгә караганда яхшырак аңлыйбыз, димәк ки, безнең эш сезнекенә караганда фәлсәфирәк, мәгънәлерәк. Иске ел поезды финишка вакытында килеп өлгерәме-юкмы, безнең язмыш шуңа бәйләнгән. Ә син күктә, болытлар өстендә яшисең, ул поездларга төкермисең дә.

— Поезд, поезд,— дип кабатлады Искәндәр.— Мин үзем поезд кебек...

— Әйдә, безнең рестораннар трестына эшкә кер алайса, дим бит.

— Син һаман шаяртасың, Фидан. Ә минем эшләр шаярудан узган.

— Ул хәтле нәрсә булды соң әле сиңа? Кителеп төшкән җирең күренми. Сөмбел киткәч, иҗади фантазиягә куәт керә башласа гына...

— Шаярмыйм мин, Фидан. Инде менә бер ай буе һәр төнне төшемә поезд керә. Шпаллар арасыннан чәчәк җыеп

йөргәндә, әллә каян гына килеп чыга да ажгырып өскә килә. Мин чабам, чабам, поезд аның саен якыная, менә-менә сытып-изеп узар сыман. Мин һаман алга йөгерәм, ә рельстан читкә чыгарга башыма да килми. Инде поезд җилкәмә килеп терәлде генә дигәндә, кычкырып уянып китәм. Төш юрый беләсеңме син?

— Әби-чәби шикелле әллә төшкә ышана башладыңмы инде?

— Төш — кешенең еллар буе уйлап-хыялланып йөргән хисләренең соң чиккә җитеп кысылган бер йомарламы ул. Юк нәрсә төшкә керми. Кеше дөньяда булмаган нәрсә турында уйлый да, хыяллана да алмый. Бу поезд да юктан гына түгел. Минем язмыш — поезд язмышы кебек. Туу белән мине бер рельска кертеп җибәргәннәр дә, әле менә һаман шуннан чыга алганым юк. Кешеләр җил-давыллы, кайгы-хәсрәтле станцияләрне читләп үтә. Ә мин — юк, мин турыга барам, мин рельстан чыга алмыйм. Сөмбел киткәч, рельссыз тормыш башланыр, дигән идем, баксаң, бүтәнчә яши белмим икән.

— Син, Искәндәр, тормышыңны юкка катлауландырасың. Тормыш син уйлаганча ук катлаулы түгел бит ул. Һәркем үзенең бәхете турында үзе кайгыртырга тиеш. Һәр кеше бәхетле булса, бар халык бәхетле була, дөнья түгәрәк була. Бары шул гына, бик гади бит югыйсә. Син инде үзеңне зур максатлар өчен дөньяга килгән дип саныйсың. Сана, әйдә, саный бир. Институтта укыган чакта ук йолдыз чире белән чирли идең. Һаман терелеп җитмәгәнсең икән. Әллә мине... музыканы үзеңә караганда кимрәк ярата дип уйлыйсыңмы? Һо-о, юк! Арып-талып эштән кайткач, пианино янына килеп утыруга, бу дөньяның бар әрҗәләре, капчыклары эреп әллә кая юкка чыга. Менә шул чакта мин дә канатланам, мин дә яши башлыйм, шул чакта гына үземне бәхетле хис итәм мин. Ә болар,— Фидан бүлмәгә, өстәлдәге нигъмәтләргә битараф караш ташлады,— болар бер юаныч кына. Миннән барыбер композитор да, зур музыкант та чыкмый. Ә яшәргә кирәк. Типтереп, сиптереп, кешеләрнең күзләрен яндырырлык итеп яшәргә кирәк. Музыкант Фиданны тыңларга теләмәгән идегезме, ярый, менә хәзер склад мөдире Фидан янына килерсез. Бил бөгә-бөгә керерсез, рәхмәт укый-укый чыгып китәрсез. Ә ул сезнең арттан мыскыллап көлеп калыр.

— Ярый, мин китим әле, Фидан.

— Кая ашкынасың? Үпкәләдеңме әллә? Буш өйгә кайтып, нәрсә эшләмәк буласың? Кем көтә анда сине?

— Кунаклар киләсе. Өстәл әзерләргә кирәк. Кибетләргә йөрисем бар.

— Нинди кибет ди ул тагын? Нәрсә кирәк, бөтенесен төяп җибәрәм хәзер. Әй, Шамка!

— Нинди Шамка ул тагын? Кирәк түгел.

— Шамил аның чын исеме. Нәрсә кирәк сиңа?

— Бернәрсә дә кирәк түгел.

— Ә нигә генә кердең соң монда? Минем янга йомышсыз кермиләр...

Фидан аның буш сумкасына карап куйды.

— Хәлеңне белергә.

— Әйдә, алай булгач, юл аягына берне күтәреп куйыйк. Яңа елны каршы алу да шул булыр.

— Ярый, мин китим инде.

Искәндәр, буш сумкасын селки-селки, әрҗәләр арасындагы лабиринт буйлап әкрен генә чыгып китте. Фидан, башын артка ташлап, сүзсез генә сейф-бүлмә эчендә басып калды.

* * *

Урамга түшәлгән ап-ак кар һәм кояш яктылыгыннан Искәндәрнең башы әйләнеп китте. Ул, баскыч култыксасына таянып, күзләрен йомган килеш шактый ара басып торды. Җиргә сибелгән миллион «йолдызлар» күзне авырттырып җемелди. Искәндәр буш сумкасы белән аяк балтырына шапылдатып сукты да кар-йолдызларны шыгырдата-шыгырдата атлап китте. Шәһәр чите булгангадырмы, урам буш, бары тик сары чәчле малайга охшаган кояш кына, биек йортлар артыннан башын күтәргән дә, якты күзләрен олы итеп ачып үрелә-үрелә, шәһәргә карый. Шулчак Искәндәргә дөньяда кояш белән үзеннән башка беркем дә юктыр сыман тоелды. Хәмитләр, Интизар, Альфред, Рүдәл, Фиданнар — барысы да үз өннәренә кереп качкан йомраннар. Алар, тышта кар эреп, дөнья җылынмыйча, гөлләр чәчәк атмыйча, шул өннәреннән чыкмаслар, җыйган ризыкларын эшкәртеп ятарлар кебек. Ә ул аларның өнендә яши алмый, аның йомран өненә керәсе килми, анда аны кабул итәргә атлыгып торучы да юк...

Искәндәрнең борын төбеннән генә гөрселдәп буш трамвай узып китте. Ул тукталышка кадәр йөгереп барды да трамвайның иң арткы утыргычына кереп утырды. Трамвайда беркем дә юк иде, шуңадырмы ул бөтен көченә чаба, озын гәүдәсе белән як-якка атына. Шулай атынып бара торгач, Искәндәр үзенең йокыга киткәнен сизми дә калды.

* * *

Трамвай ап-ак каен урманын урталай ярып чаба да чаба. Туй күлмәге кигән сылу каеннар, сискәнеп, юл читенә тайпылалар. Каен урманын чыгуга, яшькелт киемле солдат егетләргә охшаган усаклар арасына ажгырып килеп керделәр. Аннары алда колач җитмәс гәүдәле имән баһадирлар күренде. Трамвай ачы тавыш белән сызгыра, бөтен гәүдәсе белән калтырый, коточкыч авазлар чыгара. Аның кыяфәтен күрүгә, йөз яшьлек имәннәр тамырлары белән куптарылалар да җан-фәрманга чаба башлыйлар.

— Туктатыгыз! Туктатыгыз! — дип кычкыра Искәндәр.

Ә трамвай һаман чаба да чаба.

— Туктатыгыз! Мин төшеп калам!

Аның сүзенә колак салучы, аны ишетүче, аңа җавап бирүче юк. Ул урыныннан сикереп тора да буш вагон буйлап чабып китә. Трамвай йөртүче кыз утырган кабина ишеген йодрыклары белән төяргә тотына, буш сумкасы белән шап-шоп суга.

— Туктатыгыз! Без кая барабыз? Мин төшеп калам! — дип инәлеп кабатлый ул.

Ә трамвай һаман күз иярмәс тизлек белән алга ыргыла, барган саен урман куера, караңгылана. Ишекне төятөя Искәндәрнең куллары арый, башы стенага бәрелә. Ә дию арбасы һаман чаба. Менә арба ут булып кыза, аны ялкын чорный, Искәндәр бер баштан икенче башка чаба, тирләп-пешеп чыга, чәчләреннән бу күтәрелә. Һәм ул, аптырап, хәлдән таеп, утыргычка утыра да, үзенең көчсезлегеннән гасабиланып, тавышсыз гына үксеп җибәрә. Шулчак дию арбасы туктый, алда яктырып, миллионлаган рубин йолдызлары белән күзләрне чагылдырып экият сарае балкып күренә. Түрдәге пыяла ишек ачыла да аннан... кинаяле елмаеп... алды кап-кара, арткы ягы ап-

ак күлмәк кигән... Сөмбел килеп чыга. Килеп чыга да аяклары җиргә тияр-тимәс атлап... юк, атлап түгел, йөзеп аңа каршы килә... Килеп җитә дә сак кына аның җилкәсенә кагыла.

— Әйдә, төшәбез! — ди ул, боерган аваз белән.— Килеп җиттек.

Шулчак колак төбендә меңләгән йолдызлар чыңлап куя да сүнә. Искәндәр күзләрен ача. Кырыйга шуып төшкән бүреген рәтләп куя, сәерсенеп, өскә күтәрелеп карый.

— Төшәргә вакыт, гражданин. Инде өченче тапкыр әйләнәсез. Билет та алмадыгыз.

Трамвай йөртүче кыз, Искәндәрнең уянганын күреп, кулын җиңеннән җибәрде.

— Әллә йокы планы тулмаганмы? — дип, янәшәдәге таза-базык гәүдәле, ямьшәйгән сумкалы, җиңенә кызыл бәйләгән хатын аның сүзен ялгап алып китә.— Сезнең йокы планы тулмаган, безнең — штраф планы. Билетыгызны күрсәтегез әле.

— Юк, алмадым мин.

— Куян бәясе — бер тәңкә.

— Ничек, ничек? Нинди куян? — Искәндәр уянып җитмәгән күзләрен челт-челт ачып йома да, гаҗәпләнеп, өскә күтәрелеп карый. Аннары, үзе дә сизмәстән, авыз тутырып елмаеп җибәрә.

— Яңа ел котлы булсын!

— Акылың өч потлы булсын! Безнең вакыт юк, халык көтә. Чыгар әйдә бер тәңкәңне!

— Бер тәңкәсез Яңа елга керү юкмы?

— Телеңә салынма. Бушка йөрисең килсә, тәпи-тәпи атла яисә машина ал. Кая теләсәң, шунда йөрерсең. Ә бу җәмәгать транспорты дип атала. Аның үз маршруты, үз законнары бар. Бер тәңкәңне...

Искәндәр, юләр кеше шикелле, авызын ерган да тик тора. Ул әле сәер төшле йокысыннан уянып җитмәгән, ул әле, һаман кулга-кул тотынышып, Сөмбел белән әкият сарае каршында басып тора кебек. Трамвайдагы халык шаулаша башлагач кына, күз алдындагы томан таралып, боз каткан тәрәзәләр, рәт-рәт тезелгән утыргычлар, каршыда басып торган ике кеше әкрен-әкрен пәйда булды. Искәндәр, кабалана-кабалана, кесәләрен актарды, кулга иң беренче эләккән акчаны тартып чыгарды да җиңенә кызыл бәйләгән хатынга сузды. Егерме бишлекне күргәч, хатынның салкын йөзендәге боз эреп киткәндәй

булды, ул Искәндәргә ихтирамлы караш ташлады, тавышы да йомшара, ягымлылана төште.

— Кая бара идегез соң? Кайсы тукталышка кадәр?

— Соңгы тукталышка кадәр. «Бәхет» тукталышына. Уятмасагыз, билләһи, барып җитә идем.

— Болай йоклап йөрсәң, ерак китә алмассың. Кулыңдагы бәхетне дә ычкындырырсың. Яшь кеше ут чәчеп торырга тиеш, баскан килеш йоклап йөрергә түгел.

«Монысы да акыл сата башлады,— дип көлемсерәде Искәндәр.— Шулкадәр мәхлук кыяфәтле микәнни соң мин? Кая гына барсам да, кемне генә очратсам да, акыл өйрәтә башлыйлар».

Контролер хатын иске сумкасыннан бөгәрләнеп беткән берлекләр, көмеш-бакыр тиеннәр чыгарып, кат-кат озаклап санады, аннары аларны, учы белән көрәп, Искәндәрнең учына салды.

— Санап ал, акча санаганны ярата. Мә, квитанция, хатыныңа отчет бирерсең. Кыеклатып карама, алдамадым, бер тәңкәңне генә алдым.

— Бәхет кыйммәт тормый икән сездә.

— Трамвайда йөрү дә булдымы бәхет?

Искәндәр, әй, синең белән сөйләшеп, тел әрәм иткән мин юләр дигәндәй, кулын селкеде дә, ашыгып атлыйатлый, арткы ишектән чыгып китте.

* * *

Табак-савытларны юып, тузаннарны сөртеп, урын-җирне тагын бер кат пөхтәләп чыккач, ул, хәлдән таеп, креслога утырды. Бер эшсез кеше кебек, түшәмдәге ярыкларга, җөйләргә, почмактагы обой җыерчыкларына, шкаф җекләренә, идән ярыкларына кадәр күздән кичерде. Шулчак бүлмәсе искиткеч зур булып тоелды аңа. Ипи-тоз күтәреп беренче тапкыр ишекне ачып кергәч тә шулай күренгән иде. Аякларын төрек солтанына охшатып бөкләп, идән уртасында шактый озак онытылып утырган иде ул чакта. Стеналар шып-шыр, күк йөзе төсле якты түшәмнән, кояш кыйпылчыгына охшап, сүрән лампочка елмаеп тора, кызгылт соры идән көзге болын кебек зур да, буш та...

Искәндәр идәндә гаҗәпләнеп утырган арада, Сөмбел кухняга кереп чыкты, туалет, ванна ишекләрен ачып ка-

рады, унитаздагы суны чыжлатып агызды, аннары бүлмәне аркылыга-буйга адымлап үлчәп чыкты. Үзе йөри, үзе бертуктаусыз сөйләнә:

— Менә монда диван куябыз, монда — өстәл, бу почмакка — телевизор, бу якка — сервант, ишек катына — шифоньер.

Искәндәргә аның сүзләре стена аша сөйләшкән кебек тонык кына ишетелә. Ул, күзләрен йомып, Сөмбел сөйләгән әйберләрне күрергә тырышып карый, ләкин алар, үч иткәндәй, күз алдына килми дә килми. Ул тагын күзләрен йома, шулчак стеналар музыкаль шкатулка сыман зеңгелдәп куя да буш бүлмәгә бөтен җирдән: тәрәзәләрдән, ишекләрдән, вентиляция торбаларыннан, идән ярыкларыннан музыка агыла башлый. Музыка авазларыннан аның колаклары авырттырып чыңлый, гәүдәсе кош сыман җиңеләеп кала. Ә музыка агыла да агыла. Музыка, аллы-гөлле төсләргә кереп, аның күзләрендә чагыла, музыка, чишмә чылтыравына охшаган көлү авазы булып, идәнгә чылтырап коела.

— Тахта белән сервант арасына пианино алып куярсың... Бигрәк тар инде... Бер бүлмә — бер бүлмә инде... Алгач-алгач, зуррагы кирәк иде... Әнә, кешеләр...

Искәндәрнең күз алдына ап-ак пианино калкып чыга. Аның капкачы үзеннән-үзе ачылып китә дә, икегә аерылып, ике канат сыман як-якка җәелә.

— Кеше шикелле бер урында гына төпләнеп эшләсәң, күптән әллә кем булыр идең инде. Йөрисең бит шунда әнәк эте сыман, ары тулганып, бире болганып. Аңа гына ярамый, ул гына талант, имеш. Талантны үлчи торган прибор табылмаган әле, кешене хәзергә эше буенча бәялиләр. Эшләгән ашый, эшләмәгән... баш кашый...

Ак пианино өстенә көл коелган төсле булды, аннары ул күзгә күренеп карала башлады. Бары тик ак клавишлары гына, ап-ак тешләргә охшап, елмаеп, балкып тора.

— Моннан ары болай яшәп булмый. Зарплатаңның тиенен тиенгә миңа биреп барасың. Җүнлерәк мебельгә җыярга кирәк. Шушы мәктәбеңдә кешечә генә эшлисең. Музыка язам, дисең икән, яз, сине беркем дә тыймый. Юк нәрсә белән маташуыңны аңлагач, үзең белеп туктарсың әле.

Искәндәр шаркылдап көлеп җибәрде.

— Нәрсәдән көләсең? Әллә, бер бүлмәле квартир алдым дип, акылдан яза башладыңмы?

— Сөенә белмисең син, Сөмбел. Гаҗәпләнә, шакката белмисең.

— Нәрсәсенә шаккатасың моның?

— Бик азга гына да гаҗәпләнә белергә тиеш кеше. Шунсыз дөньяның бер кызыгы да юк бит. Һәр нәрсәгә гадәти әйбер дип карасаң, туып торуыңнан ни мәгънә?

— Һәр очраган нәрсәгә шаккатып карап тора башласаң, урам чатына да чыгып җитә алмассың. Олы юлга, ерак сәфәргә чыккан кеше һәр әремгә сокланып, һәр чәчәкнең таҗ яфрагын санап тора алмый.

Искәндәр ярым шаярып, ярым җитди кыяфәт белән җыр сузып җибәрде:

Олы юлның тузанын ла, күрми калдым тузганын,
Күрми калдым, сизми калдым яшь гомеремнең узганын.

— Менә, менә, нәкъ өстенә бастың. Гомер кыска, юл озын, аргы башына барып җиткәнче...

— Әйбәт кеше син, Сөмбел. Синең һәр сүзең үзең өчен шулкадәр дөрес, ә минем өчен — дөрес түгел. Мин шушы бәләкәй генә фатирны да зур итеп күрәм, шуңа сөенәм. Ә синең аңа исең дә китми...

— Кеше алга карап яшәргә, зур хыяллар белән хыялланырга тиеш.

— Зур хыяллар...— Искәндәр, сүзен бүлеп, бармагы белән тәрәзә пыяласына тиз-тиз генә ике сызык сызды, аннары алар өстенә аркылы таяклар тезеп чыкты, шлагбаум ясап куйды.— Мин бу шәһәргә поезд белән килдем.— Ул тәрәзәдәге үзе ясаган тимер юлга күрсәтте.— Поезд ерак, бик ерак бара иде. Җир читенә хәтле. Ә миңа анда барырга кирәк түгел, мин шушы шәһәрдә төшеп калырга тиеш. Миңа башта шушы беренче тукталышны өйрәнергә, шунда яшәргә, гаҗәпләнеп, сокланып яшәргә кирәк иде. Әгәр дә, син әйтмешли, зур хыяллар белән хыялланып, бер тукталышта да тукталмыйча, гел алга барсам, ерак, бик ерак китәр идем мин. Ләкин ерак китүдән ни файда? Мин бит тирә-юньдәге матурлыкны күрмәс, дөньяның мәгънәсен аңламас идем. Буш вагоннар таккан поезд кебек мәгънәсезгә чабар да чабар идем. Юк, миңа андый тукталышсыз ерак сәфәр кирәк түгел. Һәр тукталыш — минем өчен соңгы тукталыш кебек. Шул тукталышны ачып, өйрәнеп бетермичә, алга бара алмыйм мин.

— Син, гомумән, кая барганыңны белмисең, Искәндәр.— Арлы-бирле йөри торгач, Сөмбелнең аяклары арыды булса кирәк, ул идәнгә, аның каршына килеп чүгәләде.— Шуңа күрә дөньяны беркайчан да аңлый алмаячаксың. Мине дә аңламыйсың. Менә син поезд, дисең. Уйлаганың бармы соң, без шул поездда урыннары очраклы гына янәшә туры килгән пассажирлар кебек бит. Соңгы станциягә кадәр бергә барып җитеп булырмы?

— Соңгы станция...— Искәндәрнең күз алдына аермачык булып кара пианино килеп басты.— Син ераграк китәрсең, Сөмбел. Мин шушында гына калырмын инде. Гаҗәпләнеп, шаккатып, сокланып бетмәдем әле мин.

— Кемең бар соң синең монда?

Искәндәр аның бу соравын җавапсыз калдырды. Сүзне уенга борып җибәрмәкче булды:

— Син, чынлап та, вокзалдагы сыман сөйләшә башладың. Әйдә, шундый көнне дә ямьсезләнешеп утырмыйк әле. Чыгар термосны, ал азык-төлекне. Вокзалда икән, вокзалдагыча булсын, юлда туктап, тамак ялгап алу зыян итмәс.

Аннары ул кинәт кенә туктап калды да: «Кемең бар? — дип кабатлады.— Кемең бар монда?»

Искәндәр, термосны ачып, капкачына чәй агызды, авызын пешерә-пешерә тиз генә йотып җибәрде. Кайнар чәй үңәчен көйдереп узды, утлы шар булып эченә кереп утырды. Утлы шар әкренләп бөтен тәнен яндырды, тамагына кайнар төер күтәрелде, гәүдәсе, куллары, башы кызышты, һәм бөтен бите буйлап, әчеттереп, ирексездән ике утлы тамчы тәгәрәп төште. Ул, йөзен яшерергә теләп, башын аска иде.

] ] ]

Шулчак, сискәндереп, нидер чылтыраган аваз ишетелде. Искәндәр беркавым аңына килә алмыйча торды. Кабалана-кабалана күлмәк итәкләрен кыстырды, битләрен учы белән сыпырды. Битенең юеш икәнен күргәч, аптырап калды. Йөгереп барып көзгедән карады. Ике як бите буйлап сузылган кызыл эзләр күргәч, ботын чеметте. Юк, ул йокламый, ул үз аңында. Тагын кыңгырау чыңы ишетелде. Ул, йөгереп барып, телефон трубкасын алды. «Кит-кит, кит-кит»,— дип, телефон салкын тавы-

шы белән кабатлап торганда, әлеге чыңлау тагын ишетелде. Ул, трубканы ташлап, ишек янына атылды.

— Кем анда? Хәзер, хәзер! Хәзер ачам!

Ачкычын таба алмыйча, яңадан бүлмәгә йөгереп керде, аяк астындагы паласка абынып егыла язды. Ишек төбендә дөньяда иң кирәкле кеше көтеп торадыр, ул китсә, бөтен нәрсә челпәрәмә килер, аның болай да мәгънәсен югалткан тормышы бөтенләй сүнеп-сүрелеп калыр сыман иде. Ачкычны өстәлгә куйган икән, аны алганда, күзе өсте-өстенә өелгән ризыкларга, тәлинкә, чәнечке, пычакларга төште. Аларны рәткә китергән арада, ишекне дөбердәтергә үк тотындылар... Менә, бөтен фатирны шаушуга тутырып, бер-бер артлы кешеләр керә башлар. Иң алдан кергән Хәмит тунын салып идәнгә ташлар да шампанский шешәсен шартлатып ачып җибәрер. Аның артыннан кочагы белән чәчәкләр күтәргән Интизар күренер. Аннары, тальян гармунын каерып тартып, Альфред килеп керер, Рүдәл ишек төбендә басып калыр, Фидан кочагындагы төргәкләрне диванга китереп аударыр...

Искәндәр, башына агылып торган хыялый сурәтләрне сыпырып төшерергә теләгәндәй, маңгаен уч төбе белән ышкыды. Ишекне тагын дөбердәттеләр. Ачып җибәрсә, ишек төбендә күрше Хәбир абый басып тора. Искәндәрнең ачылган авызы ябылмыйча калды, ул, үзенең каударлануыннан үзе оялып, песи баласы сыман, ишеккә елышты.

— Бик озак юандың. Әллә яшь килен алып кайттыңмы, күрше?

— Өстәл әзерләп йөрим.

Искәндәр, әле генә аңына килгәндәй, нәрсә әйтергә дә белмичә, тын калды. Ул тагын да бөрешеп, бәләкәйләнеп китте.

— Бер егет сиңа язу калдырганые.

Хәбир абый пинжәк кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды.

— Ишек төбендә басып торгач, чакырып керттем үзен. Бигрәкләр җор телле егет булып чыкты, мәлгунь. Мәзәк сөйләп, эчне катырып бетерде.

— Кем ул, кайда ул?

— Китте инде, көтеп тормады. Кадыйр исемлеме шунда. Ну, анекдотларны сибеп кенә тора! Мин дә сынатмадым, бер акбашны чыгарып утырттым. Во, Хәбир абыең!

Искәндәр шунда гына күршесенең шактый кызмача икәнен абайлады. Кәгазьне алды да, нидер вәгъдә итеп тә вәгъдәсен үтәмәгәнне күреп үпкәләгән кеше төсле, боек кыяфәт белән бүлмәсенә керде.

Кадыйр аның авылдашы иде. Ул мәктәптән соң тракторчы булып китте. Отпускыда көньякка санаторийга барган икән. Кайтышлый, аның янына сугылырга иткән. Ике сәгатьтән артык көтеп утырган. Поездга соңга калам, ашыгам, дигән.

Искәндәрнең кул аркасындагы кан тамырлары күзгә күренеп бүртеп чыкты. Ул ишекле-түрле йөрде, тәрәзәдән урамга карап торды, почмактагы чыршыны, күтәреп, икенче башка илтеп куйды. Вокзалга шылтыратты, Кадыйрның поезды җиденче унике минутта китәргә тиеш икән. Җиңен кайтарып, кул сәгатен карады: җиде туларга биш минут. Күңел түреннән күтәрелеп килгән өмет хисе белән стена сәгатенә таба борылды. Иске сәгать алты туларга җиде минут күрсәтә иде. Ул беркавымга икеләнеп калды. «Кайсы дөрес йөри боларның?» Борынгы сәгать, аны үртәгәндәй, ябалак күзләре белән карап тора. Ул диванга менеп басты да стена сәгате телләрен кул сәгате белән дөресләп куйды.

Кадыйр аңа бала чактан, мәңге кире кайтып булмый торган үткән гомердән килгән илче кебек тоелган иде. Кадыйрны күрсә, үзенең бала чагы белән очрашыр, бүгенге аһ-зарлардан, матавыклардан котылып, яңадан сабый хәленә кайтыр, өр-яңадан яши башлар иде кебек.

Ул үзенең, китап тулы портфель күтәреп, беренче тапкыр мәктәпкә барганын күз алдына китерде. Тирә-юньдә чәчәк ташкыны агыла, көлү тавышы, урамга сыймыйча, капкаларга, йорт стеналарына барып бәрелә. Шулчак йортлар, капкалар сихри бер төскә кереп балкый башлый. Менә Искәндәрне, күтәреп алып, урындыкка утырталар да кулына гармун тоттыралар. Ул олы гармун артында бөтенләй югалып кала, нәрсә уйнарга да белмичә, бармакларын гармун телләренә куйган килеш, тик тора. «Уйна! Уйна!» — дип, хор белән кычкыралар аңа. «Нәрсә уйныйм соң?» — ди ул пышылдап кына. «Совет Армиясе»н уйна, «Каршылау маршы»н уйна!» Ул гармун күреге өстенә башын кыңгыр сала да уйнап җибәрә. Гармун авазына кушылып, бар халык гөр килә. Уйнап бетергәч, мәктәп директоры аны кочагына ала да башыннан сыйпый. «Каян өйрәндең болай оста уйнарга? Музы-

кант чыгачак синнән. Юлыңнан тайпылмыйча барсаң, менә дигән композитор чыгачак». Директорның сүзләре күңелне рәхәт кымырҗытып тора башлый. Шул сүз аның төшләренә керә, малайлар таяк атка атланып йөргәндә, ул шушы тылсымлы сүз канатында оча, бүтәннәр башын мендәргә төртеп мыш-мыш йоклаганда, шул сүз аны ай сукмагы төшкән урман аланнары буйлап атлата, йолдызларга кадәр алып менә.

Ул, менә-менә Кадыйр килеп керүен көткәндәй, күзләрен ишектән алмый торды. Ләкин балачак ишеге ачылмады, ул мәңгегә ябылган иде.

Искәндәр пианино янына килеп утырды. Аның куллары кагылуга, пианинодан сагышлы музыка агылды. Искәндәр, бар дөньясын онытып, алга-артка чайкала-чайкала уйнады да уйнады. Музыка өермәсе аның күңел җилкәннәрен кабартты. Шулчак ул үзенең әле моңа кадәр ишетелмәгән, ләкин аһәңнәре инде ничә еллар буе җанында яңгырап торган гаҗәп таныш та, ят та, сәер дә, шулай ук искиткеч якын да бер көй уйнаганын аңлады. Бу аның язмышы турындагы көй иде. Искәндәр үзенең бармакларын да, гәүдәсен дә тоймады, ул үзе каядыр эреп юкка чыкты, аның урынында бары шул көй генә торып калды.

Шулчак кемдер көмеш шөлдер чылтыратты. Аны чакыралар, аның музыкасын, аның җан авазын ишеткәннәр дә кешеләр Искәндәрне үз араларына, үз яннарына чакыралар. Ул аларга кирәк...

Искәндәр авырлык белән башын күтәрде, чигәләрдә чыңлаган авазлардан арына алмыйча, бер ноктага текәлеп торды. Көмеш шөлдер тагын аваз салды. Ул, ихтыярсыз атлап, телефон янына килде.

— Искәндәр! Искәндәр! Нигә эндәшмисең? Искәндәр, дим! Өф! Әллә телефон эшләми инде?

— Мин бу, тыңлыйм.

— Нәрсә, йоклый идеңме әллә? Тавышың җәһәннәм читеннән килгән шикелле ишетелә.

Искәндәрнең телефонны, төбе-тамыры белән йолкып, тәрәзәдән урамга ыргытасы килде.

— Ни кирәк сиңа?

— Бик кырт сөйләшәсең. Мин сиңа яңа хәбәр җиткермәкче булам, ә син...

— Ни булды?

— Телеграмма килде. Сөмбелдән...

Искәндәрнең трубка тоткан кулы хәлсезләнеп асылынып төште. Ул ваемсыз кыяфәт белән уттай янып торган кызыл телефонга текәлде. Аннары, аңына килеп, трубканы колагына китерде.

— Сөмбелдән? Ул кайда? Нәрсә дигән?

— Яңа ел белән котлаган...

— Телеграмманы каян суккан?

— Хәзер карыйм, менә монда язылган бугай. Якты юл, дигәнме шунда? Әйе, Якты юл.

— Кайда икән ул?

— Белмим... Колакка чалынган да сымак үзе. Юл булгач, берәр олы юл буендагы шәһәр кисәгедер. Хәзер көн тудымы — яңа шәһәр салалар бит. Якты да булгач, бүгенге яңа шәһәрдер... Үзең нишләп ятасың соң әле?

— ...

— Кунакларың килә башладымы? Безнекеләр белән монда өй тулды инде. Утырыр урын да юк. Чакырмыйча-нитмичә килделәр дә керделәр. Кичкә үзебез дә чакырулы бит. Ничек котылырбыз болардан.— Хәмит, шикәр кимергән кебек, кетердәтеп көлеп җибәрде.— Төнге уникедән соң, җыелышып, үзәк чыршы янына чыгабыз. Әйдә, шунда күрешәбез. Берәрне кыстырып та чыгарбыз. Яңа елда иң беренче күргән кешең мин булыйм әле...

Хәмит сөйли дә сөйли, ул сөйләгән саен, Искәндәрнең колаклары томалана бара, күңеле һаман саен ныграк үртәлә. Әгәр хәзер трубканы ташламаса, аның колаклары чукракланыр күк.

Ул телефон трубкасын шапылдатып куйды да, өстәл янына килеп, коньяк шешәсен ачты, рюмканы тутырып салды. Кулын күтәреп, каршысыннан чәкешергә кеше эзләде, беркем дә юк икәнен аңлагач, рюмкасын яңадан куйды. Шулчак аның тыны кысыла башлагандай тоелды. Ул форточкаларны ачты, күлмәк якасындагы өске төймәне ычкындырды, әмма сулыш алу җиңеләймәде. Аптырагач, подъездга чыкмакчы булды. Коридордан үтешли, чөйгә эленгән пальто кесәсеннән тырпаеп торган гәзитләрне алды. Аннан берничә хат белән открытка да ияреп чыкты. Хатның берсе мәктәптә бергә укыган кыздан, икенчесе курсташы Сәбиләдән иде. Сөмбел киткәч, ялгызлыктан каңгырып, нишләргә белмичә утырган көннәрнең берсендә ул бөтен таныш-белешләренә Яңа ел белән котлап открыткалар салды. Шуңа җавап килгән... Хатлар бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган.

«Открытканы алдык, рәхмәт. Үзеңне дә якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйбыз. Эшеңдә, иҗатыңда яңадан-яңа уңышлар телибез».

«Боларның күңелендә бер генә җылы сүз дә калмадымы икәнни?» — дип уйлады Искәндәр. Салкын кәгазьле хатларны урындыкка ташлады, игътибарсыз гына соңгы открытканы әйләндереп карады. Беренче хәрефләрне күрүгә үк, бармаклары буйлап, чемердәп, җылы йөгерде. Открытка аның кызыннан — Ләйсәннән иде.

*«Әткәй!*

*Без хәзер монда яшибез. Кайда икәнен язсам, әнкәй ачулана. Ул хәзер эштә, мин мәктәптән кайттым. Бездә озакламый Яңа ел җитә. Шифоньерда минем Миләүшә исемле курчагым калган. Бер кулы юк аның. Бер кулы безнең әйберләр арасында киткән. Миләүшәгә читендер инде хәзер. Кулы булмагач, берни эшли алмыйча, тик кайгырып утырадыр. Чыгарып ташлый күрмә аны. Мин бик-бик яратам аны.*

*Ләйсән».*

Искәндәр, ниндидер серле мәгънәсен ачарга теләгәндәй, һәр сүзне кат-кат укыды. Хатны кулына тоткан килеш, шифоньердагы бер кулсыз курчакны өстәл уртасына китереп утыртты. «Миләүшә, Миләүшә»,— дип кабатлый-кабатлый аның башыннан сыйпады.

Ләйсән хатын укыганнан соң, ул үзенең бу шәһәрдә беркемгә дә кирәге юклыгын тагын да ныграк тойгандай булды. Ул бүген, үзләре яңа йортка күчкәндә, иске йорт капкасы төбендә ташлап калдырылган хуҗасыз эт сыман, көне буе шәһәр буйлап кая бәрелергә белмичә йөрде. Һәркемнең үз мәшәкате, үз кайгысы. Хатыны булып хатыны Сөмбел дә аны ташлап китеп барды. Ул чынлап та яши белми, ахрысы. Кеше җылысына өмет итеп яшәмәскә, иң элек үз учагыңны тергезергә кирәк. Кемнең учагы зуррак, халык шуның янына җыелачак. Учагың сүнә башласа, сине ташлап китәләр. Беркемне дә гаепләп булмый. Әгәр дә син кешеләр арасында яшисең икән, аларның гореф-гадәтләрен, йолаларын хөрмәт итәргә тиеш.

Искәндәр пинжәген киде, ишек катына килеп, бераз уйланып торды да, подъездга чыгып, күрше ишекне шакыды. Ишектән Хәбир абыйның тирләп-пешкән канәгать йөзе күренде.

— Әйдүк, күрше, әйдүк! Күрше хакы — Алла хакы, диләр. Түрдән уз.

— Юк, Хәбир абый, мин синең үзеңне чакырмакчы идем.

— Әттәгенәсе, минем монда бер батальон кунаклар чакырулы бит. Чакырсак, чакырабыз инде кунакны! Во, Хәбир абыең!

— Озакка түгел, күз сирпеп кенә чыгарсың. Сүзем бар иде.

— Сүз булса, керәбез. Сүзне сүз итәргә кирәк. Аллага шөкер, кеше сүзен аяк астына салып таптаган булмады. Во, Хәбир абыең!

Искәндәргә нишләптер рәхәт булып китте. Хәбир абыйның мәзәк атлап йөрүләренә, һәр сүз әйткән саен, йоткылыкларына хәтле күрсәтеп авыз еруларына, күңеленә хуш килгән саен, «Во, Хәбир абыең!» дип куюларына хәтле якын, үз тоелды. Ул моңа кадәр аңа бөтенләй игътибар итмичә йөрүе, аның белән аралашмавы өчен үз-үзен битәрләп куйды.

— Басып сөйләшкән сүзнең иманы булмый. Утырыйк әле, Хәбир абый. Мин бер көй язган идем бит әле, Хәбир абый.

— Көй, дисеңме? Әйтәм, төннәр буе дыңгыр да дыңгыр килеп, йокы бирмисең.

Хәбир абый пианино ягына кинаяле елмаю белән карап куйды.

— Уйнап күрсәтимме?

— Уйныйммы, дип, уйнар өчен язгансыңдыр бит инде. Минем үземнең болай яшьләр уйный торган көйләргә колак күнекмәгән.

Хәбир абый күз карашын өстәлгә күчерде.

— Әйдә, салып куйыйк әле башта! — Аның күңелен уятасы, күңелен музыка тыңлар өчен әзерлисе килә иде Искәндәрнең.

Аягүрә басып, рюмкаларны зыңлатып эчеп куйдылар. Хәбир абый озак кына тын алмый торды, нәрсә бу дигәндәй, коньяк шешәсен әйләндереп карады.

— Менә хәзер уйнасаң да була.

Искәндәр, пианино янына барырга кыймыйча, әле тәрәзә төбенә, әле ишек катына килде. Әйтерсең музыка белгече каршында имтихан тотарга җыена.

— Тизрәк бул, минем кунаклар җыела анда.

Искәндәр, аның сүзләренә буйсынып, капылт кына туктады да пианино каршына килеп утырды.

Ургылып аккан суга чумарга җыенган малай сыман, кулларын алга сузып, күңелендә кайнаган музыка ташкынына башы әйләнгәнче өстән карап торды. Хәзер, хәзер ташкын аны бөтерә-бөтерә үз эченә алып керәчәк...

— Хәбир, дим, Хәбир! Мондамы син?

Елга тынып, туктап калды.

— Эчеп, күңел ачып утырасызмы? Инде бу дуадак каз янынаияләштеңме? Аңа карама, эчәр дә, печәр дә ул. Хатыны белән баласын куып чыгарып, берүзе квартирда типтереп ята бит әнә.

Искәндәр, бу сүзләрне ишетмәс өчен, клавишларга бар көченә суга-суга марш уйнарга тотынды.

— Әйдә, әйдә, каккан казык сыман басып торма. Тоз суы сипмәгәннәрдер монда. Аракы үзебездә дә мүре.

— Соң, хатын, көй яздым, ди бит, җыру яздым, ди. Шуны гына тыңламакчы идек. Шуңа гына чакырды, әйдә, син дә тыңла.

— Шушы да булдымы көй? Көйсез кешеләр көе бу. Кухняда пәрәмәчләр көя, көтә-көтә кунакларның күзе күгәрде. Нинди көй ди ул тагын? Радиодан, телевизордан көне-төне шалтыраганнары да җиткән. Колаклар тонып бетә. Әйдә, әйдә!

— Көйсез кодагый булма әле, хатын.

— Әйдә, дим, мин сиңа!

Хатыны Хәбир абыйны җилтерәтеп алып чыгып китте.

Искәндәр, өскә күтәрелеп карарга да кыймыйча, уттай кызган маңгаен пианинога терәде. Аның хәзер кемгәдер сыенасы, кемнеңдер кочагына кереп җылынасы, иң өстенә башын куеп иркәләнәсе килә иде. Ләкин кара пианино аны юата алмады, бары тик күңелгә сагыш кына өстәде.

Подъездда кычкырып сөйләшкән, көлешкән авазлар ишетелде. Искәндәр шунда гына бүлмәгә кичке караңгылык иңгәнен күрде. Ут кабызгач, яктылыкка күзләре чагылудан, тәрәзә каршына килеп басты.

Урам буйлап халык агыла. Шулчак ул нигәдер кич авылда урам тутырып сарык көтүе кайткан чакны исенә төшерде... Кешеләр елмая, көлә, бер-берсенең колагына иелә-иелә нидер сөйли, каядыр ашыга. Шушы кадәр халык арасында аның хәлен белергә теләгән, үз мәшәкатьләреннән азга гына булса да арынып, аның янына сугылырга уйлаган бер кеше дә юк микәнни соң?

Урамның каршы ягында бер хатын кибет ишеге төбендә туктады да туп-туры аның тәрәзәсенә карап тора башлады. Бераздан кулындагы сәгатенә күз сирпеп алды, арлы-бирле йөреп килде. Тагын каршыга туктап, бер урында таптанып торды, аягы таеп, егыла язды. Менә бер ир, кибеттән чыкты да, теләр-теләмәс кенә аның янына килде. Ата каз сыман муенын як-якка боргалап торгач, бүреген күтәребрәк куйды, тәмәке кабызды. Аннары хатынга нидер әйтте. Хатын сәгатенә карады. Искәндәр дә ихтыярсыз стенадагы сәгатькә күз салды. Сәгать туктап калган, сәгать йөрми иде. Ачкычын табып, тиз-тиз генә сәгать пружинасын борды. Бераз гына кул сәгатенә карап торды да борынгы сәгатьнең телләренә кагылды. Шулчак сәгать, аның яңагына суккандай, яңгыратып сугарга тотынды. Искәндәр авыз эченнән: «Ничек телисең, шулай йөр»,— дип сөйләнә-сөйләнә, яңадан тәрәзә каршына килде. Теге хатын белән ир һаман нидер сөйләшеп тора. Менә хатын ир кешенең җиңеннән тотты да аны каядыр алып китмәкче булып тарткалый ук башлады. Ир кеше кулын кисәк кенә тартып алды һәм урам буйлап ашыга-ашыга атлап китте. Хатын, йөгереп барып, тагын аңа ябырылды. Ир кеше, борылып, аны этеп җибәрде, хатын тротуар читендәге кар өеменә егылды. Искәндәр, үз-үзен белештермичә, күлмәкчән генә урамга йөгереп чыкты, машина көтүен ера-ера аргы яктагы тротуарга килеп җитте дә ир кешенең якасына ябышты. Каршында чәчләре тузгыган яланөс кешене күргәч, ир кеше бер мәлгә каушап калды.

— Җибәр мине! — диде ул, өзек-өзек сулыш алып. Аның тавышы еламсырап чыкты.— Җибәр, диләр сиңа!

— Җибәрермен мин сиңа! Нигә хатын-кызга кагыласың?

— Нинди хатын-кыз булсын ул?

Ир кеше Искәндәрнең яка тоткан кулына китереп сукты.

— Җибәр яхшы чакта!

Искәндәр аның кулын артка каерып китерде дә башын карга чумдырды. Шулай бераз токкач, җибәреп, җирәнгән кыяфәт белән кулларын бер-берсенә ышкыды.

— Хатының өстереп чыгардымы?

Ир кешенең бите әллә кардан, әллә күз яшьләреннән юеш иде.

— Ярый, бетердек. Хатын-кызга бүтән кул күтәрәсе булма.

— Эт шикелле арттан сагалап йөрмәсен.

— Нишләп йөри соң ул?

— Нишләп йөрсен? Бүтән эше булмаганга йөри. Эштән арып кайткач, өч борынга берне сындырырга гына хакым бардыр бит инде минем.

— Үз хатыныңмыни?

— Булганнан булмаганы яхшырак.— Ир кеше, елап җибәрергә җыенгандай, танавын мышкылдатты. Искәндәргә боек кыяфәтле, еламсырап сөйләшә торган бу кеше кызганыч булып китте. Ул аны күрткә чумдырып алуына үкенде.

— Әйбәтләп ресторанга кереп утырсаң йә өйгә алып кайтып эчсәң, сүз әйтмәс иде.

— Ресторан, һе, ресторан. Кергән бар анда да. Башта, оҗмахка кергәндәй, сәгать буе ишек төбендә басып торасың. Кердем дигәч, күзең талганчы официантканы көтәсең. Салат-малатка гына риза түгел, өстәл тутырып алмасаң, синең белән сөйләшеп тә тормый алар. Ә миңа йөз грамм гына кирәк, күңел җебетер өчен, тел ачкычы өчен...

— Шешәсе белән өйгә алып кайт та, өстәл артына утырып, хатының белән чөкердәшә-чөкердәшә сөйләш.

Искәндәр, як-ягына борылып, аның хатынын эзләде. Ул, эреп аккан кебек, юкка чыккан иде.

— Бәхетле кешедер син... Исемеңне белмим инде...

— Искәндәр.

— Бәхетле кешедер син, Искәндәр туган. Син минем авызны җимерә яздың, мин сиңа туган, дип торам тагын.

— Мин белмәдәм бит, гафу итегез...

— Бер белмәгән кешенең якасына барып ябышу икеләтә начар инде. Без хатын белән талашырбыз да, килешербез дә. Хатын белән ир арасына бер чакта да кермә син.

Искәндәр ир кешенең әле генә кибеттә эчеп чыккан йөз граммы сөйләшә башлаганны аңлады.

— Киттем мин, бар, син дә кайт, хатының көтәдер.

Ир кеше, чытырдатып, аның җиңенә ябышты.

— Китмә, ашыкма. Күрешкәнбез икән, димәк, Ходай шулай кушкан. Әйдә, кибеткә кереп чыгыйк әле. Акчаң бармы? Булмаса, эзләмә, минем — җитәрлек.

Ул Искәндәрне кибеткә таба өстерәде.

— Бик эчәсең килсә, әйдә, миңа керәбез.

— Прокурорың өйдәме?

— Нәрсә?

— Хатының, диюем...

— Ә-ә, юк.

Алар, малайлар сыман җитәкләшеп, урам аша йөгереп чыктылар.

Ир кеше пальтосын салып урындыкка куйды. Түргә узарга ашыкмады, квартира сатып алырга җыенган кешедәй, озаклап тирә-юньне күзәтте.

— Да-а, туган, хатының ташлап киткән икән. Әйтәм чәбәләнәсең...

Искәндәр ботинкасын салган җирдән, аптырап, башын күтәреп карады.

— Каян беләм, дисеңме? Әнә, идәнең аннан-моннан юылган. Гомер буе хатын белән яшәп, ялгыз тормышка ияләшмәгән, күңеле утырмаган кеше генә идәнне шулай юа. Стенадагы келәмеңне дә сатып эчмәгәнсеңдер, андый кешегә охшамыйсың. Өйләнмәгән кеше өстәл уртасына кулсыз курчак утыртып куймый. Димәк ки, синең кызың бар. Малай кеше булса, машина-мазар торыр иде. Һәм, иң кыены, син кызыңны сагынасың. Шушы минутта син кызыңны сагынасың. Шуңа күрә күңелең нечкәрә дә, урам читендә хатынын җәберләп торган ерткыч ирне күреп, йөгереп чыгасың...

— Шерлок Холмс!

— Тормыш өйрәтә ул. Баш авыртканда, хатын яшергән аракыны эзли башласаң, Шерлок Холмс та булырсың. Өстәлең ярлы күренә. Төшемле эштә эшләмисеңдер.

— Музыкант...

— Музыкантның да төрлесе була... Атаклысы, танылганы, бае, ярлысы, бәхетлесе, бәхетсезе...

— Мин соңгысыдыр инде.

— Мескенләнмә. Мескен кешедә бер чакта да өмет юк.— Ир кешенең еламсырак тавышы торган саен көрәя барды, ул күзгә күренеп җанланды.— Музыкант булсаң, әйдә, һөнәреңне күрсәт.

Искәндәр, үз ирегe белән аның музыкасын тыңларга теләгән кеше күрүенә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сакланып кына клавишларга кагылды. Ир кеше күзләрендә җитди моңсулык төсмере чагылгач, бармаклары җитезләнде, көй үзеннән-үзе агыла башлады. Ул башта Сәйдәш көйләрен уйнады, аннары, сиздермичә ге-

нә, үз көйләренә күчте. Уйнап туктагач, күтәрелеп карарга кыймыйча, озак вакыт аска текәлеп торды.

— Уйна, тагын уйна! — дип өзгәләнде ир кеше.

— Уйнармын. Танышу хөрмәтенә башта берәрне күтәреп куйыйк әле!

— Музыка хөрмәтенә, яхшы музыка хөрмәтенә эчәм.

Ир кеше рюмканы бер йотуда каплап куйды. Искәндәрнең бу кеше белән туйганчы сөйләшәсе, аңа бар эч серләрен ачасы килде. Ләкин күңелендәге хисләр, сүз кыяфәтенә керә алмыйча, музыка булып агылалар иде.

— Музыка, музыка...— дип кабатлады ул.— Шуның өчен яшим, шуның белән күңел юатам инде мин.

— Һәркемнең бер күңел юанычы була.— Ир кешенең, коньяктанмы, хисләнүдәнме — борын очларына хәтле тирләп чыкты.— Мин менә кибет төбендә юаныч табам. Шунда килеп күңелемне бушатмасам, төн йокыларым кача, эшем эш булмый. Шунда гына телем ачыла минем. Юк, уйлама тагын, өч борынга керер өчен генә килмим мин анда. Үз ишләрем шунда җыелганга киләм. Алар белән генә иркенләп сөйләшә алам, бары алар гына аңлый мине. Ә син ресторан, дисең. Ресторанда миңа сандугач көтүенә ияргән чыпчыкка караган шикелле карыйлар. Ә кибет төбендә без — барыбыз да чыпчык. Әйдә, уйна әле тагын, Искәндәр туган.

Көй уйнаган саен, ир кеше җанлана барды, сүзсез генә авыз эченнән шыңшып та куйды, аһ-уһ килеп ыңгырашып та алды. Искәндәр, өстәл янына йөгереп килеп, аның рюмкасын тутырды да тагын пианинога сарылды. Ул бирелеп, бар дөньясын онытып музыка тыңлаган кешенең чыгып китүеннән, аның йөрәгеннән ургып ташыган музыканың, кояр диңгез тапмаган елга кебек җәелеп, бар дөньяны басып китүеннән курка иде.

Тора-бара ир кеше рюмкасына үзе салып эчә башлады. Искәндәрнең моңа да хәтере калмады, киресенчә, сөенде генә. Ул хәзер музыкадан башка бер нәрсәне дә ишетми, бер нәрсәне дә күрми иде.

Җилкәсе артында сәер тавышка борылып караса, өстәл артындагы урындыкка утырган ир кеше башын өстәлгә куйган да ваемсыз гырлый иде.

Искәндәр сикереп торды да, йөрәгендә кинәт купкан үпкә катыш ачу давылын тыя алмыйча, аның җилкәсеннән селки башлады.

— Уйна, уйна,— дип кул селкеде аңа ир кеше.— Уй-

на, мин йоклыйм. Сәйдәшне уйна! Син — сандугач, мин — чыпчык...

Искәндәр пальтосын кидереп, башына бүреген батырды да ачу белән эткәли-төрткәли исерек ирне урамга чыгарып җибәрде.

Ул бүген үзе янына беркем дә килмәсен аңлады. Бүген дә, иртәгә дә... беркайчан да... беркем дә... килмәячәк. Аның йөрәге, атылып чыгардай булып, ярсый-ярсый типте, җаны, ялгызлык исе сеңгән бүлмәдә калырга теләмичә, форточкадан очып чыгарга итте. Искәндәр йөгереп барып форточкаларны япты, телефонны розеткасыннан тартып чыгарды. Шулай иткәч, шәһәр белән, бөтен дөнья белән алыш-биреше өзелгәндәй тоелды. Диван артындагы иске чемоданны сөйрәп чыгарды да аңа өстәлдәге бар нәрсәне сыпырып төшерде.

Өстәл уртасындагы сыңар куллы курчак кызы, йомылмас күзләрен тутырып, аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды.

Урамга чыккач, читлегеннән качкан арыслан сыман, кая барырга белмичә, як-ягына каранды. Яшел утлы такси күренүгә, аның каршына йөгерде. Чемоданын арткы утыргычка ыргытып, үзе таксист янәшәсенә утырды да, шашкан кеше төсле, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Вокзалга!

## ПОЕЗДДА

Поезд, кемдер арттан этеп җибәргән кебек, кисәк кенә талпынып куйды, аннары, бераз уйланып торгач, ыңгыраша-ыңгыраша, авырлык белән кузгалды.

Ул кергәндә, купедагы өч пассажир нәрсә турындадыр бирелеп сөйләшәләр иде, аны күрүгә, кинәт туктап калдылар. Искәндәр чемоданын илтифатсыз гына утыргыч астына тибеп кертте дә өстәл янындагы буш урынга килеп утырды. Беравык барысы да тын тордылар. Тынлыкны өстәлнең каршы ягында утыручы какча йөзле, маңгайга таба өчпочмакланып төшкән көл төсендәге чәчле агай бүлде:

— Отылдым, ярты — миннән,— диде ул һәм Искәндәргә ачулы караш ташлады.

Аның янәшәсендәге түгәрәк йөзле кеше бу сүзгә аңлатма бирергә ашыкты:

— Бәхәсләшкән идек без монда. Ир кеше керәме, ха-

тын-кызмы, дип. Безнеке дөрес булып чыкты. Рәхмәт сиңа.

Өстәлгә терсәге белән таянып, тәрәзәдән карап баручы кеше авызы тулы алтын тешләрен күрсәтеп көлеп җибәрде, бирчәеп беткән кулы белән өстәлгә сукты.

— Рәхмәт, егет, безнең сүзне сүз иттең.

Искәндәр аның кулында бер бармагы юклыгын искәрде. Килеп керүгә, пенсионерлар арасына эләктем дип көрсенгән иде, берничә минут эчендә күңеле күтәрелеп киткәнен сизде.

Какча йөзле кеше, чемоданында шактый казынгач, теләмичә генә шәраб чыгарып утыртты. Түгәрәк йөзле агай, күзләрен кыса-кыса, аны дүрт стаканга тигезләп бүлде, өстәл артындагы сумкасыннан каклаган каз боты алып, вак телемнәргә кисте. Дүрт бармаклысы, ул кискәндә, авызларын чәпелдәтә-чәпелдәтә карап торды.

— Алдык, егетләр!

Өчесе дәррәү стаканнарны күтәрделәр. Искәндәр чыгып китәргә җыенып торып басты.

— Кая син болай? Ашыкма, егет. Син булмасаң, бу шәрабның гомер чыгасы юк иде. Әйдә әле, тотып җибәр салганын, белеп кайдан алганын...

Түгәрәк йөзле агай, кулга стакан алгач, бәхет кошының койрыгыннан эләктергән сыман, бөтенләй канатланып китте.

— Әйдә, әйдә, егет кеше булуың өчен бер күтәреп куйыйк әле.

Искәндәр тартынып кына стаканга үрелде. Стакан читенә иренен тидергән килеш, астан гына сөзеп, агайларның эчкәнен күзәтте. Какча йөзлесе стаканны бер селкүдә йотып куйды, түгәрәк битлесе ләззәт белән әкренләп, ими имгән яшь бозау сыман туктый-туктый эчте, дүрт бармаклы агай уртлап куйды да бераз тәрәзәдән карап торды, тагын уртлап куйды. Искәндәрнең стаканы тулы килеш тора бирде.

— Болай ярамый, егет, ярамый. Чит кешеләр, дисеңдер инде. Алайса танышыйк.— Түгәрәк йөзле агай аңа ике кулын сузды.— Миңнемотыйгулла. Авылда Мотыйк дип кенә йөриләр. Безнең якларга барып чыксаң, сора: «Балта остасы Мотыйк кайда тора?» — диген. Йөз чакрым тирә-юньдә белмәгән кеше юк мине.

— Мине алай ук белмиләр, шулай да танышыйк.— Какча йөзле агай озак итеп аның кулын селкеп торды.—

Ибраһим атлы булам мин. Ибраһим дип тутырып әйткән кеше юк инде бездә. Бригадир Ибрай дип кенә җибәрәләр.

Тәрәзә буендагы агай танышканда торып ук басты. Сул кулын йөрәге турысына куеп, уң кулын алга сузды.

— Монысы Сәгыйдулла абыең булыр инде. Үзеңнең атың ничек соң?

— Искәндәр...

— Һай, һай, пәйгамбәрләр исемен эләктергәнсең үзең.— Сәгыйдулла агай, Искәндәргә олы хөрмәт белән карагандай, башыннан аягына кадәр күз йөртеп чыкты.— Әтиең иманлы кеше булгандыр, күрәсең. Хәзерге заманда...

Бригадир Ибрай буш стаканны кул аркасы белән этеп куйды да сүзгә кушылды:

— Заманга тел тидермә, агай-эне. Бәхетле заманда яшибез. Өстеңә кияргә бармы? Бар. Торыр җирең бармы? Бар. Тамагың тукмы? Тук. Хөкүмәткә рәхмәт укып, мич башында тик ят.

— Заманнан зарланган кеше юк. Аллага шөкер, өс бөтен, ачтан үлгән кеше дә юк. Барысы да җитеш, шулар янына иман да булса...

— Нинди иман кирәк сиңа тагын? — Бригадир Ибрайның Сәгыйдулла агайга ачуы чыкты.— Иман да иман. Менә мин — кырык дүртенче елны сугыштан яраланып кайтканнан бирле бригадир, шул елдан бирле — коммунист. Әллә мине дә имансыз дияр идеңме тагын? Нәрсә өчен көрәшәбез без җирдә? Коммунизм өчен. Димәк, иманыбыз — коммунизм безнең.

— Лекция укыма әле син миңа, туган. Син белгәнне мин күптән киптереп элгән. Алтмыш бер яшьлек башың белән җитмеш сигезне тутырган чал сакаллы бабаңа акыл өйрәтеп утырасың.

Искәндәр бары шунда гына Сәгыйдулланың түгәрәк пөхтә сакалына, пөхтә мыегына игътибар итте. Аның да бу бәхәскә кушыласы килә башлады.

— Мулла-мазар түгелсеңдер лә, Сәгыйдулла бабай? — Ул стаканга күрсәтеп елмайды.

— Ерма авызыңны! Менә сезнең кебек акыллы егетләр бәхетле тормышта яшәсен дип, кырык биш яшькә чаклы илнең бер башыннан икенче башына дошман куып йөрдек без.

Бригадир Ибрай, үзен яклаучы табылганга куанып, Искәндәргә яратып карады.

— Менәтерә, яшьләр бозыла, дисең, ә янәшәңдә барган бер дигән егетне күрмисең. Мондый егетләр булганда, дошманга махы биру юк!

Сәгыйдулла бабай, каршы әйтергә сүз таба алмыйча, уң кулындагы дүрт бармагы белән өстәлне тыпырдатып алды.

Купе почмагында оеп утырган Мотыйгулла, монда мин дә бар дигәндәй, иренеп кенә сүзгә кушылды:

— Ташлагыз шул юк-барны. Иман да иман. Кесәңдә бер тиен акчаң булмаса, коры иманың белән әллә кая китә алмассың. Менә минем кесәдә ошбу минутта мең тәңкә акча бар,— ул түш кесәсен иркәләп капшады,— димәк теки, ике-өч айга минем иманым бар.Ул беткәч, шул иманны эзләп тагын чыгып китәм. Йорт килешеп, көнне-төнне белмичә ике-өч ай эшлим. Эшләгәндә, авызга тамчы да алмыйм мин. Кесәмдә акчам булмаса, үземне кешегә санамыйм. Һәм шулай ук бүтәннәр дә кешегә санамый...

— Акча иманыңа әйләнгән, алайса.— Сәгыйдулла агай бу сүзләрне әйткәндә борылып та тормады. Әйтерсең ул аның белән түгел, ә тәрәзә артындагы төпсез төн диңгезе белән сөйләшә иде.

— Әйләнсен, аннан кемгә зыян? Үзем эшлим, үзем ашыйм, үзем эчәм.

— Ә кешеләр турында уйлаганың бармы соң?

— Минем турыда беркем дә уйламый бит әле...

— Хатының, балаларың турында, димим, туганнарың, дус-ишләрең, авылдашларың турында?..

— Минем беркемем дә юк.

Шулчак Искәндәрнең тизрәк шушы балта остасы Мотыйк белән ялгыз каласы, аның эч серләрен сөйләтәсе килә башлады. Ул, купедан чыгып китәргә сәбәп эзләп, якягына каранды, өске ятактагы сөлгене иңенә салып, коридорга чыкты. Коридордагы тәрәзә каршында озак басып торды, Мотыйкның чыгуын көтте. Ләкин купе ишеге ачылмады, эчтә кызып-кызып ни турындадыр бәхәсләшәләр иде. Искәндәр тәрәзә артындагы агачларга беренче күргәндәй йотылып-йотылып карады. Агачлар юл буйлап бер рәткә тезелгәннәр дә җан-фәрманга аның каршына йөгерәләр. Инде килеп җитеп, кочакка ташланам дигәндә, туктый алмыйча, яшен тизлеге белән янәшәдән генә узып китәләр. Агачлар гына түгел, юл кырыена өелгән тау-тау кар көртләре, кар астыннан башын тырпайткан чакрым

баганалары, куаклар арасыннан атылып чыккан куяннар, күктәге әллә нинди җәнлек-җанварларга охшаган болытлар да — барысы-барысы аның каршына йөгерәләр, аның кочагына керергә ашыгалар кебек. Ул җирне, табигатьне, дөньяны, тәүге кат күргәндәй сокланып, гаҗәпләнеп, яратып, күзләре талганчы, вагон тәрәзәсеннән карап барды.

Юынып купега керсә, агайлар өстәл артында чөкердәшеп чәй эчеп утыралар.

— Әйдүк, мактап йөрисең,— дип, балта остасы Мотыйк аңа үз яныннан урын күрсәтте.

Авызларын пешерә-пешерә чәй эчкән арада, бригадир Ибрай өзелгән сүзне ялгап алып китте:

— Син чыккан арада без монда ярты Европаны әйләнеп кайттык. Бигрәк озак йөрдең, әллә берәр кызның башын әйләндердең инде?

— Безнең арада иң идейный, иң иманлы бәндә Ибраһим абзагыз булып чыкты бит әле.— Сәгыйдулла бабай, хөрмәт күрсәткәнен аңлатып, өстәлдәге конфетларны аның алдына этеп куйды.— Беләсеңме нишләгән ул? Төн уртасында малаен өйдән куып чыгарган.

— Чыгардым шул.— Бригадир Ибрай гәүдәсен турайтты, иреннәре хәйләкәр елмаюдан юкарып калды.— Кыек юлдан йөрсә, тагын куып чыгарырмын.

— Кәпрәймә, үзеңне куып чыгармасын,— диде балта остасы Мотыйк һәм гөргелдәп ләззәт белән көләргә тотынды.— Син срогыңны тутыргансың, нәрсә алып кайтсалар, шуңа риза булып тик утыр.

— Мин урын өстенә калган кеше түгел әле.— Ибрай торып ук басты.— Үлем түшәгендә ятканда да рөхсәт итмәм. Күпме яшәп, минем йортыма хәрәм ризык кергәне булмады. Мин исән чакта керәсе дә юк!

— Нинди хәрәм ризык булсын ул сиңа? Малаең җир өстендә калган бәрәңгене чүпләп алып кайткан бит, колхоз амбарыннан урламаган. Ә син, бушаттырмыйча, машинасы белән фермага илтеп аударткансың. Чал чәчле башың белән уйлап кара әле: басуда калса, ул бәрәңге барыбер черегән булыр иде бит, әйеме?

Мотыйк белән Ибрай, башкаларны онытып, кулларын җәя-җәя, икесе генә сөйләшә башладылар.

— Чересен,— дип үҗәтләнде Ибрай.— Чересә, колхоз җиренә ашлама булыр.

— Ул аны көннәр буе җыйган, хезмәт куйган. Син, һич югында, аның хезмәтен хөрмәт итәргә тиеш идең.

— Кушсаң, эшләмәс иде әле.

— Ну, алып та кайтты, ди. Шул бәрәңгене малга ашатсаң, кемгә файда була? Сиңа бит. Ә син колхозныкы. Димәк ки, колхозга да файда була. Син аннан печән сорап бармыйсың. Син хөкүмәткә шул бәрәңгене ашаган сыерны сатасың, базарга ит алып чыгасың. Кайсы яктан карасаң да файда.— Мотыйк, дөрес сүзгә җавап юк дигәндәй, Ибрайның күзләренә карап торды да шопырдатып чәен эчеп куйды. Ләкин тегесе һич тә бирелергә җыенмый иде, киресенчә, аның саен үҗәтләнә генә барды.

— Сиңа нәрсә, сиңа — ике дөнья бер морҗа. Бүген монда син, иртәгә — җәһәннәм читендә. Ә мин шул нигездә туган, шунда үскән, шунда соңгы туй күлмәген киясе. Исән чакта минем яманатым чыгарга тиеш түгел. «Бригадир Ибрай малае машинасы белән колхоз бәрәңгесе кайтарып аударган»,— дисәләр, оятын кая куям мин аның? Өй саен кереп, ул бәрәңгенең барыбер басуда чериячәк икәнен аңлатып йөримме? Аңлатып булмый аны кешегә. Җилгә таралган сүзне җыеп алып булмый. Кермәсен ул хәрәм ризык минем өйгә, поты бер тиен... Безнең иман, Мотыйк туган, менә шул була инде.— Ибрай Сәгыйдулла карт ягына күз ташлады.— Сезнеке ничектер, белмим...

— Малаең ни диде соң? Аңладымы?

— Аңлатырсың аларга! Җәһәннәмеңә керсәләр дә, көлеп кенә йөрерләр...

— Шул җәһәннәм читеннән һаман кайтып җитә алган юк әле минем. Сугышка кадәр киткән идем, кайтам-кайтам туган ягыма, кырларыма-тугайларыма дигәндәй, һаман кайтып җитә алган юк. Киткән җирең ерак булгач, кайтыр җирләрең дә ераклаша икән.— Сәгыйдулла бабай авыр итеп көрсенде.— Шунда төпләнеп калдым, өйләнеп тамыр җибәрдем. Куптарылып кайтып булмады инде. И-их, күпме яшәп тә аңлап бетереп булмый бу дөньяны.

— Нәрсәсен аңлыйсың инде аның? — дип, Мотыйк сүзгә кушылды.— Барысы да ап-ачык. Эшләсәң, умырып акча аласың, акчаң булса, морҗа башына басып йөрисең. Аңладым мин дөньяның кая барганын, биш бармагым кебек беләм мин аны.

Тәрәзә артындагы иксез-чиксез басу-кырлар, урман-болыннар, вакыт артыннан калырга теләмәгәндәй, җан-фәрманга чабалар. Юл буендагы агачлар, каршыга йөге-

реп килеп, вагон тәрәзәсеннән үрелә дә, үзенә кирәкле кешене күрмәгәндәй, ары чабып китә. Баш очындагы кызлар кашы кебек нәзек ай да, болыт көртләренә чумачума, поезд артыннан калышмый йөзә. Ай нурына манылган көмеш болытлардан ак басулар өстенә талгын музыка агыла. Искәндәр, соклануын яшерә алмыйча, күзләрен күккә төбәп пышылдады:

— Айлы соната...

— Ай, дисеңме? — Сәгыйдулла бабай да тәрәзә янынарак елышты.— Һә-һәй, яңа туган ай ласа бу. Тот та хәзер үк мәчет манарасына менгереп куй.

— Авылыгызда мәчет тә бар мәллә?

— Бар, дисәң дә була, юк, дисәң дә...

Бригадир Ибрай җаваптан канәгать булмады, ахрысы, төпченә үк башлады:

— Ничек аңларга инде моны? Мәчете бар, манарасы юк, шулаймы?

— Манарасы да бар. Тик бик нык таушалган, кыегаеп аварга тора, калайлары, такталары кубып беткән. Җил чыккан саен, менә-менә авам дип ыңгыраша.

— Кеше өстенә авып, бер-бер имгәк ясаганчы, кисәргә дә төшерергә аны...

Сәгыйдулла бабай Ибрайның бу сүзләреннән соң кинәт кенә басылып, сагаеп калды.

— Ник кисмәкче буласың әле син аны? Кемгә зыяны тия аның? — дип, үз-үзенә сорау биргәндәй әйтеп куйды ул.— Төзәтергә, рәтләргә иде, диген, юньле бәндә булсаң. Минем өчен мәчет түгел ул, халыкның алтын куллы осталарына һәйкәл, архитектура истәлеге, бик беләсең килсә...

— Синең аварга торган кыек манараңның кемгә кирәге бар? Сөембикә манарасы түгел бит ул. Сөембикә манарасы галимнәргә кирәк. Алар аның кайчан салынганы турында, ничә сантиметрга авыш икәне хакында бәхәсләшәләр.

— Манарасы өчен тотмыйлар аны, халык тарихы шуңа барып тоташкан өчен, җанга якын булганы өчен тоталар.

Сәгыйдулла бабай, сүз шушының белән тәмамланды дигәндәй, дүрт бармаклы кулы белән өстәлгә таянды да тынып калды. Искәндәргә, алар сөйләгән саен, дөнья киңәйгәннән-киңәя баргандай тоелды. Моңа кадәр ул, чүп савытында казынган урам эте кебек, юк-бар уйлар белән тулы күңелендә казынган, дөньяның бәләкәй генә бер кисәген бәләкәй генә бүлмәсенә биклән, шуннан тырыша-

тырыша музыка сыгарга азапланып яткан икән. Аның өчен бу агайларның һәр сүзе моңа кадәр белмәгән яңалык ача, ул хәтта кемнең дөрес, кемнең ялгыш сөйләгәнен дә уйлап тормый, аңа һәр сүз кадерле, һәр сүз якын. Искәндәр купедагы картларга тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Балта остасы Мотыйк, ишек төбенә үк килеп, ике кулын ике тезенә куйган килеш, башын аска игән дә өнсез калган. Бригадир Ибрай өстәл җыештырып маташа, әйтерсең өстәлдә тәртип урнашкач, үз күңелендәге болгавыр уйлар да тәртипкә килер дип уйлый. Ә Сәгыйдулла абый элеккечә йотылып-йотылып тәрәзәдән карый...

Тынлыкны бу юлы Ибрай бүләргә булды:

— Яшьләрнең урын — түрдә, карт-корыныкы — гүрдә, диләрме әле? Кыеш-мыеш мәчетләрең белән яшь егетнең башын әйләндереп утырма. Яшьләр хәзер шәһәрләр сала, космоска, Алланың үзе янына менә алар хәзер.— Ул саллы кулын Искәндәрнең иңенә куйды.— Шулай бит, энекәш?

Искәндәр, ни әйтергә белмичә, елмаеп тик торды. Аның өчен җавапны Сәгыйдулла бабай бирде:

— Галәмгә менү, анысы, безнең акыл җитмәс эш инде. Шулай да кадим заманнарда ук күккә менәргә омтылган безнең халык. «Ай югары, ай югары, айга менәсем килә»,— дип җырлаганмы әле борынгылар? Мәчет манарасы салуы да шул күккә менәсе килүдән эшләнгән эштер әле ул. Аннары, сезнең игътибар иткәнегез бар микән, мәчет манарасы үзе дә ракетага ике тамчы су кебек охшаган бит ул. Менә синең игътибар иткәнең бармы, энем?

Искәндәр Сәгыйдулла бабай янынарак шуышты.

— Журналларда да язалар бу турыда.

— Ә мин үзем генә шулай уйлыйм дип йөрим тагын.

— Галимнәрнең төрлесе төрлечә фараз кыла. Хәзер кешенең килеп чыгуы турында да төрле гипотезалар йөри бит. Берәүләр Дарвин теориясен яклый, без маймылдан яралган, ди. Икенче берәүләре кеше чит планетадан килгән дип исәпли. Маймыл теориясен яклаучылар мәчет-чиркәү манараларының өскә таба очланып килүен табигать шартларына җайлашу нәтиҗәсе дип саный. Очлы манарага яңгыр үтми, төп авырлыгы аскы өлештә булганлыктан, аның ныклыгы арта.

— Дөрес уйлый, алар авылда тормаса да, каян белә

диген. Минем йортның түбәсе дә текә, текә булган саен, түбә озаккарак чыдый,— дип җөпләде аны Ибрай.

Искәндәр дәвам итте:

— Галимнәрнең икенче бер өлеше, Сәгыйдулла бабай, нәкъ менә сез әйткәнчә, манара ракетага охшатып эшләнгән, ди. Кеше хәтеренең кайсыдыр бер почмагында бабалары очып килгән ракетаның сурәте чагылып калган, имеш. Ул, үзе дә сизмичә, шул ракеталарга охшатып мәчет-чиркәүләр сала, шулай итеп, хыялында гына булса да, күккә менмәк була, имеш. Кан тарта аны, туган планета туфрагы тарта, имеш. Минем сүз түгел бу, галимнәр шулай ди.

— Галимнәр, галимнәр... Нәрсә белә алар? Хәзер әнә йортларны тип-тигез түбәле итеп җиткерәләр. Ә боларның бабалары шакмаклы башлы булганмы? — Ишек төбендә моңа кадәр сүзгә катнашмый утырган Мотыйкның авыз эченнән мыгырданганы ишетелде.— Шул галимнәрегезнең бөтенесен, бер ракетага төяп, күктәге бабалары янына йә джунглидагы туганнары катына озатыр идем мин. Җирне пычратып бетерделәр, тын алырга да һава юк хәзер.— Ул, чыннан да, һава җитмәгәндәй, буыла-буыла сулый иде. Бераз тотлыгып торгач, кесәсеннән алып, бер уч дару йотып җибәрде.— Астма минем, кем әйтмешли, Әсмабикә түтиегез бугаздан ала. Коньяк кирәк. Шуны йотып куйсаң, Әсмабикә апаңның күңеле йомшый. Ресторанга барып килмисеңме, егет? Хәлем начар...

Искәндәр, утыргыч астындагы чемоданын ачып, өстәлгә коньяк шешәсе чыгарып куйды. «Һә-әй, бөтенләй истән чыккан»,— дип сөйләнә-сөйләнә, бәйрәм табыныннан сыпырып төшергән ризыкларын берәм-берәм тезә башлады. Мотыйк абыйның башы күтәрелде, күзләре ачылып, йөзенә нур кунгандай булды. Башкаларны көтмичә, калтыранган куллары белән стаканны алып, эчеп тә куйды.

— Ярый, туганнар, минем төшәр чак та җитә,— дип башлады бригадир Ибрай.— Гаеплэп калмагыз. Ялгыш сүзләр ычкындырган булсам, күңелегезгә авыр алмагыз.

Балта остасы Мотыйкка бөтенләй дәрт керде, сулышы да күзгә күренеп тигезләнде, тост әйтергә җыенгандай торып басты.

— Минем теләк шул. Яңа елны менә дигән итеп каршы ал, малаеңа бүтән сүз әйтәсе булма. Авызыңа кергәнне төкермә, кеше авызыннан тартып алма.

Бригадир Ибрайның Мотыйк әйткән сүзләргә хәтере калды бугай, ул стаканын этеп үк куйды.

— Иркенләп сөйләшергә вакыт юк. Әйдә, минем белән төш, кунак та булырсың, честный авыл кешесенең ничек яшәгәнен дә күрерсең. Бик атаклы балта остасы да икәнсең үзең. Минем мунча да тузган... Сиңа, кайда төшсәң дә, барыбер түгелмени?

— Барыбер түгел. Сиңа мунча салганчы, кесәдәге менә бу мең тәңкәне салып бетерәсе бар әле.

Бригадир Ибрай, синең белән сөйләшеп эш чыкмас дигәндәй, кулын селкеде дә Искәндәргә эндәште:

— Ә син кайда төшәсең, егет? Бу станциядә түгелдер бит? Безнең авылга яңа ветврач киләсе, дигәннәр иде. Алай-болай шул түгелсеңдер бит?

— Юк, ул түгел...

— Сорамадык та, кая барасың соң син?

— Белмим әле.

— Ничек белмисең? Әйтәсең килмиме?

— Ерак барам, моннан күренми.

Искәндәрнең бәйләнчек сүзләргә җавап бирәсе килми иде.

— Кыркуланма әле. Бу яшьләргә авыз ачып бер сүз әйтеп булмый. Яңа ел алдыннан нинди ерак юлга чыгу ди ул? Яңа елны поездда каршы алмассың бит. Әйдә безгә! Йорт станциягә терәлеп кенә тора минем. Бәйрәм итәрбез, теләсәң, иртәнге поезд белән үз юлыңа китәрсең. Билетын үзем алып бирермен. Аңа гына калмаган. Әйдә, чынлап, төшәбезме? Нигәдер якын иттем мин сине. Билетың кая хәтле алынган соң?

— Карамадым. Соңгы станциягә хәтле, дигән идем кассирга...

— Кемең бар соң анда?

— Беркемем дә...

— Мине җүләргә санама.

Балта остасы Мотыйк бригадир Ибрайның төпченүен ошатмады бугай, авыз кырыен сыпырып куйды да теш арасыннан сүзләрне сытып кына әйтеп куйды:

— Тинтерәтмә егетне. Төшәсең икән, җыена башла. Һәркемнең үз станцасы...

— Әле ярты сәгать вакыт бар минем.

Алар сөйләшә калды. Искәндәр, буфетка барып килү нияте белән, җил-җил атлап, купедан чыгып китте.

Күрше вагон ишеген тартты — ачылмады. Ишек бик-

ле иде. Вагоннар тоташкан аралык бик каты чайкала, Искәндәр бер мәлгә үзен ат өстендә чапкан җайдактай хис итте. Җайдак чабу да ардырды, ә ул һаман ишек төбеннән ары китә алмады. Искәндәр, аптырагач, боз каткан ишек пыяласын сулышы белән өреп җылыта башлады. Пыялада түгәрәк күз ясалды, һәм күз алдында дулкынланып төшкән коңгырт чәч пәйда булды. Бу чәч төсе гаҗәп таныш иде аңа. Ул ашыга-ашыга тагын боз тәрәзәгә сулышын өрде: чәч дулкыннары кызның иңнәренә төшеп ятты. Нәкъ аның чәче кебек...

* * *

Имтиханнарны тапшырып бетергәч, алар, группалары белән җыелышып, саубуллашу мәҗлесе үткәрергә булдылар. Мәҗлескә читтән дә дус-ишләр чакырылган иде. Искәндәрнең урыны өстәл янында Фидан белән янәшә туры килде. Фиданны һәрвакыттагыча тамада ясадылар. Ул сөйли дә сөйли, кулларын җәеп мактый-мактый кешеләргә сүз бирә, ә Искәндәр, терсәге белән бәрелер дип, аның һәр хәрәкәтеннән сискәнеп китә. Искәндәрнең күзләре өстәл түрендә Рүдәл белән янәшә утырган кызда. Иңбашларына агып төшкән чәч дулкынында коенып утыручы кыз исә Фиданның авызына караган да тораташ булып хәрәкәтсез калган. Ул Рүдәлне дә, мәҗлестәге башка кешеләрне дә күрми, берни дә ишетми сыман. Фидан моны сизә, сизгән саен ныграк сүзчәнләнә бара, аңа ошарга тырыша.

Хәмит баш җитмәс физик формулалар кыстыра-кыстыра сөйли башлагач, кыз карашын аңа күчерде. Хәмитнең озын төз гәүдәсе, җөмлә әйткән саен, тагын бер яңа фикер суырып чыгаргандай, башын капыл гына артка ташлап куюлары, вакыт-вакыт туктап, «шулаймы?» дип сорау бирүләре кызның күңеленә хуш килде, ахрысы, ул Рүдәлнең колагына иелеп нидер пышылдады. Аннары, Рүдәлгә битараф караш ташлаганнан соң, аңа җилкәсе белән борылып утырды.

Интизар торып баскач, аның гәүдәсенә сыланып торган соңгы мода белән тегелгән костюмына, кардай ак күлмәгенә, якасына кунган кара күбәләгенә, бармагындагы имән чикләвеге кадәр кашлы йөзегенә карап, мәҗлестәге барча кыз өнсез калды. Ул авызын ачса, аның

авызыннан алтын сүзләр генә коелыр сыман иде. Дулкын чәчле кыз аңа йотардай булып карап торды, костюмының һәр җебенә кадәр өйрәнеп чыкты.

— Мин сезгә бер кызык хәл сөйлим,— дип башлады Интизар.

«Кызык» диюгә үк, кызлар дәррәү елмаешып куйдылар.

— Көннәрдән бер көнне бер профессорның «Волга»-сын урлаганнар. Милициягә хәбәр итә бу. Көне буе эзлиләр, машинаны таба алмыйлар. Кич гаражына чыгып караса, «Волга»сы, елык-елык килеп, үз урынында тора. Бер җире имгәнмәгән, сыдырылмаган, көзгеләренә, «дворник»ларына хәтле исән. Машина эчендә дә бар нәрсә исән-сау. Алгы утыргычта театрга ике билет һәм бөкләнгән кәгазь ята. Кәгазьдә мондый сүзләр язылган: *«Хөрмәтле профессор, машинагызны алып торган өчен гафу итегез. Безгә ул бүген сезгә караганда кирәгрәк иде. Исән-сау килеш китереп куйдык. Сцеплениесе начар аера иде. Төзәттек. Тормозыгызны да көйләдек, бензины да — бак тулы. Шулар өстенә, прокат бәясе итеп, театрга ике билет калдырабыз. Театрда премьера бүген, билетлар ике ай алдан сатылып беткән, бармый калмагыз».*

Хөрмәтле профессор, намуслы каракларга рәхмәт укый-укый, хатынын җитәкләп театрга бара. Ә кайтуына — ишеге ачык, бүлмәләре — шып-шыр. Болар театрда утырган арада, әлеге караклар квартираны чистартып чыкканнар.

Интизар мәгънәле итеп елмайды да урынына утырды. Кызлар гөрләтеп кул чаптылар. Фиданга бу ошамады. Ул, Интизарның яңа костюмына май тамызырга теләгәндәй, сорау бирде:

— Бу гыйбрәтле вакыйганың мәгънәсе нидән гыйбарәт инде, Интизар әфәнде?

— Мәгънәсеме? Аның мәгънәсе...

— ...юк,— дип, Интизарның җөмләсен очлап куйды Искәндәр.

Барысы да аңа борылып карадылар. Бу көтелмәгән борылыш Фиданга да ошады, ул, чүп арасыннан алтын тапкан сыман, бөтен карашын Искәндәргә юнәлтте.

— Акыллы кешедән акыллы сүз чыга, диләр. Интизар бик озын һәм кызыклы итеп гыйбрәтле вакыйга сөйләде. Рәхмәт аңа.

Кызлар, аптырашып, бер-берсенә карап куйдылар.

Фидан аскы иренен тешләп бераз тын торды да сүзен дәвам итте:

— Ә Искәндәр ике хәрефле бер сүз белән шул гыйбрәтле вакыйганың мәгънәсен аңлатып бирде. Дәвам ит, Искәндәр, тост әйтергә синең чират.

Искәндәр югалып калды, керфек арасыннан күз сирпеп, ташкын чәчле кызга карады. Бу юлы кызның бөтен игътибары анда иде. Ул тагын да ныграк каушады, тотлыга ук башлады. Фидан, аның хәлен аңлап, коткарырга уйлады.

— Бөекләр күп сөйләшми,— дип, Искәндәргә карап әйтте ул.— Бөекләр безнең кебек фани дөнья мәшәкатьләре белән яшәми. Аларның тормыш күктә, алар илаһи уйлар белән яши, алар поэзия телендә, музыка телендә сөйләшә. Таныш булыгыз: сезнең алда — киләчәкнең бөек композиторы Искәндәр Бикмурзин.

Өстәл астына борчак тәгәрәгән сыман, көлү авазлары коелды.

— Әйдә, Искәндәр!

Ул Искәндәр алдына баян китереп куйды. Искәндәр шунда гына гәүдәсе калтыраудан туктаганны сизде, баян каешларын иңнәренә салды да салмак кына борынгы көй уйнап җибәрде. Аны бетергәч, дәртле заман көйләренә күчте. Шул арада мәҗлестәгеләр торып басты, Искәндәрне, урындыгы-ние белән күтәреп, коридорга алып чыктылар. Бу минутта ул үзен патша тәхетендә утырган кебек хис итте, Искәндәр баян төймәләренә кагылуга, җырлар-биюләр башланды, мәҗлестәгеләргә күрше бүлмәдәге студентлар да килеп кушылды.

Искәндәр, бар дөньясын онытып, бармаклары кызыша башлаганчы уйнады. Вакыт-вакыт башын күтәреп, дулкын чәчле кызны эзләде. Ул әле Фидан белән бии, әле аны Интизар бөтереп алып китә. Рүдәл җитез биюләргә кушыла алмый, шуңа күрә вальс башланганны гына көтә дә кыз янына карчыга кебек ташлана. Ә ул берсен дә борып җибәрми, кем чакырса да, биергә чыга, очыныл-очынып бии, коридорны яңгыратып туктаусыз көлә. Аның чәчләре музыка агышына кушылып тирбәлә, дулкынланып йөзенә төшә, ул үзенең чәчләре арасына кереп адаша. Егетләр, бүтән кызларның барлыгын да онытып, аның белән биергә чират көтә, ул моны күреп, тагын да ныграк җилбәзәкләнә, музыка ташкынына ияреп, туктый алмый бөтерелә дә бөтерелә...

...Искәндәр, тырнакларын авырттыра-авырттыра, тәрәзәдәге бозны зурайтырга тырышты. Ишек тоткасын да бар көченә басып карады. Кыз аңа җилкәсе белән борылган да кем беләндер көлә-көлә сөйләшә. Ул көлгәндә, әйтерсең җир өстенә бәллүр йолдызлар коела. Искәндәр әкрен генә, кыяр-кыймас кына ишек пыяласын шакыды. Ишекнең теге ягында көлешкән авазлар ишетелде. «Кертмибез! Оҗмах ишеге бикле!» — дип кычкырды аңа ир кеше авазы. Искәндәр өнсез калды. Ишекнең теге ягында Сөмбел белән Рүдәл басып тора кебек иде...

* * *

Искәндәр, дулкын чәчле кыздан күз алмый уйный торгач, үзенең туктап калганын да сизмәде. Аның бармаклары, хәлсезләнеп, баян төймәсенә баса алмас хәлгә килгән иде. Баянны Фиданга тоттырып, оеган аякларын көчкә яза-яза, Рүдәл янына килде. Аның тирәсендә дулкын чәчле кызны күрмәгәч, кабалана-кабалана, күзләре белән кызлар арасыннан эзләде. Ләкин ул беркайда да күренмәде, ул гүя бии-бии эреп юкка чыккан иде. Искәндәр Рүдәлнең сүзләренә җавап биреп тә тормады, кешеләрне аралый-аралый, коридор буйлап китте. Беренче катка төшеп менде, коридорның аргы башыннан урады. Искәндәр тагын Рүдәл янына әйләнеп килде, ул да, якягына каранып, аны эзли иде. Турыдан-туры сорамаска җай чыкканны күреп, ул Рүдәлгә эндәште:

— Кемне эзлисең?

— Сөмбелне.

— Кемне, кемне?

— Кайда соң ул?

— Фидан үпкәләтте бугай аны. Елап, икенче катка йөгерде.

— Ә син?

— Кызлар туалетына кермәм бит инде...

Искәндәр беренче катка йөгереп төште дә урамга чыкты, кайсы якка барырга белмичә, бераз аптырап торгач, трамвай тукталышына таба китте. Тукталышта Сөмбел кулъяулыгы белән күзләрен сөртеп тора иде. Аны күргәч, кырт кына борылды. Искәндәр бер сүз дә әйтмәде, килеп кызның кулыннан җитәкләде дә тулай торакка

таба алып китте. Сөмбел каршылык күрсәтмәде, тын гына аның янәшәсендә атлый бирде.

Алар тулай торак янына килеп җиттеләр, сүзсез генә аны да үтеп киттеләр. Ике ягына өрәңге агачлары тезелгән тар сукмакка кергәч кенә, Искәндәр сүз башлады:

— Сез бүгенге мәҗлеснең королевасы булдыгыз.

— Зинһар, мәхәббәт турында сөйләмәгез, гашыйк булдым, дия күрмәгез.

— Әйтсәм, ни була? Сезгә гашыйк булмаган кеше юк иде бүген.

— Миңа түгел, үзләренә гашыйк иде алар. Һәрберсе үзен күрсәтергә тырышты. Мин алар өчен көзге, лакмус кәгазе генә идем.

— Тыйнаклык әйбәт нәрсә...

— Ә чыннан да шулай түгелмени? Бер сүз әйтәләр дә миңа карыйлар, бер сүз әйтәләр дә борылып карыйлар. Шәп әйттемме, янәсе, бу кызның йөзе үзгәрдеме? Реакциясе ничек? Син ул яктан сынатмадың, миңа күтәрелеп тә карамадың, матур сүзләр дә сөйләмәдең.

Искәндәрнең иреннәрен тутырган елмаюны төн караңгылыгы үзенә яшерде, Сөмбел аның керфекләре дымлануын да күрмәде.

— Мин бар сүзләремне музыка белән сөйләдем. Аңламадыгызмыни?

— Музыка барыбыз өчен дә уртак иде бит...

— Мин аны сезнең өчен генә уйнадым.

— Рәхмәт, бик яхшы уйнадыгыз.— Сөмбелнең сүзләре бу юлы ихлас яңгырады.

— Безнең һөнәр шул бит. Уйный белмәгән кеше юк бездә. Фиданның уйнавын ишетмәдегез...

— Бозык кеше ул...

— Нигә алай дисез?

— Анысын үзеннән сорагыз.

— Алайса, мин дә бозыктыр инде...

— ...

Алар, шәмәхә күк читендәге түгәрәк ай эреп юкка чыкканчы, шәһәр урамнары буйлап йөрделәр. Ай белән бергә аларны бер-берсеннән аерып торган еллар киртәсе дә, шикләнүләр, икеләнүләр томаны да эреп юкка чыкты.

Йокысыннан иртә уятканга үпкәләгән малай сыман, кызарынган йөзен йодрыклары белән уа-уа кояш түшәгеннән торганда гына, алар, арып-талып, Искәндәрләр бүлмәсенә кайтып егылдылар. Бүлмәдәшләр кичә кани-

кулга кайтып киткән иде. Аулак бүлмәне эчтән бикләп куйдылар да, чишенмичә генә, караватка барып ауды-лар.

Искәндәр күзләренә төшкән кояш яктысыннан уянып китте. Караватны шыгырдатмаска тырышып, Сөмбелгә таба борылды. Аның чәчләре мендәргә таралып төшкән, күлмәк изүләре ачылган. Искәндәр, үз-үзенә исәп бирмичә, Сөмбелнең кояшлы иреннәренә капланды. Сөмбел, татлы төш күргән сыман, күзләрен ачмыйча гына, Искәндәрнең башын кочагына алды. Искәндәр аның керфекләрен, яшьле күзләрен үпте, чигәләрен, колакларын, борынын үпте, иреннәре белән муенын иркәләде, күкрәкләренә кагылды. Сөмбелнең йокылы тәне әкрен-әкрен уяна барды, аның тәнендәге калтырау Искәндәргә күчте. Ул бер җилкенүдә күлмәген салып ыргытты. Егерме биш ел буе сусыз чүл кичеп әлсерәгән күңел сусавын басарга теләгәндәй, Сөмбелгә сарылды, аның башыннан сыйпады, иңнәреннән сыйпады, биленнән сыйпады... Сөмбел, башын артка ташлап, күзләрен чытырдатып йомды, аның калтыранган иреннәреннән бары бер сүз генә пышылдап чыкты:

— Ис-кән-дәр...

Искәндәрнең иреннәре аның иреннәренә капланды.

Алар гүя котырынган диңгез уртасында калган кечкенә көймәдә чайкалалар иде. Дулкын көймәне әле аска, әле өскә бәрә, дулкын яшь тамчысы булып битләргә сибелә, дулкын: «Яра-там, я-ра-там!» — дип өзлексез пышылдый.

Шулчак диңгезнең астын өскә китереп күк күкри. Искәндәр, ни булганын аңламыйча, чытырдатып көймә кырыена тотына. Күк тагын күкри. Күк күкрәгән саен, диңгез тына бара, дулкыннар әкренләп басыла-басыла да дөнья тып-тыныч булып кала. Искәндәр күзләрен ача. Сөмбелнең яшьле күзләрен күргәч, аны ничек юатырга белмичә, үзалдына бер үк сүзләрне кабатлый башлый:

— Син минеке, син ми-не-ке, син ми-не-ке ге-нә... Мин сине беркемгә дә бир-мим!

Тагын күк күкри. Бу юлы күк күкрәве якында гына, ишек артында гына ишетелә.

— Кем кирәк? — дип, җан ачуы белән кычкыра Искәндәр.

— Сөмбел андамы? — Рүдәлнең тавышы күк күкрәүнең зәгыйфь кайтавазы булып ишетелә.— Ач ишекне,

ач, үтерәм,— дип, ике кулы белән дөбердәтә ул.— Ач, кертегез!

— Кертмибез! Оҗмах ишеге бикле! — ди аңа Искәндәр.

— Сөмбел! Син андамы?

Сөмбел аңа җавап бирми.

— Ач, Сөмбел, үтенеп, ялварып сорыйм, ач!

— Ачмыйбыз! Оҗмах ишеге бикле! — дип кабатлый Искәндәр.

* * *

Сентябрьдә институтка җыелгач, егетләр арасыннан Искәндәр белән исәнләшүче булмады. Ләкин аның моңа исе китмәде, ул әле ялгызлыкның нәрсә икәнен белми, ул әле бәхетле иде. Шул көнне алар Сөмбел белән загска гариза илтеп бирделәр.

* * *

Искәндәр тамбур ишеген ике куллап төяргә тотынды.

— Ачыгыз! Ачыгыз! — дип өзгәләнеп кычкырды ул.

Ишек артындагылар аңа игътибар итмәделәр, көлә-көлә сөйләшүләрендә булдылар.

Ул ачу белән ишеккә тибеп куйды да кире үз вагонына керде. Күзенә ак-кара күренмичә барганда, ачык ишектән аңа эндәштеләр. Искәндәр туктап калды.

— Купеңны үтеп барасың бит, кая ашыгасың? — Авызы колагына җиткән Мотыйк аны җилтерәтеп купега алып керде.— Булдымы, алып кайттыңмы?

— Нәрсә?..

— Булуына үзем дә ышанмаган идем, кирәк чагында әйбер табып буламыни? Борчылма син, без монда чарасын күрдек инде. Итәк асты дәүләте яшәсен.

Искәндәр күзләрен бер ачып, бер йомды. Ул әле генә тулай торак бүлмәсендә иде, аны Сөмбел кочагыннан каерып алдылар да тып итеп монда төшереп утырттылар.

— Чабыштан кайткан ат шикелле мышныйсың, әллә артыңнан куа килделәрме? — Бригадир Ибрай, утыргыч астындагы чемоданын ала-ала, үзалдына сөйләнде: — Сөлек кебек егетләр шәһәрдә әрәм булып ята бит. Шәһәрнең холкы кырыс аның, шәһәр синең җелегеңне суыра-

суыра да, кирәгең беткәч, чыгарып ташлый. Авылда алтын бәясе булыр иде сиңа.

— Һәр тавык үз кетәклеген мактый,— дип бүлдерде аны Мотыйк.— Яшь чагында кеше дөнья гизәргә тиеш. Яшь кешегә туган җир якын түгел, торган җир, йөргән җир яхшы.— Ул башын тыгып купе ишегеннән карады.— Нишләп килеп җитми соң әле бу? Бригадир Ибрай абзасын озатырга өлгерми бит, каһәр.

— Минем өчен булса, борчылмагыз. Мин үз өемә кайтып җиттем. Миңа шуннан ары берни дә кирәк түгел.

Ул чемоданын куеп саубуллашырга кул сузганда, купега проводница хатын килеп керде. Итәк астыннан алып, сүзсез генә, Мотыйкның кулына коньяк шешәсе тоттырды. Учындагы бөгәрләнгән акчаларны сузды. Мотыйк аның кулын кире этәрде.

— Кирәк түгел, монысы өчен дә рәхмәт.

Проводница хатынның йөзе кояш төсле балкып китте. Ул кат-кат иелә-иелә, арты белән чигенеп, ишектән чыкты. Бригадир Ибрай авызын ачкан килеш катып калды, аннары, лып итеп, утыргычка иңде.

— Ай-яй-яй-яй! — дип, бугаздан сызгырып чыккан тавышы белән озак сузып торды ул.— Ай-яй-яй-яй!

Аңа күтәрелеп карауччы булмады, һәркем үз уе белән мәшгуль иде. Искәндәр ишек төбендә нишләргә белмичә таптанып тора, Сәгыйдулла бабай тәрәзәгә текәлгән дә бар халәте белән төн караңгылыгына кереп чумган, Мотыйк өстәл тирәсендә әвәрә килә. Ул, стаканнарга коньяк салып, һәркемнең алдына кабымлык тезеп чыкты да шат аваз белән дәште:

— Рәхим итегез! — Аның башкаларга сүз бирергә исәбе юк иде бугай, туктамый сөйләнүендә булды: — Безнең дүрт кешелек җәмгыятьтә ул иң акыллы, иң иманлы, иң тәүфыйклы, иң гадел кеше иде. Әгәр дә һәр җирдә шулай дүрт кешенең берсе әүлия булса, бик җиткән. Артыгы белән җиткән. Бригадир Ибрай абыегыз ул — Җир кешесе, ул үзенең бәхетен шушы Җирдән эзли, шуннан таба да. Ә без нәрсә? Менә Сәгыйдулла картны алыйк инде... Бу Алла бәндәсе җәһәннәм читенә китеп оялаган да үткәне белән бүгенгесе арасында киләп сарып йөреп вакыт уздыра, тәне — анда, җаны монда аның. Җаның үзең белән булмагач, бәхет тү-тү инде ул. Ә бу егет кая барганын, нәрсә эшләгәнен дә, димәк ки, нәрсә өчен, ни өчен яшәгәнен дә белми. Аның тамыры юк, аны җил

очыртып йөртә. Ә монысы,— ул күкрәгенә сугып куйды,— монысы, үз җанына урын таба алмыйча, авыл саен күчеп йөри. Бу авылда туя башласалар, икенчесенә китә, анда да берәр кырын сүз ишетсә, тагын ары китә. Күңеле яралы аның, авыр сүзне күтәрә алмый ул. Әйдәгез, җирдәге иң бәхетле кеше өчен! Бригадир Ибрай абзый өчен күтәреп куйыйк әле моны!

Балта остасы Мотыйк Ибрайны кочаклап алды, аның күзләреннән ике бөртек яшь сытылып чыкты. Тегесе, аңышмыйча, аптырап карап торды. Алар беравыкка купеда башка кеше барын да оныттылар. Сәгыйдулла бабай стаканга кагылмады, миңа җитте дигәндәй, кулын күкрәгенә куйды да, аякларын бөкләп, утыргычка менеп утырды. Искәндәр кулларын әле кесәсенә тыкты, әле пинжәк астына кыстырды. Шунда гына, учында тирләп беткән кәгазь акча барын күреп, аны Мотыйк абзыйга сузды.

— Ишек бикле, ачмыйлар...

— Вакланма! — дип, Мотыйк аның кулын этәрде.— Вакланма! Акча бездә бер букча ул. Барыбер эчеп бетерәм мин аны. Син — юл кешесе, ал, кирәге чыгар. Үз авылында бер эт тә сәлам бирми торган Мотыйк абзаңны җир читенә җиткәч, искә алырсың. Мә, ал! — Ул, сөрлегеп, егыла язды.

Искәндәр Мотыйкны иплән кенә урынына утыртты да, сиздермичә генә, акчасын аның түш кесәсенә тыкты.

— Ай-яй-яй-яй! Ай-яй-яй-яй! — дип сөрән салды шулчак бригадир Ибрай.— Ай-яй-яй-яй! Акыллы кешедә — акыллы акча, юләр кешедә — юләр акча, дип юкка әйтмиләр икән. Уңга-сулга чәчә башлады бу миллионер. Ай-яй-яй-яй! Егерме бишлектән сдача алмады! — Ул, башын чайкый-чайкый, шул сүзләрне берничә мәртәбә кабатлады.— Ай-яй-яй-яй! Бер коньякка егерме биш тәңкә бирде! Егерме бишлектән сдача алмады!

Поезд, карурманга кереп адашкан юлаучы сыман, йөрешен акрынайтты да, алда төн караңгылыгыннан башка берни дә күрмәгәч, туктап калды. Бригадир Ибрай купедагылар белән тиз-тиз саубуллашты, бары Искәндәрнең кулын гына озак кысып торды.

— Ният итсәң, кил безнең якка. Бөтенләйгә кил. Каңгырып йөрмә болай. Муеның булса, камыты табылыр. Сорамадым да, бер-бер һөнәрең бармы соң синең?

— Музыкант мин.

Бригадир Ибрай, кызганган сыман, аңа моңсу караш ташлады.

— Әйтәм, бик моңлы бала күренәсең... Нигә бу кадәр күңелгә якын әле бу егет, дип, юл буе уйлап килдем. Үзем дә гармунчы бит мин. И-их! Һөнәрең катлаулы икән шул. Безнең тавык кетәге чаклы авылда оя табылмас шул сиңа.— Ул, сөйләнә-сөйләнә, коридор буйлап китте, Искәндәр аны озата барды.— Безгә тракторчы, комбайнчы, сыер савучы кирәк. Безнең авылга күңелең ятмас шул синең. Юкка кыстадым төшәргә, безнең станция кулай булмас шул сиңа. Ары барам, дисең инде, алайса?

Искәндәр, әйе дигәнне аңлатып, башын какты.

Бригадир Ибрайның чыгып киткәнен әле генә аңлап, алпан-тилпән килә-килә, коридорга Мотыйк чыкты.

— Сау бул! — дип, коридорны тутырып кычкырды ул. Тавышка купе ишегеннән проводница башын чыгарды. Кем икәнен күргәч, ачуланырга әзерләнгән авызы, елмаюга күчә алмыйча, тотлыгып торды.— Сау бул! Малаеңа сәлам әйт! Брат братның көтү көткәненә рад... Ике бармак арасына ит үсми... Шушы сүзнең кайсы дөрес икәнен белсә, кеше чыгар аннан. Мотыйк абыең әйтте диген.— Ул, хәле бетеп, стенага сөялде.— Мунчаңны салдырмый тор, менә бу мунчаны салып бетергәч,— ул кесәсенә төртеп күрсәтте,— килермен. Авылыңның исеме ничек?

— Камышлы Күл. Бригадир Ибрайны сорарсың.

— Курыкма, күп алмам... Мал бетерә башларны...— Балта остасы Мотыйк, җырлый-җырлый, купега кереп китте.

Бригадир Ибрай, сөйләнә-сөйләнә, вагон баскычыннан төште:

— Ай-яй-яй-яй! Ай-яй-яй-яй! Егерме бишлектән сдача алмады. Ай-яй-яй-яй, егерме бишлектән, егерме бишлектән сдача алмады бит!

* * *

Поезд кузгалгач кына, Искәндәр кинәт уянып киткәндәй булды. Ашыга-ашыга килеп, проводницаның ишеген шакыды.

— Ресторанга бармакчы идем, күрше вагонга узып булмый, ишек бикле.

— Күрше вагон өчен мин җавап бирмим.

— Ачыгыз инде, үтенеп сорыйм, ачкычыгыз ярый бит.

— Минем ачкыч кая ярамас.— Проводница ишекне шыгырдатып ябып куйды.

Искәндәр ишек төбендә бераз аптырап торды да, үз купеларына кереп, Мотыйкны култыклап алып килде. Ул, эшнең нәрсәдә икәнен аңламыйча, проводница каршында чайкалып торуында булды. Проводница мул авызын тутырып елмайды да, ачкычларын шылтырата-шылтырата, Искәндәргә эндәште:

— Бара тор, хәзер килермен.

Искәндәр, атлый-йөгерә килеп, тамбурга керде. Ишек пыяласындагы күз томаланган, ул, иреннәрен түгәрәкләп, зәңгәрсу бозга җылы сулышын өрде. Күз ачылды, ләкин тамбурда дулкын чәч күренмәде. Анда кемнәрдер арлы-бирле йөриләр, кычкырып сөйләшәләр, ара-тирә көлешеп алалар. Искәндәр, сагаеп, аларның сүзләренә колак салды.

— Урлап алган малда бәрәкәт юк анда,— диде ир кеше тавышы.

— Керәм дигән бәхет тешеңне сындырып керә ул,— дип җавап бирде аңа икенчесе.

— Кеше өлешенә керергә ярамый. Һәркемне үзенә дигән бәхете көтеп тора. Эзлә, тап ул бәхетне. Ә кеше бәхетенә кызыгып, көнләшеп йөрмә, аның бәхетен тартып алырга да тырышма. Үзеңнекен тап.

— Кеше бәхете белән бәхетле булып булмый.

Аларның сүзләре аңа нәрсәсе беләндер бик тә таныш сыман иде...

Туйга чакырып та килмәгәч, шактый вакыт узып, онытыласы үпкәләр бераз онытылгач, Искәндәрләр группадагы иң якын кешеләрне генә аерым җыярга булдылар. Сөмбел кунакларны үзе чакырды. Рүдәлдән башкалары барысы да килделәр. Мәҗлес башында сүзне сүзгә ялгый алмыйча шактый озак аптырап утырдылар. Торабара телләре ачылды. Бүлмә хуҗасының иске пианиносы да бар иде, бераздан шул якка күчтеләр.

— Мин уйнамыйм, тарих үзе уйный монда,— дип, Фидан пианино капкачын ачты да уйный башлады. Искәндәр, беренче ноталар яңгырауга ук, өнсез калды.

«Сөмбел» дигән көйне уйный иде ул. Искәндәрнең бу көендә Сөмбелнең бар дөньясын онытып очына-очына би-

юләре дә, трамвай тукталышындагы моң тулы сораулы күзләре дә, тулай торак бүлмәсендә кояшлы иреннәре белән пышылдаган мәхәббәт хисләре дә, түбәләре ай нурына манчылган өрәңге агачларының аларга сөйләгән мәңгелек серләре дә бар иде. Фидан уйнаганда, Искәндәрнең йөрәге, уч төбенә кыскан кош баласы кебек, талпынып-талпынып типте, битләре, колак очлары кызарды. Мәҗлестәге кешеләрнең барысы да аның уй-хисләрен, теләкләрен, өметләрен беләләрдер кебек тоелды. Әйтерсең шушы минутта аның йөрәген суырып алганнар да, учларына салып, әйләндерә-әйләндерә карыйлар иде.

Сөмбел, күбәләк төсле, уртага җилпенеп чыкты да музыка агышына ияреп бөтерелә башлады. Аның белән бергә Искәндәрнең бар хисләре, уйлары, хыяллары да бөтерелде. Туй көнне, башын аска иеп, оялчан елмаю артына яшеренеп утырган Сөмбел бүген яңадан үз стихиясенә кайткан, бераз ял итеп алганнан соң, күккә күтәрелгән күбәләк сыман, ирекә чыккан иде. Интизар томырылып карап торды-торды да түзмәде, биек үкчәле туфлиләре белән фырт атлап Сөмбел янына килде. Музыка өермәсе аларны шундук күтәреп алып китте. Интизар берничә тапкыр бөтерелүгә, аларны Хәмит килеп аралады... Искәндәр урыныннан кузгалмады, Сөмбелне үзенең күз карашы җылысында коендырып, музыка рәхәтеннән оеган килеш тик басып торды. Тулай тораактагы мәҗлестән соң мондый рәхәтне беренче кичерүе иде әле аның. Ул, Сөмбел белән танышкан кичәне уйлап, елмаеп куйды. Ул кичне дә мәҗлес түрендә Сөмбел бөтерелде, ул кичне дә барчасы аңа гашыйк иде.

Музыка авазлары тынуга, кунаклар кул чаптылар.

— Яшә, Сөмбел, булдырдың!

— Чып-чын балерина инде.

— Йөзеп кенә йөри, аккошмыни!

Искәндәрнең йөрәге кинәт кенә талпынып куйды да, хәлсезләнеп, уктай аска таба атылды. Ул бары тик шунда гына аларның үзе янына түгел, Сөмбел янына, Сөмбелне күрергә, Сөмбел белән сөйләшергә килүләрен аңлады. Аңлады да телсез калды. Искәндәрнең музыкасын ишетүче, аңа җылы сүз әйтүче, хәтта сүз катучы кеше дә булмады. Алар өчен гүя ул дөньяда бөтенләй юк иде. Шулай итеп, алар Искәндәрдән үч алалармы, әллә Сөмбел күзләрен томалаган, сихерләгән идеме — ул аңлый алмады.

Сөмбел, башын артка ташлап көлә-көлә, бүлмәдән чыгып китте. Кунаклар, хан кызы тирәсендәге кәнизәкләр кебек, аның артыннан иярделәр. Искәндәр, елап җибәрүдән куркып, аскы иренен тешләде дә, гасабиланган күңелен басар өчен, пианино өстенә иелде. Музыка аның күңелен әкренләп тәртипкә салды, бераздан ул бөтенләй тынычланды. Бармаклары, үзләре дә сизмичә, аның бердәнбер көен — «Сөмбел»не эзләп тапты. Бу инде Фидан уйнаган шашкын хисле Сөмбел түгел, ә киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле, мәрхәмәтле Сөмбел иде. Ул уйнаган саен, Сөмбел һаман якыная барды, менә-менә музыка пәрдәсе артыннан елмаеп, ул үзе килеп чыгар сыман иде. Ләкин Искәндәр күпме генә уйнаса да, аны чакырып дәшүче, аның янына керүче булмады. Ул мәҗлестә үзенең хуҗа икәнен дә белә, ләкин күрше бүлмәгә керергә базмый, үзен анда нигәдер артык сизә иде.

— Их, син мондамыни әле? Кунакларга кадер-хөрмәт кайда? А ну, безнең янга! — Фидан аны, сабый бала кебек кулыннан тотып, җилтерәтеп алып керде.— Карагыз әле моны! Ком-по-зи-тор! Музыкадан аерыла алмый...

Фиданның сүзенә кушылучы булмады, мәҗлес соң чиккә җитеп кызган, кунаклар берсен берсе бүлдерә-бүлдерә бәхәсләшәләр иде.

— Бәхет — материаль төшенчә түгел.

— Аның нигезендә барыбер конкрет әйбер, материя ята. Мәсәлән, машина алдыммы, димәк, мин бер көнгә генә булса да бәхетле.

— Машина алу факты бәхет түгел, машина алам дип хыялланып йөргән көннәр бәхет. Машина алгач, син бу хыялыңны үтерәсең. Хыял белән бергә бәхет тә үлә. Бәхет белән хыял кулга-кул тотынышып йөри ул.

— Машина да булдымы бәхет? — Монысын Сөмбел әйтте.

— Ә синеңчә, нәрсә ул бәхет?

— Бәхет ул — мәхәббәт.

Сөмбел, чыпчык көтүенә җим ташлаган кебек, сүзен әйтте дә туктап калды. «Чыпчыклар», очына-очына, җим өстенә ташландылар.

— Мәхәббәтнең бәхетлесе, бәхетсезе була.

— Өйләнгәнче — бәхетле мәхәббәт, аннары бәхетсезе башлана, шулаймы?

— Берең яратып, икенчең яратмаса, мәхәббәт — мәхәббәт түгел, трагедиягә әйләнә.

— Мин сине яратам, анда синең эшең юк.Теләсәң — ярат, теләмәсәң — дүрт ягың кыйбла. Мин болай да бәхетле, мин яратам — шул җиткән.

— Әтәчләнмә! Чын мәхәббәт турында түгел, идиот мәхәббәте турында сөйлисең син.

— Минме идиот? — Интизар, кызып, торып ук басты. Фидан аны җиңеннән тартып утыртты.

— Мәхәббәт һәм бәхет — икесе ике нәрсә,— диде ул. Фидан, Искәндәрнең сүзгә катнашмыйча утыруын күреп, мәҗлесне тынычландырырга тели иде.— Мәхәббәтнең гомере кыска. Мәхәббәт мизгел генә ул. Һәм аның шулай булуы яхшы да. Әгәр кеше гомере буе мәхәббәт хисләреннән айный алмый яшәсә, аның җәмгыятькә бер тиенлек тә кирәге булмас иде. Таһир белән Зөһрәне, Ромео белән Джульеттаны гына карагыз. Төннәр буе бер-берсенең күзләренә карап утырудан башка нәрсә эшләгән алар? Мондый мәхәббәтнең нигә кирәге бар, аннан кешеләргә ни файда? Яратасың икән, син җыр җырлап, музыка уйнап кына утырма, хисләреңне материаль шартлар белән дә исбат ит. Материаль дөньяда яшисең бит син, күктә түгел.

Искәндәргә бүген барысы да читләтеп кенә аның турында сөйлиләр, теге кичтә Сөмбелне алып киткәне өчен астыртын гына үч алалар кебек тоелды. Аның чигәләре сызлый башлады. Хәмит тавышын ишеткәч кенә, бәлки, монысы бүтән нәрсә турында сөйләр дип, аңа ялварып диярлек карады.

— Файдалы-файдасыз дигән сүз — мещаннар теориясе ул. Файдасы юк дип, без, синеңчә, көлмәскә, еламаска, шатланмаска, кайгырмаска тиешме? Күктәге йолдызларның безгә файдасы бармы? Ләкин алар кирәк, күңел өчен кирәк. Дөньяның чиксез икәнен, үзеңнең бик бәләкәй генә бер бөҗәк икәнеңне белү өчен кирәк.

— Бәләкәй кеше икәнемне мин болай да беләм.— Фидан Хәмитне үртәп сөйләшә иде.— Йолдыз сезгә кирәк, зур кешеләргә, озын куллы кешеләргә, безнең кул барыбер йолдызга җитми. Бәлки, шул бәләкәй булганга да, бәләкәй мәхәббәт кирәктер миңа? Бер минутлык, күп дигәндә, бер төнлек мәхәббәт.

Искәндәр, Сөмбелнең теге кичне әйткән сүзләрен искә төшереп, йодрыкларын кысты, аның ягына күз ташлады. Ләкин Сөмбел, берни булмагандай, битараф иде. Фидан сүзен дәвам итте:

— Мин айлар, еллар буе мәхәббәттән исереп йөри алмыйм. Миңа эшләргә, яшәргә кирәк. Ә бәхет, үзегез белгәнчә, эш белән генә табыла. Эш плюс мәхәббәт тигез була бәхет.— Фидан, әле генә зур ачыш ясагандай, авыз тутырып елмаеп куйды.— Ә синеңчә ничек, Искәндәр?

Ул сискәнеп китте, нәрсә әйтергә дә белмичә, ярдәм көткәндәй, Сөмбелгә карады.

— Минем... бу турыда уйлаганым юк.

— Мин болай да бәхетле диюеңме инде бу?

— Бәхет... Бәхет... бүген булмый бит ул. Бәхет йә кичә булган була, йә аны иртәгәдән көтәсең...

— Ничек? Ничек?

— Монысы өр-яңа теория түгелме соң?

— Үткәндәге иң кадерле минутны искә төшереп утырганда гына бәхетле сизәм мин үземне. Ә шул бәхетле минут үз вакытында сизелмичә үтеп киткән була. Киләчәк турында уйлаганда да, ерактагы ирешелмәс бер максатны күз алдына китерергә тырышып утырасың-утырасың да, үзеңне бәхетле итеп сизә башлыйсың. Ә шул хыял тормышка ашкач, бөтенләй бәхет булып чыкмый, бераз шатланасың да — шуның белән бетә.

— Синең теорияңә логика җитми,— дип бүлдерде аны Фидан.— Үткәнне искә төшерәсеңме яисә киләчәк турында хыялланасыңмы, иң мөһиме, син бүген искә төшерәсең, бүген хыялланасың. Димәк, син бүген бәхетле.

— Бәхетнең чыганагы минем янда юк бит, ул — үткәндә яисә киләчәктә... Мең ел элек сүнгән йолдызның яктысы бүген дә безгә нур сибеп, шатлык биреп торган кебек... Йолдыз үзе сүнгән, йолдыз үзе юк бит... Бәхетнең чыганагы юк...

— Ул синең йөрәгеңдә.— Хәмит шуның белән Искәндәрнең сүзләренә йомгак ясады.

Ләкин Фиданның туктарга исәбе юк иде.

— Бәхет турында сөйләшү — бәхетсезләр эше. Кемнең кайсы төше кычыта, шул төшен кашый. Һәркемнең бәхете үзенчә. Әнә, Искәндәр асыл кошны тәпиеннән эләктерде, бәхет кошы тотты. Аңа хәзер хыялый бәхет турында теоретик семинарлар үткәрсә дә була. Ә безгә әле җирдәге бәхетне табасы бар. Концерт беткәннән соң, гомеремдә бер генә мәртәбә булса да зал мине аягүрә басып алкышласа, бис, браво, афәрин, дип кычкырса, мин үземне гомергә бәхетле санар идем. Күпне өмет итмим мин, бер генә мәртәбә... Ә инде йөз дә беренче скрипкачы

булып, сәхнә почмагында гомер уздырганчы, урам себерүең мең артык.

— Бәхетне көтеп, сагалап торып булмый, бәхет үзе килми, аңа каршы барырга, аны көрәшеп, яулап алырга кирәк.— Искәндәр сүзгә кушылып киткәнен сизми дә калды.

— Минем кебек, дип әйтәсең киләме? — Фидан аңа мыскыллы караш ташлады.— Сөмбелне авызыгыздан тартып алдым да бәхетле булдым, ә сез, саламторханнар, авыз ачып карап калдыгыз. Шулаймы? Безгә нәрсә, әнә, Рүдәл кара көеп йөри. Синең эш җиңел, син берәр теория уйлап табып үзеңне акларсың. Материя бардан юк булмый, юктан бар булмый, бер халәттән икенче халәткә генә күчә. Сөмбел элек Рүдәлнеке иде, хәзер — минеке... Ә-ә-әй! Бәхетле кеше акланып тора димени?!

Искәндәрнең кинәт кенә өстәлне әйләндереп җибәрәсе, аларның барысын да өйдән куып чыгарасы килде. Гүя бүген алар махсус аннан көләр, аны мыскыл итәр өчен генә җыелганнар иде.

— Урлап алган малда бәрәкәт юк анда,— дип, Интизар Искәндәр күңелендә дөрләгән учакка утын ыргытты.

— Керәм дигән бәхет шулай тешеңне сындырып керә ул,— дип, Хәмит учакка бер уч су сипте.

— Кеше өлешенә керергә ярамый. Һәркемне үзенә дигән бәхете көтеп тора. Эзлә, тап шул бәхетне, ә кеше бәхетенә кызыгып, көнләшеп йөрмә, аның бәхетен тартып алырга да тырышма. Үзеңнекен тап...

— Тук-та-ты-гыз бу комедияне! — Искәндәр бар көче белән өстәлгә китереп сукты.

Барысы да, аптырап, аңа карап калдылар.

— Сөмбел, син чакырдың! Махсус оештырдың бу кәмитне.

Сөмбел бер агарынып, бер кызарынып торды-торды да аның яңагына чалтыратып җибәрде. Искәндәр, исәр кеше көлүе белән шаркылдап көлә-көлә, урамга чыгып йөгерде.

* * *

Сары күлмәкләрен аяк астына салып ташлаган каен кызларына карый-карый бар табигать тавышсыз гына елый иде. Искәндәрнең чәчләре, юешләнеп, маңгаена ябышты, күлмәге тәненә сыланды. Урамда очраган ке-

шеләр, аның җан-фәрманга йөгереп барганын күреп, борылып карыйлар, ләкин бите буйлап яңгырга кушылып аккан күз яшьләрен күрмиләр иде.

* * *

Икенче көнне Фидан аңа, берни булмагандай, ерактан ук сәлам бирде. Интизар белән Хәмит тә дустанә сөйләштеләр. Искәндәр, бик авыр имтихан тапшырган кебек, җиңеләеп китте. Ләкин Сөмбел генә шул көннән соң басынкыланып калды, аның күңел күгендәге кайсыдыр бер тәрәзәсе Искәндәр өчен инде ябык иде...

* * *

— Йокыга талмагансыңдыр бит? Нәрсә мәрткә китеп торасың?

Проводницаның гөргелдәп чыккан тавышы аның вагон-вагон булып агылучы уйларын шлагбаум кебек бүлеп куйды. Ишек ачылуга, Искәндәр тамбурга атылып керде. Ләкин анда тәмәке тартып торучы ике кешедән башка беркем дә күренмәде.

— Монда бер кыз бар иде. Зәңгәр күзле, туры борынлы бик чибәр кыз. Чәчләре дулкын булып иңенә төшкән. Күрмәдегезме?

— Үткән станциядә генә бер егет белән төшеп калды. Шуларны әйтәсеңдер инде?

— Исемен белмисезме соң?

— Кем сораган аны.

Искәндәр, сикереп төшеп калырга ниятләгәндәй, вагон тоткасына ябышты.

— Гражданин, ишекне ачарга ярамый.

Проводницаның шлагбаум төсле аклы-каралы кырыс тавышы аны айнытып җибәрде. Тәрәзә артында шалтырый-шалтырый буш товар вагоннары уза башлады.

* * *

Аның гәүдәсе кинәт кенә авыраеп китте. Ул, аякларын көчкә сөйри-сөйри, купега керде дә хәлсезләнеп

утыргычка елышты. Йөрәге, вагон тәгәрмәчләрен уздырырга теләгәндәй, ашыга-ашыга тибә, вакыт поездын узарга теләп атлыга, алгысына иде.

Әле генә шау-гөр килеп торган купе моңсулык белән тулган. Балта остасы Мотыйк башын өстәлгә салып мәлҗерәгән, Сәгыйдулла бабай, тәрәзә артындагы төпсез караңгылыкның серенә төшенергә теләгән сыман, күзләрен кысып онытылган. Күкнең куе шәмәхә төстәге түшәгенә ятып, аларны озата килүче айга карап бара торгач, Искәндәрнең күңеле дә тынычланды, уйлары тәртипкә килде. «Алар бөтенесе миңа каршы яшерен заговор оештырганнар, алар Сөмбел белән безнең бергәлекне кичерә алмаганнар. Мин, юләр, шуны да аңламаганмын. Алар һәр бәйрәм саен минем янга түгел, ә Сөмбел янына, Сөмбел белән сөйләшергә, Сөмбелне күрергә килгәннәр. Ә мин аларны һаман дус санап йөргәнмен, алар өчен кичләр буе музыка уйнаганмын, аларга бар серләремне, күңелемне ачканмын. Сөмбел шуларның барысын күреп, белеп торган, ләкин эндәшмәгән. Бәлки, шул мәҗлесләрдән яшерен бер ләззәт тә тапкандыр әле ул. Сөмбел, мине ташлап, алар белән генә калырга мөмкин түгеллеген аңлаган, аларны ташлап, минем белән бер бүлмәгә бикләнеп яшәүдән дә курыккан, бәлки, теләмәгәндер дә...

Мин шулай үз-үземә урын таба алмыйча, ике арада бәргәләнеп йөргәнмен. Киләчәк белән бүген арасында таган атынганмын... Һәм, ниһаять, бердәнбер дөрес юлны сайлаганмын: бөтенесен калдырып, үзем генә китеп барганмын».

Искәндәрнең кинәт кенә уйлары ачылып киткәндәй булды, ул еллар буе җанын газаплап йөргән сорауларга, ниһаять, җавап табуын аңлап, аһ итте. Аның анда-санда сибелеп-чәчелеп яткан уйлары, кинәт кенә бер җепкә тезелеп, вагоннар кебек бер-бер артлы тәртип белән агыла башлады. Ул үзенең, бар дөньяга кул селтәп, беренче очраган поездга утырып китүенә сөенеп бетә алмады. Әйе, бары поезд, аның йөрәгенә кушылып текелдәгән вагон тәгәрмәчләре, бераз беркатлырак, ләкин авылча хәйләкәр, авылча үҗәт бригадир Ибрай, күпме яшәп тә, җирдә үз урынын тапмаган, күңеле утырмаган сәрхуш Мотыйк, бүген белән үткән арасында йөреп, киләчәге турында кайгыртырга оныткан Сәгыйдулла бабай гына аңа тормыш мәгънәсен аңлата ала иде.

Вакытны белергә теләп, ул стенага күтәрелеп карады. Үзенең вагон купесында барганын белсә дә, ниндидер могҗиза белән борынгы сәгать тә монда килгәндер, бу бәхетле минутларны, үз гомеренең мәгънәсен аңлый башлаган минутларны шул борынгы сәгать саныйдыр кебек тоелды аңа... Ләкин стена буш иде... Шулчак дөнья тагын үзенең мәгънәсен югалткан кебек тоелды...

Сәгыйдулла бабай, тәрәзәдән аерылып, аңа таба борылды. Күзләрен хәйләкәр кыскалап куйгач, Мотыйкка төртеп күрсәтте:

— Карале моны, гел сабый бала кебек, тәмам эрегән бит. Аракы нишләтә кешене, ә?!

«Аракы» сүзен ишетеп, Мотыйк башын калкытып куйды да тагын оеды.

— Арыгандыр, өч ай эшләп кайтам, ди бит.— Искәндәрнең нишләптер аңа тел тидерттерәсе килми иде.

— Гәүдәсе түгел, җаны арыган аның. Җанына ял бирергә кирәк... Станциясен йоклап уза күрмәсен тагын.— Сәгыйдулла бабай Мотыйкның башын күтәрде.

Тегесе күзләрен ача алмыйча торды, бераздан, айнырга карар кылгандай, башын селкеде:

— Син башта шифер белән ябабыз, дигән идең, хәзер калай, дисең.

Сәгыйдулла бабай бот чабып кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Менәтерә, безнең купе түбәсен шифер белән яба башламасын бу. Әй, Мотыйгулла, идән тактасын ышкылаган ягы белән аска җәйгәнсең түгелме?

Мотыйк дерт итеп уянып китте. Үзенең кайда икәнен аңлагач, үпкәләгән кыяфәт белән бераз авызын турсайтып торды да иренеп кенә көлгәндәй итте. Сәгыйдулла бабай сүзне икенчегә борды:

— Станцияңне узып китә күрмә, дим. Шуңа уяттым.

— Сәгать ничә әле?

Искәндәр ирексездән тагын стенага күтәрелеп карады. Мотыйк авызын учы белән каплап ютәлләргә тотынды. «Вакытка суык тигән»,— дип пышылдады ул. Аннары теләмичә генә кулындагы сәгатенә карады:

— Дөрес булса, унынчы унбиш минут.

— Унбер тулганда гына барып җитәм әле мин. Аңа хәтле тагын әллә ничә ак алъяпкычлы түтәйнең эч серен бушатырга була.— Ул өстәлдәге яртылаш бушаган коньяк шешәсенә күрсәтте.— Тик... менә... сез генә булышмыйсыз. Бергә-бергә күңеллерәк булыр иде. Әллә

ошатмадыгыз инде мине? Мә, егет, алып кил әле тагын бер тутәйне.— Мотыйк күкрәк кесәсеннән иллелек суырып чыгарды.— Тарихи очрашу бит бу. Без бүтән беркайчан да менә шушылай өчебез бер поездда, бер вагонда, бер купеда очраша алмаячакбыз бит. Беләсезме, беркайчан да! Кадерен белергә кирәк...

Сәгыйдулла бабай кинәт кенә уйчанланып китте. Аннары, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, тын гына әйтте:

— Шушы көнне, шушы елның соңгы сәгатьләрендә... И-их, үтә гомер, яшисе дә яшисе иде бит әле юкса... Нигә килә бу яңа еллар? Вакыт үз көенә аксын иде ул, ә син үзең теләгән вакытта, поезддан төшеп калган сыман, аннан төшеп кал идең. Күңелең бимазалый башласа, тагын менеп утыр идең вакыт поездына. И-и-их, үләсе килми... Әле яши башларга гына исәп итеп тора идем лә...

— Үз-үзеңә ясин чыгып утырма әле.— Мотыйкның тавышы моңа кадәр ишетелмәгәнчә усал чыкты.— Үләргә җыенмыйсыңдыр бит? Авылыңда кара авызын ачып кабер көтеп тормыйдыр? Үзең кунакка кайтам, дисең... Сөенергә кирәк. Елга бер туган ягыңа кайтасың... Мине авылда көтеп торучы булсамы?..

— Көтеп торучы... Көтеп торучы... Мине кем көтә дисең? Мине көтмиләр алар, менә шушыны көтәләр.— Сәгыйдулла бабай шешә башына бармагын куйды.— Мин кайтканга иң нык сөенүче кем авылда, беләсезме? Белмисез шул. Бастырык Гыйльмулланың чатан кызы кибетче Әлфинур.

— Кибете-ние белән сатып аласыңмы әллә?

Сәгыйдулла бабай Мотыйкка җавап биреп тормады, өзелгән җөмләсен дәвам итте:

— Бер алдыма, мең артыма төшә инде шул Әлфинур. Бабасы Мәкәрҗәдән бер олау кызыл билле прәннек алып кайткан диярсең. Мин кайткан көнне яныма авылның барча ир-аты җыела, сабантуй җиткән диярсең. Ә мин, Мәкәрҗә сәүдәгәре кебек, кибет ишеген киереп ачып керәм дә Әлфинурга кычкырам: «Чыгар, үскәнем, булган малыңны!» — дим. Әлфинур башта, итәге белән сөртәсөртә, бер ярты чыгарган була, үзе минем күзгә мөлдерәтеп карый. «Чыгар әрҗәсе белән!» — дип кычкырганны көтә ул. Анысын да озак көттермим, чөнки ирләрнең күз карашы үземдә икәнне сизеп торам. «Әйдәгез, туганнар, ир йөрәге тар бүлмәгә сыямыни? Сәйрәнгә чыгыйк!» — дип сөрән салам да кибетче алдына бер уч

акча ыргытам. Ул, чатанлый-чатанлый, әрҗәсе белән китереп куя. Аны күтәреп урман авызындагы чишмә буена менеп китәбез. Кич буе, төн буе гүли урман авызы. Мине күтәреп күккә чөяләр. Таң атканчы шуларның сүзләренә оеп, онытылып утырам. Аннары, кочаклашып җырлый-җырлый, авылга төшәбез.

— Аннары, аннары? — дип кыбырсыды Мотыйк.— Аннары нәрсә булганын әйтимме?

— Әйт.

— Аннары, икенче көнне, шул ирләрнең хатыннары, өеңә килеп, беттән алып эткә салып китәләр, урамга чыксаң, артыңнан кычкырып калалар.

Сәгыйдулла бабай рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Аннары да аннары... Аннарысы кайда да бер инде аның.— Ул көтмәгәндә җитдиләнеп калды.— Үткән елны шундый бер сабантуйдан соң авыл советына чакыралар үземне. Бардым, кердем. Урын күрсәттеләр, утырдым. Сельсовет председателе: «Сәгыйдулла абый, сезнең өстән жалоба килде бит әле»,— ди. «Нинди жалоба? — мин әйтәм.— Кешегә тигәнем, кешенекен урлаганым юк. Мин монда — кунак кеше. Шул булдымы кунакка хөрмәт? Рәнҗетәсең, кем... Минҗиһан». Ә ул, усал кыяфәт алыйм дипме, әллә болай күзе начар күрүдән генәме, күзлеген киеп куйды. Аннары өстәлдәге кәгазьгә күз төшергәч, җанга үткәрердәй итеп сөйләргә тотынды: «Хатыннар өстеңнән жалоба язганнар, Сәгыйдулла абзый. Ирләрен җыясың да әрҗәсе белән аракы эчертәсең икән. Шуңа семьяда тавыш чыга, колхоз производствосына зыян килә». «Мин аларның авызларына көчләп коймыйм бит. Берсен дә кыстамыйм, эчәсе килгәне эчә, эчәсе килмәгәне — юк. Демократия...» «Син, Сәгыйдулла абый, олы башың белән демократияне аракы янына куеп сөйләмә. Гаиләне, җәмгыятьнең нигезен тәшкил иткән гаиләне, таркатуга китергән демократиянең безгә кирәге юк». «Гөнаһлы булма, Минҗиһан, нахак бәла ташлама кеше өстенә. Моңа кадәр ташлаганнары да җитеп ашкан. Елга бер күңел ачар өчен кайтам бит мин авылга. Елга бер. Ел буе эшләгән акчамны җыеп киләм. Авылыма кешечә кайтыйм, ким-хур булмыйм, дим». Шуларны әйткәч, бераз йомшады тагын үзе, күзлеген дә салып куйды. «Жалоба килгән икән, без аңа җавап бирергә тиеш»,— дип, үз өстеннән җавапны алгандай итте. «Синең үз башың бар бит, Минҗиһан»,— дим мин аңа. Шуннан соң бу тагын

кызып китә. «Яхшылап әйткәнне аңла, Сәгыйдулла абый. Акчаң күп икән, йорт салып кер, җирен бирербез. Ни әйтсәң дә, син бу авыл кешесе». «Бер киткән җиргә кире кайтулары, ай-һай, кыен...»

Сәгыйдулла, күңеле нечкәреп китүдән оялып, туктап калды, күлмәк якаларын рәтләде, пинжәк төймәләрен каптырды. Әйтерсең әле ул хәзер авыл советы председателе каршында басып тора иде. Аннары Искәндәргә карап әйтеп куйды:

— Авылда Җилпуч Сәгыйдулла дип йөртәләр иде мине элек. Элек чәчүне тубал белән чәчәләр иде бит. Миңа тубал бәләкәй тоелгандырмы, әллә таба алмаганмындырмы — хәтерләмим,— чәчү вакытында беркөнне муенга әнинең җилпучын асып чыктым. Симәнәмнең яртысы җилгә сибелә, халык бот чабып көлә... Менә шул көннән Җилпуч кушаматы ябышып калды миңа.

Мотыйк, ишек катында басып торган Искәндәрне күреп, аптырап эндәште:

— Һаман китмәдеңмени әле? Бар инде, энем, сиңа ни тора ул. Булмаса, әнә, проводницадан сора. Җир тишеgennән табып бирә алар.

— Бар бит әле. Сиңа җитәр. Без эчмибез... Мин эчмим.

— Теңкәсенә тимә әле егетнең,— дип, Сәгыйдулла бабай да аның сүзен җөпләде.

— Алайса, сөйләп бетер, тагын ниләр диде ул?..— Мотыйк ачы итеп сүгенеп куйды.

Сәгыйдулла бабай аңа карап йөзен чытты, бераз торгач, сөйләп китте:

— «Син бит тулы хокуклы совет гражданины, кайт та яшә»,— дигән була бу. Моны күргәч, минем ачу гел ныгытып кузгала башлады. «Туктале, Минҗиһан,— мин әйтәм.— Әгәр дә мин шушы авылда картаеп, шушы авылда уллар, кызлар, оныклар үстерсәм, шушында эшләп пенсиягә чыксам, Ходай кушып, почетлы колхозчы да булып куйсам, менә шул чагында шулай сөйләшер идеңме син минем белән? Чит мин сезгә, чит, ә читнең күңеле китек була аның. Ә минем шушы авыл туфрагында җан бирәсем килә. Шуңа кайтам мин, ел буе шуңа акча җыям». «Кешеләргә яхшылык эшлисең килә икән, әнә, акчаңны тынычлык фондына бир»,— ди бу. «Тынычлык фондына бөтен гомеремне бирдем инде мин. Акчасын да кызганмадык, булдыра алган кадәр бирдек. Картайган көнемдә җан тынычлыгы кирәк миңа. Бу акчамны җан

тынычлыгы фондына җыям». «Картайган көнеңдә кибет төбенә ирләр җыеп, аракы эчү дә булдымы җан тынычлыгы?» Минҗиһан, миңа төртеп күрсәтә-күрсәтә, күз яшьләре атылып чыкканчы көлде. Мин ачудан чәчрәп чыктым. Кесәдә өч меңгә якын акча калган иде, чыгарып салдым шуны өстәлгә. «Мә, мин әйтәм, иске мәчетегезнең манарасы кеше өстенә аварга тора. Турайтыгыз, рәтләгез шуны! Үлгәч, бәлки, бер искә алырлар үземне». «Әллә мулла булдыңмы? Сәдакага җыйган акча түгелдер бит бу?» — диде председатель, күзлеген янә киеп. «Мулла түгел, авылда кеше үлгәч, авыз ачып «бисмилла» әйтер кеше дә бетеп бара. Дин, дип түгел, авыл яме өчен төзәтегез. Теләсәң, музей ясап җибәрергә була. Крайны өйрәнү музее, диләрме әле? Менә шуны. Ата-бабалары ничек яшәгәнне, нинди михнәтләр күргәнне белсеннәр, бүгенге бәхетле тормышның кадерен аңларга өйрәнсеннәр яшьләр. Акча җәл түгел. Торгызып куегыз шул манараны». «Бер аягыбыз белән коммунизм бусагасына басып торган заманда авып беткән манаралар белән маташырга вакыт юк безнең»,— диде дә сельсовет председателе бүтән сөйләшеп тормады, кибет янына чыкмаска кисәтеп, кайтарып җибәрде.

— Авылыгыз тимер юлдан еракмы? — дип сорады Искәндәр.

— Алты чакрым. Нигә?

— Күренә микән дигән идем.

— Көндез күренә дә, хәзер...— Ул, чем-кара күзләрен мөлдерәтеп торгач, тәрәзәгә ымлады.— Ә син эч, безгә карама,— дип, Мотыйкка эндәште.

Сәгыйдулла бабай чемоданына вак-төякләрен тутырды да чөйдәге пальтосын алып киде. Аннары, чыгарга җыенып, чемоданына үрелде.

— Үзем күтәрәм, озата чыгам,— дип, Искәндәр чемоданны аның кулыннан алды.— Ай-һай, саллы бу, алтын тутырдыңмы әллә? Ничек күтәреп кайтырсың моны? Каршы алучың бармы соң?

— Хәбәр-мазар биреп тормадым. Эш кешесе бит алар, борчып йөрисем килмәде.

— Туган-тумача арасында борчып йөрү дигән сүз булмый инде.

Алар өчәүләшеп тамбурга таба киттеләр. Поезд, Сәгыйдулла бабайның төшәргә җыенганын сизгәндәй, йөрешен әкренәйтте. Тәрәзә артында, кара төн пәрдәсенең

сары ямаулары булып, анда-санда утлы тәрәзәләр чагылып узды. Сәгыйдулла бабай төшәр дә шул төн пәрдәсе артына кереп югалыр кебек иде. Тамбурга җиткәч, ул, рәхмәтен белдерергә теләгәндәй, Искәндәрнең иңенә кулын салды.

— Син, улым, минем өчен борчылма, мин дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше. Ничек тә югалмам. Шул алты чакрымны үрмәләп булса да кайтып җитәрмен. Шуннан ары китәр җирем дә, китәрлек дәрманым да юк минем. Менә синең юлың озын, яшисе гомерең озын. Кая барып чыгарсың? Шул турыда уйлап килдем әле мин, үзем турында түгел. Кая барасыңны да тәгаен белмисең, әллә белеп тә яшерәсең... Яшерсәң яшерерсең. Әмма ләкин кайда гына яшәсәң дә, бер нәрсәне онытма: кешеләрдән читләшә күрмә, янында якын кешең булса, берчакта да югалмассың. Әнә син, туганнар арасында борчып йөрү дигән сүз булмый, дисең. Анысы шулаен шулай. Ярый ла туганнарың булса... Авылда сыңар туганым да калмады бит минем. Тамыры корыды безнең нәселнең. Заманында өрлектәй алты егет идек. Шулардан хәзер берүзем торып калдым. Икесенең башына кулаклар җитте, өчесе Ватан сугышыннан кайтмады. Авылда кереп баш төртерлек бер туганым да калмады. Бәләкәй чакта бергә уйнап үскән дустым янына кайтып йөрим хәзер. Рәхмәт инде аңа, ачык йөз белән каршы ала, тәмле тел белән озата. Дуслар кирәк, дус-иш кирәк якты дөньяда яшәгән чакта.— Ул кинәт кенә Искәндәрнең йөзенә күтәрелеп карады.— Син нишләп болай тиктомалга күтәренеп юлга чыктың соң әле? Үзең башлы-күзле кеше дә икәнсең.

Искәндәр уң кулындагы балдагына карап куйды, нәрсә әйтергә белмичә, ык-мык итте.

— Хатыннан уңмадым, дип әйтмәк буласыңмы әллә? Хатын-кызның барысы да бер камырдан аның. Шул камырдан үзеңә ошаганын үзең әвәләп ясарга тиеш син хатынның. Шуны булдыра алсаң — синнән ир чыга, шуны эшләсәң — күгәрченнәр кебек гөлдер-гөлдер килеп яшисең, булдыра алмасаң — гомер буе иза чигәсең.

«Күгәрченнәр кебек» дигәч, Искәндәрнең күз алдына бүреген батырып кигән алсу йөзле, түгәрәк бүксәле Рүдәл килеп басты. Ул йөзен җыерды.

— Минем күгәрчен кебек яшисем килми...

— Һә-әй, онытып торам, музыкант, дип әйттең бит әле син. Сандугач нәселеннән, димәк. Ә сандугач, көз җиллә-

ре исә башлауга, җылы якка китә. Җәй җиткәч, тагын бу якка кайта. Шулай җылыдан җылыга очып, кышны күрмичә гомер кичерә ул. Шуңа күрә матур сайрый, дөньяның гүзәллегенә соклана. Ә мескен чыпчыклар, песнәкләр, тукраннар туган җир, туган ил, дип ябышып ята. Аның рәхәт чагын да, михнәтле чагын да күрә. Сандугачка караганда, туган якның чыпчыгы кадерлерәк миңа.

Проводница вагон ишеген ачты. Поезд тавышсыз-тынсыз гына туктап калды. Әйтерсең аның төн кочагына кереп оеган станцияне йокыдан уятасы килми иде.

Сәгыйдулла бабай, сул кулына чемоданын күтәргән килеш, уң кулы белән Искәндәрнең җилкәсеннән какты.

— Әй, улым, улым,— диде ул аңа яратып.— Күп гиздем мин дөньяны, төрлесен күрдем. Сиңа киңәшем шул: кайт кире семьяңа, хатыныңа кайт. Кайткан малда өмет бар, диләр.

Искәндәргә шушы станциядә аны Сөмбел белән Ләйсән көтеп торадыр сыман тоелды. Ул, башын сузып, станция ягына карады. Ләкин тирә-юнь буп-буш, тып-тын иде. Бары тик күктәге йолдызлар гына, үзләре янына чакыргандай, бер-бер артлы күз кысыштылар, сары иреннәрен тутырып, үртәгән сыман, ай елмайды.

— Хушыгыз, оланнар, гаеплэп калмагыз. Хәерле юл сезгә! — дип, Сәгыйдулла бабай вагон баскычыннан төшә башлады.

Менә ул, чемоданын җиргә куеп, як-ягына карангалады да болай да алга сөрлеккән гәүдәсе белән тагын да иелә төште. Гүя аның бу чиксез дөньяда шушы җирдән башка сыеныр урыны калмаган, гүя шуны сизенеп, Җир аны үзенә тарта иде. Искәндәр, вагон тоткасына ябышып, бөтен гәүдәсе белән алга омтылган килеш, күзләрен Сәгыйдулла бабайдан алмады. Менә ул хәл алырга чемоданы өстенә утырды. Авырлык белән кузгалды да әкрен генә атлап китте. Һәм, төн караңгылыгына чумып, юкка чыкты. Шулчак күкнең утлы күз яше җир өстенә тамып төште — йолдыз атылды.

Балта остасы Мотыйк та кинәт кенә аңына килгәндәй булды. Ул, Искәндәрне бер читкә этәреп, вагон баскычына чыгып басты.

— Сәгыйдулла абый! Ниятләсәгез, миңа хәбәр ит! Манарагызны үзем торгызырмын! Алтын куллы осталарга һәйкәл булырлык итеп эшләрмен. Шунда музей ачарсыз. Хәбәр ит! Бүтән кешегә әйтә күрмәгез! Эчмим мин,

эшләгәндә эчмим, айнык килермен. Бүтән кешегә әйтә күрмәгез! Үземне чакырыгыз! Бер тиен акча да кирәк түгел. Бушка эшлим. Хәбәр ит! — дип кычкырды ул.

Аның тавышына сәерсенгән төн, тынлыгын бүлгәнгә гаҗәпләнгәндәй, йолдыз күзләрен чекерәйтеп карап торды да ачу белән поездны алга этеп җибәрде. Вагон тәгәрмәчләре: «Кит-тек, кит-тек»,— дип пышылдый-пышылдый, алга тәгәрәделәр.

* * *

Проводница купесы яныннан узганда, Мотыйк тагын кесәсеннән акча чыгарды.

— Беткән баш бетсен, тагын берне эшлә әле! — дип эндәште ул аңа.

Искәндәр аны акча тоткан кулыннан җитәкләде дә сөйрәп диярлек коридор буйлап алып китте.

— Җитте сиңа! Кешедән оял. Күпме эчәргә була...

Проводница аңа ашардай булып карады.

Купега кергәч, Мотыйк бөтенләй мескенләнеп калды. Кулыннан уенчыгын тартып алган малай диярсең. Бераздан үпкәләве басыла төште бугай, тыныч тавыш белән Искәндәргә сүз катты:

— Әй, егет, сәгатең ничә әле?

Искәндәр, ялт итеп, стенага карады, аннары уңайсызланып башын аска иде.

— Ун туларга җиде минут күрсәтә...

— Юаштан юан чыга, диләр, шактый кыдрач күренәсең тагын. Җилтерәтеп кенә алып кердең. Киткән чакта, хатыныңны шулай җилтерәтеп алып керәләр ие аны. Менә шунда егет булыр идең. Хатын-кызның аягы китәм, дигәндә, күңеле китмим, дип әйтә аның. Катлаулы халык алар. Мин нәрсә? Мин кеше исәбеннән күптән чыккан инде. Мине кая сөйрәсәң дә була.

— Бер дә кире якка китмәгәнсең әле, үз аягың белән авылыңа кайтып барасың.

— Кая барыйм соң мин? Кешенең бер баш төртер җире булырга тиеш бит инде.

— Гомерең буе шулай буйдак булдыңмыни соң син?

— Гомерең буе...— Ул, исәнме дигәндәй, башын капшап карады.— Әгәр минем гомерне дә гомер дип булса?.. Өйләнгән идем мин. Бер кызым да бар...

Искәндәрнең чигәләре кысты, колагы томаланып, бөтенләй ишетмәс булды. Аңа Мотыйк үз язмышын түгел, юри аның киләчәге турында сөйлидер кебек тоелды.

Менә ул кулына стакан алды, үрелеп шешәне күтәрде, әле буш стаканга, әле яртылаш калган шешәгә карап торды-торды да кире өстәлгә куйды. Искәндәрнең колагы әкренләп ачылды.

— Эчмим, дисәм, эчмичә дә тора алам бит,— дип, эчке бер горурлык белән сүзен дәвам итте Мотыйк.— Эчәсе килгәннән эчмим мин, күңелемдәге бушлыкны тутырырга эчәм.

— Йортым да бар, дисең бит. Нигә соң үз авылыңа кайтып кына яшәмисең? Балта остасына колхозда эш бетмәгән.

— Нәрсә беләсең син? Сәгыйдулла бабаң хәлләре ише генәмени минем хәлләр? Аның әле кайда булса да төпләнгән бер җире бар. Ә мин кем? Бүген егылып үлсәм — беркем белмәячәк...

— Алай ук түгелдер инде.

— Алай ук түгелдер... Сугышта пленга эләктем мин. Анда күргән газапларны күз алдына китерсәм, әле хәзер дә чәчләр үрә тора. Сугыш беткәч, коткардылар. Берничә ел иза чиккәч, авылга кайтып егылдым. Җиң сызганып эшләргә, халык алдында йөз аклыгы алырга иде исәбем. Ә мине...— Мотыйк сулкылдап елый башлады. Бераздан, тынычланып, сүзен дәвам итте:— Мине авыл капкасыннан ук кара йөз белән каршы алдылар. Бәләкәй генә кыек эш эшләсәм дә, күзгә төртеп: «Сатлык җан!» — дип кычкыралар иде. Чәчү вакытында бер көн чирләп эшкә чыкмый калдым. Председатель өйгә килгән. Түшәктә ятканны күреп тора, шулай да бугаз киереп кычкыра: «Имәндәй ирләр җиңү өчен сугышта башларын салды. Әнә, бер аягы гүргә кергән картлар чәчү чәчеп йөри. Ә син өйдә иркәләнеп ятасың. Сугышта да теге якта сырт кыздырдың, монда кайткач та игелек күрсәтмисең»,— ди. Ишек төбенә барып җиткәч, борылды да, теш арасыннан сыгып: «Дезертир!» — диде. Шул минутта күз алларым караңгыланып китте. Анда да түздем. Икенче көнне, аякларны көчкә сөйрәп, басуга чыктым. Көндез хәлдән таеп буразнага егылганмын, атка салып алып кайтканнар. Башны аска иеп, телне аркылы тешләп, ике елга якын йөрдем. Өйләндем. Кызым туды. Ләкин дөньям түгәрәкләнмәде. Җай чыккан саен, пленны

искә төшереп, җанга тоз сибәләр. Шулай әкренләп салгалый башладым. Авылда әле ул чакта аракыны авызга алган кеше сирәк иде. Шулай бара торгач, кеше исәбеннән бөтенләй төшеп калдым мин. Хатын да, баласын алып, әниләренә кайтып китте. Күрше авылдан иде ул. Әни белән әти карт та дөнья куйдылар. Мин берүзем калдым.

— Ә хәзер? Хәзер ул заманнар түгел. Кайт та яшә.

— Башың яшь шул әле синең. «Бер кергән суга ике мәртәбә кереп булмый» диме әле бер философ абыең. Бер киткән җиргә дә кире кайтып булмый...

— Шунда кайтып барасың түгелме соң әле?

— Мин анда кесә тулы акча белән менә шушы ярсу аргамакка атланып кына кайтам.— Ул өстәлдәге шешәгә күрсәтте.— Югыйсә үлгәндә дә, үз аягым белән авыл капкасын атлап керә алмас идем. Ә бу алып кайта, ул бер нәрсәдән дә курыкмый. Шуңа атланып кайтам, кесә бушап калгач, кеше күзе күрмәгәндә генә ындыр артлап тагын чыгып таям аннары.

— Утырып сөйләшерлек бер кеше дә юкмыни соң авылыгызда?

Искәндәр, ник сорау биргәненә үкенеп, уңайсызланды. Чөнки шул ук сорауны Мотыйк аңа бирсә, ул үзе дә кыен хәлдә каласын аңлады. Мотыйкның тавышы аның уйларын бүлде. Күңелсез уйлардан арынуына ул үзе дә сөенеп куйды.

— Сәгыйдулла абый кебек бөтен авылны сыйлап йөри алмыйм инде мин. Бик теләсәм дә, йөри алмыйм. Минем белән эчсә, шул ике-өч алкаш кына эчә. Ә алар белән нәрсә сөйләшәсең? Аракы ипидән эшләнгәнме, әллә нефтьтәнме? Шул аларның бөтен сөйләшкәннәре.

— Берәр атна булса да айнык йөреп караганың бармы соң?

— Айнысам, үз-үземнән ояла башлыйм, бөтен кеше миннән көләдер төсле.

— Айнык баштан берәр кешегә сүз катып караганың бармы соң?

Мотыйкның йөзенә рәхәт елмаю җәелде. Ул, елмаюын озаккарак сузарга, шул елмаю нурында җылынып калырга теләгәндәй, авызын ерып торды. Ләкин торабара йөзе кырысланды.

— Моннан берничә ел элек авылга кайткач, авыру аяктан екты мине. Тән кызыша, баш чатный, укшыта — грипп булды, ахрысы. Берьялгызым түшәмгә карап тик

ятам. Тән кайнарлыгын басмасмы дип, көч-хәл белән торып су эчәм дә тагын урынга килеп егылам. Ничә көн шулай ятканмындыр, хәтерләмим, берзаман аякка баса алмас хәлгә килдем, онытыла башладым. Караватбелән төпсез чокырга кинәт кенә убылып төшеп китәм дә озак-озак итеп тагын өскә күтәреләм. «Җан бирсәм, күземне йомдыручы да юк бит»,— дип, үз-үземне тыя алмыйча җылап җибәрдем. Шулчак кемдер йомшак куллары белән яшьләремне сөртте. Күзләремне ачарга тырышам, ачылмыйлар. «Кем ул?» — дип пышылдадым. «Мин бу, күрше, Зәмзәмия»,— дигән аваз колагымда бик озак зеңләп торды.

Бер атна янымнан китмәде ул, сабый баланы караган кебек карады. Тир белән манма булган күлмәк-ыштаннарыма хәтле юды, мәтрүшкәле чәйләр кайнатып эчерде, көчли-көчли ашатты. Бераз хәл алып, тирә-юньгә күз ташласам, шаккаттым: инде ничә ел су тимәгән идәннәр ялт иткән, саргаеп, акшарлары кубып беткән мич, ярәшелгән кыз сыман, балкып көлеп тора, тәрәзә кашагалары күз явын алырлык! Башта үз өемне үзем танымый тордым, кемнәргәдер кертеп салганнардыр, дип уйладым. Зәмзәмиянең кулын кысканмын да җибәрмим генә икән. «Нишләвең бу, Мотыйк абый? — ди ул, миңа аптырап-гаҗәпләнеп карый.— Кулны авырттырасың ла... Каян килде сиңа бу кадәр көч? Үзең чирле...» — Үзе сөйли, бахыр, үзе көлә. Аннары такмаклый-такмаклый биергә үк тотынды: «Терелде, терелде, Мотыйк абый терелде!» Рәхмәтемне ничек белдерергә дә җай тапмыйча, тик ятам шунда, урында. Ниһаять, телем ачылды. «Ничек керәсе иттең, Зәмзәмия? — мин әйтәм.— Нинди фәрештәләр колагыңа изге сүз пышылдады?» — дим. Ул, күзләрен хәйләкәр уйнатып, озак уйлап тормыйча гына әйтеп салды: «Кызганам мин сине, Мотыйк абый. Шуңа кердем. Күңелем сизде. Элек ике-өч айсыз китми идең бит. Ә бу юлы бер айдан юкка чыктың. Бер-бер хәл булды микән әллә, дип кердем. Шикләнә калдым. Шуңа кердем. Чирең бик көчле, больницада ятып чыгасыңмы әллә, Мотыйгулла абый?» «Рәхмәт, Зәмзәмия, рәхмәт,— дип, аның кулларыннан сыйпадым.— Син кермәсәң, якты дөнья белән саубуллаша идем». «Син үзең дә, мин авырган чакта, янымнан китмәдең бит. Менә, әҗәтемне түләдем»,— диде ул, моңсу гына. Шул сүзләрне әйтте дә, күңелендәге олы кайгысы уянгандай, сыгылып төште. Аннары, саубуллашмый-нит-

ми, тиз генә чыгып китте. Шуннан соң күргәнем булмады аны. Авылдан китеп, төзелешкә эшкә урнашкан, диделәр. Шәһәр сала башладылар бит бу якларда...

— Нигә җибәрдең соң аны? Тотарга да шуңа өйләнергә иде...

Искәндәрнең сүзләре Мотыйк абыйга ошамады, ул аяк астына төшкән шешә бөкесен ачу белән тибеп җибәрде.

— Тотарга да өйләнергә... Сез генә хәзер биш минутта көйләнеп, ун минутта өйләнеп куясыз. Аннан, алга-артка карамый, шул хатынны ташлап качасыз.

— Ә син үзең? Кешегә гаеп ташларга барыбыз да оста. Үзеңнеке күренми.— Искәндәрнең тавышы калтырап чыкты. Ул үз-үзен көчкә тыеп калды.

— Миңа тимә син, егет. Мин күргәнне күрсәң, хатыннан гына түгел, якты дөньядан да китеп барган булыр идең. Хатын хәзер дә чакырып тора. «Кил, эчүеңне ташласаң, менә дигән итеп яши башларбыз. Бала хакына кил, аны ятим итмик»,— ди.

— Нигә бармыйсың соң?

— Кызымнан оялам.

— Үз кызыңнанмы?

— Үземнекеннән шул. Кешенеке булса, оялмас идем. Уналты ел буе синнән башка ятим үссен дә, кеше булып җиткәч кенә, туп итеп ничек килеп керим мин анда? Менә, этиең мин булам инде, үзгәрәм, эчүемне ташлыйм, акылга утырам, кабул гына итегез, дип әйтимме? Мин аны карап үстерергә, акыл-киңәш бирергә, аңа таяныч булырга тиеш идем бит. Ә хәзер үзем алардан таяныч эзлимме? Юк, кайта алмыйм мин анда, мескен булып кайта алмыйм. Үткәнгә кире кайтып булмый икән ул...

Купе ишеге шыгырдап ачылып китте, аннан проводницаның тулы гәүдәсе күренде. Ул Искәндәргә көйдереп карап куйды да ягымлы тавыш белән Мотыйкка эндәште:

— Йоклап кала күрмәгез, дип керүем. Сезнең станциягә җитеп киләбез.

— Сизелмичә дә калды,— дип көрсенде Мотыйк.

Проводница күпме юл йөреп башына килгән иң зур фәлсәфи фикерен әйтми кала алмады.

— Гомерең дә шулай үтеп китәр, сизми дә калырсың...— Аннары капыл гына шешәгә төртеп күрсәтте.— Тагын кирәк түгелме?

Искәндәр, кирәк түгел дигәнне аңлатып, башын селкеп куйды.

Проводница аңа ялт итеп карап алды да кырт кисте:

— Кешедән алдан сикермә, синнән сорамыйлар.

— Берне китер, авылга кайткач, төн үткәрергә кирәк бит әле. Яңа елны каршы алырга. И-их, калсын иде бөтен хәсрәт-кайгың шушы иске елда. Аяк киемеңне салып кергән кебек, бар борчуларыңны калдырып керсәң икән ул Яңа ел бусагасы төбендә. И-их!

Искәндәрнең проводница сүзләренә кәефе кырылган иде, тәрәзәгә таба борылды да тын калды. Мине ташлап китмәгез, дигән сыман, ай һаман поезд артыннан йөгерә, барган уңайлый ул агачларның ябалдашларын ап-ак куллары белән сыйпап уза, үз янына чакырып, вагон тәрәзәсеннән күкнең түренә хәтле көмеш сукмак салып куя.

— Булдымы?

Искәндәр, проводница кергәнен сизсә дә, борылып карамады.

— Үземә дигән берәү генә бар иде. Яхшы кешегә берни җәл түгел.— Проводницаның кыштыр-кыштыр кесәсенә акча тыкканы ишетелде.— Ну, егетегез усал сезнең,— диде ул, чыгып барышлый. Аның тавышы бераз җылына төшкән иде.— Моның белән торган хатынга Алла түземлек бирсен.

— Тимә син аңа. Әйбәт егет ул. Аның белән ерак барасы әле сезгә. Кыерсытма, тел тидермә аңа. Мә тагын...— Мотыйк проводницаның учына тагын бер кәгазь акча төртте.— Сиңа нәрсә, синең эшең шул, сине акча йөртә. Ә моны язмыш куалый, йөгәненнән тотып тыя алмасаң, язмыш әллә кайларга илтеп ыргыта ул сине. Ирек кенә бир аңа...

Проводница ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

— Күңел бик нәзберек икән синең, егет,— дип эндәште Мотыйк.— Һәр әйткән сүзгә авыз турсайта башласаң, иренең кабартма булыр. Төкер син аларга.

— Аларның һәрберсенә төкереп йөрсәң, төкерегең җитмәс.

Мотыйк шаркылдап көлеп җибәрде, Искәндәр янына күчеп утырды, аны кочаклап алды.

— Үз улым кебек,— дия-дия, аркасыннан сөйде ул аның.— Төштә кызымны һаман бишектә елап яткан килеш күрәм. Минем өчен һаман шул мәм-мәм сорап яткан елак кыз әле ул. Аның шундый чагын гына күрдем бит. И-их, урам буйлап җитәкләп йөрергә, мәктәпкә озата барырга, икеле алып кайткач, юри генә ачуланырга

иде бер үзен! Бергәләп киноларга йөрергә, бәйрәмгә яңа күлмәк алып бирергә иде!

Искәндәр аның сүзләренә кушылмады, бу минутта ул, күңеле белән Ләйсәнне җитәкләп, шәһәр урамыннан бара иде. Ләйсән кибет тәрәзәсенә төртеп күрсәтә, алар эчкә керәләр дә кочакка сыйган кадәр курчаклар, китаплар, уенчыклар төяп чыгалар, аннан, авыз кырыйларыннан тамыза-тамыза туңдырма ашыйлар. Ләйсән урам читендәге афишага карауга ук, ул аны сүзсез аңлый, алар, бер-берсенең авызына карап көлешә-көлешә, кинога керәләр. Залда ут сүнә, Ләйсән, караңгыдан курыккандай, этисенә сыена, ул аны кочагына ала.

Мотыйк белән башларын башка салган килеш кочаклашып утыруларын күргәч, Искәндәрнең күңеле нечкәреп китте.

— Ярый, сиңа җыенырга вакыт,— диде ул, кырысрак булырга тырышып.— Әллә төшәргә уйламыйсың инде?

— Төшми кая барасың? Һәркемнең — үз станциясе... Син үзең генә каласың инде. И-их, яшь чакларым булса, ияреп китәр идем сиңа!..

— Кайсы станциядә төшәсең син, Мотыйк абый?

— Менә сиңа иске авыздан яңа сүз: киләсе станциядә, дип торам ич.

— Анысын беләм, станциянең исеме ничек, дим.

— Ә-ә-ә, анысын әйтәсеңмени? Тыңламас станциясе, ә авыл Баганалы дип атала безнең. Элек авыл башында кара багана торган безнең. Бу авылда кылынган эшләргә патша хөкүмәте җавап бирми, дигәнне аңлаткан ул. Юлаучылар, безнең авылга кермичә, читләп үтә торган булганнар. Шул кара баганалы авылның бер малае инде мин. Минем язмышның да капка төбенә кара багана утыртып куйганнар бугай. Гомер буе бәхет читләп үтте. Бөтен юанычың шушы зәмзәм суына калгач, юк инде ул...

— Әй, сөйләп бетермәдең бит әле син, Мотыйк абый, теге Зәмзәмия кая китте соң ул? Нинди әҗәтен түләде ул сиңа?

— Зәмзәм суы, дигәч, исеңә төштеме? Инде аяк сузам дигәндә, чып-чын зәмзәм суы булды ул миңа. Бу шайтан төкереге түгел.— Аның кесәсендәге шешә чупылдап куйды.— Язмышы бик гыйбрәтле ул Зәмзәмиянең...— Мотыйк, станциягә якынлашып килүләрен дә онытып, иркенләп сөйләргә тотынды. Тамак төбенә утырган ачы төерне йотып җибәрде дә, иркен сулап, сүзен дәвам ит-

те: — Сугышка хәтле үк булды бу хәл. Минем егермене тутырып килгән чак, Зәмзәмия ике-өч яшькә кечерәк. Нәрсәдән булгандыр, белмим, көннәрдән бер көнне моның бөтен тәне шешә башлады. Аны өшкертеп тә карадылар, догалы су да эчерделәр. Ул чакларда врач дигәнне ишетеп кенә беләләр иде авылда. Им-том белән шактый тилмерттеләр кызыйны. Зәмзәмия көннән-көн үзгәрә барды, күзләре тоныкланды, ут янып торган йөзенә ваемсыз саргылт төс кунды, сүзләре дә бутала башлады. Авылда аның турында имеш-мимешләр таралды. Әтиәниләре аны кешегә күрсәтмәскә тырышалар, урамга бөтенләй чыгармыйлар иде. Шулай беркөнне ул өйдә кеше юклыгын гына чамалап торган да урамга чыгып йөргән. Артыннан куып та тота алмаганнар. Ике көн, ике төн эзләгәннән соң, аны урман буендагы Изгеләр чишмәсе яныннан тапканнар. Күлмәкләре ерткаланып беткән, аяк-куллары сыдырылган, чәчләре тузгыган — урман пәрие диярсең. Чишмә кырыендагы ташка утырган да, бар дөньясын онытып, җир астыннан кайнап чыккан суга карап тора, ди. Авыл халкы аның алмашынганын инде үз күзләре белән күргәч, сүзләр ачыктан-ачык йөри башлады. Әти-әнисе чакырмаган карчык, эчермәгән үлән, укылмаган дога калмады, ләкин Зәмзәмия терелмәде. Имче чакыртып, өшкертә башлауга: «Төкермә, ник төкерәсең миңа?» — дип, аның өстенә ташлана икән. Шуннан соң аны бөтенләй чыгармас иттеләр. Ләкин, үзең беләсең, авыл халкының эше бетәрлек түгел бит, гел аны гына саклап утыра алмаганнардыр инде, тагын берничә тапкыр өйдән качып чыгып китте ул. Бу юлы да чишмә яныннан таптылар аны.

Шул хәлдән соң аны үз иркенә җибәрделәр. Ул еш кына безгә керә иде. Керә дә ишекле-түрле йөренә башлый, үзалдына туктаусыз сөйләнә: «Ямьле язлар да җитте, сыерчыклар да кайтты. Мин генә кайтмадым. Мин юләр. Мин сыерчыклар белән ничек сөйләшим? Алар мине аңламыйлар бит. Мин юләр.— Аның тавышы шундый сагышлы, шундый кызганыч чыга, мин, елап җибәрмичә, көчкә тыелып торам. Аннары ул кинәт кенә шаркылдап көлеп җибәрә. Сыерчыкларга бармак белән төртеп күрсәтә-күрсәтә көлә.— Карагыз әле, карагыз, сыерчыклар кара күлмәк кигән! Яз көне кем кара күлмәк кия инде? Минем күлмәгем матур, минем күлмәгем матур,— дип, баласынып, бармаклары белән итәк очларын

тота-тота бөтереләә. Бөтерелеп арыгач, минем кулдан тота да урамга сөйри башлый.— Әйдә инде, әйдә инде, Мотыйк абый! — ди, томанлы күзләре белән еламсырап, миңа карый. Мин ихтыярсыз аның артыннан иярәм. Юл буе бер сүз эндәшмичә, тын гына барабыз. Чишмә янына җиткәч, ул каушап калгандай була, кемнедер күрергә теләгәндәй, тезләнеп, күзләре талганчы чишмә суына карап тора. Аннан чишмә суында кулларын юа, битләрен, чәчләрен, колакларын, аякларын чылата. Шул вакытта беразга гына аның хәрәкәтләренә мәгънә кергән кебек тоела, томанлы күзләрендә бәләкәй генә очкын кабынып алгандай була. Аның зәгыйфь акылы шулай итеп күңелен тәртипкә салырга тырыша. Кичке эңгер төшкәч кенә, кайтыр юлга чыгабыз. Кайтып җиткәч, ул минем баштан сыйпый да, әбәк, дип, җилкәгә сугып, өйләренә йөгереп кереп китә.

Җәй буе, мине ияртеп, көн саен чишмәгә төште ул. Бүтән беркемне дә якын җибәрми, беркем белән дә сөйләшми, беркемнең дә сүзен тыңламый — бары мине генә үз итә иде. Ә көз җиткәч, аны шәһәргә больницага илтеп салдылар. Аннан бөтенләй терелеп кайтты ул авылга...

Әмма авыл халкы өчен мәңгегә Сәер Зәмзәмия булып калган иде инде ул. Чибәрлек ягыннан тирә-юньдә аңа тиңләшерлек кыз юк иде, дисәм, валлаһи, алдау булмас. Кашыкка салып кабып йотарлык иде, бичара. Шулай да егетләр аны читләп үтәләр иде, кызлар да үз араларына алмадылар. Ул моны бик авыр кичерә, шуңа күрә торган саен кешеләрдән читләшә бара иде.

Шулай беркөнне инде караңгы төшеп килгәндә, энисе безгә йөгереп кергән. «Зәмзәмия югалды, иртән чыгып киткән иде, һаман юк»,— ди. Минем күңел нидер сизенде бугай, Изгеләр чишмәсе янына төшеп киттем. Менә бүгенге кебек айлы төн иде. Ерактан ук күрдем мин аны. Чишмә буена су алырга төшкән ап-ак күлмәкле Зөһрә кыз төсле, суга иелгән дә, үз матурлыгына үзе соклангандай әсәрләнеп, үз шәүләсенә карап тора.

Себер ягына ниндидер төзелешкә эшчеләр җыеп йөриләр иде, эти-энисе киңәш иттеме, әллә үз хәлен үзе аңладымы,— озакламый шунда китеп барды Зәмзәмия. Шул китүеннән юкка да чыкты. Сугыштан соң авылга кайтып, берничә ел узгач кына хәбәрен ишеттем. «Кияүгә чыккан, бер баласы туган, менә дигән итеп яшәп яталар икән»,— дип сөйләде эниләре. Аларның сүзен

расларга теләгәндәй, аннан ай саен диярлек посылка килеп торды. Тик үзе генә кайтмый иде.

Әниләре инәлеп-инәлеп чакыра торгач, ире белән баласын ияртеп кайтты ул сабантуйга. Киемнәр ефәктән генә, элеккечә үк булмаса да, төс-кыяфәт тә Комган Әптери кызлары белән янәшә куярлык түгел. Авыл урамы буйлап үткәндә, бар халык капка төбенә йөгереп чыга иде. «Һе-һей, менә сиңа мә, Сәер Зәмзәмиягә дә кияү чыккач, ул да ефәк-бәрхеткә төренеп йөрерлек булгач, безнең кызларга ни сан инде»,— дип, хатыннар тел шартлата. Кызларның да күзе кыза, читкә китәм дә читкә китәм, дип, эти-әниләрен тинтерәтә башлый. Егетләрнең моңа ачуы чыга, менә-менә куенына керәм дип торганда, җиде җир читенә җибәреп булмый бит инде кызны. Авыл халкының авызында сүз торамыни?! Сүз ияртә сүз чыгып, бер җае килгәндә, Зәмзәмиянең иренә кайсыдыр төрттереп куя. «Авыл тормышы тирес тә тузан инде, чери монда адәм башы. Шәһәр шәһәр шул инде, кемлегеңә карамый, эшләсәң, умырып акча бирә, чистага ятасың, чистаны киясең. Кешегә хөрмәт бар шәһәрдә. Әнә, синең хатынга элек бездә көлеп кенә карыйлар иде. Шәһәр нишләткән үзен, хан кызы булган бит, кем әйтер аны хәзер Сәер Зәмзәмия дип». Шулай җай гына сөйләгән була бу. Ә ире кайта да Зәмзәмиясен табалый башлый: нигә моңа кадәр миңа бу турыда әйтмәдең, ди. Зәмзәмия бөтенесен дә сөйләп бирә. Ире, башы поезд астына кергере нәрсә, ташлап китә моны. Зәмзәмия аның артыннан бармады, авылда торып калды... Хәзер яңа калага эшкә урнашкан, диләр...

Мотыйк озак итеп башын селкеп торды-торды да көрсенеп куйды. Поезд станциягә якынлашып килсә дә, аның җыенырга исәбе юк иде сыман. Искәндәр аңа бу турыда әйтмәкче булды, ләкин уйларыннан бүләргә базмады.

«Кайтмаска иде аңа кире, бар дөньясына төкереп яшәп ятарга иде шул Себерендә. Утка алданган күбәләк кебек, гел күз алдында torгандыр шул авыл. Барыбер түзәргә кирәк иде, кайтмаска кирәк иде. Хатын-кыз күңеле күбәләк кебек шул...» — Мотыйк Искәндәргә күтәрелеп карамады, аның барлыгын да онытты бугай, үзалдына сөйләнеп, үз-үзе белән бәхәсләшеп барды.

— Син нигә кайтасың соң? Син дә кайтма. Тот та, Зәмзәмия янына барып, эшкә урнаш.

— Нинди эшкә? Кем алсын мине анда эшкә? Җиде класс белемем белән кемгә кирәк мин анда?

— Үзең «атаклы балта остасы» дисең, үзең...

— Авыл өчен — атаклы. Авыл йортын күз йомып та җиткерәм мин аны. Шәһәр бит ул... Аннары... шәһәргә күңел дә ятмый минем, һава җитми миңа анда.

— Алайса, Зәмзәмияне ал да берәр авылга барып төплән.

Ул арада ишекне каты итеп дөбердәттеләр, җавап биргәнне дә көтмичә, ачып җибәрделәр.

— Каласың бит. Поезд туктады. Синең станция. Әллә төшмисеңме?

Мотыйк теләр-теләмәс кенә кузгалды, утыргыч астыннан рюкзагын алып, идәнгә куйды. Хәрәкәтләре артык салмак, дәртсез, хәлсез иде аның. Ул, станциягә җиткәннәренә ышанмагандай, тәрәзәдән тышка карады. Анда төннең кара пәрдәсеннән башка берни дә күренмәде. Күктәге ай да, сезнең арттан күпме барырга була дигәндәй, каядыр артта калган иде. Бары тик йолдызлар гына, сүнеп барган учак көле арасында ялтырап киткән күмер күзләре кебек, җилдә дөрлиләр.

Искәндәр, рюкзакны алып, купедан чыкты. Мотыйк һаман кузгалмады. Аннары, лып итеп, утыргычка иңеп төште.

— Чыкмыйм әле. Йөрәгем кага,— диде ул, ыңгырашкан тавыш белән.— Авылга кайтып җитә алмам кебек.— Ул мөлдерәгән күзләре белән Искәндәргә текәлде. Хәзер аның тезләренә башын куяр да үкси-үкси елый башлар сыман иде Мотыйк. Аның иреннәре калтырады, борын яфраклары кабарды.— Китәсем килми минем моннан, Искәндәр энем, китәсем килми,— диде ул, хәлсез тавыш белән.— Инде күптәннән бер кеше белән дә болай рәхәтләнеп сөйләшкәнем юк иде. Эч серләремне сөйләгәнем юк иде. Күңелем бушап калды. Яңадан туган кебек булдым. Ачуланма, тагын бер генә станция барыйм әле. Миңа, кайда туктасам да, барыбер. Ул станциядән теге яңа калалары да якын гына. Исәп итсәм, Зәмзәмия янына да сугылып чыгармын. Хәлен белермен. Елаша-елаша сөйләшеп утырырбыз бер. Яңа елга алып чыгасым килми бу кайгы-хәсрәтләрне. Яңа елда яңача яши башларга иде!..

Мотыйк, сүзен әйтеп бетерә алмыйча, ютәлләргә тотынды, һава җитмәүдән изүләрен чишеп җибәрде. Бер кулы белән авызын каплаган килеш, икенчесе белән, кармалап, кесәсеннән шешә тартып чыгарды, калтыранган куллары белән пыяла чыңлата-чыңлата, стаканга коньяк

салды. Күзләрен йомып, аны эчеп куйгач, бераз тын торды, аннан иркен сулап куйды. Гаепле эш эшләгән кеше сыман, керфекләрен күтәрмичә генә, Искәндәргә эндәште:

— Әйдә минем белән! Гостиницага урнашырбыз! Ду китереп Яңа елны каршы алырбыз. Әйдә, җыен, төшәбез дә калабыз. Зәмзәмия апаң белән дә танышырсың. Кияү җегете булып барырсың. Табабыз аны, өй борынча йөреп булса да табабыз. Шәһәр дигәч тә, безнең авыл хәтле генә әле ул. Җиткерә генә башладылар. Кайчан телисең, шунда китәрсең. Билет өчен борчылма. Кирәк булса, йоклап яткан түшәгең кырыена китереп бирерләр. Акча китерттерә ул... Әйдә инде, яшь кешегә бер җилкенеп алу ни тора?

Мотыйк Искәндәрнең пальтосын чөйдән алды, бүреген кидерде, иңнәреннән сыпырды. Ничек кенә булса да Искәндәрне күндерәсе, үзе белән алып каласы килә иде аның.

— Булмый, Мотыйк абый,— диде Искәндәр. Бу сүзләрне ул шундый авырлык белән әйтте, әйтерсең ниндидер зур җинаять эшләде, әйтерсең тиктомалга Мотыйкның яңагына китереп сукты.

— Алла хакы өчен, тыңла сүземне! — дип инәлде Мотыйк.— Бәйрәм арасы бит. Бәйрәмне кайда үткәрсәң дә барыбер түгелмени? Монда ошамаса, безнең авылга кайтырбыз. Авыл халкының күзен кыздырып, урам буйлап узарбыз. Мотыйк абзыйларының бөтенләй төшеп калган кеше түгеллеген күрсеннәр! Алар ни генә сөйләшмәсен, ә ул менә нинди гөрнәдирдәй егетләр белән йөри! Аннары Сәгыйдулла абыйның хәлен белеп килербез. Бәлкем, бербер ярдәм кирәктер. Нияте зурдан бит картның. Исәп итсәк, бригадир Ибрайга да сугылырбыз. Талканы коры булуга карама, күңеле туры ул кешенең. Шундый кешеләр ясаган да инде революцияне, тоткан җирдән өзә торган кешеләр. Безнең ишеләр түгел...

Сөйләгән саен, аның йөзе ачыла барды, сыгылып төшкән гәүдәсе турайды, күзләрендәге сүрән очкыннар уянып ялтырый башлады, әйтерсең ул инде, чынлап та, үзе хыялланган дөньяда йөри иде. Ул поезд кузгалып киткәнне дә сизмәде, Искәндәрнең пальтосын яңадан чөйгә элгәнен дә күрмәде. Бары тик, поезд тизлеген арттырып, вагон як-якка чайкала башлагач кына, әкренләп аңына килде.

— Әйдә инде, күтәреп кенә йөртермен. Җәмгысы ике көн вакытың узар...— Сөйләүдән туктаса, Искәндәр авызын ачар да аның бар хыялларын чәлпәрәмә китерер дип

уйлады, ахрысы, сүзләрен йота-йота, кабалана-кабалана сөйләде.

Искәндәр, аптыраганнан, өстәлне җыештырырга тотынды. Чүпләрне гәзиткә төреп, купе ишеген ачты. Мотыйк, ярты сүздә бүленеп, туктап калды.

— Кая син? Ничек? Нигә? — дип, бәйләнешсез сүзләр тезде.

— Чүп кенә түгеп киләм.

Ул кире кергәндә, Мотыйк тынычланган, аның йөзенә гамьсезлек төсмере кунган иде.

— Шулай итеп, минем белән калмаска булдың инде?..— диде ул, илтифатсыз гына.

— Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

— Мин сине базга ябарга җыенмыйм лабаса.— Мотыйк чып-чынлап аны ачулануга ук күчте.— Ике-өч көн бәйрәм итәрбез, күргән-белгәнне йөреп чыгарбыз да, син тагын үз юлың белән китеп барырсың.

— Бер туктагач, авыр кузгалам мин. Китә алмый шунда калырмын дип куркам.

— Куып җибәрермен. Бер станцага бер бәхетсез җиткән...

— Мин үземне бәхетсез санамыйм...

— Тиктомалга кубарылып юлга чыкмый бәхетле кеше. Ялгыз кеше — бәхетсез кеше инде ул. Ничек кенә күңелеңне юатырга тырышма, ялгыз барыбер ялгыз инде.

Искәндәрнең җавап кайтарасы да, башлап сүз әйтәсе дә килми иде. Ул утыргычка матрас тәгәрәтеп җибәрде дә, ике кулын башы астына салып, чалкан ятты. Аның ялгызы гына калып тынычланасы да килә, Мотыйкны да кызгана иде. Ул киләсе станциядә төшеп калыр да, кибән эченә кереп югалган энә кебек, йортлар, авыллар, кешеләр арасында юкка чыгар, аны беркем дә күрмәс, эзләмәс, тапмас кебек иде.

— Йокламыйсыңдыр бит?

Искәндәр җавап бирмәде, күзләрен генә зур итеп ачты.

— Йоклама! Яңа елны йоклап каршы алырга ярамый.

— Нигә?

— Андый кеше вакыт кадерен белми, гомере заяга уза аның.

— Үзеңнән беләсеңме?

Искәндәр, ваемсыз-дорфа тонга күчкәнен аңлап, эчтән үзен битәрләп куйды.

— Әйе, үземнән.

— Йоклап калсаң, нәрсә була? — Кызыксынганын сиздерергә теләп, ул торып утырды.

— Яңа ел чиге — ил чиге генә түгел ул, энем. Ил чикләрен күп үттем мин. Шуның аркасында күпме каһәр ишеттем. Кеше күңеле барысын да күтәрә, барысына да ризалаша. Тик менә вакыт үтүенә, гомер узуына гына ияләшә алмый. Үлемгә өйрәнә алмый кеше. Ә иске ел синең гомереңнең үлгән бер елы бит ул. Яңа елны каршы алганда, кеше тын калып шул турыда уйларга, тормышның кадерен аңларга тиеш. Шул вакытта йоклап ятсаң, димәк, сиңа ике дөнья — берморҗа. Кеше Яңа елны нигә уйлап тапкан? Үзен юату өчен. Шулаймы?

Искәндәргә Мотыйкның, авыл картлары шикелле, башын бер якка кырын салып, күзләрен хәйләкәр кыскалый-кыскалый, үзе кичергән хәлләр белән ныгытып, фәлсәфә сатуы, аңа вагон селкенгән уңайга салмак кына чайкалып бару ошый иде.

— Нигә тындың? Дөрес әйтмәдемме әллә?

Ул, бишектә оеп тирбәлгән бала кебек, гаҗәпләнгән күзләрен тутырып карады да тагын онытылды.

— Телеңне йоттыңмы әллә?

— Вакыт — юк нәрсә ул, Мотыйк абый. Вакыт төшенчәсен кеше үзе уйлап тапкан. Аны сәгатьләргә, көннәргә, айларга, елларга бүлгән. Чиксезлекне, мәңгелекне башына сыйдыра алмаганга, шулай эшләгән ул. Мәңгелек янында үз гомеренең молекула хәтле дә булмавын аңлаган, шуңа күрә еллар уйлап чыгарган да, илле ел яшәде, йөзгә җитте, дип, кеше гомерен зурайтып күрсәтергә тырышкан.

— Башны бутыйсың син, энем. Юк белән башны бутыйсың.

— Синеңчә ничек соң?

— Мин үземнекен әйттем инде...

Шулчак, ачы сызгырып, тәрәзә артында поезд үтә башлады. Мотыйк җөмләсе поезд астында калгандай шып туктады. Искәндәр тәрәзәгә капланды. Аның күз алдыннан бер-бер артлы якты тәрәзәләр йөгереп узды. Һәр тәрәзәдә кемнеңдер йөзе чагылып калды. Ул, үзе ташлап киткән шәһәр ягына да поездлар йөрүенә, шунда кешеләр баруына сәерсенгәндәй, күзен алмыйча, соңгы вагон үткәнче карап торды. Каршы килгән поезд, артыннан куа килүче Яңа елны җиткерергә теләмичә, бар көченә чабадыр сыман тоелды аңа. Ә ул, киресенчә, Яңа

елның каршысына ашыга, тәгәрмәч авазларына кушылып типкән йөрәге иң якын кешесе белән очрашуны көтеп ярсыгандай алгысына иде.

Искәндәр сәгатенә күз салды. Бу юлы ул стенага күтәрелеп карамады, ул инде үзенең поездда баруына күнегә башлаган иде. Үзе өчендерме, әллә Мотыйк ишетсен дипме, аһылдап әйтте:

— Бер сәгать кенә калган.

— Унбер тулдымыни?

Алар икесе дә, сагаеп, тын калдылар. Гүя шушы бер сәгать эчендә нindidер зур вакыйга булырга, алар гомер буе көтеп килгән нindidер бер нәрсә чынга ашарга тиеш иде.

Мотыйк ашыкмый гына рюкзагын иңенә элде, бүрек колакчыннарын чишеп яңадан бәйләде, бияләен киеп салды. Аның нәрсәдер әйтәсе килә, ул нәрсәдер көткән сыман иде. Менә ул, башын аска иеп, купедан чыкты. Ишек төбендә тукталып калды. Искәндәр аның китәсе килмәгәнен бөтен җаны-тәне белән аңлады. Әйтерсең шушы поездан төшеп калса, ул вакыт арбасыннан төшеп калыр, айларның, елларның исәбен югалтыр, болай да буталчык тормышының мәгънәсен таба алмыйча, мәңгелеккә китеп барыр кебек иде. «Вакыт арбасы,— дип уйлады ул эчтән генә.— Менә ни өчен бар дөньяга кул селтәп, шушы поездга ашыккан икән ул. Вакыт арбасы. Ул, дөнья мәшәкатьләре арасында буталып, хыялы артыннан җитешә алмый башлагач, вакыт каршына үзе чыгып йөгергән. Хыялын куып җитмәк булган. Күктәге кошлар — кешеләрнең җаны түгел, хыялыдыр алар. Хыялсыз кеше — канатсыз кош, дип юкка әйтмиләрдер. Кеше, дөнья ваклыкларына чумып, хыялын онытса, ул, аны ташлап, кош кыяфәтендә күккә очадыр».

Ул, хыялын капшап карарга теләгәндәй, күкрәгенә кулын куйды. Күкрәк читлеге эчендәге кош, күккә күтәрелергә омтылгандай, тыпырчына-тыпырчына тибенә иде. «Димәк, ул хыялын куып тоткан. Бригадир Ибрай, Сәгыйдулла бабай, балта остасы Мотыйклар белән очрашмаган булса, бу ачышны ясый алыр идеме икән ул?» Искәндәр шунда гына Мотыйкның саубуллашмый-нитми чыгып киткәнен аңлады. Купе, тузгытылган кош оясы кебек, буш һәм шыксыз иде.

Мотыйк, ярты гәүдәсе белән ишектән кереп, проводницага нидер сөйли.

— Бер нәрсәң дә юкмыни соң?

— Юк инде, юк. Миндә каян булсын? — дип аклана проводница.

— Тап инде, нәрсәң булса да бардыр бит.

Искәндәр, тагын шәраб теләнә, дип, йөзен җыерды. Нигә шулкадәр мескенләнә инде?

— Менә моны бир алай булгач.

— Нишлисең аның белән, юләр?

— Бир дигәч бир. Мә ун тәңкә. Кызылын бир.

Мотыйк купедан башын алды да Искәндәргә таба атлады. Кулында проводницалар йөртә торган кызыл флагчык иде аның. Килеп җиткәч, кулын аның иңенә куйды, авыр итеп көрсенде.

— Яңа елга берәр нәрсә бүләк итәсем килгән иде. Алдан уйланылмаган. Очрашасын кем белгән аны. Менә сиңа кызыл флагчык. Моның белән каршыңа килгән теләсә кайсы поездны туктатып була. Теләгем шул: каршыңа бәхет килсә — уздырып җибәрмә, шушы флагчыкны күтәр.

Ул бүген беренче мәртәбә шулкадәр сөенеп елмайды, хәтта Искәндәрнең күзләренә яшь килде. Кулда йөри-йөри керләнеп, таушалып беткән флагчыкны күкрәгенә кысты да кат-кат бер сүзләрне кабатлады:

— Рәхмәт, Мотыйк абый! Рәхмәт, Мотыйк абый!

Алар, бер-берсенә сыенышып, буш коридорда икесе генә шактый озак басып тордылар. Мотыйк рюкзагын рәтләп куйды һәм:

— Килеп җиттем,— дип, тәрәзәгә таба ымлады да тамбурга таба китте.

Поезд туктауга, Искәндәрнең йөрәге дә тибүдән туктаган сыман булды. Аның тәне буйлап суык йөгерде, аяклары хәлсезләнде, керфекләре авырайды, куллары салынып төште. Ул вагон баскычына басты да, сикереп төшәргә җыенгандай, бар гәүдәсе белән алга — караңгы төн кочагына сөрлекте. Мотыйк берничә адым атлады да туктап калды.

— Сау бул, Мотыйк абый! Зәмзәмия апага сәлам әйт! — дип кычкырды Искәндәр.

Салкын җилдән Искәндәрнең йөзе уттай кызышты, чәчләре тузгыды. Җил җан ачысы белән сызгырды, үксиүкси елады. Җиһан белән саубуллашучы иске елның хәсрәтле җиле аңа шулай үзенең соңгы серләрен сөйли иде.

— Төшеп каласың бит! Аннары җавап бир сезнең өчен.

Проводница, Искәндәрнең иске елда төшеп калуыннан курыккандай, вагон ишеген бикләп куйды.

Искәндәр кинәт кенә үзенең гәүдәсе җиңеләя башлаганны тойды, әйтерсең борчып, күңелен газаплап торган бар уйлары Мотыйк белән бергә шушы караңгы станциядә төшеп калганнар иде. Ул кулындагы флагчыкны әйләндерә-әйләндерә карады, ачык ишекле купе янына җиткәч, проводницага эндәште:

— Шушы нәрсә белән поездны туктатып буламы?

— Туктамый, кая барсын ул?

Купе эчендә әле дә Мотыйкның җылысы саклана иде кебек. Ул сәгатенә карады. Унике туларга егерме җиде минут калган. Искәндәр сәгатен сыйпап куйды. Әйтерсең егерме җиде минуттан аның каршында бәхет капкасы ачылырга тиеш иде.

Ул купе почмагына сөялеп утырды да, иске елның соңгы минутларын санап дөпелдәүче йөрәк авазын тыңлый-тыңлый, оеп барганын сизми дә калды.

...Поезд бар тәрәзәләре белән балкып, сөенеп Яңа елның ап-ак дәүләтенә килеп керде дә шатлыгыннан кычкыртып җибәрде. Искәндәр моны сизмәде дә, ишетмәде дә. Ул, бар дөньясын онытып, изрәп йоклый иде.

Төшендә Яңа елның бәллүр капкасы өстенә эленгән галәмәт зур сәгать күрде. Әйе, бу аның өендәге сәгать, бабасыннан калган борынгы сәгать иде. Ул, бар дөньяны яңгыратып, төнге уникене суга башлады. Ләкин элеккечә буыла-буыла, гыжылдый-гыжылдый түгел, ә илаһи музыка авазлары таратып, ярсый-ярсый суга иде. Искәндәр, бу илаһи музыканың сәгать сугуыннан түгел, үз күңеленнән агылып чыкканын аңлап, һушсыз калды. Күзләрен күккә төбәп, әкрен генә пышылдады: «Бабай сәгате терелгән. Борынгы сәгать терелгән. Иске сәгать дөрес йөри!»

Ул йокысыннан уянганда, поезд «Якты юл» станциясенә якынлашып килә иде.

*1981*

# *Яшисе килә*

*Хезмәт вазифаларын башкарганда күрсәткән ныклык һәм батырлыгы өчен рядовой Миргазизов Рифкать Шәфкать улын «Батырлык өчен» медале белән бүләкләргә (үлгәннән соң).*

СССР Югары Советы
Президиумы Указыннан

*Татар халкының каһарман улы Рифкать Миргазизов батырлыгына багышлыйм.*

## 1

— Тукта... тукта,— дип ыңгырашты Рифкать.— Тукта... хәзер...

Ул аска таба оча да оча, ә парашют һаман ачылмый. Тирә-юньдә беркем юк — дөм караңгы. Рифкать бар көче белән парашют бохрасын тарта. Бармаклары әрни, ут яна, ә парашют ачылмый да ачылмый. Башы өрөзлексез шаулый, чатнап авырта — әйтерсең самолет моторын башына терәп куйганнар да бөтен көченә үкертәләр. Ә ул оча, һаман оча. Колак төбендә әче җил сызгыра. Менә хәзер, менә җиргә атылып төшәр дә чәлпәрәмә килер...

— Тукта! — дип тагын ыңгырашты Рифкать.

Кайда соң аның иптәшләре? Кайда башка солдатлар? Бөтен җир дөм караңгы. Әй, ул күзләрен йомган икән бит. Хәзер күзләрен ача да дөнья яп-якты була. Нәрсә бу? Күз кабакларын авыр әйбер белән бастырып куйган кебек. Ул һаман саен тизрәк оча. Әллә шулай тиз очканга күзне ачып булмыйммы? Берни дә күренми... Җиргә ерак калды микән? Юк, юк, тизрәк күзне ачарга кирәк! Юкса... Әнә, кер-

фекләр селкенде. Димәк, ачып була. Әнә, еракта, бик еракта, алсу яктылык сирпелә. Кояш нурлары... Кояш чыгып килә. Ә җир күренми. Колак шаулый, колак төбендә җил сызгыра. Ә җир һаман юк. Әллә җир бөтенләй юкка чыкканмы? Әллә ул төпсез упкынга очканмы? Алай дисәң, әнә, кояш нурлары да күренә. Иптәшләре генә юк. Ә-ә... Аның парашюты ачылмаган бит! Димәк, алар артта калган... Хәзер менә, соңгы көчен җыеп, боҗраны тарта да... Ур-ра, ачылды!.. Әнә, баш очында ап-ак гөмбәз! Әкренәйде. Ул хәзер әкрен генә оча, җилдә чайкала-чайкала, әкрен генә оча. Әнә, аяклары да җиргә тиде...

Рифкать авырлык белән генә күзләрен ачты. Күзләрен ачты да, куркыныч төштән айнып җитмәгән сабый кебек, тагын бер ыңгырашып куйды:

— Башым...

— Аңына килде...

«Аңына килде! Аңына килде!» — дип чыңлады аның колагы.

Баш очында ап-ак гөмбәз талгын җилдә җилфердәп торды-торды да ап-ак җәймә булып аның өстенә ташланды. «Чуалды, парашют чуалды,— дип уйлады Рифкать.— Тизрәк аннан котылырга да алга чабарга кирәк...» Ул куллары белән чәбәләнде, аяклары белән тыпырчынды. Ә нишләп: «Атакага!» — дип кычкырмыйлар? Нишләп бу десантниклар ап-ак парашютка төренгәннәр дә бер урында тик басып торалар. Йөзләре дә бик кырыс. Парашютны вакытында ача алмаганга ачуланалармы аңа?

— Ят, Рифкать, ят, торырга ярамый сиңа.

Рифкать, аптырап, күзләрен ныграк ачты. Күз алдындагы аксыл томан әкренләп сыегайды. Иң беренче булып каршында тәрәзә һәм тәрәзә артында кояш пәйда булды. Аннары ул ап-ак түшәмне, ак стеналарны, ак халатлы кешеләрне төсмерли башлады.

— Нәрсә булды? — дип дәште ул, ләкин тавышы, бик зәгыйфь булып, хәлсез пышылдау гына булып чыкты.

Рифкать ачу белән тамагын кырып куйды да, бар көченә кычкырмакчы булып, авызын ачты, ләкин шулчак тагын чәнчеп-чәнчеп башы авырта башлады, һәм бөтен гәүдәсе буйлап күтәрелеп килгән әрнү, үпкә катыш җан авазы тамак төбендә буылып калды. Ул тешләрен кысып ыңгырашты, күзләрен чытырдатып йомды.

— Шприц! — диде кемдер.

Менә аның аркасы черки тешләгән кебек аз гына авырту сизде, менә бөтен тәненә акрын-акрын гына җылы йөгерде, күз алдындагы куе кызыл пәрдә теләр-теләмәс кенә күтәрелде һәм бөтен тирә-як тагын ап-ак төскә керде.

— Бирешмә, егет! Солдат бирешмәскә тиеш!

Рифкать тавыш килгән якка борылмакчы булды, ләкин башы тыңламады, тарттырып бәйләгән кебек, үз урынында ята бирде.

— Кыймшанма, кыймшанма, сиңа кыймшанырга ярамый,— диде шул ук тавыш.

«Кем соң бу? Нинди таныш тавыш соң бу? Нинди кешеләр җыелган монда? Кайда соң мин?

Ә-ә-ә! Ул парашютына чуалган да болар аңа булышырга, аны коткарырга килгәннәр!»

Рифкать сүрән генә елмаеп куйгандай итте. Күзләрендә кабынган елмаю бит алмаларында бераз алсуланып торды да иреннәренә барып җитә алмыйча сүнде. Ул тагын күзләрен ачты һәм, каршысында басып торган өлкән яшьтәге хәрби кешене күреп, бераз аптырап калды. Җилкәсенә ак халат япкан кеше, урындык алып, аның янәшәсенә утырды.

— Хәлләр ничек, солдат? Бик авыртмыймы?

Кинәт, һич көтмәгәндә, Рифкатьнең тамак төбенә җылы төер килеп тыгылды, башы утлы кыршау кидергәндәй яна башлады.

— Шприц! — диде тагын әлеге тавыш.

Аны тагын чак кына кузгаттылар, озакламый җилкәсе буйлап тагын рәхәт җылылык таралды. Рифкать бераз вакыт керфек кагарга да кыймый ятты. Кемдер баш очында утлы кыршау тотып тора кебек тоелды аңа. Күзен ачыйм дисә, утлы кыршауны башка кидерә дә куя. Менә ул, әлеге Газраилгә сиздермәскә тырышып, әкрен генә керфекләрен күтәрде, аннары, баш очында утлы кыршау күренмәгәч, күзләрен ачты.

Каршында шул ук хәрби кеше утыра. Аның янында — кулына шприц тоткан ак халатлы апа. Ә арттарак — тагын ак халатлы кешеләр...

— Түз, егет, түз, герой! — дип елмайды хәрби кеше. Ләкин аның елмаюы бик моңсу да, сәер дә килеп чыкты.

— Генерал...— дип пышылдады Рифкать.

— Әйе, мин бу, рядовой Миргазизов, мин. Мин исән, иптәшләрең дә исән, барысы да исән! Рәхмәт сиңа.

Һәм шулчак барысы да, барысы да, аермачык булып, Рифкатьнең күз алдына килеп басты. Ирексездән аның йөрәге кысылып куйды, ике күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәп төште, бераздан башы шаулаудан туктады, гәүдәсе җиңеләйгәннән-җиңеләя барды, менә инде ул аны бөтенләй тоймый да башлады.

Рәхәт. Рәхәт тә, бераз куркыныч та. Парашютта төшкәндә шулай була иде. Ул әле хәзер дә оча түгелме соң?! Әйе, әйе, оча! Ләкин шунысы гаҗәп, җиргә түгел, ә өскә, зәңгәр күккә таба оча! Аста автоматтан аталар, «Ур-ра!» кычкырып йөгерәләр, танклар үкереп чаба. Ә ул гранатасын уч төбенә кыскан да һаман-һаман өскә күтәрелә, күтәрелгән саен, күңелгә рәхәтрәк була бара, көләсе, җырлыйсы килә. Ләкин ул көлә дә, җырлый да алмый, чөнки кулында — граната. Менә аның бармаклары ут яна башлый. Ычкындырмаска, түзәргә, түзәргә! Әгәр бармакларын язса, граната шартлаячак, ул, атылган коштай, җиргә егылып төшәчәк. Аның белән бергә кояш та, ай да, йолдызлар да шартлаячак, сүнәчәк.

Рифкать иреннәрен кысып ыңгыраашты. Аңа тагын укол кададылар.

Күзне иркәләп, палатада кояш уйный. Тып-тын.

Беркем бер сүз дәшми. Басканнар да тик торалар. «Бөтенесе басып тора, мин генә нишләп болай ятам соң әле?! Мин тормаганга сөйләшмиләрдер»,— дип уйлады Рифкать һәм, күтәрелергә исәп итеп, кыймшанып карады. Ләкин кыймшануга ук тирә-юнь караңгыланып китте, кешеләр томан эченә кереп югалды. Ул, елап җибәрүдән куркып, тешләрен кысты да түшәмгә текәлде.

Тагын тынлык. Бу тынлыкны бары тик колак төбендәге берөзлексез шаулау авазы гына бозып тора. Самолет гөрелтесенә охшаган шаулау авазы. Әллә һаман самолетта очалармы соң? Юк, юк, ул инде хәзер барысын да хәтерли, барысы да күз алдындагы кебек.

Аларны төн уртасында тревога белән уяттылар. Ул икенче каттагы караватыннан сикереп төште дә, юл уңаеннан киенә-киенә, казарма ишегенә таба йөгерде. Дөбер-шатыр килеп баскычтан чабып төштеләр дә казарма каршына тезелделәр. Караңгы күктә чекерәеп йолдыз-

лар яна. Ике көн, ике төн берөзлексез койган яңгырдан соң дөнья киңәеп, иркенәеп киткән кебек. Түбәңә басып, күңелне борчып торган болытлар таралгач, күк шундый биегәйгән, ниндидер бер тантаналы төскә кергән. Шундый биек күккә карагач, хәтта башлар әйләнә. Беренче тапкыр театрга баргач, шулай булган иде. Гомерендә мондый биек түшәм күргәне юк иде аның. Кешеләр тамаша карый, ә ул һаман күзен түшәмнән алмый.

— Смирно!

Өлкән лейтенантның төн тынлыгын ярып яңгыраган авазыннан хәтта йолдызлар да, бер-берсенә бәрелешеп, чыңлап куйдылар кебек.

— Десантниклар,— диде өлкән лейтенант Киреев, тавышын акрынайта төшеп,— көньяк-көнбатыш яктан дошман гаскәрләре һөҗүм итеп килә. Безнең бурыч — дошман тылына төшәргә һәм, көтмәгәндә арттан көчле удар ясап, аны юк итәргә! Калганын юл уңайлый аңлатырмын. Ма-ши-на-га!

Яшькелт-соры төстәге машина ут капкандай алга ыргылды да, тимер капка аша чыгып, аэродром ягына таба юл алды. Әллә инде йокыдан уянып җитмәгәннәр, десантникларның берсе бер сүз дәшми, тын гына машина көенә чайкалып баралар. Бары тик ара-тирә генә парашютны җайлабрак куялар да янтыкка төртеп торган автоматны кырыйга шудыралар. Рифкатьнең сул ягындагы чегәннеке төсле кара чәчле, каратут йөзле, бөркет борынлы азәрбайҗан егете Вагыйз дә сүз башламый. Мондый чакта ул, гадәттә, мең төрле мәзәк сөйләп, эчне катырып бетерә иде. Бер уйласаң, мәзәге дә искитәрлек түгел үзенең, ә көлмичә түзә алмыйсың. Ул рус сүзләрен шундый кызык итеп, балаларча ватып-сындырып сөйли. Аның мәзәген кабаттан сөйләп кара, кешеләр, көлү түгел, елмаеп та карамас. Бөтен кызыгы шул сөйләвендә бугай.

— Илдус...

Рифкать сул ягындагы егетнең терсәгенә кагылуга, тегесе дерт итеп китте, башын күтәрде.

Илдус, соры күзләрен яртылаш кына ачып, аңа карады, дәшмәде. Үзең дә беләсең бит, янәсе. Рифкать, әй, сиңа дәшкән мин юләр дигәндәй, башын илтифатсыз гына кыегайтып куйды да, артка таба йөгерүче агачлар шәүләсенә карап, уйга чумды.

Соңгы арада алар, көн дими, төн дими, хәрби өйрәнү-

гә әзерләнделәр. Тәннән соңгы тирне сыгып чыгарганчы йөгерделәр, иңбашлары өзелеп төшәр хәлгә җиткәнче, граната ыргыттылар, билләре тораташка әйләнгәнче, парашют сүттеләр, парашют җыйдылар. Кичләрен Ленин бүлмәсенә кереп хат язарга утыргач, тупасланган бармаклар ручкага иялнә алмый тилмерә иде.

Бу арада нишләп хат килми икән аңа? Тәлгатьтән дә җавап юк. Инде язганына ике атна булды бит. Әллә акыл өйрәтә, дип үпкәләде микән? Ниләр язган иде әле ул аңа? Монда хат язарга вакыт бик аз кала. Шуңа күрә ул язасы сүзләрен юлда йөргәндә йә берәр җирдә ялга туктаганда уйлап куя, ә инде казармага кайткач, аларны бары кәгазьгә генә төшерәсе кала. Шулай иткәч, шома да, тиз дә булып чыга. Хатларны төрле итеп, кызык итеп язасы килә аның. Ләкин яза башлагач һаман шул бер чамадан артмый.

*«Исәнме, Тәлгать!* — дип авыз эченнән сөйләнде Рифкать (хатны һәрчак «Исәнме»дән башлый ул). *Исәнме!*

*Сиңа солдат сәламнәре юллаучы дустың Рифкать. Бераз үзем турында язып китәм. Хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Дөресен әйтик, сез анда, теге җырда җырланганча, мине бөтенләй онытып бетергәнсездер инде.*

*Минем хезмәт яхшы бара, кәеф әйбәт, спорт белән шөгыльләнәм. Көннәр бик эссе тора, бөркү, түзәрлек түгел. Монда инде чия өлгерде, бар халык шуңа ябырыла. Кичә «Унике урындык» фильмын карадык, шунда сине искә төшердем.*

*Тиздән минем хезмәт итә башлаганга сигез ай тула. Озакламый, шушы айда, хәрби өйрәнүләр булырга тиеш. Менә үзем турында шулар гына. Хәзер көндезге сәгать бер. Әле генә мунчадан кайттык.*

*Тәлгать, безгә кереп, Азатка әйт әле, миңа бер-ике кассета җибәрсен. Монда бик шәп дисклар бар, яздырыр идем. Азатка хат язган идем, сорарга онытканмын.*

*Шулай итеп, эшләп йөрим, дисең инде. Эшлә, эшлә. Ләкин начар эшлисе булсаң, кара аны! Кайткач, мин техникумга керермен, ахрысы. Ярый, бүтән язар сүз бетте бугай.*

Рифкать.<br>Хат яз!<br>22.06.76.

*P.S. Биш көннән миңа унтугыз яшь тула».*

Менә туган көн дә узып китте. Ике шешә лимонад алып, дуслар белән утырдылар да, тагын гадәти солдат тормышы башланды.

«Иртәгә өйгә хат язарга кирәк,— дип уйлады Рифкать.— Хәрби өйрәнүләрнең ничек үткәнен дә язармын». «Исәнмесез, әнкәй, әткәй, Азат, Әнфисә!» — дип башлармын хатны. Юк, алай гел бертөсле була. Бу хатын ул болай башлар: «Исәнме, әнкәй! Исәнме, әткәй! Исәнме, Азат! Исәнме, Әнфисә!

Мин үзем исән-сау яшим...»

Менә кызык, исән булуын белә торып, кешегә «исәнме», диләр! Харис бабасыннан бер сораган иде инде ул. Бабасы мыек астыннан көлемсерәп кенә куйды. Аннары, чалгысына таянып, моңсу күзләрен еракка, бик еракка, Вятка болыннары аръягына төбәде.

— Һәр сүзнең хикмәте була, улым,— диде ул.— Сүз ул күктән төшмәгән, кеше күңеленнән өзелеп төшкән.

— Исән кешегә «Исәнме?» дип әйтүнең ни хикмәте бар соң? — дип кабатлап сорады Рифкать.

— Әй, улым, улым, күп нәрсәне белмисең шул әле син. Кайчакта шундый хәлләрдә каласың: исәнме-юкмы икәнеңә шикләнә башлыйсың. Ә инде исән икәнеңне белгәч, сөенеп бетә алмыйсың. Сугышта күп очраттым мин андый хикмәтле хәлләрне. Менә бу күзне фашист пулясы шаярткач, якты дөнья йөзен бер күрергә тилмереп яткан чаклар күп булды. Сау-сәламәт кеше генә яшәү кадерен белми ул. Бармагыңа шырпы керсә дә, үрле-кырлы сикерә башлыйсың. Үләсе килми, якты дөньяларны калдырып, кара гүргә керәсе килми адәм баласының! Яшьләргә ни?! Тормыш кадерен беләмени яшьләр? Сезгә әле ике дөнья — бер морҗа...

Шулай диде дә Харис бабай, бер сәбәпсезгә чыккан ачуын басарга тырышкандай, киерелеп-киерелеп, чалгысын селтәргә тотынды.

Рифкать, үчләшкәндәй, һаман үзенекен итте:

— Шулай да тере кешегә «Исәнме?» дип әйтү дөрес түгел инде. Хәерле көн! Здравствуйте! — дияргә кирәк.

Харис бабай, капыл туктап, чалгысын печән пакусы өстенә ыргытты да куак күләгәсенә барып утырды. Шешә бөкесен ачып, чәй уртлап куйды, кара кәләпүше астыннан чыгып торган яулык чите белән маңгай тирен сөртте.

— Исәнме дә исәнме?! Нәрсә аңлыйсыз соң сез? Здравствуй, имеш. Кемгә — нәрсә, кәҗәгә — кәбестә, ди. Аларныкы үзләренчә дөрес, безнеке — үзебезчә. Урыс әйтә: «Яшә, дөнья рәхәтен күр!» — ди, ә без: «Исәнме, саумы, хәлләрең ничек?» — дибез. Исән булсаң, тазалыгың булса, Ходай җүн бирер. Әнә, сугышта күпме әзмәвердәй ирләр ятып калды. Алардан «Исәнме?» дип сораган кеше юк бит. Ә аңа кадәр күпме кырылган? Безнең халыкның башы сугыштан чыкканга күпме генә әле! Гомер буе — сугыш, гомер буе — кырылыш. Шул мәхшәрләрне күрсәң, үзеңнең исән икәнеңә сөенеп бетә алмас идең.

Харис бабай үпкәләгән кыяфәт белән Рифкатькә карап торды да, син аңлый торган нәрсәмени бу дигәндәй, чаж-чож чалгысын янарга тотынды. Аннары, баш бармагын чалгы йөзенә тигереп карагач, аякларын аерып басты һәм, ачу белән селти-селти, киң пакус алып кереп китте. Рифкать аның артыннан иярде. Бабасы бүтән дәшмәде, авыз эченнән берничә тапкыр: «Исәнме? Исәнме, имеш»,— дип кабатлады да йөзтүбән капланучы үләннәргә карап онытылды.

## 2

— Десантниклар!

Рифкать бермәл уйларыннан арына алмый торды. Чалгы тавышы әкренләп тынкланды, печән пакусы күзгә күренеп ерагайды-ерагайды да бөтенләй күздән югалды. Колакка машина гөрелтесе кереп тулды, өлкән лейтенант Киреевның өзек-өзек сүзләре ишетелде:

— Десантниклар! — дип кабатлады ул.

Башка вакытта аның һәр сүзе бик тә ачык булып, авызыннан гаҗәеп олы борчак тәгәрәп төшкән кебек ишетелә иде. Ә бүген каршы искән машина җиле сүзләрне әле бер, әле икенче якка очырта, шуңа күрә җөмләсе, машинада барганда язылган хат юллары кебек, тигезсез чыга, авазлары, сүзләре калтырый, аслы-өсле килә.

— Без бүген дошман тылына төшәчәкбез,— дип дәвам итте Киреев.— Һәр адымыгызны үлчәп атлагыз, һәр хәрәкәтегезне уйлап эшләгез! Ашыкмагыз, кабаланмагыз! Иң мөһиме — һәркем үзе өчен дә, янәшәдәге иптәше өчен

дә җавап бирсен! Һавада вакытта ук бер-берегезне югалтмаска, бергә булырга тырышыгыз. Сез бүген үзәк штабтан килгән комиссия каршында, ил каршында, Ватан каршында сыналасыз. Әйдәгез, десантникларның кем икәнен күрсәтик!

Өлкән лейтенант ничек башлаган булса, шулай капыл гына сөйләүдән туктады, уңайсызланып кына елмайды. Әле яңа мыек чыгып килгән бу егетләрне ни көтәсен яхшы белә ул. Шуңа күрә аларны җилкендерәсе, берәр җылы сүз әйтәсе килә. Ләкин андый сүз табылмый да табылмый.

Киреев, ни әйтергә белмичә, егетләргә карап-карап торды да:

— Җыр башларга! — дип кычкырды.

Шуны гына көткәндәй, Вагыйз әллә кайдан, эчтән чыккан тавышы белән җырлап та җибәрде. Аңа казакъ егете Тансык кушылды, аннары грузин Гурамның тамак төбеннән калтырап чыккан авазы ишетелде. Аларны Коля, Виктор, Илдус — бөтен взвод күтәреп алды. Ә Рифкать авызын кыймылдатып кына торды, җырламады. Мондый да бай тавышлы гаҗәеп хорны беркайчан да тыңлаганы юк иде аның. Дөрес, алар бик еш җырлыйлар, ләкин бүгенге җыр, караңгы төндә тын далада яңгыраган җыр, моңа кадәр җырланган бар җырлардан да матуррак кебек иде, ул күңелне чеметеп-чеметеп ала, сулык-сулык китерә иде. Казакъ далалары киңлеге дә, рус бәйрәмнәренең шашкын дәрте дә, Грузия тауларының кайтавазы да, татар моңнарының моңсулыгы да бар иде бу җырда.

Рифкать тагын бераз ләззәтләнеп, хыялланып тыңлады да, үзе дә сизмәстән, ирексездән җыр агымына ияреп китте:

Без — канатлы десант солдатлары,
Бөркет булмый безгә ярамый.

Җыр, машина гүләвен, җил сызгыруын басып, япан далага таралды, агач ботакларын сыйпап узды. Аны арттан килүче машинадагылар күтәреп алды. Бер мизгелгә десантниклар үзләренең хәрби өйрәнүгә баруларын да, алда мең-мең сынаулар торуын да оныттылар. Бөтен җирдә, бөтен дөньяда бары тик җыр, шушы җыр гына калды, ул әле генә боегып утырган егетләргә канат куйды,

йөрәкләргә дәрт, кыюлык өстәде, аларны бөркет итеп күккә күтәрде.

Машина тормозлары ачы итеп чыелдады. Солдатлар дәррәү җиргә сикереп төштеләр. Җыр, басу өстендәге тургай кебек, һавада тирбәлеп калды. Төшкән уңайга тезелделәр дә, команда яңгырауга, самолетка таба йөгерделәр. Самолетның иләмсез зур крокодил авызына охшаган «капкасы» күз ачып йомганчы десантникларны «йотып» җибәрде. Аннары авыз акрын гына ябыла башлады. Рифкать, күрәсеңме дигәндәй, Илдуска төртте. Илдус гадәттәгечә башын гына кага ул, беркайчан да сиңа каршы килми. Кайчакта бу Рифкатьнең ачуын да китерә, ләкин ул моңа күнегеп бара. Менә хәзер: «Әйе шул, бигрәк зур»,— дисә, теле өзелеп төшмәс иде бит.

Монысы — Рифкатьнең инде сигезенче сикерүе. Ә шулай да ияләшеп бетә алмый әле. Бу самолетны десантниклар, яратып, үз итеп, «оча торган сарай» дип йөртәләр. Чыннан да, бигрәк зур шул, Рифкатьләрнең ике катлы казармалары хәтле булыр... Беренче тапкыр сикергәндә, шактый шүрләгән иде. Әле хәзер дә, шул искә төшсә, оялып куя. Ул сикерә торган люк пропеллер белән янәшә иде. Сикерүгә үк, пропеллерга килеп эләгер кебек тоелды аңа. Командир: «Киттек!» — дип, җилкәсенә кулын куйгач, берара икеләнеп калган иде. Аннан күзләрен чытырдатып йомды да сикерде. Сикерүгә үк, тыгыз җил агымы аны артка таба чөеп җибәрде. Бүген ничек булыр икән? Күңел түрендә посып яткан курку хисе бүген тагын баш калкытырмы? Төнлә беренче тапкыр сикерүләре бит.

«Крокодил авызы» ябылып беткәч, самолет акрын гына гүли, калтырый башлады. «Нәрсә бу, моңа кадәр болай булганы юк иде бит, әллә авырыйммы?» — дип уйлады ул. Ә башы аның саен ныграк авырта. Рифкать, авырту басылмасмы дип, маңгаен самолет тәрәзәсенең салкын пыяласына терәде. Тәрәзә артында, кул сузымы гына ераклыктагы офыкта, кызыл мишеньгә охшаган кояш күтәрелеп килә. Таң ата.

Тәрәзә аша төшкән кызыл кояш нурларыннан солдатларның йөзләре бронза төсенә кергән. Рифкать, тәрәзә артындагы матурлыкны күрсәтергә дип, Илдуска дәшмәкче булган иде, түшәмдә кабынган сары утны күреп, уеннан кире кайтты.

— Әзерләнергә!

Бронза һәйкәлләргә охшап утырган десантниклар калкынып куйдылар, парашютларын, автоматларын рәтләгәч, дәррәү торып бастылар. Шулчак түшәмдә яшел ут кабынды. Тавыш-тынсыз гына люклар ачылды.

— Киттек! — дип кычкырды командир.

Бүген рәт башында Вагыйз тора. Бүген ул беренче булып сикерәчәк. Беренче булып сикерү бигрәк куркыныч-тыр, дип уйлады Рифкать. Иксез-чиксез күк дәрьясына берүзең, ялгызың гына чумасың бит. Берүзең генә су коенган кебек. Самолетта бөркү. Их, су коенудан да рәхәт нәрсә бар микән дөньяда?! Әтисе карьерда эшләгәндә, көн саен барып йөри иде Рифкать. Ул алып килгән ризыкны бергәләп ашыйлар да, хуш исле печәнгә чалкан ятып, бераз хәл җыялар.

— Үскәч, кем булырсың икән син? — дип сорап куя әтисе.

Икесе бергә калдылармы, гел шулай дип сорый ул. Ә Рифкать ни дип тә җавап бирергә белми.

— Ә бабай нигә Түбән Камага килми? — дип, әтисенең соравына сорау белән җавап бирә ул.— Анда ялгызына читендер бит, бездә яшәр иде.

— Әллә ничә әйтеп карадым инде. Киләме соң? Үзең күрдең бит, кунакка килгәч тә, бер кич кунуга: «Илмәт, Илмәт»,— дип сөйләнә башлады. Авылы да ерак түгел, Кама аръягында гына бит. Кайтып-китеп йөрер иде. Юк шул, аерып булмый кешене үз нигезеннән.

— Менә сез аерылгансыз бит әле. Авылны ташлап, Кизелгә дә киткәнсез, монда да килгәнсез.

— Әй, улым, үз ихтыярың белән йөрүмени ул. Нужа куып йөртте бит, нужа. Сугыштан соң, бәхет эзләп, ярты авыл шахта ягына кузгалды. Әниең белән без дә шуларга иярдек. Шунда тормыш корып җибәрдек. Ике авылдаш бергә булгач, азрак күңел дә тынычланып китте, ике сагышны бер итеп яшәдек инде шунда. Аннары сез дөньяга килдегез. Ә менә син: «Нигә авылны ташлап киттегез?» — дисең. Яратмаганнан дип уйлыйсыңмы әллә? Яра-ту гына түгел, чуар тавыкларына, урам этләренә кадәр сагына идем, төнлә төшләремә кереп тилмертә иде. Кан береккән, җан береккән инде безнең ул авылга. Ата-баба туфрагы бит. Кама буенда шәһәр салынуын ишеткәч, дәррәү күтәрелеп кайтып төштек. Ни өчен кайттык дисең? Шәһәр кайда да шәһәр инде ул: таш белән тимер дә тө-

тен. Үзебезнең якка, туган якка якынрак булыйк, дидек. Ә менә авылга ук кайтып җитеп булмады. Бер аерылып киткәч, кире кайтулары, һай, кыен ул! Авыл безне үз итмәс, кешеләре иш итмәс кебек тоелды.

Рифкать чалкан яткан да күктә талпынып-талпынып сайраучы тургайны күзәтә.

— Әллә тыңламыйсың да инде?

— Тыңлыйм, тыңлыйм.

— Нәрсә тыңлыйсың, тургайнымы?

— Әткәй, ә мин, үскәч, авылга кайтам. Харис бабай белән бергә яшим. Печән чабам, утын китерәм, гармунда уйнарга өйрәнәм.

— Һе-һе,— дип көлемсери әтисе.— Карарбыз, азрак күзең ачыла башласын әле.

Аннары ул фуражкасын батырып кия дә, олы-олы атлап, экскаваторына таба китә. Чылбыр тәгәрмәчкә менеп баскач, артына борылып, Рифкатькә кычкыра:

— Әйдә, утырасыңмы? Йөртергә өйрәтәм.

— Юк! — дип кычкыра Рифкать.— Юк! Мин балык тотам. Уха пешерәм.

Кармак таягын текә ярга кадап куйгач, ул аскарак төшеп чишенә дә суга чума. Ләкин артык эчкә керми, яр буенда гына йөзә. Әтисе белән йә Әнфисә белән коенганда, бу күлне аркылыга-буйга иңләп йөри ул, ә үзең генә булганда ничектер куркыта. Юк, батудан курыкмый ул, кирәк булса, Рифкать Каманы да аркылы йөзеп чыга ала. Су түгел, ялгызлык куркыта бугай аны. Мәктәптә дә, урманда да берүзе йөрергә яратмый ул, өйдә дә ялгызы каласы килми. Янында кеше булмаса, бик тә моңсулана, хәтта башы авыртырга тотына. Әле менә хәзер дә чигәләре кыса. Яр буенда экскаватор үкерә, аның тавышы да миен бораулап-бораулап керә.

— Киттек!

Рифкать, сискәнеп, башын күтәрә һәм каршында янып торган яшел утны, бераз алга иелеп баскан десантникларны күреп елмая. Соңгы арада шулай бик еш хыялга чума башлады әле ул. Әллә сагындыра инде. Менә бу өйрәнүләр үткәч, озакламый көз дә җитәр. Ә аннары — отпуск!

Самолет моторларының тонык, авыр гүләве колакларны чыңлата. Әйтерсең кемдер иләмсез зур агач тукмак белән башка суга да суга, суга да суга.

Каршында — ачык люк. Командирның «Киттек!» дию-

ен ишетү белән, ул алга ыргыла. Тизрәк сикерергә, тизрәк котылырга кирәк бу мәхшәрдән. Самолеттан сикерүгә, мотор тавышлары тынуга, салкын җил кочагына чумар да баш авыртуы басылыр кебек тоела аңа. Ләкин бер адым атлауга, битне кайнар дулкын сыйпап ала, аркасы, бөтен тәне буйлап ток йөргәндәй була. Әйтерсең ул очмый, ә бер урында һавада асылынып тора. Аннары әкренәкрен баш авыртуы да кими. Бөтен тән буйлап рәхәт җылылык йөгерә. Еракта, бик еракта кемнеңдер сөйләшкәне ишетелә.

## 3

— Хәле ничек? — ди калын тавышлы ир кеше.

— Саташа. Вакыт-вакыт онытылып китә. Кычкыра. Укол кадагач, тагын аңына килә. Бик күп кан югалткан. Кан бирергә кирәк.— Тавышы ягымлы хатын-кыз, гаепле кеше сыман, бик тә борчылып сөйли.

— Өлкән лейтенант Сидоров, ротага хәбәр итегез, рядовой Миргазизовка кан кирәк, диегез. Округ госпиталеннән хирург килеп җитмәдеме?

— Берничә минуттан самолетлары аэродромда булачак. Каршыларга машина җибәрдек.

— Яхшы. Барыгыз.

Таныш тавышлар ишеткәч, Рифкать күзләрен ача. Палатада шул ук кешеләр. Генерал гына киткән. Аның урындыгында полк командиры утыра. Сул кулына шприц тоткан халатлы апа уң кулы белән аның битен сыйпый. Кулы шундый җылы, йомшак. «Битне сыйпаган җылы җил шушы икән»,— дип уйлый Рифкать.

— Уяндыкмы? Хәлләр ничек? — дип, акрын гына, сак кына сүз башлады полковник.

— Иптәш полковник, авыруны борчырга ярамый, ул бераз ныгырга, хәл җыярга тиеш.

Рифкать күз карашын врачка таба күчерде. Түгәрәк йөзле, коңгырт чәчле. Маңгаенда сырлары да бар. Нәкъ аның әнисе инде. Мөлаем, моңсу күзләрендә әнисенеке төсле бераз киная дә бар төсле. Әйтерсең Рифкать берәр ярамаган эш эшләгән дә, ул аны: «И-и, шулай итәләрме соң, нәрсә уйладың соң, бала?» — дип, яратып кына ачулана сыман.

— Бик авыртмыймы, улым? Яхшы, яхшы. Тик кенә ят. Кыймшанма, улым, кыймшанма. Хәзер менә кан бирәбез. Хирург та килеп җитәр.

Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки, врач апа сөйләшкән саен, баш авыртуы кими бара, баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә, кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә. Аннары ул җылы бергә җыела да тамак төбенә килеп тыгыла. «Еламаска, еламаска! Еларга ярамый!» — дип, эчтән генә кабатлый Рифкать. Шуңа гаҗәпләнә ул: кыйнаганнары да, ачуланганнары да бар аны, берчакта да еламый иде. Ә менә җылы сүз ишеткәч, «улым» дип битеннән сыйпагач, ирексездән күңеле тулды да куйды.

Ул озак кына, бернәрсә дә уйламаска тырышып, түшәмгә карап ятты.

Шулчак, сулык-сулык килеп, уң кулы сызларга тотынды, сызлау тора-бара бөтен гәүдәсенә күчте. Ул тешләрен кысты, йөзе җыерылып килде. Аңа тагын укол кададылар, бераздан авыртуы басыла төште, ул, хәлдән таеп, бер хәрәкәтсез ята бирде. Әйтерсең аны бик каты кыйнаганнар да, ул, әнисе сизмәсен дип, тын гына ята. Ыңгырашмый да, зарланмый да. Ә әнисе, сизсә дә, сизмәгәнгә салыша: «Нәрсә, әллә арыдыңмы? Ят, ял ит, авырып китә күрмә тагын»,— дип юата.

Аның эчендә ачу кайный. Шул малайларга кыйнатып торган өчен, җаны әрни... Арттан килеп сукмаган булсалар, үзләренә дә эләгәсе иде...

## 4

Алар, Энфисә, Галия, Илдус, Рифкать, танцыдан кайтып килгәндә, каршыга биш малай чыгып басты. Арадан берсен, сары чәчле, олы башлы, озын гәүдәле егетне инде берничә тапкыр күргәне бар Рифкатьнең. Күрше мәктәптән, баскетбол командасында уйнап йөри. Танцы мәйданчыгыннан читтәрәк бер эскәмиядә Рифкать гитара уйнап утырганда, өерләре белән әллә ничә бөтерелгәннәр иде. Малайлар, кызлар Рифкать утырган эскәмияне сырып алганнар да шау-гөр киләләр. Әле көлешәләр, әле җыр башлап җибәрәләр. Ә тегеләр ни танцыга бармыйлар, ни бу төркемгә килеп кушылмыйлар.

— Әй, тартырга бармы? — дип сорады озын буйлы егет эскәмиядәгеләрдән.

— Тартмыйбыз бит, әнә, безнең өчен химкомбинат торбасы тарта.— Тәлгать илтифатсыз гына шәһәр читендә кара төтен болыты ургып торган иләмсез биек торбаларга таба ымлады.

Әнфисә белән Галия пырхылдап куйдылар.

Озын буйлы егет кабаланмый гына кесәсенә тыгылды. Егетләр-кызлар, нидер көтеп, тын калдылар, гитара да, җыр авазлары да өзелде, бары тик танцы мәйданчыгында гына, колакларны чыңлатып, музыка авазы ишетелә иде. Егет, башын чайкап, тузган чәчләрен артка чөйде дә уч төбеннән бер бакыр акча алып, Тәлгатькә сузды:

— Никулинга өч тәңкә түләп кергән идем. Мә, үз бәяңне ал, юморист! Кәмит күрсәтсәң, биш тиен дә бирермен.— Шулай диде дә, инде үзенә каршы сүз әйтә алмаслыгына ныклап ышангандай, авызын ерып җибәрде. Аннары, кисәк кенә борылып, Галияне култыклады: — Әйдә, чибәркәй, бер селкенеп килик әле!

Галия башта югалып калды, ләкин, тиз генә аңына килеп, кулын тартып алырга теләде:

— Җибәр! Авырттырасың!

Ләкин егет аңа колак та салмады, Галияне өстерәп диярлек музыка гөрелтесенә таба баруында булды.

— Җибәр, дим! Нәрсәгә каныктың, оятсыз!

— Минме оятсыз? Ха-ха-ха! — Егет көчәнеп кенә көлде.— Минме оятсыз? Оятымның кайда икәнен күрсәтер идем инде мин сиңа.— Ул тешләрен шыгырдатты да чертләтеп төкерде.— Бала-чага бар. Әйдә, читкәрәк...

«Сары баш»ның әйтә башлаган җөмләсе ярты юлда өзелеп калды, Галия, кулы бушаганны сизеп, бер читкә йөгерде.

Рифкать егетнең сул кулын артка каерып китергән, ә тегесе, авыртудан кыймшанырга да кыймыйча, алга бөгелгән килеш тик басып тора иде. Менә ул ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Егетләр! Нәрсә карап торасыз? Егетләр, бирегез шуларга!

Ләкин «егетләр» урыннарыннан кыймшанмадылар, танцы мәйданчыгы янында йөрүче дружинникларга карап, бер урында тик басып тордылар.

— Җибәр! Сиңа тигән кеше юк бит.

— Әгәр тагын кызларга кагыласы булсаң, тәмәкенең кайда үскәнен күрсәтермен мин сиңа.— Ачудан Рифкатьнең тавышы калтырап чыга иде.

Рифкать, синең белән нигә кул пычратам дигәндәй, җирәнгән кыяфәт белән егетне этеп җибәрде.

— Бар, әниең янына кайт. Сөйләшергә өйрәнмичә, монда күренәсе булма.

«Сары баш» сөрлегеп китте, ләкин егылмады, барган уңайга гәүдәсен турайта-турайта, куаклар арасына кереп югалды. Моңа кадәр, кузгалырга да куркып, бер урында шым торган дүрт егет аның артыннан иярде. Бераз баргач, алар, туктап, куак төбендә казына башладылар.

— Ни эзлисез анда? Әллә җир тишегенә кереп качмак буласызмы? — Ниһаять, Илдус та телгә килде.

— Синең кебек бер бәләкәй малаебызны шушында калдырган идек. Еламасын дип. Шуны таба алмыйбыз.— Озын буйлы егетнең тавышы тагын көрәйгән, аңа элекке усаллыгы кире кайткан иде.

— Кара аны, артык шалтырама, баганаң башына фонарь элеп куймасыннар.— Илдус бер-ике адым алга атлап куйды.

— Ташла, Илдус, тәмәке төпчеге эзлиләрдер,— дип, Рифкать аның итәгеннән тартты. Аннары гитарасын, солдатлар автомат аскан сыман, җилкәсенә шудырып куйды да уң кулын дустының иңбашына салды һәм әкрен генә атлап китте. Үзе гамьсез генә сызгыра, үзе тегеләргә таба бара. Аның артыннан башкалар да иярде. Агач төбендә казынучы «Сары баш»ның кулында нидер бар иде бугай, шуңа күрә исе китми, сукмак уртасында басып тора. Аның артында «тән сакчылары» караеп күренә. Ләкин, үз өстенә тоташ стена булып килүче малайларны күргәч, ул югалып калды, бераз таптанып торды да, кыеклый-кыеклый атлап, әкрен генә китеп барды.

— Аракы исе аңкый үзеннән,— диде Галия.

— Кесәсенә ниндидер тимер салды, тагын берәрсенә бәйләнә инде болар,— дип өзгәләнде Илдус.— Өченче көн генә бер егетнең башын ярганнар иде.

Ләкин болар сөйләшеп торган арада, колга егет тә, аның иптәшләре дә юкка чыккан иде инде. Тегеләйгә чабып карадылар, болайга йөгерделәр — җир астына кереп киттеләрмени, эзләре дә юк.

— Фу, бандитлар,— дип, алар югалган якка йодрык күрсәтте Әнфисә.

— Борын салындырмагыз, әйдәгез, көлегез әле,— диде Рифкать. Аннары, нәрсәдер исенә төшергәндәй, кинәт кенә кычкырып җибәрде: — Рөстәм, Галия, Сережа, Илдус, Тәлгать, әйдәгез, Саша янына!

— Ни сөйлисең, Рифкать, безне бу вакытта кем больницага кертсен? — диде Тәлгать.

— Ә без кермәбез, тәрәзә төбендә генә торырбыз. Гитара уйнарбыз, җырларбыз.

— Берүзенә күңелсездер аның,— дип, Әнфисә Рифкатьне куәтләде.

— Хәле бик авыр аның, малайлар, безнең күршедә врач тора, шул әйтте, терелеп чыгуы да икеле, ди.

— Әйе, әйе,— дип, Сережаны баш кагып тыңлады Илдус.— Умыртка сөяге сыну уен эш түгел.

— Киттек, егетләр, киттек! — диде Рифкать һәм, дәртләндереп, егетләрнең җилкәләренә суккалады да, гитарасын алып, озын көй башлады.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Менә кызык, караңгы төн, дип җырлыйлар, ә җырлаган саен, киресенчә, төн яктыра барган кебек. Бигрәк серле, сихерле инде бу җыр дигән нәрсә. Җыр булмаса, дөнья бик тә күңелсез булыр иде.

Больница ишегалдына кергәч, җырлаудан туктадылар. Тәрәзәдә утлар балкый. Тәрәзә аша палаталарның ак түшәме, ак стеналары күренә.

— Кайсы тәрәзәдә икән соң ул? — дип пышылдады Илдус.

— Теге якта,— диде Рифкать.

— Каян беләсең?

— Мин монда көн саен киләм. Палатадагылар өйрәнеп беттеләр инде. Килгәнне көтеп торалар. Саша гына тәрәзә янына килә алмый. Ләкин барыбер ишетә бит ул. Сөйләшә дә.

— Рифкать, Сашаның тәрәзәдән сикерүе дөресме? — дип, кыяр-кыймас кына сорады Тәлгать (ул бүтән мәктәптә укый, шуңа күрә бу турыда кешедән ишетеп кенә белә иде).

— Сикергән шул.

— Сикереп дөрес тә иткән,— дип чәчрәп сүзгә кушылды Әнфисә.— Егет кеше андый чакта ике уйлап торырга тиеш түгел.

— Кызлар бит аңа яхшылык эшләргә теләгәннәр. Азрак акылга утыртмакчы булганнар.

Илдус, кызларны яклавына үзе дә оялып, башын аска иде.

— Дәрестән соң алып калып самосуд оештырганчы, кызларга башта эшнең нидә икәнен, Сашаның нигә начар укый башлаганын ачыкларга кирәк иде. Ә алар тотканнар да тәрбия эшенә тотынганнар.— Рифкать ачудан гитара кылларына берьюлы биш бармагы белән сугып куйды. Гитара ыңгырашты да тынды, Рифкатьнең дә ачуы басылды.

— Фу, кызларның шул инде аларның,— дип, саргылт кашларын җыерып куйды Әнфисә.— Алга-артка карап тормыйлар, турыга яралар. Ә Сашаның начар укый башлавының үз сәбәбе булган. Әйбәт кенә укып килгән егет тик торганда икеле ала башламый бит инде. Димәк, ул йә берәр начар компаниягә ияргән, йә аның өендә бер-бер хәл булган. Өйләрендә гауга купкан аларның, этисе белән энисе аерылышуга кадәр барып җиткән. Билгеле инде, шундый чакта кемнең кәефе булсын да, кемнең дәрес әзерләп утырасы килсен. Малаебыз көннәр буе, кичләр буе урамда каңгырып йөри икән. Шул чакта кызларга аның күңелен юатырга, үзләре арасына алырга кирәк иде дә бит, ә алар тотканнар да самосуд оештырганнар.

— Ул әйткән бит, кисәткән бит,— дип, Әнфисәне бүлдерде Рифкать.— Хәтта ялынган да бугай әле. Кызлар, чыгарыгыз, чыгармасагыз, тәрәзәдән сикерәм, дигән. «Хөрәсән судьялар» көлгән генә. Сикерә, имеш, каян килгән Котовский. Ә ул тоткан да ачык тәрәзәдән урамга сикергән...

— Тсс...— Әнфисә бармагын авызына куйды.— Ачык тәрәзә шуларныкы бугай, ишетмәсен.

Тәрәзә төбенә килеп җитүгә, Рифкать, сигнал биргәндәй, гитараның иң нечкә кылына чиертеп алды. Шунда ук тәрәзәдән берничә баш күренде.

— Килде, безнең гитарист килде! — дип шаулашты алар.— О-о, бүген тулы бер ансамбль болар! Саша, дустың килде.

— Безнең «парашютист»ның хәле ничек? — дип кычкырды Рифкать.

Палата эченнән Сашаның тонык кына тавышы ишетелде:

— Исем китте, сез килде дип сикереп тордым ди менә. Рәхәтләнеп ятам әле.

— Сикерүен сикергәнсең, ә парашют алырга оныткансың,— дип шаяртты Әнфисә.

— Соң син морфлотка китәм дигән идең бит, нишләп десантныйга язылырга булдың әле? — Рифкать шулай диде дә, ник әйткәненә үкенеп, башын аска иде. «Кая инде хәзер аңа морфлот? Сынган умыртка сөяге белән, адәм рәтенә кереп, тигез җирдән атлап йөри алса да, әйбәт булыр әле. Юкка әйттем, морфлот дип авыз суларын корыта иде бит ул. Иң авырткан җиренә кагылдым»,— дип уйлады Рифкать.

— Мин бит үземне океан лайнерында йөзәм дип уйладым. Корабка «дошман» басып кергәч, тоттым да суга сикердем. Ләкин мин йөзәсе диңгез өстен асфальтлап өлгергәннәр икән.

— Әй, Рифкатьме әле исемең? Ташлагыз әле юк сүз сөйләвегезне. Сашагыз нык егет, бирешә торганнардан түгел, терелер, капитан гына түгел, контр-адмирал булыр әле.

— Контр булдым инде, адмирал буласы гына калды.

— Әй, җырлап күрсәт әле,— дип, өзелгән сүзен ялгап китте тәрәзәдәге агай.— Мать якасына ул авыру-сырхауларның. Шул гитараңда бер җыру сузып җибәр! Дару түгел, җыру терелтә адәм баласын. И-их, гармунда уйнасаң икән син. Бу шалтыравыгың күңелне кытыклап кына уза бит ул. Ә гармун бар хәсрәт-кайгыңны актарып чыгара.— Агай: — И-их,— дип, озын итеп сузып куйды да буй-буй больница күлмәгенең якасын ачып җибәрде.— И-их, без яшь чакта... Әйдә, Рифкать энем, чиртеп җибәр әле шул нечкә муенлы нәрсәңне!

Рифкать гитара кылларын барлап чыкты, аннары авызын тутырып елмайды, тыңлагыз дигәндәй, тәрәзәгә күтәрелеп карады. Тәрәзә төбенә сөялгән агайның ачык якасыннан бинт белән уралган күкрәге агарып күренә, уң кулы, гипслап, муенына асып куелган: күкрәгенә ак биләүле сабый кысып тоткан диярсең.

— Ә син үзең турында сөйлим дигән идең бит. Ничек больницага эләгүең турында. Сөйләмичә — уйнау юк.

Рифкать, чынлап әйтәм дигәндәй, гитараны аркасына ук этәреп куйды.

— Нәрсәсен сөйлисең аның?

— Сөйлә инде!

— Сөйлә, абый!

— Ялындырма инде!

Егетләр-кызлар, берсен-берсе бүлеп, агайны кыстый-үгетли башладылар.

— Муеныгызны сузып тормагыз, әнә теге каралты өстенә менегез. Аннан палата эче дә уч төбендәге шикелле күренергә тиеш. «Парашютист»ны да күрерсез.

— Әй, шуңа да башыбыз җитмәгән. Киттек, егетләр!

Әнфисә артыннан тәрәзә каршында гына җиткерелә башлаган каралтының караңгы баскычы буйлап менеп киттеләр.

— Берни күренми бит монда.

— Аякны сындыра яздым.

— Әнфисә, яулыгыңны чиш әле, сары чәчеңнән яктылык төшмәсме?

Шулай көлешә-көлешә өскә менеп җиттеләр дә, тәрәзә каршына аякларын асылындырып, тезелеп утырдылар.

Чыннан да, палата эче моннан аермачык күренә икән. Әнә, аларга карап, Саша елмайды, кузгалырга иткәндәй, аз гына, акрын гына талпынды да кебек.

— Сез монда алтау икән бит,— дип гаҗәпләнүдән сызгырып куйды Рифкать.— Тора алмыйлармыни?

— Тора алган кешене бу палатага кертмиләр шул. Менә мине инде берничә көннән күчерәбез, диләр. Ремонтлап бетердек, слесарный мастерскойдан чыксаң да була, диләр. Дару исе иснәп тә туйдым, тизрәк кайтырга иде инде. Тракторым да көтәдер.

— Сөйлә инде...

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның. Сөйлә дә сөйлә, диләр. Район гәзитеннән дә Рәхим атлы олы башлы корреспондент килеп, ярты көн төпченеп утырды. Сорамаган нәрсә калдырмады, җиде бабама җитте, кабер ташларындагы язуларга кадәр сорашты. Гәзиткә язып чыгарган. «Герой» дигән булган. Һе-ем, агай-эне, кинода күргән бар, герой андый булмый ул. Трактор нәрсә ул? Тимер өеме. Тимер өчен яшәми бит кеше. Үзе өчен яши, гаиләсе, дусише өчен яши, кеше өчен яши. Тракторга ни аңа, кот-

кардың ни дә, коткармадың ни, җаны юк бит аның, берни аңламый ул.

— Ә үзең тракторым көтәдер, дисең.

Башка вакытта сүзгә кушылмый, ни әйтсәң дә, «әйе», «әйе» дип баш кагып кына торган Илдуска бу юлы кыюлык каян килгән диген.

— Көтә, дип... ияләштем инде мин аңа, егетләр. Баштарак йоклый алмый идем, төшләремә керә иде.

— Ничек коткардың соң син аны?

— Былтыр җәй бик коры килде бит. Инешләр корып бетте, чишмә хәтле генә калды. Янгын-мазар чыкса, чиләк тутырып алырлык та су юк. Миңа бульдозер белән буа буарга куштылар. Көне буе эшләдем дә, тракторны буа каршында калдырып, өйгә кайттым. Ашап-эчеп йокларга гына яткан идем: «Ут чыккан, ут чыккан! Галимҗан абзыйның тракторы яна!» — дип, урам буйлап бер малай йөгереп узды. Аннан безнең капканы дөбердәтә башладылар. Чалбарны гына эләктердем дә чыгып чаптым. Килеп җитсәм, тракторымны арттан ялкын ураган. Җирдә яткан майлы бишмәтемне алдым да утны кыйнарга тотындым. Ә ул сүнәргә уйламый, суккан саен, күпереп-күпереп китә. Бишмәтне ыргыттым да пускачка барып тотындым. Пускач бавы уралып беткән. Димәк, бала-чага шаярган. Аны чишеп, рәтләп бетергәнче, ут кабинага ук керде. Болай булса, ягулык багы кызып шартлаячак, аннары инде тракторың вәссәлам, диген. Бер тарттым пускачны, ике тарттым — кабынды бит, җаным, хуҗасын таныды. Калганын инде үзем дә юньләп хәтерләмим. Ут чорнаган кабинага атылып кердем дә арткы скоростька салдым. Тракторны көндез буган буага алып кереп киттем. Шуннан соң уянып китсәм, больницада ятам.

— Ә янып үлгән булсаң,— диде Тәлгать.

— Андый чакта алдын-артын уйлап торасыңмыни инде аның...

— Үзең, тракторның җаны бармыни, нәрсә аңлый ул, дисең, үзең шуның өчен утка керәсең. Аңлашылмый.— Рифкать, аптыраган кыяфәт белән, кулларын җәйде.

— Җаны юк, дип... Аның җаны булмаса, минеке бар бит. Җаны булган кеше ничәмә-ничә ел эшләгән тракторын күрәләтә утка саламыни? Аннары, егетләр, нигә шул бер сүзгә бәйләндегез әле. Җаны юк та җаны юк. Ха-

тын-кыз шикелле.— Галимҗан агайның тавышы калтыранып китте.— Менә шул җансыз трактор үстереп биргән икмәкне бөгәсез бит әле. Җансыз дип тормыйсыз.

«Кем тигән соң аңа?», «Нишләп яна башлаган?» дип күпме генә сорашырга, аның телен ачарга теләсәләр дә, агай сүзгә кушылып китмәде. «Аптыратмагыз әле, белмим»,— диде дә больница коймасы артындагы иген басуына карап тора бирде. Шулчак Рифкать эчтән генә көлемсерәде дә гитарасын алды.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы трактор кирәк үтәргә...

Агай бөтен палатаны яңгыратып көлеп җибәрде.

— Их, шельмалар, их, рәхмәт төшкерләре. Хәзерге яшьләр уен-көлке өчен генә яралгандыр алар. «Яхшы трактор кирәк» дисезме? Менә шул яхшы трактор янына сезнең кебек әзмәвер егетләр дә кирәк бит. Кая инде сезгә, фанер такта чиртеп, урамда трай тибеп йөрүдән башканы белмисез. Белмим инде, белмим, кая бара бу дөньялар, үскәч, кем булырсыз...

— Иртәгә өчен ишәк кайгырткан,— дип, илтифатсыз гына әйтте Сережа.

— Ишәк тә кайгырган, ди. Ә син, иртәгәңне уйламагач, ишәктән дә кайтыш буласың инде.

— Әй, син анда, картлач, чамалабрак сөйлә! — дип кызып китте Сережа.— Юкса монда...

— Туктале, әтәчләнмә әле! — Рифкать Сережаның терсәгеннән тотты.— Ә син, агай, кайгырма, кешедән ким булмабыз.— Шулай диде дә гитарада җитез генә бер көй уйный башлады.

Утларга да бер керербез әле,
Без менәрбез әле күкләргә,
Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

— Шулай бит, Саша,— дип кычкырды Рифкать һәм җырын ялгап китте:

Без кайтырбыз ныгып, ирләр булып,
Ике елы бик тиз үтәр дә.
Уттан чыгар солдат мәхәббәте...
Риза булса кызлар көтәргә.

— Булдырасыз, егетләр, юкка тел тидердем бугай сезгә,— диде агай, җыр тәмамланугa.— Колакка кергән җыр түгел, яңадыр инде. Безнең бабай мәрхүм әйтә торган иде: «Солдатка бармаган кеше гомер буе малай булып кала, ир була алмый»,— ди торган иде. Хак булган шул сүзләре, әнә, безнең авылныкылар, киткәндә, песи кебек юаш кына малайлар иде, арыслан булып кайттылар. Ә армиягә бармаганнарның күбесе кибет төбе саклап утыра. Тегеләрнең дә утте ике ел гомере, боларның да. И-их!

— Йөриләр шунда урам буйлап киләп сарып. Билләренә кадәр чәч үстергәннәр, җитмәсә. Кызмы, егетме икәннәрен дә белерлек түгел. Менә шулар арасыннан чыга инде бандитлар! Барыгыз, барыгыз, авыру кеше җанына тоз салып йөрмәгез! Болай да шау-шу җитәрлек монда...

Берсе-берсе икешәр потлы җәен балыгы хәтле кулларын тәрәзә тупсасына җәеп салган хатынның ачулы сүзләрен ишеткәч, барысы да тын калдылар. Тирә-юнь кинәт кенә салкынаеп, шыксызланып киткәндәй булды. Бу үле тынлыкка хатын үзе дә аптырап калды бугай: авыз эченнән нидер мыгырданды да тәрәзәне шапылдатып ябып куйды. Тавыштан сискәнеп уянган тополь яфраклары, берсен-берсе уздыра-уздыра, кул чаба башладылар.

— Әй, егетләр, кызлар! Тагын җырлагыз әле!

— Әйдә, егет, өздер әле!

— Әйдә, алайса, үзебезнең җырны җырлыйбызмы әллә? — диде Рифкать.

Озатып вокзаллар каршында
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар.

— Үзебез Саша янына килдек, үзебез аны бөтенләй оныттык,— диде җыр тәмамлангач Рөстәм.

— Әйе шул.

— Юк, юк, мин сезне тыңлап ятам бит. Сезнең белән сөйләшеп туйган инде, ә менә җыр тыңлау рәхәт.

Рифкать сизеп тора: Саша бүген кирле-мырлырак сөйләшә. Үзе янына шулкадәр кеше килүенә, дуслары килүенә эчтән генә сөенә иде ул. Ләкин үзенең шулай хәрәкәтсез, хәлсез ятуын аларга күрсәтәсе килми, бигрәк тә кызлар алдында уңайсыз аңа. Рифкать үзе генә килгән-

дә, сәгатьләр буе сөйләшә иде бит. Ә бүген гел кирегә сөрә. Юк, аларга түгел, үзенә ачуы чыккан аның.

— Ярый, алайса, без киттек,— диде Рифкать.

— Сау бул, Саша!

— Тизрәк терел.

— Сау бул, агай!

— Тракторыңа бездән сәлам әйт.

Егетләр, караңгы баскычтан капшана-капшана төшеп, больница капкасына таба атладылар. Алар артыннан: «Тагын килегез!» — дип кычкырып калдылар.

— Егет кеше гармун уйный белергә тиеш. Гармун белән килегез!

Арада тракторчы агайның тавышы аерылып тора иде.

Тәрәзәләр берәм-берәм ябылды, палаталарда утлар сүнде. Көләч йөзле кеше шикелле балкып торган больница кинәт төсен югалтты, караңгыланып калды. Әйтерсең ул моңа кадәр, уен-көлке, музыка-җыр белән күңел юатып, онытылып торган да менә хәзер аның эчендә бөтен әгъзалары сызлый башлаган. «Ә минем бер тапкыр да больницада ятканым юк,— дип уйлады Рифкать.— Саша ничек түзә икән? Аңа кузгалырга да ярамый бит. Хәзер үкенәдер дә бит. Аның урынында булсам, мин нишләр идем икән?»

Урамга чыккач, саубуллаштылар да, ике төркемгә бүленеп, ике якка китеп бардылар.

## 5

Рифкать әкрен генә гитарасын чиертә. Тик берсе дә җыр башламый. Әллә инде шаярып-көлеп туйганнар, әллә инде төнге шәһәр тынлыгын бозарга кыймыйлар — сүзсез генә атлыйлар да атлыйлар.

— Сашаның хәле шәптән түгел,— дип үзалдына әйтеп куйды Илдус.

Аңа җавап бирүче булмады. Бераз баргач, Әнфисә кинәт кенә гитара кылларына уч төбе белән басты.

— Тукта әле, Рифкать! — Больница янында гел басынкыланып калган иде, ә хәзер аның тавышында чаялык сизелеп куйды.— Безнең класста Саша турында һаман имеш-мимешләр йөри бит. Берәүләр аны яклый, дөрес сикергән, ди, кызларны гаепли, ә кайберәүләр исә — киресенчә...

Галия Әнфисәгә кушылды:

— Тәнәфес саен бөтен класс шуның турында чыш-пыш килә. Кемгә ышанырга, кемне якларга да белгән юк.

— Класста җыелыш җыеп, шуны хәл итәргә иде,— диде Әнфисә.

— Саша да инде...— дип куйды Илдус.

— Нәрсә Саша, Сашага нәрсә булган? — Рифкать сабыр гына Илдуска күз ташлады.

— Нәрсә булган? Юләрлек эшләгән. Кызлар ачуланган саен, тәрәзәдән сикерә башласаң, дөньяда исән кеше калмас иде.

— Аңламыйсың син, Илдус,— дип, Әнфисә Рифкатьне яклады.

— Аңламыйсың. Эш монда кызлар ачулануда гына түгел, эш — принципта.

— Принципта, имеш. Принцип дип, тәрәзәдән сикерәләрме инде, йә?

— Синеңчә, нәрсә эшләргә тиеш иде соң ул? — диде Рифкать.

— Анысын белмим. Ярый, сикерде ди. Шуның белән нәрсә исбат итте инде? Үзенең юләрлегенме?

Рифкать, арттырып җибәрәсең дигәндәй, ачу белән Илдуска карады.

— Менә син, Илдус, аның урынында булсаң, нишләр идең?

— Нигә миңа бәйләнәсез әле? Нишләр идем. Бер нәрсә дә эшләмәс идем. Партага утырыр идем дә кызлар акылга килгәнче кыймшанмас идем.

— Ә алар акылга килмәсә? Синнән көлсә, сәгать буе акыл өйрәтеп торса?

— Белмим лә!.. Мәгънәсезгә тәрәзәдән сикерергә кем дип белдең соң мине?! Баш ике түгел бит. Әнә теге агай шикелле тракторың янып, шуны коткарырга дип утка керсәң — башка эш. Тракторы да исән, үзе дә исән, әле гәзиттә дә «герой» дип язып чыкканнар. Ә Саша янына синнән башка килеп караган кеше дә юк. Менә үзең кара инде: ул тәрәзәдән сикереп егетлек күрсәтмәк булган. Ә кызлар ике көн мыштым гына йөрделәр дә тагын элекке хәлләренә кайттылар. Дөнья үзгәрдеме — юк, тамчы да үзгәрмәде. Ә ул инвалид булып калса?..

— Синең өчен үзгәрмәсә, минем өчен үзгәрде,— диде Рифкать һәм гитарасын кулына алды.

— Нәрсә дидең?

Ләкин Рифкать онытылып җырлый иде инде:

> Утларга да бер керербез әле,
> Без менәрбез әле күкләргә.
> Солдат булу безгә кыен түгел,
> Риза булса кызлар күтәргә.

Аны Әнфисә белән Галия күтәреп алды. Илдус арткарак калды, җырга кушылмады.

Трамвай юлын аркылы чыгып, Рифкатьләр өенә таба борылгач, арттан аяк тавышлары ишетелде.

— Рифкать, йөгер! Кызлар, качыгыз!

Илдус үзе кычкыра, үзе бар көченә чаба иде. Аның артыннан, олы-олы атлап, озын буйлы, тузган сары чәчле егет куып килә. Арттан тагын дүртәү йөгерә. Озын егет Илдусны куып җитте дә кулын күтәреп кизәнде.

— Мә гитараны, Әнфисә!

Рифкать алар янына ыргылды, чабып килгән уңайга озын егетнең эченә китереп сукты, тегесе тротуарга барып төште, яткан килеш ыңгырашып кычкырды:

— Изегез, егетләр! Гитарасын алыгыз! Бүтән урамга чыкмаслык итегез! — Һәм бер кулы белән эчен тоткан килеш, икенче кулы белән тротуарда яткан Илдусны дөмбәсләргә тотынды.

Рифкать аның кулын артка каерып китерде дә бар көченә этеп җибәрде, егет, сузылып, кырыйдагы агачлар арасына барып төште. Ләкин шул арада дүрт егет аны уратып алган иде инде. Ул Илдусны җирдән күтәрде дә, сул кулы белән аны кочаклап, уң кулын селки башлады. Егетләрнең берсе Әнфисә кулыннан гитараны тартып алды. Ул чәчрәп кычкырды, аңа Галия кушылды. Шулчак Рифкатьнең йөзенә китереп суктылар. Аның күз аллары кинәт яктырып китте, һавада утлы күбәләкләр оча башлады. Ул чайкалып куйды, ләкин егылмады. Аңа тагын суктылар, тагын. «Егылмаска, егылмаска! — дип кабатлады ул эченнән.— Егылсаң, таптыйлар, изәләр». Менә кемдер фонарь белән күзләренә төбәгәндәй булды. «Хәзер тагын сугалар» дип уйлады ул. Ләкин күзләрен ачса, каршында фараларын яктырткан милиция машинасы тора, ә теге егетләр куак арасыннан чаба иде.

— Бандитлар! — диде ул һәм авызына тулган канны җиргә түкерде.

Менә хәзер Рифкать урында ята. Шул егетләргә бирешеп торганга эчендә ачу кайный. Әнисе аның хәлен сизсә дә, сизмәгәнгә салыша: «Арыгансыңдыр, улым, ял ит. Бигрәкләр озак йөрисез шул»,— дип сөйләнә-сөйләнә, алдына чәй китереп куя. Рифкать әнисенә елмайгандай итә дә тешләрен шытырдатып кыса. Кинәт түзеп булмаслык булып башы авыртырга тотына. Әйтерсең кемдер баш миенә кадак кага, каккан саен, кадагы эчкәрәк керә. Тук-тук, тук-тук килә чүкеч.

— Хәзер, хәзер,— ди әнисе. Ул нишләптер русча сөйләшә.

## 6

Менә баш миенә кергән кадак әкрен-әкрен эри, менә ул бөтенләй сизелми дә. Рифкать күзләрен ача. Каршында, елмаеп, врач басып тора.

— Йоклыйсыңмы, әллә болай уйланып кына ятасыңмы? — диде врач.

Рифкать сүз әйтмәк булган иде, сүз чыкмады, иреннәре кыймылдамады. Врач апа, хәлен аңлагандай, ияген кагып куйды.

— Хәзер, хәзер,— диде дә сулы мамык белән иреннәрен чылатты, маңгаена сулы чүпрәк куйды.

— Уйладым гына...

Рифкать сүзләренең шундый көчсез, ишетелер-ишетелмәс кенә чыгуына гаҗәпләнде.

— Артык уйламаска тырыш. Башыңа ял кирәк синең. Түшәмгә кара да тик кенә ят.

— Ә мин уйламыйча булдыра алмыйм. Уйламаска тырышам, булдыра алмыйм, уйлар үзләре килә.

— Ярый, ярый,— дип, врач апа аның иреннәрен тагын сулы мамык белән сыпырды.— Алайса, яхшы нәрсәләр турында гына уйларга тырыш.

— Мин шулай итәм дә.— Рифкать, врачның күңеле булсын дип, шактый вакыт түшәмгә карап ятты. Юк, болай күңелгә әллә нинди уйлар килә. «Округ госпиталеннән хирург чакырырлык булгач, димәк, хәлем шәптән түгел инде. Операция ясарга кирәк, диләр».

Ул элек уколдан да курка иде, качып йөри иде. Ә менә хәзер — операция. Аннан исән-сау чыгармы? Баш

бит. Уң кулы да исән түгел. Әтисенең дә кулында бармаклары юк. Шахтада өздергән. Ә Рифкатьнең бармак кына түгел бит. Гитарада сул кулы белән уйнарга өйрәнергә туры килер. Рифкать тешләрен шыгырдатты, йөзен чытты.

— Авыртамы, улым, әллә тагын укол кадыйкмы? — диде врач.

— Кирәк түгел... Болай гына ул...— Аның сүзләре өзек-өзек чыга иде.— Өйгә хәбәр итмәдегезме?.. Кирәк түгел... Әнкәй белмәсен... Миңа хат килмәдеме икән...

— Синең янга бер солдат килгән иде. Кертмәдек, борчымасын, дидек. Якташың бугай.

— Илдусмы?

— Әйе, шулай диде кебек. Көтте-көтте дә, кертмәгәч, китте.

— Кертәсегез калган. Хат алып килгәндер.

— Синең янга килүчеләрнең исәбе-хисабы юк бит. Барысына да рөхсәт бирсәң. Рифкать Миргазизовка кан кирәк, дигәч тә, бөтен полклары белән ябырылдылар. Арадан унберен сайлап алдык. Кан группалары туры килгәннәрен. Әй сөенделәр, бәгырькәйләрем! Әнә, ишетәсеңме, ишек төбендә шулар шаулаша инде. Керергә даулыйлар.

— Нигә кертмисез соң?

— Ярамый.

— Бер минутка гына.— Рифкать күзләрен мөлдерәтеп врачка карады.— Бер генә минутка...

— Хәлең авыр бит...— диде доктор, ләкин каршындагы инәлүле күзләрне күргәч йомшарды.— Ләкин озакка түгел. Үзең сөйләшмәскә тырыш. Тыңлап кына ят. Сөйләшкәндә, башың селкенә, яраң кузгала.

Солдатлар, тавыш чыгармыйча гына басарга тырышып, палата түренә уздылар. Зәңгәр береткаларын салып кулларына тотканнар.

— Сәлам, Рифкать.

— Терелабезме?

— Синең янга якын да китермиләр хәзер.

— Биш минутка гына керттеләр.

— Илдус киттеме? — диде Рифкать.

— Әле генә китте. Капканы да чыкмагандыр. Чакыриммы? — дип ашыга-ашыга тезеп китте таныш булмаган солдат һәм, җавап та көтмичә, шап-шоп атлап чыгып йөгерде. Врач, йөзен чытып, аның артыннан карап калды.

Солдатлар сүз башларга кыймый тора. Мондый вакытта ни әйтергә икәнен белми аптырый алар: юатсаң, Рифкать бала-чага түгел, кызганырга килгәннәр дип аңлар, үпкәләр, уен-көлке сөйләсәң дә урынлы түгел.

— Бүген бөтен полкны җыйдылар. Генерал синең турында сөйләде,— дип, ниһаять, сүз башлады кече сержант.

Рифкать аны аз гына төсмерли, бер-ике тапкыр очрашканнары да бар. Володя исемле бугай. Әйе, Володя, Владимир, Владимир Чигарев.

Рифкать солдатларга карап ята. Күбесе аңа таныш та түгел. Аның уйларын белгәндәй, Владимир исемнәрен атый башлады.

— Син егетләрне белмисеңдер дә әле. Ефрейтор Роман Шильтут, рядовойлар Виктор Бурка, Виктор Желятин, Николай Меблев, Владимир Богданов, Константин Абашкин, Владимир Ярмошевич, Михаил Бахтеев...

Сержант исемнәрен атауга, солдатлар бер адым алга атлыйлар. Әйтерсең Рифкать аларның командирлары, әйтерсең ул, строй алдына басып («һи-и... басып...» дип уйлады эчтән), солдатларын барлый. Ә алар, уңайсызланып, тагын тын калдылар.

— Стройда тормыйсыз бит, утырыгыз,— диде врач.

Алар, уңайсызланып кына, каршыдагы караватка тезелешеп утырдылар. Утыргач, кинәт кенә барысының да теле ачылды.

— Тынычрак, тынычрак, кайда икәнегезне онытмагыз,— дип кисәткәч кенә, кинәт аңга килгәндәй тынычланып калдылар.

— Рифкать,— дип, шактый вакыт узгач кына Володя аңа эндәште.— Син чыгарган гәзит һаман казармада эленеп тора әле. Рәсемнәрен бигрәк шәп ясагансың.

— Ротада бүген синең турында чыккан хәрби листокны командир кычкырып укыды.

— Часть музееннан прапорщик фотоңны сорап килгән иде. Полковник кушкан.

Рифкатька алар барысы да бик еракта, томан аша күренгән кебек, ә тавышлары күрше бүлмәдән ишетелгән шикелле.

— Рифкать! Якташ!

Палатадагы томан тора-бара сыегайды һәм каршында Илдус пәйда булды. Үзе мыш-мыш килә, маңгаена тир

бөртекләре тезелгән. Әллә инде тир бөртекләреннән, әллә елаудан күзләре дә юешләнгән.

— Мин анда бөтенесе белән танышып беттем инде,— дип өзек-өзек сулыш ала-ала тезеп китте ул. Үзе иреннәрен җыя алмый елмая. Дустының нинди хәлдә ятуын да онытып, ниһаять, больницага Рифкать янына керә алуына сөенеп бетә алмый. Менә ул бераз тынычланды, сулышы да тигезләнде, караватнкырыендагы урындыкка утырды.

— Солдатлар! Вакытыгыз бетте, саубуллашыгыз,— диде шулчак врач.

Илдус гаҗәпләнү һәм инәлү катыш күз карашлары белән ак халатлы ханымга текәлде.

— Сезгә чыгарга вакыт, ә якташы калсын.

Егетләр теләр-теләмәс кенә торып бастылар, тавыш чыгарырга курыккандай, пышылдап кына саубуллашып, ишеккә таба чигенделәр. Барысы да чыгып беткәч, ишек ачылды, аннан Коляның башы күренде.

— Без хәзер бертуган, Рифкать! Онытма! — дип кычкырды ул.

Илдус Рифкатьнең башын, кулларын, бөтен гәүдәсен капшап чыкты.

— Исән, бөтен җирең дә исән!

Рифкать, менә кара дигәндәй, уң кулын кыймшатып куйды.

— Кул гына — чепуха. Анысы төзәлер. Хәзер әллә нинди протезлар ясыйлар, чын кулдан аерырлык түгел.

Рифкатькә аның сүзләрен тыңлау рәхәт иде. Туган шәһәре, дуслары исенә төште.

— Миңа хатлар килмәгәнме?

— Юк. Килер әле! Язалардыр.

Рифкать кинәт кенә моңсуланып калды, беркавымга хәтта янында Илдус барлыгын да онытып, уйга чумды.

Бу арада нишләп бер хат та килми соң әле аңа? Әллә авырып киттеләрме? Әллә вакытлары юкмы? Аның өйгә язганына шактый вакыт булды бит инде.Ниләр язган иде соң әле ул? Гадәттәгечә: *«Исәнмесез, минем өчен иң кадерле булган әнкәй, әткәй, Әнфисә, Азат!* — дип башлаган иде.— *Солдат сәламе белән сезгә гвардия рядовое Рифкать Миргазизов яза.*

*Мин яхшы гына яшим, дигәч тә, сез минем ничек яшәгәнне күз алдына да китерә алмыйсыз. Өйдәгечә иркенләп ятулар, нәрсә теләсәң, шуны ашаулар, кая теләсәң, шунда барулар турында хыяллана да алмыйсың хәзер. Һәрнәрсә режим буенча, һәрнәрсә приказ белән эшләнә монда. Ләкин сез анда исән-имин яшәсен өчен, илебез тынычлыгы өчен хезмәт итүеңне уйлыйсың да, күңелең горурлык хисе белән тула. Җир җимертеп яшәр көннәр алда әле. Тормыш башлана гына безнең. Моңа кадәр күп нәрсәне аңламаганмын икән. Иң беренче тапкыр самолеттан сикергәндә генә дөньяның нинди матур икәнен күрдем, яшәү мәгънәсен аңлый башладым бугай. Шулчак бөтен кешеләргә ишетелерлек итеп «Яшисе килә!» дип кычкырырдай булдым.*

*Ярый, мин артык нечкә күңелләләнеп киттем, ахрысы. Шулай да бераз солдат тормышы турында да язып үтәм. Кичә безнең монда бәйрәм булды. 800 метр биеклектән тагын парашюттан сикердек. Самолеттан сикерүгә күңел шатлык белән тулды, боҗраны тарткан идем, парашют ачылды да китте. Җиргә төшкәч, парашютны төрдек тә җыелу урынына киттек. Парашютлар бик шәп безнең, күрсәгез шаккатыр идегез.*

*Безнең ротада Татарстаннан биш кеше. Димәк, сагынган чакта күңел юатырга якташлар бар. Бөтенесе әйбәт, тик менә вакыт кына җитми. Күптән түгел өч километрга кросс белән йөгердек. Полкта дүртенче урынны алдым. Беренче өч урынны алганнар отпускыга өйгә кайтып киттеләр. Ә мин биш секундка калыштым. Ярар, барысы да алда әле.*

*Тәмәкене ташладым. Бөтен көчне спортка бирәм. Десант гаскәрләре иң яхшы, үрнәк гаскәр бит ул. Десантник булу бик җиңел түгел икән. Җиде кат тирләр чыга. Хат язарга да вакыт тими. Менә бу хатны өченче көн язам инде. Тиздән бездә бик җитди хәрби өйрәнүләр була. Шуңа әзерләнәбез.*

*Хәзер әле мин «салага» гына, бер елдан «фазан» булам, ә аннары — «дембель». Шулай хыялланып ятам.*

*Ярый, сау булыгыз! Барысына, барысына миннән күп сәлам тапшырыгыз.*

*Рифкать».*

Ул, хат азагында ясаган рәсемен күз алдына китереп, көлемсерәде. Үзен киң җилкәле, кабарып торган мускуллы итеп ясаган иде. Башта — кырын салынган берет, авыз ерык. Көлкеле рәсемнәр ясарга ярата ул. Мәктәптә дә стена газетасын ул бизәде, частьта да гел ул ясый иде. Аның рәсемнәрен карагач, шаркылдап көләләр иде. Хәзер көлкеле рәсемнәр ясый алмас инде.

Хәзер аның елмаясы да, көләсе дә килми. Узар микән бу? Аның да күңеле күтәрелер микән? Моңа кадәр гомере уен-көлке белән генә үткән икән... Гитара, магнитофон, дуслар, шаяру, көлешү. Бер урында утырып, озаклап уйланган чаклары да сирәк иде. Һаман вакыт җитмәде. Гомер буе сау-сәламәт булыр, шулай уйнап-көлеп кенә яшәр кебек иде. Карасаң... Хәзер аның кемгә кирәге булыр икән? Галиягәме? Әлфиягәме? Соңгы арада хатлары да юк. Больницадан чыккач, бик озын итеп, бөтенесенбөтенесен әйтеп хат язарга кирәк. Һе-е, диде ул, үз уйларыннан үзе көлеп. Кулсыз язарсың инде хат. Нинди хат ди әле ул? Кулсыз солдат була димени? Терелү белән кайтарып җибәрәләр инде аны. И-их!

— Нәрсә, нәрсә?

Илдус Рифкатьнең хәрәкәтсез күз карашына, акрын гына кыймылдаган иреннәренә карап утыра, сүз дәшәргә дә кыймый. Ул бары тик «И-их!» дигән уфтану авазын гына ишетте.

— Их, монда гитара булсын иде, ә! — дип, тавышын күтәрә төшеп, күңеллерәк булырга тырышып башлап китте ул.— Хәтерлисеңме, Түбән Камада больница тәрәзәсе каршында уйнап торган идек.

Рифкать, «әйе» дигәнне аңлатып, керфек какты.

— Саша тәки гел кеше булды бит. Әйтергә онытып торам: өченче көн өйдән хат алдым. Саша диңгез училищесына кергән. Оренбургтан бер борылып кайткан булган. Тагын барып Одессага кергән. Кап-кара моряк киеме киеп, шәһәр урамын көнгә әллә ничә урый, ди. Адмирал булганмыни!

— Саша егет ул. Адмирал да булыр.

— Ул умыртка сөяге сындырып та кеше булды. Синең нәрсә, кул да баш кына.

— Баш кына,— дип мыскыллы елмайды Рифкать. Бер хәрәкәтсез ятса да, ул тәнендә көч кайнап торганын сизә. Ярасы кузгалган саен, бөтен мускуллары җәягә тар-

тылгандай була. Ә менә уң кулы белән башы бертезлексез сызлый да сызлый. Кул вакыт-вакыт онытылып та тора, ә менә баш авыртуы аз гына да туктамый, укол кадагач, суга тыккан утлы кисәү кебек сүрелеп ала да беркавымнан тагын ялкынланып яна башлый. Әйтерсең ниндидер утлы өермә баш капкачы эченә кереп оялаган да дулый да дулый, утлы кисәүне бертезлексез яндырып тора. Рифкатькә ул мәңге шулай янар, бу авыру мәңге бетмәс кебек тоела. Авыртуны басарга тырышып, ул авыз эченнән генә көйли башлады:

Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

Илдус аны саташа дип белде, ахрысы, врачка таба борылып карады. Ак халатлы ханым, игътибар итмә дигәндәй, кулын гына күтәрде, дәшмәде.

— Сиңа кан бирделәрме әле, Рифкать?

— Юк.

— Хәзер бирә башлыйбыз,— диде врач.

— Ә миннән кан алмадылар. Группаң туры килми, диләр. Ничек инде, мин әйтәм, туры килмәсен, аның белән безнең бөтен нәрсә дә туры килә. Бергә укыдык, ничә ел дус булдык, бергә хезмәт итәбез. Димәк, кан да туры килергә тиеш.

Рифкать сүзгә кушылмады. Кинәт кенә аның бернәрсәгә дә исе китмәс булды. Дуслар, якташлар, хатлар, юату сүзләре — барысы да ниндидер мәгънәсез нәрсә кебек тоела башлады. Врач ым какканны күргәч, Илдус тыптын гына палатадан чыгып китте. Рифкать аны сизмәде. Ул уйлары белән моннан бик еракта, Кама аръягындагы иксез-чиксез болын уртасында йөри иде инде.

## 7

Мәктәптә укулар бетеп, каникул башлануга, һәр җәйне Илмәткә кайтам, дип атлыгып тора Рифкать. Кайткан көнне үк, болынга төшик йә урманга барыйк, дип, бабасын тыкырдатырга тотына.

— Сабыр ит, улым, сабыр иткән — морадына җиткән. Юлдан соң бераз хәл җый.— Харис бабай шулай сөйләнә-сөйләнә, кечкенә сандалга куеп, чалгысын чүки баш-

лый.— Авыл халкы эшсез кешене өнәми ул. Бераз печән дә чабып кайтырбыз.

Быел авыл бигрәк үз, якын тоелды Рифкатькә. Әллә инде тиздән армиягә китәсе булганга, туган як белән саубуллашыр чак җиткәнгә күңеле нечкәрә башладымы? Бабасы чалгылар көйләгән арада, ул җәһәт кенә Изгеләр чишмәсенә дә менеп төште, инеш буен да урады. Авылга кайттымы, әллә нинди үзе дә аңлый алмый торган хис били аны, иңнәренә канат чыккандай була, моңа кадәр күңелне борчып торган вак-төяк кайгылар да онытыла. Авылда аңа белгәне дә, белмәгәне дә сәлам бирә. «Шәфкатьнең кече малае кайткан!» дип, зурлар ерактан ук сүз ката, шәһәр хәлләрен сораша, егетләре кичен капка төпләренә килеп утыра. Шәһәрдә өйләр бөтенесе бер-берсенә охшаш, ә монда һәр каралты, һәр йорт үзенчә. Аларның йорты Харис бабайның үзенә охшаган: какчарак йөзле, җиңел гәүдәле, ә-әнә, каршыдагы өй фуражкасын батырып кигән төксе йөзле кеше төсле, тәрәзәләре дә караңгы, ә менә монысында киң күңелле кешеләр яшидер: тәрәзәләре дә олы итеп куелган, капкалары да көне буе шар ачык тора.

Шулай һәр йортны кемгәдер, нәрсәгәдер охшатып бара торгач, авыл башына чыгып җиткәнен сизми дә калды. Басуга чыккач, дөнья яктырып киткәндәй булды. Бөтен җир сап-сары, бары басуның аргы ягындагы комбайн гына, кызыл чикерткәгә охшап, теркелдәп төшеп килә. Тулы башаклы игеннәр, чәчләренә чал кунган аксакаллар кебек, башларын акрын гына селки-селки нидер серләшәләр, кызыл чикерткәгә күтәрелеп карыйлар да, качарга теләгәндәй, тагын аска иеләләр.

— Игеннәр дә өлгерде...— дип куйды Харис бабай. Сөенә идеме, әллә уфтанамы — Рифкать аңлый алмады.

— Их-их, яшь чагым булса, каерып бер пакус алыр идем дә кереп китәр идем басу буйлап!

— Комбайн белән диген. Чалгы белән иген чапмыйлар инде.

— Чабалар иде, улым, заманында чабалар иде.

— Ул заманнар узган инде, хәзер техника эшли бит. Әле газетадан укыдым, бер комбайн әллә ничә йөз атны, меңләп кешене алыштыра, дигән.

Харис бабай һич көтмәгәндә кеткелдәп көлеп җибәрде. Рифкать аптырап аңа карады.

— Дөнья күрмәгән кеше язган аны, улым. Каптырмалы кабартма ул, белдеңме? Дөнья күргән кеше авызыннан мондый сүз чыкмас. Мең кешене алыштыра, дисеңме? Алыштыра, чуртым! Кешене алыштыра торган нәрсә җир йөзендә яралмаган әле. Юка башлар сүзе ул.— Харис бабай чалгы сырты белән җиргә сугып куйды. Кисәк хәрәкәт белән колак аппаратын тартып алды да кесәсенә салып куйды. Ачуы чыкканда, кеше белән сөйләшәсе килмәгәндә шулай итә ул: аппаратын тартып ала да бөтен дөньяда бер ялгызы кала.

Аннары инде аңа сөйләдең ни дә сөйләмәдең ни. Ләкин бу юлы ачуы нык кузгалган, ахрысы, тыела алмый, һаман кемнедер сүгә.

— Тамакларына аркылы килгере, уттай урак өстендә бакча артында сырт кыздырып яталар. Комбайннары тик тора, ә ул мәлгуньнәрнең исләрендә дә юк. Килгән кешедән нинди иман булсын инде? Җир кадерен, икмәк кадерен беләмени алар? Авылда күзгә кырып салырлык та яшьләр калмады, барысы шәһәргә качып бетте. Ни дип шул сасы төтен иснәргә кызыгалардыр. Бик иснисе килсә, исле мунчага кереп ятсын иде. Алар анда сигез сәгатен тутырып кайта да, ихаха да михаха килеп, түшәмгә төкереп ята, ә монда эшләр кеше юк. Быел игенне җыеп бетерүләре дә икеле әле. Комбайннары тик тора, кул җитми. Әнә шәһәрдән китергәннәр иде. Күргәнсеңдер, безнең ындыр артында кызыл сыер көтүе шикелле комбайннар тезелеп тора. Шәһәр кешесе таш җанлыдыр ул. Утырып кала бит игеннәр, утырып кала. Әле бер тишек борыны авыз ерып көлеп торган була: «Кайгырма, бабай, ил зур безнең, хөкүмәт бай, монда иген булмаса, читтән китерерләр, мул җирдән»,— дип акыл сата. Кеше ашын ашап өйрәнмәгән, безгә үзебезнеке җиткән. Гомер-гомергә шушы басу туйдырып килде, читләргә ялынмадык.— Харис бабай бераз тынычлана төште бугай, чалгысын иңенә салды да атлап китте.— Шушы җирне урак белән егып сала идек без, уч төбе хәтле кәкре урак белән. Ә хәзер комбайн белән кырпак төшкәнче маташалар. Ә син... мең кешене алыштыра, дисең. Алыштырмый торсын әле.— Ул, артык кызып киттем дигәндәй, туктап тын алды да Рифкатькә дәште: — Нигә сиңа сөйләп башыңны катырам соң әле? Сиңа нәрсә, син — шәһәр кешесе. Сезнең өчен ипи кибеттә үсә. И-их, менә синең шикелле егер-

ме-утыз гына егет булсын иде хәзер монда. Бу басуларны ялтыратып кына куярлар иде. Әллә армиядән соң, чыннан да, авылга кайтасыңмы, улым?

— Күз күрер,— диде Рифкать.

— Нәрсә дисең, нәрсә?

— Кайтырмын, бабай, кайтырмын.

— Нәрсә дисең? — Харис бабай колак аппаратын салганын исеннән чыгарган булса кирәк, Рифкатьнең сүзләрен ишетмичә, кабатлап сорады.

— Кайтам! — дип, ике кулын авызына бүрәнкәләп куеп, бар көченә кычкырды Рифкать.— Кайтам!

Аның тавышын игеннәр дә ишеттеләр кебек, авыр башларын кагып куйдылар.

## 8

Рифкать, уйларыннан арынып, палатага күз ташлады. Врач чыгып киткән, ахрысы, беркем юк. Башы да артык чәнчешми, еракта ишетелгән комбайн тавышы кебек берөзлексез гүли генә. «Кая, кеше юкта торып карыйм әле». Торырга талпынып карады, ләкин кузгала алмады. Көчәнүдән аякларын көзән җыергандай булды, тәнен калтырау алды, бар мускуллары киерелде, тик башы күтәрелмәде, хәрәкәтсез ята бирде. Башына кереп оялаган аждаһа, тик кенә ят, кузгалма, дигәндәй, кыймшанып алды. Кинәт аңа бу авыру беркайчан да бетмәс, ул мәңге шулай хәрәкәтсез ятар кебек тоела башлады. «Тизрәк... тизрәк,— дип пышылдады Рифкать.— Нәрсә тизрәк? Нәрсә булса да, тизрәк кенә булсын... Юк, ул үләргә тиеш түгел!»

Ул беренче тапкыр үлемне күз алдына китерергә тырышып карады.

Менә ул кызыл табут эчендә ята. Табут каршында солдатлар тезелгән. Командир нидер сөйли дә сөйли. Ята торгач, Рифкатьнең җилкәсе чәнчи башлады. Ул ике кулы белән табут кырыена таянып, әкрен генә торды да, җиргә төшеп, стройдагы үзенең буш торган урынына таба атлады. Үзе атлый, үзенең аяклары берни дә сизми, әйтерсең һавада очып бара. Солдатлар «урра!» кычкыра.

Менә аны, ак кәфенгә төреп, Илмәт картлары күтәреп бара. Алда Харис бабайның тавышы ишетелә: «И улым,

улым, авылга кайтам, дигән идең, кайтуың шушы булган икән». Зират капкасы төбенә килеп җиткәч, басу ягыннан таныш гүләү ишетелә башлый. Бу тавыш көчәйгәннән-көчәя бара, колакларны ерып керә, башка каба. Рифкать барган көйгә урыныннан торып утыра да, кулын каш өстенә куеп, тавыш килгән якка иелә. Ә анда, иген басуын урталай ярып, комбайн килә. Үзе дөберди, шатырдый, тәгәрмәчләре, чылбырлары әйләнә, өстеннән тузан болыты күтәрелә, ә үзенең штурвалы артында беркем юк. Рифкать җиргә сикереп төшә дә, ак кәфенен сүтә-сүтә, комбайнга таба йөгерә...

Менә ул үз өйләрендә олы бүлмә уртасына куйган караватта ята. Өстендә — солдат киеме, күкрәгендә значоклар. Бөтенесе елыйлар, аның битеннән сыйпыйлар, соңгы тапкыр фотога төшерәләр. Рифкатьнең, еламагыз, дип, әнисен, әтисен, туганнарын юатасы килә, ләкин авызыннан сүз чыкмый. Керфекләре аша саркып тәрәзәдән төшкән яктылык күренә. «Галия кайда?» — дип уйлый ул. Дәрестән кайткач, кичләр буе шушы тәрәзәдән карап утыра иде. Каршыда — Галияләрнең тәрәзәләре. Теге кичне ниләр булганын өйләренә кайтып сөйләгән дә, менә хәзер Галияне бөтенләй диярлек урамга чыгармас булдылар. Элек Рифкать аңа гел игътибар да итми иде. «Сары баш» белән чәкәләшүе дә Галия өчен түгел, ә егеткә ачуы чыгудан, аның шулай тупас сөйләшүеннән, юкка бәйләнүеннән генә булды сыман.

Менә хәзер ул тәрәзә төбенә кунаклаган да, җәнлек сагалаган аучы төсле, тын да алмыйча каршы балконны күзәтә. Балкон ишеге ачык. Димәк, ул бүген барыбер ишек янына киләчәк, ябар өчен генә булса да киләчәк. Ә инде килгәч, балконга чыкмый түзә алмаячак... Әнә пәрдә артында шәүләсе чагылып китте. Әнә зәңгәр күлмәге төсмерләнде. Әнә, әнә балконга чыкты. Чыкты да Рифкатьнең дөньяда бар икәнен дә белмәгәндәй, бу якка күз ташлап та карамады, балкон аратасына таянды да тик тора бирде. Рифкать, тәрәзә төбеннән сикереп төшеп, бер бүлмәдән икенчесенә чабып йөрергә тотынды, аннары кинәт кенә туктады да стенадагы зур көзгене алды. Кызның чәчләре, йөзе, иңбашлары кояш нурына коенды. Ул бермәл аптырап, берни дә аңламыйча, һушсыз басып торды, аннары як-ягына каранды һәм, Рифкатьне күргәч, авыз тутырып елмайды, нидер кычкырды. Ләкин аның

яңгыравык тавышы вак кисәкләргә таралып юкка чыкты, Рифкать янына килеп җитә алмады. Рифкать, кояш кыйпылчыгын кызның йөзеннән алып, стенага күчерде һәм көзгесен боргалый-боргалый хәрефләр «яза» башлады. «Я». Хәреф шундый зур булып, балкон стенасына көчкә сыйды. Кыз, аңлаганын белдереп, баш селкеде, урамны яңгыратып көлде. «Р». Галиягә бу уен бик ошады бугай, ул кулларын чәбәкли-чәбәкли сикерергә үк тотынды. «А-Т-А-М». Рифкать калган хәрефләрне тиз-тиз генә язып бетерде дә, җавап эзләгәндәй, кояшны Галия йөзенә күчерде. Ә ул, күзләрен кулы белән каплап, бераз тын торды да капыл гына өйгә кереп китте, бераздан кире чыкты. Аның кулында да шундый ук зур көзге иде. Ләкин ул, күпме тырышса да, кояш җибәрә алмады, аларның йорты күләгәле якта иде. Галиянең шуңа бөтенләй кәефе китте, ахры, ул, салкын көзгесен кочаклап, тын калды. Рифкать кояш нурын аның көзгесенә төшерде, көзге, кинәт ялтырап, балкып китте, Галиянең дә йөзе ачылды. Менә ул, көзгесен күтәреп, Рифкатьнең кояшын кире үзенә җибәрде. Рифкатьнең күзләре, чагылып, яшьләнде, йөрәге дөпелдәп ярсый-ярсый тибәргә тотынды. Галия, асфальтка пыяла ташлагандай, чылтыр-чылтыр килә-килә урамны тутырып көлде дә көлде. Көлеп арыгач, кояш көлтәсе белән стенага сүзләр яза башлады. «Р-и-ф-к-а-т-ь+Г-а-л-и-я». Шулчак ишек ачылып ябылды. Әнисенең: «И улым!..» — дигән еламсыраулы тавышы ишетелгәндәй булды. Ул, яшерергә теләп, көзгесен тәрәзә пәрдәсе артына таба шудырды, һәм кинәт бөтен дөнья караңгыланып калгандай булды. Стенадагы кояшлы хәрефләр дә сүнде, Галиянең көзгесе дә, боз кисәгенә охшап, салкынаеп калды, бераздан Галия үзе дә юкка чыкты. Ул, аптырап, өзгәләнеп, үз-үзен белештермичә, кычкырып җибәрде: «Га-ли-я!» Ә... тавышы... тавышы... «Әлфи-я!» — дип яңгырады. Ул, әллә саташаммы дип, якягына каранды, хәлсезләнеп башын тәрәзә пыяласына тәрәде...

— Хәзер, шприцлар гына әзер булсын да, сестра сиңа кан бирәчәк,— диде врач, Рифкатьнең маңгаена юеш салкын чүпрәк куя-куя.— Унбер егет каны кергәч, баһадирның баһадиры булырсың инде. Егетләре дә нинди бит әле. Әзмәверләрмени!

## 9

Врач ишектән чыгуга, кинәт кенә Рифкатькә рәхәт булып китте. Илдусны гына үпкәләтте бугай. Ни әйтсәң дә, якташ бит. Якын итеп килгән. Теге вакытта Саша турында дөрес әйтмәде әйтүен. Үзгәрер әле. Гел «әйе», «әйе» дип кенә тормас. Тормыш өйрәтә ул. Донор егетләр хәзер шәһәрдә йөридер инде. Терелеп чыккач, алар белән бер җыелып утырырга иде. Моңа кадәр кешеләрне аңлап бетермәгән икән ул, кешеләрнең кадерен белмәгән. Аннары солдатта күп нәрсә приказ белән генә эшләнә бит. Җылы сүз бик тансык ул солдатка. Бергәләп увольнениегә чыгарлар. Бу тирәнең табигате безнең якныкы шикелле үк матур түгел дә. Шишкин урманнарын, Кама ярларын, Вятка болыннарын күрсәтергә иде аларга. Чыннан да, алар хәзер Рифкатькә кан кардәшләр шикелле. Яз көне ул да донор булган иде бит. Кан биреп чыккач, шәһәр буйлап йөрделәр. Мондагы халык гел бүтән икән, сөйләшүләре дә үзләренчә. Колак салып тыңлагач, кайбер сүзләре аңлашыла да. «Әллә татарлар инде»,— дип уйлады Рифкать. Хәтта бер кызга сүз дә катты. Тегесе горур булып чыкты: башын югары чөйде, җавап кайтармады. Читтәрәк торган кара чәчле, каратут йөзле апа белән абый да, курыккан сыман, кабалана-кабалана кызларын ашыктырдылар.

— Әй, агай, әллә безнең яктанмы сез? Таныш булыйк, мин — Татарстаннан. Телегез аңлашыла, шуңа әйтәм,— дип эндәште Рифкать.

Агай артка борылып карады да: «Җир йөзендә бар адәмнәр дә бер-берсенә туган. Шуны аңлаучы гына юк»,— дип китеп барды.

— Безнең халыкны, солдат халкын бик өнәп бетерми алар,— дип аңлатты прапорщик. Ул үзе Казан тирәсеннән, шуңадырмы Рифкатьне үз итә иде. Буе ике метр булыр, куллары утын яра торган үтмәс балтага охшаган. Балта диярлеге дә бар шул, кулы белән бер сугуда кирпечне сындыра ул.

— Ә нигә өнәп бетермиләр?

— Солдат халкы бик шаян бит, бер дә тик тормый. Ә монда кызлар чиб-бәр!

— Нинди халык соң алар?

— Кем икәннәрен дә белмәссең. Бик күп алар монда.

Ну эшчән дә халык инде үзләре. Шушы ком даласында оҗмах ясап куйганнар бит. Оҗмахтагы берәр хур кызы белән танышасы килмиме соң, якташ?

— Белмим...

— Ниткән «белмим» ул тагын? Киләсе увольнениедә, күр дә тор, таныштырам берсе белән.

Алар, шәһәр урамын иңләп, көлешә-көлешә күл буена төштеләр. Күл бик зур, Вятка киңлеге булыр. Чишенеп суга кергәч, Рифкать борылып карады. Яр башында, экскаватордан башын тыгып, әтисе карап торадыр шикелле иде аңа. «Әти, сиңа нишләп Шәфкать исеме кушканнар?» — дип сораган иде ул аннан бер тапкыр. «Кем белгән инде аны, улым! Аны-моны уйлап тормаганнар, тотканнардыр да кушканнардыр». «Юк-юк, алай булмый инде». «Нигә дип, шәфкатьле булсын, дигәннәрдер. Миргазиз бабаң бик нечкә хисле, бала күңелле кеше иде. Шул кушкандыр. Нәкъ синең төсле иде инде: аксыл чәчле, озынча йөзле, зәңгәр күзле. Көлгәндә дә шаркылдап көлмәс, синең шикелле рәхәтләнеп елмаер гына иде. Ул елмайганда, күңелләр рәхәтләнеп китә иде». «Әткәй, ә нигә аңа Миргазиз дип кушканнар?» «Кайлардан белеп бетерим соң инде, улым? Бик тә олы җанлы бәндә иде бит, әүлия иде инде, чын әүлия. Кеше сораса, соңгы ыштанын салып бирергә әзер иде. Гомер буе изгелек кенә кылып яшәде. Шул, гөнаһы булмаганга, күңеле чиста, кеше алдында йөзе якты булганга сиксән сигез яшенә җитте дә. Безнең нәсел озын гомерле ул. Әнә Харис бабаң да җитмешнең өске ягына чыкты. Алла боерса, без дә бирешмәбез. Син, Миргазиз бабаңа охшаган, йөзгә җитәрсең әле». «Аңа нигә дип Миргазиз кушканнар соң?» Бер сүзне кабатлап тору әтисенең күңеленә тиде бугай, малаен кырт кистерде: «Нигә булсын, мир газиз дә җир газиз, аннан кала ир газиз»,— дип сөйләнә торган гадәте бар иде мәрхүмнең. И-и, сине күрсә, сөенер иде!»

— Рифкать, нәрсә каккан казык шикелле торасың? Чум әйдә!

Ул, су чәчрәтә-чәчрәтә, йөгереп барды да колач җәеп йөзеп китте. Әгәр менә бу су Камага барып чыга, шуңа хәтле йөзә аласыңмы, дисәләр, ике дә уйламыйча «әйе» дияр иде. Увольнениегә чыккач гел шулай туган як турында уйлый ул. Әле самолетка утырып кайткандай бу-

ла, әле поезд, әле машина белән кайта. Ә менә бүген йөзеп кайтырга да риза. Тизрәк отпуск җитсен иде инде.

Йөзеп арыгач, алар озак кына кайнар ком өстендә кызынып яттылар. Прапорщик (Рифкать аның исемен дә белми, бөтенесе дә «иптәш прапорщик» дип эндәшкәч, ул да шулай гына йөртә) һаман анекдот сөйли. Бер җөмләсен әйтә дә буыла-буыла көлә, тагын әйтә дә тагын көлә. Кеше тыңлыймы-юкмы, аңа барыбер. Ул аны кеше өчен сөйләми дә кебек. «Үзе сөйли, үзе көлә, үз күңелен үзе күрә»,— дип уйлады Рифкать. Ул шулай юл буе шаркылдап кайтты. Әйтерсең эченә бәләкәй генә шүрәле баласы кереп утырган да кытыклапмы-кытыклый тегене. Ул көлгән саен, Рифкатьнең кәефе төшә бара, әллә инде кан бирүдән, әллә эссе кояш астында ятудан укшыта, башы әйләнә.

— Тукта! — дип кычкыра ул, ачуы чыгып, прапорщикка.— Җитте, маймылланма, туйдырдың.

Моңа кадәр үзенә каршы әйткәнне ишетмәгән прапорщик аптырап кала. Бер мизгелдә ул шарык-шорык анекдот сөйләүче авыл малаеннан мәһабәт прапорщикка әйләнә.

— Нәрсә дисең, са-ла-га? Әллә башыңда кирпеч ярып күрсәтимме? — Ул кизәнә, янәсе, Рифкатьне куркытмакчы була. Рифкать җәһәт кенә читкә тайпыла һәм, башы әйләнеп, чак егылмыйча кала. Солдатлар аны, бөҗра ясап, ул-бу хәл килеп чыкмасын дип әйләндереп алалар. Прапорщик көрәк кулын йомарлаган килеш басып тора-тора да кинәт кенә борылып китеп бара.

## 10

Рифкать күзен ачарга тырыша, ләкин күз кабаклары җилем белән ябыштырылган кебек кузгалмый. Кояш нурлары, утлы инә шикелле, башны тишеп керә. Менә ул утлы инәләр баш эчендә бергә тоташтылар да зырылдап әйләнергә тотындылар. Рифкать авызында бик тә ачы тәм сизде, аның күз аллары, күз аллары гына түгел, әйләнә-тирә, бөтен дөнья төпсез караңгылыкка чумды.

Шундый шомлы төш иде бу. Әле ул самолет пропеллерына ябышкан да аның белән зыр килеп бөтерелә, аяк-

лары, гәүдәсе өзелеп чыгарга җитеп тартыла, әле ул Илмәт урманына кереп адашкан да, кая барырга белми, бабасын чакыра, әле ул больница тәрәзәсе төбендә инде ничә сәгатьләр буе Саша өчен гитара уйнап тора: караса, уйный-уйный бармаклары чиләнеп беткән; әле ул ялкын чорнаган трактор кабинасына сикереп керә дә бар көченә рычагны тарта, ә трактор кузгалмый. Менә ялкын аның киемнәренә каба, куллары, аяклары пешә, чәчләренә үрли, күз алмалары шартларга җитеп кызыша һәм ул үзүзен белештермичә кычкырып җибәрә:

— Су!

Аның иреннәре буйлап су агып төшә, муены, җилкәсе юешләнә, керфекләре калтыранып куя. Өстән, югарыдан, тонык, салкын яктылык сирпелә, бөтен җиргә чәчелгән яктылык торган саен җыела, кечерәя бара һәм, ниһаять, бәләкәй генә ноктага әйләнә. Рифкать, баш очындагы лампочканы күреп, җиңел сулап куя.

— Уяндыңмы? — Врачның ягымлы тавышын ишеткәч, Рифкать, куркыныч төштән арынып, яңадан ак палатага кайта.— Озак йокладың, егет, кан биргәндә дә уянмадың.

Нишләп болай аның әнисенә охшатып сөйли соң әле ул? Әллә әниләр бөтенесе дә бер-берсенә охшаган микән? Увольнениегә чыккач, ашханәгә кергәннәр иде. Анда да аш бүлүче апаны әнисенә охшатып озак басып торды. Елмайганда бөтен кеше дә бертөсле. Ачуланганда, усал чакта гына төрле була алар. Бик күп уйлый бугай ул. Әллә башы шуңа авыртамы? Унтугыз яшьлек кешенең дә искә төшерер нәрсәсе булыр икән? Юк, чыннан да артык уйлый бугай, болай хыялыйланып китүең дә бар. Картлар гына үткәнне уйлый ул. Ә аңа киләчәге турында хыялланырга кирәк. Авылда «Миргазиз карт» дип юкка кушамат такмаганнар икән үзенә. Бөтенесен уйлый, ә менә әнисе, әтисе, Азат, Әнфисә турында уйларга курка. Алар искә төшсә, ничектер күзенә яшь килә. Әнисенең күңеле йомшарырга гына тора иде бит. Армиягә озатканда да елады. «Исән-сау әйләнеп кайт, улым!» — дип кат-кат кабатлады. Сизгән диярсең. Озату мәҗлесендә дә баштарак күңелле утырды да азакка таба гел коелып төште.

— Сугышка китмим бит, әни, нигә елыйсың? — дигән иде аңа Рифкать.

— Дөнья хәлен белеп булмый, улым.

— Бер мин генә түгел бит, бар да китә.

— Анысы шулай да. Минем өчен син бер генә шул.

— Ташлале, Миңниса, шул суган сыгуыңны. Малаең солдат булганга еларга түгел, сөенергә кирәк. Менә нинди егет үстереп бирдең бит. Хезмәт итсен әйдә, илне, җирне куандырсын! Безнең нәсел, Аллага шөкер, моңа кадәр сынатмады, утка да, суга да керде, Рифкать тә йөзгә кызыллык китермәс. Шулаймы, әнисе, шулаймы, улым,— дип, әтисе өстәлнең әле бер башына, әле икенче башына йөри-йөри сөйләде.— Әйдә, улым, кунакларның күңеле ачылсын, үзебезчә бер көй сыздырып җибәр әле.

— Әрет әле йөрәк маен!

— Җыр да җырламагач, солдат озату буламыни!

Кунаклар гөр килеп шаулаша башлагач, әнисенең дә йөзенә нур кунды. Рифкать үз бүлмәсенә кереп гитара алды да өстәл янына килеп басты.

— Нәрсә уйныйм соң?

— Һи-һи! Кит моннан,— диде аңа җизни тиеш кеше.— Бу шалтыравыкка кушыла алмыйм мин.

— Ташлале шул тимерчыбыклы әрҗәңне.

— Гармун кирәк, гармун.

— Гармунның көе аккан су шикелле бит аның. Ә бу нәрсә шылтыр да шолтыр.

— Ярар инде, агай-энеләр,— дип, аларны тынычландырды әтисе.— Кемгә нәрсә бит. Безнең колак шуңа күнеккәндер инде. Соң, улым, авылдан өйрәнеп кайттым, дигән идең бит. Кунакларның күңелен күр әле бер.

Рифкать гитарасын стенага сөяп куйды да иңбашына гармун каешын салды.

— Юньләп уйный белмим бит.

— Әйдә, әйдә, ялындырма!

Ул гармун төймәләренә карый-карый уйнап җибәрде. Шактый гына кызып киткән кунаклар, берәм-берәм сөйләшүдән туктап, тын калдылар. Өстәл почмагына утырган агай гына нәрсәдер әйтергә талпына, ә хатыны, аны тыярга тырышып, терсәге белән төртә. Менә ул хатынының кулын этәреп куйды да торып басты:

— Ә минем малай бармый! — дип кычкырды ул.— Минем малай институтка керәм, ди! — Мактануы идеме бу аның, әллә уфтануымы — беркем дә аңламады, аңа игътибар итүче дә булмады.

— Тукта инде, җүләр,— дип, хатыны итәгеннән тартып урынына утыртты.

— Ә минем малай бармый, ә минем малай...— дип һаман сөйләнә бирде ул. Ләкин шулчак Рифкатьнең этисе җыр башлап җибәрде, һәм аның тавышы күмелеп калды. Җырны барысы да күтәреп алдылар.

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына
Кайтыр идем яшьлегемә,
Тик сине алып кына.

— Әйдә, кушыл, кода.

— Җиңги, җиңги, нигә авызыңа су капкандай утырасың?

— Ә-әй, күрше, малай көн дә китми бит армиягә, селкетик әле дөньясын!

Әтисе белән әнисе берсен-берсе уздырып кунакларны кыстый, болай да кызып җиткән мәҗлесне тагын да ямьлерәк, күңеллерәк итәргә тырыша иде. Җыр кунакларны җилкетеп җибәрде, кайберләре сикереп торып биергә үк тотынды. Рифкать бию көен белми, шуңа күрә гармунын өзек-өзек тарткалап кына торды. Ләкин җыр, бию, кычкырып сөйләшү авазлары астында гармун тавышы ишетелми дә иде. Ирләр чүгәли-чүгәли бии, ә хатын-кызлар өстәлнең бер башына җыелган да бер-берсен бүләбүлә нидер сөйләшә:

— Мәрфуганың малае армиядән кайткан, ул киемнәре, ул буй-сын, коеп куйган гөрнәдир инде.

— И-и, кызый, әле генә елак бер малай иде бит. Әнисе итәгенә ябышып йөри иде.

— Сафуранныкыннан да хат килгән. Макарон булып калам, дигән. Анысы нәрсәдер инде тагын? Солдатларны ашатып торучыдыр йә.

Ирләр дөбер-шатыр бии, ә өстәл читендәге агайның үз кайгысы кайгы — каршысында торган шешәдән сала да эчә, сала да эчә. Эчкән саен йөзен чытып куя да һаман бер сүзне кабатлый: «Ә минем малай бармый. Минем малайны алмыйлар. Ул институтка керәм, ди, зур начальник булам, ди».

Үзен беркем дә тыңламаганга аның кәефе китә, ахрысы, әле берсенә, әле икенчесенә төртә. Ә кунаклар, борылып, баш кына кагалар да тагын уен-көлкегә бирeләләр.

Тора-бара гармунның да кирәге бетте, һәркем үзе яраткан, үзе генә белгән җырны җырлады: «Порт-Артур»ы да, «Дранча»сы да, «Баламишкин»ы да калмады.

Кунаклар таралышканда, төн уртасы җиткән иде инде.

— Улым, саубуллаш,— диде әнисе.

Рифкать һәрберсе белән аерым-аерым саубуллашып чыкты. Агайларның күңел йомшаган иде: аның җилкәсеннән сөйделәр, башыннан сыпырдылар, кочакладылар, ә ул нишләргә белмичә, кызарынып, бер урында таптанып торды. Исерек абый, алпан-тилпән атлап, Рифкатьнең кулын тотты да җибәрми генә:

— Әйдә инде, саубуллаш та киттек,— дип, кырыенда хатыны тыкырдатып тора.

— Тс-с! — ди ул. Үзе нәрсәдер әйтергә тели, ләкин сүз таба алмый, Рифкатьнең кулын кыскан килеш тик тора. Хатыны башына бүреген кидергәч кенә, ул, аңына килгәндәй, күтәрелеп карады да ишеккә таба атлады. Пальтосын кигәндә чайкалып китте дә стенага сөялде.

— И Ходайларым, мәҗлестә дә кешечә утыра белмисең бит. Уҗымга чыккан сыер шикелле күбенгәнче эчмәсәң!

— Тс-с, хатын,— дип еламсырады ул һәм бармак янады.— Тс-с! Ә минем малай бармый...

— Тукта инде, җүләр, тукта, ишеттек бит, бөтенесе дә ишетте. Бармаса, бөтен кешегә дә армиягә китеп бетәргә димәгән бит.

— Минме җүләр? Мин җүл-ләр түгел! Малаең җүләр синең. Боламык ул, мәми авыз. Синең эш, син шулай тәрбияләдең. Үчтеки-үчтеки итеп үстердең. И-их, без яшь чакта! Армиягә киткәндә мине бөтен авыл озаткан иде. Бөтен авыл. Сабантуйда беренче килгән атны җиккәннәр иде. Шөлдерләр тагып, сөлгеләр элеп. Яшь чагым булса, тагын бер китәр идем! И-их!

Хатыны аңа артык сөйләшергә ирек бирмәде, таза кулы белән каерып алды да төрткәли-төрткәли алып чыгып китте. Подъездда аның исерек тавышы ишетелде:

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына...

Кунаклар киткәч, өй кинәт тынып, бушап калды. Рифкать, үзенә урын таба алмыйча, ишекле-түрле йөрде, ан-

нары, бүлмәсенә кереп, магнитофон кабызды. Кухнядан әнисенең тавышы ишетелде:

— Улым, үзеңнең җырларыңны яздырып калдыр әле. Сагынганда тыңларбыз.

— Сагынырсызмы соң?

— Әй, сөйләмә әле юк сүзне.

— Ярый, иртәгә көндез яздырырмын. Иртәгә дә көн бар бит әле. Өстәл җыярга булышыйммы?

— Кит аннан, ир кеше эше түгел ул.

— Моңа кадәр җыештырганда сүз әйтми идең бит әле.

— Моңа кадәр әле син малай идең, менә инде хәзер ир-ат булдың.

— Хәзер хатын-кызга, ир-атка аеру бетте инде ул.

— Алайса, нигә Әнфисәне армиягә алмыйлар соң? Аеру бетсә, аңа да солдат шинеле кидерерләр иде.

Рифкать җавап кайтармады.

## 11

Инде тәрәзәдән төн шәүләсе дә сизелә башлады, ә аның һаман күзенә йокы керми. Күрше бүлмәдә сәгать тавышы ишетелә. Келт-келт, келт-келт. Тагын бер төннән ул китәчәк. Келт-келт, келт-келт. Кара, моңа кадәр ул сәгатькә матур уенчык кына итеп, дәрескә барыр вакыт җиткәнне, тәнәфес беткәнне, этисе эштән кайтырга чыкканны, кино башланганны күрсәтә торган серле бер уенчык итеп кенә карый иде. Баксаң, әйтеп тә, сөйләп тә аңлатып булмый торган вакыт атлы нәрсәне, гомер узганын, аның һәм башкаларның да гомере узганын искәртеп тора икән бит сәгать. Келт-келт... Этисе белән әнисе дә йокламый бугай, стена аша аларның пышылдашып кына сөйләшкәне ишетелә:

— Әллә Казанга хәтле озата барасыңмы соң, Шәфкать?

— Кит инде, булмаганны сөйләмә. Кеше көләр.

— Бик кыерсытмасалар гына ярар иде инде үзен. Бигрәк йомшак күңелле бит. Кешегә күтәрелеп бәрелә торганнардан түгел.

— Алай димә, әнисе. Юаштан юан чыга, диләр. Бабасына охшаса...

— Анда караватлар ике катлы икән. Өстәгесенә эләгеп егылып төшмәсә ярый инде.

Әтисе әкрен генә көлеп җибәрде.

— Син инде бөтенләй бетереп ташлыйсың малаеңны.

— Күңелем тыныч түгел. Төпчек малай булгангамы, бер дә читкә җибәрәсем килми.— Әтисенең тавышы ишетелмәде.— Ни кушсаң, шуны эшләргә генә тора иде.

— Иде дә иде... Мәрхүм кеше турында сөйләмисең бит,— дип кызып китте әтисе.

— Игезәк бала үстерү авыр, диләр иде, болар икесе бер бала караган шикелле дә булмады. Әнфисәсе дә бик тәүфыйклы. Тик менә, Шәфкать, игезәкләрнең берсе озак яшәми, диләр, хакмы икән шул сүз?

— Авызыңнан җил алсын! Каян башыңа килә мондый тузга язмаган уйлар? Әллә, мин күрмәгәндә, шайтан суының катырагын да авыз иткәнсең инде?

— Болай гына әйтәм инде, аптыраганнан.

— Йокла әйдә, йокла, юк белән бетеренмә.

Әнисе авыр сулап куйды да тын калды. Ләкин аларның йоклый алмауларын, түшәмгә карап һәр икесе тиң үзалдына уйланып ятуын Рифкать стена аша да сизеп тора иде.

Иртән ул Әнфисә тавышына уянып китте:

— Подъем! Торырга вакыт, солдат. Казарманы җыештырасы бар. Әйдә, паласларны кагып керәбез!

Рифкать бераз гына иркәләнеп ятты да, сикереп торып, магнитофоннан музыка җибәрде.

— Хәзер, җыя тор!

Өчәр-дүртәр баскычны берьюлы сикерә-сикерә урамга йөгереп чыктылар. Паласны, ике башыннан икесе тотып, кага башладылар. Рифкать кинәт кенә ныгытып тартып җибәрә дә, Әнфисә паласны кулыннан ычкындыра.

— Мин киткәч, бу паласны ничек кагарсың икән? — ди ул, ә үзе көлә.

— Бер башын баганага бәйләп куярмын.

— Ул баганаң да армиягә китәргә йөри бит.

— Әй лә, синең белән сөйләшеп тә булмый... Китсә, синекеләр кала бит. Киленнәрне чакырырмын.

— Нинди киленнәр ул тагын?

— Галия белән Әлфияне.

— Икесен дә берьюлымы?

— Әйе.

— Чакырсаң соң, исем китте...

— Исең китмәсә, бохар мәчесе шикелле көннәр буе тәрәзә төбендә утырмас идең... Сер итеп кенә әйт әле, кайсын яратасың аларның?

— Икесен дә... Кайсы миңа хат яза, кайсы мине солдаттан кайтканчы саргаеп көтә — шунысын... Солдат булу безгә кыен түгел, риза булса кызлар көтәргә...

## 12

Кич аларга дуслары, классташлары, иптәшләре җыелды. Әтисе белән әнисе, яшьләргә комачауламыйк дип, туганнарына китмәкче булганнар иде дә, никтер яхшысынмадылар, Рифкать бүлмәсенә кереп утырдылар. Яшьләрнең сүзләре дә бүтән, уен-көлкесе дә бүтән. Кичәге кунаклар шикелле тәмләп, озын-озак итеп сөйләшми болар: әйткәнне ярып әйтә, хет җир астына кереп кит, җырласа, әдәп саклап, авыз эченнән генә көйләп утырмый, түшәмнәр күтәрерлек итеп яңгырата. Рифкать тә бүген таныйрлык түгел, артык сүз сөйләмичә, ни әйтсәң дә елмаеп тора торган малай мәҗлес үзәгенә әйләнде дә калды. Әле, кызык сүз әйтеп, кызларны көлдерә, әле егетләрне дәртләндереп ала, әле гитарада уйнап, үзе җырлый. Әтисе, йомыш белән чыккандай итеп, бүлмә аша узды. Күрә Рифкать, өстәлне тикшерә инде: бик тә шаулашалар, ул-бу юкмы, янәсе. Андый-мондый нәрсә күрмәгәч, суыткычтан алып, өстәлгә шампанский шешәсе утырта. Кызлар: «У-у-у!» — дип куя, егетләр бөтенесе бергә «урра!» кычкыра. Рифкать шешәсен төби дә: «Биреләсеңме, атам!» — дип кычкыра. «Бирелəм, бирелəм». Ул шешәне икенче, өченче кешегә төби, алар да кулларын күтәрә.

— Хәзер сез — минем әсирләрем. Ни әйтсәм, шуны эшлисез, кая кушсам, шунда барасыз,— дип көлә Рифкать.

— Риза, риза! — дип кычкыра барысы да.

— Автоматларны корырга! — Ул рюмкаларга күбекле шәраб коя.

— Коралларны әзерләргә! — Кызлар, егетләр, командага буйсынып, кулларына кашык, чәнечке алалар.

— Ата-ка-га!

— Ә тост? — дип сорый арадан кемдер.

— Дуслык өчен!

Рюмкалар чәкешә, тәлинкә шалтырый, уен-көлке, шаян сүзләр сибелә.

— Җыр башларга! — дип, барысының тавышын басарга тырышып кычкыра Рифкать. Ләкин аны ишетмиләр. Ул аптырап карап тора да кулына гитара ала.

— Теге яңа җыр ничек әле?

— Солдат турындагымы?

— Башладыкмы шуны.

Утларга да бер керербез әле,
Без менәрбез әле күкләргә.
Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

Кунакларны озатканда, Рифкать Рөстәмне үз бүлмәсенә чакырып кертте.

— Мә, Рөстәм,— диде ул, бүреген аңа сузып.— Миңа барыбер кирәк түгел. Картлар әйтмешли, ашау байдан, үлем Ходайдан анда.

— Кирәк түгел, кайткач киярсең.

— Кайткач, малай, тагын да затлырагын алырбыз. Мә, минем төс итеп киярсең.

Алар гитара уйнап, кочаклашып таңга кадәр Түбән Кама урамнарын әйләнделәр. Йокыларыннан уятмыйк, дип, Әнфисә белән чышын-пышын сөйләшә-сөйләшә ишекне ачсалар, борыннарына коймак исе бәрелде, кухнядан таба чыжлавы ишетелде.

— Кайттыгызмы? — Әнисе, онлы кулларын алъяпкычка сөртә-сөртә, аларга каршы чыкты.— Пинжәгең кая? Әллә хулиганнар салдырдымы? — дип, әнисе күлмәкчән генә торган Рифкатькә карап алды.— Әллә...

— Борчылма, беркем дә бәйләнмәде. Бирдем мин аны.

— Кемгә бирдең?

— Кемгә булса да барыбер түгелмени,— дип, Рифкатьне якларга ашыкты Әнфисә.

— Бирдем дип... Әйбер кызганудан түгел... Кайтмаска китмисең бит... Әйбер — кеше шикелле бит ул, кайтканыңны көтеп торыр иде. Көтәр әйберсе күбрәк булган саен, тизрәк кайта, ди, адәм баласы. И-и, улым...— дип сукранды-сукранды да әнисе кухнядан тәлинкәсе белән коймак алып чыгып өстәлгә куйды.— Ашагыз, ачыккансыздыр.

Рифкать бу бөркеп торган тәлинкәгә үрелде, ләкин, коймакка кагылуга, бармакларына ут капкандай булды, ул үрсәләнеп кычкырып җибәрде:

— Кайнар!

— Нәрсә дисең, улым?

...Күзләрен ачса, бернинди өй дә, әнисе дә, коймак та юк, бары тик акшарланган буш стеналар да ап-ак түшәм генә.

— Нәрсә кайнар? Башыңмы?

Шундый рәхәт, татлы уйлардан бүленеп, газаплы, борчулы дөньяга кайтканы өчен Рифкатьнең җен ачулары чыкты, ләкин үзенең кайда икәнен аңлагач, шушы шыксыз палатага ямь биреп торган таныш йөзне күргәч, күңеле тынычланды. Ул дәшмәде, аның өзелеп-өзелеп җылы өйләренә, уйларында гына булса да, әнисе янына кайтасы, тубалдай зурайган, утлы шарга әйләнгән башы белән әнисенә сыенасы килә иде. Ләкин күпме тырышса да, әлеге уйлар төш кебек бик еракта калган, таралган, юкка чыккан иде инде. Врач апа палата түрендә үзенең инструментлары белән әвәрә килә: берсен ала, икенчесен куя, суга сала, мамык белән сөртә. Нәкъ әнисе кухняда кайнашкан кебек. Ләкин монда төчкелтем коймак исе урынына, борынны ярып, күңелне болгатып, дару исе килә.

Бер карасаң, бигрәк гади дә инде бу дөнья. Кеше туа, үсә, тегеләй итәм, болай итәм, дип хыяллана, дуслар таба, әллә кемнәр белән бозылышып бетә, тагын татулаша; шулай шау-гөр килеп яшәгәндә кинәт кенә үлә дә китә. Нигә мәңгелек түгел икән соң бу адәм баласы? Карга булып, бернинди максаты, олы хыяллары булмаган гапгади карга да йөз ел яши, диләр. Анысы, үлем бөтенләй булмаса, яшәүнең дә тәме бетәр иде. Кеше нәрсәдән булса да куркырга тиеш. Кайчан да булса үләсен, мәңге яшәмәсен белгәнгә күрә дә, эшләнәсе эшләрен тизрәк эшләп, хыялланасы хыялларны хыялланып бетерергә ашыга ул. Ә мәңгелек булса, түшәмгә төкереп тик ятар иде. Ялкау кеше үлемгә ышанмыйдыр ул. Ләкин үлем мәрхәмәтсез... Ул, урам хулиганнары шикелле, һич көтмәгән җирдә сагалап тора да якаңа килеп ябыша. Бу дарулар белән генә кешене терелтеп булса... Медицина хәзер теләсә нәрсә эшли ала, диләр. Йөрәкне дә күчереп утырта-

лар. Минем... баш бит. Башны күчереп утыртып булмый... Юк, юк, үлсәм башта ук үлгән булыр идем инде. Кан да бирделәр. Миңа үләргә ярамый. Мин бит авылга кайтырга вәгъдә иттем, әткәйгә дә, дусларга да кайтам, дидем. Кайтмасам, алдакчы булам. Әнә, Сашаның умыртка сөяге сынган иде, терелгән бит. Яз көне авариягә очраган солдатка кан биргәннәр иде. Ул да кеше булды. Азат абыйсы биш катлы йорт түбәсеннән егылып та исән калды. Ә ни өчен Рифкать кенә терелмәскә тиеш? Әле ул бернәрсә эшләргә дә өлгермәде бит. Кайткач, аны слесарь итеп алмаслар инде, кулы юк. Әлфия белән ничек исәнләшер икән?! Исәнләшеп тормас, кочаклар да алыр. Тәлгатькә, техникумга керермен, дип язган иде, ярар, аныһы качмас, көтеп торыр әле. Тотар да авылга китәр. Авыл халкының кул юкка гына исе китми аның. Әнә, бабасын инвалидка санаган кеше дә юк. Бүтәннәр белән бер рәттә йөри, җир җимертеп эшли. Аһ, ул тегеләй, аһ, ул болай дип араламыйлар. Аннары, бераз түл җыйгач, күз күрер әле. Читтән торып укырга да була. Ныгытып тотынса, кешедән ким укымас. Өйдә, кич җиттеме, гел шул уку турында була иде сүз. Әнисе көндәлеген карый да көрсенә, карый да көрсенә. Ә ул юләр кеше шикелле елмая гына. Аңа бу уку мәңге бетмәс, бүген укымаса, иртәгә укыр кебек тоела. Чирек азагы җитәрәк эшнең мөшкеллеген сизенә башлый да көне-төне китап белән утыра. Гел шулай. Спорт буенча мәктәптә аңа тиңнәр юк, дуслары да күп — барысы да әйбәт, тик менә көннекенкөнгә укып, дәресләрен карап бара алмый. Унынчыны бетергәндә дә ике-өч ай кала гына ныклап әзерләнә башлады. «Булмый инде синнән, шул гитара, магнитофон белән җенләнеп, чабыш аты шикелле басу буйлап йөгерүдән ары китә алмассың»,— дип, әнисе көн дә колакка тукый башлагач, моңа да барып җитте бугай, кинәт кенә басынкыланып калды, өстәл читенә китапларын өеп куйды.

— Зимнийны штурм белән алырга булдыңмыни? — дип көлде аннан Әнфисә.

— Нигә, без кемнән ким?

— Әйдә, әйдә, маташып кара.

Рифкать дәреслекләренә аның саен үҗәтләнебрәк тотынды, төн йокылары качты, урамга да чыкмады, ябыгып, суырылып калды.

Имтихан тапшырган көнне ул өйгә атылып кайтып керде. Керә-керешкә: «Әнфисә кайда?» — дип сорады һәм аны күрүгә: «Зимнийны алдык!» — дип кычкырды. «Ничәле, өчлеме?» «Зимнийны алдык, дим бит. Котла, дүртле!»

Ә имтиханнарны биреп бетергәч, күңелендә бушлык сизде ул. Нишләргә, кая барырга? Әнфисә ГПТУга керәм, ди. Аның йөрәге каядыр атлыга, ярсый, ләкин кая икәне билгесез. Әнисе укырга керергә кыстый, укымаган кешегә сан юк хәзер, дип тә карый. Әтисе теге якка да, бу якка да кистереп сүз әйтми. Ә Рифкать көче ташып торган әзмәвердәй гәүдәсе белән тагын кысан парта арасына кереп утыруны күз алдына да китерә алмый, ул, көтүдән аерылып, үз иркенә чыккан тай кебек, бертуктаусыз чаба да чаба, тәртә арасына керер алдыннан соңгы тапкыр уйнап калырга ашыга кебек. Аның инде күңел түрендә ныгытып куйган уе да бар, ләкин хәзергә бу турыда берсенә дә әйтми. Чөнки өйдә: «Малаебыз кем булыр икән, кайда урнашыр икән?» — дип, әти-әнисенең ләззәтле борчылу белән табын янында сөйләшкәнен тыңлау аңа әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә иде. Август ахырына хәтле шулай яшьлек иләслегенә бирелеп йөрде дә көннәрдән бер көнне серне ачарга булды.

— Әнкәй, мин монтажлау идарәсенә язылып кайттым. Өйрәнчек слесарь итеп алалар.

— Һе-е,— дип аптырап карап торды әнисе.

Рифкать бу «һе»нең хуплаумы, әллә өнәп бетермәүме икәнен төшенмәде, шуңа күрә, акланган шикелле, тизтиз аңлатырга тотынды:

— Киләсе елга барыбер армиягә китәсе. Азрак эшкә өйрәнермен. Беренче эш хакыннан сиңа менә мондый зур бүләк алып кайтырмын.

— Анысы өчен рәхмәт. Слесарь дисеңме әле?..

— Әйе.

— Нигә, бик яхшы һөнәр,— дип сүзгә кушылды әтисе.— Малайның тимер-томырга кулы ятып тора.

— Шулай да бит...

— Кайгырма әле юкка, әнкәй, менә күрерсең, армиядән кайткач та укырга керермен. Ә хәзергә эшче класс булып карыйк. Менә син үзең ярты гомереңне шахтада эшләгәнсең, хәзер — маляр. Исемеңне гел мактап телгә алалар.

— Безнең заманасы бүтән иде, укырга җай чыкмады, ә хәзер бөтен нәрсә җитеш бит.

— Генетика дигән фән белән таныш түгел бугай син, әнкәй. Менә шул фән әйтә, бер нәсел кешеләренең холык-гадәтләре, төс-кыяфәтләре — бөтен нәрсәсе буыннан буынга күчеп йөри, ди. Димәк, телисеңме-теләмисеңме, син әллә кайчангы бер бабаңа охшаган булып чыгасың. Ә безнең нәсел, белгәнеңчә, эшчеләр нәселе, игенчеләр нәселе. Шулай итеп, мин әлеге нәселнең бер чылбыры, табигать законының табигый бер чагылышы булып чыгам.

— И-и, әллә нинди сүзләр белән баш болгатып утырасың инде. Алма агачыннан ерак төшми, охшасаң охшарсың икән...

— Миргазиз картка,— дип йомгаклады әтисе.

## 13

Рифкать, уйларыннан арынып, тагын күзләрен ачты. Кич җитә бугай, кояш нурлары сүрәнләнгән, палата да тоныкланып, бәләкәйләнеп калган сыман. Ята торгач, бик кызык уен уйлап тапты бит әле ул: тели икән, күзләрен генә йома да шунда ук әллә кайдагы кешеләр янына барып чыга, алар белән сөйләшә, күңел юата, тели икән, күз кабакларын гына күтәрә дә мең чакрым ераклыктагы палатага кайтып төшә. Тора-бара бу уен белән шундый мавыгып китте ки, ул хәтта янына кешеләр кереп чыгуын да сизмәде, укол кадаганда гына бераз айнып, нәрсәдер тойгандай булды да тизрәк күзләрен йомып, иксез-чиксез әкияткә охшаган татлы уйлар, истәлекләр, хатирәләр дөньясына ашыкты. Ни гаҗәп бу, элек алай булмый иде, ә хәзер күз алдында бар нәрсә шулкадәр ачык, кул сузымы җитәрлек якын булып күренә. Әнә аларның казармасы. Уртада ара калдырып, ике стена буена типтигез тезелгән икешәр катлы караватлар. Һәр ике карават арасында — тумбочка. Тумбочка өстендә — китаплар. Әнә иң өстә Рифкатьнең кызыл тышлы блокноты ята. Анда дусларының адреслары, шигырьләр язылган. Йокларга ятар алдыннан көн саен диярлек шуны бер актарып чыга ул. Армиягә килгәч тә, әле «ямь-яшел» чакта ук башлаган иде аны. Беренче битенә яшел кара белән солдатның нинди булырга тиешлеге язылган. Поли-

тинформациягә әзерләнгәндә бер китаптан тапты бу сүзләрне. «Солдат теләсә нинди хәлдә калганда да үз алдына куелган бурычны үтәп чыгарга, моның өчен берни белән дә исәпләшмәскә, кирәк чакта тормышын да куркыныч астына куярга, Ватан намусы өчен, иптәшләре өчен гомерен дә кызганмаска тиеш. Бөек Ватан сугышы елларында мондый канатлы сүз телгә керде: «Үләргә мөмкин, ләкин Ватан приказын үтәмәү мөмкин түгел». Совет солдаты шундый булырга тиеш». Блокнот битенең астына ул десантниклар эмблемасы ясап куйган иде.

Казарма тып-тын. Ишек төбендәге дневальныйның гына вакыт-вакыт таптанып куйганы ишетелә. Казарма түрендә, агачны көйдереп бизәлгән стена буенда, күзе ачык килеш аягүрә йокыга киткән солдат төсле, тын гына телевизор тора.

«Илдус килгәч, әйтергә кирәк, кызыл тышлы блокнотны алып килсен иде».— Анда ниләр язылганын сүзгә-сүз хәтерләсә дә, никтер блокнотын актарып карыйсы килде аның. «Мин — Советлар Союзы гражданины Миргазизов Рифкать...» Ант бирергә әзерләнгән чакта шул сүзләрне язгач, озак уйланып утырган иде. Бигрәк тантаналы яңгырый: Советлар Союзы гражданины. Мәктәптә аны тугызынчы класс укучысы, унынчы класс укучысы дип йөрттеләр, ярыш вакытында спортсмен дип әйткәлиләр иде, ә авылда Миңниса малае, Шәфкать малае булды. Ә хәзер — Советлар Союзы гражданины. Ничектер күңелгә сыйдырып, мәгънәсен аңлап бетереп булмый бу олы сүзнең.

Ватан алдында тугрылыклы булырга ант биргәч, аларны часть музеена алып килгәннәр иде. Музей каршындагы аллеяда уникe батырның, уникe Советлар Союзы Героеның барельефлары уелган стена тора. Командир алар хезмәт иткән частьның хәрби традицияләре, часть узган данлы сугыш юлы турында сөйләде. «Бу традицияләр бүгенге көндә дә дәвам итә,— диде прапорщик һәм, музей түренә узып, утны кабызды.— Менә монда — тыныч вакытта батырлык кылган десантниклар турында сөйләүче экспонатлар».

Стендтан нәкъ Рифкатьнеке төсле форма кигән, аның яшьләрендәге ике егет елмаеп карап тора. Сурәтләре астында эре хәрефләр белән болай дип язылган:

«ГВАРДИЯ СТАРШИНАСЫ САВЧЕНКО АНАТОЛИЙ ИВАНОВИЧ, 1953 ЕЛДА ТУГАН, ВЛКСМ ЧЛЕНЫ, БЕРЕНЧЕ КЛАССЛЫ СПЕЦИАЛИСТ, СОВЕТ АРМИЯСЕ ОТЛИЧНИГЫ.

ГВАРДИЯ ӨЛКӘН СЕРЖАНТЫ КОТКО ВИКТОР ВЛАДИМИРОВИЧ, 1954 ЕЛДА ТУГАН, ВЛКСМ ЧЛЕНЫ, БЕРЕНЧЕ КЛАССЛЫ СПЕЦИАЛИСТ, СОВЕТ АРМИЯСЕ ОТЛИЧНИГЫ.

ХӘРБИ ҺӘМ ПОЛИТИК ЭШТӘГЕ ЗУР УҢЫШЛАРЫ, ЮГАРЫ ХӘРБИ ОСТАЛЫКЛАРЫ ҺӘМ АВЫР ҺАВА ДЕСАНТЫ ТЕХНИКАСЫН «ДОШМАН» ТЫЛЫНА ТӨШЕРГӘНДӘ КҮРСӘТКӘН БАТЫРЛЫКЛАРЫ ӨЧЕН КОМСОМОЛЕЦЛАР А.САВЧЕНКО ҺӘМ В.КОТКО КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ».

Рифкать үз күзләренә үзе ышанмады. Күктә тургайлар сайрап торган тып-тыныч заманда ничек итеп шундый зур батырлык эшләде икән соң алар? Армиядә төрлесе булырга мөмкин: автоматтан да аталар, граната да ыргыталар, туплар да гөрселди, самолетлар да сызгырып оча, танклар да җир селкетеп йөри,— чын сугыш бара диярсең. Ләкин шул чакта игътибар белән тирә-якка карасаң, полигон читендә чайкалып утырган игеннәрне, зәпзәңгәр тыныч күк йөзен күрәсең дә бу хәрби өйрәнүләрнең, ни әйтсәң дә, киноларда күргән, китапларда укыган, бабасы сөйләвеннән ишетеп белгән чын сугыш түгеллеген, ә бәлки бик зур һәм кирәкле, бик җитди уен гына икәнен аңлыйсың. Нәрсәсе беләндер ул бала чакта уйнаган сугыш-сугыш уенын да хәтерләтә кебек. Бәләкәй чакта, уйный торгач, чынлап сугышып киткән чаклары да була иде. Чөнки уенга бирелеп, кызып җиткәч, уйный торган иптәшең чын-чыннан дошман булып күренә башлый. Монда алайга ук барып җитми җитүен, ни әйтсәң дә, балачага түгел бит, солдатлар. Ә шулай да өйрәнүләр вакытында, кайчак үзең дә сизмәстән, онытылып китәсең, әгәр инде шундый чакта каршыңда чын дошман да торса, үзүзеңне аямыйча, өстенә ташланасыңа бер шигең дә булмый.

Наполеон заманыннан калган мылтыкларны караганда да, төрле револьверлар, пистолет-наганнар, автоматлар, туплар, сугыш трофейлары белән танышканда да Рифкать һаман шул турыда уйлады. Музейдан чыгып казар-

мага кайткач та, елмаеп карап торган ике егет сурәте күз алдыннан китмәде. «Димәк, солдат хезмәте — сугыш-сугыш уены гына түгел. Орденны юкка бирмәсләр. Сугыш вакытында да теләсә кемгә бирмәгәннәр аны»,— диде ул эчтән генә үз-үзенә.

## 14

Нәрсәдер шапылдаган тавыш ишетелде. Гөр килеп палатага берничә кеше килеп керде.

— Шушымыни инде безнең герой? Берәр җире тырналган мәллә? Хәзер без аны...— Түгәрәк йөзле, итләч борынлы, ак башлыклы врач, Рифкатьнең чынлап ятуына ышанмаган кебек, шаяра-көлә урындыкка килеп утырды. Баш бармаклары белән аскы күз кабакларын тартып карады: бер дә врач димәссең, нәкъ шәһәр ашханәсендәге пешекче абый инде.— Шактый бәргәнсең икән шул. Сакларга кирәк иде, нәрсәне-нәрсәне, ә башны сакларга кирәк иде.

— Куркак кеше генә арты белән суга сикерә бит, иптәш доктор,— дип, кыяр-кыймас кына сүз катты шушындый ук ак халат, ак башлык кигән аксыл-сары йөзле егет.

— Батыр кеше башы белән утка керә дисеңме?

— Әйе.

— Анысы дөрес. Егет кеше утка да керсен, суга да төшсен — шуңа күрә «җегет» дип атаганнар аны. Ләкин исән чыксын! — Шулай дип кистереп кенә әйтте дә, тавышын йомшарта төшеп, Рифкатькә эндәште: — Ә син борчылма, күпкә түзгәнне, азга гына түзәрсең. Эчеңдәге юк-бар уйларыңны чыгарып ташла. Кара аны, берсен дә калдырасы булма, башыңны ачкач, барыбер күрәм мин аны, миннән яшерә алмассың. Без аны, момент ачып, тимер-томырын алабыз да шалт итеп ябып куябыз. Сизми дә калырсың. Ярый, син әзерлән. Без киттек.

Рифкать идән шыгырдаганны гына ишетте, күзләрен күтәреп карыйсы килмәдеме, әллә хәле киттеме — тавыш-тынсыз, бер хәрәкәтсез ятуында булды.

«Исән чыксын!» — диде врач. Әйтүе генә җиңел. Андый чакта ничек чыгасыңны уйлап торып буламыни? «Ачабыз да ябабыз»,— ди. Алай җиңел генә булыр микән?

Алар шаяргач-көлгәч тә, Рифкать үз хәлен үзе генә белә. Авыртуны басам дип көчәнә торгач, тешләре сызлый башлады инде. Күңел дә болгана. Әллә дару исеннән инде? Тәрәзәләрне ачсалар иде, ичмасам. Врач апа да чыгып киткән. Ул да арыгандыр инде. Тәүлек буе яныннан китми утыра бит, бичара. Артык сөйләшми дә, борчырмын дип уйлый, ахрысы, моңсу күзләре белән аңа карый да шулай сәгатьләр буе тик утыра. Тәрәзә артында сәрви куаклары арасыннан алсу күк йөзе күренә. Кояш инде йортлар артына кереп югалган. Димәк, монда төгәл бер тәүлек ята. Авыру кешеләргә гомер бик озын тоеладыр ул. Әллә киресенчә микән? Шулайдыр. Аларга әле яши дә башламаган кебектер, бөтен гомерләре — киләчәк матур-матур гомерләре алдадыр, ә монысы яман бер төш, саташу, табигать ялгышы кебек кенә тоеладыр. Ә минем хәл башкачарак бит. География дәресендә узган субүлгеч кебек кенә. Субүлгечнең бер ягында — кояшлы тау итәгеннән челтерәп агып төшүче саф сулы чишмә төсле онтугыз ел гомер, ә икенче ягында — караңгы тау итәге. Ул ягында нәрсә булыр, нинди сулар агар анда? Әллә төпсез упкын булырмы? Хәзер ул кояшлы тау итәгенә таба йөз белән басып кыяташ өстендә тора. Ә артка, дөресрәге, алга, киләчәккә, киләчәк гомере ягына борылып карарга курка. Борылып карауга, төпсез упкынны күреп, башы әйләнер дә шунда очар төсле. Ничек кенә булса да, шушы таш кыядан ычкынмаска кирәк, тырнаклар белән ябышып булса да торырга, ләкин егылмаска, түзәргә, бирешмәскә кирәк!

Ничек кенә булды соң әле бу? Өйрәнүләр дә үткән, барысы да исән-сау, ә мин монда ятам. Врач дөрес әйтте, болай юк-бар нәрсә уйлап, үземне газапламаска кирәк. Онытырга, барысын да онытырга!

Йә булмаса, врач әйтмешли, яхшырак нәрсәләр хакында уйларга кирәк...

## 15

Самолеттан сикерүгә ул, җил тыгызлыгыннан, җил ачылыгыннан саклану өчен, ирексездән күзләрен йомды. Нәрсәгәдер таянырга теләп, тырыша-тырыша аякларын аска сузды, куллары белән тотынып җир эзләде.

Берни дә таба алмагач, нәрсә булса, шул булыр дигәндәй, бөтенләй битараф калды. Ләкин бу битарафлык озакка бармады, күңелгә бер-бер артлы шомлы уйлар килә башлады. Гүя ул шаулап агучы тау елгасына егылып төшкән дә ярга чыга алмыйча ага да ага.

Рифкать, колач җәеп йөзәргә теләгәндәй, кулларын бутап алды да, гәүдәсе ныклыгын югалтып бөтерелә башлавын сизгәч, күзләрен ачты. Аста бик зур тәлинкәгә охшаган түгәрәк күренде. Кинәт аңа ул үзе аска таба төшми, ә күлләр-елгалар, басу-кырлар тезелгән шушы гаҗәп зур тәлинкә, Җир атлы тәлинкә, күзгә күренеп якыная, өскә таба очып килә кебек тоелды.

Менә кызыл көчеккә охшаган кояш, астан гына үрелеп, алсу теле белән тәлинкәнең бер читен ялый башлады. Көчек-кояш башын күтәргән саен, аның кызыллыгы сыегая. Ул әкренләп үзенең алтын-сары төсенә керә бара — әйтерсең кемдер аны ялгыш кызыл буяулы чиләккә төшергән дә хәзер, кеше-кара күргәнче дип, ашыга-ашыга сөртә иде.

Җылы кояш нурлары, тыгыз һава белән өретелгән, шартларга җитеп киерелгән гөмбәз аша узып, салкын шәмәхә төскә керде. Күк йөзе тулы шәмәхә гөмбәзләр. Күзне кысыбрак карасаң, ниндидер җан ияләре болыт мендәрләргә эленеп торган кебек күренә. Рифкатьнең шул чак җырлыйсы килеп китте.

Фәрештәдәй күктән төшә дә ул,
Җен шикелле керә сугышка...

Бүген аларга, чыннан да, җен кебек чабарга туры киләчәк. Рифкать сул кулы белән автоматын капшады. Җир, тәлинкә формасын югалтып, гадәти җиргә әйләнеп калды. Аста — куе яшел төстәге дала. Анда-санда, төрле зурлыктагы күзге ватыкларына охшап, күлдәвекләр ялтырый. Ике көн тоташ яуган яңгырдан соң җир әле кипшерә дә башламаган. Кояш нурлары, яңа гына йокысыннан торып юынырга җыенган малай кебек, иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә күлдәвекләрдә коена. Рифкать башын күтәреп карады: зәңгәр күк йөзен исәпсез-сансыз гөмбәзләр чуарлаган, хәтта кояш та болыт арасыннан башын тыгып караган сыман күренеп-күренеп кенә китә. Бу гөмбәзләр барысы да төшеп җиткәч, җирдә басар урын да калмас шикелле. Көнбатыш яктан салкынча җил исеп

куйды. Әйтерсең, бу хозурлыктан аерылып җиргә аяк баскач, аларны ни көтәсен искәртә иде ул. Әллә инде өстә генә шулай тын булган, төшкән саен җил көчәйгәннән-көчәя бара, парашют гөмбәзенә кереп сызгыра, аны үзенә ияртеп алып китмәкче була. Төшеп җитәргә берничә йөз метр калгач, ул бөтенләй чыгырдан чыкты, офык читеннән шактый күтәрелеп өлгергән кояш та, бу минем эш түгел дигәндәй, уңайсызланып кына елмая. Ә җил һаман саен котыра, парашютны йолкып-йолкып ала, өреп сүндерергә теләгәндәй, кояшка ташлана, ә кояш, җил искән саен гаҗәеп зур утлы күмердәй кызара да, яңадан күксел элпә белән капланып, тоныкланып кала. Җир өстенә шомлы караңгылык иңә, колак төбендә улаган җилдән күңелләр чымырдый. Әле генә шундый тыныч, шундый матур дөнья, кемдер авырткан сөяленә баскандай, өзгәләнә, ачуын кемнән алырга да белмичә, ачы җиле белән юлында очраган һәр кешенең битенә китереп бәрә, дала буйлап чәчелеп яткан күлдәвек йөзләрен шадралатып уза, үләннәрнең башын җиргә бәрә-бәрә кыйный. Әйтерсең аста, иге-чиге күренмәгән дала эчендә, чыннан да мәхшәр купкан, әйтерсең анда хәрби өйрәнүләр түгел, ә чын сугыш бара. Командир: «Өйрәнүләр сугыш шартларына якын китерелеп үткәреләчәк»,— дигән иде. Анысы шулайдыр, ләкин бу давыл да командир приказы белән килмәгәндер бит.

Менә кояш бөтенләй күздән югалды. Парашют гөмбәзе хәтле генә болыт астыннан кояш озакламый яңадан килеп чыкты, ләкин аны болытның икенчесе — зуррагы каплады. Офык ягыннан, көннең тәмам бозылганлыгына шик калдырмыйча, өем-өем болытлар агыла иде. Бер караганда алар «дошман» десантникларына охшап күренә, әйтерсең уңай вакытны гына көтеп торганнар да менә хәзер хәйлә белән артка төшмәк булалар.

Рифкать үз уйларыннан үзе көлеп куйды һәм, җиргә якынлашуын күреп, автоматын кулга алды. «Та-тата. Та-та-та». Кемдер алданрак өлгерде, күктә бер-бер артлы «урра!» кычкырган авазлар ишетелде. Җирдә атканда алай булмый иде: автомат иңбашына китереп бәргән саен, гәүдә артка таба этәрелеп, шуышып китә. Менә аяклар җиргә тиде, Рифкать тез буыннарын йомшатып чүгәләде, бер аягы чокырга туры килеп, гәүдәсе чайкалып китте, ләкин егылмады, күн итек астын-

нан чәчрәп чыккан су өскә сибелде. Ул, сул кулына автомат тоткан килеш, уң кулы белән битендәге мәтеле суны сыпырып төшерде дә җир өстендә тыпырчынып яткан парашют гөмбәзен үзенә таба тартты. Гөмбәз эченә кереп тулган җил, бирешергә теләмичә, парашютны алга өстери, тәгәрәтеп йөртә, ак ефәкне пычрак суга манып-манып ала. Рифкать тиз генә бауларын ычкындыруга, парашют, үпкәләгәндәй, бөтерелә-бөтерелә җиргә төшә калды, ә ул җилгә йөз куеп алга йөгерде. Берничә минуттан батальон җыелу урынында сафка тезелгән иде инде.

— Булдырдыгыз, егетләр! Һавада вакытта ук ут ачып, сез «дошман»ның алгы позициясендә торган шартлы көчләрен чигенергә мәҗбүр иттегез. Ләкин «дошман» мәкерле, бик көчле. «Дошман» көньяк-көнбатыш яктан һөҗүм итеп килә, ул бик нык коралланган. Без хәйлә белән аның тылына үтеп керергә һәм җитәкчелек итү пунктын кулга төшерергә тиеш. Башка батальоннар, маневр ясап, «дошман»га һич көтмәгәндә китереп бәрәчәкләр, ә без, бөтен ударны үзебезнең өскә алып, турыдан һөҗүм итәбез! Десантниклар, алга!

Солдатлар береткаларын батырып киделәр дә, алга иелә төшеп, йөгереп киттеләр. Җил бар көче белән гәүдәне артка этә, автомат көпшәсенә кереп ачы тавыш белән сызгыра, күзләрдән яшь чыгара. Аяк асты тайгак, үзле балчык ябышып, күн итекләр күтәрә алмас хәлгә килде, җитмәсә, бер булгач булсын дигәндәй, йөзгә бәреп яңгыр сибәли башлады.

Иртәнге хозурлыктан соң кинәт купкан бу мәхшәр шундый да урынсыз һәм гаҗәеп тоела, әйтерсең табигать бүген күкне аяз итим, дөньяны ямьләндерим, урман-болыннарны, басу-кырларны сөендерим дип, изге ният белән офык капкасыннан кояшны тәгәрәтеп җибәргән дә, күз алдында төтен бөркеп, тирә-юньне дер китереп очучы самолетларны, исәпсез-хисапсыз болыт ертыгына охшаган парашют гөмбәзләрен күргән, һәм, мин сезгә яхшылык теләгән идем, ә сез аңламадыгыз, мәгез инде, алайса, күрмәгәнегезне күрегез дигәндәй, котырынырга, бөтен патшалыгын пыран-заран китерергә тотынган.

Солдатлар чылбыр булып як-якка сибелеп йөгерәләр. Командир арткарак калган солдатларны дәртләндереп кычкыра, шаян сүз әйтеп ала да кинәт кенә усал һәм

таләпчән тавыш белән сөрән сала: «Чылбыр! Чылбырны өзмәгез!»

Рифкать чылбырның уртасында, юл буйлап бара. Танклар, машиналар йөреп, юл инде саз боткасына әйләнгән, урыны белән хәтта күн итекнең кунычы да күренми. Командир аның хәлен аңлый бугай, бер сүз дә эндәшми, бары тик ара-тирә янәшә үк килеп, бергә йөгереп бара да, аны үз урынына калдыргандай, тагын чылбыр читенә китә. Өйрәнүләргә әзерләнгәндә үк, берничә солдатны җыеп: «Сез полкта физик яктан да, мораль яктан да — кыскасы, бөтен яктан да иң әзерлекле солдатлар. Шуңа күрә өйрәнүләр вакытында бүтәннәрне үз артыгыздан ияртергә, иң кыен җиргә башлап керергә тырышыгыз. Десантниклар өчен иң кирәк нәрсә: физик көч, теләсә нинди шартларда да югалып калмау, тиз ориентлаша белү һәм рухи яктан нык булу. Мин сезгә ышанам!» — дигән иде командир. «Сезгә ышанам,— дип эчтән генә кабатлады Рифкать.— Менә ни өчен миңа сүз катмый икән ул».

Инде маневрга киткән батальоннар да күптән күренмәс булды, аяклар кайнар суга тыккан шикелле кызышты, бөтен тәннән пар күтәрелә башлады. Ә «дошман» юк та юк. Ниһаять, командирның кырыс тавышы яңгырады: «Туктарга! Унбиш минутлык ял».

Ләкин тирә-юньдә ышыкланырга, җилдән качып сыенырга, баш төртергә ник бер агач, ник бер куак булсын! Әллә нинди җанвар авазлары чыгарып үкерүче җил дә шәрә яланны ярсый-ярсый чәбәкләүче рәхимсез яңгыр гына.

— Кил монда, палатка корабыз! — дип кычкырды аңа Володя Ищенко. Володя — музыкант егет, торбада уйный. Гитара уйнаганга, җыр яраткангадыр инде, Рифкатьне гел якын итә ул, бәхәс чыкса да, гел аны яклый, һәрчак булышырга гына тора. Әллә торбада уйный-уйный мускуллары тартылган, әллә тумыштан ук шулай булган — ике як яңагы, авызына йомырка капкан шикелле, кабарып тора.

Рифкать, пот-пот саз пычрагы ияргән аякларын өстерәп, палатка белән кайнашучы Володя янына килде.

— Нинди палатка кору ди ул? Унбиш минуттан кузгалабыз бит. Корып та булмый аны бу җилдә.

Володя каршы сүз әйтмәде, палатканы җиргә җәйде дә кайтарып өстенә япты.

— Бөркәнеп кенә утырабыз, кил!

Ләкин җил аларга иркенләп утырырга ирек бирмәде: әле палатканы баш өстеннән каерып ыргытты, әле, бөтерелеп килеп, яңгыр тамчысы белән йөзгә сыпырды. Йөгереп манма тир булганнар иде, хәзер менә тән буйлап салкын тәпиле бөҗәкләр чабыша башлады, аннары, тешләр тешкә тиеп, калтыратырга ук тотынды. Ярый әле шулчак күтәрелергә команда булды, юкса Рифкатьнең аяклары да, оеп, кузгала алмас хәлгә җитеп килә иде.

Сикереп тордылар да тагын «атакага» ташландылар. Рифкать үз урынына, соры тасма булып сузылган баткак юлга чыкты. Дерелдәп торган салкын үзле балчык аякларны суырып-суырып ала. Кырыйдан йөгерүчеләргә бераз җиңелрәк, анда әле җир алай ук актарылмаган, болгатылмаган — суы сулай, җире җирләй аеры тора, шуңа аякка да алай ук иярми. Ләкин җиле барыбер шул ук җил инде...

Рифкать, аяк тавышлары ишетеп, борылып карады. Егерме метрлар чамасы гына артта юлның ике як чите буйлап генерал белән полк командиры килә. Алардан аз гына алдарак — өлкән лейтенант Киреев.

Рифкатьнең ару-талуы кинәт юкка чыккандай булды, ул, барган уңайга аягындагы ләмне төшерә-төшерә, иптәшләрен куып җитәргә ашыкты.

Генерал киләсе дип сөйләгәннәр иде инде аларга. Ләкин менә шулай, һич көтмәгәндә, янәшәдә күрермен дип уена да китермәгән иде Рифкать. Җил-давылга, яңгырга карап тормаган, полигонга чыккан. Хәер, нәрсәгә шаккатырга, заманында генерал да солдат булган бит, сугышта мондыйларны гына күрергә туры килмәгәндер аңа.

Әллә инде йөгерә торгач җылынды, әллә арттан командирлар килүен сизеп торганга шулай булды — Рифкатьнең җилкәсе буйлап җылы май агып төшкән сыман тоелды. Алда «дошман» күренгәндә, ул инде җил-яңгырны да сизмәс дәрәҗәгә җиткән, аның бөтен тәне утлы йомгак төсле кызышкан иде. Шулчак һавада ракета кабынды, алдан киткән батальоннар «дошман»ның тылына төшкәннәр иде, ә Рифкатьләр батальоны «маңгайдан» китереп бәрде.

Ләкин, «идарә итү пункты» алынгач та, «дошман» бирешергә теләмәде, үзенең резервын кертеп, соңгы көче белән һөҗүмгә күчте. Монысы инде — иң соңгы, иң хәлиткеч бәрелеш иде.

## 16

— Гранаталарны әзерләргә! — Командирның җан ачысы белән ертылып кычкырган авазы, яңгыр пәрдәсен үтеп, солдатларга ишетелде.

Рифкать, саз чапырдатып йөгергән уңайга, гранатасын алды. Каршы искән җил керфекне күтәреп карарга да ирек бирми, тир белән кушылган яңгыр суы, маңгайдан агып төшеп, ачыттыра-ачыттыра күзгә керә. Бөтен тән: баш та, аяклар да, куллар да, гәүдә дә ут яна, хәзер менә атылып барган шәпкә танк астына ташланса, аның кызуыннан танк яна башлар сыман иде. Бары тик кулдагы граната гына, салкын бака кебек, уч төбен кытыклап тора. Бу кытыршы салкын тимерне тизрәк «дошман» өстенә ыргытасы, тизрәк аннан котыласы, бу игечиге булмас төсле тоела башлаган мәхшәрле көнгә чик куясы килә. Мәрхәмәтсез җил дә, бөтен тәнгә генә түгел, хәтта үзәкләргә үтеп яуган яңгыр да шушы күз алдына анык китереп булмый торган шартлы дошман эшедер, ул дошманны җиңүгә җил дә басылыр, яңгыр да туктар һәм, болытларны куа-куа, түгәрәк йөзле, ерык авызлы, көләч кояш килеп чыгар төсле.

Рифкать граната бөҗрасын тартты да, уң кулы белән кизәнеп, артка каерылды. Бөтен көченә киерелүдән мускуллар зыңлагандай булды. Хәзер... хәзер... граната «дошман» өстенә очачак. Ул, аякларын саздан суырып чыгара-чыгара, алга атлады. Каршыда бәләкәй генә таучык калкып чыкты. Хәзер... менә шул калкулыкны гына үтә дә... Кинәт аның сул аягы һавада асылынып калды. Нәрсә булды, әллә башы әйләнәме, әллә аягы оеды да берни сизмиме? Ул, җир катысын тоярга теләгәндәй, гәүдәсенең бар авырлыгын сул аягына күчерде һәм, тигезлек саклый алмыйча, янтаеп китте. «Чокыр! Аяк чокырга туры килгән!» Яшен тизлеге белән ялтырап куйган уйдан баш мие бер мизгелгә яктырып киткәндәй булды, күздән утлы инәләр чыгып очты. Ниһаять, сул аяк җирне эзләп тапты, ләкин тотынып кала алмады, таеп китте, һәм Рифкать таучык итәгенә барып төште. Уң кулының терсәге ирексездән язылып китте... Һәм граната җиргә тәгәрәде. Рифкать, ни булганын үзе дә аңламыйча, граната өстенә ташланды, әләктереп алды да аны учына кысты. Шулчак баш миен өтеп, көйдереп утлы өермә узды.

Ул, сытып юкка чыгарырга телэгэндэй, гранатаны һаман саен ныграк кысты. «Дүрт секунд!..» — дип пышылдады ул. Рифкать граната тотып тезлэнгэн җиреннэн сикереп торды: тэндэге бөтен ару-талулар сыпырып алгандай юкка чыккан иде. «Тизрэк! Тизрэк!» дип типте йөрэге. «Тизрэк! Тизрэк!» дип исте җил. «Тизрэк! Тизрэк!» дип, колагында кайтаваз яңгырады, колагы чыңлады. Кинэт алда, калкулык артында, җир астыннан калкып чыккан кебек солдатлар пэйда булды. Әле генэ мишень белэн ике арада буш ялан иде бит... Әллэ миңа гына шулай күренэме дип, ул күзлэрен бер йомып, бер ачып карады. Әйе, алда, аннан ерак та түгел, солдатлар, десантниклар йөгерэ иде. «Туктагыз!» — дип кычкырырга һэм, бар көченэ йөгереп барып, гранатаны алар алдына томырыргамы? Юк! Юк! Дөньяларын онытып алга омтылучы десантниклар аның тавышын ишетмэслэр, ишетсэлэр дэ, аңламаслар.

Дүрт секунд...

Дүрт секундтан граната шартлаячак! Кая куярга, кая яшерергэ, кая томырырга аны? Әгэр тигез, коры җир булса, йөгереп килеп кизэнер иде дэ эллэ кая еракка очырыр иде. Юк, йөгереп булмый, йөгерү түгел, батман-батман үзле балчык өстерэгэн итеклэрне урыныннан кузгатулары да кыен. Нишлэргэ? Алга ыргытырга ярамый, алда — солдатлар, алда — аның иптэшлэре. «И-их,— дип, тешлэрен шыгырдатты Рифкать.— И-их!» Граната ыргыту буенча частьта беренче урынны алгач, командир аны бөтен солдатлар каршында мактаган иде. «Миргазизовка гранатомет та кирэк түгел, ул болай да гранатометтан ераграк ата»,— дип шаярткан иде. Хэзер күрсэ...

Рифкать, граната тоткан кулын баш очына күтэргэн килеш, уң якка борылып карады. Анда да, берни булмагандай, «урра!» кычкыра-кычкыра солдатлар бара. Күз алмалары атылып чыгар дэрэҗэгэ җитеп киерелде, йөрэк ярсып-ярсып типте. Нишлэргэ?

Дүрт секунд!

Рифкать аптырау һэм сорау катыш күзлэрен сул якка төбэде. Чылбыр булып сузылган десантниклар алдагы «дошман»нан башка бернэрсэ дэ күрми чаба да чаба. Йөрэк тибеше аермачык булып чигэгэ бэрэ, бармак очларын чэнчеп-чэнчеп ала.

Дүрт секунд! «Секунд! Секунд!» дип тибэ йөрэк.

Рифкать, башын борып, артка карады һәм кул сузымы гына җирдә, үзеннән егерме метр чамасы гына ераклыкта, олы-олы атлап килүче генералны, аңа нәрсәдер аңлатып, колагына иелгән полковникны, майор белән өлкән лейтенантны күрде. Атылып чыгарга җитешеп типкән йөрәк тагын бер тапкыр «Секунд» дип куйды да тын калды, әйтерсең бөтенләй эреп юкка чыкты. Әллә кайдан астан, күңел түреннән ачыттырып, бөтен тәнне куырып ниндидер дулкын күтәрелә. Менә ул күкрәк турын яндырып узды, менә ул бугазга килеп тыгылды. Рифкать бер мизгелгә генә күзләрен чытырдатып йомды. Ул нидер уйларга, нәрсәдер исенә төшерергә тырышып көчәнде. Ләкин бер әйбер дә хәтергә килмәде; бар дөнья, бөтен истәлекләр, барча дуслар һәм якын кешеләр урыннарыннан купканнар да бергә җыелып өстән, күктән, тын гына, сүзсез генә карап торалар төсле.

Рифкать соңгы мәртәбә як-ягына күз йөртеп чыкты. Аның тирәсендәге боҗра кысылганнан-кысыла бара иде. Алда һәм ике якта — десантниклар, артта — командирлар. Ул, граната ыргытырга урын эзләгәндәй, аптыраудан күккә күтәрелеп карады. Анда кайнап, ярсып, әллә нинди коточкыч кыяфәтләргә кереп болытлар актарыла. Кинәт кенә аның күккә күтәрелеп китәсе, шул болытлар арасына кереп адашасы, югаласы килде. Шулчак тамак төбендә буылып торган утлы дулкын әкрен генә юл ярып баш миенә тула башлады һәм тиздән аның башы утлы тубалга охшап калды. Рифкать инде берни күрми дә, берни сизми дә иде. Бары тик кайдадыр, күңел түрендә генә әйтеп-аңлатып булмый торган үпкәләү һәм аптырау, ачу һәм үҗәтлек катыш бер хис туып килә. Ул бөтен тирәюньне, иксез-чиксез даланы, бар дөньяны яңгыратып нидер кычкырырга теләде, ләкин кирәкле сүз табылмады, тамак төбеннән ыңгырашуга охшаган «аһ» авазы гына чыкты. Онытылып торган йөрәк тагын уянды, тагын атылып-атылып тибәргә тотынды, салкын граната, кызганнан-кыза барып, уч төбен, бармакларны көйдерде. Рифкать җан ачуы белән кулын суырып китерде дә күкрәгенә кысты һәм, кемнәндер гафу үтенгәндәй, җиргә тезләнде. «Хәзер! Хәзер!» — дип пышылдады ул. Йөрәге бөтен гәүдәсен селкетеп тибә, бөтен дөньяда шул йөрәк тибешеннән башка бернәрсә дә юктыр кебек. Яңгыр суы бит буйлап ага. Әллә күз яшьләре инде? Юк, ул елый

алмый, аның күңеле каткан, бары тик баш миенең бер почмагында гына сөенечкә дә, горурлыкка да охшаш бер юләр уй кисәге генә шарчык төсле тәгәрәп йөри. Нин-дидер куркыныч нәрсә буласын сизенгән, шуны тукта-тып калырга, булдырмаска тырышып та көченнән кил-мәгәнен аңлаган табигать елый, болытлар елый, өстәге-ләр елый.

Кинәт, караңгы күкне чәрдәкләп, яшен яшьнәгәндәй булды, җир гөрселдәде, аяк астындагы дала бер якка та-ба шуышып китте дә томан арасына кереп юкка чыкты. Рифкать бермәл, һичнәрсә аңламыйча, һавада асылынып торды, аннары салмак кына каядыр аска, төпсез упкын-га төшә башлады. Төшкән саен дөнья караңгылана бар-ды, күз алдында бөтерелеп торган утлы шар сүнде, ко-лаклардагы гөрселдәү шавы тоныкланды...

## 17

— Дусларың килгән.

Рифкать врачның упкын төбеннән килгән тавышын ишетә, ләкин җавап бирергә кирәкме-юкмы икәнен аң-ламый, күзләрен күтәреп карамый, аңа хәзер тирә-юнь-дәге бар нәрсә буталган, үзенең элекке әһәмиятен, мәгъ-нәсен югалткан кебек тоела, әйтерсең ул моңа кадәр аңы-на килә алмыйча, үлем исереклеге белән саташып яткан да менә кинәт кенә үзенең ни эшләгәненә, нинди хәлдә калганына төшенгән иде.

— Дусларың килгән, Рифкать...

«Ә мин монда әллә ниләр искә төшереп, хыялланып ятам,— дип уйлады Рифкать.— Бөтенесе беткән, бөтене-се артта, граната шартлавы артында калган инде. Хә-зер... бары тик саубуллашып кына була... Хыяллар... Кирәк түгел. Дуслар да... саубуллашырга килгәннәрдер. Округ госпиталеннән хирург чакыртмаслар иде. Димәк...»

Рифкать, һәрнәрсәнең шулай кинәт кенә яңа төсмер алуына гаҗәпләнеп, мыскыллы елмаерга уйлады, ләкин елмаю барып чыкмады, бит мускуллары, иреннәре аны тыңламады.

Ишек ачылып ябылды. Солдатлар, кемнедер йокыдан уятудан курыккан сыман, аяк очларына гына басып, Риф-кать янына якынлашалар. Аларга үч иткәндәй, аяк ат-

лаган саен, тешләрне камаштырып, идән шыгырдый. Менә алар караваt янына тезелешеп бастылар да, ни әйтергә белми, тик торалар. Сүзне, ниһаять, Вагыйз башлады. Ул көчәнүдән кызарынып, бүртенеп чыкты, дугаланып торган кара кашлары уртадан сынды, күзләре кечерәеп, сүрәнләнеп калды.

— Нихәл, Рифкать!

Әйтте дә, мәгънәсез сүз ычкындыргандай, бер урында таптанырга тотынды, бармаклары белән гимнастерка төймәләрен барлап чыкты. Рифкать иреннәрен кыймылдатты, ләкин сүз чыкмады, аннары, минем хәлне үзең дә күреп торасың дигәндәй, моңсу итеп карады да тагын үз эченә бикләнде. Аның хәле юк иде. Вакыт үткән саен, ул мускулларында кайнаган көчнең кими баруын, ком сәгате төсле каядыр агуын сизә. Менә ул агар-агар да берзаманны бөтенләй бетәр, бөтенләй юкка чыгар төсле. Баш миенең бер почмагына кереп оялаган шомлы уй бераз гына онытылып тора да тагын тырмаша башлый, өскә чыга, аннары бөтен күңелне актарып ташлый. Юк, үлем куркытмый аны. Ни өчен алай эшләгәненә дә үкенми, шулай иткән икән, димәк, дөрес эшләгән, димәк, аның башка юлы булмаган. Тумаган кеше генә үлми, диләр бит... Билгеле, әле яшәргә дә яшәргә иде. Армиядән кайтып әти-әнисен сөендерәсе, дуслары белән бергә урам тутырып йөрисе, эшкә урнашасы, укырга керәсе, нытытып гашыйк буласы, гаилә корасы, нindидер зур эшләр майтарасы иде. Ә ул әле яши дә башламаган иде, әле ул яшәргә әзерләнгән генә иде бит. Туды, үсте, дөресрәге, үстерделәр: киендерделәр, ашаттылар, эчерттеләр, мәктәпкә озатып җибәрделәр, теләге булса, үтәделәр. Пионерга керде, комсомол булды, спорт белән җенләнде, музыка-җыр белән шашып йөрде... Ләкин болар барысы да нindидер зур эшкә әзерлек кебек кенә иде. Армиягә килгәч, аларны ай буе карантинда тоттылар, солдат мәктәбен үткәрделәр, аннары тагын айлар буена парашютны мең сүттереп, мең җыйдырдылар. Бары тик шуннан соң гына самолеттан сикерделәр. Кеше дә шулай ярты гомерен әзерлек хәстәре белән үткәрә, бары тик үзендә көч, ныклык, ышаныч сизгәч кенә күккә күтәрелә. Мин кеше гомерен үземчә аңлатам — десантникларча, ә бабай бүтәнчә сөйли иде. Кеше гомере — тау кебек, ди иде ул. Кеше тау итәгендә туа да ярты гомере буе өскә күтәрелә, ме-

неп җиткәч, хозурланып як-ягына карана — бөтен дөнья уч төбендәге кебек, бар нәрсә кечерәеп, бәләкәйләнеп калган, ә ул — зур, ул хәзер теләсә нәрсә эшли алыр, аның кулыннан бар нәрсә дә килер төсле. Ләкин... туктап кала алмый. Вакыт — рәхимсез, вакыт аның аякларын сәгать маятнигы иткән дә алга-артка, артка-алга йөртә, ул ирексездән хәрәкәт итәргә мәҗбүр, ул ирексездән атлап бара. Кеше башта кая барганын да аңламый тора, аннары кинәт кенә аңлап ала да аякларын терәп түбән төшмәскә тырыша, ә маятник туктамый, алга-артка, арткаалга йөри дә йөри. Тау төшкән саен, кешенең күңеле дә төшә, аңа шул ук агачлар да, шул ук үләннәр дә, шул ук чәчәкләр дә бүтәнчә күренә, дөнья да караңгылана барган сыман тоела. Аның күз аллары томалана, ул алдындагы әйберләргә игътибар итми, һаман-һаман теге як тау итәген, андагы кояшлы аланнарны, чыклы үләннәрне, сайрар кошларны, таугa менү ләззәтен искә төшерә, бары шуның белән генә яши...

## 18

Кинәт Рифкать сискәнеп китте... Ул да бүген көне буе бала чагын, үткән көннәрен уйлап ятты бит. Ул да тау төшә микәнни? Юк, ул әле тауга менеп тә җитмәгәндер... Менеп җитә алмыйча егылып төшкәндер. Аның күз алдына аермачык булып тау килеп басты. Менә алар, альпинистлар кебек бер бауга тезелешеп, кыяга үрмәлиләр. Бау очында: Вагыйз, Тансык, Илдус, Володя, Юра, астарак: генерал, полк командиры, өлкән лейтенант, ә уртада — Рифкать. Менә аягы таеп китте дә ул упкын өстендә асылынып калды, иптәшләре дә, командирлар да, нишләргә белмичә, аптырашып карап тора. Берничә секундтан алар барысы да упкынга очачак. «Юк! — дип кычкыра Рифкать.— Юк!» Һәм кесәсеннән пычак алып үзен бәйләгән бауны кисеп җибәрә, зур бау тартылудан зыңлап куя һәм Рифкать аска, упкын төбенә оча.

— Аһ!

Ул, тотынып калырга теләгәндәй, сул кулын һавада бутады һәм, кулы ниндидер җылы әйбер тапкач, күзләрен ачып җибәрде. Илдус аның өстенә иелгән дә кулын

кыскан килеш ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдый иде:

— Рифкать, тынычлан, Рифкать, без монда.

Томан эченнән әкрен генә Вагыйз килеп чыкты, аннары Тансык күренде, аннары — Юра...

— Әйе...— диде Рифкать.

Ул — әле яртылаш кына монда, ә яртылаш ул үзенең уйлары дөньясында иде. Шуңа күрә бу «әйе»нең нәрсәгә әйтелгәнен дә аңлап бетермәде: менә килеп тә җиттек, таудан түбән тәгәри башладык, дияргә теләдеме ул, әллә, янында дусларын күреп, әйе, мин сезне күрәм, әйе, мин исән, мин сезнең белән бергә яшәячәкмен әле, дип расларга уйладымы? Аның уйлары хәзер соң чиккә җитеп буталган, әйтерсең баш сөяге эченә умарта күче оялаган иде. Күчнең гөжләве көчәйгәннән-көчәя бара, кортлар иреккә чыга алмаган ачудан яндырып-яндырып тешлиләр, чыгарга юл эзлиләр сыман.

Врач килеп укол кадагач, умарта күченең гөжләве баcыла төште, һәм Рифкать үзе янында кешеләр бар икәнен исенә төшерде.

— Ә син артык үзгәрмәгәнсең.— Тансык болай да зур авызын җәеп җибәрде, күзләре урынында кара сызык кына калды.

Рифкатьнең инде иртәдән бирле үз-үзен күрәсе килә иде. Йөзен генә ачык калдырып, башын бәйләгәннәр — анысын сизә, ә менә күзләре, борыны, кашлары, авызы, бите нинди икән? Берничә тапкыр врачтан көзге сорарга да җыенды, ләкин никтер җөрьәт итмәде. Менә... хәзер җае чыкты.

— Көзге...— дип пышылдады ул.— Үземне күрәсем килә.

Илдус, кабаланып, гимнастеркасының түш кесәсенә тыгылды, тик шулчак, Вагыйзнең күз карашын күреп, акрын гына кесәсен яңадан төймәләде, кулын кая куярга белми аптырап торды да береткасын әвәли башлады. Рифкать аның бу хәрәкәтен күрде, һәм, мөлдерәп тулган чиләк өстенә бер тамчы тамганнан соң ташып түгелгән су төсле, күңелендәге ачыну хисе бөтен күзәнәкләренә таралды. Илдус та, Вагыйз дә — барысы да ул белмәгән нindидер яшерен һәм коточкыч бер серне беләләрдер, бары тик аннан гына яшерәләрдер, аңа гына әйтмиләрдер төсле тоелды аңа.

— Без чиратлап синең янда утырырга теләгән идек. Врач рөхсәт итми,— диде моңа кадәр бер читтә сүзсез генә торган Юра. Ул, гомумән, күп сөйләшергә яратмый, авыз эченнән генә һәрчак нидер көйләп йөри, кеше сүзенә кушылып китми, бары тик кирәкле урында, инде сүз әйтмәскә мөмкин булмаган җирдә генә бер-ике сүз ыргыта да тагын көйли башлый.— Операциягә кадәр ярамый, диделәр.

— Тыш-та... җы-лы-мы? — дип, әйтергә җиңел булсын өчен, һәр сүзне иҗекләргә бүлә-бүлә сорады Рифкать.

Егетләр, сүзнең палатадан тышка чыгуына куанып, бер мизгелдә балкып киттеләр, аларның йөзләренә нур кунды.

— Җылы!

— Шундый шәп!

— Әй, һавасы да һавасы, сулап туярлык түгел.

— Аяк асты да корыды.

— Бөтен җирдә — җиләк тә җимеш, шартлаганчы ашадык.

Егетләр, берсен-берсе бүлдереп, көнне мактый, алар сөйләгән саен, Рифкать тә үзен суырып торган куркыныч уйлар баткагыннан чыга бара, ул да алар белән бергә сөенә, аның да җаны талпына башлый. Вагыйз бөтенләй кызып китте, ул пышылдавын онытты, шау-гөр килергә тотынды, аннары кинәт кулын җәеп җибәрде.

— Ә-әй, егетләр, оныттык түгелме соң? Рифкатькә күчтәнәч алып килдек бит без. Кая әле, Илдус.

Илдус урындыктагы төргәкне сүтеп җибәрде.

— Бу шәфталуларны ашасаң, терелмәс җиреңнән терелерсең,— дип тезеп китте Вагыйз.— И-һи, безнең якта инде ул шәфталу — телеңне йотарлык. Менә өйгә генә кайтыйм...

— Кайтырсың да безне онытырсың әле,— дип, юри генә үпкәләгәнгә салынып, Тансык аның сүзен бүлде.

— Минме онытам, минме!

Шулчак Юра да сүзгә кушылырга булды:

— Әйдәгез, егетләр, хәзер үк килешеп куябыз,— диде ул.— Армиядән кайтып, бер ел узгач, отпусканы бергә туры китереп алабыз һәм кайда да булса очрашабыз. Мәсәлән, беренче елны бөтенегез дә миңа кунакка килегез, Ярославльгә. Мин сезгә шәһәрне күрсәтермен, безнең шә-

һәр бик борынгы ул, һәр йорты музей кебек, хәзерге шырпы каплары түгел. Ә безнең кызларны күрсәң, кызларны...

— Кызлар кайда да бар ул,— дип, исе китмичәрәк кенә сүзне ялгап алып китте Илдус. «Шырпы кабы» дигәнгә бераз күркәсе кабарды бугай аның.— Безнең Түбән Каманы яшьләр шәһәре дип йөртәләр. Менә безгә килеп карагыз әле! Урамнары болын шикелле — үзе киң, үзе ямь-яшел, кырыенда гына — Кама, Кама буенда исәпсез-сансыз күлләр, нарат урманнары, химкомбинат белән ике арада — оҗмах бакчалары төсле алма бакчалары...

— Һи! Рәхәтләнеп атта чабарлык даласы да булмагач, нинди җир ди ул? — Тансык, атта чапкан сыман итеп, ике кулын җәйде.— Чабасың-чабасың, ә даланың очы да, кырые да күренми. Аннары озын итеп сузып җырлап җибәрәсең.— Ул, онытылып, җырлый да башлаган иде, ләкин барысының да уңайсызланып, аңа карап торуын күреп, кисәк туктап калды.

— Җыр-ла... җыр-ла...— диде аңа, өзеп-өзеп, Рифкать.

— Юк... гафу итегез, мин... онытылып киткәнмен. Сагындырган... шуңадыр.

— Җырла, Тансык, әкрен генә җырла, беркем дә ишетмәс.

— Ялындырма инде!

Ләкин Тансыкның күңеле утырган иде инде.

— Алайса, әйдә, үзебезнең җырны җырлыйбыз! — дип, Илдус Рифкатьнең баш очына ук килеп басты. Рифкать, «әйдә» дигәнне аңлатып, күз кабакларын селкетте.

Утларга да бер керербез әле,
Без менәрбез әле күкләргә.
Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

Илдус, Рифкатьнең җырга кушылмавын, дөресрәге, кушыла алмавын күреп, ничек башласа, шулай капыл туктады да: «И-и-их!» — дип сузып куйды.

— И-их, кайткач...

Барысы да, әллә инде туган якларына кайткач нәрсә эшлиселәрен уйлап, әллә җыр моңыннан тәэсирләнеп, тын калдылар. Кичке кояш нурлары идән буйлап шуышып килделәр-килделәр дә кыяр-кыймас кына Рифкать

янына, караватка үрмәләделәр. Алсу яктылыктан күзләр чагылды, палата сихри төскә керде, егетләрнең йөзенә ут капкандай булды. Алар, күзләренә кояш нуры төшмәсен дип, кулларын каш өстенә кыйгачлап куйдылар. Вакыт үткән саен, тынлык көчәя барды. Рифкатьнең якты, ләкин салкын кояш нурларына да исе китмәс булды. Ул егетләрнең болай сүзсез торуына борчыла, моңа үзен гаепле саный, әгәр дә шулай ятмаса, сүзләрнең дә, уен-көлкенең дә башкача буласын, башка төсмер аласын сизенә һәм, иң кыены, алар аннан нәрсәдер яшерә, әнисе үлгән баланы: «Кунакка гына китте, тиздән кайтыр әниең»,— дип юаталар төсле тоела. Бу хис торган саен көчәя барды, ә инде куллары белән кояштан күзләрен каплагач, моның анык шулай икәненә ышанды, әйтерсең алар дөресен әйтмәгәннәренә, алдаганлыкларына оялып күзләрен яшерәләр иде.

— Минем тәкъдимне оныттыгыз бугай. Кайткач, миңа кунакка киләсез! Чакыру шушы булыр.— Юра сүздән туктады, каш өстендәге кулын төшерде.

— Кайткач, кайткач...— дип кабатлады Вагыйз.— Самолетта очкан саен, тәрәзәгә карыйм, туган як күренмәсме, дим. Зуррак су күзгә чалынса, Каспий диңгезе дип уйлап, йөрәк дөп-дөп тибә башлый... Миңа килгәндә самолет белән килегез. Азәрбайҗан илен башта һавадан, өстән карарга кирәк. Югыйсә синең дала шикелле,— ул Тансыкка таба борылды,— такыр басу түгел ул. Таулары ни тора, таулары! Йөзем, карбыз, кавын, анар...

— Нәрсә ул анар? — дип сорады Илдус.

— Анармы? Сезнеңчә ничек соң әле?.. Эче тулы кызыл төш инде, кыссаң, әчкелтем ширбәт сиптерә, тешләрне камаштыра, әй тәмле дә үзе! Сездә ничек диләр соң әле аны? Һи, истән чыккан,— Вагыйз кашларын җыерып куйды, аннары кинәт кенә кычкырып җибәрде: — Гранат! Гранат, диләр! Гранат ашатам мин сезгә!

Шулчак егетләр барысы да сискәнеп киттеләр, аптырау катыш сораулы караш белән Рифкатькә төбәлделәр. Аның йөзенә газаплы елмаю чыккан иде. Вагыйз дә авызы ачык килеш туктап калды.

— Рәх-мәт...— дип пышылдады Рифкать.— ...Мин... а-ша-дым... ин-де...

Бу сүзләрне ул шаяртып әйтергә, шуның белән егетләрнең әңгәмәсенә кушылып китәргә уйлаган иде, ләкин

аның сүзләре аһылдауга охшап чыкты, аларда усал кинаядә, үзенең хәлен искәртергә теләү дә бар иде сыман. Юра Вагыйзнең ялгышын төзәтергә уйлады, ахрысы, сүзне бөтенләй бүтән якка борып җибәрде.

Моңарчы алар, арыслан читлеген урап йөргән балалар кебек, иң төп нәрсә — Рифкатьне бөтен солдатлардан аерып, берничә секунд эчендә әллә кая өскә, югарыга күтәреп куйган вакыйга турында сөйләшүдән курәләтә качарга тырышалар, гүя, шулай итеп, бу турыда бөтенләй онытырга уйлыйлар иде. Ләкин Юраның бүтән түземе калмаган иде.

— Граната шартлар алдыннан, мин синең янәшәңдә үк идем. Барысын да күреп тордым,— диде ул, үзенең гадәти, җырлап чыга торган сузынкы тавышы белән.

Салкын суда бер чирканчык алган шикелле, егетләрнең дә куркулары бетте. Вагыйз карават башына таянды.

— Ә мин күрмәдем, мин алда идем,— диде ул.

— Мин артта калганмын,— монысын Илдус әйтте.

— Граната шартлавын ишеткәч, борылып карасам...

— Мин граната шартлавына да игътибар итмәдем, быргы авазы яңгырагач кына туктадым.

— Быргыны ничек кулга алуымны да, ничек «отбой» уйнавымны да юньләп хәтерләмим.

— Юраның «отбой» уйнавы булды, бөтен солдатлар туктап калды. Бөтенебез дә синең янга йөгердек. Син инде... аңсыз ята идең. Командир белән врач башыңны бәйли. Аннары сине алып киттеләр. Ә без тагын «атакага» күтәрелдек.

Әле генә граната вакыйгасын искә төшерергә дә куркып торган егетләр, урмандагы күккә ашкан зифа агачны екканда кызганып та, өйгә алып кайткач, аңа инде табигать бизәге дип түгел, ә утын итеп караган, хәзер инде аның җылысыннан ләззәт тапкан агай кебек, хәрби өйрәнүләр вакытынданиләр булганын, кичә-бүген частьта Рифкатьнең исеме телдән төшмәвен бер дә тартынмыйча, хәтта иркенләп үк диярлек сөйләргә тотындылар. Шулай итеп алар, үзләре дә сизмәстән, палатага җан керттеләр, матур ялганга охшаган юату сүзләре, томан сыман таралып, тирә-юнь яктырып киткәндәй булды.

## 19

Тәрәзә артындагы сәрви куаклары караңгылык кочагына кереп чумгач, Рифкать үзенең ак палатасын кара төн диңгезе буйлап йөзүче корабльгә охшатты. Диңгездә давыл купкан. Ул, корабын дулкыннарга каршы куеп, зилзилә белән көрәшкән, рубкасыннан чыкмаган. Һәм, ниһаять, диңгез тынычлангач, каютасына кереп егылган. «Каюта...» — дип көлемсерәде Рифкать. Бераз тын торгач: «Саша»,— дип көрсенеп куйды. Ул, беренче тапкыр күргәндәй, палатага күз йөртеп чыкты. Өстә — кайгыдан арына алмаган кеше маңгае төсле җыерчыкланган саргылт түшәм. Каршы як стенада — дүрт кнопка белән беркетелгән олы гына плакат. Анда ике кеше сурәте ясалган. Берсе авызына пычрак алма капкан, үзе дә бик шапшак. Яшькә яшь булса да, бөкресе чыккан, гәүдәгә бетәшкән. Ә икенчесе кран астында җиләк-җимеш юып тора. Анысы — Алып батыр сыман таза, йөзләре алсуланып тора. Плакат астына шигырь белән болай дип язылган:

Яшим дисәң йөз яшьне,
Юып аша җимешне!

Рифкать плакатка озак карап тора алмады, качарга теләгәндәй, күз карашы белән стена буйлап йөгереп китте. Ләкин палатада күз нуры төшәр, күз карашы туктап ял итәрлек урын юк иде. Аптырагач ул, чыгар урын эзләгәндәй, тәрәзәгә таба текәлде һәм анда караңгы төннең чекерәеп торган олы күзләре белән очрашкач, йөзен читкә борды.

Йомшак чүәкләре белән акрын гына атлап врач апа палатага керде. Аның ак халатыннан Рифкатьнең күзләре чагылып киткән төсле булды. Әйтерсең күктәге якты ай аның ялгыз ятуын күргән дә тәгәрәп төшеп палатага килеп кергән.

Врач, төн тынлыгын бүлдерүдән курыккандай, сүзсез генә Рифкатьнең сул кулын сызгандырды, мамык белән ышкыды да шприцка дару суыртты. Бары тик шунда гына, телгә килеп, сүз катты:

— Дусларың киттеме?

Рифкать керфекләрен какты.

— Әниеңә... бергәләп хат язасыгыз калган...

— Хат язасы калган... Калган... Калган...— дип кабатлады ул эчтән.— Калган нәрсәләр күп әле ул. Әтиәнисе белән һич югы бер тапкыр иркенләп сөйләшеп утырасы, күңелендәге бар уйларын ачып саласы калган... Әнфисәгә вәгъдә иткән күлмәген бүләк итәсе, Әлфияне... Галияне кочакка алып бер суырып үбәсе калган... Бабасына печән чабып өясе, авыл малайлары белән туйганчы уйныйсы, танышлар белән ныграк танышасы, дуслар белән ныграк дуслашасы калган... Түбән Кама урамнарын, Зәй, Кама болыннарын, нарат урманнарын, түгәрәк күлләрен күзләре талганчы карыйсы, аларга җылы сүз әйтәсе калган... Калган... Калган!..

Рифкатьнең ирен читләреннән әрнүле елмаю дулкыннары йөгереп узды.

— Хәзер сиңа операция ясаячаклар.

Рифкатьнең чырае үзгәрмәде. Врач, шприцын өскә караткан килеш, бермәл уйланып торды да, кинәт кенә хәрәкәтләнеп, инәне кулга кадады. Ничектер гадәттәгедән авырттырыбрак, хәтта бераз дорфарак та итеп ясады ул бу юлы уколны. «Арыгандыр, мине каравыллап хәлдән калгандыр»,— дип уйлады Рифкать. Шушы авыруы белән күпме кешегә борчу китерде. Әле күпме кешегә китерәчәк... Шунда граната шартлауга ук гомере өзелгән булса...

Ул торган саен гәүдәсенең җиңеләя барганын сизде, башында утлы сөңгеләр әкренләп сүрәнләнде, аннары бөтенләй юкка чыкты: кулларын күтәрергә теләде, ләкин мускуллары аны тыңламады, нәрсәдер кычкырмакчы итте, әмма тавышы чыкмады. Рифкать, соңгы көчен җыеп, тешләрен кысты, ачу белән кулларын йомарлады, һәм шулчак уң кулы беләзектән түбән көйдереп алгандай булды. «Аһ! Граната!» дигән ыңгырашу авазы күкрәктән өзелеп чыкты да һавада асылынып калды. Ләкин ул аваз таралып бетмәде, киресенчә, һаман үсә, зурая барды, менә ул болытка әйләнде дә бәреп-бәреп биткә салкын яңгыр яварга тотынды, менә ул өермә булып бөтерелде, һәм Рифкать, шул өермәгә ияреп, күккә күтәрелеп китте.

Гәүдәсе мамык кебек җиңел, бары тик башы гына авыраеп аска таба сөйри. Җиргә егылып төшмәс өчен, ул сул кулы белән ашыга-ашыга ишә. Ә уң кулын кыймшатмый. Уң кулда — граната. Ул дүрт секундтан шартлаячак. Күз кабакларын күтәреп торыр хәл дә юк, үлеп йо-

кы килә. Яшел түшәк төсле дала өстенә төшәсе дә изрәп йокыга китәсе килә!

Ярамый!

Дүрт секунд!

Юк, өч, ике секунд кына калгандыр. Аста, тузгытылган кырмыска күчедәй, солдатлар йөгерешә. Әгәр хәзер граната шартласа, алар барысы да һәлак булачак. Рифкать сул кулы белән һаман-һаман ярсып иште. Полигон да күздән югалды. Югары күтәрелгән саен, җир дә шар кыяфәтенә керә барды һәм берзаман бөтенләй олы карбызга охшап калды. Әнә тегендә, аксыл зәңгәр җеп сыман гына булып күренгән елга буенда, аның туган шәһәре Түбән Кама булырга тиеш, ә монысы — Кара диңгез, Саша диңгезе, монысы — төтен бөркеп торганы — Казан, ә теге тракторчы абыйның авыллары бармак башы хәтле генә... Ә... граната?! Граната шартлаячак! Әгәр ул аны кулларынан ычкындырса, әтисе дә, әнисе дә, Әнфисә белән Азат та, дуслары, бөтен туганнары да шартлаячак, юкка чыгачак. Аста — җирдә чакта ул әле боларны күреп, аңлап бетермәгән. Аның гранатасы шартласа, бөтен Җир шары чәлпәрәмә киләчәк бит! Ул күз иярмәс тизлек белән өскә үрелде, менгән саен сулыш алу да җиңеләйде, гәүдәсе дә, башы да сизелмәс булды. Хәзер инде кулны селкетәсе дә юк, ул, граната тоткан уң кулын алга сузган килеш, талпына-талпына күккә оча, җирдән һаман саен ныграк ераклаша бара иде.

## 20

— Операция бүлмәсенә кертегез! — дип дәште кемдер.

Аны ипләп кенә тәгәрмәчле өстәл өстенә салдылар да палатадан алып чыгып киттеләр.

## 21

Тау артыннан иң элек кояшның кызыл түбәтәе күренде, аннары ул әкрен генә, сакланып кына күтәреләә башлады. Кояш әле йокысыннан айнып җитмәгән, аның йөзе әле караңгы кызыл төстә иде.

Ул, түшәгеннән аерылып китә алмыйча, беркавым әсәренеп карап торды да авырлык белән генә кузгалды, күзләрен ачты һәм, иң беренче эш итеп, үзенең биләмәләрен барларга, бер төн эчендә анда нинди үзгәрешләр булганын тикшерергә тотынды. Кояш нурлары дала кылганнарын сыйпап узды, өй кыеклары буйлап йөгерде, полигон читендә тезелешеп торган самолетларны санап чыкты, казармалар түбәсеннән атлап үтте һәм палата тәрәзәсе төбендә туктап калды. Сәрви куакларының шомлы кыштырдавына бераз колак салып торгач, ул тәрәзәдән эчкә таба үрмәләде, идәнгә шуышып төште, әкрен генә караватка якынлашты. Кояшның йөзе агарганнан-агара бара иде. Менә ул, караватка менәргә куркып, кырыйдагы тумбочка өстенә күтәрелде, кайнарланган нурларын суытырга теләгәндәй, стакан эчендәге суга төште һәм, анда да үзенә урын таба алмыйча, кинәт түшәмгә сикерде дә тавышсыз гына ярсып-ярсып биергә тотынды. Ләкин бу хәл озакка бармады, кояш, аңына килеп, ашыга-ашыга карават буйлап шуышты, анда Рифкатьне күргәч, бер мизгелгә тынычланды да, тагын сикереп, кулларын сыйпады, ачык яткан йөзен сыйпады, җылытырга теләгәндәй, кабалана-кабалана сыйпады. Ләкин Рифкатьнең күзләре ачылмады, кулларына, йөзенә җылы кунмады.

Кояш аптыраудан, сәерсенүдән һушсыз калып торды-торды да, үлгән баласын күреп акылдан шашкан ана төсле, шаркылдап көлеп җибәрде. Аның көлү авазы, баш өстендәге тургайлар сайравына әйләнеп, көчәйгәннән-көчәя барды. Җир өстендә якты көн тууын күреп, бар дөнья сөенде, ләкин кояшның күзләренә текәлеп караучы булмады. Кояш бүген сөенми, ә тилмереп, газапланып көлә иде.

*1978–1979*

# ЭЧТӘЛЕК


Мирас (роман) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

Повестьлар

Эт кояшы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
Иске сәгать дөрес йөри . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 323
Яшисе килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 433

Литературно-художественное издание

**Валеев** Разиль Исмагилович
(**Валеев** Разиль)

ПРОИЗВЕДЕНИЯ
В ЧЕТЫРЕХ ТОМАХ

**Том 2**

Казань. Татарское книжное издательство. 2006
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Вәлиев** Разил Исмәгыйль улы
(**Вәлиев** Разил)

ӘСӘРЛӘР
ДҮРТ ТОМДА

**2 том**

Мөхәррире *Р.Ә.Зәһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.10.2006. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 26,88 + вкл. 0,84 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 28,77.
Нәшер-хисап табагы 27,48 + вкл. 0,88 + форз.0,36. Тиражы 3000 д. Заказ З-922.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.